
ISSN 0206—4189

# Казан утлары

2.2002



# «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ




1930 елга кадәр журнал "Безнең юл" исеме белән чыга. Аның дәвамы **"Атака"** (Татарстан Пролетариат Язучылары Ассоциациясе— ТАПП органы) һәм **"Яңалиф"** (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасының журналы).

1930 елның июль аенда "Атака" журналының (редакторы **Г. Гали**) беренче саны дөнья күрә. Ул айга ике мәртәбә чыга торган әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы булып тәкъдим ителә. ТАПП идарәсе һәм "Атака" журналы редколлегиясе укучыларга мөрәҗәгать итеп, болай яза: "..."Атака"ның төп бурычы партиянең матур әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә тоткан сәясәтен тормышка үткәрү өчен, пролетариат әдәбиятының гегемониясе өчен көрәшкә кайтып кала"

ТАПП журналы буларак, беренче чиратта, "Атака" эшче яшьләргә, завод-фабрикадагы хәбәрчеләргә исәп тота, аларны актив иҗади эшкә чакыра һәм шул чор идеологиясен чагылдырган язмалар бастыруга әһәмият бирә. Бу эштә язучылар да бик актив катнаша. Алар арасында Ш. Камал, Ф. Хөсни, А. Алиш, И. Туктарның илебездәге социализм индустриясе төзелешләренә, Г. Иделле, М. Гали, Н. Баянның колхоз-совхоз эшчәннәренә багышланган очерклары бар. "Атака" журналы битләрендә хикәяләре һәм шигырьләре белән Галимҗан Мөхәммәтшин, Г. Хужи, М. Садри, Х. Мөҗәй, М. Сөндекле кебек яшьләр танылалар.

Журнал латин имласында 1932 елның ахырына кадәр 1500-1600 данә тираж белән чыга.

Казан утлары
Qazan utları

2002

2
(952)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## *Бу санда*

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Марат КӘБИРОВ. Сары йортлар сере. *Повесть* ..... 5
Мөдәррис ӘГЪЛӘМ. Ходай бирде безгә ярлыкны. *Шигырьләр* ..... 27
Суфиян ПОВАРИСОВ. Оҗмахка бер адым. *Роман* ..... 32
Рәфикъ ЮНЫС. Габделвәли бабама. *Шигырьләр* ..... 71
Марат КӘРИМОВ. Китәсе килми. *Шигырьләр* ..... 74
Марс ШАБАЕВ. Сөенә дә, көенә дә күңел. *(Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның тууына 60 ел)* ..... 105
Кадыйр СИБГАТ. Бурыч. *(Басылмаган шигырьләреннән)* ..... 109

### ТАРИХ

Солтан ШӘМСИ. Низаглы йортта ..... 77

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Яңа гасыр, иске проблемалар. *(«Казан утлары» журналы редколлегиясенең киңәйтелгән утырышыннан)* ..... 113
Тәлгать ГАЛИУЛЛИН. Җанында халык гаме *(Әхмәт Гаделгә 60 яшь)* ..... 129

### ПУБЛИЦИСТИКА

Мәхмүт ӘХМӘТҖАН. Сәяси уйланулар ..... 122
Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Чынлык көче *(Рәфкать Кәрамигә 60 яшь)* ..... 136

### КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

20—Та-ha (Та-ha) сүрәсе ..... 140
21—Әнбия (Пәйгамбәрләр) сүрәсе ..... 146

### СӘНГАТЬ

Мидхәт МИНШИН. Язмышны булмый алдап *(Галим-педагог һәм музыкант Рәгъде Халитовка 60 яшь)* ..... 152
Шамил МОНАСЫЙПОВ. Бакый Урманче шәмаилләре ..... 161

### ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Таһир ГЫЙЛӘҖЕВ. Габделбари Баттал—тәнкыйтьче ..... 173

### БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Атылган йолдыз кебек *(Тәбриз Мөбәрәковның тууына 70 ел)* ..... 181
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

### ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Розалина ШАҺИЕВА. Казан тәхете ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть М. КАБИРОВА «Тайна желтых домов», роман С. ПОВАРИСОВА «Один шаг к раю», стихи М. АГЛЯМОВА, Р. ЮНЫСА, М. КАРИМОВА, К. СИБГАТА *(предисловие М. Шабаева)*.
«История»: С. ШАМСИ «В скандальном доме» *(страницы истории Золотой Орды)*.
«Литературная критика»: «Новый век, старые проблемы» *(Отчет с расширенного заседания редколлегии журнала)*.
«Публицистика»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Размышления на политические темы».
Коран на татарском языке.
«Искусство»: Ш. МОНАСЫПОВ «Шамаилы Б. Урманче».
«История литературы»: статья Т. Гилязова «Г. Баттал, как литературный критик».
В номере отмечаются юбилеи писателей А. Гаделя, Р. Карами и музыканта Р. Халитова.
Наш календарь.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Казанский трон», поэт С. Мулла-Гали.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": M. KABIROV'S narrative «The mystery of yellow houses»; S. POVARISOV'S novel «One step to paradiset»; the verses of M. AGLIAMOV, R. UNUS, M. KARIMOV, K. SIBGAT (M. SHABAEV'S preface).
"History": S. SHAMSI "In scandalous house" (the history pages of Gold Orda).
"Literary criticism": "New century, old problems" (the report from widen meeting of editorial board).
"Journalism": M. AKHMETZIANOV'S article "Reflections by political themes"
"Koran in Tatar language".
"Art": SH. MONASIPOV "Shamails of B. Urmanche".
"History of literature": T. GILIAZOV'S article "G. Battal as literary critic."
Our jubilees: A. Gadel, R. Karami and musician R. Khalitov.
Our calendar:
The diary of social and cultural life.
In our covers: "The Kazan throne", poet S. Mulla-Gali.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.01.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8765 Заказ Б-43
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.

**Марат Кәбиров**

# САРЫ ЙОРТЛАР СЕРЕ

ПОВЕСТЬ

## I

Бу сары йортның алтынчы подъездыннан, кешеләрнең тынычлыгын алып, тормыш рәвешен үзгәртергә, шом, курку һәм үкенүләр эчендә яшәргә мәҗбүр иткән серле подъездыннан, элегрәк тә этләр өргәне ишетелә иде. Ләкин соңгы арада этләрнең тавышы көннән-көн көчәя барып, болай да котлары алынган халыкны һуштан яздырырлык дәрәҗәгә житте, кешеләр төннәр буе керфек какмадылар, тамакларына ризык үтмәде, куллары эшкә бармады, үзләрен вокзалдагы кебек хис иттеләр, үткән гомерләрен тагы бер кат энә күзеннән үткәреп, эчке бер тетрәнү белән нинди дә фажига, кыямәт көне белән чагыштырырлык афәт көттеләр. Кайчагында этләр өрмидер, этләр шушы кадәр үк булдыра алмыйдыр, ә бу тавыш аларның колагына гына ишетеләдер сыман тоелды. Этләр өрүе аларның җанын талады, берчә чыдап булмаслык дәрәҗәдә көчәеп, берчә азга гына тынып калып (ә бу тынлык, бу коточкыч тынлык, бу бөтен күзәнәкләреңне чатнатып ярырлык тынлык, иң ачы тавыштан да газаплырак иде), берчә сабый бала елавыдай әрнетеп үзәкләргә үтте. Сары йортларда яшәүчеләрнең кайберләре акылыннан шашып башларын таш стенага бәрде, кайберләре тәрәзәдән сикереп җан бирәлми газапланды, гүя алар өчен үлем дә, яшәү дә берни түгел, бары шушы тавыштан котылу мөһимрәк иде. Әлеге газапка башкача чыдарлыгы калмаган кешеләр кайда киткәнлекләрен хәтта гаиләләренә дә әйтеп тормастан, берәм-сәрәм алтынчы подъездга керделәр. Көтмәгәндә әллә кайдан килеп чыккан карчыкның һәртөрле могжизаларга ия булып, үзләренә бетмәс-төкәнмәс зыяннар китерергә сәләтле икәнен белсәләр дә, йөрәкләре табан астына

---

Марат КӘБИРОВ *(1970)—шагыйрь, прозаик. «Онытма таңнарыңны», «Серләшик әле», «Күңелле табын» исемле шигырь китаплары авторы. Уфада яши.*

төшсә дә, алар башкача булдыра алмады; әлеге җәһәннәмнен серен белү, котылу юлын эзләү теләге күпкә, бик күпкә көчлерәк иде. Ләкин алар сары йортларда яшәүчеләр өчен бер файда да китерә алмадылар, карчыкнын фатирына ачкыч ясатып керү белән, фатир аша үтәли искән жил, ишекне шапылдатып япты да үзе бикләнмәле инглиз йозагы аны келәләп тә куйды, әмма керүче моңа игътибар итмәде, фатир идәнендә тәгәрәп яткан сөякләр, кеше башларын күреп, аның коты алынды, ул бермәлгә һушын югалтты һәм ач этләрнең мизгел эчендә ничек үзен ботарлап ташлавын да сизмәде. Кешеләр еш керә башлагач, этләрнең тавышы тына төште һәм сары йортларда яшәүчеләр азга гына булса да авыр газаптан котылды. Тик хатыннарны ничектер юкка чыккан ирләренең һаман кайтмавы гына борчыды, аларнын алтынчы подъездга юнәлүен күрүчеләр табылды... Өч-дүрт көннән этләрнең өрүе тагын көчәя башлады, ул инде чыдый алмаслык дәрәжәгә житеп елый-елый улауга әверелде. Чыдаунын чигенә чыккан кешеләр жыйнаулашып серле фатирга юнәлде, әмма көтмәгәндә каршыларына килеп чыккан гүзәл кызны күреп, туктап калдылар.

*Бу гади кыз түгел иде, бу чибәр кыз кыяфәтенә кергән сихерче карчык иде. Теге дәһшәтле көндә күккә ашканчы әле, карчык берчә әлеге гүзәл, берчә эт, берчә сабый кыяфәтенә кереп йөри иде.*

*Шуннан соң да теге кызны күргәч, без катып калдык, ә ул бер генә сәер караш ташлады да атылып подъездына кереп китте һәм бераздан этләрнең тавышы икеләтә көчәйде. Алар безнең колак төбендә өргән, юк өргән генә түгел, җилкәләребезгә басып башыбызны кимергән сыман тоелды, без, ломнар, балталар, мылтыклар тоткан ир-егетләр, баскан җиребездә тамыр җәйгәндәй, урыннарыбыздан кузгалыр көч тапмадык, тәннәребезне калтырау алды, хәтта үзебезнең ни өчен шулай коралланып җыйналуыбызны да оныткан идек. Кинәт котырынып өргән тавышлар тынып калды һәм без әкренләп һушыбызны җыйдык, ләкин беребез дә бер хәрәкәт тә ясамады, дөресрәге, аңыбызга кайтсак та, без әле мускулларны тоярлык хәлдә түгел идек. Ә инде ни өчен җыйналуыбызны аңлап, карашларыбызны подъездга юнәлткәндә, кинәт ишек ачылып китте... Аннан ике эт килеп чыкты һәм, алар, без нәрсәдер уйлап өлгергәнче, агачлар арасына кереп югалдылар. Юк, туган, мин ул этләрнең нинди нәселдән икәнен белмим, алар дә-ә-ү гәүдәле, борыннары чучканыкынарак охшап тора иде, ә күзләре ни өчендер миңа кызыл сыман тоелды. Без ни уйларга, ни кылырга да белми торган арада бер иптәшебез алга чыкты да: «Әйдәгез, кереп карыйк! Астын-өскә китерик! Күпме шулай түзәргә була?»—дип кычкырды һәм без, атакага ташланган солдатлар сыман, алга омтылдык. Бездә еллар буена җыела килгән нәфрәт көчле иде. Карчык яшәгән фатир ишеге төбенә җиткәч, кинәт туктап калдык; баскыч мәйданчыгы куе кызыл канга баткан, ә тирә-якта адәм сөякләре аунап ята. Коточкыч күренеш иде бу, туган, акылдан язарлык күренеш иде. Тик монысы баласы гына булган икән әле... Карчыкның фатирына узгач, безне мәхшәр каршы алды: идәннәрне катып беткән кан каплаган. Әле анда, әле монда кеше башлары, кабыргалар, аяк-куллар чәчелеп ята; өстәл-урындыклар ауган, ватык савыт-саба пыялалары белән дөнья тулган; алар арасында без югалган күршеләребезнең сәгатьләрен, ертык кием кисәкләрен, йөзекләрен таптык. Кайсысы кемнең сөяге икәнен генә аера алмадык. Хәтта баш сөякләрендә дә бер генә бөртек ит кисәге дә калмаган иде. Ә явыз карчык үзе күренмәде, без беренче катның башка фатирларын да караштырып чыктык, тик аны тапмадык, күрәсең, эт кыяфәтенә кереп чыгып шылгандыр... Шулай, туган, карчыкның өенә керү безгә тынычлык өстәмәде: колакларыбызда чыңлаган эт тавышлары икеләтә көчәйде, аңа эт корбаны булган күршеләребезнең җан өзеп кычкырулары өстәлде, аларның идән буйлап сибелгән сөякләре күз алдыбыздан китмәде; төшләребездә безне әле эт талады, әле шул сөякләр бугазларыбыздан буып алды, без атналар буе табынга якын килә алмадык, өстәлдәге ризыклар кеше ите булып күренде, су эчсәк тә кан эчкәндәй булдык. Тора-бара тәмам хәлдән таеп гәүдәләребезне дә күтәрә алмас хәлгә җиттек, өн белән төшләр буталды, үзебезнең теге дөньядамы,*

*монысындамы яшәгәнебезне оныттык, без кояш нурларын да, төннәр карасын да күрмәдек, күз алдыбызны соры томан басты. Бу мәхшәрдән котылырга теләдек, тик ничек икәнен генә белмәдек, теге этләрнең кабат кайтуын, безнең дә җаннарыбызны алуын көттек, тик алар башкача күренмәде. Коточкыч вакытлар иде ул, туган, коточкыч дәвер иде...*

Шәһәр читендәге бистәнең ике катлы сары йорты якындагы «П» хәрефенә охшаш сары йортлардан бер нәрсәсе белән дә аерылмый иде. Анда да фәләнешәр дистә елын завод-фабрикаларда эшләп фатир алган гади кешеләр, үз кыекларны булуга куанып, аз гына хезмәт хакына ачлы-туклы гомер кичерә иде. Үз тормышларына зарланмыйлар да, байларга карап көнләшмиләр дә, «ач тамагым—тыныч колагым»,—дигәндәй, юктан канәгатьлек табып, үз күнелләрен үзләре күтәреп яши бирәләр, подъездлар алдындагы эскәмиягә утырып гәп сугалар, үзләре күргән-белгәнне сөйлиләр. «Башларыннан үткән» хәл-вакыйгаларның күбесе шыр ялган һәм дөньяда мәнге булмастай шәп-шәрә хыяллардан гына торса да, аларның дөреслеген беркем дә шик астына алмый, чын күнеленнән ышана, кызык урында шаркылдап көлә, кызганыч урында күз яшьләрен сөртеп ала, яки күзен читкә бора.

**Бер-берсенә охшаган ике катлы сары йортларда бер-берсенә охшаш беркатлы кешеләр яши иде. Хәтта ишегалдында һәр гаиләнең үз агачы, һәр агачның үз исеме бар һәм кешеләр аларга үз балаларына карагандай карый, иркә сүзләр белән эндәшә, кәүсәләреннән сөеп иркәли иде.**

Гомере буе сәламәтлеккә зарарлы химикатлар тирәсендә тир түккәнлектән, бу кешеләрнең барысы да үз яшьләреннән күпкә өлкәнрәк, кырыктагылар—алтмыш, илледәгеләр—житмеш яшьтә булып күренә, ә инде нинди дер могжиза белән житмешкә житүче кеше булса, ана жиде гасыр гомер иткән карт төсе керә. Аның акылы күптән жуелып килделе-киттеле сүзләр сөйләсә дә, аның һәр тәгъбирен изге сүз урынына күрәләр, ана тирән мәгънә салып, урынлы-урынсызга да кабатлыйлар иде. Болар барсы да Бөек Ватан сугышына калдәр туып, булыр-булмас белем белән авылларыннан бәхет эзләп чыгып киткән, барысы да бер дәвердә зарарлы урыннарга эшкә кергән, барысы да бер вакытта фатир алган кешеләр иде. Алар туган-үскән жирләре белән күптән араларын өзгәннәр, хәзер үзләренең нинди милләткә, нинди дингә караганнарын да онытканнар иде. «Кеше дөньяга ни өчен килә?» дигән сорау бирсәләр, алардан һичшиксез: «Завод-фабрикаларда эшләп, менә шушындый сары йортларда яшәр өчен»,—дигән жавап ишетелер төсле иде. Кайберләренең, заводка эшкә килгәнче гаилә корып өлгергәннәренең, берәр баласы бар, ләкин ул балалар инде әти-әниләре белән яшәми, башлы-күзле булып үз дөньяларын көтәләр һәм шәһәр читендәге сары йортларны күптән онытканнар иде. Калганнарының баласы-фәләне юк, хатын-кызлары да, ир-егетләре дә үзләренең ата-ана булу мөмкинлеген аларга яшәр урын һәм ашар ризык биргән сөекле заводларында калдырган һәм алар моның өчен тамчы да үкенми, сабый дип авыз суын корытмый, бала үстерүне мал симертеп хөкүмәткә тапшыру сыман гадәти бер эш итеп күрәдер төсле иде. Менә шулай бер төрле шартларда бертөрле тормыш белән гомер итүче бер төрле кешеләрне сөекле заводлары көннәрдән бер көнне пенсиягә озатты һәм  эш атына, ишәккә әйләнгән адәм балалары, үз язмышларына риза булып, вакыт агымының үзләрен әҗәл куенына илтеп житкерүен тавыш-тынсыз гына көтеп, уртак һәм тагы да бертөрлерәк тормыш белән гомер үткәрә башладылар.

Менә шушы сары йортларның иң читтә урнашканының алтынчы, иң кырыйдагы подъезды гына башкаларына охшамаган иде. Монда килеп керү белән мәче бәвеле исе күзне томаламый, ватык тәрәзәләрдән кергән жил ишекне каерып ачмый, шакылдатып япмый, монда нинди дер хуш исле үләннәр исе аңкый, чисталыктан ялтырап торган тәрәзәләрдән көндезләрен якты нур тарала. Аның каравы, кичләрен керсән, күзгә төртсәң күренмәслек караңгылык хөкем сөрә, чөнки бу подъезда бер

генә лампочка да янмый, яңаны куйсаң да шундук шартлый яки кызып эштән чыга һәм караңгылыктан котылуны мөмкин булмаган хәлгә әйләндерә иде. Бу подъездның тагы бер үзенчәлеге шунда: җәйләрен монда чебеннәр мыжгып тормый, дымсурак җирдә урнашып, тирә-якта агачлар күп булса да, черкиләр җәфаламый, бөтен шәһәрнең хуҗасы булып алган тараканнар әлеге подъезддагы фатирларга якын да килми, вак соры кырмыскалар җанга тими, гомумән, монда бернинди зарарлы бөҗәк тә керергә җөрьәт итми, әгәр берәр адашкан чебен форточкаданмы, подъезд ишегеннәнме эчкә үтсә, ул берничә минуттан ук үлеп идәнгә килеп төшә, ә кире урамга ыргытсаң—терелеп очып китә иде. Пенсиягә чыккан эш атлары ишек алларын һәрчак тәртиптә тотса да, ялгыз карчык кына яшәгән бу подъезд алды һәрчак пычрак килеш кала, алар монда якын килергә курка, шулай да эскәмиядә утырып гәпләшүчеләрнең күбесе үзләренең әлеге подъездга төннәрен кереп караулары хакында сөйли, анда җен-пәриләр, ут шарлары, тагы әллә нәрсәләр күрүләре, карчыкның фатирыннан ыңгырашу авазлары, колакка ятышсыз чинау тавышлары, эт өргәне, сыер мөгрәгәне, бүре улаганы ишетелүе хакында озак-озак тәфсилләп бәян итәләр. Боларны сөйләгәндә аларның иреннәре калтыранып куя, маңгайларына тир бәреп чыга, күзләре зур ачыла, йөзләре агарынып китә һәм бу, һичшиксез, тыңлаучыларның йөрәгенә шом сала, алар, бер-бер нәрсә килеп чыкмагае дигәндәй, алтынчы подъезд ягына әледән-әле караштырып алалар иде.

Әлеге подъездның бер бүлмәле фатирында яшәүче карчык үзе дә күңелгә шом салырлык, аның күзләре зәңгәр һәм нигәдер песинеке түгел, ә әкияттәге кара кешенеке кебек, аларга туры карасаң, үзеңнениндидер күренмәс җәтмәгә эләккәндәй хис итәсең; битләрен җыерчыклар басып бетерсә дә, карчыкның озын чәчләре чем-кара һәм ул аларны иңнәренә таратып йөри. Борыны карчыга томшыгыдай кәкре, ә юка иреңле авызы кечкенә булганлыктан, ул мәче башлы ябалакны хәтерләтә, тавышы да төнге кара урманда кисәк ишетелгән көчле кычкыру сыман тоела, андагы металл чыңы, бәрелешкән машиналар шыңгырдавы һәм тагы әллә нәрсәләр бала йоннарын кабартырга мәҗбүр итә иде. Бу йортка ул моннан биш ел чамасы элек килде. Өстендә—кәлүш йөзенә төшеп торган бәбәй итәкле кара күлмәк иде. Беренче күргәндә ничек булса, биш ел үткәннән соң да шулай калды, картаймады да, яшәрмәде дә, кыяфәтен дә, киемен дә үзгәртмәде, хәтта кыш көннәрендә дә, яланбаш, өстендә шул кара күлмәк, аягында кәлүш булды, һәм еллар үтүгә болар аның киеме түгел, ә организмының аерылгысыз бер өлешедер сыман тоела башлады.

...Тәүге күренүендә ул ишегалдында гәпләшеп утыручылар янында тукталды, исәнлек-саулык сорашты да, аларның җавап бирмичә, каян килгән бу әкәмәт дигәндәй, кызыксынулы карашларына да, гомумән, бер нәрсәгә дә игътибар бирмичә, ярты сәгатьләп утырды, һәр кешене бер-бер артлы бик җентекләп, йөзендәге кечкенә җыерчыктан алып аяк киеменең читеннән ашала башлаган табанына кадәр өйрәнеп чыкты. Аннан соң аларның коммунизм көтеп, киләчәк рәхәтлекләр турында хыяллануын тыңлап авызын кыйшайтып алды да торып басты һәм: «Син! Син!»,—дип, унлап кешегә төртеп күрсәтте. Ул күрсәткәннәрнең барысы да әлеге алтынчы подъездда яшиләр иде. Аның сәерлегенә аптырап авызларын ачып калган кешеләргә исе дә китмичә ул: «Сезнең өчен коммунизм өч көннән соң киләчәк», дип әйтеп салды. Тиздән рәхәтлеккә чыгачак күршеләренә соклану авазлары яудырган бу беркатлы кешеләр аның кай арада кая китеп баруын да сизми калдылар, әбигә тагын берничә сорау бирергә дип авызларын ачкач кына аның араларында юклыгын белделәр. Ә өч көннән соң алтынчы подъездда яшәүчеләрнең барысы да бер-бер артлы теге дөньяга китте. Аларның менә шулай кисәк кенә кырылуына сары йорттагылардан башка беркем дә аптырамады, җирләүләр бюросында гына гаҗәпкә калучылар хәтсез булды. Юк,

үлемнәренә түгел, ә тереләр исемлегеннән күптән төшеп калган бу бәндәләрнең әле һаман да исән, дөресрәге, әлеге вакытка кадәр яшәп ятулары аптыратты һәм алар тел шартлатып иннәрен генә сикертте: «Гафу итегез, мәрхүм булулары турында белешмә бирә алмыйбыз, чөнки яшәүләре турында документлары юк». Аларны җирләүгә өч көн үткәннән соң коммунистлар партиясенең үзен җирләделәр. Сары йортларда яшәүчеләр баштарак алтынчы подъезддагы күршеләренә «Коммунизмны үзләре белән алып киттеләр, безгә аз гына да калдырмадылар,—дип рәнҗесәләр дә, соңыннан үзләренең дә тиздән теге дөньяга күчәчәген уйлап, аларның каннары суынды, күңелләре тынычланды. Ләкин теге сәер карчык хакындагы уй җаннарына һич кенә дә тынгы бирмәде, ул янадан яннарына килеп, серле ишарә ясар һәм тагы үлем-китемнәр, һәртөрле сырхаулар башланыр төсле тоелды. Ишек алларына чыгып утыручыларның телендә гел шул булды, алар әлеге хәлнең серенә төшенергә, нәрсәнедер ачыкларга тырыштылар, тик миләрендә эш һәм җан асрау турында уйлый торган ике генә сыр калганлыктан, бер фикергә дә килә алмыйча, күңелләрен кара шом басты... Карчык озак көттермәде, ишек алдындагылар янында тагын пәйда булды. Аның кай арада, ничек килүен сизмәсәләр дә котылгысыз карашын һәркем тойды, җанын курку басты, тик беркем дә кузгалып китә алмады. Карчык, әйтерсең, утырган урыныннан шул карашы белән барысын да бергә бәйләп куйган иде. Алар хәтта сөйләгән сүзләреннән дә туктый алмадылар, берсе тынса, икенчесе үз ихтыярыннан тыш, әңгәмәне дәвам итте, ана өченчесе кушылды. Карчык берни әйтмәстән алтынчы подъездга кереп киткәч тә урыннарыннан кузгалмадылар, аның кире урап чыгуын көттеләр. Озак торса да ул чыкканчы беркем авыз ачып бер сүз эндәшә алмады.

Карчык яннарына кабат килгәч кенә әңгәмәләрен дәвам иттеләр, ә тегесе аларны тыңлап күзәтеп утырды һәм кинәт үзенчәлекле тавышы белән барысын да тынып калырга мәҗбүр итеп: «Мин әнә теге бер бүлмәле фатирда яшәячәкмен»,—дип куйды. Ана каршы бәрәү дә бер сүз дә әйтмәде, күңелләреннән генә аның үлемен, башкача монда күренмәвен теләүчеләр дә: «Рәхим итегез, без бик шат. Бик шат!»—дип баш какты. Карчык исә аларның яшерен уен сизгәндәй астыртын елмайды һәм тавыш-тынсыз гына утыручыларны өйрәнүен дәвам итте. Аннан соң эскәмиянең ике башында утырган ирле-хатынлы икәүгә күрсәтеп: «Син! Син!!!,—диде,—Мин иртәгә күчеп киләм, яныма керергә онытмагыз!» Һәм китеп тә барды. Тавышы металл чыңын хәтерләтсә дә, адымнары өрәкнекедәй җиңел, ул, әйтерсең, атламый, ә йөзеп кенә бара иде.

Икенче көнне карчык, чынлап та, күченеп килде. Аның бөтен мөлкәте берничә капчык һәм һәртөрле пыяла савытлар тутырылган бер зур гына кап булып, ул аларны кечкенә куларбага төягән иде. Сары йорттагылар аның эскәмиягә чыгып утыруын шомланып көтсә дә, карчык никтер күренмәде. Ә теге икәү, карт белән кортка, бу сәер кешенең сүзләре җаннарына тынгы бирмәсә дә, күршеләре «Барыгыз, кереп күренегез, юкса, зыян салуы бар», дип йөдәтсә дә, үзләре дә моның белән килешсә дә карчык янына керергә йөрәкләре җитмәде. Аның җаныңның астын өскә китерә торган карашыннан, күңеленне игәгәндәй тоелган тавышыннан курыктылар. Бәлки, үзе тагын чыгар да ни өчен керергә кушуы турында әйтер, ә, бәлки, бу хакта бөтенләй онытыр да бер зыян да салмас, дип көттеләр. Карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә күренмәде, шулай итеп атна үтте, ун көн... Электән үк битләрен кара-сакал баскан карт белән кортка көннән-көнгә кибеп, саргая барды, күз төпләренә яшелле-сарылы дүңгәләкләр чыкты, хәлләре бетә башлады һәм тиздән бөтенләй күренмәс булдылар. Аптырап ишек ватып өйләренә кергән күршеләре аларны идәндә бөгәрләнеп яткан хәлдә тапты, икесенең дә тәне суынган иде.. Бу вакыйга сары йортларның куркуын тагын да ныграк көчәйтте, аның күзенә чалынмаска тырыштылар, карчыкның үзләре янына килгәнен күрсәләр, барысы да дәррәү кубып өйләренә

тарала башладылар. Аның кайсы вакытларда өзгәләнеп: «Туктагыз, бичаралар! Кырылып бетәсез бит...»—дигән сүзләре күпләрнең төн йокысын алды, төшләрендә аның күзләрен күреп саташып чыктылар, тавышын ишетеп куркып уяндылар, алтынчы подъезд эскәмиясенә якын да бармас булдылар, гомумән, кешеләр карчыкның үзен дә, яшәгән йортын да урап үтәргә тырыштылар. Ә явыз карчык аның саен алар белән очрашырга, мәче күзләре белән җаннарын актарырга омтылды, җыелып торган урыннардан дәррәү таралышсалар, берәм-берәм эләктереп алды һәм үз фатирына керергә кыстады, сүз белән генә ипкә китерә алмагач, беләкләреннән тотып өстерәргә итте, тик куркудан гайрәтләнгән кешеләргә көче җитмәде. «Һәлак буласыз бит, акылсызлар, һәлак буласыз бит»,—дип мыгырданып калды ул алар артыннан һәм моның белән генә тынычланмыйча, берәм-берәм фатир ишекләрен кагып йөрергә тотынды. Тик ана ачучы булмады, ишекләрен җиде йозакка бикләп, тәрәз пәрдәләрен тартып өй эчендә дер калтырап утырды кешеләр. «Инде афәт үтте»,—дип тынычланып барганнарның җанын телеп урамда карчыкның ачы тавышы яңгырады: «Кадалышып бетегез, алайса! Кадалышып бетегез...». Бу хәлдән соң карчык күренмәде, әмма бер кеше саргаеп кибеп җан бирде. Аны җирләп кайтуга сары йортлар янында сирена тавышлары ишетелде, «ашыгыч ярдәм» һәм тагы әллә нинди машиналар килеп тулды, ак халат кигән кешеләр озын шланглар тотып фатирларга таралды, анда яшәүчеләрне машиналарга төяп шифаханәләргә алып киттеләр, өйләрендәге һәрнәрсәгә нииндидер сыекча сиптерделәр. «Ярый әле кешелекле илдә яшибез, ярый әле изге күңелле докторлар бар, юкса, бу явыз сихерче барыбызны да һәлак итеп бетерә иде»,—дип сөенде сары йортларда яшәүче халык, айга якын больницада ятып, ике-өч айлык пенсиясен түләп кайтканнан соң. Карчыкка булган нәфрәт катыш куркулары тагын да ныграк көчәйде. Атнага якын өеннән чыгучы булмады. Ләкин бертөрлелектән ялкып, аралашуга сусаган кешеләр яңадан ишек алдындагы эскәмияләрдә җыелыр булдылар. Тик карчык инде алар белән очрашу эзләмәде, берсенә дә якын бармады, эндәшмәде. Бу кешеләр—үзләре, ул—үзе бер дөнья булып яши башладылар. Хәтта сәер сихерче хакында сөйләшүләр дә сирәгәя төште. Әмәлгә калгандай, шул көннәрдә «якындагы зоопарктан бер юлбарыс качкан икән» дигән хәбәр таралды. Сүзләр гел шул тирәдә йөрде, аның монда килеп чыгу мөмкинлеген, килсә нинди зарар китерәчәген, аннан ничек котылу юлын тикшерделәр. Ир-атларның кайсысы үзләренең балконда ятып тутыга башлаган мылтыкларын чистартып майлап куйды һәм бу хакта күршеләренә: «Монда килеп чыкса куркыныч юк, һә дигәнче егып салабыз, тик менә башка урынга китеп кенә зыян итмәгәе»,—дип шапырынып алды. Шулай шапырынып сөйләнеп утырганда, аларның сүзен тикшереп карарга теләгәндәй, агачлык арасыннан юлбарыс килеп чыкты. Халык «аһ» итеп куйды, тик аларның майланган мылтыклары өйләрендә һәм алар бу очрашуга әзер түгел иде. Ә юлбарыс, үзенең көченә ышанган генерал шикелле, сабыр һәм ыспай гына атлап, кешеләрнең каршысына килеп басты, аларның котын алып ырылдап куйды, эре тешләрен күрсәтергә теләгәндәй, авызын ачты. Бу авыз—адәм башын без алма ашаган җиңеллек белән йотарга мөмкин икәнен аңлаудан, кешеләр селкенергә дә куркып калды, ә юлбарыс кайсысын башта ботарларга микән дигәндәй, әле берсенә, әле икенчесенә карап маңгаен җыерды, кемдер артын пырылдатып, кемдер ыштанын юешләп торганлыктан, ул, әйтерсең, икеләнеп калган иде. Үз ризыгын җентекләп тикшерергә теләгәндәй, ашыкмый гына кешеләр утырган эскәмияләрне бер әйләнеп чыкты да кабат урынына килеп басты. Нәкъ шул чакта тавыш-тынсыз гына үзенә якынайган карчыкны абайлап, аңа таба борылды, ачуланып ырылдап куйды, ләкин килүченең бер генә күзәнәгендә дә курку әсәре сизелмәде, күзләрендә шүрләү дә, явызлык та юк иде карчыкның. Алар ике адым чамасы ераклыкта бер-берсенә текәлеп катып калдылар. Бераздан юлбарыс тыныч

кына борылды да, ничек килгән булса, шулай итеп агачлыкка кереп китте.

Бу вакыйга сары йортларда яшәүчеләрне шулкадәр тетрәтте ки, инде карчыкның җәнлек-җанварлар телен белеп, үзе дә теләсә нинди киеккә әверелә алуына беркем дә шикләнмәде. Җитмәсә, теге юлбарыс шул көнне үк үзе зоопаркка кайткан икән дигән хәбәр дә таралып, кешеләрнең бу фикерен ныгытып куйды, әлеге вакыйгадан соң сары йорттагылар үзләренә очраган җан ияләренә йомшаграк, мәрхәмәтлерәк булырга тырышты, подъездда куышып йөргән мәчеләрне пыр туздырмадылар, чүплектә ризык эзләүче этләргә таяк ыргытмадылар, ишек алдына кунган чыпчык-күгәрченнәргә җим сиптеләр, үзләреннән арткан сөякләрне иске тәлинкәләргә салып ихатага чыгарып куйдылар, ә песиләр өчен баскыч мәйданчыкларында чәркә белән сөт утырттылар. Алар әлеге мәхлукларның берәрсе сихерче карчык булыр да, үзен рәнҗеткән кешегә газаплы зыян салыр, дип курыктылар. Бу куркудан туган шәфкатьлелек тора-бара гадәткә әйләнде, алар үзләренең йорты тирәсендә генә түгел, башка урыннарда да дүрт аяклы җан ияләренә, кош-кортларга изгелек кыла торган булдылар һәм көтелмәгән ачыш ясадылар: әйбәтлекне җәнлекләр, хәтта иң усал, иң явыз дигәннәре дә анлый һәм шундый ук яхшылык белән җавап кайтарырга, һичьюгында койрыкларын болгап булса да рәхмәт белдерергә омтыла икән ләбаса! Бу ачыш аларның сөйләшен дә үзгәртте: телләре ягымлыракка әйләнде, ә үзләренә ошамаган кешеләргә карата еш әйтелә торган «эт», «хайван», «фәлән нәрсә» кебек сүзләр бөтенләй кулланудан төшеп калды.

Шулай бер көнне эскәмиядә гәпләшеп утырган җирдән бер ирнең сулышы кысыла башлады. Ул сары йортта яшәүчеләр арасында иң яше, кырыкка да житмәгәне булса да, әлеге авыруы соңгы вакытларда бик еш кабатлана, аның шулай көтмәгәндә авыр чиргә уралуы күршеләрен хафага сала, моны да алар карчыкның рәнҗеше дип уйлый, ләкин үзләренә зыян төшүдән куркып, кычкырып әйтергә базмый иде. Яше кырыкка да житмәгән ир кешенең йодрык зурлык кына йөзе тагын да кечерәеп, күкшелләнеп калды, газап һәм курку катыш күзләре зур ачылды, зәңгәрсу-кызгылт төскә кергән колаклары тырпайды. Моны чиксез хәвеф белән күзәткән кешеләр карчыкның яннарына ничек килеп басуын да сизми калдылар. «Бозым бар синдә!,—диде ул хәтта буылучының үзе дә бер мизгелгә тынып калырлык итеп,—Рәнҗеше төшкән сина берәүнең». Теге кеше елт итеп якындагы тирәк төбенә карап алды, моны бер кеше дә сизмәде. Әмма карчык аның күз карашын гына түгел, ә тәненнән күтәрелгән парның күләмен дә тоя иде. Карчык авыру янына килеп басты да учларын аның башы тирәсендә йөртте һәм эченнән нәрсәдер пышылдый-пышылдый күкрәк янына төшерде дә нәрсәнедер йолкып алып жиргә ташлаган хәрәкәт ясады. Аннан соң кулларын бер-берсенә ышкып селкеп куйды. Бераздан чирле кеше торып басты һәм косарга тотынды. Арыш ипие, дуңгыз мае, чәй чүпләре, кәбестә кисәкләре өстенә бармак буе кара корт килеп төште һәм күз иярмәс тизлек белән чәбәләнергә тотынды. Бу кара җәнлек бары тик карчыкның утлы карашы һәм догалары тәэсирендә генә тынып калды, ә бераздан бөтенләй юкка чыкты. Кешеләр могжизадан айныганда карчык үзенең алтынчы подъездына кереп бара иде инде. «Ялгыз әниемне ташлап килгән идем бит мин монда,—дип ыңгырашты теге кырык яшьлек карт, һушына килгәч,—Шуның рәнҗешләре төште микәнни?.. Яратып йөргән кызымны да авырлы килеш калдырып киткән идем...» Ул шул рәвешле үз гөнаһларын санады да санады. Бу хәлдән соң сары йортларда яшәүчеләр бер-бер жирләре авыртып торса, яки чирләп китсәләр: «Миндә дә бозым юк микән, миңа да берәрсенең рәнҗеше төшмәде микән»,—дип үз күңелләрендә казынып булып киттеләр, үткәндәге гөнаһлары өчен үкенеп тәүбә кылдылар, яңадан начар гамәлләр эшләмәскә, хәтта берәүгә дә авыр сүз әйтмәскә тырыштылар, өннәрендә кемнең дә булса кәефен

кырсалар, бармак зурлык теге кара корт төшләренә керде. Алар хәзер кешенең завод-фабрикаларда эшләп, сары йортларда яшәр өчен генә дөньяга килүенә шикләнә башладылар. Болардан тыш та кеше нәрсәләргәдер ирешергә тиештер кебек тоела башлады. Ләкин бу үзгәрешләр аларга кирәкми, алар өчен бу үзгәрешләр тормыш ритмын бозып, бөтен дөньяларының астын-өскә китерә торган, үзләрен мескен бер бөҗәктәй тоеп, газапланырга мәҗбүр итә торган авыр йөк, ә тормыш агымында үз әҗәлләрен көтеп яшәгән бу бәндәләрнең мондый йөкне күтәрерлек рухи ныклыгы да, аны күтәрергә теләкләре дә юк иде. Һәм бер көнне алар, бөтен куркуларын җинеп, ишегалдына чыккан карчыкны сырып алдылар: «Нишләтәсең син безне? Ни өчен безгә авырулар, шик-шөбһәләр, күңел газаплары җибәрәсең? Ник безнең көннәребезнең нурын, төннәребезнең тынычлыгын аласың, ник безне бәхетсезлеккә дучар итәсең?»—диделәр. Карчык аларның моң-зарын тыңлап бетерде дә җаннарны өшетеп, бала йоннарын кабартырлык, бер дәһшәт белән кеткелдәп көлде, аннан соң һәрберсенең күзенә карап чыкты (алар бу мизгелдә үзләренең аяк астында җир убылгандай хис иттеләр) һәм гасырлар буена колакларда чыңларлык тавыш белән: «Сез каберләр өстендә яшисез,—диде һәм, йөзләре кинәт агарынып киткән кешеләргә карап сүзен дәвам итте,—Үзегезнең каберләр өстендә яшисез сез!» Һәм... китеп тә барды. Кешеләр шунда тирә-якларына карады һәм яңа гына күзләре ачылган сабый сыман гаҗәпкә калдылар. Алар әллә ничәшәр ел шушында гомер кичереп күрмәгән бернәрсәгә игътибар иттеләр: сары йортлар янында үскән агачлар гарип икән бит, кәүсәләре кәкре дә бөкре, ботаклары чуергалы, яфраклары да артык кечкенә һәм алар җәй уртасында ук саргаеп коела икән, ул агачларга кошлар да кунып сайрамый, кышын кар сарылмый, алар җәен-кышын япа-ялгыз икән, ә кайберләре бөтенләй үз асылын җуйган—ботаклары да, яфраклары да юк, алар якындагы завод-фабрикаларның торбалары сыман серәеп каткан икән. Менә шушыларны күрүгә, эченнән кара корт чыккан ир кеше баягы тирәккә текәлде, калганнар да һәрберсе бер агачка карап тораташка әйләнде, йөзләре ап-ак булды, күзләрен әйтеп бетергесез сагыш һәм үкенеч ялмады, күгәргән иреннәре калтыранды, колакларында карчыкның: «Каберләр өстендә яшисез сез! Үзегезнең каберләр өстендә!..» дигән сүзләре яңгырады.

Чынлап та, каберләр өстендә яши иде бу кешеләр. Завод моржаларыннан чыккан сасы төтен сулар һаваны пычратып, агачларны гына гарипләп калмаган иде, ул кешеләрнең рухи мохитен дә пычракка батырып, җаннарын да гарипләгән иде. Ләкин сары йортта яшәүчеләр ул хакта уйламады, агачларның үсмәвендә алар үзләрен гаепле санады. Карчыкның тавышы аларны бик ерак булып тоелган үткәннәргә, яшьрәк чакларына алып китте. Заманында агулы матдәләр арасында эшләп зур хезмәт уңышларына ирешеп, рәсемнәре завод-фабрикаларның почет тактасында торган, ә үзләре бөтен уңайлыклары булган иркен фатирларда шатланышып яши башлаганда, сары йортлардагы хатыннарның билләре юанаеп киткән чакларда алар бер-берсен: «Кайчан туа? Синеке кайчан?»,—дип сәламлиләр, ләззәтле бер ашкыну белән бала карау хәсрәтләре хакында сөйләшәләр иде. Ләкин көмәннәре зураеп, көтелгән вакытлар житсә дә, алар бер-берсен котлый алмадылар, кайберләре кара көеп: «Үле туды»,—диде, кайберләре берни дә дәшмәде. Болай да аңлашыла иде. Мондый хәлләр озак дәвам итте, кайсыбер хатыннар бер баладан ук төшенкелеккә бирелсә, бәгъзеләре өчәр-дүртәр тапкыр авырга узды, ләкин берсенә дә бала төсе күрергә насыйп булмады. Юк, үле тумады аларның сабыйлары, ул балалар йә ике башлы, йә өч куллы, йә дүрт аяклы, йә сыңар күзле булып, гарип булып туды һәм нарасыйларын да, үзләрен дә гомерлек газапка дучар итәргә теләмәгән әти-әниләре аларны үтереп төннәрен ишек алдындагы агачлар төбенә илтеп күмде, ул агачларга күңелләреннән генә гарип балаларына кушылырга тиешле исемнәрне бирделәр. Бу сары йортларда яшәүчеләрнең һәрберсе белә торган һәм берсе дә беркайчан да ычкындырмый торган әрнүле сер иде. Алар һәр көн саен агачлар белән сөйләшәләр, кәүсәләрен сыйпап иркәлиләр иде. Бу

дистә еллар буе шулай дәвам итте, ә ул агачларның да гариплегең менә хәзер генә, сихерче карчыкның сүзләреннән соң гына күрделәр һәм күңелләрен чиксез курку биләп алды. Үз балаларына кылган бу гамәлләре агачларны гарипләгән икән, димәк, башка вакыттагы хаталары, яманлыклары табигатьнең, тирә-якның бүтән нәрсәләренә дә зәгыйфьлек китергәндер, алар сары йортларда яшәүчеләргә нык рәнҗидер, үзләренең дошманы итеп күрәдер сыман тоелды. Кешеләр үзләрен бар Галәмдә бер ялгыз калгандай хис итте. Хәтта мәче башлы ябалакны хәтерләткән сихерче карчыкның бүтән җиргә түгел, ә нәкъ үзләре янына килеп, аларның тыныч тормышларын пыр туздыруын да кылган гөнаһлары өчен табигатьнең үч алуы дип уйладылар. Җәнлек-җанварларның, агачларның, гомумән, бөтен нәрсәнең дә телен белгән һәм теләсә нинди кыяфәткә керә алган бу карчык, кешеләр фикеренчә, гади карчык кына түгел, ә нәкъ менә табигатьнең бер вәкиле, бөек хөкемдар тарафыннан чыгарылган җәзаларны тормышка ашыручы булырга тиеш иде һәм кешеләр, үзләренең мондый газаплы тормышына чик куярга, һичьюгы аны бераз җиңеләйтергә теләп, сонлап булса да, агач төпләренә күмелгән гарип балаларын, йола кушканча итеп зиратка күчереп җирләргә булдылар. Ләкин зәгыйфь агачлар янына килеп җиргә баккач, тагы гаҗәпкә калдылар, сабыйларның кабер урыны кап-кара җир булып тора иде. Башка вакытта ничек күрмәгәннәр дә, ничек сизмәгәннәр, дистә еллар буе монда үлән үсмәгән икән, ләбаса... Каберләрне икешәр колач тирәнлектә казып карасалар да берни табылмады. Югыйсә, аларның гарип балалары ярты гына метр аста булырга тиеш иде бит...

*«Коточкыч көннәр иде бу, туган, коточкыч көннәр иде. Җаннарыбыздагы яра өстенә яралар өстәлеп торды, үкенүләр өстенә үкенүләр өелде, үз хаталарыбызны төзәтүдән, юк, төзәтергә тырышудан да мәхрүм идек без, гомер буена күпме ялгышлар, күпме бозыклыклар эшләвебезне аңладык, ләкин ни дә булса үзгәртергә соң, бигрәк соң иде инде. Шуны тоюдан көннәребез көн, төннәребез төн төсен җуйды, яшәвебез яшәү булмады. Әмма монда без генә гаепле идекме соң? Әгәр шатланышып, көннәре-минутларына кадәр санап көтеп алган балаларыбыз сау-сәламәт булып туса, без нинди бәхетлеләр булыр идек! Аларны үтереп агач төпләренә күмәр идекмени? Без бит аларны агач төпләренә генә җирләп калмадык, йөрәк түрләребезгә дә күмдек, гәүдәләре җирдә булса да, әрнүләре йөрәкләребездә булды. Әнә шушы хакта без карчыкка әйтергә теләдек, юк, аның җәзаларын җиңеләйтүен көтмәдек, бу гөнаһларыбызның сәбәбен, гомер буена җанга тынгылык бирмәгән күңел кичерешләребезне аңлавы безнең өчен күпкә мөһимрәк иде. Һәм без, бөтен тәвәккәллекләребезне җигеп, алтынчы подъездга кердек...»*

## II

Карчыкның фатирында чәчелеп яткан сөякләрне зиратка илтеп җирләгәч тә, тәүге мәлләрдәге тетрәнүләр бераз үтә төшсә дә кешеләр инде тамагына ризык кабар, эскәмиягә чыгып сөйләшеп утырыр хәлгә килсә дә, күңелләрендәге шом басылмады, алтынчы подъездтан бала елаган, эт өргән тавышлар тынмады, ул инде элеккечә җанны тырмап, акылдан шаштырырлык дәрәҗәдә булмаса да ара-тирә ишетелеп-ишетелеп кала, хәтәр көннәрне искә төшерә һәм афәтләрнең моның белән генә бетмәячәген искәрткәндәй тоела иде. Дәһшәтле көндә сихерче карчыкның күккә ашуын үз күзләре белән күрсәләр дә, сары йортта яшәүчеләр аның сау-сәламәт килеш җирдә, үзләре арасында, ниндидер кыяфәткә кереп яшәп ятуына шикләнмиләр, гомумән, алар бу карчыкның үлү мөмкинлегенә ышанмыйлар, аны гади кеше итеп түгел, ә бөек хөкемдарның ихтыярын үтәр өчен адәм балалары арасына җибәрелгән бер вәкил дип исәплиләр иде. Ә подъездда сирәк-саяк ишетелеп калган тавышлар аның үлемсезлеген исбатлаучы бер дәлил кебек булды.

Карчыкның фатирында моңа кадәр дә адәм сөякләрен күргәне бар

иде кешеләрнең. Теге вакытта, агач төпләренә күмелгән балаларын таба алмагач, алар шушы подъездга керделәр. Карчыкның ишеге бикле түгел иде, эчкә узу белән барысы да катып калды, юк, аларны түрдәге караватта берни белмичә берәүгә дә игътибар бирмичә кулларын күкрәгенә куеп тыныч кына йоклап яткан карчык та, стена буйлап тезелеп киткән шкаф киштәләрендәге сансыз банкалар да, бөтен өй эченә таралган сәер һәм шул ук вакытта тәмле ис тә, хәтта бер почмакта тавыш-тынсыз гына утырган, менә кадәр күзгә-башка күренмәгән овчарка да гаҗәпкә калдырмады. Барысының да чәчен үрә торгызган нәрсәләр, ак биләүгә төрелгән сабый сөлдәләре булды, өч биләүдән күренеп торган өч баш сөягендәге өч пар күз чокыры көтмәгәндә килеп кергән кешеләргә рәнҗеп һәм үпкәләп карый төсле иде.

*«Коточкыч күренеш иде бу туган, коточкыч күренеш иде. Без баскан урыннарыбыздан кузгалырлык көч тапмадык, гүя бөтен күзәнәкләребез таралып, тәннәребез камырга әйләнгән, хәтта уй уйларлык та хутыбыз калмаган иде. Күпме шулай басып торганбыздыр, әйтүе кыен, һушларыбызга килгәч, ниһаять, әлеге сөякләрнең почмакта утырган эттән калганлыгын аңладык һәм кинәт килгән ярсу белән аңа ташландык. Эт өрмәде дә, каршылык та күрсәтмәде, тик ничектер җиңел генә безнең аша үтеп урамга чыгып югалды. Аны тота алмадык, ә кабат өйгә кергәч, явыз карчыкны уятып барсы өчен дә аннан сорау алырга һәм үзен дә җәзага тарттырырга булдык. Безнең нәфрәт чиксез иде, ләкин аны менә шулай, йоклап яткан килеш үтерергә беребезнең дә кулы бармады, аны уятырга һәм: «Менә бит, без генә гөнаһлы түгел бит, син үзең дә пычрак җанлы икән бит»,—дип бугазыннан алырга кирәк иде. Тик без аны уята алмадык...».*

Кешеләр күпме генә тырышмасыннар, карчык күзләрен ачмады, шуннан соң кемдер башын аның күкрәгенә салып карады да тын алмавын әйтте, икенче берәү беләген тотты—карчыкның пульсы юк, йөрәге типми иде. Кешеләр бер-берсенә карашып алды, алар ышанырга да ышанмаска да, шатланырга да шатланмаска да белмәделәр—көннәренең тынычлыгын алып, дөньяларның астын-өскә китергән, уйсыз-моңсыз көннәрен онытгырып газап эчендә йөзәргә мәҗбүр иткән карчык, сихерче карчык, явыз карчык үлгән иде. Әмма кешеләр куанычтан бәйрәм ясарга ашыкмады, менә шулай кинәт кенә килер өчен, менә шулай җиңел генә бирелер өчен бу артык озак көткән һәм искиткеч зур шатлык иде. Сары йортта яшәүчеләр өчен бу фани дөньяда оҗмах ләззәтен кичерү белән бер булды, ә оҗмахка элегү бәхетен алар бу дөньядан гына түгел, ә теге дөньядан да көтмиләр иде, шунлыктан йөрәкләре чиксез бәхеттән ярсып-ярсып типсә дә, хисләрен тыярга тырышалар, хәтта шатланырга куркалар иде. Сабыйларның сөлдәсе дә, чыгып качкан эт тә онытылды, хәтта ашау-эчүләр, йокы-фәләннәр онытылды, кешеләр бары тик бер нәрсә—карчыкның үлеме хакында гына уйлый ала иде, хәтта бер-берсе белән очрашканда да «Исәнме-саумы?»,—дип түгел, ә «Чынлап микән, малай», «Чынлап булсын иде»,—дип исәнләштеләр.

Карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә шул хәлендә ята бирде. Ниһаять, кешеләрнең шиге бетте. Күнелләрендә басылып яткан тойгылар тышка ургылды, алар өчен кояш нурлары яктырыбрак киткәндәй тоелды, сулар һавалары сафланып, тын алулары иркенәеп калды, атлап йөрешләре җиңеләйде, телләре чишелде, хәтта ишек алдындагы гарип агачлар да оҗмахның җимеш бакчасы булып күренде. Алар кесәләре мөмкинлек биргәнчә, иң татлы ризыкларны, иң яхшы эчемлекләрне алып сыйландылар, бер-берсенә кунакка йөрештеләр, ишек алларына чыгып гармун көйләренә ярсып-шашып биеделәр, юк тавышларын бар итеп, дөнья янгыратып җыр суздылар, шатлык-куанычтан аларның көннәре белән төннәре буталды.

*«Искиткеч мәлләр иде бу, туган, искиткеч мәлләр иде. Без ни кылганыбызны, кайда басканыбызны да тоймадык, без атлап түгел очып йөри идек, ирексездән дәртле җырлар суздык, аяклар үзләреннән үзләре биеп торды, йөзәр еллар тоткынлыкта ятып, көтмәгәндә-уйламаганда ирекккә чыккан коллар кебек идек, иңнәребезгә гүя канат үсте, иңнәр нәрсә, йөрәкләребезгә үсте сихри канат һәм ул*

*безне күккә, иркенлеккә, биеклеккә әйдәде, күңелләрдә ургылган хисләр өермәсе йолдызларга алып менде безне, без үзебез дә кара болытларны ерып чыккан йолдызлар кебек, бар дөньяга карап көлә идек, шаян нурлар сибеп балкый идек, без җиде көн буе бәйрәм иттек, безнең өчен җиде көн буе төн булмады, күктә кояш, җирдә тик без идек...*

Күнелләре булганчы бәйрәм иткәч, карчыкны җирләргә кирәклеге исләренә төште һәм алар кабат теге фатирга керделәр, бер нәрсә дә үзгәрмәгән иде монда. Ак биләүдә—сабый сөлдәләре, караватта—карчык мәете. Кешеләргә инде ул явыз булып күренмәде, ана карап нәфрәт кичермәделәр, үзенең үлеме белән сары йортларда яшәүчеләрне бәхетле тормышка чыгарган бу әбигә алар рәхмәтле иде, шуна күрә, аны бөтен йолаларын китереп, иң кадерле кешеләре кебек тәрбияләп җир куенына тапшырырга булдылар.

*«Зиратка барып карчыкка урынны үзем сайладым. Урын табып, кабер казыттым. Тик бер нәрсә, гаҗәп нәрсә күрдем мин анда. Юкса, ул зиратта күп тапкырлар булганым бар иде, әмма моңарчы никтер күрмәгәнмен. Балаларның, агач төпләренә күмеп, кабат табылмаган балаларның кабердәре шушы зиратка күчкән иде, исем-атлары да, туган-үлгән еллары да язылган иде. Җитмеш җиде кабер иде барлыгы, тик өчесе генә шул казылган килеш калган иде. Без, моңа кадәр: «Алла юк»,—дип өйрәнгән кешеләр: «Ә моннан соң... ни хәл итәсең...»,—дип авыр сулап куя башладык...»*

Башта карчык фатирында яткан өч баланы җирләделәр, бөтен йолаларны төгәл үтәргә тырышсалар да күнелләрендә шик калды, нәрсәнедер дөрес эшләмәгәннәрдер, ниндидер зур хата ясаганнардыр кебек тоелды аларга. Бердән, сабый сөлдәләренең исем-атларын белмәү борчыса, икенчедән, сөякләр бик күптәнге, хәтта моңа кадәр дә җир куенында булгандыр сыман иде. Ләкин аларны менә шул килеш карчык-ның өсталендә саклап та булмый ич. Бу житди сәбәп, һәрхәлдә, кешеләргә үзләрен акларга мөмкинлек бирүче сәбәп булганлыктан, сары йорттагылар жаннарын талаган шик шөһбәләренә зур әһәмият бирмәскә, тизрәк онытырга тырышты. Балаларны үз йолаларынча күмеп кайтканнан соң, тагы аптыраштa калдылар: ничә еллар бергә яшәсәләр дә, алар бу карчыкның кем икәнен, кайсы яктан, нинди милләттән булуын, хәтта исемен дә белмиләр икән бит. Бөек көчләр тарафыннан кешеләр арасына җибәрелгән могжиза иясенең, бәлки, туган елы да, милләте дә булмагандыр, моны ачыклау, бәлки, мөмкин дә түгелдер, әмма карчыкны рухы рәнжемәслек итеп, өрәк булып янадан сары йортларга кайтмаслык итеп җирләргә кирәк иде, ә күршеләре анын нинди дин кешесе булуын, димәк, нинди йола буенча җир куенына тапшырырга кирәклеген белмичә аптырады. Йортның тәртибен бозып өй хуҗасын да, карчыкның рухын да рәнҗетмәскә тырышып кына, зур саклык белән алар бөтен фатирны тентеп берәр документ, һичьюгы исем-аты гына язылган берәр кәгазь кисәге эзләделәр, хәтсез генә китаплар, яшел кара белән язылган дәфтәрләр табылды, ләкин сары йорттагыларга болар бер нәрсә турында да сөйләмәде. Кешеләр ни гарәп, ни латин язмасын белми иде. Китап шүрлегенең иң күренеп торган урынында ятса да, иң ахырдан гына игътибарны җәлеп иткән өч кәгазьнең берсе урыс графикасы белән язылган иде. Әмма укый башлагач, ул да серләрен ачмады: «Һәза мә әүса биһи фүланүн әүса вә һуа йәшһәдү ән лә иләһә иллаллаһү вә әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү...» дигән сүзләрдән кешеләр берни дә аңламады, ләкин Мөхәммәт исеменең ишетелүе бу карчыкның мөселман икәненә шик калдырмады һәм аны ислам дине, шәригать кануннары кушканча җирләргә булдылар. Тик ул кануннарны сары йортта яшәүчеләрнең берсе дә белми иде, авылда яшәгән чакларда җирләүләрне бик еш күргән булсалар да, хәзер инде онытып бетергәннәр, җеназалар гына түгел, башка йолалар, гореф-гадәтләр дә хәтерләреннән чыккан һәм телләре дә әллә ничә милләт сүзләренен җыелмасына әйләнгән. Гомумән, бу кешеләрнең үткәне юктыр, алар татар балалары булып туып авылларда үсмәгәннәрдер, ә туганда ук завод-фабрика

эшчеләре булып туганнардыр сыман тоела иде. Берәүнең танышының танышы аша ак сакаллы бер карт чакыртып китерделәр, ул карт өйрәткәнчә итеп, колашага салып башта алгы ягын, сул кабыргасына яткырып уң ягын һәм аркаларын сабынлап юдылар, юып беткәч, пакь җәймә өстенә салып корыттылар, өч катлап кәфен тектеләр, кәфенләнгәч, башын көн батышы тарафына каратып җиргә куйдылар да карчыкның күкрәк турысына басып аксакал җеназа укыды.

*«Аксакалның тавышы безгә иң моңлы, иң якты җыр булып ишетелде, җаннарны иркәләде, аның тавышыннан йөрәк яралары уңалгандай тоелды, җеназа моңы түгел, ә иң зур бәйрәмнәрдә яңгыраган җырлар да бу кадәр ук тәэсир итми, күңелләрне сафландырмый иде, югыйсә. Без газаплардан да арынып калгандай тоелдык, шундый рәхәтлек биргәне өчен ак сакаллы картка да, мөселман алласына да чиксез рәхмәтле идек без...»*

Җеназа тәмам булып, хәерләр өләшкәч, күтәреп зиратка алып китәргә дип мәет янына килергә генә торганда, барысы да сискәнеп китте һәм «Син дә күрдеңме, әллә миңа гына шулай тоелдымы?», дигәндәй, бер-берсенә карашып алдылар, күршеләренең күзләрендә дә курку катыш гаҗәпләнү билгеләре күреп, күңелләрен шом басты. Димәк, чынлап та, мәет кыймылдап куйган, димәк, бу күзгә генә күренмәгән, димәк, алар юкка шатланганнар. Күңелләрен тагын шом басты, юк, бу шом теге вакытлардагы кебек кенә түгел, ә икеләтә-өчләтә көчлерәк иде. Бердән, карчыкның үлемсезлеген тою үзе үк мәхшәрләрнең мәңгегә дә бетмәячәген искәртсә, икенчедән, ул кешеләрнең ничек шатлануын, йөзләрендәге тантананы күреп яткандыр, шуңа рәнҗегәндер һәм хәзер үч аладыр сыман тоелды. Курку һәм үкенеч аларны тораташка әйләндерде, күзләрен карчыкның кәфененә төбәп ни кылырга, ни уйларга белмичә басып тордылар. Ә карчык тагын, тагын кыймылдап куйды һәм бераздан ниндидер дога укыганы ишетелде. Аның тавышы кешеләрнең йөрәгенә ут, тәмуг уты салды. Бераздан ул әкрен генә торып утырды, кәфенлек эченнән ике елан сыман куллары шуып чыкты һәм алар карчыкның битендәге япманы сыпырып төшерделәр. Янып торган ике зәңгәр күз һәр кешене берәм-берәм көйдереп үтте. Сары йортларда яшәүчеләрнең барысы да шушында булып, барысы да бер үк нәрсәне тамаша кылса да, карчыкның терелүен алар төрлечә күрделәр, һәрхәлдә, төрлечә итеп сөйләделәр.

*«Искиткеч мизгел иде бу туган, искиткеч мизгел иде. Мәетнең кыймылдаганын күреп без һушсыз калдык, һәм кинәт дөнья нурланыбрак киткәндәй тоелды, җаныбызның-тәнебезнең һәр күзәнәген ниндидер сихри ләззәт биләп алды, колакларда назлы моң яңгырады һәм без күккә бактык. Ә һавадан ике кош, нурдан гына торган ике ак кош очып килде дә фәрештәләр сурәтенә кереп, карчыкның баш очына басты һәм кулларын сузып аны торгызып бастырдылар. Карчык үзе дә нурга коенды, ул мәче башлы ябалак түгел, ә гүзәл кыз булып күренде, әйтерсең, ул моның белән: «Сезнең янда гына котсызмын мин, ә гүзәл җаннар арасында мөнә нинди булам!», дияргә теләгән иде. Тик ул бөтенләй башка нәрсә әйтте: «Яңа чорга дәшәм сине, кешем!»,—диде ул. Аның сүзләре һәрберебезгә аерым әйтелде һәм барыбызга да берьюлы ишетелде, ишетелде дә бөтен булмышыбызны яулап алды, йөрәккә кергән сүзләрнең кайтавазы кан тамырларында яңгырап торды. Һәм кулларын сузды. Тик без, әлеге күренеш белән ничек кенә тәэсирләнсәк тә, яңа чорга атларга әзер түгел идек, ул безгә кирәкми, ул безне куркыта, без карчык килгәнгә кадәрге тормышта тыныч кына яшәп, тыныч кына дөньядан китәргә теләгән идек. Ул кулларын сузып чакырса да, беребез дә аңа иярмәдек, күңелләрдә ирексездән нәфрәт кабынды, ә фәрештәләр күз алдында эреп юкка чыкты һәм бераздан гүзәл кыз да котсыз карчыкка әверелде. Без тормыш чынбарлыгына кабат кайттык, дөнья кабат соры төскә керде, тирә-ягыбызда гарип агачлар пәйда булды, сулар һавабыз тын юлларын кысты һәм безнең күңелләрне бәхет кошын кулдан ычкындыргандагы кебек, чиксез үкенеч биләде...»*

*«О, ул мизгелләр... Ап-ак кәфенгә төрелгән карчык әкрен генә торып басты да һәммәбезне дә берәм-берәм күздән кичереп чыкты, аның карашларында оҗмах*

*нуры да, тәмуг уты да бергә уйный иде. Җаннарыбызны дулатып барыбызның да күңеленә курку салгач, ул болай диде: «О, кешеләр! Сез тиздән яңа чорга аяк басачаксыз. Шушы мизгелдә сезне афәтләрдән коткарачак пәйгамбәр туды. Коткаручыгызның кадерен белегез, күңел тәрәзәләрегезне сөртеп багыгыз аңа, эт хөкемендә яшәтмәгез...» Без аның сүзләренә ышанмадык. Без гомумән, Аллага да, дингә дә ышанмый идек, аның серле сүзләре йөрәккә шом салса да, күңелләрнең бер почмагында мәсхәрәле елмаю ялтырап китте һәм карчыкның өстендәге ап-ак кәфен аның без белгәннән бирле киеп йөри торган кара күлмәгенә әйләнде...»*

*«Әлхәмдел иллаһи шөкер, Аллаһы Тәгаләмез үз мөэминебезне җир куенына тереләй бирүдән саклады. Азан намазын укып бетерүемә үк мәрткә киткән кешенең йокысын ачты... Юк, мин фәрештәләрне дә, сихри нурларны да күрмәдем, яшем олы бит инде, күзем дә начараядыр, колаклар да ныгып киләдер... Карчык әкрен генә торып утырды, аягына басты, тирә-ягына, кешеләргә гаҗәпләнеп озак карап торды, авызларын ачып-ябып, ачып-ябып алды... Сүзен ишетмәдем, берни дә әйтмәде бугай. Бәй, башкаларга ишетелсә... Күңелләре белән нәрсәдер көткәнгә, өмет иткәнгә шулай тоелгандыр, һәркем үзе теләгәнне ишеткәндер...»*

Алар үзара шундыйрак сүзләр сөйләделәр, ә ул чакта карчыкның терелүенә гаҗәпләнүләренең чиге юк иде. Кешеләр өч көн буе алтынчы подъезд төбендә басып тордылар, атна буе авызларын ачып сүз әйтәлмәделәр, һәм телгә килгәч тә сөйләшер сүз тапмадылар. Кара көннәр һаман дәвам итә, ачы кайгылары—уртак, ул хакта тел тибрәтүнең мәгънәсе юк сыман иде. Ә бераз тынычлангач, теге сихри мизгелдә күргәннәрен берберсенә сөйләп тәм таптылар. Ишек алларында җыелып, шулай гәпләшеп утырганда элекке тыныч тормышта гомер иткән чаклар аларга кире кайткан сыман иде. Карчык та хәзер озак кына күзгә күренми торганлыктан, сары йортларда яшәүчеләр «Әллә чынлап та яна чорга аяк бастык микән, газаплардан арынып калдык микән?»,—дип сөенечле уйларга бирелә башлады. Әмма алтынчы подъездга әледән-әле кереп-чыгып йөргән овчарка гына күңелләренә шик өстәде, ә көннәрнең берендә алар коточкыч ачыш ясады: карчык хәзер эт кыяфәтенә кереп йөри башлаган икән бит! Моны нигезләрлек сәбәп тә бар иде—теге вакытта аны үле килеш күргәндә, почмакта бер эт тора иде ич. Димәк, карчык үз гәүдәсен калдырып эткә күчкән булган, ә җирләү алдыннан, гомергә эт булып калудан куркып кабат кайткан. Бу ачыш белән бәхәсләшүчеләр табылса да, аны бөтенләй үк инкарь итеп тә булмый иде. Чынлап та бит, әнә, карчык күренсә, эт күренми башлый һәм, киресенчә, эт йөргәндә карчык юкка чыга... Бу ачыш карчыкның шәхесенә берниндн дә ачыклык кертмәде, киресенчә, аны тагын да серлерәк итә барды, аның сихри мөмкинлекләрен кинәйтте, димәк, кешеләрне үзләренең көчсезлегенә ныграк ышандырды. Овчарка үзе үк кешеләрне пошаманга калдырыр дәрәҗәдә сәер иде. Ул башка этләр кебек чүплекләрдә чокчынмады гына түгел, хәтта маэмайлар өчен махсус куелган тәлинкәләргә дә якын бармады. Ишегалдында күренсә, бүтән этләр койрыкларын бот арасына кыстырып табанын ялтыратты. Ул кешеләрдән тамчы да курыкмады, киресенчә, нинди дер сихри нур белән балкыган карашлары белән сары йорттагыларны чарасыз калдыра, коелып төшәргә мәҗбүр итә иде. Ул өрми дә, ырламый да, чыгып кайлардандыр урап килә дә кешеләр гәпләшеп торган эскәмияләр янына туктала, сүзләрен бераз тынлап тора, аннан соң шул утлы карашлары белән һәркемне өйрәнеп чыга, һәм нинди дер аңлаешсыз аваз чыгарып, алтынчы подъездга юнәлә. Бигрәк тә менә шушы гадәте үртәде кешеләрне, менә шушы гадәте аларның шик-шөбһәләрен таратты. Карчыкның эткә әйләнүе алар өчен бәхәссез иде хәзер. Шуна күрә дә яннарына килүче овчарканы куруга үк сүз берләшкәндәй барысы да авызын йома, ләкин бу гына да ярдәм итми, күзләре этнең карашы белән очрашуга ук җаннарын нәрсәдер көйдереп ала. Бу эт аларның үткәнен, киләчәген, әлеге мизгелдә нәрсә уйлаганын—һәммәсен дә белеп торадыр, ул кешене үтәдән-үтә күрергә сәләтледер кебек тоела иде.

Инде шушы сынауларга күнегеп, карчык белән этнең бер үк зат

икәненә инанып килгәндә, кинәт аларның бөтен гоманнарын җимерерлек хәл булды—карчык эте белән бергә күренде. Монысы инде тагын да коточкычрак күренеш иде, димәк, карчыкның сихри мөмкинлекләре чиксез, димәк, ул берьюлы үзе дә, эт тә була ала. Аның икегә генә бүленүен дә исбатлап булмый бит әле, бәлки, ул берьюлы әллә ничә төрле кыяфәткә керәдер? Һәм кешеләрнең күнелен шик томалады, һәр җан иясе, һәр агач, һәр үлән аларга карчык булып тоелды, хәтта бер-берсеннән дә шөбһәләнә башладылар, якын күршең кыяфәтенә кереп эч серләренне сөйләтмәгәе, дип курыктылар. Хәзер инде ишегалдына чыгып гәп куертулар, кунакка чакырышулар сирәгәйде, күбрәк өйләренә бикләнеп утырырга күнектеләр. Тик алай да күнелләре тынычланмады, хәтта фәләнешәр ел бергә яшәгән җәмәгатьләренең сәеррәк ягын эзләделәр, таптылар һәм «Карчык минем тормыш иптәшем кыяфәтенә кермәде микән» дип шүрләделәр, алай гына да түгел, кайберәүләр хәтта үз-үзеннән шикләнеп куйды.

Менә шулай итеп кешеләрнең тормышы газапка әйләнде, газап өстенә газап өелде. Һәркем бу мәхшәрдән котылу юлын эзләде, ләкин үз уйларын башкалар белән бүлешергә курыкканлыктан, һәркем үз алдына гына эш кырырга тырышты һәм сары йортларда могҗизалар көннән-көнгә арта барды. Беркөнне ишегалдында, подъезд төпләрендә, баскыч мәйданчыкларында үле этләр, мәчеләр гәүдәсен күреп кешеләрнең чәче үрә торды. Икенче көнне берәүнең ире тәрәзәдән ташланып җан бирде. Өченче көнне алтынчы подъезд төбендә бер хатын ерткыч капкынына эләгеп аягын өздерде... Мондый бәла-казаларның чиге-чамасы булмас төсле иде. Бу хәлләр кешеләрдәге курку хисен тагын да арттырды гына, карчык аларның уй-фикерен белеп тора, шуңа күрә һәркемгә җәза җибәрә кебек тоелды.

Мондый явызлыклардан соңгы чиккә җиткән кешеләр кинәт айнып киткәндәй булды, көн саен һич югы бер афәт чыгып торса да, карчыкның бик хәтсездән күзгә-башка күренгәне юк, лабаса. Үзе булып та, эт булып та йөргәне юк... Бу хәл аларны бераз тынычландырып җибәрде. Кешеләр карчыкка каршы аерым-аерым көрәшүләрен туктатып, тагы нәрсә буларын көтә башлады һәм кисәк кенә теге афәтләр дә юкка чыкты, беркем дә капкынга эләкмәде, беркем дә баскычтан егылып имгәнмәде, гомумән, бәла-казалар сары йортларны урап үтте. Кешеләр кабат ишегалдына чыкты, эскәмияләргә утырып гәп куерттылар, бер-берсенә булган шик таралды, тормыш үз агымына кайткандай булды.

«Ләкин бу тыныч тормышта озак яшәмәдек без, туган, озак яшәмәдек. Үз хәлләребезгә күнегеп, бер-беребезгә ышаныч арта гына башлаган иде, алтынчы подъездда бала елаган, эт өргән тавышлар кабат ишетелә башлады. Эт өрүе берчә шулкадәр нык көчәя, көннәр буена дәвам итә, берчә тынып тора, ә бала елавы теләсә кайчан ишетелеп-ишетелеп ала иде. Безнең йөрәкләрне тагын шом басты... Ә бермәлне... Ә бермәлне чәчләрне үрә торгызып, күзләрне маңгайга мендерерлек бер хәл булды: алтынчы подъездан бер гүзәл кыз чыкты. Моңа кадәр аны күргәнебез юк иде безнең, тик менә ант итеп әйтә алам, ул таныш та кебек иде. Мин озак, бик озак баш ваттым бу турыда, мин аны кайдадыр күргән идем, ул миңа шундый таныш иде. Ләкин кайда күргәнемне һич кенә хәтерли алмадым, бу хакта күршеләргә әйттем, алар да минем хәлдә иде һәм без карчыкның гүзәл кыз кыяфәтенә керүен аңладык...»

Теге вакытларда овчарка аларның тынычлыгын ничек алган булса, хәзер гүзәл кыз йокыларын очырды. Юк, бу кыз сәер дә, усал да түгел иде, бу кыз алар янына килеп сүзләрен тыңламады, күз карашлары белән җаннарын көйдермәде.. Ул аларга һәрчак ягымлы булды, очраганда исәнлек сорашты (тик кешеләр җавапсыз калды), берәрсе авыр сумка белән кибеттән кайтса, юл уңаена кыз аның сумкасын күтәрешергә итте (тик аңа ирек бирмәделәр), кыз алар белән сөйләшергә, аралашырга омтылды (тик, кешеләр якын китермәде). Сары йортта яшәүчеләрне көтмәгәндә пәйда булган бу гүзәлнең матурлыгы, ягымлылыгы, ярдәмчеллеге, ихласлыгы куркытты. Бер-берсенә дә тулысынча ышанып бетмәгән бер дәвердә, бөтенләй чит кешегә

алар тамчы да ышанмый, ышана алмый иде. Аларның фикеренчә, әйбәт булып кыланучы бу гүзәл кыз чынында сихерче карчык иде һәм кешеләр аннан мөмкин кадәр ераграк булырга тырышты. Кыз аларны куркытып алды, әмма бернинди дә зыян салмады.

Ләкин көннәрнен берендә ишегалдында карчык, кыз һәм овчарка бергә чыкты. Һәм кешеләр янә таяк тыгылган кырмыска оясына әйләнде. Алар үзләренчә нәтиҗә ясады, бер-берсенә булган ышаныч җимерелде, алар кабат үзләренә бикләнде, афәт-бәлаләр сары йортларга кабат кайтты, серткыч капкыннары, агулар кабат кешеләрне корбан итә башлады... Ә бер көнне теге гүзәл нәни бер малай ияртеп чыкты... Бу сары йортта яшәүчеләр өчен һәлакәт белән бер иде. Бу гүзәл кыз олы хатын булып, бу бәләкәч малайга әверелгәнче күптин-күп сулар агачак, димәк, алар үлгәнче шушы мәхшәрдә яшәргә тиеш булачак. Котылу юк иде аларга, котылу юк иде...

Шулай да күнелләрендә бераз өмет тә бар иде. Алар моннан ике ел элек булган вакыйганы—карчыкның үлеп терелгән чагын, аның яңа чорга чакырганын, яңа пәйгамбәр тууы хакындагы сүзләрен хәтерләделәр һәм әлеге кызны яңа дәвергә дәшеп кулларын сузган гүзәлгә охшаттылар, ана ияреп чыккан малайның да ике яшьләр тирәсендә икәненә игътибар иттеләр. Юк, бу ачышлар да аларның күнелләрен тынычландырмады, киресенчә, хафага гына салды: элек алар бу затларның явызлыгына ышанган булсалар, хәзер аларның изгеләр нәселеннән, әүлияләр кавеменнән булу мөмкинлеге куркытты аларны. Элек аларны гөнаһ чыганагы дип исәпләсәләр, хәзер үзләренен бөтен үткән гомерләренен дә, уй-хисләренен дә дөреслеге шикле тоелды. Алар тормыш агымында адашкан кешеләр иде, барысы бергә һәм һәркайсы аерым-аерым адашып калган кешеләр. Алар үзләренең кайчан, кайда, ни дәрәҗәдә адашканлыкларын да аңлый алмый тинтерәделәр һәм кайсыдыр тарафтан күренгән кечкенә яктылыкка да ияреpгә әзер иделәр. Шул ук вакытта ул яктылык аларны куркыта, уй-хисләрендә, кылган гамәлләрендә хаос тудыра иде...

Әйе, кешеләр карчыкны аңламады, аның үзеннән дә, сүзеннән дә, кылган эшләреннән дә курыкты. Бәлки, карчык та, гүзәл кыз да, эт тә һәм сабый бала да изгеләр затыннан булып, адәм балаларына тик игелек кенә теләгәндер, ләкин... Галимнәр кешеләрнең маймылдан яралуын раслый, хайваннан бәндәгә әверелер өчен фәләнешәр миллион еллар кирәк булган. Бүгенге кеше, әйтик, Мөхәммәтәмин, маймылны юындырып, кырындырып, адәмчә киендереп заводтагы гади бер станок артына бастырырга гына теләсә дә, хәтсез вакыт әрәм булыр һәм моннан маймыл да, Мөхәммәтәмин дә бернинди дә файда күрмәс иде. Бәлки, сары йортларда яшәүчеләр белән карчык арасындагы мөнәсәбәтләрне дә шуның белән чагыштырырга мөмкиндер. Ничек кенә булмасын, кешеләр карчыкның могҗизаларыннан да, үзеннән дә тизрәк котылырга теләде, алар үзләренчә капкыннар корды. Куркыныч күршеләренә күбрәк зыян салып, аның көчен һәм яшәү теләген киметергә тырышты, күкләрдәге бөек затларга, илаһи көчләргә көн-төн ялварып явыз карчыкны юк итүләрен теләделәр. «Күлләрдә бик озак, йөзәр еллар яшәп симергән еланнар аждаһага әверелеп кешеләргә чиксез зыян китерә икән, шул чакта, бөек көчләрнең кушуы буенча, болытларга төренеп күл өстенә изге фәрештәләр килеп төшә дә аждаһаны күккә күтәреп алалар икән, күтәрелгән чакта аждаһаның койрыгы җирдән сөйрәлеп бара, аның койрыгы тигән җирдә печән кибәннәре ишелә, агачлар егыла, йортлар җимерелә икән, ә аждаһаны күтәреп алгач, аны үтереп Каф тавы артына илтеп ыргыталар икән», дигән сүзләрне ишеткәне бар иде кешеләрнең. Алар әнә шундый якты болытлар ябынып киләчәк фәрештәләрне көтте, күл буенда түгел, ә шәһәрнең пычрак бистәсендә яшәсәләр дә, теләкләренен чынга ашуына өмет өзмәделәр.

Һәм ул килде... Әгәр кара болытлар ябынып килгән бу дәһшәтне фәрештә дип әйтеп була икән, җен-шайтаннарның кодрәте дә кылган гамәлләре дә моның янында уен гына, аяусыз диктаторларның явызлыгын шук малай гаебе белән тиңләп булмагандай, әлеге фәрештәләрнең дулавын

бернәрсә белән дә чагыштырырлык түгел иде. Сары йортларда яшәүчеләр әлеге нәрсәнең үзләренең чакыруы буенча килүенә ышансалар да, күңелләре тынычланмады, бу алар чакырган, алар көткән, алар күз алдына китерә алган нәрсә түгел иде.

*«О, коточкыч күренеш иде бу, коточкыч күренеш иде. Ул гаҗәп зур елан сымак кап-кара төскә кереп, берчә аксылланып, берчә тараеп, берчә юанаеп килде дә шәһәр янындагы агачларны төбе-тамыры белән йолкып күккә күтәрде, заводларның биек торбаларын җимереп ташлады, кечкенә йортлар, зур-зур станоклар һавада әверелде. Аның яралы ерткыч кебек үкерүе генә дә җирләрне тетрәтте, тирә-якка таралган сасы исе сулышларны томалады. Ул әле безнең янга килеп җиткәнче үк ниндидер бер сихри көч белән йөрәкләрне суырып алырга теләгән төсле иде. Ул җәйдә ахырзаман җитәчәк, дөнья бетәчәк дигән сүзләр йөрде халыкта һәм без моның дөнья бетүе икәненә шикләнмәдек, шул ук вакытта без бу афәтне үзебез чакырып китерүебезне дә онытмадык. Завод ихаталарын пыр туздырып ул сары йортлар янына якынлашты, шәһәр читендәге бер-ике йортны күтәреп күккә чөйде, шул чакта без карчыкны күреп калдык, ул йортлар арасындагы калкулыкка басып кулларын күккә сузган. Үзе нәрсәдер кычкыра иде, без куркуыбызны оныткандай булып, карчыкны күзәтергә тотындык. Якындагы дәһшәт нәзек кара еланга охшап, аның янына юнәлде. Безнең күңелләрдә карчык һәлак булачак һәм без кабат элеккечә яши башлаячакбыз дигән сәер өмет елтлап китте. Ләкин елан нечкәргәннән-нечкәрә барды, кара төстән ул алтынсуга әверелде, яралы ерткыч гүләве моңлы бер авазга әйләнде, һәм менә шушы илаһи күренеш карчыкны нурлы бер алиһәгә әйләндереп күккә күтәрде. Ул югарырак менгән саен тавыш көчәя, моңлы бер җырга әйләнә барды һәм бу сихри моңнардан безнең күңелләребез тулды, күзләребезгә яшь кунды. Ә бөтен дөньяны җимереп юкка чыгарырдай тоелган гайрәтле зур елан, әкрен-әкрен генә алтын баганага әверелеп, кояш чыгышына табан юнәлде һәм бераздан бөтенләй күздән югалды. Без ни уйларга, моны нәрсәгә юрарга да белмәдек, әмма карчыкның сихри кодрәткә ия булуы һәм безнең аннан котылуыбыз бәхәссез иде».*

Карчыкның күккә ашуы аның зур тылсымнарга ия булуы хакындагы сүзләрне көчәйтте генә. Берәүләр аны изге затка исәпләде, икенчеләр диюләр патшасы икән диде, өченчеләр исә, чит планета кешесе дип сөйләде. Аның үле гәүдәсен тапкандагы кебек бәйрәм итмәсәләр дә, карчыктан котылуга һәркем шат иде һәм аның хакында сөйләүләр әкият кебегрәк яңгырый иде.

Ләкин карчыкның фатирында ара-тирә яңгырап, азак көчәеп киткән һәм бераздан тынып калган, ә күпмедер үткәч шул ук тәртиптә янадан ишетелгән этләр өргән тавыш, сары йортларда яшәүчеләрнең күңелен тырнап торды, үткәннәрнең кире кайтмаячагына булган ышанычларын какшатты.

## III

...Әйе, карчыкның фатирында чәчелеп яткан адәм сөякләрен зиратка илтеп җирләгәч тә кешеләрнең күңеле тынычланмады. Алтынчы подъезда эт өргән, бала елаган тавышлар әледән-әле ишетелеп торды, ә кешеләр анда эт кыяфәтендәге баламы, бала кыяфәтендәге этме— ниндидер кеше-җәнлек күрүләре хакында берсеннән-берсе хәтәррәк хәбәрләр сөйләп бер-берсенең йөрәгенә шом салды. Имеш, бер эт белән бер бала төннәрен ишек алдына чыгып йөри икән, алар кешечә дә сөйләшә, эт булып та өрә икән... Моны карчыкның кире кайтуы дип фараз иттеләр, әгәр ул үлгәннән соң да терелгән икән, нишләп әле күккә ашканнан соң кабат кайтмаска тиеш?! Ул үлемсез... Ул кешеләрнең бозыклыгы һәм вөҗданы кебек үк мәңгелек. Сары йорттагылар карчыкның «Шушы мәлдә яна пәйгамбәр туды»,—дигән сүзләрен кабат-кабат хәтерләде дә кешелек тормышының яңа дәвергә, газаплардан азат дәвергә керүен теләде...

...Ә карчык уянып табутыннан торган мәлдә, чынлап та, дөньяга бер малай туды. Дөресрәге, ул көнне туган балалар саны миллионлаган иде,

ләкин әлеге малай башкаларыннан аерыла, чөнки аның әнисе Мәрьям, унсигез яшьлек гүзәл кыз, кияүгә чыкмаган, алай гына да түгел, гомерендә бер генә тапкыр да ир-егет куены күрмәгән саф кыз иде. Кызның исеме Мәрьям булса да, ул диннәр үлеп барган дәвер кызы иде, шуна да баланың гөнаһсыз булуына ышанучы табылмады. Хәтта врачлар да «Хәзер бит ирсез дә бала табып була, әйтик лабораторияләрдә, донорлар ярдәмендә»,—дип уйлады. Әмма кызның сафлык пәрдәсен карагач, иңнәрен генә җыердылар. Ә кайбер шәфкать туташлары өчен Мәрьямнең ирсез бала табуыннан бигрәк, унсигез яшенә кадәр кызлыгын саклап йөрүе дә гаҗәп тоелды.

Мәрьямнең мондый гаҗәп хәлен гәзитчеләр бөтен илгә таратты, гади халык кызыксынып укыды, әлбәттә, динчеләр моны Ходайның хикмәте белән аңлатты, ә докторлар табигатьнең шаяруына нигезләмә эзләп кызны кабат-кабат тикшерде, аның үткәндәге авыруларын энә күзеннән үткәрде. Гади кыз иде ул, тик докторларның игътибарын бер нәрсә җәлеп итте: Мәрьям моннан берничә ай элек яраланып больницага эләккән. Урамнардагы атыш вакытында аның касыгына пуля тия, җәрәхәте төзәлә һәм җиде ай үтүгә ул күреме тукталуга зарланып кабат больницага килә... Бу гаҗәп хәл иде, ләкин ул бер нәрсәгә дә ачыклык кертә алмады. Әмма врачлар тикшерүне дәвам итте һәм тагын бер ачыш ясадылар: Мәрьям белән бер үк вакытта бер үк урыннан яралы милиционерны да больницага китергәннәр, бандит пулясы аның ирлек горурлыгын тамырыннан өзеп киткән була. Димәк... Бу, чынлап та, аптырарлык күренеш иде, милиционерның орлыгы пуляга ияреп Мәрьямнең аналыгына кергән һәм... үлем чәчәргә тиешле корал бер кеше гомеренең яралуына сәбәпче булган.

Ләкин бичара кызга моннан гына берниндидә җиңеллек килмәде, аның якыннары медицина тарихын да, табиблык кануннарын да белми иде. Шуңа Мәрьямнең бер сүзенә дә ышанмадылар һәм аны азгынлыкта гаепләделәр. Яратып йөргән егете: «Күтләк!» дип яңагына шаплады да кырт борылып китеп барды; дус кызлары: «Презерватив кулланырга иде, тиле... Хәзер безнең дә эшләр сизелә башлаячак...»,—дип битәрләп читләштеләр, әти-әнисе, югары уку йортының абруйлы хезмәткәрләре: «Репутациябезне харап иттең, дәрәҗәле урыннан колак кактырдың, син безнең кызыбыз түгел»,—дип күз ачтырмады. Моңа кадәр һәркем арасында сөйкемле сөяк булып йөргән Мәрьям сабые белән япа-ялгыз калды. Ә бер көнне «җан биргәнгә юнь бирер әле», дип бөтенләйгә өйннән чыгып китте. Матди авырлыклардан бөгелеп төшәрдәй көннәре күп булса да аның күңеле тыныч, җанын чеметүчеләр юк иде. Ләкин көтмәгәндә баласы чирләп китте.

Мәрьямнең документлары югалган иде, аны болай гына бер больницада да кабул итмәделәр. Ул түзмәде, трамвайда урыннары янәшә туры килгән бер әбигә үз кайгысын сөйләп бирде. Карчык аны игътибар белән тыңлады, баласының күз кабакларын сыпырып, эчләрен тоткалап карады да үзенә чакырды. Мәрьям башта кыенсынып торса да, әбинең кыставына карыша алмады. Шәһәр читендәге сары йортның алтынчы подъездында яши иде карчык. Аның почмакта гына посып утыручы овчаркасы да бар иде. «Курыкма,—диде карчык, этенә күрсәтеп,—беркемне дә юкка рәнҗетми ул. Бер кышны урамнан табып керткән идем, адәм акыллы булып үсеп житте... Әйдә, кызым, яткыр менә монда бәләкәчне...» Карчык үзе карт һәм ямьсез булып, тавышы иләмсез тупас янгыраса да, аның күзләрендә ниндидер җылылык, күңелне әсир иткеч ягымлылык бар иде. Ул ниндидер үләннәр кайнатып балага да, Мәрьямнең үзенә дә эчерде. Төнәтмә тәмсез иде, әмма сабый аны йотлыгып эчте дә тынычланып йоклап китте. Мәрьям дә соңгы вакытта беренче тапкыр ләззәтле тынлыкка чумды.

Карчык белән очраштырган өчен язмышына рәхмәт укып бетерә алмады Мәрьям. Алар, ничектер, уртак тел тапты. Мәдинә әби (серле карчыкның исеме шулай иде) аның ахирәте дә, әти-әнисedәй якын таянычы да булды.

Мәдинә әби гасыр башында туып, заманының абруйлы шәхесләре, зур галимнәр белән якыннан аралашкан укымышлы карчык иде. Илдәге

үзгәрешләр гомеренең һәр чорына үз тамгасын салган: Октябрь революциясе аның зыялы әти-әнисен һәлак итеп гаиләләрен ятим калдыра, гражданнар сугышында ике абыйсы ике якта сугышып икесен дә корбан итә, репрессия елларында татарның күренекле биологы булып танылган ирен тотып аталар. Мәдинәнең үзен ике баласы белән Себергә сөрәләр, бер улы шунда ачлыктан вафат була; хатын икенчегә кияүгә чыга, тик өч ай да бергә яши алмыйлар, Бөек Ватан сугышы башлана һәм ире шунда китеп хәбәрсез югала; сугыштан соңгы авыр елларда күз терәп торган бар юанычы—икенче баласы да вафат була. Мәдинә үзенең гомерлек һөнәре итеп медицинаны сайлый, фронтның алгы сызыгында йөри, тик соңыннан, абруе үсә башлагач, яман телләр чагып аның үткәннәрен кабат хәтерлиләр һәм «тыныч еллар» КГБ коридорларында уза. Әти-әнисенең зыялылыгы, иренең данлылыгы, яуда үлгән икенче иренең билгесез югалуы, чәчәк кебек чакларын Себердә, алмадай мәлләрен фронтта үткәреп тә бүген дә тыныч-имин генә яшәп ятуы, үз һөнәрендә уңышларга ирешүе өчен акланырга туры килә. Тиздән аны хезмәткә яраксыз дип табалар һәм ялгыз хатын үзе житәкләгән шифаханәдә идән юучы булып тамак туйдырырга мәжбүр була. Әмма көчле терапевтны дәваланучылары онытмый, качып-посып булса да аның дәвалавын телиләр. Мәдинә алар сүзен екмый һәм үз башына тагы бәла ала. Аның белән Иминлек хезмәте кабат шөгыльләнә башлый һәм хатын бәхилләшү хаты белән киемнәрен елга ярында калдырып бөтенләй икенче шәһәргә юллана. Тормышның ачысын-төчесен татып, карт көнендә сукбайлыкта йөри торгач, сары йортларга килеп чыга. «Ленин үлде, Сталин дөмекте, социализм жимерелде, партия жирләнде, ә мин бер яклаучысыз гади татар хатыны һаман яшим әле»,—дип сөйли иде ул Мәрьямгә һәм керфекләрен дымландырып өстәп куя иде,—кызганыч, бу көннәрне балаларым күрәлмәде... Аларны бит «татарин» дип кимсетәләр иде...»

Зыялылар нәселеннән булып, кечкенә чагында ук фән нигезләрен яхшы үзләштергәнлектән, дөньяга карашы гажәеп киң иде Мәдинә карчыкның. Ул әдәбиятны да, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын да, географияне дә, химияне дә тирән белә, ә дин аның өчен үзеңнең татарлыгың белән аерылгысыз бер нәрсә кебек иде. Яши-яши ул телепатия һәм гипноз серләрен дә үзләштерде, Бурбанк ысулы белән үсемлекләрнең төрен үзгәртү, аларның телен аңлау, хәтта жәнлекләр белән аралашу мөмкинлегенә ия булды. Мәдинә карчык бик күп күренешләрне, хәл-вакыйгаларны, кешеләр язмышын алдан әйтеп бирергә сәләтле иде, ләкин ул моның белән акча яки дан тупларга омтылмады. Кулыннан килгәнчә кешеләргә ярдәм итте һәм алардан бернинди бүләк тә, хәтта рәхмәт тә көтмәде. Шулай да изгелеген күреп тә рәхмәт әйтеп китә белмәүчеләр ана кызганыч иде. Һәртөрле күрәзәчеләргә, экстрасенсларга ышанмады карчык, изгелек-явызлык төшенчәләре, дини догалары белән кешеләрнең башын катырмады, ул үз сәләтен Ходай биргән көтелмәгән бүләк, гайре табигый бер могжиза дип түгел, ә күп еллар буена бик күп фән нигезләрен тирәнтен өйрәнү нәтижәсе итеп исәпли һәм аны вак-төяк максатлар өчен куллануны хурлык саный иде.

Әнә шулый сукбайлыкта йөргән көннәренең берендә ул сары йорттагыларга килеп юлыкты һәм аларның завод төбендәге агулы зонада, хәтта агачлар, үләннәр гарипләнерлек урында яшәүләрен күреп нык кызганды, бәлки, берәр ярдәмем тияр, дигән уй белән якыннанрак танышырга булды. Яннарына килеп сүзләрен бераз тынлап тору белән бу кешеләрнең төзәлмәслек авырулар икәнен сизде. Араларында берничәсе ике-өч көннән үк жан бирәчәк иде, житмәсә һәркайсы диярлек сары авыруы эләктергән һәм тиздән бөтен шәһәрне эпидемиягә уралык хәлдә иде. Мәдинә карчык боларның үгет-нәсихәткә килүенә шикләнде дә мәсьәләне каты тотарга булды: «Син! Син!..»,—диде ул төзәлмәслек чирлеләргә төртеп күрсәтеп. Ләкин аны аңламадылар, аңларга теләмәделәр. Завод-фабрикалар һәм үзләренең буш хыялларыннан башканы белмәгән бу кешеләр карчыкны үз даирәсенә кертмәде, ул алар өчен бөтенләй бүтән дөнья кешесе иде. Шуннан карчык һәрберсен аерым-аерым дәваларга теләде,

тик бу да барып чыкмады, кешеләр аннан куркалар иде, гайрәтле дәүләтнең курку белән туып, курку эчендә яшәргә күнеккән бичара балалары, агулы тормыштан тәннәре генә түгел, жаннары да гарипләнгән бәндәләр иде. Дәваларга мөмкин булып та, үз чирен үзе белмичә, белергә теләмичә үлеп китүчеләр ешая башлагач, Мәдинә карчык медицина үзәгенә хәбәр итте һәм бу кешеләрне «ашыгыч ярдәм» машиналарында больницаларга алып киттеләр. Кешеләр Мәдинә карчыктан куркалар иде, ул аларга изгелек иткән саен сары йорттагыларның куркуы көчәйде, куркулары арткан саен алар әйбәтрәк була барды. Тик бу әйбәтлек тыштан гына иде, икейөзлелек кенә иде, ә күнелләре белән алар тамчы да үзгәрмәде, күнеленнән алар үзләре кылган яхшылыкка каршы, үзләренең әйбәт якка үзгәрүеннән үзләре үк курка иде. Мәдинә карчык аларны шушы куркудан азат итәргә, күзләрен ачтырып тирә-якка, һәр кешегә бер генә бирелә торган гомерләренә байкау ясатырга теләде һәм... бу кешеләрнең ин зур дошманына әверелде.

«Сез каберләр өстендә яшисез!»,—диде ул бермәлне аларга. Юк, анымоны уйлап әйтмәде, үзегезнең гомерегезне, гүзәл һәм кабатланмас гомерегезне юкка әрәм итәсез, дигән мәгънәдә әйтте. Анын бу сүзләре сары йорттагыларны тетрәтүен сизде, бу кешеләр үзләренә бирелгән гомерне генә түгел, ә үзләре яралткан гомерләрне дә үтерүчеләр икәнлеген анлады. Һәр агачның исеме булуын, кешеләрнең алар белән «бәләкәчем» дип сөйләшүләрен ул ишетеп йөри иде һәм әлеге бәрелешүдән сон һич көтелмәгән нәтиҗә ясады: болар үз балаларын үтереп агачлар төбенә күмгәннәр икән бит... Һәм төннәрнең берендә агач төбен чокып карарга булды. Агач төбеннән алынган балалар сөякләрен кабергә илтми булмый иде инде. Анын һәр төне шушы авыр хезмәт белән үтте, карт сөякләре генә түгел, йөрәге дә сызлады карчыкның. Сары йорттагыларга ул кызганып карый иде, аларны рәхимсез системаның корбаны дип уйлый иде. Алай гына түгел икән шул, рәхимсез дөньяның кансыз корбаннары икән бит болар. Үткәннәрен генә түгел, ә киләчәген дә һәлак итүче өметсез бәндәләр икән. Авылларда туып-үскән үз милләтен, әти-әнисен, туган жирен оныткан мескен колларны ул башкача кызгана алмады, алар карчыкка жирәнгеч булып тоелды. Бу кадәр үк коллыкка төшәрлек нинди авырлык күргән дә, нинди тетрәнүләр кичергән әле бу бәндәләр? Мәдинә карчык күргән газаплар боларның төшенә дә кереп карамаган бит, ә бит ул сына да сыгыла да ала иде... Тик ул бирешмәде, ул үткәннәрен онытмады гына түгел, ә киләчәк буыннарга да калырлык гыйлемнәр туплады, аны кешеләргә бүләк итәр өчен әзерләп, китапларга туплап бернечә телдә, бернечә жирдә калдырды. Ул китаплар—белем чишмәләре, Мәдинә карчыкның үлеменнән сон бәреп чыгачаклар, авторы билгесез калса да, гыйлем үз юлын алачак. Ул яшәде, ул әле дә яши. Ә бу бәндәләр... Ләкин карчыкның нәфрәте озакка бармады, уйлары бөтенләй башка юнәлеш алды—бу бәндәләр бит туганда ук кеше булып түгел, ә кол булып туган гарип жаннар һәм үз гариплекләренә үзләре генә гаепле түгел алар... Мәдинә бит шәхесләр заманында шәхес булып туды, ә болар кеше булып түгел, ә халык массасы булып дөньяга килделәр... Зәгыйфь балаларын үтереп күмүләре—үзләренең коллыгын анлап, гариплар токымына чик куярга теләүдәндер, бәлки... Менә шундый авыр эшләр һәм авыр уйлар аны тәмам хәлдән тайдырды, хәтта һәртөрле төнәтмәләрнең дә ярдәме азая барды, ә көннәрнең берендә ул ятты да кабат торалмады... Ләкин бу әҗәл булып чыкмады, әйтерсен, Ходай Тәгалә анын тереләр арасында гомер итүен хуп күреп, яшәр һәм эшләр өчен ял бирергә тели иде. Мәрттә булып кайткач, сары йорттагыларның мөнәсәбәте икеләтә начарланды, карчык инде башка урынга күчү турында уйлана, шуна жай эзли башлады. Шулай эзләнеп йөргән көннәрнең берсендә ул Мәрьямне очратты. Могжиза белән бала табып, сабыен үстерү хакына дусларыннан, житеш тормышыннан, хәтта әти-әнисеннән баш тарткан Мәрьямнең батырлыгы аны хәйран итте. Бу яшь хатын сары йортларда кол булып яшәүчеләрнең барысыннан да өстен иде. Яхшылыкны анлый, бәяли белә торган, үзе дә яхшылыкка омтылучы гүзәл зат иде ул. Һәм карчык

аны үзе янына чакырды. Мәрьям баласы терелгәнче генә торыр да китәр, сары йортлардагы мәхшәргә түзә алмас, дип уйлаган иде. Ә ул чакта, чынлап та, коточкыч хәлләр хөкем сөрә иде: кешеләр карчыкның үзен генә түгел, этен дә күрә алмадылар, кемдер аны агуларга теләп ишек алларындагы эт тәлинкәләренә агу сибеп чыкты да тирә-юньдәге бөтен маэмайларны кырып бетерде. Бер күршесе йорт тирәләренә капкыннар куеп чыкты, аңа бүтән күршеләре эләкте... Шул рәвешле астыртын явызлыкларның чиге булмады. Тик карчык, чиксез гыйлем иясе булганлыктан, кайларда афәт барын, хәтта аны кемнәр әзерләгәненә кадәр сизеп-тоеп торды. Шуна да исән котылды. Мәрьямне үзләренә алып килгәч тә өеннән бик чыгармаска тырышты, күршеләрнең юньсезлеген белмәгәнлектән, ул әллә нинди бәла-казаларга эләгергә мөмкин иде. Бермәлне кешеләр ничектер тынычланып калды, шунда гына ул Мәрьямгә чыгып йөрергә рөхсәт итте. Мәрьям ачык күнелле, саф йөрәкле гүзәл кыз иде, шуңа да карчык аны күршеләре белән ешрак аралаштырырга тырышты. Бәлки, алар белән татулашып алса, ике арага күпер салучы да булып китәр дип өметләнде. Тик Мәрьямнең күренүе кешеләрне тагын куркуга төшерде... Ләкин гомер буе үз фатирында бикләнеп яту мөмкин түгел иде. Бермәлне алар бергәләп чыгып йөри башладылар...

Мәрьям китмәде, үзенә изгелек кылган Мәдинә карчыкның сердәшкә, ярдәмчегә мохтажлыгын ул яхшы белә иде. Аннан соң, шундый гыйлемле кешедән күп нәрсәләргә өйрәнергә дә тели иде кыз. Баласы имчәктән аерылып күп тә үтмәде, Мәрьям авырып китте. «Монда мин генә ярдәм итәлмәм, операция кирәк, балам»,—диде Мәдинә карчык, аны тикшереп карагач һәм больницага илтеп урнаштырды...

Яшен йөзгә якынлашканда нәни бала карау җиңел түгел иде, шулай да Мәрьямнең әти-әнисе: «Безне тыңламады, баласын больницада гына калдырмады, хәзер теләсә нишләсен»,—дип бусагадан борып җибәргәч, карчык малайны күтәреп кабат сары йортларга кайтты. Тик фатир ишеген ачарга иткәндә, янындагы тугры дусты, овчаркасы, беләгенә асылынды, ишеккә якын да җибәрмәскә тырышты. Мәдинә карчык бөтен гыйлемен җыеп, бөтен сәләтен җигеп нәрсә булганын ачыкларга тырышты һәм эшнең асылын аңлагач, авыр көрсенеп, икенче каттагы фатирга юнәлде. Мәрьям дә күренгәч, кешеләр кабат котырына башлаган иде шул. Капкыннар, агулар һәм башка астыртын явызлыклар тагын хәрәкәткә килгән иде. Ләкин бу кадәр үк юньсезлеккә барырлар дип башына да китермәде карчык. Аның фатирына кемдер ачкыч ярату кереп (ә ишектәге инглиз йозагын тутык кадак белән дә ачып була иде) ике ач эт калдырып киткән иде. Моның ни өчен икәнен аңлый алмады Мәдинә карчык. Ләкин аның сиземләве буенча бу этләр үтә дә явыз заттан, кешеләргә зыян салыр өчен махсус өйрәтелгән ерткычлар булырга тиеш иде. Аны, йөзгә житеп килгән карчыкны, үтерергә дә мөмкин инде, әмма алма кебек хатынны, яшь баланы эткә ашатырга теләмәгәннәрдер бит инде. Моның кем эше икәнен дә тикшереп тормады ул. Бер-ике көннән соң эт өргән тавышлар жанына ук тия башласа да, күршеләренә берни сиздермәде. Әлеге эш кемнең явызлыгы булса, үз гамәленең нәтижәсен күрер өчен иң беренче булып шул бәндә киләчәк иде.

Этләрнең өрүе көчәйгәннән-көчәя барып, атнага якын вакыт үтүгә теге вакытта эченнән бармак зурлык кара корт чыккан адәмнең алтынчы подъездга керүен күрде. Тиздән ачтан котырып чиккә житкән этләр кара яу куптардылар да бераздан тынып калдылар. Ә кеше кире чыкмады... Мәдинә карчык бу адәмнән элек бераз шикләнә иде, ләкин үзе үлемнән алып калган кешенең шундый ерткычлыкка бара алуына барыбер дә әле ышанып житмәде. Башкаларны нахак жәзадан кисәтергә теләп ул эскәмиядә утыручылар янына атлады, ә тегеләр, пәри күргәндәй, куркышып таралыштылар. «Этләр бар минем фатирда!—дип кычкырды аларга Мәдинә.—Анда кермәгез. Сак булыгыз...» Кешеләр аны әллә ишетте, әллә юк. Күптән инде алар карчыкка илтифат күрсәтмиләр иде. Шуннан соң ул фатир ишекләрен шакыды: «Этләр бар минем өйдә! Кемдер этләр керткән! Сак

булыгыз! Сак бул...» Кешеләр ишек ачмадылар, әмма аның тупас тавышын ишетми калмаганнардыр. Икенче көнне ул, нәни баласын күтәреп, яшәр урын эзләргә чыгып китте.

Аның алтынчы подъездда күптән яшәмәгәнен белмәгән кешеләр һаман һәртөрле явызлыклар корды һәм үз капкыннарына үзләре эләгеп һәлак була торды. Аларның җанын бигрәк тә этләр өрүе өзгәләде һәм кыюрак кешеләр карчыкның фатирына ачкыч ятатып керде дә... кабат чыгалмады...

Карчык җиргә сеңгән кечкенә бер йортның бер бүлмәсендә вакытлыча урын табып (Мәрьям әле больницадан чыкмаган иде), сабый белән шунда яшәп торды, ә этен өйгә кертергә рөхсәт итмәделәр. Шунлыктан аның күңеле бик үк тыныч түгел иде. Хуҗалар башта аларны кызганып кабул итсәләр дә, бала мәшәкатьләреннән тиз ялыктылар һәм үзләренен үпкәләрен тәүдәрәк читләтеп, сонрак турыдан-туры белдерә тордылар. Ахыр чиктә, Мәдинә карчык бу бүлмәне дә калдырырга мәҗбүр булды. Сабыен күтәреп, этен ияртеп сары йортның алтынчы подъездына кабат кайтты. Кешеләр аның китүен тоймаган кебек, кире кайтуын да сизмәделәр.

... Мәдинә карчык аны өч көн алдан сизде. Ул җанына тынгылык тапмады, тамагына аш үтмәде, күзенә йокы кермәде. Күңелендә көчле дулкын кубып, үткән бөтен гомерен айкады. Соңгы вакытларда ничектер онытылып торган газиз кешеләрен уйлап сагынды, бәхетле балачагын, үсмер елларын, тәүге мәхәббәтен, кичергән шатлык-кайгыларын йөрәгеннән кабат үткәрде. Ничектер, үз-үзенә урын тапмады ул, шундый чакларда үз хисләрен сабый балага сөйләде дә: «Эх, синен дә телен юк бит, ичмаса, бер серләшер идек туйганчы» дип, аны күкрәгенә кысып иркәләде. Бу кечкенә малай да Мәрьямнеке түгелдер, ә үз улыдыр сыман тоелды. Бар дөньяны тетрәтеп, агачларны тамырыннан йолкып, йорт-кураларны, завод моржаларын җимерердәй дәһшәтле өермә иң тәүдә Мәдинә карчыкның күңелендә купты. Өермә икәнен ачык кына белмәсә дә, ул шушы арада ниндидер афәт буласын көтте. Ул афәт карчыкны бик куркытмады, ул үзен ни өчендер аннан кодрәтлерәк итеп тойды. Менә бер дәлиле булмаса да, үзенең шул һәлакәтләрне туктата алачагына бар булмышы белән ышанды. Алай гына да түгел, ул үзенең дөньяга килүен нәкъ әнә шушы фаҗигане туктатыр өчен дип бәяләде. Шәһәр читенә якынлашкан көчле өермәне күргәч, ничектер кәефсезләнеп куйды, ул үзендә заман ахырын җиңәрлек көч тоя иде бит, ә монда ниндидер гади бер торнадо, тик нишләмәк кирәк инде хәзер, димәк, язмышын шуннан һәм карчык сабый белән этен фатирында калдырып өермәгә каршы атлады...

Якынлашып килгән дәһшәтле давылга каршы киткән карчык һәлак булачак һәм без кабат элеккечә яши башлаячакбыз, дигән сәер өмет ялтлап китте сары йортларда яшәүчеләр күңелендә. Ләкин өермә нечкәргәннән-нечкәрә барды, кара төстән ул алтынсуга әверелде, яралы ерткыч гүләве моңлы бер авазга әйләнде һәм менә шушы сихри күренеш карчыкны нурлы бер алиһә итеп күккә күтәрде...

Карчыкның үлеме сары йорттагыларга искиткеч зур шатлык алып килде, аның үле гәүдәсен тапкандагы кебек үк тилереп бәйрәм итмәсәләр дә, үзләренең яшәү тәртибен бозган бу явыздан котылудан һәркемнең күңеле куаныч белән тулы иде. Әмма бу халәт озакка бармады, аны алтынчы подъезддагы этләр тавышы бозды. Элегрәк бу тавыш бер сүрелеп, бер дулап торым-торымга кабатланса, хәзер ул көннән-көнгә көчәя барды һәм явыз карчыкның һаман да исән булуына шик калдырмады. Болай да коты алынган халык һуштан язар дәрәҗәгә җитте, алар төннәр буе керфек какмадылар, тамакларына ризык үтмәде, куллары эшкә бармады, үзләрен вокзалдагы кебек хис иттеләр, гомерләрен тагы бер кат әнә күзеннән үткәреп эчке бер тетрәнү белән ниндидер бер фаҗига, фани дөньяның тәмугы булырдай афәт көттеләр. Кайчагында этләр өрмидер, этләр бу кадәр үк булдыра алмыйдыр, ә бу тавыш аларның колагына гына ишетеләдер сыман тоелды. Этләр өрүе аларның җанын талады, сары йортларда яшәүчеләрнең кайберләре акылыннан шашып башын стенага бәрде, алар өчен яшәү дә үлем дә түгел, ә шушы

тавыштан котылу мөһимрәк иде. Әлеге газапка чыдарлыгы калмаган кешеләр жыйнаулашып серле фатирга юнәлде, әмма кәтмәгәндә каршыларына килеп чыккан чибәр кызны күреп туктап калдылар. «Бу гади кыз түгел иде, бу гүзәл кыз кыяфәтенә кергән сихерче карчык иде...»

... Мәдинә карчык мона кадәр көн саен диярлек, һич югында да, атнасына берәр кабат сабыйны күтәреп, Мәрьямнең хәлен белеп китә иде, ә соңгы вакытта бөтенләй күздән югалды. Бу югалу озаккарак сузылгач, хатынның түземлеге калмады, хәле бик үк яхшыдан булмаса да, больницадан качып чыгып сары йортларга юнәлде. Болай да хәле авыр кешене борчымыйм дип, карчык аңа фатирдагы этләр һәм үзенең икенче катка күчүе хакында әйтмәгән иде. Алтынчы подъездга житү белән Мәрьямнең күңелен шом басты, мона кадәр Мәдинә карчыкны дошман күргән кешеләр аның бусагасы янында тора иде. «Бер-бер бәла-казага юлыктылар микән әллә?»,—дигән уй Мәрьямнең йөрәген телеп үтте һәм ул жыелган халыкка бер генә караш ташлады да атылып подъездга кереп китте...

Юк, ул ерткычларча өргән этләрне ишетмәде дә, алар кайгысы түгел иде, ул газиз баласы, анасы урынына калган Мәдинә әби өчен яна иде. Фатир ишеген ачып та жибәрде, ачлыкның соңгы чигенә житкән ике ерткыч аның өстенә ыргылды да. Мәрьям сүз әйтергә генә түгел, уй уйларга да өлгерә алмый калды... Ә берничә минут үтүгә баскыч мәйданчыгында сылу яшь хатынның ботарланган сөякләре генә ята иде инде...

*«Коточкыч күренеш иде бу, туган, коточкыч күренеш иде. Тик монысы баласы гына булган икән әле, карчыкның фатирына узгач безне мәхшәр каршы алды. Идәннәр катып беткән канга буялган, әле анда, әле монда кеше башлары, кабыргалар, аяк-куллар чәчелеп ята, алар арасында без югалган күршеләребезнең сәгатьләрен, йөзекләрен, ертык кием кисәкләрен таптык. Ләкин кайсы кемнең сөяге икәнен генә аера алмадык... Юк, карчыкның өенә керү безгә тынычлык өстәмәде. Колакларыбызда чыңлаган эт тавышлары икеләтә көчәйде, аңа корбан булган күршеләребезнең жан өзеп кычкырулары өстәлде; аларның идән буйлап сибелгән сөякләре күз алдыбыздан китмәде. Без атналар буе табынга якын килә алмадык, өстәлдәге ризыклар кеше ите булып күренде, су эчсәк тә кан эчкәндәй булдык. Без тәмам хәлдән таеп, гәүдәләребезне дә күтәрә алмас хәлгә життек, өн белән төшләр буталды, үзебезнең теге дөньядамы, монысындамы икәнлегебезне оныттык. Без кояш нурларын да, төн карасын да күрмәдек, күз алларыбызны соры томан басты. Без бу мәхшәрдән котылырга теләдек, тик ничек икәнен генә белмәдек...»*

Карчыкның фатирында чәчелеп яткан сөякләрне жирләгәч тә тәүге мәлләрдәге тетрәнүләр бераз үтә төшсә дә, кешеләр инде тамагына ризык кабар, эскәмияләргә чыгып сөйләшеп утырыр хәлгә килсә дә, күнелләрендәге шом басылмады, алтынчы подъезддан бала елаган, эт өргән тавышлар тынмады. Ул инде элеккечә жанны тырмап акылдан шаштырырлык дәрәжәдә булмаса да, ара-тирә ишетелеп-ишетелеп кала, хәтәр көннәрне искә төшерә һәм афәтләрнең моның белән генә бетмәячәген искәрткәндәй тоела иде.

Сары йорттагылар карчыкның сау-сәламәт килеш жирдә, үзләре арасында, нинди дер кыяфәткә кереп яшәп ятуына шикләнмиләр, гомумән, алар бу карчыкның үлү мөмкинлегенә ышанмыйлар, аны гади кеше итеп түгел, ә бөек хөкемдарның ихтыярын үтәр өчен адәм балалары арасына жибәрелгән бер вәкил дип исәплиләр иде. Ә подъезда сирәк-мирәк ишетелеп калган тавышлар аның үлемсезлеген кабатлаучы бер дәлил кебек иде. Кешеләр анда эт кыяфәтендәге баламы, бала кыяфәтендәге этме—нинди дер сәер кеше-жәнлек күрүләре хакында берсеннән-берсе хәтәррәк хәбәрләр сөйләде. Бер эт белән бер бала төннәрен ишек алдына чыгып йөри имеш, алар эт булып та өрә, кешечә дә сөйләшә, имеш... Ничек кенә сәер тоелмасын, бу хәбәрләр дөрестән дөрес иде, Мәдинә карчыкның акыллы овчаркасына ияреп кешеләр арасында эт тормышы белән гомер итүче малай Мәрьямнең гөнаһсыз яралган улы иде.



## Мөдәррис Әгъләм

### ХОДАЙ БИРДЕ БЕЗГӘ ЯРЛЫКНЫ...

**Нәкъ шул кичтә**

Әллә инде бер фаҗига булып,
Әллә инде бәхет булыпмы,
Дөнья яратылгач яратылган
Изге сөю безгә юлыкты.

Элек ханнар ярлык бирә булган,
Язмыш безгә ярлык бирмәде...
Сиңа—парлык бирде,
Миңа—парлык бирде,
Юклык бирде,
Барлык бирмәде.

Ә барыбер сөенеп яши алдык
Икебезнең җирдә барлыкка.
(Төкердек без элек ханнар биргән
Бүген кыйммәт торган ярлыкка.)

Ник кирәк ул ярлык
Шигъри сафлык,
Пакьлек,
Саклык,
Хаклык бирмәгәч.
Кавемеңнең бөтен халыклары
Шул ярлыкка башын имәгәч.

---

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ *(1946)—шагыйрь, «Учак урыннары», «Киләчәккә кайту», «Иман тәрәз шакый», «Кан тамырын кистем» һ.б. шигырь китаплары авторы. Г. Тукай премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Талашкан да булабыз бит әле.
Син—Атабай кызы,
Мин—Зәйдән.
Син: Ярдан сикерәм,—дип кычкырасың,
Мин: Ташлана дип, канат киңәйгән...

...Һәм кинәт бер шаукым булып ала
Җир тетрәнә кебек шул чакта:
Икебез дә шаулап көләбез дә
Ташланабыз уртак кочакка...

...Менә бүген җан әчесе белән
Кычкырасы килә:
Ко-чак-ла...

Ә шул кичтә,
күккә ашкан кичтә
Без кичердек сөю барлыкны.
Элек ханнар ярлык биргән ич, ә?
Мәхәббәттә безгә нәкъ шул кичтә
Ходай үзе бирде ярлыкны.
...Без аңладык Сөю барлыкны.

## Соңгы юаныч

Соңгы тапкыр күрешергә дәштең,
Башны кыстым, тыялмадым яшьне.
Аяк тартмый.
Бара алмадым.
Мөһим түгел, син картмы, бик яшьме—
Егет булып кала алмадым.

Белә идем авыр буласыны,
Калсын дидем алда гүзәл сының.
Ничек булган
Нәкъ шул хәлендә.
Бер миңа да килер гомер соңы,
Белмим нинди кимәлләрендә.
Баралмадым, әмма барачакмын,
Мәңгелеккә бергә калачакмын,
Баралмаганыма үч итеп.
Әле азмы газапланачакмын,
Синең чакыруны ишетеп.

Аккош күлендәге шул йорт тора,
Үткәндер күк бары минут кына,
Тулы гомер аккан ишелеп.
Елмаясың әнә тоныкк кына,
Ауган агач кебек киселеп.

Бер сөенеч иден, бер куаныч
Дөрес булды микән без кылган эш,
Кабатланыр сыман тагын бер.

Күңелемдә яши бер юаныч:
Барачакмын сиңа барыбер.

## Син алмадың, алалмадың аны

Әни шулай, әти шулай китте...
Туйдым. Туйдым чирдән... һаман чир.
Балаларым житте дигәч кенә
Ник кагылган сиңа яман чир.

Юк, фажига түгел иде миңа
Башка белән дөнья коруың;
Кирәк иде алган максатыма
Житкәнемне карап торуың.

Юк, еладым димим, еламадым—
Мин үземдә үзем булмадым.
Кулга каләм түгел,
Шәраб кенә
Күтәрәлдем, бәгырь, ел ярым.

Тыштан тыныч,
Эчтән актарыла,
Белгән генә аңлар хәлемне...
Үз-үземне авызлыклаганда
Мин бит беләм кемлекләремне.

Кайчагында усал булса сүзем—
Үзем, күзем тулы моң гына...
Туктап торсам
Бу—ышаныч өчен
Дөрес юлдан барганлыгыма.

Син нишлисең? дигәч, әжәл күзен
Әйләндереп кенә карады.
Әйтерсең лә ул погонлы бәндә,
Ә мин исә кесә карагы.

Юк, юк, әжәл, син алмадың аны,
Иле чирле... Илдә һаман чир.
...Яңа бала—яңа булыр, дибез,
Һәр яңа туганы —яман чир.

## Танышу

Бу ажунда аерылу бабыдай
Танышу да кызык...
Без очрашкан урам исеме дә
Сәер—Кызыл Сызык.

Сызык, дигәч, май сызыгы түгел,
Утлы сызык иде—
Яшьлек белән һәм юләрлек белән
Барсы кызык иде.

Борынгы бабайлар җилеп кенә
Менгән кебек атка
Без тулай торакта очып йөрдек—
Йөрдек каттан-катка.

Кино, дисәк, тоташтырып торды
Асылмалы күпер.

Ярлылык та, байлык та юк иде—
Анысына да шөкер!

Һәр почмакта Зөһрә елап кала,
Суда ага Таһир.
Бер катта ун бүлмә булса—
Бүлмәдә өч шагыйрь.

Әгәр шигырь сөйли башласалар,
Бетер генә йотып,—
Һәр кызда Зөләйха яши иде,
Һәр егеттә Йосыф.

Өч катлы диварда яши
Мәхәббәти бер җен.
Бер бүлмәдә Ләйлә йоклый алмый,
Бер бүлмәдә—Мәҗнүн.

Әле хәзер ис-акылым китеп
Шаклар катып йөрим:
Өске катта Фәрһад тора иде
Аскы катта—Ширин.

Без дә шулай шашып сөю тоттык,
Сәер булды.
Кызык...
...Менә хәзер... тагын ... соңгы урам.
Соңгы—Кызыл Сызык.

## Җитәкләшеп

Күзе күз генә идеме,
Гүя безнең яшьлек.
Очраштык та китап кибетендә
Бер-беребезгә дәштек.

Әйтерсең лә үсеп-җитеп килми
Кызыбыз—улыбыз.
Гайбәтләргә бер генә төкердек:
«Бәхетле булыгыз!»

Игътибар да итми хатын-кызга,
Затлы ир-затына,
Җитәкләшеп икәү китеп бардык
Татар зиратына.

Мәрҗани, Камал, Тукайга,
Карига баш идек,
—Һәм сөендек әле үзебезчә:
«Ярый ла баш идек!»

Кайчан әле бергә бу зиратка
Зиярәт кылар идек.
Әле кайчан үткәннәрне буйлап
Уйлап елар идек.

Кан тамырларында җен йөгерде:
«Гөнаһ та кылыгыз!»
Намус, Вөҗдан әйтте: «Аерым-аерым
Бәхетле булыгыз!»

Аерым узар ике гомер шулай
Мәңгелеккә дәште...
...Безнең белән җитәкләшеп кайтты
Казаныма—яшьлек.

## Килдек без яланаяк...

Бәрхет чүпрәктән тегелгән
Аяк киемен аяп,
Бәрәңге түтәле казыйм—
Казыймын яланаяк...
(Элек мондый хезмәтеңә
язалар иде «таяк».)

Әнисе чыгарып бирә
Кәлүшле киез ката.
Лүзиям көлә тәгәрәп
Түтәлгә ята-ята.
(Сукмактагы радио гына
Мәскәүчә акыл сата.)

Мәскәү ул кемнең бәрәңге
Алганын белми әле,
Татарның Лүзияләре
Калганын белми әле.
(Алар барында бу татар
Үлми ул, үлми әле.)

Атабайда шундый рәхәт,
Без, гүя, кияү-кәләш...
Ник кирәк аның дөньясы,
Яхшыга үзгәрмәгәч...
(Мәскәве нигә кирәк соң
Богаудан җибәрмәгәч.)

Барыбер шулкадәр рәхәт,
Без инде җиде күктә—
Саф кызлык та, саф егетлек
Бу көзге тирәлектә.
(Шулай бәрәңге алыр күк
Алар гел мәңгелектә.)

Бәрәңгесе бәрәңгеме?
Татарча—бәләк-бәләк...
Безгә дә кирәк тимәгән,
Китсә дә имгәткәләп.
(Әниебез яхшы аңлый
Яшьләрдә нинди халәт.)

Атабай, әнә, тып-тыныч,
Тәрәз янында чия:
—Сез әнә чәчәк атасыз,
Мин быел беттем, дия.
(Ул да бит безгә елмая,
Көзлеген кия-кия.)

Шулкадәр рәхәт... яшьлектә
Рәхәт бик азга төшә.
Ә гомер?... бәрәңге сыман,
Гөбердәп базга төшә.
(Өлгерү—көзгә төшә шул,
Чәчәк чак—язга төшә.)

Ни генә димә, дан булган
Бәрәңге алулары,
Атабайда бәрәңгедәй
Тәгәрәп алулары.
(Ә бит бу безнең яшьлекнең
Шигырьдә калулары.)
...Мин бүген Аккош күлендә,
Үземне аяп-аяп,
Катлы-катлы итек киеп
Җир казыйм...
Ә күңел—яланаяк.



## Суфиян Поварисов

# ОҖМАХКА БЕР АДЫМ

РОМАН

### Беренче бүлек

Галимҗан Ибраһимовны «халык дошманы» дигән гаеп тагып, 1937 елның 29 сентябрендә кулга алдылар.

Бу вакытта ул Ялтада яши иде әле.

... Шәһәрнең үзенә генә хас асыл сыйфатлары шактый. Әллә кайдан килгән кемсәләрне дә якты йөз белән каршылап, аларны җылы кочагына ала.

Биредә кояш нурлары да башка. Күңелгә ләззәт, тәнгә сихәт, җанга тынычлык, йөрәккә ял, рухка илһам бирә торган шифалы нурлар.

Анын күге дә башка җирдәгегә караганда биегрәк кебек. Табигать, әйтерсең, тын алырга иркенрәк булсын өчен шулай эшләгән. Җир—йомшак түшәк, йолдызлар белән чигелгән Күк—бизәкле юрган. Күкнең аръягында оҗмах бар кебек.

Бу урындагы шифалылыкны «Һава» дигән бер сүз белән генә дә аңлаталар. Һава үзе дә дәва. Шифалылыкның күк аръягыннан килүе турында да күп риваятьләр бар. Бу дөрестер, бәлки. Тукай әйтмешли: «Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул».

Менә шушы «Һава—дәва» булган урында Галимҗан Ибраһимов 1927 елдан бирле яши инде. Казанда Газраил аның якасына килеп ябышты, урынга ук салды. Әмма Галимҗан Ибраһимов бирешмәде. Моңа чаклы булган гаярьлеген, рухи вә җисмәни көчен күрсәтергә тырышты. Ана Казанның иң мәшһүр табиблары ярдәмгә килде. Газраил бер мәлгә чигенде. Шулай да Галимҗан Ибраһимовны аякка бастырырга көчләре җитмәде Казан табибларының, Кырымга китәргә киңәш иттеләр. Аның өчен хәзер һавасы дәва булган «җир җәннәте» Ялтада яшәүдән башка чара юк.

---

Суфиян ПОВАРИСОВ *(1924)—язучы, филология фәннәре докторы. «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Язмыш корбаннары» һ. б. китаплар авторы. Уфада яши.*

Ул чакта Казан җәмәгатьчелеге арасында каршылыклы фикерләр йөрде. Бәгъзе берәүләр нык шатланды: Ялта аның авыруын ялт иттереп алып ташлаячак; икенчеләр башкачарак фараз кылды: ай-һай ла, барып житә алырмы, бик беткән бит, тире дә сөяк кенә; юл газабы-гүр газабы, шактый ерак ара лабаса, дип кайгырышты алар.

Чыннан да, Ялта һавасының дәва икәнлеген беренче көннәрне үк сизде Галимҗан Ибраһимов. Рәхәтләнеп, күкрәк киереп, илаһи бер мөкиббәнлек-хозурлык белән сулыш алырга мөмкин икән бирелә. Һәр йотым һава—үзе бер зур дәва!

Әлбәттә, табигать ул—көйсез кияү белән бер. Ялтада давыл-гарасатлар да булып тора. Менә бүген иртәнге саба җиле Галимҗан Ибраһимовка гомер вәгъдә итеп исте, кичке сәҗдә җиле исә аның яшәү өметен кисте.

Төн урталарында, эштән арыгач, утны сүндереп, инде ятарга дип торганда, кемдер ишек шакыды. Өйдәгеләр гаҗизләнеп калды. Кем булыр? Төн заманында бер дә ишек какканнары юк иде ләбаса. Галимҗан ашыгып киемнәренә үрелде, Хәдичә ханым кабалана-кабалана ут кабызды, күлмәген кияр-кимәстә үк ишеккә атылды. Шаку янә кабатланды, аннан көчле дөберд әүгә күчте; ишекне кемдер йодрык белән алагаем дөмбәсли иде. Юньле хәл түгел бу. Хәдичә ханым калтыранган, йомшак тавыш белән: «Кем бар?»—дип сораганга: «Открой!»—дигән дорфа тупыклы тавыш яңгырады. Ишекне ачуга бүлмәгә атылып хәрби кешеләр килеп керде. Алар өчәү иде. Кем икәнлекләрен киемнәре үк әйтеп тора—НКВДдан... Берсе—колгадай озын буйлысы—эчке кесәсеннән кәгазь кисәге алып, аны Галимҗанга тоттырды. Казан прокуратурасы биргән язуда Галимҗан Ибраһимовның фатирында тентү үткәрү, аннары аны кулга алу тиешлек күрсәтелгән. Күз йөртеп чыккач, Галимҗан аны «колга»ның үзенә кире кайтарып бирде.

* * *

Фатир ике бүлмәле иде. Алгы яктагысы—бер тәрәзәле. Уртада—бәләкәй генә өстәл. Ишектән кергәч, уң якта—шактый дөнья күргән кечкенә кәнәфи, сулда—тимер карават. Хәдичә ханым шушы якта йоклый. Эчке бүлмәнең уң ягында—китап шкафы, сул ягында—Галимҗан Ибраһимовның йокы караваты. Уртада—язу өстәле.

Чакырылмаган кунаклар башта ике бүлмәне, кухня, веранданы җентекләп карап чыктылар. Алар, әйтерсең, өлкән язучы фатирына түгел, азау ярган җинаятьче йортына килеп эләккәннәр. Күзләре уттай яна, бер басасы урынга биш басып, «уф» дип тә куялар: йортны пыр туздырып нидер эзлиләр, актаралар.

Шулай, бераз сөмсез сыердай кыланып алгач, «колга» үз дәрәҗәсен хәтәр саклап, алгы бүлмәдәге өстәл артына килеп басты. Буе аның һич тә килбәтсез түгел болай. Кара-кучкыл чибәр йөзендә горурлык, масаю, үз-үзен нык ярату билгесе бар. «Мин мин микән, мин кем икән» дигәндәйрәк, кукраеп тора. Башындагы яшел кырпулы фуражкасы аның горур табигатен көчәйтә кебек. Карлыгач канатыдай куе кашлар, очкын чәчеп торган кара күзләр, беренче карашка, аны мәхәббәтле ир-егет итеп күрсәтте сыман. Тукта, бу бит таныш йөз! Кайда күргән иде аны Галимҗан? Уфада, «Галия» мәдрәсәсендә укытканда булса кирәк. Әйе, әйе, бу аның шәкерте... Әй, каһәрең, исеме онытылган инде. Хәер, аның ни хаҗәте бар хәзер. Мәгәр башсыз түгел иде шикелле. Галимҗан Ибраһимов оештырган әдәби кичәдә Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Шәехзада Бабич кебек шәкертләр белән булган шигърият кичәсендә чыгыш ясаганы исендә. Хәзер аңа кырык яшьләр булыр. Шулай да төс ташламаган. Ул чакта Галимҗан Ибраһимов, татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, киләчәктә әлеге шәкертенең әдәбият мәйданында теге яки бу дәрәҗәдә шөһрәт казаначагына ышана иде. Менә тәрәкә, исеме дә кылт итеп искә килеп төште: Мөбарәк. «Кадерле», «бәхетле», «хөрмәтле» дигән мәгънәле исем...

«Галия» мәдрәсәсендә Галимҗан Ибраһимов 1915—1917 елларда укытты. Әдәби әсәр хакында шәкертләр шактый күп беләләр. Әмма шуларның һәммәсен җентекләп-җыйнап аңлатып бирү өчен әдәби, сәнгатьле тел җитешми. Татар халкының тел гәүһәрләре Казан тирәсендә тупланган. Бу—милләтнең уртак хәзинәсе. Аналарның имчәк сөте, күңел рухы, кайнар сулышы, йөрәк ялкыны, бишек җыры, хис-моңы, изге тойгылар илаһилыгы, яшәү өмете, аталарның ыру-кавем-кабилә, ил-көн, ватан, балалар, оныклар бәхете, киләчәк иминлек, җир, дөнья язмышы өчен кискен, каты, аяусыз көрәшләрдә түккән кан кайнарлыгы сеңгән кыйммәтле, кадерле, газиз тел ул! Мөбарәк исә мишәр малае, сөйләме зәгыйфь иде. Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш, Шәехзадә Бабичларга ияреп шигырьләр, вак хикәяләр дә языштырганы хәтерендә Галимҗанның. Шагыйрь, язучы тел дингезенә каткат чумарга, аның төбенә үк төшәргә, андагы сүз гәүһәрләрен җыеп, шулар белән укучы күңеленә рухи азык, татлы тәм, зәвык, мәгънә, фәһем, рух бирердәй әдәби әсәрләр иҗат итәргә тиеш. «Галия» мәдрәсәсендә каләм тибрәтүче өметле шәкертләрдән милләт йолдызлары ясарга тырышты Галимҗан. Мөбарәктә шагыйрьлек ул кадәр сизелми иде. Ә менә вак-төяк көлкеле хикәяләре әдәбият күгендә нинди дә мөмтазлык[1] яуларга ышандыра иде шикелле. Шәехзадә Бабич белән дуслашып китүләре дә шуннан килә иде булса кирәк. Чөнки Бабич юмористик, сатирик әсәрләрен укыганда, шәкертләр, аһ-ваһ килеп, эчләре катканчы бер көлеп алалар иде. Әмма ялкау иде Мөбарәк. Ялкау, йөрәксез, хис-тойгыларга ярлы кешенең язучы булуы мөмкин түгел. Бу—хакыйкать.

«Галия» мәдрәсәсенә мөгаллимлек итәргә килгәнче үк Галимҗан Ибраһимов татар, башкорт һәм башка төрки телле халыклар арасында мәшһүр язучы, көчле тәнкыйтьче, нәфис сүз сәнгате остасы, сарыф (морфология), нәхү (синтаксис) фәннәре буенча уку-укыту әсбабы язган тел галиме, тарихчы, педагог, методист, әдәбиятчы, сөйләм сөрешенең иң нечкә серләрен җитди белүче өслүбче-стилист буларак таныткан иде инде үзен.

Шәкертләрне белемле итү өчен йөрәк канын тулы килеш бирергә әзер торган Галимҗан Ибраһимовның мәдрәсәдә дә абруе тиз күтәрелде.

Дөнья куласа, әйләндереп китереп бер баса, дигәне шушыдыр инде. Шәкерте остазы муенына «халык дошманы» дигән хурлыклы камыт кидерергә маташа менә. Мөбарәк мактанчык иде. Ялагайлану гадәте дә бар иде. Заманның яман агышына җайланып, иблислек вәсвәсәсенә бирелгән дә, остазы каршында кәпрәеп тора хәзер.

Болай уйларга аның хакы бармы соң? НКВД бүгенге көндә ил йөрәгенә әйләнде бит. Ул тәртип сакларга, бозыклыкларга каршы көрәшергә, совет иле мәнфәгатен якларга тиеш. Тик теләсә нинди әрсез ояламасын иде НКВДга. Хәтер бер эшләсә эшли икән. Колчак тылында разведчик булып йөргәндә дә күргән иде бит Мөбарәкне Галимҗан. Күрү генә түгел, маңгайга-майгай килделәр. Ул чакта Колчак армиясе офицеры иде Мөбарәк. Энгер вакыт иде. Мөбарәк исерек иде булса кирәк, алама киенгән, сакал-мыек җибәргән остазын танымады ул. Мәгәр бик дорфа кыланып, юлына килеп чыккан Галимҗанны якасыннан алып җилтерәткән иде. Телендә гел кабахәт сүз. Шундый кеше уйныймы хәзер аның язмышы белән?

Әлбәттә, кулына тимер богау салыначак кешенең егерме еллар элек үзенең остазы булганлыкны белеп килгән ул. Ә менә аны «халык дошманы» дип исәплиме? Әллә, Галимҗан үзе уйлаганча, моны бер аңлашылмаучылыкка санарга да акылы җитәме?

НКВДдан килгән икенче хәрби, кыска буйлы, әмма мичкәдәй юан, урта яшьләрдәге шадра бер кеше иде. Ул, папкасыннан кәгазь-каләм алып, өстәлнең икенче бер ягындагы урындыкка—Мөбарәккә каршы урынгарак чүмәште.. Бусы, күрәсең, протокол язарга тиештер инде. Өченчесе корыган талдай какча гәүдәлесе эчке бүлмәдәге китапларны өстәл өстенә ташырга керешге. Мөбарәк китапларны саксыз актарып, караштыра да шадрага

[1]Мөмтаз—үзгә, юры, өстен, башкалардан аерылып торган.

нидер әйтә, тегесе аның сүзләрен кәгазьгә теркәп куя.

Бу шөгыльнең бик озакка барачагын аңлады Галимҗан Ибраһимов. Ни-нәрсә кылырга ана хәзер? Алар эшенә тыкшыныргамы? Юк, ярамый. Ә чир үзенекен итә: хәлсезләндерә, изә. Шулай да бирешмәскә тырышты ул. Яна ак күлмәгенә килешә торган зәңгәрсу галстугын тагып маташты, күксел костюмын киде. Хәдичә ханым исә иреннән бер адым да китмәскә тырыша. Аларнын үзләрен тыныч тотулары Мөбарәкнең ачуын кабартты:

—Хазиргә сиз ытырып турыгыз, мешать итмәгез, пунимаешь,—дип, мишәрнеке белән урысныкын боламыктай болгатып берничә сүз җикерде дә, зәнки күзләрен әйләндереп, «остазы»на карап алды.

Аларнын карашлары очрашты. Тик бик аз вакытка. Мөбарәк «остазы»нын хәлсез, алжу, ике янагы эчкә баткан ябык йөзен күреп хәйран калды. «Бу инде ашын ашаган, яшен яшәгән кеше» дигән уйдан Мөбарәк, чыраен сытып куйды. Зиһенле остазы элекке шәкертенең аның хакында нindirәк фикердәрәк торуын тиз чамалап алды. Нидер әйтмәкче булды, тик теле тибрәнде—сүзе чыкмады. Хәлсезләнеп, чайкалып китте. Егылып китүдән аны Хәдичә тотып калды. Бу юлы «колга», миһербанлык күрсәтергә теләгән булып, Хәдичәгә эндәште:

—Хале биткән бит, пунимаешь, йәткер куйкысына, халь алсин...

Хәдичә ирен эчке бүлмәгә алып кереп китте.

* * *

Бүлмә салкынчарак иде. Ибраһимов өстен салмады. Хәдичә ханым аның мендәрен караватбашынарак тартып, кабартып куйды. Таянып торган җирдән Галимҗан хәлсез, чарасыз тавыш белән:

—Сәфәргә әзерлән, Хәдичә җаным...—диде.

Ире әйтмәсә дә, Хәдичә ханым моны аңлап алган иде инде. Юлганиләр алырга? Ничек әзерләнергә? Кая алып китәләр? Ана да бергә барырга рөхсәт итәрләрме? Берьюлы мең төрле сорау игәүләде аның баш миен. Шуннан ул верандага йөгереп чыкты да, аннан зур чемодан алып керде. Юлга кирәк-яраклар тутыра, янәсе. Әмма шадра милиционер, аның кулындагы чемоданны тартып алды да, акайган күзләре белән усал карап:

—Ви жына врак народу, не смите ышту-ты дилайт!—дип җикеренде.

Урыс телен вата-җимерә сөйләвенә карап, аның надан бер татар икәнлеген аңлап алды ханым. Чемоданга теге зәнки үзләре белән алып китәргә тиешле китап-кәгазьләрне тутырырга кереште. Җан-фәрман килеп эшлиләр мәгәр.

Хәдичәгә бик кыен иде. Ул тешләрен кысты, бар көнеле белән газап дингезенә чумды. Һм... «халык дошманы хатыны», имеш. Төшме бу? Өнме? Гомер буе кеше бәхете өчен яшәгән Галимҗан нишләп халык дошманы булсын, ди? «Пәйгамбәр» дип атарга мөмкиндер аны. Адашканнарга юл күрсәтүче, бәхетнең кайда икәнлеген әйтүче Хозыр Ильяс бит ул! Бер казакъ акыны сөйләгән иде Хәдичәгә: «Ибраһим галәйһиссәләмне Нәмруд ләгыйнь утка ата, әмма Ибраһим пәйгамбәрнең аягы утка тимәс борын ук, ул урын гөлбакчага әверелә». Ләгыйньнәр, аш янында бүре, эш янында шүре кебекләр күбәя соңгы вакытта. Әмма үзләре казыган базга үзләре төшәчәк әле алар. Мона аның иманы камил! Аның ярсуы йөзенә чыкты. Ул әле Сталинга хитапнамә язачак, янына ук барып житәчәк. Ай-һай-һай, тапканнар шәп һөнәр. Галимҗанны болай мәсхәрә итәргә юл куймаячак ул!

«Халык дошманы» исемен күтәреп, кемнәр генә Себер китмәде, бу бәланең Галимҗан башына да килере ике ятып бер төшенә дә кермәде Хәдичәнең. Илаһым! Аяз көнне күк күкрәгәндәй булды лабаса бу. Дөньяга даны таралган изге Кырым җире, шифалы Ялта, кеше ышанмастай хәлләргә шаһит булсын инде, ә?..

* * *

Галимҗан Ибраһимов та шул хакта уйлап борчыла иде. Күпме фаҗига кичереп яши бу ил. Ерак тарихныкын сөйлисе дә юк. Даими булып торган канкойгыч сугыш, ачлык, ялангачлык, наданлык, караңгылык изде халыкны. Әмма югалып калмаган ата-бабаларыбыз. Авырлыкка күкрәген куйган, кайгы-хәсрәтне кайнар сулышы белән йөгәнләгән.

Ярый, үзбәк әйтмешли, хуп мәйле! Күпме генә авыр йөк салма, сынмады илнең биле, җимерелмәде халык рухы. Бөек төзелешләр санап беткесез. Халык тамагы икмәккә туйды. Башкортстан, Татарстан җирләрендә быел кырларга сыймастай булып шашып үскән игенне моңа чаклы Тарих бабайның беркайчан да күргәне булмаган әле. Шундый изге хәбәрләр алып килә иде Ибраһимовка туган як җилләре!

Социализм төзү саз уйнату, яки умарта кортларының туйга очуы гына түгел шул ул. Күпме кан түгелде, күпме гомерләр өзелде социализм төзегән елларда. Тик...

Нинди дәһшәт соң әле бу? Нигә ашыйлар кеше башын? Ник шаяралар адәм баласының якты язмышы белән? Ил гайрәтен инендә йөртүче арысландай баһадир ирләрне генә түгел, шул ирләрне ир иткән илаһи батыр йөрәкле, тормыш чәчәге булып балкыган гүзәл-алиһә хатын-кызларны да бикли башладылар ташкапчыкка. Бу күренешкә төпле бәя бирә белмәде башта Галимҗан. Унар-унбишәр елга Себер җибәрелгәннәрне, төрмәгә дыңгычлап тутырылганнарны, чыннан да, «халык дошманы», «хаин», «ил хыянәтчесе», «нәҗеслек кылучы» дип атады ул. Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, дигәне шушыдыр инде.

Уйлар, уйлар... Алар һаман күбәя, куера, үрчи бара. Вак уйлар дөньяви уйлар давылына барып тоташа. «Европада шәүлә йөри, коммунизм шәүләсе»,—дип, бу шәүләнең бөтен дөньяга бәхет дулкыны булып җәелүенә өмет ителде. Бәхет ерак икән, ә менә фашизм шәүләсе якында гына пәйда булды. Муссолини фашизмның зиннәтле, матур тормыш булдырачагы турында язып чыккан иде. Фашизм, аныңча, аксөяк-аристократ һәм демократлардан, шул ук вакытта кадимче вә тәрәккыятьчеләрдән тора. 1933 елда Германиядә хакимият дилбегәсе фашизмның канлы кулына күчте. Гитлер бөтен дөньяда фашизм байрагы җилфердәтү максатын алга сөрә. Аныңча, дөнья халкы алманлыларның табан астын ялап яшәргә тиеш.

«Бер акылсыз баш мең-миллион акыллы башны ашый»,—дияргәме хәзер? Мең акылсыз башны акыллы баш итүчеләр дә бар. Зыя Камали шундый шәхес иде. Аны да ун елга утыртып куйгач, Галимҗан Ибраһимов әлеге шәүләләрнең бер-берсенә керешеп китәчәк фаҗигасы турында тирәнрәк уйлана башлады. Шундыйларны халык дошманы итү—илнең коточкыч фаҗигасе ул, үз иленә генә түгел, бөтен дөнья юксылларына, кешелеклелеккә, гомумкешелеклелеккә, үз партиянә хыянәт итү. Кара инде бу «колга»ны... Киләчәктә ил дилбегәсе шундый аумакайлар кулына күчәрме? Кемнәр генә чыкмады «Галия» мәдрәсәсеннән: укытучы, инженер, язучы, шагыйрь, профессор... Ә бу шәкерт кисәге остазының өстәл башында, күзләрен майландырып, агу чәчеп утыра. Сүзләре мужикның тузган чабатасы кебек. Күпме тырышты Галимҗан мәдрәсәдә бу иске чабатадан елтыр итек ясарга. Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән керми икән...

* * *

Хәдичә кичен, чакырылмаган кунаклар килер алдыннан гына, Галимҗан бүләк иткән зәңгәрсу төстәге күлмәген киеп алган иде. Бу төсне Галимҗан аеруча ярата. Туган авылы Солтанмораттагы Зәңгәр чишмә төсе ич ул. Исәнбикә болынында «күбәләксыман» дигән серле-сихри матур чәчәкләр дә үсә. Нигә шундый атама бирелүе хакында мең төрле үлән-чәчәкнең мең төрле серен белүче, Галимҗанның кендек әбисе Хәмдия абыйстай сөйләгән иде. Бәләкәй генә куак шәкелендә үсә ул. Аның төрле төстәге аерым-аерым яфраклары күбәләкне хәтерләтә. Аһ, ул төсләрнеңниндие генә юк!

Күбәләкләрдәге төсләр дә санап беткесез бит. Бу чәчәккә әрвахлар рухы күбәләк булып куна, имеш. Авылның изге күнелле икенче бер әбисе җәйге монсу-матур көннәрнең берсендә сокланып карап торган-торган да: «И, күбәләкләр сыман бит чәчкәкәйләре!»—дип куйган. «Күбәләксыман» дигән атама халык арасына әнә шуннан таралып киткән.

Галимҗан Зәңгәр чишмә төсен хәтерләткән зәңгәрсу күбәләк-чәчәкне ярата иде. Боларның барысын да белә Хәдичә ханым. Бүген Галимҗанның хәле көне буе яхшы булды. Ул, бәлки, табигать кәефе белән дә бәйледер. Әле җәйнең соңгы көннәре. Кырым һавасының иң шифалы чагы. Эссе дә, салкын да түгел. Таманча гына. Монда яшәгән борынгы төрки-татарлар бу чорны «Пәйгамбәр чәчәге мизгеле» дип атаган. Пәйгамбәр чәчәге—шифалы чәчәк. Ул, имеш, житмеш жиде төрле авыруга дәва. Халыкка аны изге күнелле пәйгамбәр бүләк иткән. Шуна күрә ана шундый атама бирелгән. Кырым татарлары Галимҗанга шулайрак сөйләгән иде.

Пәйгамбәр чәчәге кырларда җәй буе кояшның эссе нурын үзенә сеңдереп үсә. Иртән аны саба, кичен сәҗдә җилләре назлап исә. Ә инде усал сырт-кырач җилләре исә икән, ул аларга һич тә бирешми, ә бәлки һаман ныгый гына бара. Көзге һава ана яна дәвалар өсти. Әнә шул мизгелдә аны ашыга-ашыга җыеп калырга кирәк. Сонладың—оттырдың. Көзге шашкын җилләр котырынып, шашынып, аның дәвасын туздырып бетерә. Эчтәге чиргә аны кайнатып эчмәсән дә, яфракларын нинди дә ярага япмасан да, чөйдә бәйләмен шул килеш кенә тотсаң да, кыш буе авыру кара канатын җәя алмый, имеш. Пәйгамбәр чәчәге кешене гөнаһтан да, чирдән дә саклый икән.

Моны Хәдичә ханымга Кырым татарларының хатын-кызлары сөйләде. Хәзерге иләс-миләс яшьләрнең күбесе андыйларга артык игътибар да итмидер. Урыслар исә бу мизгелне «бархатный сезон» дип атый.

Бүген шушы «Пәйгамбәр чәчәге мизгеле» дә унай тәэсир итте шикелле Галимҗанның сәламәтлегенә. Хәдичә белән ул озак кына йөрде тышта. Кергәч:

—Их, Хәдичә, зәңгәр күбәләк, син минем гомеремне озайттың, иллегә житкердең, тагы да бер ун ел яшәп булса... Синең хакта роман да язачакмын бит әле, исеме «Пәйгамбәр чәчәге» булыр кебек...

—Нигә алай?

—Хәдичә—Мөхәммәт пәйгамбәр хатыны исеме.

—Аның мина ни мөнәсәбәте бар?

Галимҗан чөйдә эленеп торган пәйгамбәр чәчкәсе бәйләменә күз ташлады:

—Күпме сөйли бу чәчәк бәйләме. Анда синең эчке дөньяң..

Башкасын төпченеп тормады Хәдичә ханым. Ир тарафыннан мондый җылы сүз теләсә нинди хатынга тәтемидер әле ул. Шуны уйлап, Галимҗан утырып торган арада, ана сиздермәскә тырышып, беленер-беленмәслек кенә итеп, битенә кершән-иннек сөртте, иренена алсулык йөгертеп, кашын сөрмәләп алды. Аннан әлеге зәңгәрсу күлмәген киде дә ире алдына барып басты. Галимҗан, матур чәчәккә озак сокланып карап торган кыз баладай, шактый вакыт хозуранә карап торды хәләл җефетенә.

—Тфү, күз тимәсен, зәңгәр чәчкә генә түгел, Зәңгәр чишмә сандугачы син!—диде аннары.

Әмма шундый матур көннең ахыры хәерсез бетте. Зәңгәрсу күлмәге өстеннән кара итәк, Казакъстаннан ук үзе бәйләп алып килгән күгелҗем-кызгылт төстәге кофтасын киеп алды да, «кунакларга» анда-санда күз ташлаштыргалап, ире янында утыра бирде.

Галимҗан хатынының ни өчен юл киемендә икәнлеген тиз аңлады. Хәер, юл-сәфәргә әзерләнергә кирәклек турында үзе үк әйткән иде ич. Алып китәчәкләр, әлбәттә. Бу инде—көн кебек ачык. Ә менә бу фаҗигагә хәләл җефетен ничек әзерләргә? Ул бит, әгәр иренә нидер була калса, кабергә бергә төшеп ятарга ант иткән хатын. Хәзер ул бернинди үлемнән дә курыкмаячак. «Мин аның белән», «Мине дә утыртыгыз», «Аннан аерылачак түгелмен» кебек сүзләрне әйтә-әйтә чат ябышачак ул ана. Зөләйханың

Йосыфка булган илаһи олы мәхәббәтеме соң бу? Яшь мәхәббәт узгынчы жил, карт мәхәббәт таш яра, дигәне шушымы әллә? Гөлсеме ташлап киткәч, Казакъстан далаларыннан Хәдичә килеп төште. Чын мәхәббәтнең асылын мөкатдәс кешелеклелеге белән аңлата белде ул. Йөрәгенә Зәңгәр чишмә сандугачы булып керде.

...Үзе өчен артык кайгырмый Хәдичә. Ул—сәламәт. Ул—җегәрле. Ул—рухи яктан көчле. Рухи ныклык Галимҗанда да җитәрлек. Аныкына карганда мең өлеш артыктыр әле, бәлки. Хәер, шул рухи көч бөеклеге яшәтә дә аны. Җисмәни көче һаман йомшара, зәгыйфьләнә, сүнә бара. Тәен бер кул белән генә нык бәйләнмәгән кебек, рухи көч кенә дә озак яшәтмидер адәм баласын. Иренең ни кичергәнен, нинди уйлар дингезендә йөзгәнлеген, ни өчен борчылганын яхшы белә ул. Галимҗанның йомшаклыкка бирелмәвен, күз яшьләре яратмаганлыгын, һәр авырлыкта сабырлык күрсәтергә тырышуын аңлый Хәдичә ханым. Шулай да аны иркәләргә, чәчләреннән сыйпап алырга онытмый. Ире исә, әгәр аерылышырга чыннан да туры килсә, иң соңгы сүзне дә әйтергә мәҗбүр булды:

—Хәдичә, зәңгәр күбәләгем, мин синең фәкать бер нәрсәгә ышануыңны үтенәм. Мин «халык дошманы» түгел, халык, партия, ил алдында бер гаебем дә юк!..

—Мин аны аңлыйм ла ул, Галимҗан, әмма тегеләр...—диде дә Хәдичә ханым, югарыга төртеп күрсәтте.

* * *

«Кунакларнын» шөгыле таңга кадәр барды. Аларның ихлас күнелдән, мөкиббән, горуранә нык кылануларына игътибар белән баккач, илне менә шушындыйрак иҗтиһадлы ир-егетләр инсәсе күтәрсә, һичшөбһәсез, илебез мәңге какшамас чуен багана кебек булыр иде, дип уйларсың. Барлык китаплар алгы бүлмәдәге өстәл өстенә, караватка, кәнәфигә, аларга сыймаганнары идәнгә таратып ташланды. Кул яссуы зурлыктагы кечкенә кәгазь кисәге дә, калын китаплар да дикъкать белән тикшерелде. Моңа чаклы беркем игътибар итмәгән тишек-тошык урыннарга, иске-москы киемнәрнең тишек-ертык төшләренә бармак тыгып, итек табанына салган олтырак асларын актарып карадылар хәтта. Хәдичә ханым, үзен бу мәшәкатькә артык исе китмәгәндәй тотса да, күз кырые белән генә гаепләүче карашы ташлап, бинниһая рәнҗү тойгысы белдереп йөрде. Вакыт-вакыт тамагына ачы төер килеп утыргандай тоела. Үзен-үзе ерткалап ташлар чиккә җитә. Әмма эчтәге утны тышка чыгармый. Бу утны тегеләр өстенә өрәсе килә аның. Әмма ярамый. Галимҗанга да сиздермәскә иде дә...

Галимҗан да төсен әллә ни үзгәртми. Кичерешләрен белдермәскә тырыша. Хатынының үрсәләнүен күреп:

—Борчылма, Хәдичә акыллым, аларның эше шул бит,—дип кенә куя.

Иренең тыныч халәте аңа күчә. Чыннан да, төклетурадай пырылдауның бер хаҗәте дә юк хәзер. «Сабыр бирсәнә, Алла!», «Шәфәгать кыл, Рәсуллаһ!»ларны әйтүдән башка чара юк.

Галимҗанның мондый җәбер-золым белән тәүге очрашуы түгел. Киевта да аны ташкапчыкка утыртып куйдылар. «Ташкапчык» дигәнне ул бәләкәй чакта ук ишетеп йөрде. Халыкның төрмәне шулай атаганлыгын аңлый иде ул. Әмма ул ике төрле икән. Егермешәр-утызар кешелек бүлмәләр һич тә капчыкны хәтерләтми. Ә менә Киевта Галимҗанның берүзен бер тар таш бүлмәгә ябып куйдылар. Тәрәзәсе юк. Һавасы юк. Борылып та булмый. Менә бу чын-чыннан ташкапчык иде. Киев университетындагы студентлар хәрәкәте башлыгы булган өчен шундый «хөрмәт-гыйззәт» күрсәтелде ана. Утыртканчы ул вакытта да фатирында озак-озак тентү булды. Эндәшмә, авызыңны да ачма, мулла песие кебек акыллы гына булып тик утыр. Алтыннан мең өлеш кыйммәт иң кадерле әйтерләреңне алганнар икән, йөз суыңны түгеп ялына-ялына сорасаң да кире кайтарып бирмиләр. Кыскасы, эт авызыннан сөякне тартып алып булмаган кебек бу. Киевта, язылып

беткән «Казакъ кызы» романын алдылар. Әлбәттә, кире кайтарып бирү шарты белән. Көтте Галимҗан, и көтте, анасының җылы-назлы кочагын сагынып көткән баладай тилмереп көтте. Әмма кире кайтарылмады роман.

Монда күп нәрсә китә. «Безнең көннәр» романы трилогия итеп эшләнгән иде. Шуның икенче кисәген матбугатка әзерләп куюга шактый вакыт үтте.

—Тәгәлләнгән эшне бикләп тоту зур гөнаһ, Галимҗан, нигә Казанга нәшриятка җибәрмисең?—дип, йөз мәртәбә сорагандыр Хәдичә.

—Ятсын әле, ашарга сорамый бит, тагын бер кат укып чыгасым килә, нидер җитми кебек, әнә шул «нидер» искә генә төшми бит, каһәр,— диде язучы.

«Яшь йөрәкләр» романы да янабаштан эшләнде. Анысын да җибәрергә кушкан иде Хәдичә. Җибәрмәде киребеткән нәмәстәкәй. Ул да хәзер—эт авызындагы сөяк. Башкалары да...

Кеше акылы хисапсыз йолдызга бизәлгән күк кебек киң ләбаса ул. Бу киңлекне үзебез тарайтабыз түгелме? Бер роман эченә мең-мең кеше акылы туплана. Төннәр буе уйлана-уйлана язасың. Күнелең сызлана. Йөрәгең әрни. Үзенчә, кешеләргә тормышның алар күреп, бәяләп житкермәгән гәүһәрләрен бүләк итәргә тырышасың. Акыл түгелмени бу? Акыл. 1914 елда «Безнең көннәр» романын басылып яткан чакта туктаткач, патша хөкүмәтенең гаделсезлеге өчен сызланган иде Галимҗан. Бүген килеп, «Безнең көннәр»нең икенче кисәген тартып алалар. Хәзер совет хөкүмәтенә рәнжеш белдерергәме? Ничек соң бу? Кемгә ышанырга хәзер? Теге ике шәүләнең килеп кушылуы яна фаҗига тудырамы? Тфү, тфү, уйлавы куркыныч хәтта.

Соңгы вакытта Ленин-Сталин партиясенә карата күңелдә шикләнү шөбһәсе барлыкка килгән икән, ул да, бер көнлек күбәләк гомередәй, бик тиз югала, иртән—бар, кичен—юк. Ана заманында милли мәсьәлә буенча Ленин белән житди әңгәмәләшергә туры килде. Бу аның шәхси ихтыяҗы мәҗбүрияте генә түгел бит. Бу—ил-халыкны олы бәхетле итү өчен канда кайнап аркылган теләк-хосусиятлар җыелмасы. Аның бу изге мәсләген Сталин ныклап хәл итә. Асыл нәтиҗәсе шул: Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов—Милли эшләр буенча Үзәк мөселман комиссарияты рәисе Мулланур Вахитовның ярдәмчесе.

Сталин исән. Әгәр янына барса, ул аны кочаклап алачак. Онытмагандыр. Аның күзе—бөркетнеке, колагы—сандугачныкы. Тик, каһәрең, соңгы көннәрдә Газраил галиҗәнапләренең шашынуы гына саруны кайната. Ана да сүз юк: Казанда чакта 1927 елда ук аяктан екса да, янадан кулдан тартып торгызып, янә ун ел яшәтте ләбаса. Шан-шөһрәт ана! Хәзер инде үпкәләр чут юк. Сарык каргышы бүрегә төшми.

Янә шунысы мәгълүм: мондый тикшерену бәласе бер аның башына гына төшмәгән. Ул хәзер бөтен ил буенча бара. НКВД уяу. НКВД йокламый. НКВД һәркемне энә күзеннән үткәрә. Энә күзеннән үткәндә капкорсаклар нәзегәеп кала. Галимҗан кебек коры сөякләрне анда тыгының аслан кирәге юктыр. Ахыр чиктә ул барыбер судан пакь, сөттән ак булып калачак. Чөнки Тәнре шаһит: ил алдында да, халкы каршында да черки күзе кадәр дә гаебе юк. Янә шунысы кануни хакыйкать: хаста түшәгеннән кешене кулга алырга, төрмәгә ябарга бераүнен дә хакы юк.

Судта үзен аклый алыр иде, бәлки. Әмма гомерен ана кадәр суза алмас, бәлки. Төрмә газабын күтәрерлек хәле бармыни аның? Әле 1915 елда ук, ягъни 28 яшьлек чагында болай дип язган иде ул: «... Без иске фанатизм бишегендә туган. Гакылыбыз, фикеребез иске әкиятләр белән томаланып үскән... Егерме яшьләргә кадәр гакыллары бөтен ислам дөньясын каплаган тун вә кара тәгассеп астына ябылып, фикерләре сәләф[1] сүзләре белән богауланып яткан соңра азат кылынган вә шул азат кылыну юлында бик авыр истираблар кичергән...»[2]

[1]С ә л ә ф —әүвәлгеләр, борынгылар.
[2]И с т и р а б —борчылу, тынычсызлану.

Ә инде 1927 елда болай дип язган иде ул: «Без бит ижтимагый-әдәби көрәш эчендә гомерне үткәрдек...

Бөтен үткән хәятым, яшьтән каты эшләп, бөтен 10-15 ел уку һәм яшь язучы заманнарын ачлык, ялангач һәм көрәш белән үткәрүләр мине мәҗбүри рәвештә коммунист-активист булырга хәзерләп китерделәр».

Болар—чынбарлык. Аларны шәрехләү урынсыз. Кеше өчен бары да кирәк: матур киенү, яхшы ашау, гаилә бәхете, фидакяр хезмәт, сәламәтлек... Әмма иң мөһиме—дөреслек. Хакыйкать. Иманга тугрылыклы булу.

Аны кулга алу турындагы кара хәбәр тиздән бөтен ил буенча канатын җәячәк. Бу кара канат, кара еланга әверелеп, ыслап йөриячәк, туган-тумача, кардәш-ыруларын чагып, аларның киләчәгенә агу сибәчәк. «Халык дошманы»ның кардәш-ыруларына гомер буе якты көн булмаячак...

Китапларны теге бүлмәгә ташучы тал кайрысы корты шикелле НКВД бөҗәге берара аңа акаеп карады да:

—Халкыңа шулкадәр хезмәт иткәч, нигә аның белән дошманлашырга,—дип куйды.

Акайган күздә акыл булмаганны белә Галимҗан. Шул хакта әйтәсе килеп тә куйды. Ләкин ангырага акыл сату—үзе бер ахмаклык. Мөбарәк тә, әллә озак утырудан ялкып, аның янына бер мизгелгә кереп чыкты. Аның бер күзе мәгъриптә, икенчесе мәшрикъта иде шикелле. Әллә теге ике шәүлә галәмәтеме бу? Шулайдыр, бәлки. Чөнки ике күз карашы, нәкъ ике шәүлә кушылгандай, берләшеп аңа төбәлде. Шулай да күп сүз әйтмәде «шәкерте»:

—Ялгышасыз, «остазым», хәлегез хөрти,—диде дә аңа йотардай итеп карап алды.

Галимҗан Ибраһимов бер сүз дә әйтмәскә булган иде. Шулай да бер нәрсәне сорамый калмады:

—Сез Казан прокуратурасыннанмы? Мине Казанга алып кайтасызмы?

—Без «халык дошманы» сыравына не отвечаем,—диде дә, кыр кәҗәседәй тык-тык басып, алгы бүлмәгә чыкты.

* * *

—Тыткынны хазер алгы бүлмәгә чугарыгыз!

Мөбәрәкнең түлле тавышы яңгырады.

Галимҗан тормакчы булып, кирәкми, кагылма, дигән ишарә ясады хатынына. Ләкин булдыра алмады. Торып баскач, караватына гөрселдәп янадан ауды. Хәдичә, йөгереп барып, аңа ярдәм итмәкче иде, үзенең генә көче җитмәде. Алгы якка аны ике НКВД кешесе култыклап алып чыкты. Мөбәрәк алып китәчәк әйберләр исемлеген укып, аңа Галимҗан Ибраһимовның кул куярга тиешлеге турында әйтте.

Исемлек шактый озын иде. Ике киндер капчык дыңгычлап тутырылган. Галимҗан, кулы белән ишарә ясап, исемлекне укып торуның кирәк түгеллеген аңлатты. Болай гына кул куйды ул.

Бу эшләр бетүгә яктыра башлаган иде. Чыгарга боергач, Хәдичә ханым Галимҗанга җиләнен кидерде. Тотак, китим диюгә, кискән агачтай чайкалып, хатынының кулына ауды. Аны караватка сузып салдылар.

—Юри кылана, сабакы,—дип, үртәлде шадра.

—Язучы, имеш, әрәм тамак,—диде икенчесе.

—Ун ел буе Ялтада совет байлыгын имеп яту җитмәгәндер шул, кабәхәт.

—Тик кенә сыйланып кына ятса дин син аны.

—Ил саталар бит сволочьлар.

—Фашист ялчылары...

Аларның сүзен Мөбәрәк бүлде:

—Йә җитте сизгә, бир минут срок: носилка табыгыз! Живо!

Тегеләр чыгып йөгергәч, сүз куермады. Хәдичә ханым иренә дару эчерде. Аның күнеле тәмам каткан иде инде. Шуңа күрә нидер әйтергә

телен тибрәтмәде. Аның файдасы тун җиргә борчак чәчү кебек кенә хәзер.

Тегеләр носилка алып килделәр. Идәнгә куйдылар һәм Галимҗанны шунда салдылар. Җинел гәүдәне икенче каттан алып төшү, урамга чыгаруның әллә ни авырлыгы булмады.

Бу вакытта тәмам яктырып беткән иде инде. Тик «халык дошманын» алып китәчәк «кара козгын» (НКВД машинасын халык шулай дип атаган иде) гына юк. Шунысы гаҗәп: мондый эшне ни өчен төнлә башкаралар, ә? Халыктан яшерергә теләпме? Тавыш-гауга кубудан куркыпмы? Безне капчыкта саклап булмаганны анламыйлармы алар?

Галимҗан Ибраһимов фатирында төне буе ут янгач, күрше-күлән моның юньлегә түгеллеген аңлап алган иде инде. Янә нык авырып киткәндер, дип уйлады кайберәүләр. Әмма соңлап ятучылар—Кырым һавасының кичке дәвасын күбрәк алып йокларга теләүчеләр—урамда танга кадәр йөриләр иде әле. Алар язучы-галим фатирында тынгысызлыкның төп сәбәбенә тиз төшенделәр, чөнки «кара козгын»нан төшкән өч НКВД кешесенең Галимҗан Ибраһимов торган йортка кереп китүләрен күреп калучылар булды... Шуна күрә язучыны носилкага салып урамга алып чыккач хәл-әхвәл белергә килүче күренмәде... Һәркемгә үз җаны кадерле шул.

«Кара козгын» озак көттермәде. Килеп туктау белән Галимҗан Ибраһимовны җилтерәтеп күтәреп машина эченә кертеп тә салдылар. Хәдичә ире артыннан машинага сикереп менмәкче иде, әмма аны аннан алып кына ыргыттылар. Әллә кая тәкмәрләп барып төште ул. «Кара козгын», эченә Мөбарәк тә кереп утыргач, кузгала башлады. Хәдичә ханым, ялт сикереп торып, машина алдына барып басты, аларның юлларын бүлде:

—«Чыкмаган җаны гына калган бит, юлда ук үләчәк. Алыгыз мине дә аның белән бергә. Казанга хәтле озатачакмын, төрмәдә икәү бергә утырачакбыз...—дип, өзек-өзек сүзләр белән ачыргаланып кычкырып җибәрде. Бу мәлдә аны акылдан шашкан хатын дип уйларга да мөмкин иде. «Кара козгын» артка чигенде, хатынны урап китмәкче булды. Ләкин Хәдичә ханым кисәк тәгәрмәч алдына сузылып ятты. Шадра, сикереп төшеп, аны юлдан алып ыргытты һәм селәүсен елгырлыгы белән машинага кереп утырды.

Бу юлы хатын каты барып төште шикелле. Әллә башы бәрелдеме? Еландай бөгәрләнеп ятты. Шулай да бу халәте озакка бармады—янадан сикереп торды. Тик «Кара козгын» китеп барган иде инде. Хәдичә машина артыннан йөгерде...

* * *

Ерактан карап торучылар да булган икән. Акрынлап җыела башлады. Халык фикере икегә бүленде.

—Ну, хатыны, ире өчен утта янарга әзер бит, ә минем кәнтәй, авызын ерып, суга батканда иха-хай-һай карап торыр иде әле,—диде алтмыш яшьләр чамалы юан гына симез ир.

Бер кипкән йөзле чәрелдек хатын үзенчә борчак чәчте:

—Нигә әле син, «халык дошманы»н карап яткан бер пумала башка исең китте?

Фикер давылы өчен шушы сүзләр җитә калды:

—Телегез корысын! Галимҗан Ибраһимов бит ул! Нишләп «халык дошманы» булсын ди ул...—дип йөрәген тотты кара-кучкыл йөзле карт кына Кырым татары...

Халык, артык бәхәскә керешми, тарала башлады.

## Икенче бүлек

Дөнья бер алдын, бер артын күрсәтә.

Хәер, аның шулай икәнлеген Галимҗан Ибраһимов үз язмышы белән дә раслый ала. 1927 елның апрель аенда аны, Ялтага озату

өчен, Казанның бер шифаханәсеннән носилкага салып алып чыкканнар иде. Ялтада ул биш-алты ай чамасы дәваланырга тиеш. Аның белән бергә җәмәгате Гөлсем ханым һәм уллары Рөстәм дә барачак. Юлда күз колак булырга, аның язмышы өчен гаярь солдаттай сакта торырга бер шәфкатьле табиб та тәгаенләнде. Кем әйтмешли, өф-өф итеп, яшь баладай кадерләп, биниһая хөрмәт итеп кенә китереп житкерделәр әдипне Ялтага. Ун ел буе шифалы табигать, Кырым табиблары ана фани дөнья белән хушлашырга ирек бирмәделәр. Өченче сакчысы—хезмәт иде. Хезмәт аны гүр иясе булудан саклап яшәтте. Туган иленә, киң күнелле халкына да рәхмәтле иде бөек әдип. Мондый каһарман халыкка, сүнеп барган язмышка яшәү уты бирүче илгә соңгы тамчы канынны сарыф итсәң дә аз булыр кебек. Дөнья аның өчен шәфкатьле кояш, мәрхәмәтле ана, каты куллы ата була белде.

Ничек кенә булмасын, күпме генә коточкыч чирләр кичермәсен, боларның һәммәсе—Галимжан Ибраһимов өчен дөньяның алгы ягы, яки аңа карата елмаеп торган йөзе. Бу йөзгә ул кара якмады.

Ун елдан соң, Казанга кире алып кайтканда, фатирыннан юлга носилка белән алып чыгу—дөньяның артын күрсәтүе. Ул инде елмаймый. Кызганмый. Назланмый. Симферопольгә кадәр «кара козгын»да дөмбер-шатыр китереп алып бардылар да, пассажирлар поезды эшелонына дегет чиләге урынына тагылган бер шыксыз кара вагон эченә кертеп ыргыттылар. Анда башка тоткыннар да бар иде. Бара-бара тоткыннар шактыйга җыелды. Хәзер инде алар, гүя, мичкә эчендә тынкычланган балыклар. Син берүзең генә түгел. Уртак язмыш, уртак кайгы... Беренче карашка, аларны бүлгәләсән, өлеш һәркемгә азрак та тияргә мөмкин кебек.

Вагон эче карангы. Вакыт-вакыт көн белән төнне дә аерыр хәл юк. Көненә бер мәртәбә барысы өчен дә бәләкәй генә чиләк белән су бирелә. Ләмгә катып беткән тутык калай кружка. Өләшә башлагач, ул күпләргә житми кала. Бер йотым су өчен тилмерә халык. Аннан бер кисәк тозлы балык, шырпы кабы зурлык кына кара ипи кисәге бирелә. Кыскасы, җан сакларлык чама бар. Анысын да күпләр алалмый кала. Галимҗан Ибраһимов, бер почмакка сыенып, тавыш чыгармый ята бирде. Икмәккә үрелергә дә, су сорарга да аның көче юк. Бер тәүлек эчендә ул тәмам изрәде, көчен югалтты. Икенче тәүлек башланганда, эсседә мингерәгән каз бәбкәседәй, һуштан язды. Сасы искә һич чыдар әмәл юк. Ялтада хөкемгә яки судка кадәр рухи көч җыйнау хакында хыялланган иде Ибраһимов. Хәзер бу өмете дә челпәрәмә килде.

Тоткыннар арасында төрле милләт кешеләре бар. Кемнең кем икәнлеге йөзләреннән, яисә телләреннән беленеп тора. Ач, ялангач булсалар да, нindидер тема буенча бәхәс башланса, тел тегермәннәре дәррәү эшкә җигелә. Сүзләр ялкыны куба. Ялкын ахыр чиктә ил эчендә, чит мәмләкәтләрдә барган сәяси хәлләрне, икътисади күренешләрне ялмап ала. Бик житди, мәгънәле, зыялы фикер йөртүчеләр бар. Кемнәр алар? Өлкә комитеты секретаре, район комитеты секретаре, галим, укытучы, инженер...—тагы да әллә кемнәр. Галимжан Ибраһимовның сүзгә катышасы килеп китә, сүз-фикер әйтер иде—хәле юк.

Кайбер тукталышларда кемнәрнедер төшереп тә калдыралар. Вагон ишеге, әллә нинди тутык тавышлар чыгарып, ыңгырашып ачыла. Бу вакытта тыштан аз гына һава кереп кала. Аны йотлыгып сулап аласын. Бу әлеге шырпы кабы зурлыгындагы кара икмәк һәм черегән тозлы балык башы бәрабәрендә кадерле. Аста, жирдә конвойлар йөгерешә. Тукталышларда Мөбарәк—»Колга», «Шадра», «Тал чыбыгы» да вагонга сикереп менәләр. Почмакта әлсерәп изрәп яткан Галимжанны күргәч, шатланып: «Әһә, катмаган, җаны чыкмаган хәзергә»,—дип тә сөйләнеп алалар. Казанга исән-аман алып кайтып тапшыралар, янәсе. Алар күрше вагоннарда кайтадыр, күрәсен.

Ни гаҗәп, тукталышта Хәдичәнең ачыргаланып, «Галимжан! Мин монда!» дип кычкырган тавышы янгырады. Өнме? Төшме? Хәдичәнең киләчәк язмышы хакында уйланып, аны төрле кыяфәттә, төрле хәлгә тарыган итеп күз алдына китереп, гасабиланып ятканга, хыялында ишетеләме тавышы?

«Әү, Хәдичә, мин дә монда!» дип кычкырмакчы булды ул. Ләкин касмакланып каткан тамак төбеннән бер тавыш та чыкмады. Ул газапланып, тыңлана башлады. Хәдичәнең тавышы янадан ишетелмәде. Татлы саташу гына булды, ахры...

Хәдичә чыннан да Казанга бара иде. Шушы ук поезда, тик башка вагонда. Һәр тукталышта мәхбүсләр вагоны ягына йөгерә. Вагон ачылмаса, поезд кузгала башлагач, үз вагонына ташлана. Ачылса: «Галимҗан» дип кычкырырга җай эзли. Ләкин форсат һич тә туры килми. Чөнки сакчылар вагонга якын җибәрми. Берсендә аны Мөбарәк-»Колга» күреп алды да:

—Мин сине—«халык дошманы» катыны—хазир милициягә ыздавайт итәм,—дип, ана якын ук килә башлады.

Бәхеткә, «Колга»ны икенче бер НКВД кешесе чакырып алды, кичектергесез йомышы бар иде бугай. Ул чакта качып өлгерде Хәдичә ханым. Ә берсендә, кара-кучкыл киемлеләр күрмәгәндә:

—Галимҗан! Мин монда!—дип әйтә алды. Сакчылар аны күреп алсалар да, хатын тоттырмады, кәлтә еланыдай, халык арасына кереп, качып өлгерде.

Казанга житәрәк бер тукталышта янә берничә мәхбүсне керттеләр. Шулар арасыннан берсе—шактый борчулы күренгәне—Галимҗан янына килеп утырды. Ибраһимов аны танып алды—Колчакка каршы көрәшкән Көнчыгыш фронтның бишенче армиясеннән батальон командиры Каюм Йосыпов иде ул. Аның әле берәүдә дә эше юк. Башын түбән иеп, үз кайгы-хәсрәтләренә бирелгән хәлдә, тыныч кына утыра бирә. Янындагы бөгәрләнеп яткан кешенең ыңгырашуына игътибар итте. Бәй, бәй, чынмы бу? Әллә күзләре алдыймы—Колчак тылында разведчик булып йөргән язучы ич бу?!

—Галимҗан ага?.. Бу сез түгелме соң?!.

—Мин идем лә...

—Нинди язмышлар белән?..

Язучы, сүзләрне өзеп-өзеп, бик авыр сөйләште:

—Яз... мыш... ур... так... тыр инде ул, ту... ганкай!..

—Мин Каюм Йосыпов булам, Галимҗан абый, сезне Колчак тылына разведкага озатучыларның берсе. Таныйсызмы?

Галимҗан җавап кайтармады. Чөнки аның сөйләшерлек хәл-чамасы юк иде инде. Әмма егет артык үзгәрмәгән. Уртачадан озынрак буй, ныклы гәүдә. Түгәрәк йөз. Калын иреннәр. Нигәдер Галимҗан аны танымаганга сабышты.

—Юк...

Каюм мондый сорау бирүенә үкенеп тә куйды. Кеше әнә нинди чиккә житкән, ә ул танышлык турында гәп сата. Каюм шактый кыю, тере, хәрәкәтчән кеше иде. Суны үзенә дә, Галимҗан өчен дә алып өлгерде. Су эчкәч, иркенрәк тын ала башлады Галимҗан Ибраһимов. Каюм өстендә искергән солдат бушлаты иде. Ничек саклый алгандыр—анысы үзенә генә мәгълүм. Эчке кесәсеннән бер сынык икмәк тә алып бирде ул. Капкалагач, әдипнең хәле янә берникадәр арта төште. Элекке разведчикны Казанга житкәнче үлемнән сакларга тырышты Каюм. Ә инде Казан вокзалында, тоткыннарны вагоннан төшергәч, Хәдичәнең янә:

—Галимҗан!.. Галимҗан!.. Мин монда!..—дигән ярсулы тавышы яңгырады.

Бу юлы аны Галимҗан үзе дә күреп калды. Әмма Хәдичә ханымны Мөбарәк-»Колга» эләктереп алды да, янәшәсендәге милиционерның кулына тапшырды.

* * *

Казан шәһәрендәге Пләтән төрмәсен «Кыямәт казаны» дип атады халык. Бу атаманың серен теләсә кем аңламаска да мөмкин. Кыямәт көнендә барлык әрвахларны жыялар, имеш. Алар казанда кайнаган бәрәңге урынына кайнашып торалар икән. Шунда аларның фанилыкта ак һәм кара яклары: акылы, кальбе, вөҗданы, намусы, кешелеклелек сыйфаты тикшерелә, ди.

Аннан кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күперен үтәләр. Берәүләргә—оҗмах, икенчеләргә—тәмуг.

Пләтән төрмәсе дә шуны хәтерләтә. Әй, жыялар, әй, жыялар, әй, жыялар халыкны. Хәзер, элекке кебек, кемнең кем булуына игътибар итү юк. Әмма күбрәк ил дилбегәсен тотучы түрәләр, кем әйтмешли, беренче сорт кешеләр утыра. Монда урта буын җитәкчеләр, гади кешеләр дә җитәрлек. Соңгы вакытта баскыч әйләндереп куелды. Тукай әйтмешли, «без югарыда», дип масайганнар түбән төште, түбәндәгеләр өскә-югарыга менде.

Казанга 1909 елда ук зур өметләр белән килгән иде Галимҗан Ибраһимов. Максатына иреште. Казан аның яшьлек хыялларына канат куйды. Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Кәрим Тинчурин һәм башка каләм осталары белән әдәбият, милли тәрәккыять, асыл мәдәният өчен көрәшеп, фикер көрәштереп яшәде. Хәзер аларны сагынырга гына кала.

Аны башта Пләтән төрмәсенең тоткыннар хастаханәсенә урнаштырдылар. Җавап алу өчен аның чыгар-чыкмас торган җанына иң әүвәл яшәү рухы бирергә кирәк иде. Ике табиб аны ике яктан култыклап, салам тутырылган матраска кертеп салдылар. Бер атна чамасы үткәч Галимҗан тикшерү эшләре үтәүче янына чакырылды. Анда да аны Каюм Йосыпов култыклап алып барды.

Тикшерүче тәрәзәсе шактый биек булган тар гына бүлмәдә утыра иде. Сакчы тимер ишекне ачкач, Галимҗан егылып китмәс өчен таягына ике кулы белән ябышып, эчкә үтте, исәнләшеп, башын селкеп алды һәм тикшерүче кушкан урынга барып утырды.

Тикшерүчесе кырык яшьләр чамасындагы юантык кына кеше икән. Таралмаган чәче яшь чагында, бәлки, бөдрә булгандыр. Хәзер чәче төерләнеп, укмашкан. Йөзе аксыл-кара. Ачулы. Шулай да «халык дошманы» алдында ул үзен әдәпле, игътибарлы, итагатьле тотарга тырышты. Башта, гадәт буенча, үз фамилиясен әйтте ул. Ләкин Галимҗан Ибраһимов аны ишетми калды. Чөнки сүзе аның теш арасыннан кысылып, сытылып, имгәнеп кенә чыкты. Кыскасы, авыз эчендә боламык пешерүчегә охшаган ул. «Боламык», нишләптер, башта телсез кеше кебегрәк тотты үзен. Күзләрен майландырып, Галимҗанга карап тора. Аннан башындагы төерләнгән «сарык йонын» тырнап куя. Колак тишекләрен дә кашып ала. Әллә тәҗрибәсе юк, әллә артык сынап маташа, әллә психологик атака ясарга тели? Елан бит корбанын төсе, шәкеле буенча түгел, хәрәкәтенә карап та тоя. Әллә бу шундый ысулны сайладымы? Әллә аны Галимҗанның эчкә баткан хәлсез күзләре, как сөяк булып калкып чыккан янаклары, көл төсле йөзе, карга күтәреп алып китәрлек дәрәҗәгә житкән ябык гәүдәсе куркытамы? Егылып китеп, җавап алалмый калуыннан шөллиме? Шуларны уйлап булса кирәк, тикшерүче сорауларны ашыкмый, йомшак кына тавыш белән бирә башлады. Исемен, фамилиясен, туган елын, кайда эшләвен сораштырды. Боларны, билгеле, ул яхшы белә. Алар ана протокол өчен генә түгел, сүз башлап җибәрү җәһәтеннән дә кирәк иде.

Вак-төяк сораулар беткәч, төп мәсьәләгә якынайды тикшерүче. Аның мулла малае булуын, эсерлар партиясендә торуын әйтте дә, Колчак тылында нинди максатлар белән разведчик булып йөрүе, акларгамы, кызылларгамы хезмәт итүе турында сорады.

Бу хакта бәйнә-бәйнә сөйләп бирү кыен иде Галимҗан Ибраһимовка. Ул—бик катлаулы, четерекле мәсьәлә. Аны ачыклау өчен күп вакыт кирәк. Андагы мәсьәләне ташка анлатып булса да, бу «боламык»ның миенә җиткерә алмас барыбер. Шуна күрә аны кыскача гына әйтергә булды.

—Мин үземне ул вакытта «революция солдаты» дип йөрттем. Максатым ачыклангандыр, шәт.

—Конкрет әйтергә кирәк. Революция зур төшенчә. Акларга хезмәт иттегезме, кызылларгамы?

—Кызылларга.

—Димәк, совет власте яклы булгансыз?

—Шулай килеп чыга.

—Алдашу кирәкми.

—Мин дөресен әйттем.

—Ә менә сезнең язмаларыгыз киресен сөйли.

—Аның булуы мөмкин түгел.

—Алайса, укып күрсәтәм: «... Oh, күрә алмыйм мин бу коммунистларны, динсез дәһриләрне, кыл койрыкларны, таш йөрәкләрне, шайтан коткысына бирелеп, илне кара канга манчучыларны...» Мондый язмаларыгыз бик күп. Мин әле шуларның йөздән берсен генә укып күрсәттем. Безгә сезнең фашизм ялчысы булуыгыз мәгълүм. Димәк, моның өчен хәзерлек яшь вакытыгызда ук башланган. Йә, ни әйтәсез: дөресме?

—Ялган.

—Ә бу язман?

—Ул булачак әсәр өчен язылган. Аны совет властена теше-тырнагы белән каршы торган бер карт әйтә.

—Кабатлап әйтәм: фашизм ялчысы булуыгыз турында башка кешеләр язган материаллар да җитәрлек бездә. Шуларның дөреслеген раслап, протоколга кул куярга тиешсез. Безне тыңлап, кылган гөнаһларыгыз турында ачыктан-ачык сөйләп бирсәгез, авыру икәнлегегезне дә, зур язучы булуыгызны да искә алып, коткарырлар сезне, Себер җибәрмәсләр, яки атмаслар.

—Мин фашизм ялчысы түгел. Андый протоколыгызга кул куймаячакмын.

Тикшерүче аның язмышы өчен борчылучы буларак сөйләүгә күчте:

—Сезнең зур эшләр башкарганны без яхшы беләбез. Совет хөкүмәте ун ел яшәтте сезне Ялтада. Рәхмәтегез шулмы?

—Рәхмәтем бик зур...

—Безгә күз буяу кирәкми. Бала-чага уены түгел бу. Колчак тылында кызылларга хезмәт иткән булып, аклар тегермененә су коюыгыз, совет властена каршы булуыгыз, инде килеп, фашизм коткысына бирелүегез мәгълүм...

Сөйләшү шактый озынга сузылды. Күп вакыт китте. Галимҗан чайкала башлады. Нык ачуын китерде бу тикшерүченең. Чыгырыннан чыкты ул хәтта. Үз-үзен югалту дәрәҗәсенә җиткәч:

—Сакчы!..—дип кычкырды.

Галимҗан Ибраһимовның торып китәр хәле юк иде. Сакчыга аны авыру тоткыннар янына култыклап илтеп куярга туры килде. Ә тикшерүче, катып беткән кульяулыгы белән маңгай тирен сөртеп:

—Сволочь!.. Менә нинди фашист ялчылары ут төртә совет властена,—дип ярсыды да, алагаем бер төчкереп куйды.

* * *

Төрмә хастаханәсендә төрле чирдән аһ-ваһ килүчеләр бар: берсе бавыры белән бөгәрләнеп сызлана, икенчесен йөрәге тота, өченчесенең ашказаны бозык, дүртенчесе бөердән иза чигә, күбесен кыйнап, имгәтеп бетергәннәр... Галимҗан Ибраһимовта—үпкә чиренең иң алама төре.

Янә һәммәсе өчен уртак авыру бар: ул да булса—рухи яктан кимсенү. Кайсы авыруның яманрак икәнлеген бизмәнгә салып та булмый. Әмма, салсаң, соңгысы авыррак тартыр иде. Берәү дә үзен гаепле санамый. Совет властена, коммунистлар партиясенә һичкем тел тидерми. Чөнки алар шул рухта тәрбияләнгән. Алар нахакка утыруның сәбәбен ачыкларга тели. Шул гына...

Тоткыннар арасында әллә нинди һөнәр ияләре бар: язучы Садри Җәләл, Беренче укчы татар полкының политругы Зариф Идрисов, батальон командиры Каюм Йосыпов, райком секретаре Габделхак Батталов...—тагы да әллә кемнәр. Барысы да Галимҗан Ибраһимовны беләләр, хөрмәт итәләр. Үлем хәлендә төрмәгә китереп ябуны күпләр тетрәнеп кабул итте. Чыннан да улмы, әллә аңа охшаш башка бер-бер затмы, туганы-фәләнеме? Моңа кадәр аны үз күзләре белән күрмәгәннәр язган әсәрләре, фәнни хезмәтләре,

фоторәсеме буенча беләләр иде. Әлбәттә, ул чактагы рәсеменә һич тә охшамый инде ул... Шулай да кипкән йөздә горурлык, гәүдә тотышында да ныклык чаткылары сүнмәгән иде әле. Үзе сүнгәннән соң да һаман әле Җиргә таба килгән ерак йолдыз нуры кебек иде күз карашы.

Сакчылар Галимҗан Ибраһимовны сәкедәге аның өчен тәгаенләгән салам түшәккә китереп салгач, тоткыннар аның янына бармаска тырыштылар. Һәркемнең уен бер үк сорау борчыды, сәбәбе ни монын? Галимҗан Ибраһимов кебек зур шәхес тә килеп эләккәч... Илдә барысы да ал да гөл түгел болай булгач. Әдипкә төрлечә ярдәм итәргә тырыштылар. Берсе су китереп бирә, икенчесе үз ризыгыннан өлеш чыгару ягын карый. Ничек тә аякка басуын телиләр иде.

Садри Җәләл аның яныннан китмәде дә диярлек. Ул һаман бернәрсәне—бөтен ил буенча барган бу буталышның сәбәп-тамырын белергә тели.

—Синең кебек пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрелгән кешене дә утыртып куйгач, бу ил черек тамырдан үсеп киткәнме әллә; бәс, шулай икән, аның киләчәк тәрәккыяте, яшәү дәрәҗәсе бик куркыныч бит, шулай түгелме, Галимҗан абый? Йә, әйт әле, миңа шуны тәфсилләп бир, син бит башлы, фикерле кеше, ә?—диде ул бер сөйләшкәндә.

—Пәйгамбәрләр дә утырган бит, Садри туган, Йосыф пәйгамбәрнең зинданда күпме иза чиккәнен беләсең. Бу—кеше бәхете өчен!

Садри Җәләл аның белән ризалашмады:

—Димәк, безнең башлар киләчәк буыннар өчен төрмәдә черергә тиеш, шулаймы?

—Алай ук түгел.

—Ә ничек?

—Мәсьәләгә башкачарак карарга кирәк.

—Марксизм күзлегеннәнме? Их, Галимҗан абый! Ташла син шул марксизм чукмары белән кизәнүеңне. Үз башыңа төште бит ул чукмар.

—Болгатма әле син, Садретдин энем!

Мондый сөйләшү шактый озынга сузыла. Авылыңнан башланган юлның соңгы очын табу кыен булган кебек, бу буталышларның кайдан килеп чыгышын, кая барып төртелешен ачыклау да бик авыр. Галимҗан азрак торып утыра, бераз йөрештерә дә башлагач, аның янына күпләр килеп сырыштылар да бу мәсьәләгә үз бәясен бирүен үтенделәр.

Галимҗан, язучы буларак, аңлату җиңелгәрәк төшсен өчен, төрле чагыштырулар куллана-куллана сөйләргә тырышты. Тик ул үзен зурга куеп маташмады.

—Минем дә хаталануым бар бит, агай-эне, әүлия дә, пәйгамбәр дә түгелмен, әмма ләкин сез үтенеп сорагач, бер кәлимә сүз әйтми булмас,—дип сөйләп китте ул.—Менә сез уйлап карагыз әле, гап-гади бер мисал китерәм: әйтик, берәү—моңа чаклы балта да тотмаган кеше—берүзе өй салырга дәртләнде. Димәк, ул бик гайрәтле, йөрәкле, гаярь зат. Шулай булмаса—тотынмас иде. Салды да бу йортны. Мәгәр үзе теләгәнчә, бигүк килешле, матур килеп чыкмады йорт. Бу—табигый хәл. Чөнки беренче тотынуы гына. Ә икенчесе инде, иманым камил, күз явынны алырдай гүзәл булачак. Без, бөтен дөньяда беренче буларак, социализм төзедек. Шуңа күрә аның килмәгән, килешсез яклары булу, шуларны аңлап бетермәү дә табигый күренеш. Сезгә мәгълүм: Спартак колларны көрәшкә күтәрә. Әмма җиңеләләр. Дәхи дә бер мисал: Париж коммунасы бөтен дөньяны шаулатты, озак яшәмәде бит. Мәгълүм инде: феодализм—капитализмга, капитализм—социализмга каршы. Һәр үзгәреш революцион юл белән яулап алына...

Шунда аның сүзен бүлделәр. Төрле сорау китте:

—Сез, Ибраһимов иптәш, бер йорт яхшы төзелмәсә, икенчесе шәбрәк салыначак турында әйттегез; әгәр бу социализм ошамаса, анысын җимереп, икенчесен төзергә кирәк дип әйтмәк буласызмы?

—Сез һаман революция кирәк булу турында сафсата сатмыйсызмы?

—Без бит илебезнең төрмәгә әверелә башлау сәбәпләрен ачыклавыгызны үтенгән идек.

Галимжан Ибраһимов бу юлы кыскача гына әйтте:

—Киләчәк күрсәтер. Ләкин кемнедер гаепләргә ашыкмыйк. Ил башлыклары бар. Партия бар. Шуларга ышаныйк!..

* * *

Уй дилбегәсен Галимжан Ибраһимов Гражданнар сугышының кайнап торган казанына таба какты. Колчак гаскәренен көчле ташкын булып, Иделгә таба янә шашынган чагы иде. Бер үк ил балалары бер-берсен кыра. Хәтта бер үк ата-ана балалары бер-берсен үтерә. Колчак явы барысын да сытып узар кебек иде. Бу ташкын-яуга каршы икенче бер яу корыч күкрәген куйды. Көнчыгыш фронт күкрәге аеруча ныклы иде. Аның бишенче армиясе сугышка үзләре теләп килүче татар-башкорт егетләреннән аерым-аерым батальоннар төзи башлады. Аның оештыручысы Галимжан Ибраһимовның якташы, электән үк нык таныш кеше Мәхмүт Шаһиәхмәтов икән.

Әлеге хәбәр Галимжан Ибраһимовның канын кайнатты. Ул да яуга омтылды. Кем булып барырга анда? Берәр командирмы? Яки гади солдатмы? Тик...ата да белми ич әле ул.

Шул хис-тойгыларын түкми-чәчми сөйләп бирде ул Мәхмүт Шаһиәхмәтовка. Батальоннар оештыручы, аны күргәч, үз күзләренә үзе ышанмый торган иде. Ә инде максатын сөйләп биргәч, әллә ялгыш ишетәмме, дигәндәй, колак артын кашып алды. Галимжанның шаярта торган гадәте барлыгын белә Мәхмүт. Бу шуның бер галәмәтедер, нindидер башка йомыш белән килгәндер, дип уйлады. Мондый уйлар өчен нигез яки жирлек баштан ашкан. Беренчедән, ул инде хәзер татарлар арасында гына түгел, башка төрки халыклар дөньясында да мәшһүр язучы буларак танылган зат. Аның «Яшь йөрәкләр» романы, «Яз башы», «Дингездә», «Табигать балалары», «Сөю-сәгадәт» кебек хикәяләре күпме укучыларга рухи ләззәт, мәгънәви шифа, хәяти мәгълүмат бирде. «Безнең көннәр» романы бәхет өчен ничек көрәшергә, инкыйлабый утларга ташланудан курыкмаска, ил язмышын йөрәгенә ала белергә, дошманнарга каршы рәхимсез булырга өйрәтте. Утыз яшен яңа тутырган язучы күпме асыл әсәрләр ижат итәчәк бит әле. Милләт көзгесенә, ил көзгесенә әверелгән шәхес. Халыкка хезмәт итүнең иң ләззәтле вә гыйззәтле мизгелләрен кичергән вакыты. Язучы—гасырның йөзек кашы. Тот та шул кешене сугыш утына тык. Ахмаклык булачак бу. Шулар хакында сөйләп бирде дә:

—Ялгышасыз, Галимжан абый, сугыш белән үлем—игезәкләр, сез әдәбият өчен кирәк,—диде.

Галимжан үз туксанын туглады:

—Әдәбият «женем» ач минем, Мәхмүт туган, әнә шуны туйдырырга барам сугышка.

—Аңламыйм. Гадирәк итеп сөйлә әле, Галимжан абый!

—Мина «Безнең көннәр» романының дәвамын язарга кирәк.

—Аны болай да булдырасыз. Сезнең каләм очыннан ак кәгазьгә нинди гәүһәр түгелгәнлекне беләм лә мин.

—Анысы бизәк өчендер, бәлки. Ә мина мәгънә гәүһәре кирәк хәзер. «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр» романнарының прототиплары бар. Бу—бер. Икенчесе шул: алардагы вакыйгалар үз йөрәгем аша үтте. Чөнки ул вакыйгалар казанында үзем кайнадым.

—Соң, Галимжан абый, сез бит Үзәк мөселман комиссариатында Мулланур Вахитовның урынбасары, Халык Комиссарлары Советының рәисе Владимир Ильич Ленин, Милләт эшләре буенча халык комиссары Иосиф Виссарионович Сталин белән бергә эшләгән кеше, әллә күпме роман язарлык материалларыгыз бар лабаса...

—Анысы аның, туганкай, тормышны тәрәзә аша гына күзәтү була. «Безнең көннәр» романының икенче кисәге гражданнар сугышын да үз эченә алачак. Вакыйгаларны бармак очыннан суырып язарга яратмыйм мин. Алар йөрәк аша үтәргә тиеш. Утмы ул, сумы, давылмы, гарасатмы—

минем өчен барыбер. Алар мине куркытмый. Ил ертыгын ир ямарга тиеш, ди торган иде әти мәрхүм.

—Әтиең Гыйрфан абзыйны күреп беләм лә инде мин, Галимҗан абый, каһарман йөрәкле, усал, шул ук вакытта акыллы, мәгънәле кеше иде ул. Ә сез аны да узып киттегез.

Алар көлешеп алды. Аз гына вакыт тын тордылар. Тынлыкны Мәхмүт бозды:

—Безнең яктан сезнең кебек шундый зур кеше чыгуга ифрат шатбыз, Галимҗан абый! Горурланабыз!

—Урынсызга мактау хурлауга караганда да яман, Мәхмүт туган! Тәгаен менә шушы минутта син миннән күпкә өстен. Син—батальоннар башлыгы. Ә мин—гади солдатың...

... Түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелде Мәхмүт Шаһиәхмәтов. Әлеге авыл йолкышлары, чабаталы, киндер ыштанлы, кара борынлы, яргаланып беткән яланаяклы малайлар белән туфракта аунап, бер дуслашып, бер чукмарлашып, кара хезмәтнең кадерен белеп, корычтай чыныгып үскән ир-егет ул.

—Безнең яклар синең белән дә нык горурлана, Мәхмүт энем, ходай үзеңә хәрби талантны мул биргән,—диде.—Акылың да башыңнан ашкан. Ә акыл—бер коралдыр.

—Акыл белән түгел, мылтык белән эш итәбез шул күп чакта. Кан коеп...

—Революция кансыз булмый, энем.

—Бөтенесе дә бер үк ил кешеләре бит. Нигә атышабыз?.. Чөнки акыл җитми.

—Без фәлсәфә сазлыгына кереп батмыйбызмы?

—Сезнең белән бер сөйләшеп утыру үзе бер гомер, Галимҗан абый! Әллә күпме фәһем алам. Моны сезгә элек тә әйткәнем бар иде...

—Кешене күз алдында мактау—янә бер акылсызлык. Без минем мәсләктән читләштек. Шуны хәл итик тә...

Мәхмүт Шаһиәхмәтов сәгатенә карап алды:

—Сез әйткән мәсьәләне чишү өчен дә тирән акыл кирәк, моны ач карын белән генә хәл итеп булмастыр: без, булмаса, тамак ялгап алыйк, Галимҗан абый! Ә менә ашау өчен акыл әллә ни кирәкми.

Алар янә көлешеп алды.

... Ишегалдында солдатлар кайнаша иде. Алар арасында әле шинель киеп өлгермәгән кылка киемле, чабаталы егетләр дә шактый. Галимҗан Ибраһимов аларга сокланып, мөкиббәнә, ниндидер бер эчке хис-тойгы, кызыксыну, дулкынлану белән карап торды. Шул җыртык бишмәтләргә, киндер күлмәкләргә, тузган чабаталарга авылның ачы әрем исе, туган туфрак исе, болын чәчкәләре исе, балан исе, кыскасы, бөтен авылның үз исе сеңеп килгән бит. Ә үзләре, кара, нинди фырт йөри! Баш югары. Күкрәк алга таба киерелгән. Йөзләрдә—аңлатып бирү кыен булган ниндидер шатлык билгесе. Иллә мәгәр ярлы тәкәбберлек галәмәтен килештерәләр дә соң! Кем белә: аның тирә-якта дан тоткан туган авылы Солтанмораттан да бардырдыр әле монда. Бардыр! Булмый калмас!

Галимҗан Ибраһимовның нидер кичергәнен сизде Шаһиәхмәтов. Тик аның сәбәбен генә аңлый алмады. «Шушы малайлар белән бергә сугышып йөрергә?»—дип уйлыймы? Әллә башка хис-тойгы давылына чумдымы? Нигә әле ул шулкадәр шаккатып карап тора аларга? Мәхмүт аның уйларына нокта куярга булды:

—Җә, Галимҗан абый, карап туйдыгыз шикелле инде...Киттек!

Ашханә ерак түгел икән. Ике катлы йортның теге ягында гына булып чыкты. Әле төшке аш вакыты җитмәгән. Шунадыр, бәлки, ике кешедән башка җан иясе юк иде залда. Мәхмүт Шаһиәхмәтов эчке бүлмәгә үтте. Галимҗан да калмады аннан. Бәләкәй генә бүлмә. Бер-берсенә ике өстәл терәп үк куелган. Тирә-якта—утыргычлар. Моның түрәләр өчен икәнлеген аңлау кыен түгел иде.

Алар капма-каршы утырдылар. Баягы сүзнең чылбыры өзелгән иде инде. Башта янасын әллә табарга тырышмадылар, әллә ул кирәк саналмады. Тиздән аш китерделәр.

Галимжан Ибраһимовның Ленин, Сталин белән бергә эшләвен Русия мөселманнары белә иде инде. Ә менә аннан китү сәбәбе теләсә кемгә мәгълүм түгел. Ул әле Мәхмүт Шаһиәхмәтов өчен дә караңгы. Милли мәсьәлә—бик зур төшенчә. Ул—артык бәхәсле, четерекле, катлаулы. Шул бәхәсләр давылына барып кергән Галимжанның абруе милләт көзгесе, ил көзгесе булу дәрәҗәсенә житеп күтәрелде. Ана бит теләсә кем баш тыга алмый. Анда эшләү өчен әле генә телгә алган югары ан-акыл, галәми рух, батырлык, каһарманлык, тел сәнгатен белү кирәк. Теләсә нинди шартларда милли мәсьәлә белән шөгыльләнү ялкыны сүнмәскә тиеш. Нигә ил башлыклары канаты астында эшләүне хуп күрмәгән Галимжан Ибраһимов? Ул инде, туган авылы Солтанмораттан киткәч, Оренбург каласының Вәли мулла мәдрәсәсендә какланган, Кавказда—нугай, Казакъстанда—казакъ балаларына белем энжеләре биргән, Урал буйларындагы Миас жиз эретү заводында зимагурлар белән бергә кара эшче булган, аннан соң Казан каласында кайнаган, Киевта татар балаларына сабак биреп, университет студентлары тарафыннан оештырылган түгәрәккә житәкчелек иткән өчен таш капчыкта утырып чыккан, Петербург, Мәскәү калаларын кыдырып йөргән кеше. Ә менә, пайтәхеттәге эшен ташлап, тота да туган якларына—башкорт жиренә кайта. Нигә шулай? Сагыну хисе көчлеме? Шул хакта сорады Мәхмүт Шаһиәхмәтов.

Галимжан көлемсерәп куйды да:

—Кайда күбрәк кирәксең, шунда кайнашу яхшырак бит, Мәхмүт энем.

Сагыну бар инде ул анысы.

Хәзергә кайда күбрәк кирәк булу хасияте дә шуңа бәйләнгәндер, бәлки. Ул уй-хисләр дә кәрәзләнгәндер. «Галия» мәдрәсәсендә укыганда татар-башкорт шәкертләре «Парлак», Кавказ егетләре «Ләгу», казакълар «Садак» дигән кулъязма журнал чыгара иделәр. Матбугат тезгене Галимжан кулында булды. Инкыйлаб ялкыннары дөньяны тетрәндереп, шәһәр-авылларын дер селкетеп, кешеләр йөрәген төрлечә кайнатып-шашындырып жибәрде. Ак-кара, хис-акыл, жәбер-золым кебек дөньяви төшенчәләр буталып бетте. Нинди иманны кыйбла итеп алырга? Бәхет, Ирек, Азатлык кирәк адәм баласына. Бу төшенчәләр дә кәрәзләнгән бер-берсе белән. Аларны аерып карау шактый кыен. Уфада «Ирек» дигән газета чыгара башлау шуларга бәйләнгән. Әлбәттә, баш мөхәррире—Галимжан Гыйрфан улы Ибраһимов. Урынбасары—Мәжит Гафури. Сәркәтибе—Фатих Сәйфи-Казанлы.

Янә «Авыл халкы», «Солдат теләге» кебек газеталар да чыгып килә иде. Әлбәттә, максат бер: яна тормыш төзү, искелеккә кабер казу, ярлы-ябагайны бәхетле итү. Шулай да, кояш нурларының төсе күп, шифасы төрле булган кебек, гәрчә мәсләкләр уртак булса да, юл тоткан кыйблага баруда тайпылмышлар да сизелгәли. Аннан өч газета чыгаруга көч тә күп сарыф ителә, акча да житкереп булмый, басмаханәләр дә табу кыен. Шуңа күрә өч почмактан бер маяк ясамак булдылар. Яки өч газетаны бер иттеләр дә аны «Безнең юл» дип атадылар. Баш мөхәррире—Галимжан Гыйрфан улы Ибраһимов. «Безнең юл» Шаһит Ходайбирдин, Шәриф Сүнчәләй, Гомәр Әлмөхәммәтов, Газыйм Касыймов... кебек ихлас күнелле, мәсьәләнең мөгезеннән тотып ала белә торган, ялкынлы йөрәкле, үткен каләмле журналистлар белән данланды.

Менә учредительное собраниегә сайлау көннәре килеп житте. Петроградка жибәрү өчен Уфа вилаятеннән яки губернасыннан бер вәкил кирәк. Жиңүче булып чыгучы—Галимжан Гыйрфан улы Ибраһимов.

* * *

... Петроградта ул, башка вәкилләр кебек, «Астория» кунакханәсенә урнашкан иде. Икенче көнне үк ул Милли эшләр буенча халык комиссариаты Сталин-Джугашвилидан чакыру кәгазе алды. Анда фәлән-фәлән көннең фәлән сәгатендә Сталин янында булырга тиешлеге әйтелгән иде. Аның белән бер бәйләнеше дә юк лабаса? Тәгаен бер үзен генә чакырамы? Башкалар белән бергәме? Бу фараз итү дә чынбарлыкка туры килмәде. Күрсәтелгән сәгать-минутта Смольныйга Сталин кабинетына барса, ул берүзе генә булып чыкты. Сталин янына да берүзе генә керде.

Сталин аны аяк өсте килеш каршы алды. Ул бик тыныч кыяфәттә тора иде. Йөзендә—сабырлык. Гәүдәсендә—хәрәкәтсезлек. Кулында—аз гына төтене чыгып торган трубка. Бу сыйфатта ул пошмас кешене дә хәтерләтеп куя. Әйтерсең, дөнья давылланмый. Гарасат юк. Кан коелмый. Ачлык-хәерчелек борчымый аны. Тышта салкын буран котырынганда, җил куш йодрыклары белән шашынып-шашынып тәрәзә какканда, бәгъзе бер авыл мужигы җылы мич алдында рәхәтләнеп-рәхәтләнеп тәмәке пыскытып утыра. Башка бернидә гаме юк аның. Бу да шулайрак тоелды Галимҗан Ибраһимовка. Ул әле һаман эндәшми. Күз карашлары каты, билгеле. Тикшереп карый. Хет, җыгылып кит. Ләкин җыгылмый Галимҗан. Нык тора. Күп каты карашлар алдында мәмрәп төшмәгәнлеген, ут-давылларда чынykканлыгын исбат итмәк була.

Сталин, үзен һаман шулай тыныч тоткан хәлдә, сүнгән трубкасын өстәлгә куеп сорау бирде:

—Сез ни өчен учредилканы ташлап чыгып киттегез, нинди максатлар белән?

Учредилканы ташлап чыгып китүче бер Ибраһимов кына түгел иде. Алар күпләр. Ә нишләп шул күпләр арасыннан аны гына күргән ул?

... Учредительное собрание Таврида сараенда булырга тиеш иде. Уфадан килеп төшү белән Ибраһимов шунда китте. Сарайда депутатлар төркемнәргә бүленеп утырганнар. Килеп кергәч, Галимҗан Ибраһимов иң әүвәл, кайсыгызның күңел даирәсе минекенә тәңгәл дигәндәй, төркем-төркем булып утырган депутатларга күз йөртеп чыкты. Уртага центристлар җайлашкан. Уң якта—меньшевиклар, кадетлар. Сулда—сул социал-демократлар, большевиклар. Галимҗан Ибраһимов сул социал-революционерлар янына барып утырды.

Утырыш озакка сузылды. Төнге сәгать икеләрдә бер төркем аны ташлап чыгып китәргә мәҗбүр булды. Чөнки, уңнар һәм центристлар (уртадагылар) күпчелекне тәшкил иткәнлектән, тикшерелергә тиешле күп мәсьәләләрнең дилбегәсе алар кулына күчте. Аларның хәтта советларның икенче Бөтенроссия съездында кабул ителгән декретларны да тәсдыйк итмәве—акны карага буярга тырышулары, революция казанышларын сүз томаны белән капларга маташулары, халык мәнфәгатьләрен мужикның иске чабатасы урынына да күрмәүләрен раслады. Мәҗлесне ташлап чыгып китүчеләр арасындагы сул эсер Ибраһимовка Сталин аеруча игътибар иткән иде шул. Үзенең шәхсән фикерен кыска гына аңлатты Ибраһимов:

—Центристларның һәм уңнарның революция казанышларына көл сибәргә тырышуларын аңладым мин. Җирнең крестьянга бирелергә тиешлек декретны расламаулары аларның халык хыянәтчесе икәнлекләрен күрсәтте. Андый әхлаксызлыкны күтәрә алмыйм мин. Шуңа күрә ташлап чыгып китәргә мәҗбүр булдым.

Боларны әйткәч тә әле, Сталин һаман шул каты карашы белән Ибраһимовны капшап торуын дәвам итте. Аны корыч караш дип әйтергә дә мөмкиндер. Хәзер инде бу корыч караш уклары Галимҗанның йөзенә, күзләренә генә кадалып калмады, аның ми күзәнәкләренә, күңел күгенә, йөрәк түренә үк үтеп керде. Ибраһимов корыч карашны корыч характеры белән кабул итте. Корыч баганадай басып торды аның алдында. Бу торышны яратты Сталин. Уратмый-чуратмый, кыска гына берничә җөмлә белән үз

эчке дөньясын ачып салуын, шактый катлаулы сәяси вакыйгаларны, икътисади мәсьәләләрне анлый белүен, партия-фракцияләргә объектив бәя бирүен дә ошатты.

Учредилкага «вак» милләтләрдән мөселманнар гына вәкил җибәргән. Хәзер аларның үз фракцияләре дә бар. Мәгәр шул мөселманнар арасыннан нибары Галимҗан Ибраһимов кына ташлап чыгып киткән учредилканы. Сталинның корыч карашы, әнә, ни өчен ялмап алган икән Галимҗанны. Хәзер инде ул корыч караш Ибраһимов йөзенә сынау уклары атмый. Киресенчә, караштa миһербанлык чаткылары, янә икенче төрлерәк әйтсәк, йомшару мизгеле сизелә башлады. Дустанә сөйләшүгә күчте Сталин. Ул гына да түгел, Ибраһимовны өстенрәк куйгандай, теге яки бу вакыйга буенча аннан фикер сорый башлады. Милли эшләр буенча халык комиссариаты төзүдә Сталин күрсәткән тырышлык күпләргә мәгълүм. Ә менә Ленин янә тагы да «Үзәк мөселман комиссариаты» төзүне мәгъкуль күрә икән. Шул хакта, аның максаты турында кыскача гына сөйләде дә Сталин:

—Сез ничек карыйсыз мона, Галимҗан Гыйрфанович?—дип сорап куйды.

Ибраһимов сорауның асылын аңлап бетермәде. Бу искиткеч мөһим, кирәкле, галиҗәнаб мәсьәлә ләбаса! Ә нигә аның кирәк булу-булмау кадәресен аннан сорый?

Җавапны тиз һәм аз сүз белән бирергә кирәк иде.

—Мин моңа бик нык унай карыйм!—диде дә, гәүдәсен һаман шулай нык баганадай тотып, бу юлы үзе үк Сталинга корыч караш бүләк итте.

Сталин канәгать иде аның җавабыннан. Ул янә шундый сорау бирде:

—Әгәр бу эшне оештыруны сезгә тапшырсак?

Бу кадәресен көтмәгән иде Ибраһимов. Димәк, турыдан-туры Сталин кул астында, Ленин җитәкчелегендә эшләргә, алар янында кайнашырга кирәк. Йә Уфада, йә Казанда яшәү юлына киртә куелачакмы? Аларга аның фикер рухы югарыдан гына төшеп торачакмы? Секунд мизгелендә ярып үтте аның ми күзәнәкләрен бу уйлар. Аны җилем урынына сузарга форсат-фәлән юк иде. Ике сүз белән генә бирде җавапны:

—Мин риза!

Озакламый Петроградка Казаннан Мулланур Вахитов, Оренбургтан Шәриф Манатов килеп җитте. Алар белән таныш иде Галимҗан Ибраһимов. Смольныйның тышкы ишек төбендә очраштылар. Ләкин эчкә үтмәделәр. Чөнки Ибраһимов, ашыга-ашыга, алар юкта булган вакыйга, бу хакта Сталин белән киңәшләшү, мәсьәләнең үтә җитдилеге хакында кыскача гына әйтеп, фикер алышу өчен «Астория» кунакханәсенә чакырды. Баргач, иң әүвәл боларның икесенә бер бүлмә алып бирде. Әнә шунда алыштылар фикерне. Гәрчә эшне үзе башлап җибәрсә дә, Русия мөселманнары комиссариаты рәислегенә Мулланур Вахитовны тәкъдим итте Галимҗан Ибраһимов. Нигә икәнлеген исбатлау өчен ул Мулланур Вахитовка кыскача гына бәяләмә дә биреп алды. Аның рус һәм татар телләрендә матур, мәгънәле, эзлекле сөйләве, фикер йөртү офыкларының киңлеге, халык арасында зур абруй казануы, ялкынлы йөрәкле, профессиональ революционер булуы хакында әйтте.

—Кем дә кем Мулланур Вахитов галиҗәнабләре рәислеккә үтә ди, шулар кул күтәрә,—диде. Үзе ике кулын югары чөйде хәтта. Шәриф Манатов та шуны эшләде.

Шуннан Галимҗан Ибраһимов аларны И. В. Сталин янына алып барды.

Сталин бу юлы да берүзе генә иде. Өч кеше килеп кергәч, ул аптырабрак калды. Өчесенә дә утырырга кушты. Ә үзе басып торды. Яңа килгән вәкилләрне Сталин белми икән. Ибраһимов башта Мулланур Вахитовны тәкъдим итте. Кем икәнлеге турында кыскача гына бәян кылгач, аны Русия мөселманнары комиссариатының рәисе итеп куярга килешүләре хакында әйтте.

Вахитовның Сталинны тәүге күрүе иде. Сынау күперен үткәрү өчен сорауны да ул кыскача гына бирде:

—Сез бу эшкә ризамы, Вахитов иптәш?

Мулланур, артык чишелеп китмәскә тырышып, үзе хакында кыскача гына сөйләп бирде. Җавапны:

—Мин Санкт-Петербургның Психоневрология институтында укыганда ук сәяси түгәрәкләргә йөрдем. Революция мәнфәгатенә җаным-тәнем белән бирелгәнмен. Тапшырылган эшне югары дәрәҗәдә башкаруга бөтен көчемне бирәчәкмен!

—Менә бу чын большевикларча!—дип, саран гына елмаеп куйды Сталин.

Аннан соң Галимҗан Ибраһимов Сталинны Шәриф Манатов белән таныштырды.

Сталин Үзәк мөселман комиссариатының эш кыйбласы нәрсәдә икәнлекне, алда торган максатларның юнәлешен сөйләп тормады. Бу хакта Галимҗан Ибраһимов белән фикер алышу булганлыкны әйтте дә, барысын да аннан сорарга кушып:

—Сорауларыгыз юкмы?—диде.

Сорауны Галимҗан Ибраһимов бирде:

—Үзегезгә мәгълүм: «Ярлы халык» дигән газета чыгып килә. Вакытында ул үз вазифасын начар үтәмәде. Ә хәзер аның колачы тараеп калды. Безгә башка, бүгенге көн таләпләренә туры килердәй яңа газета чыгара башларга кирәк. Мин аның исемен дә уйлап куйдым инде—«Чулпан». Мөмкин булырмы безгә шундый газета чыгарырга?

—Мөмкин!—диде Сталин.—Ихтыярыгыз—үз кулыгызда. Бүгеннән үк эш башлагыз. Бу хакта житди сөйләшү өчен хәзер Владимир Ильич Ленин янына керәбез.

* * *

Яңа дәүләт дилбегәсен ике куллап тотучы Владимир Ильич Ульянов-Ленин бүлмәсе Смольныйның өченче катында иде. Ленинны якыннан бер күрү аның якты идеаллары иманына ышанганнар өчен зур бәхет санала иде ул елларда.

Алар килеп кергәндә, Халык комиссарлары советы рәисе эш өстәле артында язып утыра иде. Аларны көләч йөз белән каршы алды. Алар берберсенә карашып калдылар. Сынаучан, житди, шул ук вакытта ягымлы караш ул. Бүлмә әллә ни зур түгел. Артык бернәрсә дә юк анда.

Сталинның алдан шылтыратуы буенча, Ленин сөйләшергә тиешле мәсьәләнең асылын белә иде инде. Шуна күрә, аны әйтеп тормастан, Сталинга карады да:

—Тыңлыйм сезне, Йосиф Виссарионович,—диде.

Сталин да, юлбашчының төзеләчәк комиссариат максатын белгәнлеген аңлап, сүзне ул хакта түгел, ә бәлки депутатлар белән таныштырудан башлады. Иң башта, кыскача, Уфа губернасы вәкиле Галимҗан Ибраһимов турында аз гына сөйләп алды. Ленин Галимҗанга сорау бирде:

—Мөселманнар өчен генә махсус комиссариат төзү максатка ярашлымы?

Ибраһимовның җавабы әзер иде:

—Илебездә күптөрле милләтләр яши. Сәяси һәм икътисадый максатларыбыз бер. Әмма һәр халыкның үз мәдәнияте, үз гореф-гадәте бар. Без боларга нык игътибар итәргә тиеш. Шул да мәгълүм булсын: патша заманында безне «инородецлар» дип йөрттеләр. Без кимсенеп яшәдек. Хәзер, яңа чорда, бернинди дә җәбер-золымга юл куелырга тиеш түгел. Мөселманнарның күбесе әле урыс телен белми. Яңа газета чыгарып, яңа җәмгыять төзү максатын халыкка аларның үз телендә аңлатып бирергә кирәк. Бу вазифа безгә йөкләтелә.

Ленин: «дөрес әйтәсен», «шулай кирәк» дигәнне аңлатып, ым кагып куйды.

Аннан соң Сталин:

—Бу депутат Казан губернасыннан килгән,—дип, кыскача гына, Мулланур Вахитов турында сөйләп бирде.

—Иптәш Ибраһимов фикерләрен раслыйсызмы сез?—дип сорады Ленин.

Мулланур Вахитов Галимҗан Ибраһимовның фикерләре дөрес булу, аларны кабатлап торуның файдасы юклыкны әйтте дә:

—Безгә бүген үк эш башларга рөхсәт итегез,—диде.

Оренбург губернасы вәкиле Шәриф Манатов Галимҗан Ибраһимов, Мулланур Вахитов сөйләгәннәрнең дөреслеген раслап, алар әйтмәгән бер фикерне куәтләде. Әгәр Төркестан, Кавказ якларыннан да вәкилләр килсә, комиссариатның аталышын үзгәртергә кирәк булачакны әйтте ул.

Владимир Ильич Ленин өч депутатка да зур ышаныч белдерде дә хәзергә дүрт бүлек: хезмәт бүлеге, мәдәният-мәгърифәт бүлеге, хәрби бүлек, крестьяннар белән эшләү бүлеге ачарга кушып, шуның белән сүзен тәмамлады.

* * *

Эш искиткеч житди, коточкыч авыр, вакыт-вакыт баш житмәс дәрәҗәдә буталчык иде. Бер дулкын китереп бәрә дә өскә чөя. Икенче дулкын үзенә тартып алып, иләмсез рәвештә, аска батыра. Өченче дулкын янә тартып чыгара. Партияләр дулкыны да көчәя. Кайсыберсе карала, болганчыклана, аннан зәгыйфьләнә, йә бөтенләй юкка чыга. Ул торган сул эсерлар партиясе шулай булып чыкты. Контрреволюция фетнәчеләренә кушылып, советка каршы һөҗүм оештырды. Ибраһимов бу хакта башта Сталин белән киңәшләште. Бу партиядән баш тартуы, анда тормаячагы турында әйтте. Сталин аны сүзсез генә тыңлады, бу хакта төпле фикерен Ленинга да әйтергә кушты.

Башта Галимҗан ил башлыгына телефон аша шалтыратты, үзен генә кабул итүен үтенде. Кабул итте аны Ленин. Ибраһимовка Сталинга сөйләгәннәрне түкми-чәчми кабатлап чыгарга туры килде.

1918 елның азакларында Галимҗан Ибраһимов авырып аяктан егылды. Эштән китәргә гариза язды ул. Ләкин рөхсәт итмәделәр. Дәвалану өчен тагы да бер ай вакыт кына бирделәр. Ак чехларның кара дулкыны Казан, Самара һәм башка күп кенә калаларга ябырылды. Төн йокылары качты Галимҗанның. Кичерешен ул Мулланур Вахитовка ярып салды, кулына мылтык алып, шул давыл эченә томырылачагын әйтте.

Әмма Мулланур Вахитов Галимҗанга утка ташланырга рөхсәт итми. Сталин белән сөйләшеп, Казанга үзе китә. Сталин Вахитов урынына Ибраһимовны куя...

Бераз савыккач, максатына ирешә Ибраһимов. Лениннан рөхсәт алып, туган ягына юл тотты, һәм менә Көнчыгыш фронты өчен батальоннар оештыручы башлыгы, якташы Мәхмүт Шәһиәхмәтов янына килеп житте.

... Шуларны артык кабатланмыйча, сүз тәмен җибәрмәслек итеп сөйләп бирде дә Галимҗан Ибраһимов:

—Берәр батальонына куй мине, Мәхмүт энем, тик арбага таккан дегет чиләге итеп түгел, ә бәлки...

Галимҗанның фикер җебе өзелде. Аны Мәхмүт ялгап җибәрде:

—Аерым батальон кырач җиледәй шашкын күнеленә тар булачак, Галимҗан абый, мин сезне бөтен Урал буйларын, Себерне иңләп-буйлап, аркылы-торкылы кыдырып йөри торган эшкә җибәрәм, бер түгел, ун роман язарлык хикмәтләр табарсың анда. Аклар ягына разведчик булып китәсең...

—Разведчикмы, шымчы яки шпион булыпмы?

—Барысы да уптым-илаһи.

—Шәп идея! Тик булдыра алырмынмы?

—Сез, үзегез әйткәнчә, Ленин-Сталин катылыгында тәрбияләнгән кеше!

—Минем төп вазифам?..

—Серләр дөньясына чуму. Колчак армиясенең төп көчләре, халыкның ничегрәк сулыш алуы, акларга, кызылларга мөнәсәбәте... Кыскасы, сезне өйрәтеп торасы түгел инде, Галимҗан абый. Килештекме?

—Килештек!

—Тик бу матур, озын чәчегез, киемегез белән «бәхилләшергә» туры киләчәк.

—Сүзгә бик остарып киткәнсең, Мәхмүт энекәш!

—Чөнки мин бәләкәй чактан ук Сезнең кебек тел сәнгате осталары белән аралашып үстем.

—Конкрет сөйлә әле.

—Чәчеңне кырып ыргытабыз. Өстеңә ямаулы бишмәт киясең. Шыгырдап торган арбага бурлы алаша җигелгән булыр. Әле генә дегет чиләге турында сафсата саттык. Арбаңа дегет чиләге такмый булмый инде, хөрмәтле Галимҗан абзыкай?

Галимҗан түземсезләнә башлады:

—Әкият сөйлисең, Мәхмүт энем, нигә кирәк бу лыгырдауларың?

—Арбаңа урактыр, чүкечтер, чалгы ише крәстиән өчен кирәкле нәмәстәкәйләр төярсең. Кыскасы, сез—кырык тартмачы карт кебегрәк. Ичегенә сакалның ни төслесен ябыштырыйк икән: карасын, сарысын, җирәнен?..

Галимҗан көлеп җибәрде:

—Кара сакал арттан калмый ул. Шунысын сылыйк.

Шуларның һәммәсен эшләгәч, Галимҗан карачкыга куярлык бер карт сыйфатына керде. Әлеге вәгъдә иткән бурлы алашаны арбага җиктеләр дә, кулына чыбыркы тоттырдылар. Яз аеның яңгырлы караңгы бер төнендә бишенче армиянең унган солдатлары Галимҗан Ибраһимовны яшерен юллар белән фронт сызыгыннан үткәреп җибәрделәр.

## Өченче бүлек

«Кеше авырлыкта сынала», дигән әйтем дөрес икән. Пелатән төрмәсендә дә төрлесе бар. Берәү бәдрәфтә асылынды. Икенчесе зәһәр еландай бөгәрләнеп үлде. Өченчесе иртән җенләнеп торды да, әллә нинди ямьсез, ачы тавышлар белән такылдарга кереште:

—Мин Аллага ышанмадым, муллаларны эт урынына типкәләп, себер җибәреп бетердем, егерме халык дошманының исемлеген бирдем НКВДга, сигез авылның мәчет манарасын кисеп аудардым, яңалыкка агу булып торучы дин тамырын корытучы да мин. Дингә ышанмадым. Минем иманым—совет власте, коммунистлар партиясе иде. Бу иман мине төрмәгә япты. Мине каторга, йә атылу көтә. Нәләт коммунистлар партиясенә! Совет хөкүмәтенә нәләт. Ленинга нәләт. Сталинга нәләт!.. Ләгънәт...

Бу вакытта яктырып килә иде инде. Күпләр уяу. Иләс-миләс йокы белән ятканнар да ачты күзләрен. Бу кеше үзен сөттән ак, судан пакъ итеп күрсәтергә, мактанырга, шапырынырга, башкалар күзенә көл сибәргә ярата иде.

Башта партиягә тел тидерүчеләргә йодрык күрсәтә иде. Хәзер аны эткә әйтмәс сүзләр белән сүгә.

Иблистәй акырып-бакырып уянган бу кешене белә Галимҗан Ибраһимов. Исеме аның—Габи. Фамилиясе—Нифаков. Габи—гарәп сүзе. «Ангыра» дигән мәгънәдә. Нифак—тыштан ялтырап, эчтән әшәкелек кылучы, ике йөзле, монафикъ, күз буяучы, алдакчы.

Галимҗан Ибраһимов Татарстан җөмһүрияте Фәннәр Академиясе үзәге рәисе итеп сайлангач, Габи Нифаков шунда инспектор кебегрәк вазифа башкарып йөргән иде. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлагач, вакыт-вакыт фәнгә мөкиббән бирелеп китә ул. Уку-укыту эшләре турында вак-төяк мәкаләләр дә язгалаштыра. Революциядән соң аның бу таланты

канат җәеп җибәрә. Галимҗан Ибраһимов аларны укыштыра һәм егетләренең фәнгә атлыгып килүләренә шатлана да иде. Казандагы Фәннәр Академиясе үзегенә эш сорап килгәч, Галимҗан Ибраһимов аның теләген кире какмады.

Ул вакытта Академик Галимҗан Ибраһимовның нотыгын анлады булса кирәк Габи Нифаков. Дәртләнеп, ялкынланып, ихлас күңелдән хезмәт итеп йөрде. Кирәк чакта утырган каздай сенеп эшли дә ала, йомыш кушсаң, яшен ташыдай атылып чыгып йөгерә, бер басасы урынга биш басып тору галәмәтен дә килештерә. Тиз кызып, озак сүрелә торган гадәте дә бар. Аннары кешеләр гәпләшкәндәге чыш-пыш, имеш-мимешләрне, былдыр-былдыр сөйләшүләрне колагына кертеп куя. Нинди дә булса бер форсаттан файдаланып, аны остазы Галимҗан Ибраһимовка житкерә. «Сезне фәлән кеше фәлән дип әйтте» дип, куштан хатыннарча авызын бишкә бөреп, сүз ләззәтен югалтмаска тырышкандай, сөйләргә керешә. Галимҗан Ибраһимовның кырыс табигате боларны кабул итә алмый, билгеле, сул кулын селтәп куя, йә «куй әле», «гайбәт җыйма», «килешми ир кешегә» кебек сүзләр әйтә.

Дөрес, Галимҗан Ибраһимовны Ялтага озатканда шактый егетлек тә күрсәтте ул. Остазы яткан носилканы ике кеше күтәрде. Шуның берсе Габи Нифаков иде.

Галимҗан Ибраһимов Ялтага киткәч, язышуын ул дәвам итте. Монда да ике койрыкны эләктереп ала. Берсе—карьера койрыгы. Аңа шөһрәтле, дан китерә торган югары урын кирәк. Икенчесе, «намусына» тигән кешеләр итәгенә ут төртү, өсләренә пычрак чәчү. Моның өчен, иң кулае—НКВДга яшерен хат җибәрү. Соңгы елларда вакыты да бик шәп туры килде. Репрессияләр китте. Һәр хаты белән бер кеше башын ашый торган «мәшһүр» коммунистка әверелә ул. Кешегә кабер казысаң тирәнрәк казы, үзең дә сыярлык булсын, диләр бит. Бервакыт ул үзе дә фани дөнья газраиле кармагына килеп эләгә...

Тоткыннарның кайсыберсе—артык авыру булмаганнары—дәррәү сикереп торып, Габи Нифаков янына барды. Аны төрлечә сүктеләр:

—Ни үзең йокламыйсың, ни безгә йокы мазасы бирмисең. Хәшәрәт...

—Муенына пычак салган чучка урынына чыелдый, кабахәт...

—Чирле түгел, врачларны алдарга маташа.

Габи һаман чәбәләнде. Берсенең битенә төкерде. Шуннан аны кемдер сугып җибәрде. Әллә кая тәкмәчләп барып төште Габи. Йөрәкләрендә нәфрәт ачуы кайнаган тоткыннар аны типкәләргә керешә.

Галимҗан Ибраһимовның хәле мөшкел иде. Шулай да, авырлык белән булса да торып, алар янына барды да:

—Кирәкми, туганнар, сукмагыз, алай ярамый, адәм баласы бит ул...—диде.

Галимҗан Ибраһимовны тыңладылар. Иллә мәгәр ачы сүз һаман Габи өстенә яуды:

—Эткә эт үлеме...

—Тагын бер шыңшыса, буам да ташлыйм...

—Вәт син аны... сасыган кәҗә тәкәсе...

Бу сүзләр бензинга ут ташлаган кебек булды Габи өчен. Ул, үгездәй үкереп, янә катырак елап җибәрде.

Галимҗан аны юатырга тырышты:

—Нигә болай йомшыйсың әле син, Нифаков, кулга ал үзеңне, кешеләр алдында оят бит...

Нифаковның ашка таш атуы барысын да нык гаҗәпләндерде:

—Мин халык дошманы түгел, син ул халык дошманы, Галимҗан абзыкай, син, син, син... Ун ел буе Ялтада совет калачы ашап ятып фашизмга хезмәт иттең. Фашист син, фашист, фашист...—дип, яраланган ерткычтан ким кыланмады ул.

Кемдер аны янә сугып җибәрде. Янә шашкан йодрыклар хәрәкәткә килде.

Ибраһимов исә һаман яклады аны:

—Кирәкми, сукмагыз, туктагыз... Минем өчен булса, тырнак белән дә чиртмәгез. Ул бит аңында түгел. Саташа. Мин үземнең саф икәнлегемне беләм. Шул җиткән миңа...

* * *

Иртәнге аштан соң Габине допроска чакырдылар. Ике сәгать чамасы торды ул анда. Ул чыккач, Галимҗан Ибраһимовка дәштеләр. Яткан җиреннән торып, атлап китим дисә, аның аяклары карышты; аларга, әйтерсең, гер ташы такканнар. Егылып китүеннән куркып, ике ир-егет ике ягыннан култыклап, тикшерүче бүлмәсе ишеге янына китереп куйдылар. Ул кереп киткәндә:

—Галимҗан абый, берүк борчылмагыз, үзегезне сакларга тырышыгыз, сезгә барыбер бернәрсә дә булмаячак, коткарачаклар, менә күрерсез,—дип калды алар.

Ләкин бу егетләрнең фараз итүе һич кенә дә чынбарлыкка туры килер кебек түгел. Тикшерүче йә мәңгелек каторга, йә атылу белән куркыта; әгәр инде аның теләкләрен үтәсә, котылу вәгъдә итә. Тик ул теләкләр Галимҗан Ибраһимовның корыч характерын йомшартырлык түгел икән шул. Чөнки аның өстенә һаман әле яңадан-яңа пычрак өелә бара. Аннан алда гына кергән Габи Нифаков күп итеп нахак бәлаләр язган да имзасын куйган. Тикшерүче аны үзе укып күрсәтте. Галимҗан Ибраһимов Академик үзәктә рәис булып торганда аны Германиягә укырга барырга, анда фашистлар белән элемтәгә керергә, аларның эш ысулларын өйрәнергә кушкан, янәсе. Шуңа охшаш тагын әллә күпме нәрсәләр язып бетергән. Ахырдан «фашист ул Галимҗан Ибраһимов» дип тә куйган.

Ярый, Габи Нифаков шулай кылансын да, ди. Икенче берәүнең, инде шактый танылган талантлы язучының шулай кылануын бернинди әхлак бизмәненә салып үлчәү мөмкин түгел. Ул драма әсәрләре дә, шигырьләр дә яза, фән белән дә шөгыльләнә. «Галимҗан Ибраһимов кебек фашист ялчысы нишләп һаман кулга алынмый» дип борчыла ул. Аны да укып күрсәтте тикшерүче. Әлеге шагыйрь-драматург аннан үч алгандыр инде, кайчандыр Ибраһимов аны Академ үзәккә эшкә алмаган иде...

«Колга»-Мөбәрәкнең дә шикаятьнамәсе бар. «Галия» мәдрәсәсендә укытканда, Галимҗан Ибраһимов: «Американың гади эшчесе дә безнең илнең буржуеннан яхшырак яши»— дигән шәкертләргә. Тагы да әллә ниләр, әллә нәрсәләр. НКВД да эшләгәч, элек аның шәкерте икәнлекне белеп, Мөбәрәктән дә допрос алганнар, күрәсең. Болганчык заманда зур шәхесләргә нахак бәла атып, үзен афәттән саклап калырга маташканлыгын Ялтада чакта ук аңлаган иде инде аның «остазы».

Колчак тылында йөргәндә Галимҗан Ибраһимов акларга хезмәт иткән, имеш. Моны да Мөбәрәк язган.

Шуларны раслап, кул куярга тиеш Ибраһимов. Галимҗан дөрес булмаганнарын кире какты. Ул Академик үзәк рәисе булып эшләгән елларда Германиядә фашизм булмый диярлек әле. Тикшерүчене ул шуны да белмәгәне өчен гаепләде. Теге галим булырга җан атып йөргән язучы шикаятьнамәсен көнләшү чире дип атады. Ә инде теге вакытта Американың гади эшчесе дә безнең илнең буржуеннан яхшырак яшәве турында әйткән сүзләреннән танмады. Бу—туган илне гаепләү түгел. Бу—Русиянең ярлылыгы өчен ачыну.

Сулыш алуы авыр булса да, күңелдә барын әйтми калмады Ибраһимов. Мәгәр үтәмәде тикшерүченең кайнар теләген. Кул куймады беркетмәгә.

—Ярый, тиешле җәзанны алырсын,—дип калды тикшерүче аның артыннан.

Котылу чарасы юклыкны ачык аңлады хәзер Ибраһимов...

* * *

Галимҗан Ибраһимовны бу юлы сакчы белән Фатыйма ханым ике яктан култыклап китереп куйды. Аның бәхетенә икесе дә миһырбанлы

кеше булып чыкты. Сакчы аның колагына:

—Галимҗан абый! Мин сезне яхшы беләм, «Безнең көннәр» дигән романыгызны укып чыккан идем. Сезне коткарачаклар. Шундый кешенең «халык дошманы» булуы мөмкин түгел.

Фатыйма ханым—табибә. Тоткыннар арасындагы авыруларны дәвалаучы. Ул да бер җае туры килгәндә беркөн аның «Яшь йөрәкләр» романын яратып укуын әйтте. Дөрес, сакчы кебек артык ачылып та китми ул. Ярамыйдыр чөнки. Ни дисәң дә врач. Ул яшь әле. 28-30 тирәләредер. Зифа буй. Нечкә бил. Ак йөз. Ачык чырай. Карашында мәрхәмәтлелек чаткылары сирпелеп тора. Даими рәвештә елмаеп йөрергә тырыша. Моның сере нидәдер—тәгаен генә әйтү кыен. Табибә булган өченме? Әллә үз галәте, самимилеге, садәлеге, рухи халәте шулаймы? Барысы да бардыр. Эче дә, тышы да матурдыр. Галимҗанга ул аеруча мөкиббәнә карый. Ниндидер серле хис-тойгы белән. «Яшь йөрәкләр» романы өченме? Әллә кызганыпмы? Ничек кенә булмасын, аның һәр карашында наз, шәфкатьлелек нуры бар.

Шулай да мәсьәләнең бер читек ягы күңелне берникадәр шомландырып та куя: нишләп бу аккош мондый кара дөнья дулкынында йөзеп йөри соң әле? Беткәнмени калада ул нур балкытып эшләрдәй якты шифаханәләр? Бу уйларының дөрес түгеллеген шундук аңлап, Ибраһимов үзен-үзе сүгеп тә куя. Кем белә: диплом алгач, аны шушында эшкә тәгаенләгәннәрдер.

Галимҗан Ибраһимовны кертеп яткыргач, сакчы чыгып китте. Фатыйма ханым да озак тормады. Авыруларны бераз караштырып, үз бүлмәсенә ашыкты. Врач кешенең шул инде: аның карамагына килеп эләккән икән хаста кеше,—җинаятьчеме, провокатормы, шпионмы ул,—аларны карарга, дәваларга тиеш. Шул изге вазифаны үтәп йөри Фатыйма ханым.

Тик ул чыгып китеп ун-унбиш минут торгач, янә тавыш купты. Габине тагын тәпәләргә тотындылар. Ул, допростан чыккач, Галимҗан Ибраһимовның—бөек шәхеснең «йөзен фаш итүе» белән мактанган икән. Әле дә: «Галимҗан Ибраһимов фашист ул» дип мыгырданып яткан. Нәтиҗәсе шул: хәзер янә йодрык сыеннан авыз итә.

Тоткыннар Галимҗан Ибраһимовка карата йөрәктә олы мәхәббәт саклый. Сәяси-икътисадый мәсьәләләр буенча аек карашлы булганы өчен генә түгел, әлбәттә. Гәрчә үзе авыр хәл кичерсә дә, аларның рухын күтәреп тора әле ул. Йомшамаска, нык булырга, начар уйларга бирелмәскә куша. Аның һәр сүзе зур мәгънәләргә ия. Дөрес, бүген бик борчылып чыкты ул сорау алучыдан. Габи белән Мөбәрәкнең әләкләре изде аның йөрәген. Кызгана ул аларны. Репрессияләр заманында үз мәнфәгате, үз корсагы, үз ипи шүрлеге өчен җан атып, башкалар бакчасына таш атулары, кешелеклелек сыйфатларын югалтулары өчен кызгана.

Фатыйма ханымның назлы, эчкерсез, җылы карашы, сакчы егет күңеленең матурлыгы, янә шуларга охшаш күркәм сыйфатлар яшәтәдер дә әле аны. Тик теге Габине тагы да дөмбәсләргә керешүләре генә әллә ничек. Үтермәскә кирәк аны. Суд эскәмиясенә утыргач әйтсен иде Ленинны, Сталинны, совет хөкүмәтен күрә алмаганлыгын. Белсеннәр иде шундыйларның кем икәнлеген. Теләсә кемнең маңгаена «халык дошманы» дигән кара мөһер чәпәмәсеннәр, гаделлекне гаделсезлектән аера белсеннәр иде. Авырлык белән торып утырса да, калкытып китә алмады Ибраһимов. Янадан салам «түшәгенә» ауды. Шуларның берсе,—гаҗәп үзенчәлеклесе, кеше йөрәген аңларга ярдәм итә торганы, начарлыктан яхшылык эзләргә кызыксындырганы,—тәсбих төймәләренең иң зурысы.

Ул—болай. 1899 елда, аңа 12 яшь чакта, Ырынбур мәдрәсәсенә укырга барырга җыенган вакытта, Хөрмәтулла исемле бер зимагорны ат койрыгына тагып йөреттеләр-йөреттеләр дә, Нәҗметдин байның салкын келәтенә кертеп ыргытып, бозау зурлыгы йозак белән бикләделәр дә куйдылар. Ул, имеш, Мөбахис мәзиннең кара сарыгын урлаган. Авылда Хөрмәтулланың «ат карагы» дигән даны бар. Төшендә ул бервакыт ат урлый. Шуны халыкка чын итеп сөйләп йөри. Шуңа сылтанып, югалган мал баласен аңа тага башлыйлар. Мөбахис мәзиннең кара сарыгы югалгач та шулай була. Галимҗан һәм

аның яшьтәшләре монын нахак икәнлеген аңлый. Шуна күрә, ачкыч яратып, келәтне ачалар да (сакчы төнлә кайтып киткән була), эчкә кереп, Хөрмәтулланы коткармак булалар. Ләкин ризалашмый «ат карагы»: «Ярамый, малайлар, мине сез качырганлыкны барыбер белми калмаслар, үзегезгә сүз килер бит, минем аркада авырлык күрерсез»,—ди. Сарык табыла. Башка бәләләр тагып, Хөрмәтулланы барыбер тереләй кабергә күмәләр. Ишле балалары, хатыны ятим кала.

Галимҗан бу вакыйганы бик авыр кичерә. Әмма Хөрмәтулланың олы йөрәген аңлау аның—мулла малаенын—гади халыкка булган мәхәббәтен янә арттырып җибәрә. Инде килеп, менә бу кыска гына буйлы, мөлаем карашлы егетнең йөрәген ярып бирергә, шулкадәр зур авыр эшне үз җилкәсенә алырга әзер торуы кешеләр хакында янә житдирәк уйланырга мәҗбүр итте аны. Әсәрләрендә Кеше йөрәгендәге асылташның кыйммәтен сурәтли алдымы соң ул? Әсәр каһарманнарын ак һәм карага бүлү белән генә шөгыльләнмәдеме? Бу яшь егетнең олы мәхәббәте әдәбиятка булган олы мәхәббәт белән бәйләнде. Әдәбият зур ул! Әдәбият бөек ул! Әдәбият илаһилык ул! Әдәбият рухлар югарылыгы ул! Әдәбият кешеләр күңеле байлыгы ул! Кешеләр күңеле байлыгын караңгы зинданга ябу—зур җинаять! Дөнья җинаяте бу! Алла алдында кылынган җинаять! Алла андыйларны гафу итми! Андый илне Алла ора! Шашынган Помпей шулай булмадымыни?

* * *

Күз йому белән генә төн катмый. Бүген аның төне Колчак гаскәрләре тылында разведкада йөргән чагындагы китап сәхифәләрен актарып үтте.

Дүрт ай сәяхәт итте ул анда. Һәр көнне баштан кичергәннәрне бәйнә-бәйнә тасвирлап язсаң, үзе зур китап булырлык. Дүрт ай эчендә, мең төрле газап чигә-чигә, әллә күпме авыллар, Курган, Красноуфимск, Төмән, Екатеринбург, Ишим кебек шәһәрләр аша үтте ул.

... Колчак тылында Галимҗан Ибраһимов берүзе генә түгел. Төрле урыннарда партизаннар отрядлары да төзелде. Алар акгвардеецларның әле уң як, әле сул як сыртларына китереп сугалар, корал складларын яндырып, хәрби көчләрен дә киметәләр, поездлары да төзелде. Алар акгвардеецларнын әле уң як, әле сул як сыртларына китереп сугалар, корал складларын яндырып, хәрби көчләрен дә киметәләр, поезд эшелоннарын чәнчелдереп, әллә күпме зыян салалар. Баштарак халык кемне тыңларга да белми аптырый иде. Бер авылның бишәр мәртәбә кулдан-кулга күчкән чаклары була. Кызыллар җир оҗмахы вәгъдә итә. Акларның да өмете дөнья йөзенә шәфкать нуры өрү, имеш. Ике якның да сүз очы бөек Русия мәмләкәтен зурлау тойгысына килеп терәлә. Бәй, баксаң, бу тигезләр. Ул вакытта әйтерләр прәме: «Патшасының башы зур, иленең ашы зур»,—диярләр. Вәт. Тигезләндеме? Ләкин дә бит хәзергә: «Патшасының күңеле күктән, халкынын төсе киткән»,—дип әйтергә мөмкин әле.

Мужикның йөрәк төпкелендә асылташ кына түгел, аның кулында акыл бизмәне дә бар. Әнә шул бизмәнгә салып үлчи ул теге яки бу четрекле, каршылыклы мәсьәләләрне. «Дөреслек бизмәне» дип аталды бу. Бизмәннең бер ягына кызыллар акылын, икенче ягына акларныкын салдылар. Кызыллар акылы авыррак тартты. Ни өчен? Чүтеки алар гаскәри йөгәннең авызлыгын тора-бара нык тешләп алып, әдәп тәртәсе арасына вакытында керә белделәр. Ватан дилбегәсе алар кулында калачакка иманнары камил булды шикелле. Дөреслек солдатка да нык кирәк. Эшнең хакыйкатен ихлас күңеле, аң-акылы, йөрәк хисе белән аңласа, Ватан өчен солдат канатлы тулпар булырга әзер тора, дөреслеккә ялган ямау сала башласалар, солдат ишәктәй кире бер җан иясенә әверелә. Ишәкнең арт ягына ут төртеп кусаң да, тулпарга әйләнми инде ул, җан кисәккәйләрем!

Боларның барысын да ишетеп, әллә нинди фаҗигаләрне, кан дәръяларын күреп йөрде Галимҗан Ибраһимов. Әллә алга бара, әллә артка, әллә уңга, әллә сулга—вакыт-вакыт ул бу кадәресен дә чамалый алмады

хәтта. Кызыллар казанында да кайнашты, аклар аланында да айкалып чайкалды. Бер авылдагы канлы фаҗигане ишеткәч, кешеләрдән юл сорашып, бурлы алашасын шул якка борды ул. Иртән көн матур гына башланды. Монаеп кына июль кояшы чыкты. Дилбегә буе чамасы күтәрелгәч, аның моны утка әверелә башлады. Төш вакытында бу ут мине кайнатыр дәрәҗәдә шашынды. Ашарына да, эчәренә дә беткән иде Галимҗанның. Бер йотым су хәзер аның өчен алтын бәрабәрендә. Ләкин юк су. Башка вакытта йә чишмә, йә бәләкәй генә булса да бер елга очрый торган иде. Әмма бүген алар да юк. Юк, юк, юк... Шөкер, кичкә таба күк йөзендә бияләй зурлык кына болытлар күренгәли башлады. Бияләйләр бер-берсенә акрынлап сырышырга керештеләр дә тора-бара мендәргә, ястыкка әверелделәр. Ястыклар бергә кушылгач, алар инде биек-биек күксел-кара хасил иттеләр. Кояш шулар артына яшеренде. Рәхәт хәзер. Җиләс җил исә. Җилгә каршы авыз ачсаң, тамак төбендәге касмак та ярчаланып беткәндәй тоела. И-и-х! Иртәрәк шатланган икән Галимҗан. Бервакыт, тау-таш җимерелгән тавышлар чыгарып, күк күкрәде; яшен утлары, зәһәр-агулы еландай кыланып, кара-кучкыл болытларны телгәләргә кереште. Болытлар һаман калыная бара. Яшен аларны һаман телгәли дә телгәли. Күк күкрәве хәзер мең иблис улаган тавышлар чыгара. Янгыр башта сибәләп кенә үтте. Бераздан кыза төште. Тора-бара чиләкләп коярга тотынды. Барачак авылны илле чакрым чамасы дигәннәр иде. Эсседә Галимҗан алашаны ул кадәр нык кумады, бер атлатып, бер юырттырып барды. Бәгъзе бер вакыт үз иркенә куйды. Хәзер инде чаптыртудан башка хәл юк. Янгыр һаман чиләкләп коя. Хәзер инде Галимҗанның энә белән төртерлек тә коры җире калмады. Шуна күрә ул алашаны кыздыра бирде. Алай-болай киреләнсә, каеш чыбыркысын яшен утыннан ким уйнатмады.

Алны, артны, уңны, сулны шәйләмәде Галимҗан. Алашасын каеш чыбыркысы белән сыйлавын белде, барачак авылына җилкенде. Алаша да хуҗасының хәлен аңлады бугай, колакларын торгызып чаптыруын белде. Ләкин хуҗа да, алаша да зур хата җибәрде. Тип-тигез юлдан чаптырып килгәндә юл, капыл сулга таба борылып, шактый озынга сузылган чокырга таба китә икән. Алаша моны сизмәгәндер дә, бәлки. Әмма әлеге каеш чыбыркы аны тәмам ярсытты. Чабып килгән җирдән аяклары таеп китте дә әллә кая барып төште. Арба кендегеннән чыгып капланды. Галимҗан нәрсәгәдер бәрелеп, һушын югалтты.

Артык эсселектән соң килгән янгыр шашынып-шашыныпява. Ләкин озакка бармый. Бүген дә шулай булды. Болытлар да таралды. Кояш Җир балаларына кызгылт, монсу, йомшак нурларын калдырып китте. Ул нурлар озак кына әле янгырдан соң сизелер-сизелмәс кенә күтәрелгән ефәктәй йомшак җир парларын, күлдәвекләрне, үлән, гөл, чәчәкләрне назлап торды. Акрын гына, хәзер менә һәммәгезне сөеп-назлап йоклатам дигәндәй, энгер-менгер зәңгәрсу-сыек пәрдәсен тартты. Җир тыныч йокыга талгач, табигать аның өстенә кара-кучкыл юрган япты. Күк йөзендә бер-бер артлы йолдызлар калыкты. Һава саф. Тәмле. Күмәч белән катыштырып ашарлык. Җәйге төн бер тотам. Тиз үтте. Кызарып кояш чыкты. Галимҗан кояш шактый күтәрелгәч кенә аңына килде. Зәңгәр күккә күз бакты. Анда сабан тургае сайрый. Бернинди тавыш юк. Торыйм дисә, гәүдә бөтенләй селкенми. Әйтерсең, аны җиргә кадак белән беркетеп кагып куйганнар. Менә аның янына ике юлчы килеп туктады. Акрын гына чыш-пыш сөйләшәләр. Әмма сүзләрен аңлар хәл юк. Менә аның берсе Галимҗанның колак төбенә үк иелеп пышылдады:

—И... апзый, син тереме, үлеме, нишләп ятасың пынта, палчыкка пуялып петкәнсең пит, мескен, ай-яй-яй... Нишләтәпес кәзер пуны, Кәерлезаман тукан, ә?...

Сөйләшүе буенча Галимҗан бу кешенең чуваш затыннан икәнлеген аңлап алды. Бу якларда да бар микәнни чувашлар дип гаҗәпләнде. Тик җавап кайтарырлык көче юк иде аның.

Юлчыларның икенчесе телгә килде:

—Кем булыр был бисара әзәм, ә? Карасы быны, Питрәй туган, гүпси эштән сыккан бит, и бисара, бисара, үзе суска урынына бысранып бөткән, вәйт кәһәрен...

Бусыныкының теле башкорт халкыныкына охшаган. Димәк, башкортлар да яши бу тирәдә. Әмма сүз кайтарырга һаман көче житмәде.

Менә бервакыт алар Галимжанны икәүләп торгызып утырттылар. Башта чуваш сөйләде:

—Пу пит, парень, Султанмураттагы Кирпан муллага укшаган, пәйт син аны, суйкан да каплаган...

Сүзне башкорт дәвам итте:

—Мин дә шул хакта уйлый инем әле, башкорт әйтмешләй, ике тамсы һыу кеүек окшаган бит прәме...

Галимжан ике генә сүз әйтә алды:

—Сез кемнәр?..

Тегеләр жавап бирергә дә өлгермәде—янә ауды Галимжан. Юлчыларга аның фажигасен аңлау кыен түгел иде хәзер. Ул килгән жирдә—тигезлек. Менә монда юл кырт кына сул якка борыла. Аннан озын чокыр-сыза яки коры үзән китә. Ул бер чакрым чамасы дәвам итә. Жигелгән ат аунап ята мескен. Арба капланган. Тирә-якка чалгы, чүкеч, игәү, балта, пычкы, арба кендеге, чиләк, чүмеч, кашык, пычак, савыт-саба, төенчек...—тагы да аллә ниләр чәчелгән. Ни галәмәт икән? Ничек исән калган бу кеше? Шуны уйлап аптырады тегеләр. Ә әжәлгә бер адым гына калган. Уң якка таба үзән эчендәге тирән чокыр китә. Болар шунда таба тәгәрәгән. Нибары бер адым чамасы жир калган текә чокырга. Шул ара үтелсә, ат та, кеше дә харап була иде бит. Арбасы инде аның чәнчелеп китсен. Яңаны ясадың куйдың. Ә менә кешене янартып булмый бит. Ат та жәл. Әмма ләкин кеше түгел бит әле ул.

—Кодай Тәкалә үзе куткарган пыларны, Кәерлезаман туган, үзе ыспасайт иткән, тәмукка... үлемгә тип әйтүем... смерткә... пары тик пер адым гына калган пит, пер адым гына...—дип өзгәләнде чуваш.

Башкорт та сызланып сөйләнде:

—Дөрес әйтәһең, Питрәй кәрзәш, пропал була язган бит, әйе, Ходай һаклаган, гүмерзәре бөтмәгәндер инде.

—Нишләйбез кәзер, Кәерлезаман, син шуны йәт, парень.

—Бараһы ергә бармый калабызмы әллә. Питрәй, ә?

—Пармайпыс, Кәерлезаман, пармайпыс и свю... Әжәле йиткән кешене ташлап китеп пулмый пит инде...

—Нишләтәбез һуң уны?

—Пелмәйем, парень, пелмәйем...

—Ыза сигеп ятмаһын был...

—Мин дә шуны уйлыйм пит...

Галимжан Ибраһимов аларның сүзен ишетеп ятты. «Әжәле житкән кеше» диләр бит. Соңгысы бигрәк коточкыч. Әжәле житкән, имеш. Кабер казымакчы булалармы әллә? «Иза жигеп ятмасын» диләр ләбаса. Бусы да шикле сүз. Димәк, үлем жәһәннәменә житмәгән әле ул.

Галимжан бармаклар хәрәкәте белән су сорады.

—Бәй, Питрәшкә, тау астында һалкын шишмә бар бит, һыпыр шунда, ана бизрәһе аунап ята, алып кил тултырып, бегом...—диде башкорт.

Чуваш су алып килгәнче, башкорт чәчелеп яткан әйберләрне, күчәре шартлап сынган арбаны, буылып яткан атны караштырып йөрде. Ә инде чуваш килгәч, башкорт Галимжан янә торгызып утыртты да кружка белән аңа иплэп кенә су эчерде. Үзе гел генә такылдап торды:

—Эс, агай, эс, башкорт әйтмешләй, һыйлаганда һыу эс; һыу, һауа ин шәп дарыу ул белгең килһә; их, беззең Солтанморат ауылының һауаһы, Зәңгәр шишмә, Кондызлы күл һыузары, һагынып һөйләргә генә калды...

Чуваш та үзенекен тәтелдәде:

—Син Кәерлезаман парень, Султанмурат та, Султанмурат дип тешен төшә; анлаем мин: һәр пака үз сазлыгын мактап пакылдый пит ул, әллә песнең Юламанда юкмы салкын шишмә, ә? Пар ул, парень, пар... нәкәнис...

Менә кызык. Галимҗан Ибраһимовның туган авылы Солтанморатта башкортлар, мишәрләр, типтәрләр, алатыр татарлары яши. Нык авыл. Күркәм авыл. Халкынын эшчәнлеге, жегәрлеге белән тирә-якта шөһрәт казанган. Башкортлар үзләре бер урам тота. Ул урам төньякка калын-кара урман итәгеннәнрәк сузылып киткән.

Башкортлар белән аралашырга аеруча яратты ул. Аңа ярдәмгә килгәне әткәсе Гыйрфан мулланың дусты Котлызаманның улы Хәерлезаман иде. Менә бу Питрәй дигәне күрше чуваш авылы Юламандагы Әптерәй дәдәй белән Кәтринә түтәй улы булып чыга. Аларның Әләксәй дигән уллары бер елны Алмачуар белән чабышка барган иде. Иң алдан килде елгыр малай. Данын күтәрде Гыйрфан мулланың. Тик ул—Әләксәй шуннан соң авырып китте. Аннан Әптерәй дусты белән киңәшләшеп, чабышка Гыйрфан мулла аның икенче улы Питрәйне әзерли башлады. Ул да алды беренчелекне. Чувашлар белән булган олы дуслык шуннан да килә.

Хәерлезаман башкорт, Питрәй чуваш, Галимҗанны бөтенләй чишендереп ташлап, алмашлап су ташып, башта үзен юдылар, аннан, киемнәрен тәртипкә китерделәр. Егетләрнең юл капчыкларында икмәк, кыздырылган ит кисәге, пешкән бәрәңге бар икән. Шулар белән сыйланып, бераз су эчеп алгач, аңа көч кереп киткәндәй булды. тегеләр ярдәмендә башта торып утырса, аннан, авырлык белән булса да, аякка басты, яңа тәпи йөрергә өйрәнгән баладай, курка-курка гына атлап та китте.

Егетләр камытына буылып яткан алашаны да коткардылар. Мең бәла белән, әлбәттә. Бәхеткә җаны чыгарга өлгермәгән иде әле аның. Аркалыгын, чөелдерек бавын чишеп, камытыннан азат иткәч, мәхлук алаша иркен тын алып җибәрде. Бераздан аны аякка бастырып, су да эчергәч, ул да яшәргә өмет бар икәнлекне сиздерде. Тик алашаның алгы уң аягы сынган булып чыкты. Арбаның арткы күчәре шартлап сынган. Димәк, ат та, арба да гамәлдән чыккан дигән сүз.

Хәл кергәч, Галимҗан:

—Рәхмәт, егетләр!—дип кенә әйтә алды.

Инде хәзер ныклап танышырга кирәк иде. сүзне башкорт башлады:

—Агай, башкорт әйтмешләй, ашаганда телһез, эшләгәндә өнһез булыу хәйерле. Телһез зә, өнһез зә булдык. Инде хәзер телде эшкә егер вакыт етте. Кем булыһыгыз һез үзегез? Ни эш кырып йөрөйһөгез? Кайза бара инегез?

Галимҗан тиз генә җавап бирмәде. Ни дип әйтергә? Революция солдаты? Шпион? Шымчы? Разведчик? Мосафир? Дәрвиш? Чынын әйтсәң, аңларлармы? Кирәкме ул? башта үзләренең ни-нәрсә майтарып йөрүләрен белү хәерледер. Тик алар биргән сорауны коры калдыру килешмәс. Шулай да серне ачарга ашыкмаска кирәк. Ул шаяртмак булды:

—Мин Хозыр Ильяс булам, егетләр!

Башкорт күзләрен чекерәйтте:

—Алдашасың, агай!

Галимҗан үзе сорау бирде:

—Нигә алай уйлыйсың әле?

—Сөнки Хозыр Ильяс ап-ак кейемле, ап-ак һакаллы мөләйем карт була...

Сүзгә Питрәй кушылды:

—Әйе, правильны әйтте Кәерлезаман, ул пит... Кызыр-Ильяс... мәңгелек... пер касан да үлмәй торган пигәмбәр... Кемнең кем икәнлеген әйтеп пирә турган пигәмбәр... Кыр пигәмбәре... вәйт...

—Кем әйтте аны сезгә?

—Кирпан мулла... шул Султанмураттагы инте... Кәерлезаман пелән икәү тыңлаган итек... малай чакта...

Галимҗан бирешмәде:

—Мин дә әйтеп бирә алам кемнең кем икәнлеген.

Башкорт кабынып китте:

—Әйт улайһа: кем булам мин?

—Синме? Син Солтанмораттагы гаярь башкорт Котлызаман абзый

белән чибәр Көнсылу түтинең улы Хәерлезаман буласың.

Егетләрнең күзләре тоздай булды. Алар бер-берсенә карашып каттылар. Озак тынлыктан соң сүзне чуваш башлады:

—Ә мин кем пына? Кем мин? Кайдан? Кайсы авылдан? Кем паласы пулам мин? Пик улай Кыдыр-Ильяс икәнсен, минекен дә әйтеп пир, пәйт... Ә-ә-ә... пелмәйсеңме? Тутылдыңмы?

—Хәзер әйтәм. Син... Син... Юламан авылы уңган чуваш Әптерәй белән матур күңелле Кәринә түти улы Питрәй буласың.

—Пәй, пәй, пә-ә-й, рас әйтә пит пу, рас әйтә,—дип гаҗәпләнде Питрәй. Аннан башкортка үпкә сүзе янгырады:—Пына син, Кәзерлазаман парень, кел генә мине мыскыл итәсең, көләсең миннән, ана ничек зурлады атайвмны Кыдыр-Ильяс, «уңган» тиде, найымды «матур күңелле» тиде, шулай пулгас, мин дә, аларның уллары Питрәй дә, якшы чуваш пулып чыгам, пәйт, мыннан сун чамалап сүләш, парень, минең пелән...

Башкорт көрәктәй куллары белән чуваш дустын билennән эләктереп алды да, аны туптай чөеп, янадан җиргә бастырып куйды.

Шаярышу әллә ни озакка бармады. Башкорт сорау бирде:

—Әгәр һин Хозыр-Ильяс икәнһең, башкорт әйтмешләй, кәнкритнәһен генә сатнатып ярып һал әле безгә: дөреслөк кем ягында, кызылдарзамы, актарзамы? Пунимаешь...

Аның соравын Питрәй куәтләп җибәрде.

Мондый сүзләрне күп ишетте Галимҗан.

—Сез егетләр сугыштан качып йөрисез бит. Кызыллар җиңәчәк, хакыйкать бу. Менә шул, иманыгыз кызыллар ягына каерсын,—диде Галимҗан.

Башкорт сорау бирде:

—Һин, абзый кеше, Хозыр-Ильяс булгас әйт әле безгә: Лилин, Ысталин янында беззең Солтанморат ауылы Гирфан мулла малайы Гәлимйән Ибраһимов эшләй икән. Шул дөресмө?

—Дөрес. Авылдашыгыз әнә кая үрмәләгән, ә сез качып йөрисез, оятсызлык бу. Хәзер кая бармак буласыз?

Башта, тупас кына итеп, башкорт җавап бирде:

—Этем белһенме уны, ауызын корт саккыры.

Чуваш та сүгенеп куйды:

—Пөтенесе дә алдай, кипенимәйтери, сапакылар...

Галимҗан Ибраһимов елмаеп куйды. Катлаулы сәяси вакыйгаларны, тарихи хәлләрне аларга гадиләштереп аңлатып бирергә туры килде.

Бу егетләрнең шактый шомарган таш икәнлекләрен аңлады. Мәгәр яшьләрен сорамады. Егермеләр чамасы икәнлеге йөзләреннән, фикер йөртүләреннән, балалык шаукымы чыгып бетмәү кыяфәтләреннән үк сизелеп тора. Нинди язмыш ялына ябышып йөрүләрен янә тирәнрәк белү өчен:

—Зимагорлыкта чакта, заводта, шахталарда эшләгәндәниләр кыйрата алдыгыз соң сез, егетләр?—дип сорады.

Җавапны башкорт бирде:

—Казынган карга кар астыннан калья таба, ә без, шахтала казынып, калья түгел, кумта[1]ла таба алманык, вәт, сабакы...

Сүзгә чуваш кушылды:

—Син, Кәерлезаман, тотасың да сүкенәсең, алай ярамый пит, парень, бигрәк тә олы кеше алдынта. Песнең чуваштa пер мәкал пар: «Ир акылы—пер алтын, ил акылы—мен алтын». Кем гаепле синең казынып-казынып калья табалмаганыңа? Ә?! Әллә аз казындыкмы? Ә? Ә калья? Шиш, брат... Ил акылына бәйләнгән бу... пына шулай...

* * *

Сөйләшә торгач, башкорт белән чувашның тәрҗемәи хәлен бәйнә-бәйнә аңлап алды ул. Үндүрт яшьтә чыгып киткәннәр бәхет эзләп. Чал

[1]Кумта—буш савыт.

Урал буйларын кыдырап йөргәннәр. Үзләре әйткәнчә, алтын приискасы, күмер шахтасы, күн заводы...—бересе дә калмаган. Уналтышар сәгать эштә этләнү, ач-ялангач яшәү, штраф түләү, салкын баракта тору...—шуларга охшаш мең төрле газап, кимсетелү, кешелеклелек сыйфатларыннны пычрату ошамаган боларга. «Әтәч үз чүплегендә патша»,—дип, хуҗаны эттән алып эткә салып үзләренчә генә сүккәннәр дә, әйткәндәй, койрыкларын сыртка салып, бәхет табуга һаман әле ышанган хәлдә, икенче урынга китеп барганнар. Тик яңа әтәч таң белән кычкырып эшкә куу, үз чүбендә патша булудан башканы белми. Язмыш жилләре аларны тагын да кайларга жилтерәтеп алып китәр иде дә бер колынлык, бер бәләкәй өйлек акчалы итәр иде—бусы бер Ходайның үзенә генә мәгълүм—1914 елда беренче империалистик сугыш уты дөрләп кабына, аларны патша хезмәтенә алалар. Гражданнар сугышы вакытында Ватанны саклау өчен патшага биргән антка тугрылыклы булалар әле. Аклар ягында сугышалар. Тора-бара буталып бетәләр.

Галимжан Ибраһимовның мәсләге—фәкать алга бару. Тик... нишли ала инде ул хәзер? Ат жигәргә яраксыз. Арба челперәмә килгән. Әйберләр үләттән калган нәстәкәйләргә охшап, тирә-якта таралып ята. Ә тәне аю тукмаган кешенекедәй, үтереп авырта. Вакыт-вакыт күз аллары караңгыланып куя. Сөйләшә башласа, теле тотлыга. Ике як кабырганы кемдер без белән төрткәләгәндәй тоела.

Егетләр алдында хәзер ул бакча карачкысына охшап тора. бакчага куйсаң, мең карга коты очып качачак. Башкорт та, чуваш та аңа ниндидер бер гажизанә аптырау белән карый. Һм... Хозыр-Ильяс, имеш. Алдый бу бакча карачкысы. Әллә нинди ышпиундыр әле. Хәерсез нәмә. Дилбегә тота белсә, болай адәм мәсхәрәсенә калмас иде. Жебегән. буш көпшә. Ә хәзер нишләтергә аны? Ташлап китәргә ярамый. Кешелексезлек була. Вәт хөрәсән. Ни пычагыма бүлде ул аларның юлын? Хәчтрүш.

Сизде Галимжан аларның кичерешен.

—Юл кешесенең юлда булуы хәерле, егетләр, барыгыз, китегез, мина кызганып карамагыз, Хозыр-Ильяс аңа мохтаж түгел, бәхет телим сезгә,—диде ул.

Башкорт кызды да китте:

—Һәй, сукынып катһана шул бәхетең менән, кәкрәкмәй ул безгә, тәтемәй, суска урынына һимергән түрәләр кинәнһен әйзә...

Чувашка ошамады башкортның сүгенүе:

—Син, парень, пырылдама әле, аңа песнең ярдәм кирәк, шул хакта уйла.

—Нәмә уйлайым? Нинә киреләнеп маташа ул? Нинә беззе китергә куша? Сер бирмәй, йәнәһе.

Сүз көрәштерү шактый озакка сузылды. Галимжан, хәле бетеп, гәүдәсен тота алмаган исерек кешедәй, гөрселдәп жиргә ауды.

—Петте бу мескен, үлде,—дип үрсәләнде чуваш.

Башкортның монда ачуы килде:

—Һин, Питрүшкә, илайһың да йөрөйһөң. Бөтә нәмәне яманлык сокорона бораһың. Улай ярамай тип мең кат әйткәнмендер.

—Ә нишләйбез сун? Ә?! Әйт! Әйт! Әйт! Ә-ә-ә, үзең дә пелмәйсең, парень...

Хәерлезаман ике кулы белән ике чигәсен тотты: үз башы белән үзе киңәшләшә, янәсе—бу минутта аңа һичкем мешать итмәсен. Әһә, тапты юлын. Чыпчык та үтәлмәслек кара-калын урманнарны кыдырап йөргән, завуч, шахты, фабрик хуҗалары белән якалашкан ата зимагүр кеше язмышы хәл ителгәндә, әлтәк-мәлтәк, әвеш-тәвеш уйларга бирелеп, өбәү иттәй[1] мәмрәп калырга тиешме? Юк. Аслан юк. Ярамый. Хәзер кире авылга китәргә. Ул моннан ике чакрым чамасы гына. Анда мулла бар. «Мулла «мә» дигәнне генә ишетә, «бир» дигәнне ишетми»,—дисәләр дә, бармаклар

---

[1]Өбәү ит—кайбер сөйләшләрдә туңып жебегән ит.

да тигез булмаган кебек, аларның да намус орылыгы бер үк зурлыкта түгел. Шәп мулла бу! Ачык күңелле. Эчкерсез. Самый главные шул: ач күз түгел— саран түгел. Чуваш белән икесе бергә ай буе мунча ясадылар. ай буе балдамайда йөздерде. Тамак аермады. Вәт покрайнимир мулла! Акчасын да өмет иткәннән икеләтә артык бирде.

Бу Хозыр-Ильясны шул муллага алып барып куймый булмас. Ыңгырашмас. тар күңеллелек күрсәтмәс. Ачык йөз белән каршы алыр. Хатыны чибәр себер татаркасына чәй әзерләргә кушар. Алар салган яңа мунчасын яктырыр. Тик бу аксак алашаны, ватык арбаны, чәчелеп яткан нәстәкәйләрне кая куярга? Үзе белән киңәшләшми булмас Хозырның.

Янына барса, башына чыпчык күзе зурлык кына булса да кайгы төшмәгән гамьсез алабармандай, зәңгәр күккә карап тик ята Хозыр. Аны торгызып утыртты да әле генә уй казанында кайнатканнарының барын да сөйләп бирде Хәерлезаман. Ләкин Галимҗан ризалашмады моңа.

—Юк, егетләр, кеше мәшәкатьләп йөрисем килми, Хозыр-Ильяска килешми ул, ярамый; ә сез барыгыз, китегез, минем аркада тоткарланып ятмагыз,—диде.

Кызды да китте Хәерлезаман:

—Һуң, агай, әллә белмәһеңме, ишеткәнең юкмы: юлда яткан бахырзы башкорт ташлап китә алмай, был яктан унын канында бер генә тамчы бозоклок та юк. Вәт. Пәнимәйт нады...

Баядан бирле тын гына торган Питрәй дә әйтеп куйды:

—Песнең чуваш калкы да шулай: һәр егылган месkенгә кул бирергә әзер тура.

—Башкорт халкының да, чуваш халкының да изге күңелле икәнлекләрен беләм мин, егетләр,—диде Галимҗан,—сез шул изгеләрдән дә изгерәксез, әмма ләкин мин бахыр да түгелмен, мескен дә түгелмен, кызганмагыз мине, түбәнсетмәгез...

Сүз көрәшенә Хәерлезаман йомгак ясады:

—Ярай, башкорт әйтмешләй, озон сүз—тозһоз, кыска һүз—монсыз. Һез калаһыз казакланып, мин китәмен канатланып. Килермен мулланың атын егеп, һез ултырмагыз бында ебеп. Вәт. Пәнимәйт нада...

Аюныкыдай тупас гәүдәсен уйнаклата-уйнаклата, җир күкрәгеннән ут чыгарырга теләгәндәй каты баса-баса, китеп тә барды Хәерлезаман.

Шуннан Галимҗан үз янына чакырды чувашны.

—Синең чын исемең Петр буладыр инде?

—Кәнишне.

Галимҗан көлеп җибәрде.

—Никә куләсең?

—Рәхәт синең белән, Петр туган, күңелле!

—Син тур, тур, аякка пас! Тәнеңне яз, һүрүштереп ал. Татар әйтмешләй, йөрөгән таш шомара. Шомар. Пәйт. Пир әле кулыңны.

Галимҗан кулын биргәч, чуваш аны ипләп кенә, җайлап кына аягына бастырды. Галимҗан башта беренче мәртәбә тәпи атларга йөрәксенгән, әмма тәүге адымны ясарга куркыбрак торган сабый бала кебегрәк тотты үзен. Аннан, аякларын бер-бер артлы җирдән аерып, акрын гына атлап китте. Чуваш аның артыннан барды. Алай-болай чайкала башласа, тотып ала, егылырга ирек бирми, янәсе. бераз баргач, туктап калды ул:

—Менә нәрсә, Петр дус, мин сине хәзер доктор итәм.

—Ничек?

—Чишмәдән бер бидрә[1] су алып кил дә кояшка җылытырга куй. Каланын үзең күрерсең.

—Момент.

—Петр киткәч, Галимҗан янадан чишенеп ташлады. Анадан-тума килеш калып, тәнен язарга кереште. Чуваш килгәч тә дәвам итте әле ул аны. Һәр әгъзасын кул бармаклары белән йомшак кына итеп баскалады.

[1]Бу як татарлары «чиләкне» «бидрә» диләр.

Аяк бармакларыннан башлады ул аны. Акрынлап тезгә таба хәрәкәт итте. Янә өскәрәк үрмәләде. Билен, күкрәген, муенын сыпырыштырды. Ә аркасын тырмаштырырга чуваш дустына кушты.

—Ә-ә-ә... пеләм мин поны... Массаж диләр. Шахтада да картлар шулай итә иде. Кайтасың эштән: эт кебек әлсерәп. Тән агачтай ката прәме. Аны аракы пелән дә йумшарталар. Тик унын өчен акча кирәк. Акчаң юк икән, давай массаж. Песнең ише яшь кеше ничауа әле ул. Ә пына картларга авыр. Алар тәннәрен менә шулай йумшарталар иде.

Шулай сөйләнә-сөйләнә ясады массажны чуваш. Ә инде су жылынгач, кыйммәтле бер дару белән оста эш иткән табибтай, аны бидрәдән азлап-азлап учлап алып, тәнен юарга керешге Галимҗан. Сабын да булса, шифасы күбрәк тияр иде, әлбәттә. Ләкин каян аласың аны? Бар тәнен су сибә-сибә кат-кат ышкып чыккач, арка өлешен Петрга тапшырды Ибраһимов. Зур ләззәт вә илаһилык белән керешге чуваш бу эшкә. Үзе һаман сөйләнде:

—Шахта Ычтапан дәдәй дә шулай иттерер иде, каткан аркасын миннән ышкытыр иде.

Галимҗан тагын да кычкырып көлеп җибәрде.

* * *

Хәерлезаман ат җигеп килеп җиткәндә, кояш кичкә авышкан иде инде. Аты шәп мәгәр. Дәртле урыс маржасы кебек. Бер басасы урынга биш басып, биеп тора. Бәй, тукта! Алмачуар ич бу! Хәерлезаман әтисе Котлызаман Галимҗанның әтисе Гыйрфан муллага бүләк иткән Алмачуар! Валлаһи шул! Суйган да каплаган. Ике тамчы су кебек охшашлар. Ни галәмәт? Әтисе Гыйрфан Алмачуарның бер-бер колынын теге вакытта шушы якка сатып җибәргәнме? Шул токым дәвам итәме? Булыр да. Себер татарлары белән безнең як татарларының алыш-биреш итешүе, сәүдә кылышуы, Тукай әйтмешли, тел-лөгать алмашып яшәве, бер-берсе белән сәдакатьле яки якын мөнәсәбәтле булуы элек-электән, Болгар чорыннан ук килә. Болгар осталары теккән сафьян итек-читекләрне себер татарлары мактый-мактый кигән. Яшь кызларның аякларын ул итек-читекләр аеруча чибәрли торган булган. Казан сөлгеләренең бәгъзе берсендә себер татарлары кызларының йөрәк жылысын, күз нурын, самими-садә хисләрен аллы-гөлле җепләргә катыштырып чиккән бизәкле нәкыш-чәмчәләр бар. Галимҗан боларның барысын, һәммәсен яхшы белә. Ә менә себер татарлары җирендә Алмачуар белән күзгә-күз килешүе—газаплы юлда очраган бер бәхетсезлекнең икенче бер бәхетле ягы. Кичә аты-арбасы чәнчелеп барып төшеп кырылмаса, бүген авылдашы, якташы белән күрешеп сөйләшү бәхетенә ирешмәс иде. Чит җирдә, бигрәк тә дошман тылында, сагыш утларында янып йөргәндә, бер чишмәнең суын эчеп үскән җирдәшләрең белән очрашу бәхет түгелмени? Җитмәсә, алар үлемнән коткарды бит әле аны. Алмачуар белән күзгә-күз очрашу бу җылы тойгыларны янә кайнарлатып җибәрде. Бак син: нәкъ аларның Алмачуары! Тарантасы да аларныкына охшаган хәтта.

Галимҗан атка якын ук килде. Алмачуарның күзләре моңсу, сагышлы, ямансу иде. Галимҗан башта Алмачуарның мангаеннан, күзләреннән сөйде, аннан муеннан кочаклап алды, биш бармагы белән ефәктәй кабарып торган ялларын тарады, сыртларын иркәләп сыйпаштырды. Аннан ат исе генә түгел, Солтанморат һавасы исе килгәндәй тоелды.

Алмачуарны сөеп туйгач, Галимҗан әллә ни ерак булмаган урында басып торган бурлы алашасына күз ташлады. Кара инде син аны: муенын сузып, күзләрен мөлдерәтеп карап тора бит бу якка. Әллә көнләшәме? Булыр да. Аерылышу мизгелен авыр кичерәме әллә? Булыр да. Ат аңлый ул. Ат акыллы ул. Барын да сизә. Белә. Йөрәге белән кичерә. Тик хис-тойгысын сөйләргә теле генә юк. Янына барсаң, кайнар мәхәббәтен, яратуын йә матур, моңлы кешнәве белән, йә башын муеныңа салып, йә аякларын тыпырчындырып аңлата. Ә без—Алла биргән җан ияләре арасында иң бөек акыл йөрткән кешеләр—шул изге мәхлукны чыбыркылыйбыз гына бит.

Йөрәге ярылып үләр чиккә житкәнче чаба, мескен ат, арый. Алжый. Манма тиргә бата. Ул, бәлки, эченнән генә әйтәдер: «Менә моннан соң, абзыйкаем, бу ерткычлыгыңны мәңге онытмам, синең ише канэчкечкә хезмәт итмәячәкмен, качам, олагам, жигәргә дип яныма килсәң, тибәм дә очырам»,—дидер. Әмма ат ачу саклый белми. Икенче көнне үк, хужасы йөгәнен ике кулы белән аерып ачып килсә, зур башын шунда тыкканлыгын сизми дә кала.

Галимжан, аксаклап-туксаклап, алашасы янына китте дә, аны да иркәләп-сөеп, ялыннан тотып, болар янына алып килде.

Хәерлезаман түземсезләнә башлады:

—Мулла абзыйга мин бөтәһен дә һөйләп бирдем, был хәлде ул белә, аты ла, әйберзәре лә калһын, үзегезне генә ултыртып алып килергә кушты.

Моның белән килешмәде Галимжан:

—Юк, туганкайларым, бурлы алашамны калдыра алмыйм, ул инде минем жан дустыма әверелде. Ташлап китсәм, гөнаһ булыр, ньк рәнжер мина.

Шуннан болар жәһәт кыланырга тырышты. Алаша тарантас артына тагылды. Әйтерләрен дә тегендә-монда тутырып бетерделәр. Кучер вазифасын үз кулына алды Хәерлезаман. Галимжан белән Питрәй тарантаска жайлашкач, үзе кучер урынына менеп утырды.

Алмачуарны акрын гына атлатты Хәерлезаман. Алаша, аксаклый-аксаклый бара бирде.

«Жәһәннәм юлы» тип әйтәләр икән был юлды»,—диде берара башкорт.

Ибраһимов эндәшмәде.

* * *

Шактый зур, матур, күркәм авыл. Галимжан аны ерактан, тау сыртыннан үткән «жәһәннәм» юлыннан барганда ук күзәтеп килгән иде. Авыл яшеллеккә күмелеп утыра. Озын тирәкләр күренә. Көн искиткеч матур. Һава саф. Зәңгәр күк йөзендә бияләй зурлык та болыт юк. Тыныч. Жил дә кайдадыр ял итә, ахры. Авыл өстендә—сыекча зәңгәрсу өрфия рәшә.

Көн ягында—тигезлек. Тукта, аның тияге Солтанморатны хәтерләтә ләбаса бу авыл. Тизрәк барып житәсе, аның эченә керәсе, шул өрфия белән ләззәтләнгән горур әтәчләрнең ара-тирә монсу гына кычкыруын, этләрнең анда-санда ялкау гына өреп алуларын ишетәсе килде. Авыл кырыеннан киң генә елга да ага икән. Бусы да Солтанмораттагыча. Эрелеваклы өйләре дә Солтанморатны хәтерләтә.

Алар сарыга буялган бер капка алдына килеп туктадылар. Капка матур бизәкле. Түбәле. Ян капкадан аксак мулла килеп чыкты. Чыкты да Галимжанга карап катты. Килеп кочаклады:

—Остазым!.. Нинди жилләр китереп ташлады?..

—Замана жилләре йөртә, Сәрвәретдин шәкертем!..

Сәрвәретдин капканы ачты. Алар эчкә—ишегалдына үттеләр. Аксак мулла остазына, тарантастан төшәргә ярдәм итте. Төшкәч, өйнең тышкы күренешен, ихатаны күздән кичерде остаз. Ихата—иркен генә. Уң якта—бакча. Арткы өлештә—абзар-кура. Сул ягында—яңа гына салынган мунча. Өй—уртача зурлыкта. Түбәсе калай белән ябылган. Тышкы күтәрмә дә сарыга буялган. Күтәрмә төбендә- бер пар аяк савыты. Ул күтәрмәгә кешеләрне пычрак аяк белән бастырмас өчен сакта тора кебек.

—Болай һәйбәт яшисең икән, шәкертем,—диде Галимжан, барына да күз йөртеп чыккач.

Сәрвәретдин егетләргә әмер бирде:

—Сез, егетләр, атны тугарыгыз, алмачуарны да, бу бурлы алашаны да яхшылап карагыз, ашатыгыз, эчерегез,—диде дә остазны өйгә чакырды.

Галимжан бер аягына, бер кылка киемле өстенә карап аптырады. Өеннең нурын алмаммы, котын жибәрмәмме бу алама кием белән, дигәнне аңлата иде аның кыланышы. Шәкерте сизде моны. Остазын юатырга керешт

ул:

—Мин хәлегезне аңлыйм, Галимҗан абый. Хәерлезаман җентекләп сөләп пиргән ите, унайсызланмагыз, әйдә, кериек әле. Монта пер куркыныч та юк.—Ул, тирә-якка карап алып, аз гына тын торды да, ни өчендер, себер татарлары теле белән сөйләүгә күчте:—Минем әүүәл аксымланган күренешләрем инте йыуашытылар[1], пер нейдән дә курыкмаң...

Галимҗан Ибраһимов җавапны алар теле белән бирергә булды:

—Ярый, шәкертем, туң цырай мән карышламаның, юлы пуылганты коткарыптың, айгырың үргә цаватың, кыран каруы көсле. Әйдә, керик[2]—диде дә итеген салып, янында гына торган шәкертенең беләгеннән тотты. Чөнки аның ярдәменнән башка шактый биек күтәрмәдән күтәрелә алмый иде ул.

* * *

Өйдә аларны хуҗәбикә каршы алды. Менә тагы: бу бит, бу бит...—казакъ кызы Карлыгачсылу. Шул! Нәкъ үзе! Суйган да каплаган. Казакълар арасында 1908 елның җәендә булган иде Галимҗан. Казакъ балаларын укытты. Карлыгач исемле бер кыз бар иде анда. Унбиш яшьләрдә иде булса кирәк.

Казакъ кызларына хас булган бөтен гүзәллек гәүһәре бар иде Карлыгачта. Бу гүзәллек «Казакъ кызы» дигән роман язарга мәҗбүр итте аны. Әсәрнең төп героинясы—Карлыгач. Тик болай әйтү генә канәгатьләндермәде Галимҗан Ибраһимовны. Аңа «сылу» сыйфатын да өстәде. Шулай итеп, «Карлыгачсылу» булды ул.

Менә шул Карлыгачсылу басып тора аның алдында.

Ә инде ире:

—Исеме—Карлыгач—дигәч, Галимҗанның күңеле йомшап, тәне тетрәнеп куйды. —Бу мин мең кат сөләгән арзаклы Галимҗан остабыз була инде, Карлыгач җанаем, көтмәгәндә ана ниндәй бәхетле очрашыу...—диде Сәрвәретдин.

—Безнең халык: «Тегенкәле йөп, енә, уймак кәрәк, көңел күтәргәле аш, йыр, кунак кәрәк[3]»,—тип сөләшә.

Сәрвәретдин елмаеп куйды да бичәсенә китәргә тиешлекне аңлатып ым какты.

Ул аш бүлмәсенә кереп китте. Ишектән сул якта иде ул. Аннан соң Сәрвәретдин өч бүлмәсен күрсәтеп чыкты. Бүлмәләр алай зур түгел. Әмма бик зиннәтле. Тәрәзә кашагаларында нәфис итеп чиккән сөлгеләр, тагын нинди-дер затлы әйберләр асылынып тора. Ике чөйдә—ике намазлык. Һәр бүлмәдә берәр тимер карават. Кәнәфи. Тәрәзә төбендә—гөлләр. Идәннәргә келәм җәелгән. Кыскасы, татар дөньясы исе аңкып тора монда. Ләкин Казан татарлары тормышыннан аермалы яклары да бар. Бер бүлмәдә идәннән алып түшәмгә диярлек юрган өелгән.

Аш бүлмәсеннән Карлыгачның:

—Цәй иңмәк[4] килгелә,—дигән тавышы ишетелде.

* * *

Аш бүлмәсе зур гына икән. Өстәл өстендә—зур корсаклы ак самовар, икмәк, чәкчәк, кыздырылган ит, башка төрле ашамлыклар, сөт, чынаяклар...

Хуҗабикә, ризыкларының тәннәренә сихәт булып баруын теләп, мунча ягачагын әйтеп чыгып киткәч, хуҗа Галимҗанга түрдән урын күрсәтте. Шулай да утырырга ашыкмады «кунак».

---

[1]Минем башта усал булган күршеләрем хәзер юашландылар инде.

[2]Караңгы чырай белән каршыламадың, авыр хәлдән коткардың, пычагың майда йөзсен, карыным нык ачты, әйдә керик.

[3]Тегәргә җеп, энә, уймак кирәк, күңел күтәрергә аш, җир, кунак кирәк.

[4]Цәй иңмәк—чәй эчәргә.

—Егетләрне дә чакырыйк,—диде.

Сәрвәретдин:

—Остаз колакны киртә, тыңламасаң сикертә,—дип такмаклый-такмаклый чыгып китте.

Галимҗан, аксаклый-аксаклый, хуҗа кушкан урынга барып утырды. Бер кайгының—бер шатлыгы, бер бәхетлелекнең—бер бәхетсезлеге турында янә уйланды ул.

Сәрвәретдин үзе генә килеп керде:

—Тыңламыйлар, остазым! Кыенсыналар.

Галимҗан чигенмәслек итеп әйтте:

—Мин сине Миасс заводында да, «Галия» мәдрәсәсендә дә тыңларга өйрәткән идем, шәкертем!

Сәрвәретдин, җилкәсен кашып, аксаклый-туксаклый, янә чыгып китте дә бераздан тегеләрнең икесен дә җитәкләп алып керде. Тегендә бу кыю, ярсу егетләр патша сараен алырга әзерләнгән солдатларга охшап торалар иде. Кыенсыну, оялу, хисенә чумганнар.

—Әйдәгез әле, егетләр, нигә болай кыенсынасыз, утырышыгыз, бергә бергә чәйләп алыйк,—диде Галимҗан, аларны авыр хәлдән коткарып.

* * *

Чәй эчкәндә Сәрвәретдин Галимҗан Ибраһимовның Мулланур Вахитов, Шәриф Манатов белән бергә Ленин, Сталин җитәкчелегендә зур эш алып баруын белүен әйтеп, нигә болай йөрүе турында сорашты.

—Син шулкадәресен дә беләсең?—дип аптырады остазы.

Сәрвәретдиннең моңа ачуы килде:

—Караңгы бер урында, тайга урманнарында яшәп, бернәрсә дә ишетмибездер шул...

Галимҗанның аны рәнҗетәсе килмәде:

—Ярый, шәкертем!—дип, бар булган кадәресен бик озынга сузмый, Сәрвәретдингә сөйләп бирде. Үз чиратында себер татарлары арасына ничегрәк килеп чыгуын сораштырды.

«Галия» мәдрәсәсеннән Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Шәехзадә Бабич кебек талантлы каләм осталары чыкты. Кайберләре инженер, укытучы һөнәрен сайлады. Мулла булып китүчеләр дә хәтсез. Сәрвәретдингә Ходай Тәгалә бәлеш төбе тәкъдим итте. Уфада бер себер татары баенең арбасына утырды да китте. Бай бер дигән өй һәм карап туйгысыз кызын бирде. Үзе моннан утыз чакрым ераклыкта яши икән.

* * *

Башта күбрәк үзе тәтелдәсә, оста барда тел тыярга кирәклекне искә алып, сүз ireген остазы ихтыярына тапшырырга тырышты Сәрвәретдин. Соңгы вакытта себер татарлары тарихы белән нык кызыксына иде ул. Нинди халык? Нинди кавем, ыру-кабиләләрдән килеп чыккан алар? Остазы «Галия» мәдрәсәсендә бервакыт төрки-татарлар тамыры булып исәпләнгән скиф, һун, алан, сармат, кыпчак, болгар, хазарлар кебек көчле кавем-кабиләләр турында сөйләгән иде. Алар юк инде хәзер. Мең-миллион еллар буе давылланган гаярь дингезләрне дә корытырга көче җиткән кебек, Тарих бабай ул кавемнәрнең дә кайнар җаннарын изге җирләре куенына акрынлап-акрынлап җайлаштырып бетергән.

Шулай да алар бөтенләй үк юк булмаган. Көзен коелган орлыктан язын башка чәчәкләр үсеп чыккан кебек, алар рухы нигезендә башка кавем-ыруг-кабиләләр барлыкка килә. Тарих бабай аларны икенче бер кабилиятле, башкачарак холыклы, бүтәнчәрәк сыйфатлы итеп ясый. Болар башта төрки-татар дип атала әле. Аннан «татар» сүзе яңа атамалар белән бөтенәя: Казан татары, Кырым татары, Әстерхан татары, Әзербайҗан татары, Төрекмән татары, Нугай татары, Кумык татары...—алар бик күп.

Бервакыт «татар» сүзен күпләр алып ыргыта. Шуннан Казан татарлары,

Кырым татарлары, Әстерхан татарлары, Себер татарлары гына кала.

Кемнәр соң алар Себер татарлары? Галимҗан Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсендә укытканда 1916 елда ук «Телләре төрле булса да, күңелләре бер» дигән хезмәт язган иде. Себер татарлары тарихы белән шунда ныклап кызыксыңды ул. Ләкин ул вакытта, кем әйтмешли, аның төбен-тамырын ачыклап бетерә алмады әле. Шулай да, җае туры килгән саен, бу тамырның ерак очын эзләү белән шөгыльләнүеннән туктамады. Моның өчен, билгеле, томнар актарырга, зур галимнәр фикеренә таянып эш итәргә туры килә. Хәзер, авызларын ачып, «Кыйссаи Йосыф»ны хисләнеп тыңларга утырган кешеләргә охшап торган табындашларына шул галимнәрнең фикерен әйтә башлады. Монда хис-тойгыга караганда аң-акыл өстенлек аладыр. Бәлки, икесе дә бардыр. Чөнки Галимҗан Ибраһимов аларның тарихын хис-тойгылар давылына күмелеп тә өйрәнде. Тик фән кешеләре, галим-голәмә күп вакыт фараз беләнрәк сөйләүчән: «бәлки», «шулай түгелме икән», «фәлән кеше әйткәнчә» кебек сүзләр белән җөпләүчән үз фикерен. Монда да мәсьәлә шулайрак тора.

Ул—болай.

Әйтик, көнчыгыш халыклар тарихын өйрәнүче күренекле галим Н. А. Аристов Көнбатыш Себер кинлекләрендә яшәүче татарларның килеп чыгышын казакъ һәм нугай кавем-кабиләләренең бер бөтен булып оешу-кәрәзләнү нәтиҗәсе дип фараз кыла. Себер тарихчысы Г. Ф. Миллер да шушы фаразга мөһер сугып куя. Дөнья китабы сәхифәләренә андый күренешләр бихисап язылган. Тик шулай да казакъ һәм нугайларны бүгенге Көнбатыш Себер татарларының ата-бабасы дип карау ике каенның бер имәнгә әверелүе ихтималы кебек кенә. Хәлбуки, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Борынгы алтай төркиләре: «И, күк Тәңресе! Ул зәңгәрлектә ниләр бар?»; «И, газиз Җир! Каралыгыңда ниләр бар?!»—дип, Табигать илаһилыгына кайнар хис, бөек акыл белән эндәшә торган булганнар. Алар, бәлки, Адәмнең Җир һәм Күк сөешүе нәтиҗәсендә барлыкка килү серен белергә теләгәннәрдер. Бусына бер Алла шаһит! Әмма ике каеннан бер имән, казакъ белән нугайдан татар барлыкка килми. Башка галимнәр бу хыялый фаразны шик астына ала. Ә менә академик В. В. Радлов хәзрәтләре Көнбатыш Себер татарларының килеп чыгышын шушы урында яшәгән борынгы төрки кабиләләре, алар янына килгән Идел буе татарлары, бохаралылар кушылмасы белән бәйли.

Менә бу чынлыкны дөнья китабы сәхифәсенә Тарих бабай дөресрәк язган кебек. Көнбатыш Себер татарларын шул зур китапның бер сәхифәсе итеп карарга мөмкин. Чынында ул—борынгы төрки кавем-кабиләләр оясы. Дүртенче гасыр башларында ук әле Алтай җирләрен ташлап киткән борынгы төрки кабиләләр Иртеш, Тубыл, Ишем елгалары буйларында йөреп-йөреп килеп чыгалар бу урыннарга. Ул борынгы төрки ыруг-кавемнәрнең атамалары Төмән, Омск тирәләрендәге кайбер авылларга күчкән. Омск өлкәсенең Тевриз районындагы Югары Әй, Түбән Әй—татар авыллары.

Тар районындагы Олы Туралы, Кече Туралы, Ишем районындагы Курта, Төмән өлкәсенең Вагай районындагы Тукуз авыллары шулай ук борынгы төрки кавемнәре Туралы, Курҗак, Тукуз атамаларын йөртәләр.

Әлбәттә, Көнбатыш Себер татарлары каны шушында килеп утырган кыпчак, Идел буе татарлары, Бохара үзбәкләре, Урал башкортлары, казакълар каны белән дә катыш. Ул канга янә монголлар, ханты-мансилар каны да килеп өстәлә. Әмма Казан татарлары каны өстенлек ала. Унтугызынчы гасыр азагында инде Тубылда гына да 7797 казан татарлары яши. Төмән, Ялутор, Тар өлкәләрендәге Казан татарлары каны елгасы башкаларныкына караганда көчлерәк ургылып ага. Икенче төрле әйтсәк, зур елга әллә күпме бәләкәй елгалар кушылу нәтиҗәсендә һаман киңәя барган кебек, бик күп башка кабиләләр белән аралашкан татарлар бирегә өстенлекне ала. Татарча сөйләшү башлана. Себер татарлары әнә шулай барлыкка килә. Ләкин кушылган башка кавемнәрнең рухияте дә, кабилияте дә, теле дә һаман саклана әле. Менә ни өчен Казан татарлары теленнән шактый үзгә ул.

Әмма киләчәктә монда да татар әдәби теле канат җилпиячәк.

Шуларны сөйләп бетергәч:

—Димәк, барысы да үзебезнең сөяк—казакъ та, нугай да, үзбәк тә, кыргыз да...—дип куйды Галимҗан.—Болар бик катлаулы, әлбәттә, җиде кат күк, җиде кат җир кебегрәк...

Сәрвәретдин, түземсезләнеп, сорау бирде:

—Бу скиф патшаларыныкы дип саналган изге кылычның Атилла кулына күчүе кебек буламыни инде?

Галимҗан, гаҗәпләнеп, сораугa каршы сорау ташлады:

—Нәрсә, нәрсә? Нинди изге кылыч ул?

—Александр Македонский яки Цезарь кебек халыклар пәйгамбәре булган Атилла кулында ялтыраган кылычның скиф бабакайлардан калуы турында сүз бара, остазым!

—Син шуларны беләсең хәтта?

Сәрвәретдин җирән мыегын, кыска җирән сакалын сыпырып куйды.

—Сез, остазым, һаман әле мине элекке кебек надан шәкерткә исәплисез кебек...

Мәгънәсез соравы өчен Галимҗан үзе дә үкенеп куйды:

—Юк, шәкертем, алай түгел, үпкәләмә, мин синең күпне укуыңа, күпне белүеңә шатланып бирдем ул сорауны. Скифлар кулындагы кылычның Атилла кулына күчүе хакында сүз йөртәсең; әле менә ул тарихи кылыч, гүя, синең көчле кулыңда ялт-йолт итә.

—Мин ул кылычның тутыгуыннан куркам, остазым!

—Тел төбеңне аңлыйм, шәкертем: сине бүгенге болганчык, кылычлы көннәр, кара вакыйгалар борчый; аларның барысы да вакытлыча, безнең кылыч ялтырар әле ул, ялтырар, барлык вәхшилекнең тамырын кисәр, алардан икенче сыйфатлы үсентеләр барлыкка килер; Себер татарлары җирендә яңа мәктәпләр ачылыр, Казан татарларының тел гәүһәрләре матурлыгы дулкын булып агылыр бирегә; шулар өчен көрәшәбез түгелме?

—Ул көрәшкә минем дә йөрәк җилкенә лә ул, остазым, әмма, кем әйтмешли, дәрт—бар, дәрман—юк. Аксак аяк белән кая барасың...

—Ә менә мине яңа, гыйбрәтле көрәш көтә.

—Нинди көрәш ул, остазым? Сер булмаса—әйтер идегез?

—Сер түгел. Мин хәзер Омскига юл тотмак булам. Колчак белән очрашырга.

—Колчак белән очрашырга?!

—Әйе. Нигә күзеңне чекерәйттең?

—Бу бик куркыныч. Сез—киләчәк зур әдәбиятка кирәк кеше!

Алар беразга тынып калды.

Башкорт белән чуваш тын алырга да куркып утырдылар хәтта. Хәзер инде алар бу Сакалбайның Хозыр-Ильяс түгел, Солтанмораттагы Гыйрфан мулла малае икәнлегенә ныклап ышандылар. Шул үзе—Ленин, Сталин белән бергә эшләгән Галимҗан Ибраһимов!

Егетләрнең нидер кичерүен аңлады Галимҗан. Әллә сынар өчен, әллә күңелләрен күтәрим дип, сорап куйды:

—Ну, егетләр, барасызмы минем белән Колчакны капкынга эләктерергә, ә?—диде.

*Ахыры киләсе санда*



# Рәфикъ Юныс

## Габделвәли бабама

*«...яхшы табигатьле, туры сүзле һәм*
*укымышлы кеше иде... Хакыйкатьне*
*эзләүдә көчле фикерле булуы...*
*белән аерылып тора иде...»*

Ш. Мәрҗани.

**Якты булсын гүрең, җәннәт**
**Була күрсен урының.**
**Бу дөньядан дәшәм сиңа.**
**Оныгың мин, туруның.**

**Якын да ара, ерак та.**
**Әтиемә син—ата.**
**Төпчегеңнең төпчегемен—**
**Арада гасыр ята.**

**Упкын ята!—баласы мин**
**Тәһарәтсез дөньяның.**
**Сихерле бер йокыдан мин**
**Әле яңа уяндым.**

**Уяндым, тик айнымадым—**
**Башымда томан әле.**
**Күбәләктәй җаннарымның**
**Канатсыз, зәгыйфь мәле.**

Рәфикъ ЮНЫС *(1943) — шагыйрь, журналист. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Вакыт чылбыры», «Сүнгән яшен», «Син һәм мин» һ. б. шигырь җыентыклары, «Татарстан референдумы» исемле тарихи-публицистик китап авторы. Казанда яши.*

Ныклык эзләп, исемеңне
Дога кебек кабатлыйм:
...бине Вәлид, бине Максуд
Әл Кәчеви...
Ярабби!

Булмасамчы буш орлыгың,
Нәселебез хурлыгы!
Хәзер мин кояш күзендә.
Туруның мин, оныгың...

## Кортладык

Анда тук-тук, монда тук-тук.
Хәлеңне, тукран, тоям.
Үзем дә бит чиләк-чиләк
Җиләк түгел—корт җыям.

Бар да чирле, бар да черек!
Җанда иман йоклады.
Менә шуңа үзебез дә...
Дөньясы да кортлады.

## Ак эт

Актыр аның тырнагы да,
Актыр борыны да.
Акбай. Тик бай түгел. Юктыр
Кунар урыны да.

Беркем дәшмәс аны, беркем
Әйтмәс: «Сөбханалла!»
Нинди кара исем чаба
Үзеннән дә алда?

Юкса чирле-бетле түгел,
Актыр, юкса, пакьтер.
Хет кочакла, хет үп аны,
Хет мендәрдә яткыр.

Затлыдыр ул. Холкы гүзәл.
Һөнәрле дә үзе:
Угрылыкны, яманлыкны
Бер чакрымнан сизә!

Кызыкканнар! Зур бәягә
Кулдан-кулга күчкән.
Түрдә булган урын. Ләкин
Базары тиз төшкән.

Судьядан да арткан. Мулла
Бәддогалап куган.
«Сөттән дә ак» түрә хәтта
Үтермәкче булган.

Ак эт барда карак берни
Апчыгалмый өйдән.
Ләкин... хәрәм малны өйгә
Ул кертми дә икән...

«Тугры хатын» аны төнлә
Түфли атып сөргән:
Сөяркәсе килгәч, ак эт
Разбой салып өргән...

Азгын ир кайткач, кертмәгән
Бусагадан ары...
Хәрәмләшкән-алдашканда
Өргән күзгә карап...

Эт йөри, эт. Ап-ак йонлы,
Ап-ак күңелле ул...
Әй, укучым, сиңа, менә сиңа
Кирәк түгелме ул?

И мәгънәсез үтә көннәр!
Ай, әрәмгә үтә лә.
Күпме өмет шытым килеш
Шиңеп калды түтәлдә.

Күпме хыял кысыр калды!
Юк максат һәм юк теләк.
Хуҗасы җуйган сәгать күк
Текелди тәндә йөрәк.

Хыял тәмен татып ымсынам мин.
Татлы төшләр күреп үртәләм.
Гөл-чәчәкле, нурлы бу дөньядан
Шуып үтте бары күләгәм.
Шуып үтте салкын күләгәм.

Бүләк гомер, бердәнбер бу гомер
Башланмаган килеш—азакта.
Канда тып-тын күпме гайрәт ята,
Җанда күпме кайнар наз ята!
Җанда әле күпме наз ята.

Тоям төптә тонык гөрелтеләр.
Олы язмыш мине көткәндер.
Бөредәге «мин»не уятырга
Баштан сыйпау, бәлкем, җиткәндер?
Чәчтән сыйпау, бәлкем, җиткәндер?

Өлгермәдем, ахры, табылып мин.
Өлгермәмен, ахры, кабынып.
Дөньягыздан, ахры, китәрмен мин
Уянмаган янар тау булып.
Янмый калган янар тау булып...



## Марат Кәримов

### Китәсе килми

Туган якларга кайтыр чакларда
Хәтта бер минут көтәсе килми.
Яшьлек тавышыдай авылым каршылый,
Мине һич тә ят итәсе килми.

Монда дусларым, монда ишләрем,
Дусларсыз юллар үтәсе килми.
Әткәй кабере... Әнкәй кабере...
Яшьләрем тама, сөртәсе килми.

Сынаусыз-нисез, сагышсыз-моңсыз
Матур көннәрнең иртәсе килми.
Туган төягем, синдә йөрәгем,
Синнән аерылып китәсе килми.
Китәсе килми...

*

Гомер башы—йөзек кашы,
Манчылгандай иде нурга.
Учак яктым, дуслар таптым
Ялкынында җылынырга.

Яннарында янып-шашып,
Сихри таңнар аз атмаган.
Ни арада үткән алар,
Учак кузын көл каплаган.

Артларымда алтынланып
Мәңге кайтмас гомер ята.
Йөрәк—учак,
тик өр генә,
Аста утлы күмер ята.
Утлы күмер ята икән—
Башланмаган гомер ята.

Марат КӘРИМОВ *(1930)—шагыйрь, күпсанлы шигырь һәм проза китаплары авторы. Башкортстан Язучылар оешмасындагы татар секциясе җитәкчесе. Уфада яши.*

## Уйлану

Шигъриятнең урамына
Мин дә салдым өемне.
Шул өемдә көй көйләдем,
Яшьлек биргән көй инде.

Яшьлек җыры—иртәнге җыр,
Аны кем соң аңламый.
Ә шулай да иртәнге җыр
Кичкелеккә ярамый.

Өй дә хәзер ялтырамый—
Куна заман тузаны.
Өем туза, гомер уза,
Маңгаемда ызаны.

Кояш төшлеккә дә җиткән.
Ни дип тулгандым әле?
Кичке уйны уйлый-уйлый
Җиңне сызгандым әле:

Өемне агартасы,
Көемне яңартасы...

## Маскарад

Бал-маскарад. Күңел ача идек
Алай итеп, болай итеп тә.
Беребезне беребез танымыйбыз—
Һәркайсыбыз бии битлектә.

Хәзер исә көн дә бал-маскарад.
Әнә кара: зәңгәр тартмадан
Кемдер безгә елап зарын сөйли,
Йөзен битлек белән каплаган.

Һәм бандит та битлек киеп алган,
Кан калтырый аннан бар тирә.
Көпә-көндез ул банклар талый,
«Ыһ» та итми кеше үтерә.

Син баһадир омончыларны әйт,
Бер бассалар, җирне сыталар.
Куркуданмы, нәрсәдән соң бу хәл?
Битлек киеп бандит тоталар.

Мондый битлек нәрсә! Мәшәкатьсез,
Киясе дә аны саласы.
Гомер буе бездән йөзен яшереп
Яши күпме адәм баласы.

Имансызлар: иман, иман, диләр,
Вөҗдансызлар безне «фаш итә»,
Акылсызлар көн-төн акыл сата,
Ә башсызлар үзен баш итә.

Ялган бии хаклык битлегендә,
Бу бәйрәм бит аның кулында.
Тоташ Рәсәй үкси-үкси елый
Бал-маскарад дигән уенда.

## Кемгә—ничек

Берәүләргә хаклык түшәм кебек,
Түшәм ныклы икән—бул тыныч.
Җил-яңгыр да сиңа тими үтәр,
Бураннар да булмас куркыныч.

Ә берәүгә хаклык—идән кебек,
Шунда басып йөри һавалы.
Шак-шок итә пычрак итекләре,
Ул итекләр корыч дагалы...

## Каеннар

Кем әйтә соң каеннарны
Сала дип кайгыларга?
Ә мин, кара кайгы килсә,
Карыймын каеннарга.

Алар мине чакыралар
Үзләре арасына.
Аклыклары дәва икән
Йөрәгем ярасына.

Яшел яфраклар: «Яшисе
Бар, бар!»—дип юаталар,
Кара кайгыны җиңәрлек
Миндә көч уяталар.

Кем килгән мәңге кайнарга
Бу дөнья мазасында!
Каен булып калсам икән
Терелер арасында...

## Әтәч кычкырганда язылган шигырь

Әтәч кычкыра авыл читендә,
Авыл читендә, иске читәндә.

Тары тапканмы, нәрсә тапкандыр.
Шатландыр, әтәч, барсын шатландыр.

Минем дә гадәт синеке сымак:
Әллә нишләп бит түгелмен «тыйнак».

Бер тинем булса,—дуслардан сора,—
Гел әтәч булып кычкырып тора.

Гел әтәч булып кычкырып тора—
Байлык дигәнем ычкынып тора.

Тапканым уртак, табарым уртак,
Киләләр икән—кабарым уртак.

Йөрәгем ачык—җылым да уртак,
Йөрәктән чыккан җырым да уртак.

Йөк уртак булгач, һич авыр түгел,
Миңа да җиңел, дуска да җиңел.

Шатланам шул хис туса бүтәндә.
Кычкыр син, әтәч, кычкыр читәндә!

## Булмаган кебек

Әле генә мәхәббәттән
Илергән идек кебек,
Чыклар ярып, Ай юлыннан
Йөгергән идек кебек.

Йөгереп арып, алмагачка
Сөялгән идек кебек,
Үбешергә тәү кат шунда
Өйрәнгән идек кебек.

Иңбашыма башың салып
Йоклаган идең кебек.
Җир шары да әйләнүдән
Туктаган иде кебек.

Ә Ай кызы үзенә чакырып
Кулын болгаган кебек.
Безнең белән булдымы бу?
Аһ, юк, булмаган кебек...

Солтан Шәмси

# НИЗАГЛЫ ЙОРТТА

## АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНЕН ТАРКАЛУ ЧОРЫННАН СӘХИФӘЛӘР

* * *

Тик көчле шәхес үз идеалы өчен гомер буе көрәшә. Әйе, ул, вакыйгалар барышына буйсынып, күпмедер вакыт актив тормыштан читкә китеп торырга да мөмкин. Ләкин бу әле тынычлану түгел. Унай шартлар туу белән аның күнелендә пыскып яткан күмерләр кабат жанлана, ялкын чәчә башлый һәм күп тә үтми аның бөтен барлыгын көрәш уты чолгап ала. Шәхес үз стихиясенә әйләнеп кайта. Гайрәтле йөрәге аны яна тәвәккәллекләргә этәрә.

Әйе, илдә низаглар купкач, Мамай мирза кабат көрәшкә ташлана, сонгы елларда ару-талуны белмичә гел хәрәкәттә була. Әйләнеп карасан, 10 ел вакыт үткән дә киткән икән! Ә нәтиҗә шул ук—ул кабат үз олысы Кырымга кайтып төште. Әйе, ул гомере буена язмыш әзерләп куйган кысаларга сыя алмады, йөрәкле булды. Мескен, вак жанлы ханнарга баш иеп яши белмәде. Бәлки аның бөтен фажигасе дә шундадыр... Инде менә урдасында яна ханны—Мөхәммәт Бүләкне күтәртте. Карап карыйк, ул үзен ничек тотар икән...

Сарайда да ныклап тамыр жибәрә алмады ул. Анда жиде яктан житмеш жиде дошман сина чокыр казый, дөнья тәмам болганды, иреннәрендә сөт тә кипмәгән күпме малай-шалай биек тәхет турында хыяллана, аларны арттан котыртып, үсендереп торучылар да житәрлек. Ярар, дөнья бит Сарайдан гына тормый. Житмәсә, ул Иделнен сул ярында урнашкан. Ике арада зур су—Идел ага. Ярнын бу ягына чыксан, күпме жирләр, калалар бар, яшел далалар жәелеп ята. Идел белән Кырым арасында кылыч уйнатсан, шул биләмәләргә урыс кенәзлекләрен дә китереп кушсан—тагын ни кирәк?! Һәм Мамай мирза, чыннан да, Иделдән көнбатышта яткан жирләрдә үз хакимиятен ныгытырга керешә.

Инде 1370 елда ук, ягъни Сарайны ташлап китүенә ике ел тулар-тулмас, Мамай мирза Суздаль һәм Нижний Новгород кенәзе Дмитрий Константиновичны Болгар олысына яу белән жибәрә. Яуга жибәрерлек булгач, алар Мамай мирза кул астында яшәгәннәр диген сүз. Гомумән, бу елларда урыс кенәзләре ышанычсыз Сарай ханнарына таянуга караганда, гайрәтле Мамай мирза белән эш йөртүне, салымнарны ана түләүне кулайрак күрәләр.

Бу вакытта Болгар олысы үзәге инде Казанга күчкән була, чөнки Болгар урыс яуларыннан сон кабат күтәрелә алмый. 1369 елда Сарайны ташлап качкан Хәсән хан Казанга барып урнаша, аны ныгыта, кальга төзи. Шулай да аның әле яу белән килгән урыс гаскәренә каршы торырга көче житми. Чыганаклардан күренгәнчә, ул кенәз Дмитрий Константиновичка зур йолым түләргә һәм бүләкләр бирергә мәжбүр була. Мамай мирза әмере буенча, урыслар Казанда Хәсән солтан белән аның улы яшь Мөхәммәт угланны (булачак Олуг Мөхәммәд) да идарәче итеп куялар. Шулай Казанда

Дәвамы. Башы 1 санда.

берьюлы ике хаким кала. Мамай мирза моны Хәсән солтанга үч итеп юри эшләгәндер, чөнки 2 ел гына элек (1368) Хәсән солтан, Габдулла хан белән аны Сарайдан куып җибәреп, үзе тәхеткә чыккан иде. Ә бер ел үтүгә үзе үк шул хәлгә төште—куылды.

Бу очракта Мамай мирза үзен бик нечкә психолог булarак күрсәтә, ул Мөхәммәт угланны атасы Хәсән солтан белән тигез куя, шулай аннан үч ала. Улы белән Казан тәхетен бүлешү Хәсән солтанга җиңел булмагандыр.

Шулай итеп, 1369—1377 елларда Мамай мирза Иделдән көнбатышта яткан җирләрдә үз хакимиятен ныгыту белән шөгыльләнә. Шул исәптән урыс кенәзлекләре тормышында да актив катнаша, төрлечә басым ясап, аларны үз канаты астына алырга омтыла. Ләкин бу процесс бер яклы гына бармый. Сарайда тотрыклы хакимият булмаудан файдаланып, урыс кенәзләре дә Идел буендагы олысларга һөҗүм итүне ешайталар, торган саен батырая баралар.

Мәсәлән, 1374 елда Нижний Новгород халкы Мамай мирзаның илчеләрен саклар өчен җибәрелгән мең ярым кешелек отрядын юк итәләр, ә баш илче Сары Айка иптәшләре белән кулга алына. Ләкин татарлар ничектер зинданнан чыгу юлын табалар да, кулга корал тотып, урыслар белән җан-фәрманга сугышалар. Шунда барысы да ятып кала. Бу хәлләр Мамай мирза белән урыс кенәзлекләре арасында тартышу барганлыгын күрсәтә.

Ә Сарайда бу вакыт эчендә тагын берничә хан алышына. Хәсән ханнан соң тәхеттә Тулунбик хан, Алибик хан, Каганбик хан, ә 1375 елда Гарәпшаһ ханнар утыра. Соңгысы чыгышы белән Себер якларыннан була. 1377 елда аңа Күк Урдадан чыккан Ырыс хан белән бик нык бәрелешергә туры килә, ахыр чиктә Сарай Ырыс хан кулына төшә. Гарәпшаһка качып котылырга гына кала. Күрәсең, ул Иделнең уңъяк ярына чыккан, Мамай мирза кул астына кергәндер, чөнки шул ук 1377 елда аның боерыгы буенча мордва җирләрендәге Пъяна елгасында урысларның Мәскәү, Суздаль, Новгород гаскәрен тар-мар итә. Бераздан ул Нижний Новгородка килеп, аны да яндыра, Рязаньга яу чаба. Шуның белән Гарәпшаһның исеме тарихтан төшеп кала. Шушы бәрелешләрнең берсендә ул һәлак булгандыр, күрәсең.

Сарай тәхетенә Ырыс хан чыккач, Алтын Урда дәүләте ике капма-каршы өлешкә бүленә дә куя. Көнчыгышта Ырыс хан хөкем сөрсә, көнбатыштагы җирләрдә Мамай мирза хуҗа булып кала. Идел исә Җучи олысын (Алтын Урданы) икегә бүлүче чиккә әверелә.

Ырыс хан биләмәләренә Сарай каласы белән беррәттән Мангышлак киңлекләре, Арал дингезе буйлары, Сыр-Дәрья тирәсендәге калалар (Сыгнак, Йаса, Отрар), киң далалар керә. Бары тик Хәрәзем олысы гына аңа буйсынмыйча мөстәкыйль яши.

Мөхәммәт Бүләк хан исеменнән идарә иткән Мамай мирза җирләренә исә Кырым, Төньяк Кавказ, Кубан, Дон буйлары, Азак белән Мажар калалары, Идел буеның байтак өлеше керә. Урыс елъязмачылары бу вакытта Мамай мирзаны «царь Волжский» дип атыйлар, чөнки ул Иделнең уңъяк ярындагы иң көчле хакимгә әверелә. Шулай Алтын Урда дәүләтенең уң канаты аның кулында кала. Шуңа да карамастан Мамай мирза өчен хәл ителмәгән бер мәсьәлә һаман яши бирә—ул да булса урыс кенәзлекләренең язмышы, аларның статусы. Соңгы елларда барган үзара низаглар аркасында урыслар артык иркен сулый башлыйлар. Вак-төякне инде әйткән дә юк, хәтта Мамай мирзаның илчесе Сары Айканы да үтерергә җөрьәт итәләр. Ә 1376 елда Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Иванович Болгар олысының Казан каласына яу җибәрә. Бу хәл Казан солтанының йолым түләве белән тәгәлләнә. Гомумән, соңгы вакытта урысларда ниндидер ирәю, бер сүзгә килү, үзара якынаю галәмәтләре нык сизелә. Әле 1372 елда ук Мамай мирза Рязань кенәзлегенә олуг кенәз итеп Олег Ивановичны билгеләгән иде. Тора-бара ул да Мәскәүнең олуг кенәзе белән якынайды, аны үзенең «өлкән туганы» дип таныды, сүз берләште. Димәк, Мамай мирза кул астыннан чыгарга жай эзли. Инде менә Мәскәү кенәзе дә еллык дань-салымның күләмен киметү турында сүз кузгата, зарлана, канәгатьсезлек белдерә. Болай барса, урысларның бөтенләй кулдан ычкынып куюлары да бар.

Бу хәтәр күренешләр Мамай мирзаны урыс кенәзлекләре белән ныклап торып шөгыльләнергә кирәк дигән фикергә этәрә. Инде әйтелгәнчә, 1377 елда ул, мордваларның урыслардан зарлануына, яклау соравына колак салып, Пьяна елгасына Гарәпшаһ угланны жибәрә, теге берләштерелгән Суздаль-Мәскәү гаскәрен туздырып ташлый, аннан Нижний Новгородка ук барып чыга. Шушы ук юнәлештә эш алып барып, Мамай мирза Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Ивановичка каршы гаскәр башы Бигеч мирзаны яу белән жибәрә. Тик аның бу адымы уңышсызлыкка дучар була. Дмитрий Ивановичның гаскәре татарларны Рязань кенәзлегендәге Вожа суы буенда каршы ала. 1378 елның 11 августында Бигеч мирза яугирләре елганы кичкән чакта урысларның көчле һөҗүменә дучар булалар. Бу бәрелеш татарлар өчен зур фажигагә әверелә. Каршы ярга чыгып сафларга төзелеп өлгерә алмаган татар гаскәре зур югалту кичерә. Шушы бәрелештә Бигеч мирза, Хажи бәй, Кабырга, Карабелек, Костров мирзалар һәлак булалар.

Бу югалтуны Мамай мирза бик авыр кичерә. Тынгысыз тормышында аның төрле хәлләргә юлыкканы бар—күп тапкырлар дошманнан өстен чыкканы да, шулай ук жиңелү ачысын татырга да туры килгәне бар. Әмма мона хәтле аның әле бер тапкыр да урыслардан жиңелгәне юк иде. Хурлык, хурлык... Кеше күзенә күтәрелеп карарга оят. Әлбәттә, бу хәлне ул татарның данын-абруен төшерә торган вакыйга буларак кабул итә. Ә бит ул инде Үзбәк хан заманнарын кире кайтару, олысларны туплау, бу башбаштаклыкларны бетерү турында ук хыяллана иде.

Нәкъ шул көннәрдә аның урдасына килеп ирешкән хәбәрләр вакыйгаларга икенчерәк төсмер бирә, Мамай мирзаның авыр кичерешләрен бераз жинеләйтеп жибәргәндәй тоела. Анда, кояш чыгышындагы олысларда, Туктамыш белән барган көрәштә Ырыс хан һәлак булган дигән хәбәр тиз арада далага таралып өлгерә. Инде менә аталары үчен кайтарырга Ырыс хан уллары Тактакыя белән Тимермәлик угланнар Туктамышка каршы күтәрелгәннәр. Димәк, тиз генә тынычлана алмаячаклар. Бу инде Мамай мирзаның артында, Иделнең сулъяк ярында, әлегә көчле дошман сагалап тормаячак дигән сүз. Болай булгач, Мамай мирза зур көч жыеп урыс кенәзләренә яу йөри алачак. Әйе, аңа да Вожа суы өчен, шул сугышта шәһид киткән мирзалары өчен үч кайтармый калу ярамас. Һичшиксез кайтарырга кирәк булыр. Аннан соң аңа халык алдында абруен ныгыта төшү дә комачауламас. Юкса, соңгы вакытта кайберәүләр аңардан күзен яшерә. Әйтеп бетермәгән уйлары бар, димәк... Әлбәттә, беренче эш итеп аңа урысның олуг кенәзе Дмитрий Ивановичны урынына утыртырга кирәк. Мәскәү тез чүксә, башкалары үзләре үк баш иеп киләчәкләр.

Шулай Мамай мирза урыс кенәзлекләренә каршы зур яу оештыру эшенә керешә. Тарихка «Куликово сугышы» дип кереп калган әлеге орыш аның өчен нинди фажига белән тәмамланасын ул, әлбәттә, башына да китерә алмый. Кеше дигәнең тәкъдирендә ниләр язылганын алдан белми шул. Белсә әллә ниләр кылыр иде.

## Гарәпшаһ углан тәвәккәллеге

Дәшти Кыпчакта, ягъни Алтын Урда дәүләтендә барган болганышлар дәверенең соңгы елларында (1377) Сура елгасы тирәләрендә Гарәпшаһ углан атлы бер идарәче пәйда була. Кайбер тарихчылар ул бирегә Иделнең сулъяк ярындагы жирләрдән—Жаек даласыннан килгән дип язалар. Бу хәбәр дөрескә чыккан очракта, Гарәпшаһ углан Туктамыш ханнан качып Мамай мирза ягына, Иделнең уңъяк ярына күчкән зат була. Чыннан да, бу вакытта Иделдән көнбатышка сузылып киткән далада Мамай мирза хөкем сөрә. Тарихчы Ризаэтдин Фәхретдин дә шул ук фикерне куәтли: «Мамай (мирза) тарафыннан Гарәпшаһ исемле бер гаскәр башлыгы 1377 елда Мәскәү кенәзенә һөҗүм итте»,—дип яза. Гадәттә, урыс тарихчылары бу вакыйгага артык тукталып тормаска, аны берничә сүз белән генә телгә алып узарга тырышалар. Сәбәбе нәрсәдә икән соң? Әйдәгез, төпченеп карыйк әле.

Әлбәттә, Иделнең унъяк ярында Мамай мирзадан тыш тагын бер идарәченең пәйда булуы урыслар игътибарыннан читтә калмый. Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Иванович, тиз арада көч туплап, үзенә кайнатай тиешле Суздаль һәм Нижний Новгород кенәзе Дмитрий Константиновичка ярдәмгә ашыга. Әмма Гарәпшаһ углан нилектәндер урыслар өстенә килми. Гомумән, урыслар күпмедер вакытка аның эзен югалтып торалар. Гарәпшаһ углан тарафыннан актив хәрәкәт көтеп арган Мәскәү кенәзе Владимир, Переяславль, Юрьев, Муром, Ярославль, Нижний Новгород калаларыннан җыелган зур гаскәрне кенәзләргә һәм воеводаларга тапшыра да өенә, Мәскәүгә кайтып китә.

Төрле яктан җыелган урыс гаскәре Сура елгасы кушылдыгы Пьяна суына таба хәрәкәт иткәндә үзләренең даладагы хәбәргәрләре аша Гарәпшаһ углан урдасының бик еракта, Северский Донец елгасы тирәләрендә үк торуын белеп алалар һәм, моңа бик тә сөенеп, кинәт тынычланып калалар. Дөрес, моннан соң да хәбәрләр килгәләп тора, тик аларга инде берәү дә игътибар итми, кул селтәп: «Ташлагыз, зинһар! Бу кадәр көчкә каршы күтәрелергә кемнең батырчылыгы җитсен! Әнә бит, Гарәпшаһ бездән куркып Дон буенда качып ята!»—диләр.

Кыскасы, бу очракта да урысларга хас ваемсызлык үзенекен итә, җиңеп чыга. Кенәзләр белән воеводалар сугышчыларга карата таләпчәнлекне нык киметәләр, уяулыкны тәмам югалтып, үзләре дә тугарылып йөри башлыйлар. Кораллар, сугыш кирәк-яраклары арбаларга төялә, тимер көбәләр, очлымнар капчыкларга тутырыла, ияр артларына бәйләп куела, сөңге башлары да сапланмаган килеш теләсә кайда аунап йөри.

Бер караганда, урыс гаскәренең болай тугарылуын, ваемсызлыгын аңларлык сәбәп тә бар кебек. Җәйнең иң матур чагы, июль урталары була бу. Көннәр гаҗәеп эссе тора, мондый чакта кемнең сугыш киемнәреннән йөрисе, тәртип саклап көчәнәсе килсен. Шуңа күрә дә сугышчылар киенер-киенмәс килеш йөри, озаклап елга-инешләрдә су керә, кояшта корсак кыздыра, берәр җирдән хәмер ише нәрсә таба алсалар, лаякыл булганчы эчәләр, рәхәтләнеп күңел ачалар, мактана-мактана татарны мыскыллыйлар, аның турында көлке хәлләр сөйлиләр.

Ә кенәзләр белән воеводалар кая карый? Соң, алар да шул ук адәм балалары ич—кумәкләшеп эчәләр, макташып озын-озын тостлар әйтәләр, ауга йөриләр, төрле интригалар коралар, кызлар белән шаяралар.

Бу хәлләр мордва җирендә була. Әлбәттә, бу кадәр әрәм тамакларны туйдыру, аларга эчәргә табу мәшәкатьләренең байтак өлеше җирле халык өстенә төшә. Мордва кенәзләренең күпмедер вакыт бу тамашаны карап-күзәтеп торганнан соң түземе беткән, күрәсең. Алар саранча кебек басып алган урыс гаскәреннән ничек тә котылыр өчен тоталар да Гарәпшаһ угланга кеше җибәрәләр. Углан исә вәзгыятьне бик тиз аңлап ала, вакытны әрәм итмичә шундук юлга чыга. Урыслар лагерына якынлашыр алдыннан ул гаскәрен биш өлешкә бүлә дә дошманга һич көтмәгәндә төрле яктан һөҗүм итә.

Татарларның һөҗүме шулкадәр көтелмәгәндә була ки, урыслар тәмам шашып кала, бер-берсен таптап, качарга керешә. Күбесе якындагы Пьяна елгасына ташлана, каршы ярга йөзеп чыгып, татар кылычыннан котылмакчы була. Шушы мәхшәрдә Нижний Новгородның яшь кенәзе Иван байтак боярлары, воеводалары, хезмәтчеләре һәм сугышчылары белән су төбенә китә, калганнары татар кылычыннан үткәрелә.

Әлеге һөҗүмнән соң Гарәпшаһ углан Нижний Новгородка юнәлә, бу хакта ишетеп алган карт кенәз Дмитрий Константинович, бәладән башаяк дигәндәй, Суздальгә чыгып качуны хәерлерәк күрә. Шәһәр халкы исә, татарлардан куркып, көймәләргә төялә дә Идел буйлап тирә-якка тарала.

Нижний Новгородта гайрәт күрсәткәннән соң Гарәпшаһ углан кире юлда Рязань кенәзлегенә дә сугыла, җирле халыкка татарның әле көчле булуын шик калмаслык итеп төшендерә, кенәз Олег үзе качып котыла.

Шулай итеп, Гарәпшаһ углан Мамай мирза әмере буенча Иделнең

уңъягында урнашкан җирләрне урап чыгып, анда кабат татар хакимиятен ныгытып йөри. Аннан соң гына далага әйләнеп кайта. Кызганыч, аның шушы яудан соңгы язмышы хакында ни дә булса әйтүе кыен, чөнки хәбәрләр теркәлеп калмаган. Татар дәүләтен саклауда күрсәткән батырлыклары белән Гарәпшаһ углан Алтын Урда тарихына кереп калган, бу затның хәтеребездә сакланырга тулы хакы бар.

Шушы урында вакыйгаларга нокта куярга да мөмкин булыр иде. Ләкин хәлләр ут күршеләребез мордва халкы өчен бик аяныч тәмамлана. Шул хакта да бер-ике сүз әйтеп узу кирәктер.

Гарәпшаһ углан гаскәре кире кайтып китеп, дөньялар бераз тынычлангач, урыс кенәзләре җәза полклары белән кинәт мордва җирләренә килеп чыгалар. Бу хәл инде кышкы зәмһәрир суыклар башлангач була. Нижний Новгород кенәзләре Борис Константинович белән Семен Дмитриевич һәм Мәскәү воеводасы Свибл (исеменә караганда, читтән ялланган адәм булса кирәк) полклары Мордва илен талап, җимереп, яндырып тәмам бөлгенлеккә төшерәләр. Нижний Новгородка куып китерелгән меңләгән мордваларны җәзалаулар, Идел бозы өстендә ач этләрдән талату, бәкеләргә тутырулар байтак көннәр дәвам итә. Шулай урыс кенәзләре үз ваемсызлыклары аркасында тар-мар ителүдән тиешле нәтиҗә чыгарасы, сабак аласы урынга мордва халкыннан үч алып акланалар.

## Куликово кыры хикмәтләре

*«Егылганнан соң кабат күтәрелә алу сәләте бөек халыкка хас бер сыйфат булып тора. Каһәрләнүе бик авыр булуга да карамастан, тиешле сәгать суккач, ул үзенең таркау яткан рухи көчләрен туплый, аларны бер бөек затта яисә берничә бөек шәхестә гәүдәләндерә һәм алар юлдан вакытлыча төшеп торган халыкны тарихның туры юлына кабат алып чыгалар».*

В. Ключевский, *урыс тарихчысы.*

### I

**1980 елның** сентябрь аенда «совет халкы» зур шау-шу белән Куликово сугышының 600 еллыгын билгеләп үтте. Урыс дөньясы өчен зур әһәмияткә ия вакыйгага үз өлешен кертмәгән бер генә гәзитә-журнал да калмагандыр. Мин ул чакта өйгә 7-8 журнал алдыра идем. Әле дә хәтердә, шушы датага хәзерлек йөзеннән журналлар җәйге айлардан ук зур-зур мәкаләләр-очерклар бастыра башладылар һәм вакыйганың апофеозы балалар чәчәк тотып мәктәпкә барган сентябрь аенда булды. Шулай ярты ел чамасы матбугат чараларында монгол-татарны, аның «иго»сы өчен «татарны» сүгү-каһәрләү дәвам итте. Бу айларда үз тарихын рәтләп белмәгән татар кешесе ирексездән татарлыктан баш тартырга, «мин татар түгел, болгар, болгар!..» дип бәргәләнергә мәҗбүр ителде. Хәер, ул елларда тарих фәнендә «болгар теориясе» әле бик көчле иде.

Әмма шулай тоелган гына икән. Шул ук 80 еллар азагында галимголяманы гына түгел, гомумән, киң җәмәгатьчелекне нык дулкынландырган бу мәсьәлә матбугат битләренә бәреп чыкты, кызу гына «болгармы?-татармы?» бәхәсе булып алды. Аның койрык очы әле бүген дә ара-тирә ялтырап киткәли, үзен сиздергәләп куя.

Сүзне Куликово сугышы юбилееннан башлаган идек. Әмма Куликово кыры вакыйгаларына барып җиткәнче берничә күзәтү ясап үтмичә ярамас, чөнки 1380 елда булып узган бу сугыш берничә гасыр дәвамында барган зур процессның мөһим бер баскычын тәшкил итә.

Көнчыгыш Аурупаның урта гасырлар тарихына гомуми караш ташлаганда, беренче чиратта, без анда ике зур суперэтносның—төркиләр белән славяннар берлегенең—гаять катлаулы һәм каршылыклы мөнәсәбәтләренә, үзара көрәшенә игътибар итәбез.

**1.** Кубрат ханның Бөек Болгариясе таралганнан соң, Көнчыгыш Аурупа далаларында төркиләр төзегән Хәзәр дәүләте генә торып кала. Бу дәүләт белән Киев Русе арасында барган көрәш 965 елда кенәз Святославның хәзәрләрне тар-мар итүе белән тәмамлана.

**2.** X йөзнең азагыннан (990 елдан) Киев Русе белән бәҗәнәкләр союзы арасында көчле бәрелешләр башланып китә. Әмма бераздан бу көрәш өзелеп кала. Эш шунда, XI йөз башларында Кимәк каганлыгыннан аерылып чыккан кыпчаклар Көнбатышка таба юл тота. Алар бәҗәнәкләр яшәгән далага килеп керә. Бәҗәнәкләр гайрәтле һәм гаять көчле кыпчаклар тарафыннан кысрыкланып, тагын да арырак—Дунайга күчеп китәргә мәҗбүр булалар.

**3.** Шулай итеп, бәҗәнәкләр урынын алган кыпчак ырулары үз чиратында Киев Русе белән көрәш башлый. (1061 елда кенәз Всеволод кыпчаклар тарафыннан тар-мар ителә.) Көрәш байтак вакыт дәвам итә һәм бары тик кенәз Владимир Мономах (1125 елда вафат) заманында гына кыпчакларның активлыгы беразга тукталып тора. Урыс кенәзләре, кыпчакларны үз якларына аударып, үзара сугышканда алардан бик оста файдалана. Кенәзләр улларын кыпчак кызларына өйләндерә, шулай үзара туганлашу, кода-кодагыйлык башланып китә. Шуңа да карамастан төрки кыпчаклар белән урыслар арасында киеренкелек сакланып килә. (Әйтик, 1168, 1182, 1184, 1202, 1205 елларда Киев кенәзләренең кыпчакларга каршы оештырган яулары шул хакта сөйли.) Сугышларның тынмавы дала батырлары кыпчакларның урыс кенәзләрен даими борчып, аларга каршы көтелмәгән һөҗүмнәр оештырып торуы белән аңлатыла. Кыпчаклар исә шактый таркау яши. Әле бер, әле икенче кенәз ягына чыгып, күп яуларда катнашалар.

Бу вакыт урыс кенәзләре үзара мөнәсәбәт ачыклау, «Киевнең алтын өстәленә-тәхетенә» утыру өчен күп көч куйсалар, шул сәбәпле гаять таркау яшәсәләр, дала уллары кыпчаклар арасында да үзара берләшеп, көч туплап, берәр дәүләт сыманрак нәрсә оештыру турында уйлаучы табылмый. Шуңа күрә XI йөз урталарында бик зур гайрәт белән Көнчыгыш Аурупа далаларына бәреп кергән кыпчакларның, уртак бер идея тирәсенә туплана алмыйча, теләсә кем белән сугышып, теләсә кемгә хезмәт итеп, һәр хан үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүләре аркасында тарихи җегәре-энергетикасы әрәм-шәрәм булып бетә. Дөрес, бу чорда Көнчыгыш Аурупа далаларында төрки массив арта төшә, калыная һәм бу хәл, монгол яулары башланып, Алтын Урда дәүләте төзелгән вакытта уңай роль уйный.

## II

**1223 елда** Көнчыгыш Аурупа далаларына монгол армиясе бәреп керү белән монда яшәгән этнослар өчен зур сынаулар, үзгәрешләр чоры башланып китә. Калка елгасындагы беренче сугышта берләштерелгән кыпчак-урыс гаскәре дошманга каршы чыга. Ләкин монголлар бу бәрелештә җиңә. Олуг тарихчыбыз Ризаэтдин Фәхретдин фикеренчә, Җучи ханның (Чыңгыз ханның улы) Дербенттан (Тимер Капу) килеп чыгуының төп максаты—кыпчак төрекләре белән берлек төзү иде. Ләкин урыс кенәзләренең котыртулары аркасында кыпчаклар белән тау халыклары Җучи хан гаскәренә каршы тордылар һәм, урысларның сугыш мәйданын ташлап качулары сәбәпле, җинелделәр» *(Р. Фәхретдин. Алтын Урда ханнары.—Казан.—1996.—16 б.).*

Бу чыннан да дөрескә охшый, чөнки монголларның сугыш алдыннан, кыпчакларга кеше җибәреп, без сезнең белән кан-кардәшләр дип, тегеләрне сугышмаска өндәве тарихи чыганакларда теркәлеп калган.

Шул ук елны монгол гаскәре даладан читтәрәк яшәгән Идел Болгариясенә дә кылыч тартып карый, ләкин, бик нык каршылыкка очрап, кыйналып кире борылырга мәҗбүр була. Ә инде тагын 13 елдан монголларның бик зур

гаскәре, Җаек елгасын кичеп, Көнчыгыш Аурупадагы дәүләтләрне яуларга керешә. 1236 елда Идел Болгариясе, 1237 дә Рязань, Мәскәү, Владимир кенәзлекләре егыла. Ике елдан соң алтын гөмбәзле чиркәүләре белән дан тоткан гүзәл Киев каласы да алар кулына төшә, аннан төрки-монгол гаскәре Галиция, Волынь, Польша, Силезия, Моравия, Венгрия, ә 1244 елда хәтта Вена шәһәре диварларына кадәр барып җитә.

Шушы дәһшәтле яулардан соң 1243 елда үзәге Идел буеның мул үләнле даласында урнашкан Җучи олысы, ягъни Алтын Урда дәүләтенә нигез салына.

Әлеге вакыйгалар турында сүз барганда, без гел «монгол гаскәре», «монгол яулары» дигән гыйбарәләр кулланабыз. Бу урыс тарих фәненә иярү күренеше. Ә бит чынында Көнчыгыштан килгән ифрат зур армиядә монгол элементы шактый аз булган. Гаскәрдә күпчелекне яулар барышында һаман өстәлә торган төрки кавемнәр тәшкил иткән. Шуңа күрә бу яулар турында сүз барганда анда кан-кардәшләребез төркиләрнең ролен гел истә тотарга кирәк. Миңа хәтта бер төрек аркадаштан «монгол яулары» дип язган өчен шелтә дә ишетергә туры килде. Ул, мәсәлән, Алтын Урданы фәкать татар дәүләте дип саный һәм дөрес эшли.

Әлбәттә, Чыңгыз хан империясен монголлар төзегән, ханнары да чыңгызыйлар, ягъни Чыңгыз хан нәселеннән чыккан затлар булган. Әмма төп масса төрки халыклардан торган. Дөньяга яңа этәргеч биргән, аңа «кан алыштырырга» ярдәм иткән бу яуларда төркиләрнең өлеше ифрат зур. Моның белән горурлана белергә кирәк. Гомумән, Монгол империясен төзегән Чыңгыз хан феномены, Александр Македонлы (Искәндәр Зөлкарнәйн) һ. б. бөек җиһангирлар эшчәнлеге кебек үк, Галәм, Илаһи Көчләр катнашыннан башка тормышка ашырыла алмас иде. Бу хакта әле фәнни әйләнешкә кермәгән эзотерик (яшерен) чыганакларда шактый ачык кинаяләр бар.

Алтын Урданың барлыкка килүе Көнчыгыш Аурупа далаларындагы таркау этносларны да, ничә гасыр буе үзара тарткалашып гомер кичергән утрак халыкларны да бер дәүләт кысаларына туплый. Объектив яктан караганда бу, һичшиксез, алга китеш, тәрәккыят күренеше. Әлбәттә, сугышларда күп кан коела, рухани һәм матди байлыклар да күп харап була. Ләкин яңаны төзү, үсешнең яңа баскычына күтәрелү һәрвакыт искене җимерү, аннан баш тарту, инкяр итү юлы белән бара түгелме? Бу бит эволюциянең төп кануны. Н. К. Рерихның «Держава Света» исемле китабында бу хакта кызыклы фикер бар. «Халыкларның бөек күченеше—очраклы хәл түгел,—дип яза ул.—Даими булып торган дөньякүләм күренешләрдә очраклылык була алмый. Шушы үзенчәлек аркасында халыкларның иң тормышчан куәте, сәләте чыныгу ала. Яңа күршеләр белән аралашу аңны кинәйтә, яңа расаларның формасын барлыкка китерә. Шуңа күрә тере хәрәкәтчәнлек ул зирәклелек галәмәте булып тора».

Монгол яуларының асыл мәгънәсе нәрсәдә соң? Мондый сорауга җавап биргәндә, иң элек теге яки бу күренешнең эволюция барышына ни өстәвен ачыкларга кирәктер, шөт. Үзебезгә якын Көнчыгыш Аурупаны күз алдына китерик. Бу вакытта Русь кенәзлекләре ни хәлдә? Пыр тузынышып сугышып яталар, үсеш тукталган, алга китү онытылган. Ә монгол яулары шушы сөрсеп яткан дөньяга хәрәкәт, яңа җилләр алып килә. Алтын Урда составына кереп, урыслар яңача төзелгән дәүләт үрнәген күрәләр; яңа хәрби система белән танышалар; яңача идарә итү, салым җыю тәртипләрен үзләштерәләр; элемтә чаралары, ягъни тиз арада хәбәрләшү ысулларын ачалар (ям чабу); яңа сәүдә юллары барлыкка килә; яңа кануннар белән танышалар һ. б., һ. б.

Бу яңалыкларны алга китеш, тәрәккыят дип карамыйча мөмкин түгел. Рас шулай икән, халыкларның бөек күчешен, олуг яулар, шул исәптән монгол яулары белән Алтын Урда дәүләте төзелүне дә Илаһи Көчләр ярдәме белән башкарылган гамәлләр дип карау дөрес булыр иде. Чөнки Галәм кешелек дөньясының эволюциясен гел кайгыртып тора, әмма кирәксезгә Җир эшләренә кысылмый, барысын да адәми затның үз кулы белән табигый рәвештә башкара. Кешеләр моны сизми генә—үзеннән-үзе шулай килеп чыкты дип уйлый. Эзотерик чыганаклар безгә шул хакта сөйли.

Монгол яуларына кадәр дә Көнчыгыш Аурупа далаларында кыпчак массивының шактый көчәюен, бу кавемнең славяннарның төп көндәшенә әверелүен искәртеп үткән идек. Алтын Урда барлыкка килү белән бу далалар, гомумән, Кыпчак даласына әйләнә—тарихка да ул Дәшти Кыпчак исеме белән кереп кала. Шулай итеп, кыпчаклар бередә төп этнос булып китә, ә аз санлы монголлар бераздан йотылып, тәмам кыпчаклашып бетә, ассимиляция кичерә. Төркиләр хаким халыкка әверелә. Әлбәттә, Идел Болгариясе дә бу процесстан читтә калмый. Болгарларның «татарлашуы» да шушы вакытта башланган дип исәпләргә нигез бар.

Форсаттан файдаланып, Алтын Урдадагы халыкның «татарлашуы» хакында бер күзәтүем белән уртаклашасым килә. Монарчы күпме тарихи хезмәтләр укысам да, әле Үзәк Азия далаларында Чыңгыз хан белән көрәшкән татарларның нинди телдә сөйләшкәнен ап-ачык итеп, өздереп әйткән хезмәт очратканым юк иде. Бәлки туры килмәгәндер. Тик шунысы сәер, тарихчылар да бу мәсьәләне гел әйләнеп узалар. Чыннан да, кайсы телдә сөйләшкән соң ул татарлар? Төрки телдәме, әллә инде монгол яисә башка берәр телдәме?

Ниһаять, «Мирас» журналының 1996 елның 7-8 саннарында басыла башлаган кыйммәтле чыганак—Ибне әл-Әсирнең «Елъязмалар төзү өлкәсендәге камиллек» исемле хезмәтендә моңа күпмедер ачыклык кертелә кебек. Чыганакта сүз Алтын Урданың Жучи улы Бәркә хан заманы турында бара. Аңа Мисыр солтаныннан илчеләр килә, аларның хан тирмәсендә кабул ителүе тасвирлана. «Бәркә *(хан)* тәхеттә утыра, янәшәсендә олы хатыны, арырак 50-60 әмир эскәмиядә утыра. Илчеләр патша *(Бәркә хан)* янына кергәч, ул вәзирләренә хатны укырга кушты... Бәркә *(хан)* янында булган баш казый хатны тәрҗемә итте һәм исемлекне *(нинди исемлек икәне аңлашылмый—С. Ш.)* ханга җибәрде; хатны Бәркә *(хан)* кешеләренә *(тезелешеп утырган әмирләр булса кирәк—С. Ш.)* төркичә укыдылар. Татарлар моңа куандылар...» *(189 б.)*

Әйтергә кирәк, соңгы җөмләдә бик кыйммәтле мәгълүмат бар. Димәк, Алтын Урда дәүләте төзелгән елларда ук (беренче хан Бату 1255 елда вафат), төрки-татарлар дәүләтне идарә итүдә актив катнашканнар. Илчеләрне кабул иткәндә хан янәшәсендә утырган 50-60 әмирнең күпмесе төрки-татарлардан булгандыр—анысы билгесез, тик Мисыр солтаныннан килгән хатның алар өчен махсус төркичә тәрҗемә ителеп укылуы һәм татарларның моңа куануы игътибарны җәлеп итә. Бу факт Алтын Урданың чыңгызый ханнарының татарларга (асылда төрки-кыпчакларга) таянып идарә итүен бик ачык күрсәтә. Шунлыктан дәүләттә кыпчак (татар) теленең тиз арада рәсми телгә әверелеп китүе табигый хәл булган, дип әйтә алабыз.

Шулай итеп, Алтын Урда дәүләтенә кергән барлык төркиләр, кыпчаклык казанында кайнап, иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни яктан бер үзәккә тартылып, көчле дәүләттә уртак тел, мәдәният һәм әдәбият хасил итәләр.

Тере организм, үзгәрүчән система буларак, Алтын Урда дәүләте дә төрле заманнар кичерә. Тик аның иң бөек, иң шөһрәтле һәм гайрәтле чагы, мәмләкәт барлыкка килеп, бер гасыр вакыт узгач, Үзбәк хан (1312—1342) идарәсенең соңгы елларына туры килә. Бу вакытта аның сәяси абруе, җәйгә салынган тормышы, икътисады, мәдәнияте шундый югарылыкка ирешә ки, күрше дәүләтләр өчен ул өлге-үрнәккә әверелә. Нәкъ шушы дәвердә ислам дине чын мәгънәсендә мәмләкәтнең рәсми диненә әйләнә. Мөселман дөньясының төрле тарафларыннан Сарайга дин әһелләре, галим-голяма, шагыйрьләр агыла. Шушы елларда Алтын Урда җирләре аша узган мәшһүр ислам сәяхәтчесе һәм олуг дин белгече Ибне Батутта юлларның иминлеге, дәүләттәге тәртип һәм тынычлык, һәр тукталышта юлчыларны кабул итәргә әзер торган кәрван-сарайлар, ханәкәләр, анда яшәп яткан суфилар, дәрвишләр турында хәйран калып яза. Сәяхәтченең юлда дала тутырып баручы процессия белән очрашуы, соңыннан ачыкланганча, йөзләгән тирмәләр белән хәрәкәт итүче бу халыкның Үзбәк хан бичәсен озатучылар булып чыгуын белеп, аның бик нык гаҗәпкә калуы гына да ни тора!

Әмма нәкъ Үзбәк хан заманында җәйгә салынган тормыштан, үзәккә агылып торган байлыктан, мәмләкәт ирешкән абруйдан, һәртөрле дипломатик

уңышлардан тынычланып калу, киләчәкне уйламыйча рәхәткә чумып яшәү, ваемсызлык галәмәтләре дә күренә башлаган булса кирәк. Билгеле хакыйкать— берәр нәрсәгә ирештем дип тынычланып калдыңмы—беттең. Бу инде үсеш тукталды дигән сүз.

Үзбәк хан шулай ук кул астындагы урыс кенәзлекләренә дә бик зур иркенлекләр бирә. Моңа заманында Р. Фәхретдин дә игътибар иткән. Бу ханның эшчәнлегенә бәя биргәндә, тарихчы аның ялгышларына да күрсәтеп үтүне тиеш таба: «Үзбәк хан алдан күреп эш итүчән, гакыллы, галиҗәнап падишаһ булса да, сәяси җәһәттән зур бер ялгышы инкяр ителмәс. Бу ялгыш Мәскәү кенәзлеген куәтләндереп, Урдага каршы киләчәк дошман хәзерләүдән гыйбарәт. Үзбәк хан гамәлдә үз араларында сугышып, кырылышып торган вак кенәзләрне бетереп, бер ноктага җыйды. Шул сәбәпле урыслар куәт алып киттеләр»,—дип яза тарихчы. Алай гына да түгел, Үзбәк хан Русия митрополиты Петрга православие дине өчен чикләнмәгән ирекләр бирә, монастырь җирләрен ясак түләүдән азат итә. Бу динне яклап хан тарафыннан бирелгән ярлыкта, Р. Фәхретдин әйтүенчә, хәтта кем дә кем христиан динен сүксә, чиркәү, монастырь вә часовняларга тел тидерсә, «ул адәм үтерелер» дигән сүзләр дә булган.

«Әлбәттә, һәр халыкның үз динен, гореф-гадәтләрен тотарга тулы хакы бар. Бу яктан караганда, Алтын Урда дәүләте заманның иң алдынгы, һәр дингә иркенчелек, тигезлек бирелүе белән Аурупа илләреннән аерылып торган. Чит илләрдән килгән кунаклар да моңа игътибар иткәннәр, андагы вөҗдан ирегең күреп гаҗәпкә кала торган булганнар, чөнки үз илләрендә бу хакта хыяллана да алмаганнар. Гомумән, Алтын Урдада дингә көчле идеологик корал итеп карау, моны аңлау бөтенләй булмаган ахры дип әйтергә туры килә.

Шул ук православие динен алыйк. Әгәр дә ханнар бу диндә мөселман татарга каршы юнәлтелгән идеологик корал күрсәләр, аның урыс халкын берләштерүче, мөселманнарга карата дошманлык тәрбияләүче көчле чара икәнен чамалый алсалар—андый ук иркенлекләр бирмәсләр иде. Урыс халкы мескенлектән фәкать үзенең руханилары тырышлыгы белән чыкты, рухи яктан ныгый барды һәм күпмедер вакыттан соң Сарайга каршы корал күтәрерлек көчкә әверелде. Шулай итеп, Алтын Урда үз куенында үсеп житкәч үзен үк чагачак елан үстерде. Шунысы кызык: Үзбәк хан тәхеткә чыгу белән монголлар арасында һаман әле яши биргән буддизмга каршы аяусыз көрәш башлый, үз дәүләтендә аның тамырын корыту өчен күп көч куя. Шуның аркасында өлкәннәре белән каршылыкка да керә. Ә менә православие диненә бөтен иркенлекләр дә бирелә. Бу ялгышы киләчәктә дәүләт өчен зур мәшәкатьләр тудырасын башына да китереп карамый.

Үзбәк хан белән Җанибәк ханнар заманында Алтын Урда әле яшьнәп яши, ләкин алардан соң тәхеткә чыккан Бирдебәк хан 1359 елда үтерелгәннән соң дәүләттә эчке чуалышлар, низаглар башланып китә. 1360—1361 елларда дәүләт икегә аерыла—уң һәм сул канатка. Иделдән көнчыгыштагы җирләр сул канатка керсә, көнбатыштагылары уң канатны тәшкил итә. Уртада—Идел елгасы. Бер якта гел алышынып торган Сарай ханнары булса, икенче якта, Сарайны кулга төшереп, анда үз ханын утыртырга омтылучы гайрәтле Мамай мирза хәрәкәт итә. Шулай итеп, дәүләттә ватандашлар (дөресрәге, ватанны харап итүчеләр!) сугышы башланып китә. Ул 20 елга сузыла һәм дәүләтне эчтән җимерүче факторга әверелә. Татарның үзара талашуыннан бик оста файдалана белгән Мәскәү кенәзлеге исә шушы елларда матди һәм рухани яктан шактый ныгып кала. Әгәр дә Алтын Урдада бу низаглар, тәхет даулары булмаса, 1380 елда урыслар корал тотып Куликово кырына чыгу түгел, ул хакта уйларга дә җөрьәт итә алмаслар иде. Татар мәмләкәте өчен исә эчке чуалышлар чоры Куликово кыры вакыйгасы белән тәмамлана. Ике дистә елга сузылган башбаштаклык, акылсыз сәясәт татарны шундый хәлгә төшерә. Бу—үлчәүнең урыслар ягына авыша башлавын кисәтүче симптом була.

Дөрес, бу очракта Куликово сугышында берләштерелгән урыс армиясенә каршы бөтен Алтын Урда гаскәре түгел, ә дәүләтнең Мамай мирза кул

астындагы ун канаты гына катнаша. Шуңа күрә без, урыс тарихчыларына иярмичә, бу сугышта «Алтын Урда гаскәре тар-мар ителде» дигән фикерне каттый рәвештә кире кагарга тиешбез. Чөнки нәкъ ике елдан (1382) Мәскәү шәһәре Урда татарлары тарафыннан алына һәм олуг кенәз Дмитрий Иванович Донской элекке кебек Сарайга ясак түли башлый.

## III

**Алтын Урда** тарихын өйрәнгәндә сәер бер хәл игътибарны җәлеп итә— дәүләтнең сәясәтенә мөселман руханиларының йогынтысы бик зәгыйфь булуын күрәсең. Дин әһелләре ханнар өчен рухани остаз, киңәшче, кыен мәсьәләләрне хәл иткәндә киңәшче дәрәҗәсенә күтәрелә алмаганнар, ахры, дигән фикер туа. Чыганаклардан күзгә ташланган бердәнбер зур вакыйга Үзбәк ханының улы Җанибәк хан заманына карый. 1357 елда Мөхетдин әл-Бәрдагый дигән атаклы бер шәех Сарай шәһәренә килә дә Әзәрбәйҗанда хөкем сөрүче Мәлик Әшрәф өстеннән Җанибәк ханга шикаять бирә, аның халыкны бик нык җәберләве, залимлеге, комсызланып мал җыюын бик тәэсирле итеп сөйләп бирә. Хан мәшһүр шәехнең сүзен игътибарсыз калдырмый, гаскәр туплап, залим хөкемдар өстенә яу чаба. Ике гаскәр Тәһран елгасы буенда очраша, зур сугыш була. Мәлик Әшрәф гаскәре тәмам туздырыла, үзе Җанибәк хан хозурына китереп бастырыла.

Киң күңелле, мәрхәмәтле Җанибәк хан Мәлик Әшрәфне гафу итмәкче булса да, Әзәрбәйҗанның олуг адәмнәре ханнан аны үтертүен сорыйлар, чөнки «ул сәламәт калса, бу тараф халкына һич рәхәтлек булмас, аның янадан әйләнеп кайтуыннан һәркем куркып яшәр», диләр алар. Һәм Мәлик Әшрәф Җанибәк хан әмере белән җәзага тартыла. Дөрес, бу очракта Җанибәк ханның нияте хакыйкатьне торгызу гына булмаган, күрәсең, чөнки кулга төшкән малның гаскәргә бүлеп бирелгәннән калган өлеше 400 дөягә төялә һәм Сарай шәһәренә кайтарыла.

Бу вакыйганы җәелеп язуның сәбәбе аңлашыладыр дип уйлыйм, чөнки Алтын Урда тарихында мондый фактлар бик сирәк очрый. Бу исә дин әһелләренең ханнарга йогынтысы әллә ни зур булмавын күрсәтә.

Ә менә урыс тарихында руханилар, нигездә митрополитлар, ямсә үзенең яшәеше, тормыш рәвеше, рухи батырлыклары белән изге дип танылган абруйлы затларның кенәзләргә, соңрак патшаларга да йогынтысы гаять көчле булган. Урыста дәүләт сәясәтен идарәче-хаким белән дин әһеле кулга-кул тотынышып алып барган. Мәгълүм ки, дин әһелләре, җәмгыятьнең иң укымышлы катламы буларак, дәүләтнең идеологиясен эшләгәннәр, аны заман таләпләренә җайлаштырып, үзгәртеп торганнар. Шулай итеп, хакимнәргә дәүләтнең яшәү максатларын ачыкларга ярдәм иткәннәр. Әлбәттә, бу традиция урысның үзендә барлыкка килеп, табигый рәвештә үсеп чыккан нәрсә түгел. Ул әзер килеш православие дине, шуңа бәйле бай мәдәният белән урысларга Византия (Рум) империясеннән килә, аннан инде җирле шартларга яраклаштырыла, үзгәрешләр кичерә.

Сарай ханнары кул астыннан чыгарга хыялланып яшәгән, хәтта бу юнәлештә инде кайбер адымнар да ясарга җыенган Мәскәү кенәзе Дмитрий Иванович 1380 елның җәй ахырында Мамай мирзага каршы яуга кузгалыр алдыннан, гадәткә кергән йола-традиция буенча, көч-таянычны дин әһелләреннән өмет итә, Куликово сугышы алдыннан алар белән киңәшеп, хәер-фатиха алырга ниятли. Тик кем белән очрашырга, кемнән фатиха алырга? Эш шунда ки, моннан ике ел элек, 1378 елда, Мәскәү митрополиты Алексей вафат була, аның урынына яңа кеше әле расланып өлгерми, чөнки урыс руханилары арасында митрополит кафедрасы өчен ун елга сузылган тарткалашу башланып китә. Бу очракта кемгә мөрәҗәгать итәргә, урыс руханилары арасында кем иң зур абруйга ия дә кем бөтен халык тарафыннан танылган изге зат санала?

Дөресен әйткәндә, олуг кенәз Дмитрий Иванович алдында андый сорау бөтенләй тормый, чөнки ул елларда рәсми куелган митрополиттан башка

изге гамәлләре, тормыш-яшәеше, рухани батырлыклары белән халык тарафыннан танылган бердәнбер асыл зат Сергий Радонежский була. Әйтергә кирәк, татарда бу руханига карата мөнәсәбәт шактый катлаулы, чөнки урыс халкын Алтын Урда белән жан-фәрман көрәшкә өндәүче, аңа көч-куәт биреп торучы, күңелләренә өмет нуры салучы төп фигура да шушы Сергий атакай Радонежский бит. Ләкин бу хәл аңа карата тискәре мөнәсәбәт саклар өчен сәбәп була алмый. Ул бит мәгълүм бер заманда, конкрет бер вәзгыятьтә үз халкының азатлыгы, аның бәйсезлеге өчен көч куйган зат, шуңа күрә бүгенге көндә тулы бәйсезлек хакында хыялланучы татарның аңа карата кинә саклавы чикләнгәнлек галәмәте булыр иде.

Аның бу вакытта зур абруй казануын тагын бер факт раслый: 1377 елда, вафатына бер ел калган чакта митрополит Алексей, көннән-көн хәлсезләнә баруын исәпкә алып, йола буенча үзе исән чакта урынына кеше билгеләп калырга тели. Шул нияте белән Сергий Радонежскийга мөрәҗәгать итә, митрополитлыкны аңа тапшырмакчы була. Тик Сергий атакай моннан баш тарта: «Гафу ит, Владыко, мин яшь чагымда да алтыннан киенмәдем, карт көнемдә дә мохтажлыкта яшәргә тиешлемен дип беләм»,—дип җавап бирә ул. Ә тагын бер елдан митрополит Алексей вафат була. Һәм, әйткәнебезчә, руханилар арасында митрополитлык өчен көрәш башланып китә. Шунысы игътибарга лаек: митрополит булырга теләүчеләрнең һәркайсы көрәш барышында Сергий Радонежскийның фатихасын алырга тырышалар. Бу исә дин әһелләре арасында аның аерым урын алып торуын, зур абруйга ия булуын күрсәтә.

## IV

**Әйе**, Алтын Урда ике канатка аерылып, 20 ел буе үзара сугышлар алып барган, шул сәбәпле татар үз дәүләтен эчтән җимергән, хәлсезләндергән, потенциал дошманы Мәскәү кенәзлегенә көч тупларга ярдәм иткән мәгълүм елларда татарлар арасыннан бу хәлнең дәүләтне һәлакәткә китерәсен аңлаган, төрле низаглардан, үзара көрәшүче фиркалардан өстен торган берәр олуг шәхес үсеп чыкканмы? Үзенең ханнар да колак салырдай саллы сүзе белән ике якны килештергән, сукыр сәясәтнең бөек татар мәмләкәтен нинди авыр хәлгә куячагын күрә белгән, шуны аңларга тырышкан берәр асыл зат булганмы? Кистереп әйтә алабыз—юк, булмаган андый шәхес. Булса, аның исеме тарихта калыр иде, андый затны халык онытмас иде. Бу очракта без чыганаклар сакланмаган дип тә котыла алмыйбыз. Халыкның хәтере дә бар бит әле. Андый шәхесләр чыганакларда гына түгел, халыкның йөрәгендә яши, риваятьләр, дастаннар булып буыннан-буынга күчә. Әнә бит, Идегәй мирза белән Туктамыш ханның үзара көрәше дастанга әверелгән, гасырлар аша безгә килеп җиткән.

Бу елларда Алтын Урда коточкыч инкыйраз-кризис кичерә, ханнар белән хөкүмәт ваклана, зур деградация кичерә, идеаллар түбән тәгәри. Балык башыннан чери дигәндәй, идарәчеләрнең әхлагы түбән булгач, гади халыктан ни көтәргә кала? Гомумән, бу кризис, болганышлар чорында илне кайгыртучы олуг шәхеснең мәйданга чыга алмавы—Алтын Урда канаты астына тупланган чуар кавемнәрнең уртак идеалы әле калыплашып җитмәве турында сөйли шикелле. Әгәр дә дәүләт тагын илле ел (ике буын) гына тыныч шартларда яшәсә, инде борынлап килгән уртак үзаң, уртак идеал, һичшиксез, ныгып өлгергән булыр иде. (Бу мәсьәләгә язманың азагында киңрәк тукталырбыз.)

Урыс дөньясында исә бу елларда бердәм булсак җиңәрбез, үзара талашуларны, әлек белән Сарайга, ханнар хозурына йөрүләрне туктатып, бер йодрыкка тупланырга кирәк дигән фикер көннән-көн, елдан-ел ныгый бара. Мәскәү кенәзләре, аларның таянычы булган урыс руханилары бу фикерне пропагандалаучы төп көчкә әверелә.

Татарда исә бу елларда—кая карама томаналык, сәяси сукырлык, рухи деградация. Бөек мәмләкәтнең тарихындагы бу дәвергә Р. Фәхретдин дә игътибар иткән, бик нык аптырагач, аңлатыр сүз таба алмагач, «җәнабы Алланың үзенә генә мәгълүм булган сәбәпләр аркасында хөкүмәтләр өстенә

кайбер вакыт кисәктән килгән фалиҗ (паралич) хәстәсенә охшаган бер афәт килә», дип чикләнергә мәҗбүр була.

Шулай да Алтын Урдада XIV йөзнең 60 елларында башланган «бөек болганыш»ның килеп чыгуының сәбәбе нидә икән? Ни өчен көчле дәүләттә кинәт көчле низаглар кабынып китә? Кайбер тарихчылар моны далада халык саны кирәгеннән артып китү (?), хәзерге терминологиягә күчерсәк, демографик шартлау белән аңлатырга тырышалар. Янәсе, көтүләр йөртү, җәйләү-кышлау өчен уңайлы урыннар, маршрутлар елдан-ел кысыла, тарая барган, шуның аркасында каршылыклар килеп чыккан. *(Э. Кульпин. Путь России.—ч. I.—С. 91).*

Ләкин халык санының бик нык артып китүенә ышануы кыен. Ни өчен?

Әйткәнебезчә, Үзбәк хан заманы дәүләтнең чәчәк аткан, иң нык күтәрелгән чагы дип санала. Табигый ки, бай һәм имин заманда халык саны да үзенең иң бөек ноктасына җиткән булса кирәк. Тик Үзбәк хан үлгәч дүрт ел да узмый, 1346 елда Алтын Урда өстенә зур афәт килә—чума эпидемиясе Дәшти Кыпчак, Идел буе һәм Кырымда бик күп халыкны алып китә. Елъязмаларда бу хакта «Үзбәк (хан) җирләрендә... шәһәрләр һәм авыллар бушап калды», диелә. Бер Кырымда гына да шушы эпидемиядән 85.000 кеше кырыла. Бу фаҗига илгә бик зур зыян сала, аның авыр нәтиҗәләре шактый елларга сузыла. Ә шушы хәлдән соң 13 ел узгач, Алтын Урдада «бөек болганыш»—ватандарлар сугышы башланып китә. Аның сәбәбен далада җир җитмәү белән бәйләү беркатлылык түгелме?

Минемчә, сәбәп биредә «җир җитмәүдә» түгел, ә 1359 елда Бирдебәк хан үтерелгәннән соң дәүләттә хакимиятнең ихтыярсыз һәм очраклы кешеләр кулына күчүендә. Шуннан башлана да инде тәхет тирәсендә ыгы-зыгы, тавыш-гауга, кырылыш. Ә үтерелгән Бирдебәк ханның кияве гайрәтле Мамай мирза, форсаттан файдаланып, Иделдән Кырымга хәтле сузылган җирләрне үзәк хөкүмәт кулыннан тартып алуга ирешә. Дөрес-рәге, сепаратист сыйфатында Сарай ханнары белән көрәш башлап җибәрә. Шушы 20 еллык даулар 1380 елда Куликово сугышы белән тәгалләнә.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «KAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Фәнис Яруллин,**
Татарстанның халык шагыйре,
Г. Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты.

# ГОМЕРЛЕК ӨСТӘЛ КИТАБЫМ



*Элеккеге «Совет әдәбияты», хәзерге «Казан утлары» журналы, әдәби әсәрләргә күңелем тартыла башлауга ук өстәл китабыма әверелде. Кытлык чорлар булганлыктан, билгеле, мин аны өйгә яздырып укый алмадым. Аны авылыбыз яки мәктәп китапханәләреннән, клубтан алып торып укырга гына мөмкин иде. Ни гаҗәп, заманалар ничек ярлы булмасын, китапханәләр, мәктәпләр, клублар газета-журналларны күп алдыра иде. Әле дә хәтеремдә, китапханәнең уку залында гына түгел, клуб өстәлләрендә дә төрледән-төрле газета-журналлар күп һәм алар бер кулның җылысын икенчесенә тапшырып, байый, калыная баралар иде. Без үскәндә клубта газета-журнал укып утыру гадәти хәл иде.*

*Күңелемә «китап корты» дүртенче класста укыганда керде; китаплардан журналларга күчте. Ә журналлар арасында иң бае, иң кызыклысы әлеге дә баягы әнә шул «Совет әдәбияты» («Казан утлары») иде.*

*Мин хәзерге акылым белән уйлап карыйм да исем китә: үсмер малай-*

Болганыш елларында дәүләтнең бер-берсенә дошман ике өлешкә бүленүенең тагын бер сәбәбе бар кебек. Ул дәүләтне икегә бүлеп аккан Идел елгасына да бәйле. Идел—табигый географик чик. Бу очракта элегрәк заманда Нугай мирзаның Теләбуга һәм Тыктай ханнарга (үзәк хөкүмәткә) каршы алып барган көрәшен искә төшерү дә җитә. Мамай мирза Нугай мирза заманында ук башланган күренешнең дәвамчысы, аның эзеннән баручы, дәүләттә яшәп килгән тенденцияне дәвам иттерүче генә. Гомумән, без Алтын Урда тәхетендә көчле ханнар утырганда гына сул канат белән уң канат арасында тату мөнәсәбәтләр саклануын күрәбез. Монда дәүләтнең һәр канатында үзгә менталитетка ия халык яшәвен дә онытмаска кирәк. Һәр канатның үз сәяси ориентирлары һәм мәнфәгатьләре булган. Ә Мамай мирза Сарай ханнарына каршы алып барган көрәшендә еш кына Кырымга, андагы бай сәүдәгәр-җәнүизләр акчасына, Литва кенәзләре ярдәменә таяна. Бер сүз белән әйткәндә, Мамай мирза үзенең сәяси карашлары буенча ярылып яткан «көнбатышчы» була.

Вожа суы буенда Урда гаскәренең җиңелүе (1378) Мамай мирза алдына кискен рәвештә Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне ачыклау бурычын китереп куя. Табигый, бу югалтуны ул авыр кичерә. Чыннан да, гомер буе урысларны дер калтыратып яшә дә көннәрнең берендә җибәргән гаскәрең кыйналып кайтсын әле. Моңа ничек түзмәк кирәк тә, бу хәлдән соң агай-эне белән бәкләрнең күзенә ничек күтәрелеп карамак кирәк. Җитмәсә, шушы бәрелештә аның Бигеч, Хаҗи бәй, Карабелек кебек олы мирзалары да һәлак була. Мамай мирза үзе тәхеткә чыгарган Мөхәммәт Буләк хан да бу затларның үлемен аннан күрә бугай. Ә үзе Мамай мирзаның киң җилкәсенә ышыкланып чип-чиста калды. Бу шартларда Мәскәүнең олы кенәзе Дмитрийны тиз чүктереп кенә Урдада абруен саклап кала алачагын Мамай мирза яхшы аңлый. Ул узынып киткән Мәскәү кенәзлегенә зур яу оештырырга кирәк дигән ныклы карарга килә. Тик бу эшкә ул инде Мөхәммәт Буләкне катнаштырмаячак. Җиңелгәндә читтә торып калып, җиңеп кайтканда дан-

*лардан башлап яшь егет һәм кызларны, урта яшьтәге кешеләрне һәм ак сакаллы картларны нәрсәсе белән кызыктырды икән бу журнал? Бу сорауга җавабым да әзер сыман. Беренчедән, ул үзенең кызыклылыгы белән алдырган, икенчедән, ошбу журналыбыз безнең өчен энциклопедия булган икән. Өченчедән, чорыбызның тарихын әдәби чаралар аша, цензура йодрыгыннан кысылып чыга-чыга халыкның аңына җиткергән. Тормыш чынбарлыгын «эзоп теле» аша булса да җаныбызга ярып салган әсәрләр чыккан. Дүртенчедән, бүгенге кебек һәркемнең өендә китапханә булмаган. Әдәбиятка сусавын ул журналлар укып басарга тырышкан.*

*Шушындый мәртәбәле журналның берәр вакыт үзем дә күпсанлы авторларының берсе булып китәрмен дип уйламый идем. Җанымда шигъри орлыклар 7-8 классларда укыганда шыта башласа да журналда үз әсәреңне бастыру күкнең җиденче катына менү белән бер иде. Шулай да, йөрәгем җитеп, 8 класста укыганда бер көлтә шигыремне җибәрдем мин анда һәм 2-3 атнадан басылып чыгуын көтеп йөри башладым. Әмма шигырьләрем басылган журнал урынына «Әсәрләрегез йомшак. Язуыгызны дәвам итегез. Әйбәт шигырьләрегезне көтәбез», дигән хат килеп төшкәч, ачудан бу хатны ерткалап аттым да «Яңа әйбәт шигырьләрне көтегез әле алайса»,—дип язудан беразга туктап тордым. Ләкин шигърият гөле күңелеңә бер тамыр җибәрсә, үсә дә үсә икән. «Казан утлары»на да ачуым басылды.*

*Армиядән ябь-яшь килеш имгәнеп кайту йөрәктә төенләнеп килгән яшен утларын көчәйтеп җибәрдеме, бәгырьдән чыккан хисләр ташкыны шушы яшен утлары белән кисештеме—куллар яңадан каләм сорый башлады. Башта шигырьләрем Баулы районының «Байрак», Ютазы районының «Коммунизмга» газеталарында басыла башлады. Аннан соң мин аларның кайберләрен «Яшь ленинчы»—хәзерге «Сабантуй»га җибәреп карадым. Бу 1961 елларның ахыры иде. Ә бераздан, 1962 еллар башында минем янга «Яшь ленинчы» газетасында әдәби мөхәррир*

шәһәрттә коенып яшәмәсен әле.

Чыннан да, урыс елъязмачылары теркәп калдырганча, Вожа суындагы кыйналудан соң «кесә ханы» Мөхәммәт Буләк белән аның тарафдарлары юк ителә, Мамай мирза Тулуг бәкне хан итеп күтәрттерә. Шулай итеп, ул каршы сүз әйтердәй кешеләрне тәхеттән читләштерүне кирәк таба.

Куликово кыры вакыйгаларына, аңа хәзерлек көннәренә күчкәнче бер мөһим мәсьәләне ачыклап үтү кирәктер шикелле.

Дөресен әйтергә кирәк, Мамай мирза үзәк хөкүмәткә каршы юнәлтелгән көрәшендә төп максатка барыбер ирешә алмый. Көрәшне башлап җибәргәндә ул Сарайны бөтенләйгә кулга төшерү, шунда тәмам ныгу, Алтын Урдага хуҗа булуны максат итеп куя. Дөрес, ул Сарайны берничә тапкыр чыннан да кулга төшерә, анда үз ханнарын да утырткалый, тик дошманнары хөкем сөргән көнчыгыш өлкәләр аңа башкалада ныгып калырга ирек бирмиләр. Һаман саен Сарайны ташлап чыгарга туры килә. Моңа аның Чыңгыз хан нәселеннән булмавы, шул сәбәпле, тәхеткә чыга алмавы да нык комачаулый. Ул гомере буе башка берәүне тәхеткә утыртып, аның исеменнән идарә итеп азаплана. Бу хәл аны, ахыр чиктә, бик нык туйдыргандыр, күрәсең. Ул үзенең Сарай тәхетенә беркайчан да чыга алмаячагын, ниһаять, аңлый булса кирәк. Ә бу инде гайрәтле һәм максатчан, үз дигәнен эшләргә өйрәнгән Мамай мирза өчен ниятенең тормышка ашмый калуы—гомерлек хыялына ирешә алмавы дигән сүз.

Әлбәттә, бу хәл белән килешү Мамай мирза өчен бөтен хыялларының җимерелүе, алардан баш тартуы булыр иде. Тик Мамай мирза кебек көчле шәхес ятып кала аламы? Әлбәттә, юк. Һәм ул, бөтен көчен туплап, тагын бер ыргылыш-акция оештырырга кирәк таба. Ул Мәскәү кенәзлегенә яу белән барачак та, аны басып алып, олуг кенәзне төшереп, Мәскәүне үз биләмәләренең үзәге итәчәк. Шулай итеп, ул үз татарлары өчен дә, урыслар өчен дә хан кебек олуг идарәчехаким булачак.

Ә Сарай? Нишлисең бит, Сарай аныкы булмады, тәкъдирдә шулай язылгандыр. Яшәсен үзенчә, болгана

*булып эшләүче Марс Шабаев килде. Ул ике-өч көн бездә булып минем кәкребөкре хәрефләр белән тыгызлап тутырылган калын-калын шигырь дәфтәрләремне укып чыкты. Казанда минем хакта зур мәкаләләр бастырды. Шуннан инде мин «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы», «Совет Татарстаны» кебек республика газеталарына да шигырьләремне җибәрә башладым. Марс Шабаев кайбер җитдирәк шигырьләрне аерып алып: «Боларын «Совет әдәбияты» журналына биреп карармын әле»,—дип аерып алып китте.*

*Мин ул чакта әсәрләрнең журнал папкаларында озаклап ятканын белми идем, берничә ай эчендә шигырьләрем күренмәгәч, «Бу журналга минем буй гына җитә торган түгел ахры»,—дип кул селтәдем.*

*Журналда әсәрләрем басылып чыгудан өметләрем киселеп ятканда безгә—Баулы районының Кызылъяр авылына дүрт язучы килеп төште. Бу 1962 елның 24 мае иде. Аларның берсе Гомәр Бәширов, икенчесе Сибгат Хәким, өченчесе Рәшит Гәрәй, дүртенчесе «Казан утлары» журналының ул чактагы баш редакторы Абдулла Гомәр иде. Әни кабалана-кабалана өстәл әзерли башлады. Өлкән әдипләр исә минем шигырь дәфтәрләремне актардылар. Абдулла Гомәр берничәсен үз блокнотына күчереп тә алды. Шигырьләремә карата нинди дә булса мактау сүзе әйткәннәрен хәтерләмим. Бары тик Сибгат Хәкимнең генә Гомәр Бәшировка карап: «Бу энекәштә өмет бар»,—дигәне истә. Киткән вакытта Абдулла Гомәр: «Безнең журналда шигырьләрең чыгып ята. Бер-ике айдан син ул журналны алырсың»,—дигәч нинди хисләр кичергәнемне бары тик шигырь язып бастыру бәхетенә ирешкән кешеләр генә аңлар.*

*Миңа «Казан утлары» журналында соңрак чорларда эшләгән мөхәррирләр Газиз Мөхәммәтшин, Рафаэль Мостафин, Гариф Ахунов һәм Равил Фәйзуллиннар белән үз өемдә чәй өстәле янында әңгәмәләр корып утырырга туры килде. Һәммәсе олы шәхесләр, күрәсең, мондый саллы журналда шундый олпат кешеләр эшләргә тиеш булгандыр.*

бирсен. Ул инде туйды, әнә картлык та якынлашып килә, ана да соңгы елларын тынычта уздырырга, бераз ял итәргә вакыттыр.

Мәскәүгә яу оештыру планы менә шундый уй-фикерләр, ниятләргә бәйле булмады микән? «Сказание о Мамаевом побоище» исемле әсәрдәге юллар шул хакта сөйли түгелме: «Яко аз не хощю тако сътворити, неко Батый, но егда дойде в (Руси), убию (большого) князя их, и который его град красный довлеет нам, и ту сядем ведати и Русью владсти, тихо и безметежно поживем». Татарча тәрҗемә иткәндә бу болайрак була инде: «Мин Батый кебек эш итәргә җыенмыйм, ләкин Руська барып житкәч, аларның (олуг) кенәзен үтереп, аның безгә яраклы матур каласында урнашып калырмын һәм Русь белән идарә итәрмен, тыныч һәм борчуларсыз яшәрмен».

Дөрес, бу сүзләрне Мамай мирзаныкы дип, урыс авторы үзе теркәп куйган. Аларның бигүк хак булмавы да бар. Тик алар бер сәбәпсез генә «Сказание» битләрендә урын алмагандыр. Һәрхәлдә, вакыйгалар логикасы, Мамай мирзаның тынгысыз тормышын күздән кичерү бу фикернең дөреслеккә якын торуын күрсәтә кебек. Мирзаның ахыр чиктә Мәскәүне үзенең төп базасы итеп сайларга җыенуы мөмкин хәл. Ни өчен дигәндә, ачык далада урда корып гомер итүнең шактый мәшәкатьле, хәтәр нәрсә икәнен ул әйбәт белгән. Артында көчле дошманнарың тормаганда бу әле мөмкин, ә Сарай ягыннан көн дә һөҗүм көтеп яшәргә калгач, авыррак туры килә шул.

Әйе, ул элеккечә Кырымга да барып урнаша алыр иде, тик аннан торып Кыпчак даласына хуҗа булу кыенрак. Аннан соң Кырымга кереп бикләнүнең хәтәр ягы да бар: Кырым— капчык, авызын бәйләп куйсалар, кая барырсың. Җәнүизләргә дә ышанып бетеп булмый, сәүдә әһле, артык шома халык... Ә Мәскәү—диварлы, ныгытылган ышанычлы кала. Бер кулга төшереп, тәртип урнаштырсаң, карт көнендә бер кайгысыз гомер итәргә мөмкин.

Менә шундыйрак планнар белән җыенмады микән Мамай мирза Мәскәү явына. Һәрхәлдә, моны гепотеза буларак кабул итәргә мөмкин шикелле.

*«Казан утлары»ның җылысында бер җылынгач аннан инде һичничек аерыла алмыйсың. Әр-яңа шигырьләрем, хикәяләрем, повестьларымны башлап анда җибәрә идем. Абдулла Гомәр, Сибгат Хәкимнәр дә мине онытып бетермәделәр. Казан хастаханәсендә ятканда да яныма килеп, яңа шигырьләремне сайлап алып китәләр иде. Укучылардан миңа иң күп хатлар китергән «Җилкәннәр җилдә сынала» повестем дә башта «Казан утлары»нда басылды. Аннары ул Мәскәүдә һәм Казанда рус телләрендә, Казакъстанда казакъ телендә дөнья күрде. Кыскасы, «Казан утлары» журналы тормышымның аерылгысыз өлешенә әйләнде.*

*Тагын шуны әйтеп утү урынлы булыр, заманында «Казан утлары» журналы илче хезмәтен дә үти иде. Бервакыт Таҗикстанның башкаласы Дүшәнбегә баргач һәр очрашып сөйләшкән татар кешесе: «Ә сез «Казан утлары»нда фәлән әсәре чыккан Фәнис Яруллинмыни?»—дип, якын кешеләре белән күрешкәндәй килеп күрешәләр иде. Үзбәкстанда да, Кырымда да, Латвиядә дә шул хәл иде. Шунда мин әдәбиятның күңелдән-күңелгә сузылган күпер икәнен аңладым.*

*Тормышта безнең миссиябез бик зур икән ләбаса. Җанны—җанга, хисне—хискә, дәверләрне—дәвергә, үткәннәрне—бүгенгегә, бүгенгене—иртәгегә тоташтыру, нинди дер кисәкләрдән торган дөньяны бербөтен итү, матурлык һәм ямьсезлекнең көрәше аша хакыйкатьне ачу. «Казан утлары»нда эшләүче барлык хезмәткәрләр: әдипләр, шагыйрьләр, публицистлар шушы миссиянең олылыгын һәрвакыт аңлап эш итәләр. Ә мин исә шушындый журналыбыз булганга сөенеп яшим.*

**4 гыйнвар, 2002 ел**

Бу вакытта Мәскәү кенәзлеге өстенә яу йөрү өчен шактый унай шартлар туа. Эш шунда, Алтын Урданың сул канатында барган көрәшләрдә Ырыс хан һәлак булганнан соң аның уллары Туктамыш белән тарткалаша. Билгеле, аларның уе әлегә Мамай мирзада түгел. Аннан соң Мамай мирзага Мәскәү өстенә йөрү өчен артында дошман тормау да зарур. Бу яктан караганда да уңайлы чак—Әстерхан белән Төньяк Кавказ да аның кулында, ягъни әлегә Иделдән көнбатышка таба сузылган җирләрдә урыслардан башка аңа каршы торырлык көч күренми. Кырым җәнүизләре дә аңа ярдәм итәргә әзерләр.

Әлбәттә, мондый зур эшкә алынганда, аркадашлар-союзниклар турында да уйламыйча булмый. Мамай мирза, Литва кенәзе Ягайло белән элемтәгә кереп, аны да бу яуга тартуга ирешә. Шулай ук Рязань кенәзе Олег та аңа ярдәм итәргә мәҗбүр була. Ни өчен дигәндә, башкача эшләргә хәле юк. Әле Бигеч мирза отряды тар-мар ителгәч тә, шул ачудан 1378 елның сентябрендә Мамай мирза аның биләмәләрендә ут уйнатты. Вожа вакыйгасыннан соң татарлар һөҗүмен һич көтмәгән кенәз Олег, калаларын саклап та тормыйча, Оканың теге ягына качып котылды. Билгеле булганча, Ока елгасы һәрвакыт татар белән урыс арасыннан үтә торган чик булып хезмәт итте. Ул чакта татарлар Дубок, Переяславль Рязанский калаларын алып, бай ганимәт малы җыеп, кире кайтып киттеләр. Ә бит Мамай мирза Мәскәүгә каршы кылыч тарта калса, татарлар кабат Рязань кенәзлеге аша узачаклар. Шулай булгач, кенәз Олегка һич тә татарлар ягында калмау мөмкин түгел.

Кайбер рус тарихчылары, Ягайло белән Олег кенәзләрнең бу яуга мөнәсәбәтен аңлатып, алар менә ничегрәк фикер йөрткәннәр дип язалар: «Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Иванович Мамай мирзаның зур яу белән үзенә киләчәген, ә безнең аның белән килешү төзиячәгебезне чамалап, йә Мәскәүдән ераграк җирләргә чыгып качачак, йә Великий Новгород белән Двина тирәләренә китеп югалачак. Ә без исә Мәскәү белән Владимирга төпләнеп калырбыз, ханны *(Мамай мирзаны—С. Ш.)* анда зур хөрмәт һәм бүләкләр белән каршы алып, кунак итеп, соңрак өенә (далага) әйләнеп кайтуын үтенеп сорарбыз. Үзебез исә аның рөхсәте белән Мәскәү кенәзлеген ике өлешкә бүләрбез—берсен Вильнога, икенчесен—Рязаньга китереп кушарбыз. Шул биләмәләр өчен ярлыклар сорап алырбыз да аларны мирас итеп балаларыбызга калдырырбыз» *(С. М. Соловьев. Сочинения в 18-и книгах.—М.,—1988.—Т. 3.—С. 275.)*.

Бу сүзләр чыннан да дөрескә охшаган. Монда Ягайло өчен дә, кенәз Олег өчен дә тулы бер программа—максимум салынган. Әмма алар Мамай мирзаның кем икәнлеген генә исәпкә алып җиткермәгәннәр. Ә бит билгеле—ул беркайчан да, беркем кулында да уенчык булмаган. Киресенчә, гомере буе башкаларны үз кубызына биетеп яшәгән. Еш кына татарның гомуми максатларына зыян китерсә дә, гел үзенекен иткән.

Урыс тарихчылары Рязань кенәзе Олегны еш телгә алалар, нигездә сүгеп, гел гаепләп язалар. Бу аңлашыла: кенәз урысларның милли мәнфәгатьләренә хыянәт итүче үтә дә булдыклы һәм хәйләкәр зат булган. Өстәвенә телгә дә кесәгә кермәгән, шул тасма теле аркасында әллә нинди кыен хәлләрдән чыга белгән. Киресенчә, берьюлы ике хуҗага хезмәт итүдән дә тайчанмаган.

Бу юлы да шулай килеп чыга: Мамай мирза аңа планнарын сөйләп биргәч, күп тә үтми Олег, Мәскәүгә кеше җибәреп, кенәз Дмитрийга татарларның зур яу оештыруын ачып сала. Бу аңа Мамай мирза белән килешү төзүен яшерү өчен кирәк була. Кенәз Дмитрийга ул болай дип яза: «Мамай үзенең барлык көчләре белән минем тарафка, Рязань җирләренә һәм сиңа таба килә. Ягайло да аның белән. Син белеп тор—безнең кул әле биек («еще рука наша высока»): әзер бул, нык тор».

Аның «безнең кул әле биек» дигәне, куллар әле корал тотарлык, дип үзенең Дмитрий яклы булуын исбатлау өчен кирәк булгандыр.

Шулай итеп, Мамай мирза яуга әзерләнә башлау белән үк, аның барлык планнары, көне-сәгате белән дигәндәй, Мәскәүгә барып та җитә. Хәер, серне кенәз Олег ачмаган очракта да, бу хәбәр сер килеш саклана алмас иде. Ни өчен дигәндәй, Мамай мирза яуга зурдан кубып хәзерләнергә җыена, кешеләре гаскәрне бөтен Дәшти Кыпчак даласыннан—Әстерхан, Төньяк Кавказ, Азак-Дон, хәтта Кырымнан да яллыйлар. Гаять чуар гаскәрдә «татарлардан» тыш

яслар (осетиннар), чиркәсләр, бортаслар, әрмәннәр, Кырым яр буенда яшәүче җәнүиз-итальяннар да була. Шундый кинлекләрдә хәбәр йөргәч, халык хәрәкәткә килгәч, ул ничек сер булып калсын ди. Сәүдәгәр халкы йөреп тора, ә алар—гомер-гомергә беренче шымчылар булган.

Шулай итеп, гаять зур гаскәр тупларга карар кылына. Аның күпме булуы төгәл билгеле түгел, тик урыс тарихчылары аның урыс гаскәреннән күбрәк булуын искәртергә яраталар. Бу Куликово сугышының әһәмиятен тагын да күтәрү өчен эшләнә булса кирәк.

Табигый, әле җәй ахырларында ук татар явы турында хәбәр алган олуг кенәз Дмитрий да кул кушырып утырмый. Рязаньнан чапкын килгәч, башта пошаманга төшсә дә, бераздан исенә килә, якыннары белән кинәш-уңаш иткәннән соң кенәзләргә атчабарлар озата. Полклар, дружиналар йөртүче кенәзләр, воеводалар, бояр уллары барысы да билгеле вакытка Мәскәүгә һәм Коломнага килеп житәргә тиеш булалар. Шуңа игътибар итик: башка вакытта шактый таркау булган, бер-берсенә аяк чалган, хәтта үзара таркалышып яшәгән урыс кенәзләре бу юлы хәлне тиз аңлап алалар, зур бердәмлек, оешканлык күрсәтеп, олуг кенәз байрагы астына ашыгалар.

Гадәттә, Куликово сугышына урыс гаскәренең тиз җыелуын халыкта татарга карата нәфрәтнең, аннан үч алу теләгенең көчле булуы, патриотизм хисләре белән аңлаталар. Әлбәттә, анысы да булгандыр. Тик бу очракта Э. Кульпин фикеренә колак салу да артык булмас. Ул менә ни дип яза: «Мамай Русь илендә хакимият урнаштыру һәм акчага хужа булуны үз кулына алырга омтылды, тегеләренә дә, боларына да куркыныч белән янады. Мәскәү кенәзләренең төп мәнфәгатьләренә кагылды. Шулай ук Мамай явы олуг кенәз кул астындагы дружинниклар белән служилый боярларның мәнфәгатенә дә бик нык китереп сугачак иде. Шундый хәвеф янаганда Дмитрий Донской тиз арада зур гаскәр туплый алды, калаларны саклаучыларсыз калдырды, шуңа күрә халык кайгыга батты. Дружинникларсыз калган калалардагы гади халык татарларның, акрын селкенүче урыс гаскәрен әйләнеп узып, сакланмаган урыс тылларыннан тоткарлыксыз-нисез үтү мөмкинлеген бик яхшы аңлый иде. Әйе, бу мөмкин иде, тик бу юлы татарлар Русьне җәзалау өчен барырга җыенмадылар» *(Э. Кульпин. Путь России.—С. 95.)*.

Шулай Ростов, Белоозеро, Ярославль, Владимир, Переяславль, Кострома, Муром, Дмитров, Можайск, Звенигород, Углич, Серпухов һ. б. калалардан үзәккә гаскәр агыла башлый. Суздаль-Новгород һәм Тверь кенәзлегеннән генә олуг кенәз карамагына полклар килми. Рязань кенәзе Олег, әйтелгәнчә, Мамай мирза ягында була. Шуңа күрә тарихчылар урыс армиясе 150 меңнән дә артмагандыр дип исәплиләр. Мамай мирза гаскәре урысныкыннан күбрәк дип язсалар да, бу яуда Алтын Урданың уң канаты гына катнашуын исәпкә алсаң, татарлар урыслардан күп булмагандыр дип уйларга нигез бар. (Мамай мирзаның союзниклары кенәз Олег белән кенәз Ягайло да яуда катнашмый кала. Хәер, ул хакта алда әле сүз булыр.)

18 августта Мәскәү кенәзе үзенең кенәзләре, воеводалары белән яуга чыгып китәр алдыннан фатиха алыр өчен Троице монастырена килә, анда телгә алынган монастырь башлыгы игумен Сергий Радонежский белән очраша. Чиркәүдә гыйбадәт кылганнан соң игумен Сергий аның төшке ашка калуын үтенә. Аш вакытында олуг кенәздән:

—Бу сугышны булдырмау өчен син барысын да эшләденме?—дип сорый.

—Барысын да эшләдем, тик уңышка ирешә алмадым,—дип җавап бирә олуг кенәз.

—Алайса дошман ахыр чиктә җиңелүгә дучар булачак, ә сиңа Ходайдан ярдәм киләчәк. Син җиңәчәксен!—ди.

Булачак дәһшәтле сугышның нәтиҗәсен шулай кистереп әйтү—үз өстенә коточкыч җаваплылык алу. Ләкин игумен Сергий андый җаваплылыкны үз өстенә алудан курыкмый. Гомумән, аны гадәти генә рухани булмаган, диләр. Аның биографиясендә алдан күрә белүче Илаһи Көчләр белән бәйләнештә торучы зат булганлыгын раслаучы фактлар аз түгел. Бу затны Куликово сугышының, Мамай мирза белән кенәз Дмитрийдан кала, өченче төп каһарманы дип әйтергә мөмкин, гәрчә ул үзе сугышта катнашмаса да. Шуңа күрә аның эшчәнлегенә бераз тукталып үтү бу очракта үзен аклар дип уйлыйм.

Малай чагында ук аның белән серле бер вакыйга була. Әтисе аны кырга атларны эзләп алып кайтырга чыгарып җибәргәч, малай анда юан имән төбендә утыручы бер карт монахны күрә дә янына килә. Карт та аны күреп алып:

—Балакай, сина ни кирәк?—дип сорый.

Малайның бу сораудан кинәт күңеле тула, ул үзенең мәктәптә бик начар укуын, күпме генә тырышса да, укуны алдыра алмавын, шуның аркасында ата-анасының да, укытучыларның да аны гел шелтәләп-тиргәп торуыннан зарлана, картның дога укып, үзенә ярдәм итүен сорый.

Карт нәрсәдер укый, малайга просфора (махсус пешерелгән түгәрәк ипи) каптыра да:

—Бу сина Ходайның рәхмәте билгесе. Изге Китапны аңлау өчен бирелә. Моннан соң, балакай, уку турында борчылма, Ходай сиңа ярдәм итәр,—дип башыннан сыйпый.

Шушы вакыйгадан соң малайның рухани дөньясында нindидер үзгәреш була, ул дини китапларга ябыша, гыйбадәткә тартыла башлаган дип язалар.

Бервакыт Стефан Пермский дигән дин әһеле чиркәү эшләре белән Мәскәүгә барган чакта, Троице монастырена дусты янына кереп чыгарга вакыты булмаганга, тугыз чакырым ераклыкта узган юлда атларын туктата да монастырь ягына карап басып: «Сәлам сиңа, рухани туганым!»—дип бил бөгеп сәлам бирә.

Бу мәлне Сергий Радонежский монастырь ашханәсендә монахлар белән тәгам җыеп утыра икән. Рухы белән дустының сәламен кабул итеп, ул аягына торып баса да, ашап утыручы монахларны гаҗәпкә калдырып, билен бөгеп үзе дә сәлам бирә. Аннан монахларга епископ Стефанның юлдан җибәргән сәламен алуын аңлатып бирә.

Әлбәттә, Сергий Радонежский тормышыннан мондый хәлләрне күп китереп булыр иде. Әмма укучыларның житмеш-сиксән елдан артык матдиятчелек (материализм) философиясе белән тәрбияләнеп, инде шактый авырая төшкән рухы аларны кабул итмәскә, скептик көлемсерәү рәвешендә йөзләрендә генә чагылырга мөмкин. Шуңа күрә могҗизаларның матди дөньяга якынрак торганнарын сайларга туры килә.

Шулай ук бу затның вафаты хакында да бер-ике сүз әйтү дөрес булыр, дип уйлыйм.

Фани дөнья белән саубуллашырга ярты ел калганда аңа бу хакта хәбәр килә. Карт монахларны үз янына җыя да шушы көннән монастырьны шәкерте Никодим кулына тапшыруы турында белдерә. Ә үзе аерым хөҗрәгә кереп бикләнеп, берәү белән дә аралашмый, соңгы айларын тулы тынлыкта уздыра. Тик вафаты көнендә генә янына җыелган руханиларга:

—Мине Ходай үзенә чакыра, Аның хозурына китәм. Ул сезгә сыену һәм дә дошмани ятьмәләрдән саклаучы нык дивар булсын,—дип фани дөньядан мәңгелеккә күчә.

Ул өзелгәндә хөҗрәдә тәмле ис таралды, дип язалар картның үлемен күргән шаһитлар.

Сергий Радонежский тормышына мул урын бирелүнең сәбәбе Куликово сугышы белән бәйле,—анысына соңрак тукталырбыз. Ә хәзергә вакыйгалар чылбырын сүтүне дәвам итик.

## V

**Олуг** кенәз Дмитрий башкаланы сакларга воевода Федор Андреевичны калдыра да үзе Коломна каласына юнәлә—анда кенәзне төрле яклардан җыелган гаскәр көтә. Монда Литва кенәзе Ольгердның уллары—Андрей белән Дмитрий полклары да олуг кенәзгә килеп кушылалар. Девичье поле дигән җирдә гаскәрне барлау үткәрелә.

Шулай әзерлек эшләре белән шөгыльләнгән чакта олуг кенәзгә Мамай мирзаның Дон аръягында торуын, анда Ягайлоның килеп кушылуын көтүен хәбәр итәләр. (Урысларның разведкасы әйбәт эшләгән, күрәсең.) Ул да бул-мый Коломнага Мамай мирзадан илче килеп төшә. Ул, элекке тәртипләрне олуг кенәзнең исенә төшереп, Үзбәк һәм Җанибәк ханнар заманындагыча ясак түләүне таләп итә. Кенәз Дмитрий, ясак түләүдән бөтенләй баш тартмаса да,

элекке күләмдә түләргә риза түгеллеген белдерә. Илче мона риза булмый, кайтып китә.

Сорау туа: илче ни өчен килгән? Ясак таләп итү өчен генәме, әллә инде урысларның хәлен-халәтен, каршы торырга исәпләре бармы-юкмы—шуны белергәме? Урыслар элекке тәртипләргә ризалашса, бәлки, Мамай мирза яу чапмаска да әзер булгандыр? Кыскасы, сөйләшү унай нәтиҗә бирми, мәсьәләне кылыч белән хәл итәргә кала.

Шул ук көннәрдә урысларга Рязань кенәзе Олегның, ике якка да ярарга тырышып, хыянәтчел уен алып баруы билгеле була.

Ниһаять, 20 август көнне урыс гаскәре Коломнадан чыгып китә, Мәскәү кенәзлеге җирләрен үтә, Ока елгасы буенда туктала. Монда гаскәргә олуг кенәзнең туганы Серпухов кенәзе Владимир Андреевич белән Мәскәү воеводасы Тимофей Вельяминович полклары да килеп кушыла. Шулай итеп, урыс гаскәре 26 августта тәмам тупланып бетә, иртәгесен яу, Ока елгасын кичеп, Рязань кенәзлегенә килеп керә. Бу хәл кенәз Олегны тәмам пошаманга сала, чөнки аның фаразы буенча, Мәскәү кенәзе татар явы турында ишетү белән качып китәргә тиеш иде. Кем уйлаган бит аны—әнә Мәскәүнең җыелма армиясе аның бусага төбендә үк тора. Аның татарлар һәм Ягайло белән элемтәгә кергәнен белә калсалар—бетте баш. Шундый уйлар белән вәсвәсәләнгән Рязань кенәзенең ул көннәрдә ниләр кичерүен күз алдына китерүе кыен түгел. Ул ачыктан-ачык Мамай мирзага да, олуг кенәз Дмитрийга да килеп кушыла алмыйча, анда-монда сугылырга мәҗбүр була. Кыскасы, кенәз Олег ике арада торып кала. Шуңа күрә Мамай мирзадан да, Мәскәү гаскәреннән дә ераграк йөрергә, күзләренә ташланмаска тырыша.

Урыс гаскәре 27 августтан 6 сентябрьгә кадәр Дон елгасына таба хәрәкәт итә, елга башына килеп җиткәч, яр буйлап юлын дәвам иттерә. Гаскәр юлда чакта урысларның разведкасы зур эш күрсәтә, дала буенча арлы-бирле чабып, татарларның кайда икәнлеген белергә тырыша. Тарихчылар фикеренчә, Лопасня тамагыннан сугыш булган Непрядвага хәтле ара 150 чакрымнар тирәсе икән. Шушы 150 чакрым араны урыслар 9-10 көн үтә. Димәк, тизлек көненә 15 чакрымнан артмаган. Алар ни өчен шулай акрын барган? Әлбәттә, бу акрынлык, беренче чиратта, татардан курку көчле булуга бәйле. Урыслар бит татар җиренә, Кыпчак даласына аяк басты, ят җирдән атлыйлар, шуңа күрә зур саклык белән хәрәкәтләнергә туры килә. Җитез татар гаскәре, көтмәгән яктан килеп чыгып, өстенә ташланырга да күп сорамас. Аннан соң бу вакытта аларга Мамай мирза урдасының кайларда икәнлеге төгәен генә билгеле дә булмый. «Дон арьягында» дигән хәбәр дә эшне җиңеләйтми. Шуңа күрә барган чакта, төрле якка кечкенә отрядлар җибәреп даими рәвештә разведка чаралары күрергә туры килә. Бер үк вакытта үзләренең килүен дә яшерергә тырышалар. Зур гаскәрне дошманга сиздермичә алып бару җиңел эш түгел. Шунлыктан барлык чаралар да күрелә. Ни өчен дигәндә, дошманның борын төбендә кинәт калкып чыгу—җиңүнең яртысына тиң.

Бу вакытта Мамай мирза исә тыныч кына Ягайлоны көтә, ул урысларның, курка-курка гына булса да, татар җиренә аяк басуын, йоланы бозып, һөҗүм итү ихтималын башына да китерми.

Ниһаять, 6 сентябрь көнне урыс гаскәре Дон ярына килеп туктый. Елга буенда татарларның сакчы отряды булган, ахры, чөнки Мамай мирзага урыс гаскәренең кинәт Дон ярында калкып чыгуын шул көнне яраланган сугышчылар килеп әйтә.

Дөресен әйткәндә, бу Мамай мирза өчен һич көтелмәгән хәл була. Айлар буе урыска каршы яу әзерлә, төрле сөйләшүләр алып бар да, инде гаскәр туплана башлаганда гына борын төбендә дошман калкып чыксын әле! Әлбәттә, бу хәл аның җен ачуларын чыгаргандыр, ул, каударланып, сугышка әзерләнә башлагандыр. Тик шунысы бар—бу вакытта урыслар да тик тормый, хәлиткеч бәрелешкә әзерләнә.

Алар 6 сентябрьдә, татар сакчы отряды белән очрашканнан соң, көне буе Мамай мирзаны көтәләр, ул күренми. Иртәгесен дә тулы әзерлек белән Дон ярында торалар, татарлар һөҗүмгә ташланыр дип көтәләр. Яр буенда җыелган

кенәзләр, воеводалар уйга кала—дошман әлегә һөҗүм итәргә җыенмый. Елганы кичәргәме, юкмы? Фикерләр икегә бүленә: берәүләр язмышны сынамаска, татарларны бу ярда гына каршы алырга кирәк дисә, икенчеләре Донны кичеп теге якта сугышуны кулай күрәләр. Каршы якка чыгып орышкан очракта беркем дә татардан куркып чигенә дә, кача да алмаячак, диләр. Бу фикерне кенәз Ольгердның уллары әйтә.

Биредә бер психологик моментны да исәпкә алу кирәктер. Яр буенда кичү-кичмәү хакында бәхәс барган чакта олуг кенәз Дмитрийга Сергий Радонежскийдан атчабар килеп төшә дә грамота тапшыра. Анда татарга каршы яуга рухландыручы гомуми сүзләрдән тыш конкрет киңәш тә була: вакытны сузмыйча үзенә һөҗүм итү кирәк диелә. Бу очракта абруйлы затның сүзе кенәзгә тәэсир итми калмагандыр. Игумен Сергий Дон буенда шундый хәл килеп туасын кайдан белгән дә, алдан грамота яздырып, нәкъ тиешле вакытында олуг кенәз кулына ничек китереп тоттырган? Гаскәр яуга чыгып киткәч Игумен Сергий көнен-төнен гыйбадәт өстендә үткәргән, дип язалар. Аның рухы күп нәрсәне алдан белеп торган булса кирәк. (Гаскәрне яуга озатканда, үз-үзенә бик ышанып, башкаларны да ышандырырлык итеп, «җиңәчәксез!» дип әйтүен генә искә төшерик.) Бүгенге көндә Галәм (Илаһи Көчләр) белән элемтәдә торучы арадашчы-контактерлар гадәти күренешкә әверелеп бара, алар аша төрле прогнозлар алу мөмкинлеге ачылды. Минемчә, Сергий Радонежский да шундый затлардан булган. Ул барысын да алдан белеп торган. Башкача моны аңлатып булмый.

Инде арадашчылык турында сүз чыккан икән, бераз алга йөгереп булса да, фикеремне ныгытырлык тагын бер дәлил китереп узыйм. Сергий Радонежскийның биографиясендә шундый факт та бар. Һәм ул Куликово сугышына карый. Бәрелеш вакытында ул Троице монастырендәге монахларга орышның ничек баруын, кайсы кенәзнең, кайсы воеводаның һәлак булуын әйтеп торган. Бу сыйфат үзе үк аның гади заттан булмавы турында сөйли. Андый кешеләрне хәзер психик күрү сәләте ачылган затлар (ясновидящий) дип йөртәләр.

7 сентябрь көнне дә татарлар һөҗүм итмәгәч, кичке 5 белән 6 сәгатьләр арасында урыс гаскәре Донны кичә башлый. Таң атканда кичү тәмам була. Әлбәттә, зур гаскәрнең елганы кичүен каршы як белеп торган, башкача мөмкин түгел. Тик Мамай мирза сүлпәнлек күрсәтә, кичү вакытында дошманга һөҗүм итми. Юкса, иң җайлы чак бит. Бәлки, ул аларның бу якка чыгуыннан үзенчә файдаланмакчы булгандыр? Орыш башлангач, дошманга чигенергә җай калмаячак, шул чак ярга китереп кысып, берьюлы эшне бетерергә уйлагандыр? Әллә инде урысларның кинәт килеп чыгуы аны каушатып җибәргәнме? Гаскәре тулыланып җитмәгән, таркау хәлдә булганмы?

Сораулар күп һәм аларга беркем дә җавап биреп бетерә алмаячак, бары тик фараз кылырга гына кала. Тик шунысы ачык—Мамай мирза, үз-үзенә артык ышанып, урысның көчен, мәкер белән дә эш итә белүен бәяләп житкермәгән, саксызлык күрсәткән булса кирәк.

Бу вакытта урыс гаскәре исә, елганы алдан кичеп, Куликово кырында үзенә җайлы урын-позиция сайлап алырга өлгерә.

## VI

**1380 нче** елның 8 сентябрь таңы бик авыр ата. Җир йөзен каплап алган иртәнге томан озак таралмый тора. Томан таралгач та, гүя бу көн яланда бүген зур кырылыш булачагын, йөзләрчә мең адәмнәрнең каны коелачагын сизенгәндәй, кояш җиһанга кызгылт йөзен ачарга ашыкмый. Ниһаять, томан таралып бетә, шул чакта гына яланның капма-каршы ягында тезелешкән ике яу бер-берсен күреп ала, акрынлап якыная башлый.

Бәрелеш алдыннан, һәр яктан берәр батырны алга чыгарып, аларны орыштыру гадәте бик борынгыдан килә. Куликово кырында да шундый хәл булган, диләр. Урыслар ягыннан монах Александр-Пересвет, ә татар ягыннан Чәләби баһадир дигән бер зат ике гаскәр арасында калган ачык җирдә көч сынашканнар, имеш. Бу хәл чыннан да булган, ахрысы, чөнки батырларның берсе—инок Александр тарихта билгеле шәхес. Чыгышы белән Брянск бояры

булып, ул дин юлына басканчы Пересвет исемен йөрткән. Урыс гаскәре яуга җыенганда Сергий Радонежский аны, оста һәм көчле сугышчы булганы өчен, олуг кенәз Дмитрийга ярдәмче итеп җибәрә.

Ә татар баһадиры Чәләби турында башка мәгълүматлар сакланмаган. Шундый зур эшкә алынгач, ул да татарның атаклы баһадиры булгандыр, дип уйларга кирәк.

Орыштта аларның икесе дә һәлак була.

Дәһшәтле сугыш сәгать унберенче яртыда гына башлана.

Урыс тарихчылары Куликово сугышы турында язганда, тарихта мондый сугышлар аз булган дип, аның әһәмиятен күпертергә яраталар. Гадәттә, аны Искәндәр Зөлкарнәйн яулары, Каталаун кырында мәшһүр Атилла белән римлы Аэций арасындагы «халыклар орышы» яисә гарәпләр белән франкларның тарихи бәрелеше белән чагыштырып, искә төшерәләр. Алай ерак йөргәнче ник берсе Аксак Тимер белән Туктамыш хан арасында булган Кондырча (1391) сугышын телгә алсын. Ә бит анда бер Аксак Тимер ягыннан гына да 200 мең кеше катнаша, шәрекъ тарихчылары язганча, «40 фәрсах җир мәет белән тула». Кем әйтмешли, үзеннеке—үзәктә шул. Әмма гаделлек өчен әйтергә кирәк: урысларның әле бу кадәр гаскәр җыя алганы да, мондый бәрелештә катнашканы да булмый.

Тарихчылар шулай ук Куликово сугышы башлангач, татар атлы гаскәренең урыс сафларына бик нык китереп сугуын язалар, шулай итеп, бәрелеш татарлар өстенлеге белән башлана, печән чапкандай кеше кырыла, аяк астына түшәлә бара. Кан исеннән, кысанлыктан, тимер чыңлаудан, акыру-бакыру тавышларыннан ярсыган атлар туктаусыз пошкыра, түзеп тора алмыйча арт аякларына күтәрелә.

Орыш башында тәмам буталып беткән татар белән урыс гаскәре берәр сәгать узуга акрынлап аңга килә башлый, яу кырында ниндидер тәртип, акыл белән эш итүгә охшаш сыйфат өстенлек ала. Аннан татарлар, зур тырышлык һәм гайрәт күрсәтеп, олуг кенәз Дмитрийның кара байрагына таба юл ярырга керешәләр. Бу хәлне күреп, Мәскәү полкының яшь сугышчылары качарга ук тотына. Бары үзен аямыйча орышкан кенәз дружинасы гына төп байракны татарлар кулына төшүдән саклап кала.

Бу вакыт калкулык өстендә яу кырын күзәткән Мамай мирза, борчылып, урыс гаскәре пәйда булганнан соң озаткан атчабарларының әйләнеп кайтукайтмавын белешеп торгандыр. Ул урыс гаскәре күренү белән кенәз Олегны ашыгычлык белән үзенә чакырткандыр. Шулай ук Ягойлага да кеше җибәргәндер. Тик аның белән ара ерак, килеп житә алмаслар. Кенәз Олег исә күптән бирегә булырга тиеш иде. Һаман күренми. Алдарга микәнни исәбе? Итек очын яларга житешеп вәгъдәләр бирүенә карамастан хыянәт итүеме бу? Кайдадыр качып ята булыр. Соңыннан ниләр сөйләр, ни дип акланыр икән?.. Сугыш барганда Мамай мирза менә шулай фикер йөрткән булса кирәк.

Әйе, Мамай мирзага сугышны уңайсызрак шартларда башларга туры килде. Урыслар ничектер һич көтмәгәндә, жир астыннан үсеп чыккандай, пәйда булды. Житмәсә ул хәстәрен күреп өлгергәнче Дон суын да кичеп чыктылар—сафларын жайлы урынга төзеделәр.

Ике сәгатьләп узгач, сугышның иң җаваплы чагы—хәлиткеч вакыты якынлаша. Инде һәр як ифрат күп яугирләрен югалткан, арый-талчыга башлаган. Шулай үлчәү тигезләнә. Инде кайсы якның, гайрәт туплап, тагын бер талпынырга көче житсә—шул өстен чыгачак, җиңәчәк.

Әйе, һәр житди бәрелештә була андый мизгел—үлчәү тигезләнә дә әле бер, әле икенче якка авыша алмыйча беравыкка катып кала. Иң хәтәр чак. Үз гомерендә күп сугышлар күргән Мамай мирзаның бөтен жаны-тәне бу мизгел якынлашканны сизеп тора. Һай, аз гына ярдәм булсачы, берәрсе килеп житсәче дип өметләнә ул. Татарларга ярдәмгә килүченең орышка керүе дә кирәк түгел, якынлашып килүләре дә житә калыр иде. Шулай дошманның йөрәгенә куркушом иңәр, жанына качу уе кереп урнашыр иде. Әмма юк, Мамай мирзаның аркадашлары күренмәде... Хәерлегә була күрсен...

Бу вакыт кенәз Олег, чыннан да, качып ята. Ул ни татарларга, ни Мәскәү кенәзенә ярдәм кулы сузмый. Хәер, аның үз хәле хәл инде. Кайсы

якка басса да «вай!». Чөнки икенең берсенә барыбер кан дошман булып калачак. Шуңа күрә ул бу бәрелештән читтә калуны кулайрак күрә. Башта сугыш тәкәнсен, җиңүче ачыклансын, анда күз күрер, дип фикер йөртә. Моңа хәтле дә, килеп туган вәзгыятькә карап, ул антын тиз боза килде. Бу юлы да үз табигатенә тугры калды. Ярар, Ходай ярдәменнән ташламас әле...

Күп сугышларда дошманга кинәт һөҗүм итү яисә берәр көтелмәгән алым-ысул куллануның җиңүгә китерүе чал тарих сәхифәләрендә теркәлеп калган. Бу очракта да урыслар, Мамай мирза өчен шундый бер «көчтәнәч» әзерләп куялар, саклык чарасы күрәләр. Гаскәрнең сул флангында урнашкан имәнлек артына олуг кенәзнең туганы кенәз Владимир Андреевич Серпуховский белән Мәскәү воеводасы Дмитрий Волынский-Боброкларның атлы гаскәре яшерелә. Урысларда андый алай «засадный полк» дип аталган. Татарда исә ул «постырма» дип йөртелгән, ягъни яшереп-постырып куелган гаскәр. Гомумән, бу алым урысларга күп тапкыр төркиләр белән аралашу аркасында күчкән, Алтын Урда дәверендә урыс аны инде тәмам үзләштереп өлгергән, бәлки әле «үзенеке» дип тә уйлый башлагандыр. Әлбәттә, Мамай мирза да үз гомерендә аны аз кулланмагандыр, тик бу юлы урысларның Дон буена кинәт килеп чыгуы аны кыен хәлгә куя, мирзага сугышыр өчен җайсыз урын туры килә.

Шулай дәһшәтле сугыш өченче сәгатенә киткәндә урысларның постырмада торган полкына да чират җитә. Ул, имәнлек артыннан атылып чыгып, кинәт татарлар өстенә ташлана. Бу һөҗүм шул кадәр көтелмәгәндә була, Мамай мирза сугышчылары ни уйларга да белмичә аптырап кала. Шул вакыт ялланган Кырым җәнүизләре, Кавказ яһүдиләре белән әрмәннәр гомумән качарга тотына. Андый чакта бер зур төркемнең түгел, бер-ике бәндәнең кача башлавы да нык тәэсир итә. Ә монда... гаскәрнең бер зур өлеше табан ялтырата. Табигый, бу хәл күпләрнең йөрәгенә шом сала, паника башлана. Дөрес, Мамай мирза баһадирлары качучыларны кире борырга тырышып карыйлар, тик бер кузгалгач, кая ул.

Гаскәрнең бирешә башлавын күрү Мамай мирзаны бер утка, бер суга салып, җаны ничек өзгәләнгәнен күз алдына китерүе кыен түгел. Аның гомерендә бу минутлар иң авырлардан булгандыр. Шул вакытта язмышы хәл ителгәнне аңлады микән ул? Гомере буе тәхеткә ханнар утырту-төшерү уены уйнаган горур мирза моны аңлар хәлдә булды микән? Хакимият адәмнәрне боза, ә озак еллар хакимлек итү икеләтә боза. Кеше үз-үзенә тәнкыйть күзе белән карау сәләтен югалта, аның урынына мин-минлек, тәкәбберлек, кеше фикерен санга сукмау кебек сыйфатлар җаннын саф авазын басып китә.

Ничек кенә авыр булмасын, Мамай мирзаның үзенә дә, янәшәсендә торган бәкләргә дә кача башлаган гаскәр артыннан иярергә туры килә. Гадәттә, урыс тарихчылары урыс гаскәренең татарларны куа баруын, турый-чаба озак әзәрлекләвен тәмләп язарга яраталар. Тик моңа ышануы кыен, чөнки бу сугышта урыслар да артык күп көч югалта, бик нык хәлсезләнә. Киресенчә, орыш тәмамланганга сөенгән булырга тиешләр. Шулай да татарларның олаулары, азык-төлек, сугыш кирәк-ярагы төялгән арбалар дошман кулына төшкәндер. Анысын инкяр итүе кыен.

Канкойгыч орыш тәмамлану белән олуг кенәзнең туганы кенәз Владимир Андреевич Серпуховский, елъязмаларда язылганча, «өелгән сөякләр өстенә менеп басып» («встал на костях») яу кырында боргылар кычкырттыра. Бу тавышны ишеткәч, төрле тарафка таралышкан сугышчылар олуг кенәзнең кара байрагы тирәсенә җыела башлыйлар. (Бу факт үзе үк урыс тарихчыларының уйдырмасын фаш итә: алар Мамай мирза гаскәрен күп чакрымнар әзәрлекләгән булса, орыш тукталу белән үк боргы тавышына җыела алырлар иде микән?) Шул вакыт бер сәер хәл ачыклана—олуг кенәз Дмитрий Ивановичның кайда икәнлеген берәү дә белми *(Н. М. Карамзин. История государства Российского.—Т. 5—Ж. «Москва».—1988.—№ 10.—С. 123)*. Кенәзләр белән воеводалар тәмам хафага төшә, тирә-юньгә таралышып, мәетләр арасыннан олуг кенәзне эзләргә керешәләр. (Гаскәр башын—олуг кенәзне дә югалтырлык булгач, урысларның хәле гаять мөшкел булган, дип уйларга кала. Димәк, урыслар соңгы чиккә җиткән булган.)

Кенәз Владимир Андреевич олуг кенәзне эзләп табучыга зур бүләкләр вәгъдә итә. Бераздан мәетләр арасыннан аның байрак йөртүчесен табып алалар.

Ниһаять, читкәрәк китеп эзләүче ике сугышчы ауган агач ботаклары арасында яткан берәүне күреп алып сөйрәп чыгаралар—ул олуг кенәз Дмитрий Иванович үзе булып чыга. Аның җуйган, тын алуы да зәгыйфь.

Барысы да аның янына җыела. Берәздан ул аңына килә, күзләрен ача, эчәргә су сорый. Шуннан соң гына кенәз Владимир Андреевич, аның каршына тезләнеп: «Олуг кенәз! Син дошманыңны җиңдең!» дип әйтергә җөрьәт итә. Шуна кадәр әле берәү дә җиңү турында авыз ачарга батырчылык итми. Ни өчен дигәндә, бу сугышта, урыс тарихчылары күрсәткән 150 мең гаскәрнең бары тик 40 мене генә исән кала. Югалтулар шулкадәр зур була ки, урыслар башта хәтта үзләренең өстен чыгуын да аңлап җиткермиләр.

Урыс тарихчылары олуг кенәз Дмитрий Иванович турында: ул бер генә яра да алмаган, башындагы шлемы, тимер киемнәре генә дошман белән орышудан яньчелеп беткән булган, дип язалар. Яра алмавы да, ауган агач ботаклары арасыннан табылуы да бигүк аңлашылып бетми бетүен. Дөресрәге, күп сораулар тудыра...

Бу вакыйганы җентекләп өйрәнгәндә тагын бер нәрсә игътибарны җәлеп итә—агач астыннан табып алганда сулар суламас яткан олуг кенәз, җиңүен ишетеп алу белән ничектер бик тиз аякка баса, тәмам савыгып китә дә яраннары белән яу кырын карап йөри, кенәзләргә, воеводаларга, баяр улларына рәхмәтләр әйтеп, барчасына да зур-зур бүләкләр вәгъдә итә.

Күренекле урыс тарихчысы С. М. Соловьев Куликово сугышы нәтиҗәләре хакында менә нинди фикер әйтә: «... Куликовская победа была из числа тех побед, которые близко граничат с тяжким поражением. Когда, говорит предание, великий князь велел счесть, сколько осталось в живых после битвы, то боярин Михайло Александрович донес ему, что осталось всего 40 тысяч человек, тогда как битву вступило больше 400 тысяч...» Шушы сүзләрдән соң тарихчы китерелгән санга үзенең мөнәсәбәтен дә әйтеп үтә: «Если история и не имеет обязанности принимать буквально последнего показания, то для него важно выставленное здесь отношение живых к убитым»,—ди ул.

Әйткәнебезчә, бүгенге тарих фәнендә урыс гаскәренең гомуми саны 150 мең булып, шуның 40 меңе генә исән калган дигән фикер кабул ителгән. Шушы «150 мең» дөрес булган очракта да урысларның югалтуы 110 мең кешегә тиң. Бу саннар Куликово кырындагы җиңүнең урыслар өчен чын җиңү булмыйча, аның бары тик мораль факторга гына кайтып калуын бик ачык күрсәтәләр.

Куликово кырында урыс гаскәре 4 кенәзен, 13 баярын югалта. Шуна күрә бу сугыш урыс риваятьләрендә, бер яктан бөек җиңү дип сурәтләнсә, икенче яктан, олуг кайгы һәм фаҗига буларак телгә алына. «Оскудела совершенно вся земля Русская воеводами, и слугами, и всяким воинством и от этого был страх большой по всей земле Русской»,—дип яза шул ук С. М. Соловьев.

Литва кенәзе Ягайлоның ни өчен вакытында Мамай мирзага ярдәмгә килеп җитә алмавы тарихчылар арасында бәхәс уята. Бу аңлашыла да, чөнки бик мөһим мәсьәлә. «Летописьная повесть» дип аталган чыганакта Ягайлоның, яуга кузгалып та, акрын хәрәкәт итүе аркасында ярдәмгә килеп өлгерә алмавы һәм, Мамай мирзаның Куликово кырында җинелү хәбәрен ишеткәч, куркып калып кире борылуы әйтелә. «Сказание о Мамаевом побоище» әсәрендә исә кенәз Ягайлоның сугыш башлаган чакта Одоев каласы янында көтеп торуы (сугыш кырыннан ике-өч көнлек юл арасы) хәбәр ителә.

Әйтергә кирәк, тарих фәнендә бу мәсьәләгә багышланган гаять бай әдәбият бар. Шулар арасында тарихчы В. А. Кучкинның фикере аерым игътибарга лаек дисәк, һич арттыру булмастыр *(Знание сила.—1980.—№ 9.—С. 23)*. Ул нииндидер Епифаний исемле инок тарафыннан гыйбадәт кылу өчен язылган ярдәмлек битләренә теркәлгән бер язуга игътибар иткән. 1380 елның 21 сентябренә караган бу язуның эчтәлеге болай: «Весть прииде, яко Литва грядут с Агаряны» (татарчасы: «Хәбәр алынды, гуя Литва белән Агаряннар килә имеш»).

Бу хәбәрдәге «агаряннар»ның Алтын Урда мөселманнары икәне шик уятмый, бу билгеле нәрсә. Ә менә 8 сентябрь көнне генә булып узган

дәһшәтле Куликово сугышыннан соң «җиңелгән» Мамай мирзаның, Литва белән берләшеп, кабат Мәскәүгә каршы кылыч тартырга җыенуы шактый сәер хәл. Тик беренче карашка гына. Димәк, без Мамай мирза тарихын житәрлек дәрәҗәдә белмибез булып чыга. Димәк, ул Куликово кырында «җиңелгәннән» соң да шул ук сентябрь аенда яңа гаскәр тупларга өлгергән һәм Мәскәүгә яуга җыенган. Һәм шул хәбәр көне-сәгате белән урысларга килеп тә җиткән.

Бу очракта инок Епифаний хәбәренә ышанырга мөмкиндер дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, Сергий Радонежскийның биографиясен өйрәнгәндә миңа әлеге инокның кем булуы тәмам ачылды. Епифаний изге атакайның бик яраткан, якын иткән бер шәкерте булган икән. Ул соңрак, остазы вафат булгач, аның тормыш юлын тасвирлап китап та яза—атаклы каләм остасы да булып китә. Күрәсең, бу хәбәр Сергий Радджонежский даирәсендә билгеле булган һәм Епифаний аны гыйбадәтнамә битенә теркәп куйган.

Тарихчы В. А. Кучкин «Сказание о Мамаевом побоище» әсәрендәге бер урынга да игътибар итә: анда Мамай мирза белән кенәз Ягайлоның Мәскәүгә каршы яуны көз җиткәч башларга ниятләүләре турында ап-ачык итеп әйтелә. Ә борынгы урыс календаре буенча көз бары тик 24 сентябрьдән генә башлана торган булган. Кабат искә төшерик: инок Епифанийның язмасы 21 сентябрьдә теркәлгән. Моннан нәрсә килеп чыга соң? Димәк, Мамай мирза Мәскәүгә яуны 24 сентябрьләр узгач башларга тиеш булган, шул хакта кенәз Ягайло белән алдан сөйләшеп куйган. Шуңа күрә, әлегә актив хәрәкәтләргә күчмичә, Дон аръягында тыныч кына кенәз Ягайлоның килеп кушылуын көтеп яткан. Ләкин урысларның көтмәгәндә аның өстенә килеп чыгуы мирзаның бөтен планнарын чуалтып җибәргән. Менә кайдан килә аның сүлпәнлек, пассивлык күрсәтүе! Аның гаскәре тупланып җитмәгән булган. Ә Ягайло бу вакытта берни белмичә татарлар белән яуга бару өчен гаскәрен җыя гына башлаган булса кирәк.

Епифанийның язуы шул хакта сөйли.

Тарихчылар күрсәтүенчә, кенәз Ягайло яуга 21 сентябрьдә генә кузгала. Бу нәрсә турында сөйли: димәк, 8 сентябрьдә ул Куликово сугышында катнашырга уйламаган да, гомумән, ул хакта соңыннан гына белгән. Ә Мамай мирза исә Куликово сугышыннан соң тиз арада кабат гаскәр туплап өлгергән, урысларның яу кырында коточкыч күп кеше югалтуын аңлаган хәлдә, Мәскәүгә яңа яу белән барырга җыенган. Әлбәттә инде, Мамай мирзаның кенәз Ягайлога кеше җибәреп: «Көчем җитәрлек, килешү үз көчендә кала, тиешле вакытка килеп җит!»—дип кабат яуга җыенуын хәбәр итәргә генә акылы җиткәндер. Менә ни өчен кенәз Ягайло 21 сентябрьдә Мамай мирза белән очрашу өчен яуга кузгалган. Чыннан да, аның Одоев каласына килеп җитү, анда Куликово кыры трофейларын урыслар кулыннан тартып алуы билгеле.

Ә менә Мамай мирза белән очрашырга аңа Ходай насыйп итми. Алар бергәләшеп Мәскәү өстенә килә алмый калалар. Нәкъ шушы көннәрдә Алтын Урданың сул канатында үз хакимиятен урнаштырган Туктамыш хан, Иделне кичеп, Мамай мирзага каршы чыга. (Куликово сугышы хәбәре моңа этәргеч биргәндер, күрәсең. Һөҗүм итәргә иң җайлы чак ич!) Шулай итеп, Мамай мирза өчен Мәскәү мәсьәләсе үзеннән-үзе икенче планга күчә, вакытлыча көн тәртибеннән төшеп кала. Гайярь мирза тупланган гаскәре белән Туктамыш ханга, асылда Алтын Урданың законлы ханына каршы кабат көрәш башлап җибәрергә мәҗбүр була. Ә Литва кенәзе Ягайло, үзара сугышкан ике татар арасына килеп кысылырга теләмичә, кире борыла. Кайтып барышлый урысларны талап, үз биләмәләренә юнәлә.

Ул көннәрдә вакыйгалар чылбыры менә шундыйрак төс алган дип уйларга нигез бар.

## VII

**Әлбәттә**, Куликово сугышы Алтын Урда тарихына караганда, урыс тарихы өчен әһәмиятлерәк вакыйга. Бу бәрелешне татар дәүләтенең зур фаҗигасе дип уйларга һич тә ярамый. Ни өчен дигәндә, әлеге бәрелештә рәсми хөкүмәткә

(Сарай хөкүмәте) карата оппозициядә торган бер як кына катнаша һәм уңышсызлыкка дучар була. Бу очракта, урыс тарихчылары язганча, Куликово кыры вакыйгаларының «дөньякүләм тарихи әһәмияте» хакында сүз алып бару, ким дигәндә, дөреслеккә хилафлык китерү булыр иде. Шул ук вакытта Мамай мирзаның уңышсыз явы Алтын Урда дәүләтендә хәлләрнең кирегә тәгәри башлавын күрсәтүче хәтәр симптом да ул.

Бу чир симптомы нилектән барлыкка килгән соң? Ни өчен татар мәмләкәтенең эшләре артка китә башлый? Нинди сәбәпләр аркасында вакыйгалар шундый юнәлеш ала?

Билгеле ки, дөньяда һәр нәрсә мәгълүм закончалык-кануннарга буйсынып яши. Ул туа, үсә, хәрәкәт итә, ныгый, картая һәм үлә. Бу кануннар бөтен җиһан өчен уртак, алардан кечкенә бер бөҗәк тә, адәм баласы да, җәмгыять тә, гомумән, кешелек дөньясы да, күк җисемнәре дә азат була алмый. Бар нәрсә дә Галәмнең кырыс һәм гадел кануннарына буйсына. Шулай ук аерым дәүләт-мәмләкәтләр дә бу кануннардан азат түгелләр.

Бар нәрсәне үзенә колачлаган ул нинди канун икән соң? Эволюция, эволюция кануны ул! Җиһанда, дөньяда бары тик эволюция кануныңа каршы бармаган нәрсә генә яши, тереклек итә ала. Каршы килде исә—бетә, акрынлапмы, зур тизлек беләнме—һәлакәткә бара.

Әйткәнебезчә, Алтын Урда дәүләтенең иң бөек чагы Үзбәк хан заманына туры килә. Бу елларда аның шәһәрләре мәшһүр мәдәният һәм сәүдә үзәкләренә әверелә, кәрван юлларында гаҗәеп иминлек, сәүдә әһелләре Кытайдан Кара диңгезгә кадәр бернинди кыенлыклар, хәвеф-хәтәр кичермичә туктаусыз йөреп тора. Италия сәүдәгәрләреннән калган документларда Алтын Урда җирләрендә кәрван саклау өчен отрядның кирәк булмавы, юлда киптерелгән балыктан, тоздан башка азык-төлекне бик арзан бәягә сатып алырга мөмкин икәне кисәтеп әйтелә. Тәхеткә Бирдебәк хан чыккач үтерешләр китә, тәртип бозыла. Аның үзен дә тиздән юк итәләр. Тәхет бүлергә керешәләр. Һәлакәт менә шуннан килә. Көйгә салынган тормыш җимерелүгә йөз тота, сәүдә дә аксый, чөнки юл йөрүләре хәтәр бер нәрсәгә әверелә. Ә бит Алтын Урданың икътисади нигезен сәүдә тәшкил иткән. Тәхет даулары аркасында Үзәк хөкүмәтнең хәлсезләнә баруын күреп, дәүләтнең олыслары аерылып чыга башлый, мөстәкыйль яшәргә керешә. Бу да мәмләкәтнең куәтен ала.

Әлбәттә, бу хәлләр берсе дә үсешкә, эволюциягә ярдәм итмәгән, шуңа күрә мәмләкәтнең язмышы инкыйразга таба борылган.

Дәүләтләр тарихын, үткән юлын җәядән ук ату белән чагыштырып булыр иде сыман. Әйтик, ук тартылганда җәянең киерелүен ыру-кабиләләрнең бер мәмләкәткә җыелуы—укмашуы дип күз алдына китерик. Шулай җәядә зур көч, киеренкелек барлыкка килә. Бу инде дәүләтнең оешып җитүен, андагы халыкларның үзара якынаюын күрсәтә, халык уртак идеал-максатны аңлар дәрәҗәгә күтәрелә. Бу этапта тупланган көч-куәт инде мәмләкәт кысаларына гына сыеша алмый башлый, тышка омтыла (ук очып китә), чит илләрне, халыкларны яулау-буйсындыру, яшәү мәйданын киңәйтү башлана.

1255 елда Алтын Урдада Бату хан вафат була. Бу вакытта дәүләттә яулар инде күптән тәмамланып, калыплашкан тыныч тормыш урнашып өлгерә. Шул сәбәпле Батудан соң тәхеткә чыккан ханнар заманында күп калалар калкып чыга, борыннан калганнары чәчәк ату чорын кичерә. Кабат ук-җәя белән чагыштыруга әйләнеп кайтсак, бу инде атылган укның инерция белән очкан чагы булыр иде. Әмма ук та мәңге оча алмый, күпмедер вакыт үткәч арый, талчыга башлый. Аңа үз авырлыгын, җирнең тарту көчен, һава каршылыгын җиңү торган саен кыенлаша бара. Шулай ук башын җиргә бора, көчен югалта.

Бату ханнан соң бер гасыр вакыт үткәч, 1357 елда Җанибәк хан да вафат була. Бу вакытта дәүләтнең күге әле аяз (ук әле барча каршылыкларны җиңеп алга оча), мәмләкәт канаты астында яшәүче бер кавем дә чыңгызыйлар урнаштырган тәртипләр кайчан да булса бетәр дип башына да китерә алмый. Тормыш мәңге шулай дәвам итәр төсле тоела. Ләкин давыл алдыннан күзәтелә торган тынлык кына булган икән.

Тагын өч елдан (1360) хәлләр кинәт үзгәрә, аерма җир белән күк арасы

кебек. Кая китте ул иминлек, көйле тормыш, тыныч кына сәүдә итүләр. Сарай шәһәре—кырмыска оясын хәтерләтә. Әллә ничә фирка үсеп чыга, һәркайсы үз кешесен тәхеткә чыгармакчы. Шул сәбәпле низаглар, мәкер, үтерешләр башлана. Дәүләт язмышын кайгыртучы, аның киләчәген уйлаучы, абруен сакларга омтылучы адәмнәр кайда? Үз мәнфәгатьләреннән өстен торган ватанпәрвәр шәхес кайда? Дәүләтнең төп максатын билгеләүче, ил язмышын уйлап эш итүче олуг затлар кайда?

Ни кызганыч, 20 елга сузылган болганыш дәверендә без андый шәхесне күрмибез. Шушы елларда ачыла да инде Алтын Урданың нинди дәүләт икәнлеге! Үткән бер гасыр вакыт эчендә бу мәмләкәт олуг максатлар эзләп табып, аларны үз алдына куя белмәгән икән ләбаса. Бер гасыр эчендә Алтын Урдада сәяси фикер чарланып өлгермәгән, аның тирәнтен уйланган үз идеологиясе эшләнмәгән.

Әйе, мәмләкәт яңа җирдә, яңа шартларда барлыкка килә, аның канат астында күп төрле менталитетка ия халыклар яши. Империя көч ярдәмендә, механик рәвештә төзелә, тик соңыннан аның нигезен ныгыту, халыкларны берләштерүче уртак идея эзләү турында уйлаучы табылмый. Аның каравы ерак далалардан ияреп килгән патриархаль тәртипләр, борынгы дала йоласы чәчәк ата. Дәүләтнең бөтен гайрәте тәхеттә утырган ханнарның шәхси сыйфатлары, зирәклеге, каты куллы була белүенә бәйле икән бит. Тарих күрсәткәнчә, ханнар вагая башлау белән аларның кулыннан дилбегә китә һәм бөек максатлары, төпле идеологиясе булмаган мәмләкәт таркалуга таба борыла.

Ә күршедә, күршедә (Сарай кул астында бит әле!) максатлары ап-ачык, дин әһелләре ярдәмендә үз идеологиясен булдырган, даими рәвештә аны халыкка сеңдереп торган Мәскәү күтәрелә. Ул үзенә ни кирәген бик әйбәт белә, башта астыртын, ә инде бераз көч туплый төшкәч, ачыктан-ачык Сарайга каршы эш алып бара. Ул һәр мөмкинлектән файдалана, кирәксә, ялагайлана, Сарай ханнарына-түрәләренә бүләкләр ташый, ара-тирә үз кенәзләрен дә саткалый, хәтта татар белән бергә аларга каршы яу чаба. Әмма ни генә булмасын, ин астыртын уен—татарны хәлсезләндерү, аның кул астыннан ирекка чыгуны һәр очракта да үзенең төп максаты итеп күрә белә. Икенче төрле әйткәндә, урыс кенәзләре, руханилары шәхси мәнфәгатьләр белән генә чикләнмичә, гомуми максатны онытмыйлар. Аны өстен куя беләләр. Әлбәттә, бу омтылышның үзәгендә Мәскәү тора, барысын да ул рухландыра.

Ни әйтсәң дә, урысларның татар даласының эченә үк үтеп кереп, Куликово сугышында инициативаны үз кулларына алуы, ифрат зур югалтулар белән булса да, өстен чыгуы—шушы максатчан сәясәтнең бер мисалы. Ә татар бу вакыйгайдан тиешле нәтиҗә чыгарганмы?

Тагын ике елдан (1382) Алтын Урдада хакимиятне үз кулына алган Туктамыш хан Мәскәүне камый, берничә көннән татарлар башкаланы басып ала. Шушы вакыйгадан соң Куликово сугышы «каһарманы» Дмитрий Иванович Донской нәкъ элеккечә Сарайга ясак түли башлый. Ә татарлар шуңа канәгать булып Мәскәүне кабат үз иркенә куя—бары ясак кына түләп торсын. Нинди акылсызлык!

«Рухны кылыч белән буйсындырып булмый»,—дигән Наполеон, гарчә үзе шуның киресен эшләсә дә. Ә Алтын Урда ханнары фәкать тупас көч куллану ысулы белән генә эш итәләр. Кул астындагы халыкларны үзара якынайту өчен башка чаралар да куллану башларына килми. Табигый, Мәскәү буйсынган төс чыгарып кына яши, ә үзе татарга китереп сугарга җай чыкканны көтә.

Ә татар нишли соң? Ул беркатлы, кызу канлы, үз көченә артык ышана, төптән уйлап эш итми, урыслар узына башласа гына килеп куркытып китә дә тагын оныта, тынычлана. Хакимиятен ныгытмый. Ясак түлиләр ич—шул житмәгәнмени?! Бер каптырмалы һәм акылсыз сәясәт! Шул харап итә дә бөек татар мәмләкәтен.

Дөрес, Туктамыш хан тәхеткә чыккач тарала башлаган дәүләтне бер йодрыкка тупларга ирешә. Тик озаккамы? Мамай мирзадан соң бушап калган тарихи мәйданга икенче сепаратист Идегәй мирза килеп чыга. Ул да нәкъ Мамай мирза ролендә, үзәк хакимияткә каршы көрәшә. Димәк, мәмләкәттә ватандашлар сугышы дәвам итә дигән сүз.

Татар: «Ике тәкә башы бер казанга сыймый»,—дип бик дөрес әйткән. Үзе турында әйткән. Туктамыш хан үзенең иң сәләтле гаскәр башы Идегәй мирза белән уртак тел таба алмый. Тегесе Сәмәркандка Аксак Тимер хозурына качып китәргә мәҗбүр була. Һәм... калган гомерен Туктамыш хан белән көрәшүгә багышлый. Бу көрәшкә ул Аксак Тимерне дә тарта, үгетли. Идегәйне биздереп, Туктамыш хан үзе утырган ботакны кисә. Ботакны гына микән әле. Гомумән Алтын Урда дәүләтен һәлакәткә этәрә. Шулай итеп, Аксак Тимер яулары дәүләтне бер җимерсә, ике татар—Туктамыш белән Идегәйнең үзара тынышa алмавы хәлне тагын да авырайта. Дәүләт хәлсезләнә, икътисады җимерелә. Халкы туктаусыз сугышлардан туеп, таралып, әрәм-шәрәм булып бетә. Шулай мәмләкәтнең абруе һаман төшә бара.

Алтын Урда дәүләте алай ук тиз сүнәргә тиешле мәмләкәт түгел иде. Һәр империя кебек, ул да үсеш, эволюция кануннарына каршы килде, үз бәхетенә аркылы ятты һәм шул сәбәпле тарих мәйданыннан төшеп калды. Һәр империя кебек, аны да нәфес, амбицияләре харап итте. Ә бит чын мәгънәсендә бөек булган бу мәмләкәт, үзгәрә-үзгәрә, әле шактый дәверләр яши алган булыр иде. Әмма ул үзенә умыртка баганасы кебек тотрыклы идея таба алмады. Дөресрәге, оеша башлаган идеянең әһәмиятен вакытында сизеп алып, аны үстерү, ныгыту юлына басмады.

Нинди идея иде соң ул?

Үзбәк хан заманында, дәүләтнең чәчәк аткан көннәрендә бу идея инде борын төртә, Идел буе халыкларында уртак үзаң оеша башлый. Алар үзләрен бөтен бер дәүләт организмының тулы хокуклы әгъзалары итеп тою баскычына күтәреләләр. Мондый үзаңның барлыкка килүенә үзәкләштерелгән көчле дәүләт, бер үк тәртипләр, тотрыклы тормыш үзе ярдәм итә. Бу үзаңның үзәген Идел-Йорт идеясе тәшкил итә дисәк, ялгышмабыз. Укучылар хәтерлидер, «Идегәй» дастанының беренче юлларында ук Идел буе төркиләренең уртак ватаны Идел-Йорт белән горурлану хисе ярылып ята:

Борын үткән заманда,
Болгар белән Сарайда,
Җаек белән Иделдә,
Алтын Урда, Ак Урда—
Данлы кыпчак җирендә,—

диелә анда. Ә шушы данлы йортның үзәген «Идел сырты Сары тау» тәшкил итә. Бу хис-тойгы, гомуми үзаң дастанның башка бүлекләрендә дә үзен сиздереп-сиздереп куя:

Йортым Идел-Йорт икән,
Үзем кыпчак би икән.

Дастанның икенче бер җирендә «данлы кыпчак җиренең» географик кысалары тагын да киңрәк күрсәтелә:

Идел, Җаек сулары,
Иртеш белән Чулманны,
Дүрт дәрьяле йортыңны...—

диелә. Ләкин шушы йорт-мәмләкәтнең умыртка баганасын Идел елгасы, аның тирәсенә сырышкан төрки кавемнәрнең уртак ватаны Идел-Йорт тәшкил итә.

Читкәрәк китү булса да әйтеп үтик: XX йөз башында татарның иҗтимагый һәм сәяси фикерендә кабат «Идел-Урал штаты» дигән идеянең калкып чыгуы очраклы хәл түгел. Аның нигез ташлары әле Алтын Урда дәверендә үк салына, әмма дәүләт таркалу аркасында ул ныгый алмый кала.

Әйе, Идел-Йорт идеясен тормышка ашыру өчен Алтын Урда идарәчеләре киләчәк турында күбрәк уйланырга, бу каләр зур территорияне киләчәктә саклап калып булмаячагын чамаларга тиешләр иде. Бу эшләнмәде. Алар үз-үзенне чикләү, нәфесенне, амбицияләренне тыю юлына басмадылар. (Әлбәттә, XXI йөз башында бу хакта фикер йөртүләре җиңел!) Моның өчен Идел тирәсендә яшәгән барлык төркиләр Идел буен туган бишекләре, Ана-Ватаннары дип санап, шушы

гүзәл жирдә үсеп чыккан көчле һәм мөстәкыйль мәмләкәт канаты астында берегергә, Идел-Йорт өчен жан атып яшәүче халык булып бер йодрыкка тупланырга тиешләр иде.

Әлбәттә, Идел-Йорт ныгып китсен өчен татар мәмләкәте идарәчеләре авыр канатларын ике тарафка жәйгән зур империяне жиңеләйтү, жыйнакландыру юлына басарга тиешләр иде (чөнки идарә итүе барыбер кыен, мәшәкате күп, ә файдасы юк дәрәжәсендә). Моның өчен, беренче чиратта, сул канаттагы Күк Урданы кыеп төшерергә, шулай ук уң канаттагы Украина далаларын, Кырымны, хәтта Мәскәү кенәзлеген, урысларны да дәүләттән кисеп ташларга, ул жирләрдән гомумән баш тартырга тиешләр иде. Ул чакта тартып барырга көч житмәслек йөкне хәтерләткән зур мәмләкәт жиңеләеп калган, яңа сулыш алган булыр иде. Әмма Алтын Урдада моны аңларлык затлар табылмады. Ә телгә алынган олыслар соңрак барыбер аерылып чыкты, ләкин инде соң иде. Бу мәмләкәтнең бетүенә китерде.

Тарихи спиральның яңа божрасында, инде безнең күз алдында, соңгы империя булган Русиядә дә шул ук процесслар бара. Ләкин империя яклы көчләр теше-тырнагы белән республикаларга, регионнарга ирек бирмәскә тырышалар. Тик бу да юкка көчәнү—Русия барыбер элекке хәлендә калмаячак, чөнки ирекле үсү, эволюция кануннарына каршы килгән һәр нәрсә бетүгә йөз тота. Бу—катгый канун, Галәм кануны. Эволюция кануннары бер Русия өчен генә ташлама ясап тормаслар дип уйларга кирәк. «Бүленмәс һәм бөтен Русия» тарафдарлары моны тизрәк аңлаган саен отачаклар гына.

Бүгенге көндә Русия дәүләте, үз вакытында Алтын Урда кебек үк, Галәмнең икенче бөек канунына да каршы килә. Бу канун—Ихтыяр һәм Сайлау ирке кануны дип атала (Закон Свободы Воли и Выбора). Империяләр һәрвакыт халыкларның ихтыярын кысып яшәгәннәр, аларга үзләренчә тормыш корырга ирек бирмәгәннәр. Бу Галәм каршында (аны Аллаһы Тәгалә дип тә атап була) зур гөнаһ санала, иртәме-соңмы барыбер жәзасын ала. Тарихтан мисаллар китереп торуның кирәге юктыр, дип уйлыйм. Кешелек дөньясы моңарчы жимертелми-таркалмый калган бер генә империяне дә белми. Шуңа күрә, Русия бу канунны исәпкә алып эш итмәсә, аны да Алтын Урда язмышы көтә. Галәм кануннары тәрәккыят юлына аркылы ятучыны һәрвакыт рисвай итә.

Әйе, Алтын Урда дәүләте тарих арбасыннан алай ук тиз төшеп калмаска тиеш иде. Бу мәмләкәтнең көче күп булса да, акылы сайрак булган. Бу сүзләрне мин, татар кешесе буларак, эче әрнү хисе белән әйтәм. Үз татарым өчен сер итеп кенә әйтәм. Без житешсез якларыбызны белеп яшәргә тиешбез. Хаталарны кабатламас өчен. Татарга гомер бакый бердәмлек һәм төптән уйлап эш итү житенкерәмәде. Казан ханлыгы да шул ук хаталар аркасында егылды. Аның да, дәүләт буларак, төпле идеологиясе, киң карашлы идарәчеләре булмаган. Гомумән, бу төрки халыкларга, алар төзегән дәүләтләргә хас сыйфат түгелме икән? Алар гомер-гомергә, гайрәтле халык буларак, дәүләтләрен бик тиз төзегәннәр. Тик саклап кала алмаганнар. Тарихта моның мисаллары байтак.

Безнең бүгенге көнгә хәтле чал тарихыбыздан, шул исәптән Куликово сугышыннан, Казан ханлыгы жимерелгәннән соң күп гасырлар буе дәүләтсез яшәвебездән, 1917 елдан соң да «автономияле» милләт булып калуыбыздан тиешле нәтиҗәләр чыгара алганыбыз юк шикелле. Бүгенге көнгә хәтле татарның үз йөзен саклап калырлык милли идеологиясе юк. Ул мәктәп дәреслекләренә кермәгән. Димәк, милләтебез үз алдына ачык программа рәвешендә эшләнгән бөек максатлар куя алмаган дигән сүз. Ә алдавычлар күп һәм безгә аларны гел тәкъдим итеп торалар. Татар һаман саен алдана килә. Татарга һаман бердәмлек, акыл, зирәклек житми, төптән уйлап эш итми, үзара талашып башлаган унай эшләрен үзе үк тарата тора.

Милли идеологиябезнең эшләнмәве соңгы еллардагы мөстәкыйльлек өчен барган көрәштә үзен бик нык сиздерде. Үзенә туры юл сыза белмәгән, шуңа ирешү өчен көн дә эшләмәгән халык якты хыялына ирешә алырмы? Безгә Куликово кыры вакыйгаларыннан, гомумән, ифрат бай тарихыбыдан сабаклар алырга вакыт түгел микән?

# СӨЕНӘ ДӘ, КӨЕНӘ ДӘ КҮҢЕЛ

## ШАГЫЙРЬ КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ



Кадыйр Сибгатуллин—сугыш елларында туган шагыйрьләрдән. Бу буын безнең шигърияткә Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов кебек кызыклы һәм үзенчәлекле шагыйрьләрне бирде. Кадыйр Сибгатуллин да шушы «обойма»га керә. Аның иҗаты хакында әдәби тәнкыйтьнең олыдан кубып сүз әйткәне, әлеге санап кителгән шагыйрьләргә биргән игътибарны биргәне юк иде югын. Шулай булуга карамастан, Кадыйр Сибгатуллинны шигърият сөючеләр бу «обойма»ның ахырында йөртмиләр, кайдадыр өченче-дүртенче урында ук күрәләр шикелле. Лаек урын.

Шагыйрь үзе дан даулап, үзенә реклама ясап йөрүчеләрдән булмады. Сабыр, саллы, тыйнак шәхес иде. Әмма аның тыйнаклыгы Туфан Миңнуллин еш кына кисәтеп әйтә торган мокытлыкка йөз тоткан тыйнаклык түгел. Ул горур тыйнаклык. Әйе, шагыйрь үз дәрәҗәсен яхшы белеп яшәде. Казаннан, тәнкыйть күзеннән читтәрәк булса да, Кадыйр үз иҗаты белән безнең шигъриятнең үзәгендә торучы шагыйрьләрнең берсе иде.

Бу кыска гына кереш сүзне мин шагыйрьнең вафатына җиде ел тулып киткәч кенә өстәп куйдым. Юкса, 1987 елда ук язылган мәкаләм булган икән...

* * *

Инде шушы керештән соң, шагыйрьнең Татарстан китап нәшриятына тәкъдим иткән «Инану» исемле күләмле кульязмасын басылып чыкканчы ук ачып укыганымны әйтеп узыйм. Мин аны рәхәтләнеп, кинәнә-кинәнә укыдым. Кадыйр Сибгатуллин өчен, үзебезнең шигъриятебез өчен куанып укыдым. Бар бит безнең әйбәт шагыйрьләр! Көчле бит безнең чын асыл шигъриятебез!

Кадыйр Сибгатуллин үзенең кульязмасын—димәк, булачак китабын—бик ныклап уйланып, җентекләп, һәр шигырьнең урынын табарга тырышып төзегән. Аның кибәнче карт турында бик матур бер балладасы бар. Булачак китап та менә шул кибәнче карт коеп куйган кибән кебек матур һәм камил сәнгать әсәре булып күзаллана.

Бездә еш кына шигырь җыентыклары нәкъ менә җыентык булып кына чыга. Бер бөтен итеп, бер композицион төзеклек белән чыгарылган шигырь китаплары сирәгрәк очрый. Ә бит укучы китап көтә.

Кадыйр Сибгатуллинның «Инану»ы—укучы көткән шундый китапларның берсе.

Шагыйрьнең шигъри сулышы иркен, диапазоны киң. Ул үзе инанганны авыз тутырып, башкаларны да ышандырырлык итеп әйтә белә. Аның үзенә генә хас шигъри күзаллавы, образлар системасы, халыкчан җор үткен теле бар. Купшы матурлык, ялган ялтыр бизәкләр исә аның шигъриятендә бөтенләй күренми. Кадыйрда олы гражданлык публицистикасы белән сугарылган хисләр дә, гаҗәеп нечкә лирик моң да бик табигый үрелеп килә. Ул—чын мәгънәсендә лирик, шул ук вакытта эпик колачка да ия шагыйрь. Аның «Утлар», «Уел» исемле поэмаларын укып караган кеше шагыйрь күңеленең нинди тирән ассоциатив катламнарга үтеп керә алуына сокланмый кала алмый.

Кадыйр Сибгатуллин—иленә, халкына җаны-тәне белән бирелгән шагыйрь. Анардагы ватандарлык гади татар авылындагы гади бер ишектән атлап чыга да («Шул бер ишек» шигыре), илләр-кыйтгаларны кичеп, олуг патриотизм хисе булып үсә, күтәрелә. Әмма бу һич тә коры кызыл сүзләр, абстракт патетика ярдәмендә эшләнми. Бу чын шигъри сүз белән сурәтләнә.

Шагыйрьнең тематик колачын күзаллау өчен һәр бүлектән берничә шигырь исемен санап үтү дә җитә. Карагыз: «Алмалы ел», «Калай кыза», «Ялган яз», «Борчак ашы», «Кибәнче карт», «Атлар көтте авыл малайлары», «Соңгы чабатачы»—болар, әлбәттә, авыл шигырьләре. Шулай булмый хәле юк, бик күп әйбәт шагыйрьләребез кебек, Кадыйр да һәр күзәнәге белән авылныкы, авылдан үсеп чыккан шагыйрь ич. Алга таба «Иргә чыкмый калган апалар», «Инвалидлар», «Хәтер», «Һәйкәлләр», «Мәңгелек утлар», «Карт солдат», «Без сугышта һаман» кебек әсәрләрдә үткән сугыш яралары сыкрый. Кадыйр, күпләребез шикелле үк, сугыш еллары баласы. Аның бу бүлектәге әсәрләрен укыганда күзгә яшь китергән мизгелләр ешая икән—гаҗәп түгел: сугыш афәтен безнең илдән дә нык татыган ил булмады... Өченче бүлектән «Кешеләрнең барын танып йөрим», «Тантаналы сагыш», «Җыргамоңга мохтаҗ чагым минем», «Мәгънә киңәйгәндә», «Хискә дә бай тормыш, төскә дә бай» шикелле әсәрләрне укып, шагыйрьнең рухи дөньясын, тормыш фәлсәфәсен, яшәеше-көнкүрешен, тоткан кыйбласын ачык төсмерлисең. Болары да бик табигый: рухи дөньясыз шагыйрь—шагыйрь түгел. Тагын бер бүлек—«Декабрист хатыннары», «Син кош булып кердең минем төшкә», «Ни гомер күрмичә йөрелгән», «Югалткан, тапкан чагым», «Озату», «Мәхәббәт» һ. б. һ. б.—әйе, әлбәттә, мәхәббәт, сөю-сөелү, хатын-кызга мөнәсәбәт... Моны инде шәрехләүнең дә кирәге юктыр. Шигъриятне мәхәббәт кенә тудыра да. Һәм, ниһаять, кулъязманың соңгы бүлегендәге «Киткәндә», «Граф паркы», «Фахишә», «Гөмбә сатучы карчык», «Роботлар турында гына», «Шимбә өмәсе», «Яшь шәһәрнең карт каены» кебек әсәрләрдә үзеннән-үзе шәһәр атрибутикасы, КамАЗлар җирлегендә үсеп чыккан—яңа кала рухы, шул калада яшәүче кичәге авыл яшьләре—бүгенге эшчеләр тормышы...

Биредә тулы бер китапны шулай туры сызыкка гына сузып салып күрсәтергә тырышуым өчен укучы, мине гафу итәр, шөт. Кадыйрның иҗаты һич тә ул сызыкка гына сыеп бетәрдәй түгел. Ул бик күп төрле бизәкләргә, төсмерләргә, нюансларга гаять бай иҗат. Биредә, бу очракта мин аерым шигырьләрдән цитата-өзекләр, үземә ошаган матур юлларны да мисалга күрсәтеп тормаска булдым. Чөнки шагыйрь шәхесе бөтен, шигърияте бөтен. Китапның кайсы битен генә ачып укысаң да, ул чын шигырь булыр.

Китапны ачып җибәргән шигыре:

Шушы җирдә бик каласы килә
Бер югалмый торган җыр булып—

нәкъ программ шигырь юллары болар! Җәлилчәрәк әйтелгән юллар.

* * *

Мин бу рецензия-бәяләмәне 1986 елның 4 февралендә язган булганмын. Бер елдан артык вакыт үтеп киткән—ни сәбәптәндер, Кадыйр Сибгатуллинның

кульязмасына нәшрият темпланында урын табылмаган... Бик аяныч хәл. Менә шулай көенеп йөргән көннәремнең берсендә—ни хикмәт!—кулыма Кадыйрның яна кульязмасын китереп тоттырдылар!

Укып чыктым.

Аннары, утырып, түбәндәге яна бәяләмәне яздым. Хикмәтнең нәрсәдә икәнен укучы үзе аңлар дип уйлыйм...

«Кадыйр Сибгатуллинның «Таңнар, кичләр...» дигән яңа кульязмасын укып чыктым да берничә көн уйланып йөрдем. Уйлар, әлбәттә, безнең шигъриятебез турында, шул шигъриятькә тугрылыклы шагыйрьләребез иҗаты турында һәм... әйбәт шагыйрьләребезне күрә белмәгән, аларны һәвәскәрләрдән, мөтәшагыйрьләрдән аера-аралый алмаган тәнкыйтьчеләребез турында иде.

Нигә соң без: «Шигырьнең бәясе төште...»—дип сөйләнәбез? Чын шигырьнең, талантлы иҗатның бәясе бер вакытта да төшми. Тукайның, Такташның, Туфанның бәясе төшә аламы? Нигә соң без чын шигырьне соңгы елларда басып баручы халтурадан, графоманлык чүпләреннән аерып ала белмибез? Аерып алып, укучыларга: «Менә шигърият!»—дип күрсәтә белмибез... Нигә бездә әйбәт шагыйрьләр иҗаты турында бик аз языла? Нигә «соры тычканнар»га—халтурага да, чын шигырьгә дә бер төслерәк карыйбыз? Каян килеп керде бу кыркып тигезләү, русчалап әйтсәк, уравниловка? Шул куркыныч күренеш әйбәт шагыйрьләрнең исемнәрен кысрыклый бара.

Ул «соры тычканнар»дан арынырга нәшриятның үзенең генә көче житми. Ни Язучылар берлеге идарәсеннән, ни шагыйрьләр секциясеннән, ни әдәби тәнкыйтьтән конкрет ярдәм юк. Ник без болай салкын-битараф? Кайда безнең әдәби бәябез-чамабыз, зәвыгыбыз?

Менә шундый күңелсез сораулар...

Кабатлап әйтәм: моннан бер еллар элек Кадыйр Сибгатуллинның бер кульязмасына эчке рецензия язган идем инде. Ун-унбер табак күләмендәге ул кульязма «Инану» дип атала иде. Бик әйбәт итеп, үзенә зур таләпләр куеп туплаган иде Кадыйр Сибгатуллин ул кульязмасын. Чын шагыйрьнең ихлас әйбәт шигырьләреннән-поэмаларыннан тупланган югары зәвыклы, укучыларны сөендерерлек китап булырга тиешле иде ул. Аяныч...—темпланда аңа урын табылмаган. Аның өлешен әлеге дә баягы «соры тычканнар» ашаган...

Шагыйрь, китабым темпланга кермәде дип, шикаятьләр язып, төрле инстанцияләргә йөрмәгән. Бер ел эчендә әллә никадәр яңа әсәрләр—әйбәт әсәрләр!—язган. «Туфан белән сөйләшү» дигән зур поэма төгәлләгән. Алдагы



*Сулдан уңга: Р. Лотфуллин, Х. Хәснуллин, К. Сибгатуллин һәм В. Имамов*

кульязмасына карата әйтелгән фикерләрне искә алып, монысын яңадан игътибар белән карап чыккан. Яңа әйберләрен дә өстәп, яңа композицион төзелеш табып, кульязмасын өр-яңадан иренмичә эшләгән.

Әйе, Кадыйр байтак кына яңа әсәрләр өстәгән. Шулар арасыннан иң беренче чиратта «Чишмәләр ага тора», «Тарала картлар җомгадан», «Тора дөнья», «Яшәсәм дә күпме» кебек әсәрләргә игътибар итәргә кирәк. Болар бик әйбәт әйберләр. Тыгыз язылганнар, уйланып, дөньяның гамьнәрен кичереп язылганнар.

«Туфан белән сөйләшү»... Бу поэма Кадыйр Сибгатуллинның йөрәгеннән өзелеп төшкән әсәр. Ул нәкъ менә бүген әйтелергә тиешле әрнүләрне әйтеп биргән. Поэма аның күңеленнән ташыган да чыккан. Әмма ул һич тә шәхси кичерешләр, шәхси мәнфәгатьләр тирәсендә генә калмаган.

Сөйләшәсе килә.
Мөлдерәмә
тулып тора күңел нигәдер.
Минем генә түгел,
башканың да
бүген ачыласы киләдер,—

дип бик гади генә, ихластан гына башлап китә шагыйрь поэмасын. Һәм Туфан белән сөйләшү аша заман турында, ил язмышы—халык язмышы турында зур фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый. Поэмада без Хәсән ага Туфан образында иле өчен иманыннан язмас, сынмас-сыгылмас зур шәхесне күрәбез.

Дөреслекне дөрес әйтер өчен
Туфаннардай булыр чак безнең,—

ди шагыйрь һәм аңа ышанасың. Әйе, нәкъ менә хәзерге өлкәнәеп килүче буыннан һәм яшьләрдән ил-халык хакыйкать сүзен әйтүне көтә, эш көтә, тәвәккәллек көтә.

Иманыбыз исән-саумы, дисәк,
синдә иде аның бизмәне.

«Хәлең ничек, энем?»—дия идең,
«Хәлем авыр минем»,—димәдең.

Яки:

Үз йөрәгең—үзеңнеке, чыдар,
бәйлисе бар халык йөрәген...

Мондый юлларны күпләп китерергә булыр иде. Болар барысы да—Туфан, аның олпатлыгы, зурлыгы хакында йөрәк түреннән чыккан сүзләр. Хәсән Туфан турында күп яздылар, ярыша-ярыша яздылар, алда да язарлар. Кайберләре «мин һәм Туфан» дип язды, кайберләре «Туфан лидерлыкны безгә калдырды, без—Туфандашлар» диюдән дә тартынмады. Туфанны бүлешәсе юк. Ул—халыкныкы. «Халык кайда—Туфан анда ул»,—дип Кадыйр Сибгатуллин бик дөрес әйтә. «Туфаннан соң—мин!»—дип күкрәк кагасы да юк. «Мин»енне онытып торып, фанилыкны туфанилыктан өстен куймыйча, тир түгеп эшләргә кирәк, гражданин булырга кирәк. Халык үзе әйтер: Туфаннан соң—кем?..

Кадыйр Сибгатуллин әнә шул шәхси вакльлыклардан өстен була алган, ул чын мәгънәсендә ил улы булып сөйләшә (дөрес, шәхси мотивлар, биографик күренешләр дә поэмада бөтенләй юк түгел, ансыз була да алмый). Авторны «Туфаннан соң—кем?» соравы түгел, башка олы гамь борчый.

«Чын остазлар... Алар урынын бүтән алалмый. Аксакаллар иртә китеп бара, калганнарның сакал агармый. Низагларга урын артып китте, Зур мәҗлестә җитми мәртәбә. Сез кабызган шәмнәр яна бүген, Нинди утлар янар иртәгә?»

Болар—барыбызны да бик нык борчый торган мәсьәләләр. Автор белән бергә без дә:

Туфан булыр өчен яшәү кирәк
заманадан бераз зур булып,—

дигән нәтиҗәне ясыйк. Сүз бирелә шагыйрь Туфан хакында гына бармаганы, ил улы—гражданин булу хакында барганлыгы ачык аңлашылса кирәк.

Йомгаклап әйтәм: Кадыйр Сибгатуллинның «Таңнар, кичләр...» исемле китабы нәкъ бүген укучылар кулында булырга тиешле китап. Ул бүгенге социаль үзгәрешләр, социаль гаделлек өчен көрәшә торган китап.»

* * *

Кадыйр Сибгатуллин арабыздан иртәрәк китеп барды (июнь, 1994 ел), аңа әле нибары илле ике генә яшь иде. Әле язасы да язасы, иркенләп иҗат итәсе иде юкса... Хәтерлим: Татарстан язучыларының чираттагы съезды (корылтае) көннәре. Кадыйр белән очраштык, озак кына сөйләшеп йөрдек. Ул, куанып: «Менә, бер бәйләм өр-яңа шигырьләремне күтәреп килдем әле! Съездыбызга бүләк...—дип, көлемсерәбрәк әйтеп тә куйды.—»Казан утлары»на калдырып китәм. Анда үзебезнең шагыйрьләр утыра бит—шигырьне ватып-сындырып бетермиләр, бәйләм-бәйләм килеш тулы итеп бастыралар,—диде.— Һи, хәзер цензура-тыюлар юк бит!»—дип, киң итеп елмаеп җибәрде.

Ике көннән без Кадыйр Сибгатуллинның вафатын ишеттек... Җан әрни... Вакытында тиешле бәясен ала алмыйча китте бугай талантлы каләмдәшебез.

Без Кадыйр Сибгатуллинны, аның шигърияten онытмаска тиешбез. Бар булган иҗатын җыеп, томлыкларын нәшер итәсе иде аның...

**Марс ШАБАЕВ.**
*1987-2001*

---

# Кадыйр Сибгат

## БАСЫЛМАГАН ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН

### Бурыч

**Гаҗәпләнеп шуны уйлап йөрим,**
**(яңа килде уйга—томана!),**
**тик бер генә сүзне хәтерләп тә**
**яшәп була икән дөньяда.**
**«Бурыч» дигән матур сүз бар икән,**
**матур итеп әгәр кулланса҅ң.**
**Күзләреңне җүнләп ачып йөрсәң,**
**төшеп калган бәндә булмасаң.**
**Кеше бурычларын кеше белми,**
**кешенекен кеше түләми.**
**Һәркем үзе билгеләргә тиеш**
**бирер бурычлары күләмен.**

Бурычлы мин, диеп йөри кеше,
бурычлы, ди, анам-атама.
Ул бурычлы икән кешеләргә,
ул бурычлы Илгә,
Ватанга.
Фикер туа:
бу—намуслы кеше,
тыйнак кеше,
уйлы-хәтерле;
җәмгыятькә безнең әнә шундый
аңлый торган кеше кадерле.
Ялгышы да күптер—
тормыш бит ул.
Эшләр һаман булмый уңышлы.
Ул үзе дә һаман әйтә тора:
бурычлы бит егет,
бурычлы...
«Бурычлы мин»,—диләр гомер буе,
«зур бурычлы мин»,—дип яшиләр.
Бурычларны түләр вакыт җиткәч
бурычлылар бер сүз дәшмиләр.

*1987*

Бәхет алып киләләр дә сиңа...
бәхетеңне алып китәләр.
Хәсрәт төяп киләләр дә сиңа,
бер бәхетле бәндә итәләр.

Бөтенесе әйбәт...
Бөтенесе...
Үкенече килми азактан.
Газапларга салучылар булгач,
алучы да кирәк газаптан.

*1985*

Хыялларда туа бөек эшләр—
кодрәт җитә торган.
Йөз елдан соң килеп карасалар,
исең китә торган.

Моңа кадәр беркем табалмаган
мәхәббәтләр туа.
Дөрли-дөрли илһам учагында
кабат яшәп була.

Нәфрәт туа. Гомереңдә тик бер
була икән андый.
Горур башың белән яуга чыксаң,
дошман исән калмый.

Ташланабыз гайрәт-йөрәк белән—
ныклап тотынабыз.

...Картаялар уйлар хыялларда—
бик тиз онытылабыз.

Кызганмаган, нәзек күңел биргән,
биргән сизгер йөрәк.
Кемнәрнедер тояр, назлар өчен
йомшак кул да кирәк.

Тотар өчен үзеңне-үзең шәбрәк
кирәк каты кул да.
Яшим дисәң, тыңла хыялыңны—
калма ярты юлда!

Калма ярты юлда!

*1986*

Бер кеше дә ике тапкыр тумый.
Ике тапкыр килми үлем дә.
Килә кеше
фани дөньяларны
бер күз ачып кына күрергә.

Аның бүтән китәр урыны юк.
Шушы Җирдә генә каласы.
Нигә кирәк булды икән тагын
уйлап табу үлем җәзасын?

*1989*

## Бердәнберең

Хаста булыр үзе.
Ә белгертмәс.
Исән-сау мин, дияр хатында.
Кайт!—дип язмас.
Үлемнәре сөйләр
озак авыруы хакында.

Азып-тузып кайтсаң—
сыендырыр.
Кеше итәр сине—
сер бирмәс.
Соңгы кисәк икмәге дә бетәр—
беркайчан да:
туйдым, кит!—димәс.

Бурычларың булса, и, зимагур,
соңгы шәлен сатар түләргә.
Синең туган минутыңнан башлап
синең өчен әзер үләргә.

Үтә күрер сине.
Сүзсез аңлар.
Аның күңелен һични алдамас.
Нинди генә җинаятьләр кылма—
хөкем итәр,
ләкин каргамас!

Аның өчен син һәрвакыт кеше.
Мәңге шулай булып кала ул.
Аңлый алсаң,
бердәнберең синең
тик бер генә кеше—
ана ул!

*1991*

## Кая таба...

Белмисең дә:
каян килеп баса?
Бәгыреңә таштай каплана.
Качасылар килә
сикереп менеп
болыннарда калган атларга.
Нинди хәсрәт?
Нинди афәт килә?
Шатлыкларны кемнәр урлады?
Кая безнең балкып торган күңел?
Күзебезнең кая нурлары?
Көннәр эссе,
ә кешеләр салкын.
Бу салкынлык кайсы тарафтан?
Ходай Җирдә адәм балаларын
җылы җанлы итеп яраткан.
Кояшның да нуры сүрелмәгән.
Кешеләрдә генә җылы юк.
Җирләр исә,
шаулый урман,
сулар...
Табигатьнең моңы-җыры юк.
Моңнары да безгә килеп җитми.
Җырлары да безгә ирешми.
Җылы сүздән курка кеше бүген.
Елмаю да безгә килешми.
Калырмы ул шулай?
Терелерме?
Ташка әйләнеп тәмам бетәрме?
...Кеше җаны
таулар күтәрә алмас
ул ташларны шактый күтәрде.
Күтәрә алмас кебек инде бүтән.
Менә шулар борчый,
куркыта.
Кая баккан бүген Кеше җаны?
Кая таба Кеше юл тота?
Йә, илаһи,
дучар итә күрмә—
таш замана, ахры, башлана.
...Җылы эзлим.
Битләремне куям
кояш нуры сеңгән ташларга.

*1992*

# ЯҢА ГАСЫР, ИСКЕ ПРОБЛЕМАЛАР...

"КАЗАН УТЛАРЫ" ЖУРНАЛЫ РЕДКОЛЛЕГИЯСЕНЕҢ
КИҢӘЙТЕЛГӘН УТЫРЫШЫННАН

*Редакциянең матур бер традициясе бар: без даими рәвештә "Казан утлары"ның идарә әгъзалары, актив авторлары, аксакал язучылары катнашында киңәш мәҗлесләре үткәрәбез һәм ул утырышларда әйтелгән фикерләр белән укучыларыбызны да таныштырып киләбез. Мондый киңәшмә-очрашуларда журнал хезмәтенә анализ ясау белән беррәттән, бүгенге әдәби процесска, гомумән, мәдәниятның киләчәгенә кагылышлы бик күп актуаль проблемалар уртага салып ихлас сөйләшеленә, фикер алышына.*

*Ел ахырында үткән җыелышыбызга да, һәрвакыттагыча, абруйлы, мәртәбәле шәхесләр—язучы-шагыйрьләр, академик-галимнәр, шулай ук хөкүмәт вәкилләре дә килгән иде.*

*Сезнең игътибарга әлеге утырыш беркетмәсеннән кыскача сөземтә тәкъдим итәбез.*

**Равил Фәйзуллин,** ***баш редактор:***

Сер түгел, татар әдәбиятының киләчәге күпләрне борчый бүген. Бу яңа гасырда әдәбият халкыбыз тормышында нинди роль уйнаячак? Без—язучылар—нинди гамәлләр кыла алырбыз? Язганнарыбыз ни дәрәҗәдә кирәк булыр? Замана кабул итәрме без язганнарны?.. Сораулар күп. Журналга бәйләнешле рәвештә, әлеге сораулар тирәсендә дә сүз булырдыр бүген.

Киләсе елга журналның юбилеен—80 еллыгын билгеләп үтәргә җыенабыз. "Казан утлары"ның халкыбыз тормышында тоткан урынын исәпкә алсак, бу—иҗтимагый әһәмияткә ия дата. Чишмә башын "Шура", "Аң" журналларыннан ук башласак, журнал тарихы тулы бер гасырны колачлый дияргә була. Кайбер журналлардан аермалы буларак, "Казан утлары"—берөзлексез чыгып (сугыш елларында бер иш басмалар чыгудан туктаган иде), халыкка ирешеп барган бердәнбер журнал. Шуңа күрә, бу юбилейны зур бер рухи бәйрәмебез итеп уздырырга иде.

Журналны тарату—безнең төп борчу-мәшәкатьләребезнең берсе. Моннан утыз-кырык еллар элек һәр татар гаиләсендә диярлек "Казан утлары" һәм "Азат хатын" журналларын алдыру—табигый бер күренеш иде. Хәзер вәзгыять бүтән. Әдәбиятны тәрбия өлгесе дип санаган буыннар китеп бара... Хәзер телевизор, компьютер йогынтысында тәрбияләнгән яңа буын килде. Нәтиҗәдә, журнал укучылар кимеде. Заманында, "Казан утлары" 100000 нән артык тираж белән чыккан елларда, укучыларыбызның яртысыннан күбрәге Татарстаннан читтә яшәүчеләр булса, бүгенге көндә алар, нигездә, Татарстанда һәм Башкортстанда гына калып бара. Әллә ничә йөз мең татар яшәгән Мәскәүнең үзендә санаулы данәләр тарала.

Журнал язмышы турында уйланганда, үзеннән-үзе татар китабы турында уйланасың. Безнең җыелышта нәшриятыбызның җитәкчеләре дә утыра. Бу хакта алар да үз фикерләрен әйтерләр, дим. Шулай ук, яшь алмаш турында, яшь язучыларның иҗаты турында сүз булырдыр.

Кыскасы, уртага салып сөйләшерлек проблемалар җитәрлек. Безнең арабызда премьер-министр урынбасары, редколлегия әгъзасы Зилә Рәхимжановна да бар. Моны мин ни өчен ассызыклап, басым ясап әйтәм? Хәзер бездә зур мәгънәдә идеология юк. Элек идеология өлкәсендә бик күп кешеләр эшли иде. Безнең хәзер төп киңәш-табыш итә торган җиребез—Республика Министрлар Кабинеты. Андагы җитәкчеләрнең берсе безнең уй-фикерләребезне, моңзарларны белеп торуы һәр яктан файдалы булыр.

## **Флүс Латыйфи,** ***баш редактор урынбасары:***

Сүзне иң элек ел дәвамында журналда басылып чыккан әсәрләрдән, аерым алганда, иң күләмле жанрдан—прозадан башлыйк әле. Прозабыз эзләнү юлында. "Тирән тамырлар", "Матур туганда" кимәлендәге романнар инде бүгенге көн таләпләренә җавап бирми һәм аларны укучы да юк. Чөнки, соңгы елларда, куәтле ташкын булып дөнья әдәбияты килеп керде. Бүген һәркем диярлек урыс телендә дөнья әдәбияты белән танышып бара һәм әгәр дә без татар прозасын шул дәрәҗәгә күтәрә алмасак, укучыларыбызны югалтачакбыз.

Эзләнү юлындагы әйберләр бар, ләкин алар әле мул ташкын булып журналга үтеп кермәгән. Аларның берничәсен инде без анализлаган идек. Шундыйлар исәбенә мин Галимҗан Гыйльмановның "Албастылар" хыялый кыйссасын, Факил Сафинның "Саташып аткан таң", Зиннур Хөсниярның "Терсәк сугышы" романнарын кертәм. Эзләнү юлындагы тагын бер әсәр—Тәүфикъ Әйдинең "Венада очрашу" исемле повесте. Күпләр производстводан, авыл хуҗалыгы темасыннан чыга алмый йөргән мәлдә Тәүфикъ Әйди эмигрантлар дөньясына барып керде һәм аларның язмышларын тасвирлый алды. Мәдинә Маликованың "Алтын ятьмә" повесте турында да әйтеп китми мөмкин түгел. Автор бүгенге татар хатын-кызлары, аларның җигелеп тормыш арбасын тартулары хакында бик тә гыйбрәтле әсәр иҗат итә алган.

Иске стильдә язылып та, укучыларыбыз тарафыннан яратып укылган әсәрләр бар. Болар—Якуб Зәнкиевнең "Өтелгән мәхәббәт", Фоат Садриевның



*Сулдан уңга: Ф. Галимуллин, Г. Рәхим, М. Хәбибуллин, М. Мәхмутов, Н. Хисамов, З. Вәлиева, Р. Фәйзуллин.*

"Бәхетсезләр бәхете" романнары һ. б. Соңгысын елның иң уңышлы әсәрләреннән дип саныйм. Биредә коммунизм чорындагы татар авылындагы вакыйгалар сурәтләнә. Коммунизм идеяләре начар түгел иде бит. Әмма аларны урындагы коммунистларның ни рәвешле бозып, диктатурага әйләндерүе һәм ничек кеше язмышларын ботарлап сындыруы хакында Фоат Садриев бик житди һәм кызыклы әсәр иҗат итә алган.

Ел дәвамында журнал битләрендә 5 роман, 7 повесть, 14 хикәя басылган. Бу инде татар язучыларының шактый нәтиҗәле эшләвен дәлилләүче күренеш.

Мине бик борчыган ике концептуаль мәсьәләгә тукталасым килә. Моннан әле ун еллар элек кенә татар китаплары иллешәр мең данә тираж белән чыга иде. Чыккан китаплар, беркем пропагандалап йөрмәсә дә, бик тиз таралып бетә иде. Чөнки ул вакытта һәр район үзәгендә китап кибетләре эшләде. Зуррак авылларда һәр кибеттә китап бүлекләре бар иде. Менә без хәзер авылларга чыгабыз, ни кызганыч, район үзәкләрендә китап кибетләре юк. Дөрес, кайбер урыннарда китап бүлекләре бар, ләкин анда Мәскәүдә чыккан ялтыравыклы детектив, эротик әдәбиятны гына очратырга мөмкин, татар китаплары юк... Безгә янадан авылларга үтеп керергә кирәк, республикабызның һәр төбәгендә китап сәүдәсе мәҗбүри рәвештә оештырылырга тиеш. Һәр мәктәптә кечкенә генә китап киоскысы булырга тиеш. Бу эш хөкүмәт югарылыгында эшләнсә генә нәтиҗәле булачак. Миңа калса, Министрлар Кабинетымы, Дәүләт Советымы, бу мәсьәләне тикшереп, авыл җирендә китап сәүдәсенең торышы һәм аны яхшырту юллары турында ниндидер бер карар кабул итәргә һәм шул карар нигезендә эшләргә тиеш. Бүген китапны авылга без илтмәсәк, авыл үзе килеп алмаячак. Хәзер безнең проза китаплары күп дигәндә 3 мең данә белән чыга. Көлке бит бу. Шигырь китапларын әйткән дә юк—арада 500 данә белән басылганнары бар.

Икенче борчыган мәсьәлә—Татарстан китап нәшриятындагы каләмхак түләү. Соңгы бер-ике ел эчендә газета-журналлардагы каләмхак түләү бераз артты, ә менә китап нәшрияты әлеге агымнан читтә калды.

**Мансур Вәлиев,** ***бүлек редакторы:***

Быел журналда байтак кына тәнкыйть мәкаләләре дөнья күрде. Әдәбиятның сыйфатын яхшырту өчен төрле формаларны кулланабыз: ел дәвамында дискуссияләр, түгәрәк өстәлләр, төрле бәйгеләр уздырыла. Иң яхшы рецензияләргә, иң кызыклы тәнкыйть мәкаләләренә быел да конкурс үткәрелде.

Биредә язучылар җыелган. Форсаттан файдаланып, үземне борчыган бер мәсьәлә хакында әйтеп узасым килә. Язучыларның узган корылтаенда Президентыбыз Минтимер Шәймиев язучыларның иҗат йортын булдырырбыз дип вәгъдә биргән иде. Әлегә кадәр бу вәгъдә сүздә генә кала бирә.

**Равил Фәйзуллин:** Кызганыч, чын мәгънәсендәге әдәби тәнкыйть бездә юк дәрәҗәсендә. Ә халыкка, укучыларга әдәби әсәрләр, әдәби процесс турында объектив бәя биреп бару—тәнкыйть бүлегенең төп бурычы саналырга тиеш.

**Камил Кәримов,** ***бүлек редакторы:***

"Казан утлары"н язып тутырырга була, журналны вакытында чыгарырга да була, ләкин аны укучыларга житкерү—бүгенге көндә иң зур проблема. Бу—ике-өч сүз белән генә әйтеп китә торган мәсьәлә түгел. Ләкин шунысын искәртәсе килә—соңгы елларда бу өлкәгә хөкүмәтнең дә, язучылар идарәсенең дә игътибары кимеде. Язучылар берлегендә эшләп киткән кеше буларак, мин "теге" заманнарны бик яхшы хәтерлим. Һәрбер идарә әгъзасына районнар бүленеп бирелә иде. Һәм подписка чорында ике-өч утырыш газета-журналларны таратуга багышлана иде. Һәркем үз районында нәрсә эшләве хакында басып отчет бирә иде. Хәзер безнең районнардагы бер-ике ышанычлы кешедән башка таянып жиребез юк. Әлеге бер-ике кеше дә кул селтәсә, бу эш

бөтенләй үз агымына калачак. Кайбыч, Апас яклары бүгенге көндә нибары 20—30 данә журнал алдыра! Коточкыч хәл бит бу! Шуңа да, бүгенге көндә пропаганда беренче урында торырга тиешле мәсьәлә. Пропаганда дигәннән, Зилә Рәхимжановна, андый бүлек Министрлар Кабинетында бармы ул?

**Зилә Вәлиева,** ***ТР премьер-министры урынбасары:***

Без бүген яңачарак формада эшләргә тиешбез. Пропаганда бүлеге оештырып кына проблема хәл ителмәячәк, бу—ямау салу, ягъни, проблеманы вакытлыча хәл итү генә булачак. Шуңа күрә пропаганданың нинди дер яңа юлларын эзләргә кирәк...

**Туфан Миңнуллин,** ***драматург, Татарстан халык депутаты:***

Камил Кәримовка белешмә: Министрлар Кабинетында шушындый эшләрне башкарырга тиешле мәдәният бүлеге оешты. Алар бүгенге көндә ТАИСны ябарга йөриләр. Беренче эш итеп язучыларга азмы-күпме акча эшләргә мөмкинчелек биргән оешмага тотындылар...

**Зилә Вәлиева:** Мин бу өлкәдә төзәтмә кертергә тиешмен. ТАИСны ябу турында сүз бармый. ТАИСның төзелеше иске кануннарга корылган. Аның житәкчесенә яңа кануннарны нигез итеп алып, килешүләрне яңача төзеп, оешмасын яңа формага китерергә генә кирәк. Бүген коммерция заманы. Коммерция оешмалары ансат кына акчаларын чыгарып салырга жыенмый. Шуңа күрә, ТАИСка документларын тәртипкә китерергә, тоткан юнәлешен дөрес юлга салырга кирәк.

**Равил Фәйзуллин:** "Казан утлары" редколлегиясендә язучыларны борчый торган төрле мәсьәләләр күтәрелү табигый.

Минә мин Ренат Харисның "Казан утлары" турында фикерләрен ишетергә теләр идем. Бездә эшләп киткән кеше буларак та, депутат буларак та...

**Ренат Харис,** ***шагыйрь, Татарстан халык депутаты:***

Сүзне пропагандадан башлыйсым килә. Зилә Рәхимжановна дөрес әйтте—хөкүмәт югарылыгында бүген андый бүлек була алмый, аның кирәге дә юк. Ул—антипропаганда булып кына кабул ителәчәк. Мина калса, безнен пропаганда үзәкләре бар һәм алар бик күп. Болар: "Казан утлары", "Идел", "Сөембикә", "Татарстан" журналлары, радио, телевидение һ. б. Нигә "Казан утлары" үзенең битләрендә татар әдәбиятын тиешенчә пропагандаламый? Һәр язылган әсәр—татар халкын игелеккә тарта торган әсәр. Аны пропаганда дип исәпләргә кирәк. Шул ук китапларга килсәк, яхшы тышлы начар китаплар чыга, начар тышлы бик яхшы китаплар да басыла. Шуларны аерып, халыкка тәкъдим итә белергә кирәк. Минә бу—пропаганда булачак.

Быелгы журналларга күз салсак, ун санда әдәби тәнкыйть дигән рубрика астында унбишләп мәкалә басылган, шуларның яртысы—истәлекләр, яртысына якыны әдәбият тарихына карый торган фәнни язмалар, бары биш проценты гына чын тәнкыйть мәкаләләре. Минә шундый чын тәнкыйть мәкаләләре күбрәк булса, бу—"Казан утлары"ның үзе өчен менә дигән пропаганда булыр иде. Жанр буларак, ижтимагый фикер формасы буларак, әдәби тәнкыйть үлем хәлендә. Моны торгызырга кирәк һәм бу юнәлештә без барыбыз да эшләргә тиеш.

**Туфан Миңнуллин:** Журналның яртысы әдәби тәнкыйтьтән торса да, язылмаячаклар!..

**Ренат Харис:** Үзегез үк әйтеп торасыз—татар авылларында, районнарда китаплар сатылмый, дип. Каян белсен ди Буа районының

карангы бер авылында яшәүче фәлән абзый "Мәгариф" нәшриятының нинди китаплар чыгарганын? Белми ул аны! Белмәгәч, сатып та алмый. Әгәр дә безнең әдәби тәнкыйтебез пропаганда үзенчәлекләрен дә алып эшләнгән әдәби тәнкыйть булса, "йоттырып жибәрә торган", бераз гына күзәтү рәвешендәге тәнкыйть булса, ана игътибар итәрләр иде. Безгә янача эшләргә кирәк! Әдәби тәнкыйтьне реклама ысуллары белән укмаштырырга кирәк! Шунда гына алга ниндидер бер адым ясалачак.

Ә ТАИСка килгәндә, бүген без ТАИСны сакламасак, ул янадан Мәскәүгә китәчәк. Кирәкмәгән налог оешмаларын, менәрләгән кеше эшләүче казначействоларны кыскартасы урында, нибары ун-унбиш кешелек ТАИСка ябырылуны мин берничек анламыйм.

Һәм, әйтәсе сүземнең иң соңгысы—журналдагы рубрикалар ни дәрәжәдә исеменә туры килүенә тиешенчә игътибар итегез әле. Рубрикалар буталмаска тиеш. Әдәбиятыбызны системага салу—бу безнең язучының аңын да иҗтимагый система алымнары белән баету дигән сүз.

**Равил Фәйзуллин:** Килешәм. Ә инде тәнкыйть мәсьәләсенә килгәндә, бу өлкәдә профессиональ тәнкыйтьчеләрнең юк дәрәҗәсендә булуын да истән чыгармыйк.

**Фоат Галимуллин,** ***Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан халык депутаты:***

Биредә Камил Кәримов башлаган сүз бәхәс уятты. Минем аңлавымча, Камил пропаганда бүлеге бармы соң, дигәндә, әдәбият-сәнгать эшен оештыру буенча, безнең хөкүмәт структурасында нинди дә булса үзәк бармы, дигән мәгънәне күздә тотты. Бүгенге көндә андый оешма бар. Министрлар Кабинетында әдәбият-мәдәният мәсьәләләре буенча бүлек эшли. Аның мөдире—Марсель Таишев. Һәм менә мин Язучылар берлеге рәисе буларак, һәрчак бу бүлекнең ярдәмен тоям. Әйтик, байтак еллардан бирле Муса Җәлил исемендәге бүләк бирелми килде. Бу мәсьәләне без быел күтәрдек һәм 2002 елда әлеге бүләкне бирү яңартылачак.

2002 елда Язучылар берлегенең чираттагы съезды булачак. Бу өлкәдә безнең тарафтан зур әзерлек бара. Гомумән, барлык юнәлешләр буенча, өч ел эчендә эшләгән эшләребез буенча йомгак ясарбыз дип уйлыйбыз. Шул уңайдан, "Казан утлары"нда да "съездны каршылап" кебегрәк рубрикалар күренсә әйбәт булыр иде.



*Алгы рәттә сулдан уңга: З. Хөснияр, Р. Харис, Х. Миңнегулов, Ф. Галимуллин*

**Нурмөхәммәт Хисамов,** ***Татарстан Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият, сәнгать институты директоры:***

"Казан утлары"—безнең бердәнбер, тотрыклы, үзенең йөзен саклаучы академик журналыбыз. Әдәби процессны, республикадагы иҗтимагый гамьне мөмкин кадәр сизгер чагылдырып баручы, зыялыларны борчый торган мәсьәләләрне игътибарыннан читкә калдырмый торган журналыбыз. Хәзерге әдәби процессның, аеруча, проза өлкәсендәге ачышларына шундый сусау сизәм ки, минем өчен журнал бу өлкәдә ике ачыш ясады. Беренчесе—Рафаэль Сибат. Кайчандыр рус әдәбиятында халык ябырылып укый торган Астафьевлар, Распутиннар булган кебек, Рафаэльнең әсәрләре дә шулай. Икенчесе—Фоат Садриев.

Тәнкыйть мәсьәләсенә килгәндә, хәтерегездә микән, Сибгат Хәкимнең елга әллә ничә тапкыр дигәндәй, поэзия, әдәби процесс турында зур, житди чыгышлары була торган иде. Ягъни, язучылар, шагыйрьләр үзләре дә тәнкыйть мәкаләләрен ешрак язарга тиеш дип саныйм мин.

"Казан утлары"ның тагын бер бик изге вазифасын әйтәсем килә. Латинга күчү мәсьәләсендә, җәй көне Фәннәр Академиясе кысаларында зур-зур төркем зыялылар катнашында житди сөйләшүләр булды. Мондый сөйләшүләрнең һәммәсендә Флүс Латыйфи катнашып, бик принципиаль рәвештә журнал линиясен үткәрде. Һәм журналның һәр санында аз булса да латин имласында язмалар, әдәби әсәрләр дөнья күрә.

**Туфан Миңнуллин:** Без әдәби тәнкыйть юлы белән генә журналны тарата алабыз дигән сүз миңа бигүк ошап бетмәде. Бөтенләй башка буын, башка вәзгыять бүген. Шуңа күрә бу мәсьәлә дәүләт тарафыннан идарә ителергә тиеш. Язучылар үз хәлен үзе карасын, реклама, фәлән-төгән дип кенә эш алып барып булмый. Идарә итүнең тарихта мисалы бар. Исландия дигән илдә язучыларны махсус хезмәт хакы түләтеп торалар. Чөнки, бары тик язучыларның әсәрләре аша гына илнең тарихы языла.

Элек райкомга чакыртып алалар да: "Правда"га языласың!"—дип боерык бирәләр иде. "Казан утлары"ның укучылары — өлкән буын. Хакимият, гадәттә, бәйрәмнәрдә өлкән буынга пакет тарата. Аның эчендә бер шешә аракы, бер пачка чәй була. Ә нигә шунда бер журналга язлыру хакында әбүнә квитанциясе кыстырмаска?! Бәясе бик аз—бер шешә аракы бәясе бит! Ә нигә бер китап куймаска? Ярый, бабай укымый да ди. Ә бит аның янында оныгы йөри. Шул китапны күрә, шул журналны күрә ул, кызыксынып сорый... Бирелә Зилә Рәхимжановна булудан файдаланып, шуны әйтәсем килә: без бу турыда инде ничә еллар сөйлибез, бәргәләнәбез, әмма безнең зарны тыңлаучы юк. Матур әдәбиятны тарату һичшиксез дәүләт кулында булырга тиеш!

Әйтик, без Пен-клубта татар язучыларының хикәяләрен инглиз телендә чыгардык. Инглиз язучыларының әсәрләрен өйрәнгәнче, нигә инглиз теле дәресләрендә шушылардан файдаланмаска? Ике яклап файда булыр иде ләбаса!

Мәктәп китапханәләрендә бүген китап юк. Авыл китапханәләре комплектацияләнми. Аларда бу эш каядыр 90 елларда туктап калган. Үзәкләштерелгән китап тарату соңгы ун ел эчендә бөтенләй булмаган... Халыкта акча юк дигән сүз дөрес түгел. Хәйдәр Бигичевка, Илһам Шакировка безнең татар халкы йөрмәде, ә жыен шырдый-бырдый концертларга 300 сумга билет алып бара. Бу—жәмгыятьтәге тотрыксызлык галәмәте. Хөкүмәтнең халыкны әдәбиятка тарту өлкәсендә сәясәте юк. Бу сер түгел. Бу хакта без гел кычкырып торабыз.

Башкортлар моны методик рәвештә эшли—чит өлкәләргә бушка китап тарата. Пермь, Оренбург өлкәсендәге бөтен татарлар башкорт китабы белән тәэмин ителгән, ә татар китаплары юк...

Шушы өлкәдә, безнең хөкүмәт тарафыннан катгый сәясәт булдырылырга, күпме акча кирәклеге исәпләнергә тиеш. Шушыларны белгәннән соң, бу

әйбер ничә миллионга төшкәнен дәүләт алдына куярга кирәк. Ул вакытта сөйләшергә була. Ул вакытта Язучылар берлегеннән, язучылардан таләп итәргә була.

Бүген мин "Казан утлары"ның районнарда таралышы хакындагы мәгълүматларны алдым—иртәгә үк аны хакимият башлыкларына күрсәтәчәкмен. Нәрсә, Апас районының йөз журнал яздырырга хәленнән килмиме? Көлке бит бу! Аларның бер колхоз бәйрәме генә миллион сумга төшә! Акча бар, игътибар житми... Мина калса, Министрлар Кабинетында шундый бүлек булдырылган икән, әлеге эш белән ул да шөгыльләнергә тиеш.

**Миркасыйм Госманов,** ***язучы, галим, Татарстан Фәннәр Академиясе әгъзасы:***

Бүген сүз пропаганда тирәсендә китте. Хикмәт шунда, базар мөнәсәбәтләренә кергәч без монарчы булган бөтен кануннарны ташлап, стихияле эш итүгә күчтек. Ә безнең халык идарә итүгә, житәкләп йөртүгә күнеккән. Бу, бер яктан, әйбәт кебек тоелса, икенче яктан, манкортлык галәмәте. Халыкта инициатива юк. Ә әдәбиятны һәм мәдәниятне стихиялелеккә бирү бигүк дөрес булмас иде. Шунлыктан, бүген администрация башлыкларына да, колхоз рәисләренә дә әйтеп-күрсәтеп торырга кирәк.

Хәзер өлкә комитеты юк, ләкин Министрлар Кабинеты бар. Менә шунда бер хезмәт булдырырга кирәк. Һәм, мөмкин кадәр, пенсиядәге карт чиновникларны утыртып түгел, бу урынга инициативалы яшь кешеләрне билгеләп, аның алдына конкрет бурыч куярга кирәк. Бөтен эш культураны кайгыртуга юнәлдерелергә тиеш. Һәм бу акыл өйрәтүгә генә кайтып калмыйча, конкрет гамәлдә күренергә тиеш.

Минем бер тәкъдимем бар: киләчәктә мондый сөйләшүләргә милли китапханәдән һәм берничә зур китапханәләрдән дә вәкилләр чакырырга кирәк. Чөнки китапханәләрнең трагик хәлен алар бездән яхшырак белә.

Икенче. Китаплар күп чыга. Ләкин мин дә күп китапларны белмим. Журналда "яңа китаплар" дигән бүлек булып, анда кыска-кыска репликалар белән генә ул китапларга бәяләмәләр, информация бирелсен иде.

**Гәрәй Рәхим,** ***шагыйрь, Татарстан халык депутаты:***

"Казан утлары"—ул әле безнең яңа басылган әсәрләребезне халыкка житкерүче генә түгел, бүгенге әдәбиятның нинди юлдан баруын күрсәтүче көзге дә. Әдәбиятыбызны нindидер яңа юлларга алып кереп китүдә ул инде үзе үк зур роль уйный.

Бүгенге сөйләшүдә журналны халыкка нинди юллар белән тарату хакында күптөрле фикерләр булды. Минем дә бер тәкъдимем бар. Дәүләт структурасында бүгенге көндә бу эш белән шөгыльләнүче ике бүлек бар. Берсе—бая әйтеп үтелгән мәдәният бүлеге, икенчесе—газета-журналлар белән эшләү бүлеге. Без теләсә кайсы вакытта аларга мөрәҗәгать итә алабыз. Болар—яңа бүлекләр, болар эшне башлады гына әле. Элегрәк без матур әдәбиятны пропагандаларга Язучылар берлегеннән районнарга чыгып китә идек. Хәзер Язучылар берлегенең дә, "Казан утлары"ның да мондый бригадалар төзеп, районнарга жибәрерлек акчалары юк. Шуның өчен, Министрлар Кабинетындагы әлеге ике бүлек белән бергәләп, шушы бригадаларны төзеп, кайсы районнарга кайчан бару планын билгеләп, барасы районның хакимият башлыкларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мөрәҗәгать ким дигәндә премьер-министрның имзасы белән китәргә тиеш. Районда моңа гына акча бар. Алар сезне үзләре килеп алып, очрашуларны оештырачак. Теләсә кайсы район моны эшли ала.

**Розалина Шаһиева,** ***сәнгать белгече:***

Журнал тарату турында сүз чыккач, гел районнар, авыллар турында гына сөйләштек. Ә бит әле безнең мәдәниятле Казаныбыз бар! Әдәбият

беренче чиратта монда чәчәк атарга, китапчылык монда үсәргә тиеш. Төркиядә, мәсәлән, төрки халыкларның әдәбияты буенча ел саен фестивальләр үткәрелә. Ә нигә аларны бездә дә уздырмаска? Нигә зур итеп татар шигырь конкурслары уздырмаска?

**Равил Фәйзуллин:** Биредә дәреслекләр төзүдә тәҗрибәсе булган галимнәребез катнашудан файдаланып, бер мәсьәлә хакында сөйләшеп үтик әле. "Казан утлары" журналын бер-ике генә сәгать булса да мәктәп программасына кертү мөмкинме? Реаль әйберме бу?

**Фоат Галимуллин:** Безнең хәзерге мәктәп программасында үз төбәкләрендә яшәүче язучылар иҗатын өйрәнү мөмкинлекләре арттырылган. Һәм шушы мөмкинлекләрне инде күп җирдә файдаланалар. Мәсәлән, Кукмара районында махсус программа нигезендә берничә сәгать җирле язучышагыйрьләрнең иҗатын өйрәнү мөмкинлеге булдырылды. Хәзерге җанлы әдәби процессны өйрәнү өчен дә ике-өч сәгать вакыт бирелде.

**Зилә Вәлиева:** Минем мәктәпне тәмамлаганыма байтак еллар үтте. Алай да исемдә, һич тә совет программаларыннан тайпылмыйча барганда да, әдәбият укытучысы ике сәгатьне берләштереп, мөмкинлек табып, шигырь уку оештыра иде. Димәк, укытучы да күп нәрсә эшли ала дигән сүз бу.

**Хатыйп Миңнегулов,** ***филология фәннәре докторы:***

Зилә ханымның сүзләрен куәтләп шуны әйтәсем килә, укытучыларда китапка, "Казан утлары"на мәхәббәтне мәктәпләрдән, югары уку йортларыннан ук тәрбияләргә кирәк. Университетта укыганда журналны алдырган, укыган кеше, гомере буе "Казан утлары"н онытмаячак.

Аннан соң, татар бит Татарстанда гына яшәми. Әйтик, бөтен Идел буе округында милләттәшләребез бар. Рәсми рәвештә, шушы округтагы татар мәктәпләре өчен, татар авыллары өчен ничек итеп журналларны, китапларны житкерергә, ничек итеп татар телендә радио-телевидение тапшыруларын булдырырга—менә шушы эшләрне хөкүмәт югарылыгында оештырырга иде. Без таләп итмәсәк, моны Нижгар өлкәсе яки Пенза кузгатмаячак.

Инде журнал эшчәнлегенә күчик. Мин узган елгы һәм быелгы саннарны чагыштырып утырдым. Күз тимәсен, быелгы журналыбыз, кайбер кимчелекләре булуга карамастан, шактый бай. Яратып укырлык әйберләр байтак. Ләкин, аерым язмаларга карата бәхәс тә бар. Мәсәлән, Вил Ганиевның елъязмасы. Әйбәт материал, жыйнама рәвештә егерменче йөз башы әдәбиятын тасвирлаган. Ләкин, мина калса, болар—һәммәсе билгеле әйберләр. Мин, мәсәлән, моннан үземә бер яналык та алмадым. Әйтик, үзебезнең арадагы берәрсенә шушындый әйберне язарга бирсәләр, моннан тирәнрәк итеп тә эшли алган булыр иде.



*Султан уңга (алгы рәттә): М. Госманов, Т. Миңнуллин, М. Шабаев; арткы рәттә: Р. Шаһиева, Ф. Сафин, М. Вәли, С. Маннапов.*

Икенче. Мирас буенча

бездә материаллар бирелеп барыла. Гаяз Исхакыйның Тукай турындагы язмасын алыйк. Әлбәттә, икесе дә бөек зат. Аларның үзара мөнәсәбәтен белү безгә бик кызыклы. Ләкин, Исхакыйның мәкаләсен биргән вакытта текстологик яктан, сүзләрне аңлату ягыннан шактый кимчелекләр киткән. Әгәр дә авторның җегәре җитми икән, әгәр дә редакциядә эшләүчеләр арасында да моңа теше үтәрлекләре юк икән, бу очракта галимнәргә бирергә иде. Мондый хаталар журналда китәргә тиеш түгел.

Дөнья классикасыннан иң әйбәт әсәрләрне бирү традициясе башланган иде. Мопассан, Байроннар дөнья күрде. Шушы рубриканы югалтмыйсы иде. Чын мәгънәсендә классик әсәрләр татар телендә укучыларыбызга ирешеп барсын. Гомумән алганда, мин үзем журнал эшчәнлегеннән канәгать, алга таба минем теләкләремне искә алып, тагын да камилләшер дип уйлыйм. Чөнки журналның хезмәткәрләре тәҗрибәле, җаваплы кешеләр.

**Зилә Вәлиева:** "Казан утлары"—бүгенге көндә гадәти журнал булып кына калырга тиеш түгел. Ул бүгенге сәясәткә үз фикерен белдерүче, актив позицияле кешеләрне туплый торган бер үзәк булырга тиеш. Тормышта нинди үзгәрешләр бара, алдагы көндә без нишләргә тиешбез, шушы глобаль мәсьәләләрне уртага салып сөйләшерлек бер җаваплы оешма булырга тиеш ул. Аның тарихы, бүгенгесе шуны таләп итә. Монда иң зыялы шәхесләребез җыелган, галимнәр, язучылар, мөхәррирләр... Аларны тагын кайда шушылай җыярга мөмкин? Мин редколлегиянең тагын да активрак эшләвен теләр идем. Чөнки, заманалар башка. Болганчык вакыт. Күпләр җәмгыятьтә үз урынын таба алмыйча бәргәләнә. Кемгә карарга?.. Нәрсә укырга?.. Кем сүзенә ышанырга?.. Әлбәттә, бу очракта язучы сүзе, халык хөрмәт иткән абруйлы әдипнең сүзе аерым бер дәрәҗәгә ия. Һәм халык тормышын, халык язмышын кайгыртырга тиешле кешеләр—язучылар—бу очракта читтә кала алмый.

Татар китабының язмышы бүгенге көндә бик мөһим мәсьәлә. Без аны Дәүләт советы утырышларында дәреслекләр турында сөйләшкәндә күпмедер дәрәҗәдә өйрәнә башлаган идек инде. Бу мәсьәләне аерым өйрәнербез. Бездә бит социаль яклау оешмалары кайбер сирәк даруларны махсус даруханәләрдә сата, бәлки китап белән дә шундый эксперимент үткәреп караргадыр? Бәлки, книготоргта район, авыл җирләре белән эшләүче махсус оешма булдырыргадыр?

Безнең халык укырга омтыла торган халык. Менә бер мисал. Күптән түгел генә кунакка София Гобәйдуллина кайтып төште. Ул яшь вакытында Милли китапханәнең уку залында еш булган. Хәзер дә, "беренче чиратта шунда барыр идем",—ди. Барып кайтты. Икенче көнне очрашабыз, күзе дүрт булган. "Бардым. Бөтен нәрсә таныш, кадерле, тик ишекне ача алмыйм",—ди. "Нигә?"—димен. "Анда китап укырга чират,—ди,—Кеше күп. Чит илдә, шул ук Алманиядә андый чиратлар юк. Китап укуга ул кадәрле әһәмият бирмиләр..."

Димәк, безнең халыкта китапка сусау, әдәбиятка сусау бар әле.

**Равил Фәйзуллин:** Утырышыбызда катнашкан милләтебезнең асыл егетләре-кызларына чын күңелдән рәхмәтебезне җиткерәм. Алга таба да бергә-бергә эшләргә насыйп булсын.

*Журнал өчен А. ГЫЙМАДИЕВ әзерләде*



## Мәхмүт Әхмәтҗан

# СӘЯСИ УЙЛАНУЛАР

## Октябрь революциясе һәм аның сабаклары

МАРКСИЗМ тәгълиматына таянып фикер йөртсәк, тарихка «Бөек Октябрь социалистик революциясе» дип кергән олы вакыйга Россиядә булмаска тиеш иде. Чөнки Маркс үзе үк «һәрьяклап алга киткән, ө иҗтимагый мөнәсәбәтләр артта калган җәмгыятьнең үсешендәге каршылыкларны тик революция генә хәл итә ала»,—дип өйрәтә. Инде Россиягә килгәндә, анда әлеге алшартларның берсе дә булмаган.

Революциядән соң төзелгән социализм—җир оҗмахы—коммунизмның беренче фазасы булырга тиеш иде. Бу җәмгыятьтә халыкның абсолют күпчелеге бәхетле, һичбер кайгы-хәсрәт күрмичә көн итәчәк, коммунизмга күчү өчен кирәкле бөтен шартлар тудырылачак, дип өйрәттеләр безне.

Кимендә ике сорау туа: «тиеш булмаса да» ни өчен ярымфеодаль, «халыклар төрмәсе булган» Россиядә социалистик революция булган һәм җиңгән? Икенче сорау: социалистик революция үз алдына куелган бурычларны үти алдымы һәм моңа ничек иреште? Бу сораулар һич те риторик түгел.

«Хакимият элеккечә идарә итә алмый, ә халык элеккечә яши алмый һәм әнә шул вәзгыять революцион шартлауга китерә»—Ленин шулай дигән. Моны безнең башка нык сеңдерделәр һәм ул фикер, нигездә, дөрестер дә.

Россиядә 1861 елда крепостное право бетерелсә дә, ил халкының 80 процентын тәшкил иткән крестьяннар һаман да бик авыр шартларда яшиләр, җир аларныкы түгел, алпавытлар, латифундистлар кулында, эшчеләрнең хәле дә җиңел түгел иде. Менә шул чынбарлык 1905-1907 еллар революциясенә китерә дә инде. Әмма, хакимият урынында калса да, бертөрле дә уңай үзгәрешләр күренми—Россия «балчык аяклы колосс» булуын дәвам итә. Табигый, халык арасында канәгатьсезлек үсә бара һәм шуның нәтиҗәсе буларак, 1917 елның февралендәге буржуаз революция бөтен илне тетрәтә. Николай II тәхетеннән ваз кичәргә мәҗбүр була. Халык зур үзгәрешләр көтә. Әмма яңа хакимият—урыс

буржуазиясе элекке сәясәтне дәвам итә—крестьяннарга җир бирелми, сугыш туктамый, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы танылмый...

Озакка сузылган сугыш халыкның тормыш-көнкүрешен бик нык кыенлаштыра. Һәм большевиклар бу вәзгыятьтән бик оста файдалана. Фронтта да, тылда да аларның лозунглары «Халыкларга—тынычлык», «крестьяннарга—җир», «эшчеләргә—завод-фабрикалар», «милләтләргә—үзбилгеләнү хокукы» дигән алдавыч сүзләр була. Әлбәттә, халык бу вәгъдәләргә ышана һәм большевиклар артыннан китә. Шулай итеп, 1917 елның октябрендә илдә моңарчы күрелмәгән түнтәрелеш була. Шунысы игътибарга лаек, вакытлы хөкүмәтне кулга алганда бер генә кеше дә һәлак булмый. Мәйданы 23 миллион кв. км. тәшкил иткән Россиянең бик күп почмакларында түнтәрелеш яклау таба. Мәсәлән, Казанда да шул ук көнне хакимлек большевиклар кулына күчә. Халык большевиклар программасын үзенеке дип кабул итә. Татарларны алсак, алар 1552 елдан соң беренче мәртәбә үзебезчә яшәү өчен шартлар туа дип куаналар.

Менә шушы шартларда большевикларның халыкка «җир оҗмахы» вәгъдә итүе бик күпләрне «йокыдан уятты», бер сафка бастырды. Әмма, ни кызганыч, бу очракта да халыкның өмете бик тиз өзелде. Большевиклар үзләрен патша заманнарына караганда да, шовинистрак итеп күрсәттеләр. Сүз уңаенда гына әйтеп узыйк: Европа, Азия илләрендә «буржуаз», «буржуаз-демократик революция» дигән төшенчәләрне күпертеп сөйләмиләр. Хәер, «буржуа» сүзе «бург—шәһәр» дигәннән алынган. «Капиталист» сүзе дә әллә нәрсә түгел, капитал—байлык дигәнгә кайтып кала.

Хаклык шунда: илдә байлар күбрәк булган саен, халыкның тормышы җиңеләя төшә. Татар байлары—Апанаевлар, Юнысовлар һ. б. күпләр мәдрәсәләр ачкан, мәчетләр төзегән. Кызганыч, бүген андый меценатлар күренеп тормый. Җыеп кына әйткәндә, «социалистик революция» башында торган большевиклар үзләренең вәгъдәләрен үтәү турында уйламый да, «вак халыкларның беркатлылыгыннан» кычкырып көләләр генә. Сталин Ленинга язган бер хатында милли коммунистларның (мәсәлән, Мирсәет Солтангалиевның) «большевистик сәясәтнең нәрсә икәнен белмәвенә» гаҗәпләнә. (Соңыннан Сталин фәрманы белән, М. Солтангалиевны башта 1922 елда ук кулга алып тинтерәтәләр, ә 1940 елда атып үтерәләр.) Шулай да, иҗтимагый хәрәкәтләрнең асылына төшенү өчен, Европада булган кайбер революцияләр һәм аларның нәтиҗәләре турында кыска гына мәгълүматлар белән танышыйк әле.

Европада беренче зур революция XVII гасыр уртасында Англиядә була. Халык аңа бик теләп катнаша, чөнки илдәге бөтен җирләр латифундистлар кулында була, алар эшчеләрне бик нык кыерсыталар... Бу революция ярты юлда тукталып кала. Корольнең башын кисәләр дә, яңа король итеп Голландиядән Эразм Роттердамский дигән күренекле зат чакырыла. Революция башлыгы Оливер Кромвельнең сөякләрен каберennән казып алып асып куялар. Яңа корольнең хакимлеге күбрәк сүздә генә була, чын хакимият парламент һәм хөкүмәт кулына күчә. Бу хәзер дә шулай—Елизавета II дәүләт эшләренә тыкшынмый. Елына бер мәртәбә хөкүмәт әзерләгән мөрәҗәгате белән парламентта чыгыш ясый, үзенә күрә хөкүмәтнең эшчәнлегенә йомгак ясый, яңа елга бурычлар куя.

Иң мөһиме шул: закон алдында монархларның да, башка кешеләрнең дә җаваплылыгы бер дәрәҗәдә.

Без урта мәктәптә тарих дәресләрендә «бөек француз буржуаз революциясе» дип өйрәнгән вакыйга 1789 елга туры килә. Корольләр хакимиятенең символы булган Бастилияне (сәяси тоткыннар ябыла торган төрмә) алу һәр елны Франциядә зур милли бәйрәм буларак билгеләп үтелә. Конституция буенча Франциядә президентның да, гади французның да хокуклары бертигез. Халык үзенең теләгенә—демократиягә ирешкән. Бу илдә, гомумән, законнан өстен булу мөмкин түгел. Ә Россиядә, хакимият башында кемнәр торуга карамастан, законнарны үтәргә уйлаучы да юк. Бу бигрәк тә хакимияткә большевиклар килгәч ачык чагылды. «Совет Конституциясе» дөнья конституцияләре стандартына туры китереп эшләнгән булса да, аның мөһим маддәләре бөтенләй үтәлми килде.

Илдә дүрт елга сузылган гражданнар сугышы барды. Чөнки большевиклар хакимиятне беркем белән дә бүлешергә, коалицион хөкүмәт төзергә теләмәделәр. «Завод-фабрикалар—эшчеләргә!» шигаре дә буш вәгъдә генә булып калды. Аларның хуҗасы, димәк, предприятиеләрнең табышы—тулысы белән дәүләтнеке иде.

Авыл хуҗалыгын алсак та, шул ук хәл. Ленин исән чакта, НЭП сәясәте вакытында, авыл хуҗалыгы зур уңышларга ирешә, чит илләргә икмәк һ. б. чыгару мөмкинлеге туа. Ләкин Ленин үлгәч, Сталин НЭПны юкка чыгара. «Шәһәрләрне, промышленностьны икмәк, чимал белән шәхси хуҗалыклар гына тәэмин итә алмый» дигән сылтау белән күмәк хуҗалыклар—колхозлар төзелә, ә иң эшчән авыл кешеләрен, «кулак» мөһере сугып, Себергә, тундрага озаталар. Шуннан соң авыл хуҗалыгы азыкларын әзерләү нык кими. Әмма иң аянычы шунда: авыл кешесе бушка эшләргә мәҗбүр ителә. Колхоз соңгы бөртегенә кадәр икмәкне дәүләткә бушлай тапшыра башлый. Колхозчының хәле крепостной крестьянныкыннан да начарлана, чөнки патша заманында крестьянга мал тоту чикләнмәгән була. Ә колхозчыга бер сыер, ике сарыктан башка мал тотарга рөхсәт юк иде. Моның өчен ул дәүләткә бушлай 50 кг ит, 400-500 литр сөт, 100 йомырка, ике тире тапшырырга, салым түләргә, заемга язылырга тиеш иде. Сталин, гомумән, авылны кан дошманы итеп күрде, авыл «вак буржуаны—кулакларны» үстерә дип карады. Шулай итеп, авыл халкын җирдән тәмам биздереп бетерделәр.

Милли сәясәткә килгәндә исә, большевиклар үзләрен чын-чынлап урыс шовинистлары итеп күрсәттеләр. «Милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы» дигән сүзләрне искә төшерүчеләрнең урыны зинданда иде. Күпләрен шундук юк иттеләр. Мисал өчен еракка китми, татар халкының язмышын гына алыйк. Татар халкы социалистик революцияне үзенеке дип кабул итте, аның җиңүе өчен күп кан түкте. Урта Азиядә «басмачылар хәрәкәте» дип аталган халык баш күтәрүен, никадәр үкенечле тоелмасын, татар егетләре, ике татар бригадасы бастырды, алар чын күңелдән «интернациональ бурычны үтәдек» дип ышанды. Моның өчен үзбәкләр безгә бүген дә нык үпкәлиләр һәм, нигездә, алар хаклы. Чөнки урыс большевиклары «басмачы» дип атаган кешеләр беркем җирен дә басып алмаган, үзләренең азатлыгы өчен генә көрәшкән иделәр. Мөселман халыкларын, төрки халыкларны бер-беренә каршы сугышырга җибәрү һич тә очраклы хәл түгел, ул йөз еллар буе дәвам иткән сәясәт.

Әгәр 1917 елда булган февраль революциясе үз бурычын ахырына кадәр үтәсә, мөгаен, татар халкының да язмышы бөтенләй башка булыр иде. Мәгънәсе болай: Февраль революциясеннән соң, киң хокукларга ия булган автономия—«Идел-Урал штаты» төзү мәсьәләсе көн тәртибенә куелган иде инде. «Штат» төзелү хакында рәсми белдерү Казанның бүгенге Ирек мәйданында ясалырга тиеш булса да, аның җитәкчеләрен төнлә кулга алалар. Алар арасында Мирсәет Солтангалиев та була... Мәскәү болай ди: «штат» статусы ул буржуаз илләр өчен генә хас. Без исә Татар-Башкорт республикасы төзиячәкбез»,—ди. Әмма монысы да гадәттәгечә чеп-чи ялган булып чыга. Өстәп, тагын шуны гына әйтәсе кала: Татарстан Республикасы төзелгәндә кимендә ике миллион татар чит төбәкләрдә торып калды. Бу махсус рәвештә шулай эшләнде, икенче төрле әйткәндә, бу адым шовинистик сәясәтнең классик үрнәге булып тора... Хәер, моны һәркем дә белә: «Татарстан АССР» дип аталган ясалма республиканың бер генә хокукы да юк иде. Бер-ике мисал китерик: Татарстан җиреннән Үзәк ел саен бушлай 102 миллион тоннага кадәр нефть суыртып ала килде, ә үзебезнең нефть эшкәртү заводыбыз да төзелмәде. Ярты республика җирләрендә газ, айлар-еллар буе янып, һаваны җылытып торса да, бер генә авылга да газ кертелмәде. Татарстанда җыела торган салымнар барысы да тиененә кадәр Үзәккә китә иде. Хәлбуки, моңа охшашлы мисалларны тагын да күпләп китерергә булыр иде.

Шулай да сорау туа, Бөек Октябрь революциясенең уңай яклары бар идеме? Һичшиксез, бар иде. Мәсәлән, җир шарындагы башка илләрнең халыклары өчен урыс революциясе зур сабак булды: җитәкче даирә-

ләр: «Әгәр халыкны соң дәрәҗәгә җиткерсәң, изсәң, аның Россиядәге кебек революция ясау ихтималы бар. Ә бу исә миллионнарча гаепсезләрнең һәлак булуына китерер иде»—дигән нәтиҗә ясадылар. Гади халык та «социалистик революциянең» нинди бәла-казаларга бәйле икәнен аңлый башлады.

Совет чорында СССР дип аталган урыс империясе көчле хәрби дәүләткә әверелде. Сәнәгать бик нык үсте. Ул, үз чиратында, инженер-техник хезмәткәрләрне күпләп әзерләү ихтыяҗын тудырды. Күпсанлы урта мәктәпләр, техникумнар, вузлар ачылды. Әдәбият, сәнгать (янәсе, «эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли») үсте. Эшсезлек юкка чыкты. Болар—уңай күренешләр. Әмма алар, һәммәсен бергә җыеп исәпләгәндә дә, канлы большевистик режим кылган явызлыкларны аклый алмыйлар иде. Шул уңайдан, сүзне А. Н. Яковлевка бирик (КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы аны сәяси репрессия корбаннары эшләрен тикшерү комиссиясе рәисе итеп тәгаенләгән кеше). Ул әле дә шул вазифасын үти. Ул болай ди: «Гаделлек, туганлык, тигезлек» дигән матур җырлар белән фашистик-большевистик идеологияле диктатура урнаштырылды... Кешеләр каны һәм сөяге белән тулган «җир астына» адымлап төшкән саен элекке романтика, җилдәге төтендәй, очып юкка чыга. Наданлыкны бетерү, галәмгә очу кебек күп кенә казанышларның берсе дә кешене шундый рәхимсез явызлык белән һәм физик, һәм рухи рәвештә юк итүне аклый алмый» (тәрҗемә безнеке. М. Ә.). Мөгаен, ул чор турында моннан да яхшы әйтеп булмыйдыр.

## Террорчылык һәм аның сәбәпләре

2001 ЕЛНЫҢ 11 сентябрендә, АКШның иң зур шәһәре Нью-Йоркта, иртәнге 8 сәгать 45 минутта, халык эшкә ашыкканда, бөтенләй көтмәгәндә, ике «Боинг» самолеты 110 катлы ике бина-манарага (аларда Халыкара сәүдә үзәге урнашкан иде) бәреп керде. Самолетларда йөзәр тонна ягулык булган, шуңа күрә әлеге биналарны күз ачып йомганчы ут камап алды. Шунда бер гаепсез 6 меңгә якын кеше һәлак булды. Ярый әле, барлык хезмәткәрләр дә эшкә килеп өлгермәгән булалар, югыйсә үлүчеләрнең саны 50 меңгә кадәр җитәр иде... Шундый ук бер самолет шул ук вакытта АКШның башкаласы Вашингтонда урнашкан Пентагон бинасы өстенә (анда оборона министрлыгы урнашкан) барып төште, 100дән артык гаепсез кеше һәлак булды. Самолетлардагы йөзләрчә пассажирлар да гаепсез килеш харап булдылар...

Көтмәгәндә ясалган мондый һөҗүмнәр террорлык акты дип атала. Аны аерым кешеләр дә, дәүләт күләмендә дә башкарырга мөмкин. «Террор» ул латин сүзе һәм нык куркыту, котны алу дигәнне аңлата. Латин теле бик борынгы, үле тел. Димәк, террорчылыкның башы борынгы заманнарга барып тоташа икән. Кайчак террор алдан сөйләшенеп оештырылган мәкер рәвешендә дә була. Мәсәлән, Рим империясенең аеруча атаклы императоры Гай Юлий Цезарьны үз даирәсендәге кешеләре үтерә. Мондый мисалларны Европа илләре, Россия монархлары тормышыннан да китереп булыр иде... XIX гасыр урталарында «народоволецлар» дип аталган революционерлар патшаларны, аларның якыннарын террор юлы белән юк итеп, хакимиятне алмаштырмакчы булалар. Шуларның берсе Ленинның абыйсы—Александр Ульяновны террорга катнашкан өчен асып үтерәләр.

Террорны аерым кешеләр генә башкара икән дип уйлау дөрес булмас иде. «СССР тарихы»н өйрәнгәндә, без совет хакимиятенең «ак террорга каршы кызыл террор игълан итүен» һәм шуны «тимер куллар» белән тормышка ашыруын белә идек. Ул күренеш «тимер Феликс» Джержинский вакытында киң колач алып совет чорында даими дәвам итте. Рәсми мәгълүматларга караганда, большевистик тоталитар система 66,7 миллион кешенең башына җиткән. Ә 2001 елның ноябрь аенда Мәскәүнең НТВ телевидениесе оештырган бәхәстә катнашкан Ирина Хакамада (Дәүләт думасының вице-спикеры), большевиклар 95 миллион кешене үтергәннәр дигән белдерү ясады. Мөгаен, ул атылган, ГУЛАГта

черетелгәннәрнең гаиләләрен дә истә тотып әйткәндер. Һәрхәлдә, шул ук дискуссиядә катнашкан Россия коммунистлары җитәкчесе Г. Зюганов Хакамадага үзеп җавап бирә алмады.

Инде Нью-Йоркта һәм Вашингтонда булган террор вакыйгаларына килгәндә, нинди генә уй-ният белән эшләнмәсеннәр, аларны һич кенә дә аклап-яклап булмый. Шунсы гына гаҗәпләндерә, яхшылап тикшермичә, төрле фаразларга таянып кына, аларны мөселман динендәге гарәп кешеләре оештырган, башында миллиардер Уссәмә бән Ләдин тора, дип АКШ президенты Джорж Буш игълан итте. Нәтиҗә бик күңелсез: Америкада яшәүче гарәпләргә һөҗүмнәр оештыру, мәчетләр яндыру кебек вандализм күренешләре булып алды. Бу хәлне көтмәгән президент Буш, акылына килепме, мәчетләрдә булып, халыкны исламга дошманлык кылмаска чакырды.

Ислам һәм христиан диннәре арасындагы аңлашылмаучылыклар күптән килә. Христианнар күп мәртәбәләр Якын Көнчыгышка тәре походлары оештыра. Әле дә христиан миссионерлары исламның көчәюенә борчылуларын яшермиләр. Чөнки моннан 150 еллар элек ислам динен тотучыларның саны 300 миллионнан артмаса, бүген бу сан миллиард ярымга җитте (Христианнар да шул чамада. 3 миллиард буддачылар бар. Яһүд динен тотучылар күп түгел). Һәм исламның үсү мөмкинлеге шактый көчле. Дөресен генә әйткәндә, ислам бервакытта да башка диннәргә каршы көрәшмәде. Тарихка күз салсак та, шуны күребез, ислам диндәгеләр бервакытта да чиркәүләргә, синагогаларга, будда храмнарына тимәгәннәр. Бу аңлашыла да: ислам үзенә кадәр булган барлык пәйгамбәрләрне, мәсәлән, Ибраһим, Муса, Гайсаны, аларның китапларын таный. Ә алар нигезләгән диннәр бөтенләй башка юлдан бара. Казан губернасында гына да, христиан дине әһелләренең әмере белән йөзләрчә мәчетләр җимерелгән, яндырылган. Көчләп чукындыру гадәти күренеш булган. Ә ислам беркемне дә көчләп үз кочагына алмый, ислам диненә көчләп кертү—зур гөнаһ итеп санала. Димәк, террорчыларны ислам динендәге кешеләр генә дип расларга тырышу—сәяси алым гына! Инде кемдер үзен ислам әһеле дип атап, террор ясый икән, ул асылда бу дин вәкиле түгел!

Ничек кенә үкенечле булмасын, «форсаттан файдаланып», Россия җитәкчеләренең дә кайберләре ваһабчыларны сылтау итеп, «ислам фундаменталистлары», «ислам экстремистлары» турында сөйләнә башладылар. Инде ил күләменә килгәндә, Россиядә төп ике конфессия вәкилләре—христианнар һәм мөселманнар яши. Һәм, тыкшынучылар булмаса, тыныч яши.

Террорчылыкны барлык илләр дә, нигездә, гаепләп чыга, куркып та, гаҗәпсенеп тә, аны бетерү юллары турында баш вата. Мәсәлән, Европа парламентлары ассамблеясе рәисе лорд Россел Джонстон «Общая газета»га биргән интервьюсында (2001 ел, ноябрь, № 44), Россиянең Чечняда алып барган террор хәрәкәтләрен гаепләп чыкты, тыныч халыкны кыруны туктатырга чакырды.

## Татар-башкорт мөнәсәбәтләренең «анатомиясе»

БУ ЯЗМАГА исемне француз язучысы Эрве Базенның «Бер аерылышуның анатомиясе» исемле китабына ияреп бирдем... Мәгънәсе: мантыйк буенча фикер йөрткәндә, татар белән башкорт арасындагы мөнәсәбәтләр ал да гөл булырга тиеш иде, чөнки гадел караганда, бу ике халыкны аера торган бер генә сәбәп тә юк, ә берләштерә торганнары—бихисап. Һәм сүзне әнә шул юнәлештә алып бару һәрьяклап отышлы булачак.

Башкортстан көньяк Уралга—дөньядагы иң матур җирләрнең берсенә урнашкан. Мәйданы—144 мең кв. км. (Татарстанның—68 мең кв. км.), халкы 4 миллион чамасы (Татарстанда 3 миллион 800 мең чамасы). Башкортстанда елгалар, күлләр бик күп. Мәсәлән, Агыйдел, Караидел, Дим, Ык, Сим, Әй, Йөрүзән, Сөн, Сакмар кебек елгалар әллә күпме җырларда

мактала. Табигать, чыннан да искиткеч матур һәм бай. Бигрәк тә Уфадан Чиләбе ягына киткәч, бихисап тайга урманнары, аланлыклар, болыннар сузыла. Бу гүзәллекне күргән кешеләр: «Башкортстан Европаның иң матур урыны саналган Швейцариядән күпкә матуррак»,—дип әйтергә ярата.

Туганлык ягына килгәндә, телләребез бик якын. Бер-беребезне аңлау өчен тылмач кирәкми. Дөньяда башка мондый халыклар юк диярлек. Мордовия республикасын гына алыйк. Паспортларына «мордва» дип язсалар да, бу халык бер-беренең телен аңламый торган эрьзя һәм мукшылардан тора. Мариларда да шундый үзенчәлек бар. Ә башкорт белән татар бөтенләй башка. Шул уңайдан Баязит Бикбайның «Карлыгач» драмасындагы бер җырын ике телдә китерәм:

Түңәрәк күл матур була,
Һыу менән тулһа гына;
Кыд бала тыуһын дөньяга,
Бәхетле булһа гына.

Татарча болай:

Түгәрәк күл матур була,
Су белән тулса гына;
Кыз бала туСЫН дөньяга,
Бәхетле булса гына.

Башкорт дәүләт академия театры, Башкорт яшьләр театры Казанда спектакльләр куйганда заллар тамашачы белән тула. Һәм бу тикмәгә генә түгел... Дин, бик күп әхлак кануннары уртак. Тарихи охшашлыклар да житәрлек. Катнаш никахларның исәбе-хисабы юк. Ике республиканың да җир өсте һәм җир асты байлыклары күпләрне кызыктырырлык. Җыеп кына әйткәндә, татарлар белән башкортларга үзара ямьсезләнер эшләр кылу өчен бер генә сәбәп тә юк. Әмма, ни кызганыч, бу ике халык-милләт арасында аңлашылмаучылык бар һәм аны яшерүдән беркемгә дә файда юк. Бу хәлнең сәбәпләрен белү өчен, бераз гына булса да, тарихка мөрәҗәгать итик.

1917 елда февраль революциясе җиңгәч, татар-башкорт халкының күптәнге хыялын—Россия составында киң хокукларга ия булган автономия төзү телөген тормышка ашыру өчен уңай шартлар туа, «Идел-Урал штаты»н төзү чынга ашардай төс ала. Мөгаен, бәхетебез булмагандыр: большевиклар хакимияткә килгәч, бу омтылышны челпәрәмә китерәләр, халыкны алдыйлар: янәсе «штат» идеясе буржуаз илләргә хас күренеш, шуңа күрә аның урынына Татар-Башкорт республикасы төзеләчәк...

Урыс хакимияте гомер-гомергә татар белән башкортның берләшүеннән, үзара якынаюыннан уттан курыккандай курка килгән. Әби патша—Анна Иоановна башкорт кызларын татар егетләренә ярәшүне тыя торган фәрман чыгара. Мәскәү әле бүген дә Уфа белән Казан арасына чөй кагу сәясәтен дәвам иттерә.

Югыйсә, татар халкы башкорт халкын бик якын күрә, аңа бер генә начар сүз әйткәне дә юк. Ни кызганыч, Уфада хәлләр бөтенләй башкача. Башкортстан массакүләм мәгълүмат чаралары, кайбер язучылар, галимнәр ачыктан-ачык итеп татарларны хурлый торган чыгышлар ясыйлар. Моның белән, мәсәлән, «Башкортстан» газетасы, башкорт телендәге яшьләр газетлары шөгыльләнә.

Айдар Хәлимнең «Книга печали...» китабын (ул аны Литваның башкаласы Вильнюста бастырды) күпләр хәтерлидер. Анда сүз татар мәктәпләрен башкорт телендә укытуга көчләп күчерүләр турында да бара. Мондый хәл СССРның башка бер төбәгендә дә булмады. Ә Уфа, Мәскәүнең татарларга карата нинди сәясәт алып баруын белә торып, үзе дә шуны кабатлау юлына басты. Уфада яшәүче татарларның саны һич тә Казандагыдан ким түгел. Казанда татар мәктәпләренең саны хәзер илле икегә житсә, Уфада татар мәктәпләре бөтенләй юк. Балалар бакчалары белән дә хәлләр шулайрак тора... Мәскәү әнә шундый астыртын уен уйный, башкортлар шуңа кул чабып тора...

«Татарларның чынлыкта кем икәнлекләрен ачыклау белән» кайбер

башкорт язучылары, галимнәре дә шөгыльләнә. Үз вакытында шуларның берсе—Әкрәм Бейешнең «Башкорт халкының тарихы һәм азатлык көрәше» дигән китабы турында язылган иде инде. Уфада 30 мең тираж белән «Китап» нәшриятында басылган 13 табаклы бу «фәнни хезмәттә» кеше ышанмаслык кына түгел, гомумән, дөреслеккә аз гына да якын килмәгән «фактлар» бәян ителгән. Филолог галим, оят тезгенен бөтенләй бушатып, татар халкы адресына пычрак арты пычрак ата. Һәм әлеге «фактларның» берсе дә документларга нигезләнмәгән. Авторның татарларга нәфрәте шул кадәр көчле ки, ул, «гомумән, татар дигән милләт юк, монголларга ияреп килгән килмешәкләр урыс халкы арасында эреп беткән; татарларда бервакытта да дәүләтчелек хисләре булмаган, автономияне дә аларга башкортлар гына юллап алып биргән; килмешәк татарлар башкорт җирләренә килеп утырганнар гына түгел, бик күп җирләрне урысларга сатканнар» дип яза. Әкрәм Бейешкә ышансак, башкорт ханнарын татарлар кырып бетереп торган. Әмма гади генә сорау туа: революциягә кадәр бервакытта да башкорт ханлыгы булмаган—монысы тарихтан билгеле. Соң, шулай булгач, нинди ханнар турында сүз булырга мөмкин? Автор ахыр чиктә мондый «ачыш та» ясый: татар дөньяга бары тик бер максат белән—башкортны юк итү теләге белән туган, ул аны кайда күрсә, шунда—урамда, урманда, мунчада, ишек алдында, юлда һ. б. урыннарда үтерә килгән. Шуңа күрә генә башкортлар аз санлы булып калганнар, имеш...

Әгәр татарлар турында «тузга язмаганны» язучы бер Бейеш кенә булса, сүз дә кузгатып тормас идек...

Тагын бер нәрсәне искә төшерик әле: 2001 елның җәендә Башкортстан Республикасының премьер-министры Р. Байдәүләтов Казанда булды. Аны иң югары дәрәҗәдә каршы алдылар. Башкортстан хөкүмәте җитәкчесе тәкъдиме белән, Татарстан үзенең нефтен Уфа нефть эшкәртү заводына озатачак, моның өчен Татарстан билгеле күләмдә ягулык алачак, һәм, үз чиратында, Башкортстан өчен кирәкле булган күп нәрсәләрне үт күршеләргә сатачак дип килешенде. Җавап төсендә Татарстанның премьер-министры Р. Миңнеханов Уфада булып, шул мәсьәлә буенча өстәмә сөйләшүләр дә алып барды. Ә бераздан Татарстан президенты М. Шәймиев белән Башкортстан президенты М. Рәхимов Актанышта очраштылар, үзара икътисади мөнәсәбәтләрне тагын да тирәнәйтү турында сүз куештылар.

Шушы сөйләшүләрне гамәлгә ашыру нияте белән, Татарстан хөкүмәтенең вице-премьеры Когогин җитәкчелегендәге бер төркем белгечләр Уфага юл тотты. Әмма «Башнефть»нең хуҗасы Урал Рәхимов (БР президенты Мортаза Рәхимовның улы), безнең делегация белән сөйләшеп тә тормыйча, аны кире борып кайтарды. Хәтта: «Татарстан нефтьчеләренең квалификациясе түбән»,—дип әйтүдән дә тартынмады. Бу бит чеп-чи ялган: Татарстан нефтьчеләре Себер киңлекләрендә эшли, Гыйрак, Иран, Ливия һ. б. илләрдә дә нефть чыгару өлкәсендә ярдәм итә.

Минем фаразым болай: Уфа, нефть эшкәртү буенча Казан белән сөйләшкәндә үк, моның ни белән бетәсен яхшы белгән. Ә «спектакль» исә Мәскәү өчен куелган, аны «өркетү өчен» эшләнгән. Янәсе, «сез Уфаның кадерен белмәсәгез, Рәхимовка өченче срокка сайланырга рөхсәт итмәсәгез, без татарлар белән берләшәчәкбез»... Ә Мәскәү, чыннан да, мондый килечәктән курка, чөнки көчле сәнәгате булган бу ике төбәк берләшсә, Үзәк белән аяк терәп сөйләшә башлаулары да мөмкин... «Татар-башкорт мөнәсәбәтләренең анатомиясе» әнә шуңа барып тоташа.

**РЕДАКЦИЯДӘН:** *Февраль аенда галим һәм язучы-публицист Мәхмүт ага Әхмәтҗанга 75 яшь тула. Аны олуг юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз, ныклы сәламәтлек һәм иҗатында яңадан-яңа уңышлар телибез.*

# ҖАНЫНДА ХАЛЫК ГАМЕ

ӘХМӘТ ГАДЕЛГӘ 60 ЯШЬ

**1942** елның җилле-буранлы, карлы-болытлы феврале. Ватан сугышының тәүлеге елына торырлык, ил язмышы кыл өстендә тирбәлгән авыр, фаҗигале көннәре. Татар һәм башка милләтләрнең чибәр, назга мохтаҗ хатыннарын, буй җиткән, әмма каһәр орыш котырынуы нәтиҗәсендә гаилә кора алмыйча калган Гөлҗамалларын, меңнәрчә балаларны ятим иткән өчпочмаклы, кара мөһерле хатларның еш килгән һәм шулай да инде немец фельд-маршалы Паулюс армиясенең Идел буенда билен сындырган сөенечле дә вакыт. Авыр сынау мизгелләрендә дә мәңгелек тереклектә өзеклек була алмый, хаят, берни белән санашмыйча, үз кануннарын куа, дөньяга көрәшчеләрнең дәвамчыларын



китереп, кендек каннарын җиргә тамыза тора. Әйтик, 1941 ел татар поэзиясе өчен аеруча уңдырышлы булды (Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Харис кебек куәтле шагыйрьләр дөньяга килде)... «Без—кырык икенче ел балалары» дип, авыз тутырып әйтерлек булмаса да, сугышның икенче елы да татар әдәбиятына миһербанлы булды, берничә иҗади шәхесне бүләк итте. Айның беренче көннәрендә (икенче февральдә) Мамадыш төбәгенең Ак Чишмә авылында, мулла соңрак Әхмәт дип исем кушкан бала дөньяга килә. Нинди шигъри атама: көмеш күбекләрен өскә чәчә-чәчә чылтырап аккан чишмә, әле үзе җитмәсә Хозыр Ильяс сакалы кеби ап-ак. Караңгылык пәрдәсен ерып таң атканда шәрран ярып үзе турында җиһанга хәбәр биргән малай исә чүл гарәбе кебек чем кара. Ак янында кара... Башка төсләр шуларның төрлечә кушылмасыннан хасил була, диләр. Ак чишмә кырында кара малай. Шундый исемле авылдан шагыйрь чыкмаса, гаҗәп булыр иде. Алгарак китеп булса да, шуны искәртәсе килә: Әхмәт Гадел дигән шагыйрь, язучы иҗатына хас чуар төсләр уены, көйгә, моңга күчкән чишмә тавышы, адашкан бураннар шәүләсе, яшерен серлелек, контрастлар уены, көтелмәгән аллегорик нәтиҗәләр дә шуннан килә торгандыр. Осталыкның серен «балачактан эзлә» дип юкка гына әйтмәгәннәрдер безгә чаклы яшәгәннәр. Кем уйлаган, заманалар узгач, шул бөтерчек хәтле малайдан ирләрчә тулырак йөзле, беркадәр астан карый торган җылы, мәгънәле, кара-коңгырт күзле, аерылган кара болыт кисәгедәй озын кашлы, борчак коймагыдай калын иренле, олпат гәүдәле ир, шагыйрь, прозаик, драматург, кино либретточысы, тәрҗемәче Әхмәт Гадел үсеп чыгар дип! Дөрес, әнисе гаиләсен, нужа бабай арбасына утыртып, шигъри исемле авылдан тиз алып китә. 1946 елда исә җиңүче булып, татар атына атланып кайткан атасы, урман белгече буларак, Саба районының Әбде урман хуҗалыгына күчерелә. Урманчыларны (башка һөнәр ияләрен дә, мәсәлән, укытучыларны, табибларны) ул елларда, тамыр җибәреп өлгермәсеннәр диптер инде, гел

урыннан-урынга күчереп торганнар. Саба, Тәкәнеш, Балык Бистәсе, Алексеевск районнары, булачак иҗатында эз калдырган Шомыртбаш авыллары пәйда була. Сугыш яралары дөньядан иртә алып киткән әтисенең күчмә тормышка тартым холкын Әхмәт тә үзенә сеңдерә һәм илләр буйлап сәяхәтен дә дәвам иттерә. Ул «бәхетле иткән» олы төбәкләрне генә атап үтик: Германия, Ташкент, Кырым, Түбән Кама, Тольятти, Казан, Мәскәү... Ә инде хезмәт иткән урыннарын, һөнәри белгечлекләрен атый-саный калсаң, искитмәле. Малай чакта урыс һәм татар телләрендә мәктәп белеме ала, әтисенә ихтирам йөзеннән, Лубян урман техникумын тәмамлый, шуннан китә хезмәт дастаны: район газетасы хәбәрчесе, мәктәптә немец теле укытучысы, производство гимнастикасы инструкторы, слесарь-монтажчы, тракторчы, компрессорчы, Казан радио-телевидениесе тәрҗемәчесе, халык иҗаты йорты хезмәткәре; унбер ел дәвамында мәдәният министрлыгында әүвәл инструктор, аннан бүлек мөдире, «Социалистик Татар-стан» гәзите хәбәрчесе, Татарстан кинокомитетының баш мөхәррире. Язучылар берлегенең әүвәл әдәби фонд директоры, аннан рәиснең беренче урынбасары була... Әмма иҗади хезмәт һәрчак беренче урында тора: татар, кырымтатар һәм урыс телләрендә басылган дистәләгән шигырь китаплары авторы ул хәзер. Гел читтә йөрү сәбәпле булса кирәк, ул алтмышынчы еллар башында дәррәү төркем булып иҗатка килгән шагыйрьләр—чордашлары «обоймасына» эләкми, шул сәбәпле аның иҗаты мактаулардан, игътибардан, үксез бала кебегрәк, читкәрәк кала. Дөрес, тәнкыйть Әхмәт Гаделне бөтенләй әйләнеп үтте дию дөреслеккә хилафлык булыр иде. Заманында В. Цыбин, И. Цеховский, А. Кудрявцев, татардан С. Гомәр-Әмин, Н. Юзиев, Р. Мостафин, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, Г. Морат, И. Кәримов аның лирикасы турында уңай фикерләр белән чыкты; иҗатына җылы карашларын Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан, Г. Ахунов кебек сүз осталары даими сиздереп, әйтеп, рухландырып тордылар.Ләкин аның үзенчәлекле иҗатын иңләгән яисә шуңа омтылган хезмәтнең әлегәчә күренгәне юк. Әхмәт Гаделнең кубәләктәй тыйнак җан очышыннан башланган тылсымлы шигърият чишмәсе акрынлап туарылып, ишелеп аккан олы дәрьяга барып тоташа, татар әдәбиятының бер игелекле тармагын тәшкил итә. Шигырь китаплары янына проза әсәрләре, тарихи-лингвистик эзләнүләре өстәлә тора.

Бүген китап киштәләрендә урын алган «Эзләнү», «Чам», «Яшьлек урамы», «Көмеш кылган җыры», «Яшьлегем былбыллары», «Серле күпер», «Командир сәгате», «Дәрт», «Алмагач кызы», «Йолдызлы чат» һ. б.—айсберг дигән серле тауның өске өлеше генә.

Әхмәт Гаделнең әле басылып чыкмаган дистәдән артык кульязма китабы үз нәүбәтен көтеп ята. «Рух бәйрәме», «Таланган болытлар», «Уходят кони в синие рассветы», «Поэмалар китабы», «Пьесалар», «Киносценарийлар»... Берничә томлык «Татар тарихы» китабы, аңлатмалы алынмалар сүзлеге. Татар һәм рус телләрендә мәкаләләре, очерклары.

Детальләрне өйрәнү, аның шактый катлаулы образларына төшенү, Гаделнең үзенчәлекле, Эзоп телен өйрәнү генә аның иҗади җимешләреннән ләззәт тойгысы алырга мөмкинлек бирә.

Ышануыбызча, Әхмәт Гадел үзенең күңеле аша берничә мәдәният катламын рух назларында кайнатып, яңа форма, яңа төсмерләр, яңа образлар булдырган шагыйрьләребездән. Хәзер аның тормыш һәм иҗат юлына күз салыйк.

Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылы мәктәбендә укыганда, сабакташы (хәзер күренекле шагыйрь) Равил Фәйзуллин белән ярыша-ярыша, рус телендә язган Әхмәт Гадел дә аңардан үрнәк алып ана телендә шигырьләр яза башлый. Ул чит илдә, армиядә хезмәт иткәндә «ачыла». Солдат тормышы үзенең катгый таләпләре, кырыс чикләүләре белән күпләрнең рухи үсешен туктатып торса, Әхмәт менә шундый кырыс һәм кыргый шартларда шашыныпшашынып каләмен сыный. Иҗат кешесенең холкы, фикерләү рәвеше үк серле дөнья, ачылып бетмәгән континент. Потстдам шәһәрендәге хәрби газета редакциясендә солдат Әхмәтнең «Поиск» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Күп тираж белән җыелган китабы туган җирләреннән, туганнарыннан,

сөйгән ярларыннан читтә яшәргә мәҗбүр булган чордашларының юлдашы, сердәше, киңәшчесе булып китә.

60-70 елларда да Әхмәт Гадел ике телдә язуны дәвам итә. Урысча ташып чыккан «Чам», «Кыз куу бәйрәме», «Йолдызлар», «Мәйданда», «Шомыртбаш урманында көз» кебек башка милләт укучыларын татар халкының рухи дөньясына, көнитеш хасиятләренә алып кергән шигырьләре үзәк матбугат игътибарыннан да читтә калмый. Аерым алганда, күренекле урыс шагыйре В. Цыбин аның эзләнүләренә югары бәя бирә. «Әхмәт Гаделнең шигырьләре—һәрвакытта диярлек хисләрнең текә, кыю, кискен алышынуы, бер-берсенә капма-каршы торган ритмнар гаммасы, буйсынмас төсләр уены, сүзнең ниндидер самими сизгерлеге—барысы да тормышны тирәннән, җирдән сиземләүдән килә» *(Тверской бульвар, 25—// Литалманах, 1972.—75 б.).*

Үзен шундый җылы кабул итү тәэсирендә шагыйрь, форсаттан файдаланып, бер-бер артлы китапларын нәшер итеп, урыс телендә иҗат итүче, торгынлык елларында уч төбендә йөртелгән әдипләр шеренгасына басарга тиеш иде кебек. Олы сәясәт шул юлга этәрә, үз туган телен оныткаңнарны, өйрәнергә теләмәгәннәрне хуплап торган манкортлар заманасы иде. Мәгәр бишек җыры, чишмә чыңы илә бала чагыннан йөрәгенә, канына сеңеп калган милли хис аңа башка юнәлеш бирә, үз халкының тарихын, бүгенгесен өйрәнергә өнди, үз кыйбласын эзләү юлына чыгара. Ул әлегә туып-үскән җире, мәңгелек мәхәббәте Татарстанны, олы стратег кебек әйләнеп йөри, чагыштырып карау өчен тәэссоратлар туплый. Сәяхәт итә, әйтелгәнчә, бик күп төбәкләрдә: Дагыстанда, Кырымда, Төньякта, Себердә, Балтыйк буе илләрендә, Урта Азиядә йөреп, яшәп, мая җыя («Күгәрченнәр», «Чам» кебек шигырь китаплары (1971, 1978) үзбәк китап нәшриятында басылып чыга.) Ул яраткан шагыйре Хәсән Туфан үрнәгендә, биштәрен аркасына асып, «дөньяның мин күрмәгән җирләре күп әле» дип, ил буйлап сәяхәт кыла...

Төрле төбәкләрдә яшәгәндә дә Әхмәт Гадел, коры җиргә эләккән су кебек сеңми, югалып калмый; үзбәкләр, каракалпаклар, әтисенең шул якларга сөрелгән кан кардәшләре белән аралаша, уртак тел таба, шивәләрен өйрәнә. Аерым алганда, шул як күренекле сүз осталары белән дуслык мөгамәләсе урнаштыра, Җәүдәт Ильясов, Хәмид Голәм, Рәим Фәрһади, Рәүф Парфи, кореялы Борис Пак, кырымтатар язучылары Рәшид Морад, Юсуф Болат, Шамил Аләдин, Сәет Гомәр Әмин, Әнвәр Сәламәт, Риза Фазыл һ. б. белән дуслыкта яши.

Иҗатының җитлеккән чорын ачып җибәргән «Чам» шигыре (кырымтатар телендә нарат агачы) Әхмәт Гаделне үзенчәлекле шагыйрь итеп таныта. Хикмәт шунда: «Чам» әсәрендә шагыйрь халыкның фаҗигасен һәм мәңгелеген—туган җиренә берегеп үсүен шул әрсез нык агач образы аша символлаштыра, аллегория ярдәмендә аның илаһи көчен, метафора белән туган җиргә, ил язмышына береккәнлеген чагылдыра. Шигырьне тән-кыйтьчеләр, әдәбият белгечләре өчен һаман каты чикләвек булган Дәрдмәнднең «Кораб»ы белән янәшә куям, хәтта, шуның дәвамы итеп кабул итәм.

Тамырлары белән туфракка тирән үтеп,
Кыяларны кочып,
Ташларга сарылып үсә,
Ялгызы үсә
Кәкре нарат—Кырым чамы!
Ботаклары күк гөмбәзен тотып тора,
Алып батыр куллары кебек.
Һәркем туган җирен сөйсен иде шулай,
Ташлы тауның батыр чамы кебек...

Шигырьнең әлеге варианты 1978 елда Казанда басылып чыккан «Яшьлек урамы» җыентыгында бирелә. «Кыяларны кочып», «ташларга үрелеп үскән Кырым чамы» шул ук. Әмма биредә инде ул ике халыкны якынлаштырган уртак җепләргә, язмышларга ишарә итеп, татар дастаны батыры Алыпны алып керә. Давыл-җилләргә бирешмичә үскән чам һәм Алып батыр... Беренче варианттагы «кыяларның ярыкларына ябышып», «Башка үсемлекләр үсә

алмаган җирдә үсә» кебек ваклыклар төшереп калдырыла, шигырь камилләшә, чарлана һәм гомумирәк төсмер ала. Шагыйрь үзенә, иҗатына таләпчәнлекне арттыра бара. Шул эзләнүләр нәтиҗәсендә «Кеше», «Моң», «Юмарт татар», «Казан», «Болгар» кебек, һәркайсы халкыбызның мәшһүр үткәнен яисә холкының бер асыл сыйфатын калкытып куйган шигырьләре туа.

Күргәнебезчә, Әхмәтнең холкы бертөслелекне яратмый, рухи кабул итми. Тәэсирләр яңартуга, хис-кичереш дөньясын баетып торуга омтылу, мәҗүси сафлык белән табигатьне, матурлыкны, халкын ярату аның канына балачактан тоз кебек сеңгән. Атасы ягыннан кырым нәселеннән булган Әхмәткә—анасы Казан арты—Әтнә төбәгенең моңын, назын, рухын сеңдерә. Рәнҗетелгән, кимсетелгән, әмма горурлыгын, киләчәккә өметен җуймаган халыкның ике нәселеннән чумырып ала Әхмәт сәләтне һәм хаксызлыкка нәфрәтне, үзенең олы дөньядагы урыны өчен көрәшә белү рухын. «Бәхетле солдат тормышы»н, «халыклар дуслыгы»н җырлаудан башланган иҗат үсә, тирәнәя бара. Рәсми сәясәт күңелләргә сеңдерә килгән халыклар арасындагы тигезлек идеяләренең сабын куыгы, алдавыч икәнен Әхмәт читтә йөргәндә ныграк аңлый. Халык хәсрәте—аның шәхси кайгысына әверелә, шагыйрь тынычлыгын югалта, әрни, сызлана.

Романтик рухлы, яңага һәвәс Әхмәт, армия хезмәтен тутыргач, шул чорда шаулап-гөрләп күтәрелә килгән Түбән Кама нефтехимия төзелешенә юл тота. Анда аны беркем көтми, урманчы белгечлегенә ихтыяҗ юк. Солдатта алган һөнәрләре ярдәмгә килә. Язудан туктамый; аны күреп алалар һәм шәһәр гәзитенә, аннан радиога эшкә чакыралар. Җитди иҗат өчен белеменең саерак булуын сизенгән егет 1970 елда Мәскәү әдәбият институтына юл тота һәм Булат Сөләйман, Эдуард Мостафин, Разил Вәлиевләр белән бер вакыттарак укый, шул ук изге максат белән уку йортына килгән Балтыйк буе, алман, болгар, маҗар, себер, монгол, гарәп, Кавказ, Урта Азия егетләре белән аралаша. Төннәр буе шигырь уку, язу, бер-берен тәрҗемә итү, аны семинарлар-да тикшерү, гаҗәеп иҗади атмосфера...

Әхмәтнең әтисе—җиңел сөякле, көчле, нык иманлы Һади абый туры мәгънәсендәге көрәшче була, әле фронттан яраланып кайтканнан соң да, күп тапкырлар сабан туйларында батыр кала. «Бу бәйгеләргә,—ди Әхмәт,—әти март аеннан ук, чабыш алдыннан тыпырчынган ат кебек, үзен әзерли башлый. Үз эченә бикләнә, аз сөйләшә... туктаусыз әстерхан һәм урман чикләвекләре ашый торган иде.»

Яшьлеге Татарстанда ипле генә узса, Әхмәт, бәлки, көрәшче булыр иде. Спортны, татар бил алышуын ярата, хәзер дә әле ул, йөрәк кысуга зарланып, үзен җәлләтеп алгаласа да, алтмыш яшьлекләрдән төз гәүдәсе, хәрәкәтчәнлеге, җилкә, күз шәрифләренең уйнаклап торуы белән аерылып тора. Ул—көрәшче. Әхмәт халкының азатлыгы, иминлеге, бәйсезлеге өчен көрәшкә каләмен күтәреп чыга. Әлегә җир шарында сүз, каләм көчен җиңәр коралның уйлап табылганы юк. Иншалла, табылмас та. Шул ук вакытта шагыйрь тавышын ясалма көчәйтми, барабаннар какмый, ә туган иленә мәхәббәтен энҗедәй нечкәлек, самимилек ярдәмендә ачып сала. Мәсәлән, «Син» (1990) шигыре ватанпәрварлек, гражданлык пафосы белән чолганып-сарылып акса да, ул Әхмәткә генә хас моңга сагышка төрелгән. Бу лирик парчаны тулысы белән китереп үтәсе килә.

Син минем ярты йөрәгем,
Син минем ике күзем.
Син миңа шундый кирәксең,
Беләсең микән үзең?

Эссе көндә сирин җилем,
Салкында җылы кояш.
Бер төсле авыр тормышның
Рәсемен, әйдә, буяш!

Син минем гади арышым,
Зәңгәр күгемдә тургай.
Мин синсез якты дөньяда
Яши дә алмам бугай.

Син миңа, җаным, кирәксең,
Терәгем син, булышчым.
Үлгәндә саклап калдырган
Иң кирәкле сулышым.

Бер генә матур илгә дә
Китә алмыйм мин синнән.
Син минем туган туфрагым,
Мин синдә үскән имән!

Бу хәтле җылы, кешенең рухын, җанын, вөҗүден агулаган мәхәббәт булыр икән, дип сокланып укыганда, соңгы куплетта сүз сөреше бөтенләй икенче ягы белән борылып куя. Сүз туган ил, газиз туфрак турында бара, ә лирик зат шул уңдырышлы җирдә үскән нык имән икән. Сүз табигатьнең җанландырылган, әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән җанлы кыйпылчыгы турында бара. Ун алты юлдан соң, көтмәгәндә ясалган борылыш, ярсып аккан елга аша сикерү, гаҗәеп фикерләү сәләте түгелме? Мондый көтелмәгән ачышлар, лириканы тар кысаларга куып кертергә өйрәнгән тәнкыйтьне авыр хәлгә куячак, көтелмәгән ачышлар Әхмәт Гадел иҗатында шактый.

Тормыш матурлыгын күрә, шуңа сөенә белгән шагыйрь, язарына азыкны һәр адымда таба. Чөнки матурлык үзеннән-үзе мөстәкыйль яши һәм шагыйрьнең илһам кылларын хәрәкәткә китереп, яңа матурлык иҗат итәргә булыша, ягъни тормыш матурлыгы шигъри юлларга, проза битләренә күчкәч, ул янәдән мәңгелеккә кешегә әйләнеп кайта, аның белән кала, юлдашына, киңәшчесенә әверелә. Менә аның «Атлар килә» исемле, һәр татар кешесенә якын ат бәйгесен сурәтләгән шигыре. Әсәр әллә нинди илаһи хисләрне уятып, романтик биеклектә башланып китә: «Атлар килә... Дөп-дөп итә йөрәкләр. Канатлана колгадагы сөлгеләр». Чабышның нәтиҗәсенә берәү дә алдан фаразлык итә алмый, кем беренче килер, кайсы егеткә «кайсы гүзәл чиккән» сөлге эләгер? Шагыйрь күргәнне кәгазьгә, мизгелне сурәткә алучы гади күзәтүче түгел. Бердән, йөрәк кагышына тиң дөп-дөп иткән тояклар көмештән, икенчедән, алар кайчандыр бабаларыбыз гомер сөргән «ерак дала ягыннан» икән. Мәгәр шигырь әле шәхеснең килеп керүен, кичерешләрнең ачылып-актарылып китүен көтә. Шагыйрь хыялы вакыйга типкеленә нинди юнәлеш бирер икән? Бетем кызыклы һәм көтелмәгәнчә:

Кайбер юрга кебек азак китеп, без
Иң элгәре бәлки әле килербез!

Шигырьнең офыгы, мәгънәсе киңәеп, гомумән, кешенең тормыштагы урыны, яшәешнең гел бәйге булуы, күп нәрсә шәхеснең үзеннән торуы хакында уйланулар боҗрасына алып чыга.

«Гитара» парчасы да сагыш, моң белән өртелгән статик халәтне күз алдына бастыру белән башлана. «Кулымда серле гитара. Кара төн, якты учак». Лирик зат үзе генә түгел, канәгать якташлары аны башларын иеп, тыңлап утыралар. Ни өчен гитара «серле», ник тыңлаучыларның башлары салынган? Чөнки гитара—үзенчәлекле уен коралы: «Өздерә татар көен: Әй газиз туган илем». Читтә яшәгәндә йөрәк түрендә туган ил рухын саклаган адәм баласы туган як турындагы нәзберек көйне башкача тыңлый да алмый. Төрле төсле, коелган яфраклар моңы сеңгән «Менә көз дә җитте инде», тарихи аң төпкелләренә иңү рухы белән язылган «Болгарда», «Соңгы буран», метафора җәюгә корылган «Күл буенда», «Куркыныч шәһәр», мәгънәсенә барып җиту өчен интеллект әзерлеге таләп иткән «Әйдә», «Ташка язу» шигырьләре заманча яңгырашлары, темпераментлары, төзелешләре, кафияләре, аваз уйнатулары белән күңелгә сеңеп калалар. «Кияүгә чыга татар», «Бакчада асылган кош зары», «Ана телем», «Милләтемнең якты йолдызлары» шигырьләрендә тирәнгә сирпелгән әчке сагыш, тарихи үкенеч, моңсу аһәң өстенлек итә. Аларның чыганагы тирәндә, тарих катламнарында ята. Бу—олы милләтләр аңламый, аларда була, туа алмый торган гаҗәеп серле моң. Булмаганны югалтмаган халыкларда да мондый сагыш туа алмый башлый. Җан ярасына дәва юк, тик үткәннән, киләчәктән таяныч кына эзләп була. Ә инде бөек халык кичерешләрен, моңын бер йөрәккә туплаган Әхмәт Гаделдә алар аеруча тирән һәм дәвамлы.

Әхмәт Гадел тормышны бөтен катлаулылыгында һәм фәлсәфи кабул итә дигән идек. Җөмләдән, «Вакыт» шигырен искә алмыйча үтә алмыйм. Хәзерге татар поэзиясендә вакыт дигән фәлсәфи төшенчә турында язмаган, аның белән бил алышмаган шагыйрь юктыр. Ә. Гадел берәүне дә кабатламыйча, Вакытны хәрәкәтчән, үтүчән олы дөнья белән янәшә, хәтта аңардан өстен куя.

Бар нәрсә фани—дөньяда.
Вакыт—үлемсез!!!—

ди автор, фикеренең ахырында сорау түгел, ә өч өндәү билгесе куеп.

Газиз җиребез һәрдаим авыр сынауларга дучар, туктаусыз аның байлыкларын, җелеген суырып торабыз, ә тереклек аңардан башка яши алмый, ә Вакыт, галиҗанәп Вакыт мәңгелек. Ул—үлемсез, бәлки, без табынырга тиешле илаһи көчләрнең берсе Вакыттыр, дигән сорауны куя философ шагыйрь.

Әхмәт Гадел мәхәббәт пакьлеге, ир-хатын, кыз-егет мөнәсәбәтләрендә сафлык, вөҗдан, намуслылык мәсьәләләрен дә оста күтәрә. Теге очракта да, бу очракта да, ул милләтебезнең киң күңеле, башка халыклар белән яшәү күперләрен, үзара мөнәсәбәтләрне матур итеп кора белә торган, тырыш, эш сөючән, батыр, фидакяр халык икәнлеген исбат итә. Кыскасы, олы дөнья турында фәлсәфи фикер йөртү, мөһим төшенчәләр белән эш итү, сыкранып уйланулар Әхмәт Гаделне гади мәхәббәт, язмыш, бәхет, ялгызлык кебек һәр кеше башыннан уза торган тормыш-көн итеш мәсьәләләреннән читкә алып китми. Позага басып, өч бармакны җилет кесәсенә, каеш төененә тыгып кына яшәп булмасын аңлап эш итә. Аның күпсанлы җырлары—яшәеш җепселләре белән якынлыгын раслаучы мисаллар. Җырларының байтагына көйне автор—Әхмәт Гадел үзе язган, үзе тудырган, уңышлылары җырчыларыбызның теленнән төшми. Исеме үк җырлап торган «Ак болытлар ага»ны Миңгол Галиев ялатып башкара. Символик мәгънәле «Көзге җил» Гүзәл Маликова, Эмиль Җәләлетдиновлар башкаруында колакларны, җанны иркәли. Салават Фәтхетдинов үзенә фәлсәфи эчтәлекле «Тормыш түгел алсу алма», «Гомер—мизгел» җырларын сайлап алган. Бу әсәрләрендә шигъри фикерләүне, шул ук шәхеснең музыкаль фикерләве тулыландыра. Тавыш һәм сүз... Алар арасында ярашу, тәңгәллек булганда гына укучы җырны кабул итә. Ә. Гаделнең тирән, самими лиризм кешелекле моң белән сугарылган шигырьләре композиторларны үзенә тартып, рухландырып тора. Күренекле композиторларыбыз Сара Садыйкова («Салават», «Аптыраш»), Әнвәр Бакиров («Үпкәлисең нигә?»), Фасил Әхмәтов («Ватан кояшы») заманында Ә. Гадел шигырьләрен күреп алып, матур әсәрләрен биреп калдырдылар. Көй чыгаручы мәңгелек мәүзугның эчтәлеген, кыйбласын, сүзләр, сурәтләр бизәклеген яңача яңгырата белгән шигырьләрне генә сайлап ала. Ә. Гаделнең шигырьләре Фәүзи Алиев, Мәсгудә Шәмсетдинова, Резеда Әхиярова, Мәсгут Имашев, Рәшит Кәлимуллин, Сафьян Ибраһимов, Ганс Сәйфуллин, Фәрит Хатыйпов, Мәмәт Арсланов, Илфат Дәүләтшин, Рәисә Имамиева, Әхмәт Кәрим кебек дистәләгән көйчеләрнең илһам күзәнәкләрен уятып, җыр язуга дәрт бирәләр.

Әхмәт Гадел нигездә лирик булса да, лиро-эпик әсәрләр дә яза—бу шигъри төрдә эзлекле тәҗрибәләр алып бара. Ул—«Ата җыры», «Өмме-гөлсем», «Минзәлә», «Вәхи», «Ут-ялкын», «Варис», «Ялтада зәңгәр яңгырлар» поэмалары авторы. Барысында да диярлек хәзерге көнүзәк мәсьәләләргә автор тарих аша килә, һәр детальдә милләте узган авыр үткән өмет чаткылары яктылыгында күзәтелә. Мәсәлән, «Минзәлә» поэмасында автор шул өязнең тарихына, дәресрәге, аның азатлык сөюче бик күпләрне интектергән, азаплаган зинданнары тарихына күз сала, аннан бүгенге көнենә әйләнеп кайта, хыяллары белән уртаклаша.

Халкыбызның газиз баласын тарих туктаусыз үзенә тартып, олы юлда бабаларыбыз ирешкән бөеклекләр күңелен күтәрсә, җибәргән хаталары әрнү, сызлану уята. Менә ул борынгы төрки шагыйре Микаил Габделлаһ ибн Шәмс әт Тәбир әл Болгариның «Шан кызы» исемле дастанын тәрҗемә кыла...

Кызганыч ки, Әхмәт Гаделнең хикәя-повестьлары вакытлы матбугатта ком арасындагы энҗедәй күренгәләп алса да, аларның әле аерым җыентык, китап булып чыкканнары юк. Дөнья күргән «Шакир кода», «Ялгыз аккош», «Сәер затлар», «Мәхәббәт газабы», «Бәхет» әсәрләре Әхмәтнең шактый мәгънәле хикәяче, нәсерче, шигърият белән проза казанышларын үреп баруга сәләтле язучы икәнлеген исбатлый.

Юбилеена әзерләнгән символик мәгънәле, иллеләп хикәяне, дистәләгән нәсерне эченә алган җыентыгында яңача фикерләү, шәхесне чикләп торган киртәләрне алып ташларга омтылу, каһарманның гамәлен, табигый ниятләрен күрсәтү гамәлен, табигый ниятләрен күрсәтү белән берргәттән, аның рухи дөньясын ачуга омтылыш өстенлек итә. Хикәядән хикәягә ул безне халык

тормышының асылына кайтара, хыял дәрьясына алып керә, шул юлда халык риваятьләренә, ышануларына киң таяна...

Аның язганнары белән танышканда тагын бер нәрсә күзгә ташлана: Әхмәт ирешкәннәр белән канәгатьләнми, чыжлап табадан төшкән кабартманы өстәлгә бирми, ягъни әсәрен матбугатка күтәреп китми, хисләргә суынырга ирек бирә, кат-кат эшкәртә, һәр җөмләсен җиз иләк аша уздыра. Ә. Гаделнең хикәяләре антология төзүчеләр тарафыннан да вакытында шәйләнмәделәр һәм җыентыкка кертелмәделәр. Үзе дә «мине күрерләр, бәяләрләр» дип, дөньяда дөреслек, объектив бәя барына ышанып йөри, бугай.

Татарстан кино комитетының баш мөхәррире булып эшләгәндә, Ә. Гадел халкының нәфис фильмнар студиясен тудыру хыялы белән янып йөрде. Бу олы нияте тормышка ашмасын аңлагач, тар кысаларда булса да, республиканың уңышларын, асыл затларын мәңгеләштереп калу шөгыленә керешә. Кино сәнгатенең үзенә генә хас үтемле үзенчәлекләренә үтеп керә алу нәтиҗәсендә документларга нигезләнгән нәфис фильмнарга тартым әсәрләр иҗат итә. Аның «Татарстан. Гасырлар һәм минутлар», «Мәйданда», «Бар илләрнең байраклары безгә килер кунакка», «Кешеләрне яратам», «Шәрык—серләр, тылсымнар» һ. б., бигрәк тә «Татар халкының бөек уллары һәм кызлары» сериясеннән чыгарылган документаль фильмнары үзләренең нәфислеге, бигрәк тә публицистиклыгы белән аерылып торалар. Бер-бер артлы Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Рөстәм Яхин, Гариф Ахунов һ. б. мәдәният әһелләре, асыл затларыбыз турында тасмалар туа. Ул шәхесләрнең күбесе фани дөньяны ташлап китте. Сәнгати образлары, сыннары, фикерләү рәвешләре, тавышлары яңа буыннар өчен киноязмаларда калды. Әхмәт аларның хәрәкәтләнүче җанлы сурәтләрен тудыруга ирешкән. Символларны, нисби төшенчәләрне, метафораларны, ялгау, кыскартуларны тасвирга алып керә. Ә. Гадел бу әсәрләрнең авторы, әңгәмәче, алып баручы, шигырьләр, көйләр авторы... Тагы шуны да онытмыйк, Әхмәт Гадел беренче татар мультфильмы авторы, тәрҗемәчесе һәм редакторы да бит әле. Бүгенге көндә дә ул «Төлке хаҗи» дигән анимацион фильм сценарие язып эшкә тапшырды.

Һәр каләм иясенең әсәрләре артыннан аның шәхесе күтәрелә. Әхмәт Гадел аралашу, мәсьәләләр хәл итү, киңәш-табыш өчен бик җайлы кеше. Йомшак, иплe холкы белән ул үзенә тартып тора. Һәрвакыт мәгънәле итеп, ихластан сөйли, үзе яраткан яисә кабул итмәгән күренешләргә анык бәясен бирә. Ихласлык—аның төп сыйфаты. Үз мәнфәгатьләре турында уйлап яши торган кеше түгел. Ул, киресенчә, үзенә игътибарсыз. Тормыш-яшәеш ваклыкларыннан Әхмәт өстен: галстугының дөрес төенләнешенә, күлмәк якасының тәгаен ятуына, кәстүм сәдәпләренең төймәләнеп бетүенә игътибар итмәс. Мондый лирик тәртипсезлек аңа килешеп тора, Әхмәтне Әхмәт итә. Вакыты белән вәгъдәгә юмартланып ташлавы бар: теге яки бу шөгыльнең аңардан гына тормаганлыгын бәяләп, шәйләп җиткерми. Татар киносын булдыру хыялы белән шашып, чиновниклар белән сугышып йөргәне хәтердә. Нәтиҗәдә, аны инфаркт белән хастаханәгә салдылар.

Аның югарыда мин бәян иткән сыйфатлары хакында Гариф Ахунов та бик мәгънәле итеп әйтеп калдырган икән: «Тирән белемле, эрудит, тиз аралашучан, ягымлы Әхмәт Гаделнең иҗаты белән танышкач, мин бер фикергә килдем. Талантка зур постлар биләп утыру кирәк түгел икән. Әхмәт Гаделнең иҗатындагы олы җанлылык, рәхим-шәфкатьлелек аның күңелендә тумыштан ята икән!»

«Әхмәт Гадел кем ул, бер җөмләгә туплап бәя биреп кара әле», дип сорасагыз, болайрак дияр идем.—Татарстанның латыйф табигате кочагында туып, олы дөньяны аркылыга-буйга иңләп, халкының тарихи фаҗигасен аңлап, ихлас йөрәге, җаны аша уздырып, һәр инсанны бәхетле, азат күрү, милләтен богаулап килгән коллык психологиясеннән коткару рухы белән яшәгән, гомерен туып-үскән туфрагында тәмамлап, туачак буынга энҗе бөртегедәй матур, гүзәл әсәрләр мирас итеп калдырырга җыенган зат, әлегә лаеклы бәясен алмаган олы язучы дип җавап бирер идем...

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,
*академик*

# ЧЫНЛЫК КӨЧЕ

РӘФКАТЬ КӘРАМИГӘ 60 ЯШЬ

Безнең татар әдәбияты, бигрәк тә аның проза тармагы һәрвакыт җиргә, чынбарлыкка, реаль тормышка таянуы белән көчле һәм кызыклы булып килде. «Бу нилектән шулай икән?»—дигән сорау куйсак та җавапны бик тиз табарбыз. Чөнки егерменче гасырның ахырларына хәтле татар халкының абсолют күпчелеге авылларда: димәк җирдә, димәк басу-кырлар, урман-болыннар кочагында яшәде. Әдәбиятка килгән иҗатчылар үзләре дә әнә шундый кешеләр мөхитеннән иде—кендекләре җиргә береккән кешеләр дөньясыннан.



Бераз соңрак әдәбиятта мондый каләм әһелләрен түбәнсетергә теләүчеләр дә күренеп алды. Бигрәк тә урыс әдәбиятында Е. Евтушенко буыныңдагы кайбер «шәһәр егетләре» каләмдәшләре В. Шукшин, В. Распутин, В. Астафьев, Ф. Абрамов, В. Белов шикелле авылдан чыккан әдипләрдән шактый сизелерлек итеп көләргә маташтылар, аларны хәтта әдәби иҗаттан ук биздерергә теләделәр.

Әмма... Әмма тормыш дәвам итте. Ул арада әлеге әдипләр буыны дөнья рухиятенә «Яшә һәм онытма!» (В. Распутин), «Патша-балык» (В. Астафьев), «Ак пароход» һәм «Яр буйлап чабучы ала эт» (Ч. Айтматов) кебек бөек проза әсәрләрен бирде. Җитмешенче елларда телгә кергән Латин Америкасы прозасына хәтле иң башта элеккеге Советлар Союзы халыклары (урыс, украин, казакъ, литва, молдаван) прозасы бөтен дөньяны шаулатты. Нәкъ әнә шул елларда безнең татар әдәбиятында да Әмирхан Еникинең, Нурихан Фәттахның, Аяз Гыйләҗевнең фәлсәфи һәм эстетик яктан әлеге әсәрләргә һич тә бирешмәстәй иҗат җимешләре булды. Әмма ни кызганыч: безнең автономия кысалары биргән матди һәм социаль мөмкинлекләр ул әсәрләрне урыс теленә һәм аның аша бүтән телләргә тиешле дәрәҗәдә сәнгатьле итеп тәрҗемә кылдыра алмады.

Танылган прозаик, күпсанлы китаплар авторы Рәфкать Кәрами иҗаты турында уйланганда күңелдән иң элек әнә шундый фикерләр узды. Чыннан да, тормыш, яшәеш көчен—ул китереп чыгара торган исәпсез-сансыз һәм кабатлангысыз мәгънәләрне башка бер генә чыганактан да алып, табып булмый бит ул!

Ә менә хәзер без сүз йөртә торган Рәфкать Кәрами дигән авторыбыз иҗатка килгәнче иң башта «тормыш университетлары»н узган: ул тәҗрибә туплаган, акыл җыйган, үзенең эчке дөньясын баеткан. Әнә шуннан соң инде алтмышынчы еллар ахырында «Дүрт кешелек каюта», «Кичке уйлар» кебек әсәрләр барлыкка килә.

«Теплоход хәзер кузгалып китәчәк.

Туристлар, телефон чыбыкларына кунаклаган кошлар кебек, өч палубага да тезелгәннәр иде. Ә озатучылар басма каршында шаулашалар, причалда, яр өстендә кульяулык болгыйлар, эшләпә, фуражкалар күтәрелә...

Күзне чагылдырып яр буенда көчле утлар кабынды. Гудок тавышына дәртле музыка кушылды һәм теплоход әкрен генә причалдан аерыла башлады...»

Кызыклы, ымсындыргыч исем куелган «Дүрт кешелек каюта» әсәрен әнә шулай башлап китә Р. Кәрами. Аннары инде без бу повестьның

каһарманнары белән танышабыз: автор аларның тәгәл, истә кала торган портретларын бирә, жайлы гына иттереп сөйләштереп жибәрә. Алар теплоход белән Әстерханга хәтле барып ял итәргә уйлаганнар икән... Бусы үз чиратында тагын безнең күңелләрне иләсләндерә, дәртләндерә. Кыскасы, повестьның агымы укучыны табигый һәм эзлекле төстә үзенә ияртеп алып кереп китә. Ятим үскән кыз Кларанын язмышы безнең алда бөтен фажигасе һәм катлаулылыгы белән, башка персонажлар тормышына бик табигый рәвештә уралган хәлдә ачылып бара. Һәм, әлбәттә, Клара белән Жәүдәт арасындагы мәхәббәт дулкыннары әсәрнең үзәк агымын, төп стихиясен тәшкил итә.

«Кичке уйлар»... Моннан 30 ел элек язылган һәм басылып чыккан бу повесть бүген дә Рәфкать Кәраминең иң житди, иң тирән эчтәлекле әсәрләреннән берсе дип саналырга хаклы. Әсәр Шакир исемле авыл абзыеның кичен өйалды баскычында уйга чумып утыруы белән башланып китә. Ни өчен һәм нинди уйга талган соң Шакир?

Сугыштан соңгы авылда туып үсеп, ярлылыктан тәмам туйган Шакир бераз өс-баш юнәтү, акча эшләү нияте белән шахтага чыгып китә. Шактый еллар тир түккәч ул үз хыялына ирешә дә: бай егет кыяфәтендә туган авылына кайта, исәбе—иң матур кызга өйләнү. Галия әнә шулай итеп аның хатыны була, ләкин Галиянең әнисе читкә жибәрмәгәч алар авылда калалар һәм бергәләп дөнья көтә башлыйлар. Ләкин инде Шакирның борынына зур акча исе кергән, ул уй-ниятнең дә иң эресен генә кора: авылда беренче булып «Волга» машинасы кирәк аңа! Шул максат белән жан-фәрман тырышу, дөнья куу башлана һәм, әлбәттә, Галиягә дә инде бүтән ял тими... Хастаханәдән кайткач авыр эш эшләү сәбәпле ул өзлегә дә, балаларын ятим, ирен тол калдырып үлеп үк китә...

Шакир хәзер менә шулар өчен кайгырып, борчылып утыра.

Аңлашыладыр—язучы үзенең әйтергә теләгән фикерен бик тә оста китереп чыгара. Шакир да, Галия дә безнең күз алдында тулы канлы образ булып яшиләр. Әсәрдә Шакирның холык-табигатен ачучы тәгәл детальләр байтак кына, әмма берсе аеруча истә калган. Бәләкәй вакытта бала-чага акча юнәтү өчен сөяк жыеп тапшыра бит. Әнә шул чагында әсәр герое Шакир сөяк табу өчен хәтта үләт базына да барудан чирканмый! Менә шушы факт әсәрне уку барышында хәтергә нык сеңеп кала һәм алга таба Шакир акча эшләү максаты белән үзе дә ныграк тырышкан, Галияне дә күбрәк изә барган саен әлеге фактның мәгънәсе дә һаман тирәнрәк булып ачыла бара. Хәтта символик эчтәлек ала сыман ул. Акча эшләү өчен үләт базы янында йөрү Шакирның тулаем тормыш мәгънәсен билгели шикелле.

Ә аннары язучының «Капитан Хәкимов» повесте дөнья күрде (1974). Бу әсәр нәкъ менә шул елны аерым китап булып басылды һәм мин аны армиядән ялга кайткан вакытымда сатып та алган идем. Ерак Көнчыгышка үзем белән бергә алып китеп Совет Армиясе турындагы бу повестьны шул хезмәттәге бер офицер буларак укып чыктым һәм бик тә әйбәт фикердә калдым. Р. Кәраминең армияне дә, шул як табигатен дә белеп язуы, әсәрнең сюжетын мавыктыргыч һәм эчтәлекле итеп коруы, китапта әллә нинди зур фәлсәфәләр хакында акыл сатмыйча—армияне авыр һәм четерекле эш, ирләрнең ирлеген сыный торган вазыйфа буларак ачуы ошады.

Менә хәзер әлеге повесть язылганга да утыз еллап вакыт узды, Рәсәй армиясе үзе дә халыкны, илне саклаучы көч булудан бигрәк куркыныч, явыз бер нәрсәгә әверелде. Аңа хәзер инде яшьләрнең барасы да килми.

Менә шушындый шартларда, армиягә карата халыкта шундый начар караш, мөнәсәбәт булганда мондый әсәрләр ничек кабул ителә икән соң дип «Капитан Хәкимов» повестен инде әллә ничәнче мәртәбә яңадан күздән кичердем. Юк, барыбер укыла, барыбер мавыктыра бу әсәр! Ни өчен шулай? Чөнки анда чын тормыш белән яшәүче чын кешеләр, безне ышандыра торган персонажлар һәм вакыйгалар бар. Анда армия чынбарлыгы, аның искерми торган асылы, нигезе дөрес чагылдырыла.

Соңгы елларда (1995) әдип безне «Каргышлы этаплар» исемле романы

белән дә сөендерде. Әсәр гап-гади бер авылда яшәп ятучы Мотаһир исемле кешенең шәхес культы елларында кичергән фаҗигасен тасвирлый. Ләкин илдә нинди генә кырыс еллар булмасын, кешеләр үзләрендәге сөю-сөелү хисләреннән дә мәхрүм кала алмыйдыр күрәсең, шуна күрә бу романның тәүге битләре дә авыл тормышының җангга тынычлык, рәхәтлек бирүче күренешләреннән башланып китә. «Уртага яткан өч яшьлек Әгъдәсне уятмаска тырышып, Мотаһир шыпырт кына хатынына дәште:

—Мөсәмирә, торасыңмы әле?!

Хатыны уяу икән. Ак яулык бәйләгән башын чак кына калкытып иренә яратып карады.

—Торыймсы соң?»

Әйе, менә шушы күренештән үк аңлашылып торганча, Рәфкать Кәрами кешеләр яшәешендәге иң мөһим, иң кадерле рухи-әхлакый хәзинәләрне үз әсәрләрендә тәэсирле итеп, истә калырдай итеп сурәтләп, күрсәтеп бирә белә... Беркемне дә җәберсетмичә тыныч кына яшәп яткан менә шушы әчкерсез кешеләр дөньясына һич тә көтмәгәндә бәла килеп керә. Үз авылларында яшәп яткан бер хөсет адәм «чагуы» буенча Мотаһирны кулга алалар. Ә чын сәбәбе мондый: Мотаһир—гадел кеше—колхозның ревкомиссия рәисе икән дә, ул кайсыбер житәкчеләргә урлашырга комачаулый икән!

Язучы игътибар иткән вакыйгаларның күбесе элекке чор тормышыннан алынса да, алар бүгенге көн өчен дә бик актуаль мәгънәгә ия. Бүгенге көн Мотаһирлары да төрле-төрле оешмаларда хәзерге житәкчеләрнең караклыгына каршы көрәшеп яталар түгелме соң?!

Романның төп каһарманы Мотаһир язмышыннан килеп чыгып хәзерге еллар яшәешенә килеп ялгана торган мондый фикерләр, нәтиҗәләр, әлбәттә, әсәрнең бәһасен дә күтәрә, тәэсир көчен дә арттыра, әчтәлеген дә киңәйтә.

Бу роман уңаеннан автор файдасына тагын шуны әйтмичә үтү мөмкин түгел: ул шомлы утызынчы еллар тормышын бик тә нык өйрәнгән. Китапны укып барганда чынлыгына шик туардай яисә ышандырмастай эш-гамәлләр күренми. Ә менә психологик яктан нечкә тотып алынган һәм шул чор тормышының, шул чор кешесенең эчке халәтен төгәл, тирән ачып бирүче ситуацияләр күп. Шулардан берсе: Мотаһир төрмә капкасы төбендә сәгатьләр буе таптанып үзен төрмәгә алып кереп китүләрен көтеп йөри. Ул болай дип уйлый: «Аны барыбер эзләп табачаклар. Ул җир читенә китеп олага алмый бит, китсә дә килгән юлына кире төшәр—өенә кайтыр. Тагын борчу, тагын шул ук каталажка, этап... Монысыннан да яманрак булыр...»

Әйе, болар—тәмам куркытылган кешенең уйлары. Империядә яшәгән һәркемне биләгән, богаулаган тойгылар алар. Ләкин әсәрне укыганда без нәкъ менә татар кешесенә хас булган сыйфатларны да байтак табабыз. Димәк, язучы Р. Кәрами үз каһарманнарының милли һәм индивидуаль үзенчәлекләрен дә ача алган дигән сүз бу.

Романдагы икенче мөһим персонаж—Мөсәмирә, тоткын Мотаһирның кечкенә малае белән, житмәсә әле тагын бер бала табарга җыенып, авырлы килеш авылда калган хатыны. Аның образын иҗат итүгә язучы бөтен күңел җылысын салган, илһамын тулы көченә эшкә җиккән. Нәтиҗәдә Мөсәмирә укучы күңелендә кала торган, үзенчәлекле образ булып чыккан. Ирен кулга алып, өйдән алып чыгып китеп барганда Мөсәмирә әйткән сүзләр дә кызыклы:

—Мотаһир, чәй өлгерде бит!

Гади авыл хатынының үзенә иң авыр вакытта әйткән әлеге сүзләренә әсәрдә автор мондый аңлатма бирә: «Кияүгә чыкканнан алып, кара гүргә кергәнчә гомерен ихатада кош-корт тирәсендә, кече якта аш-су белән әвәрә килеп үткәрүче татар хатыннарының иң кирәкле һәм урынлы дип санаган сүзе иде бу. Чөнки беркем дә аштан олы була алмый: мулламы ул, колхоз яисә авыл советы рәисеме, Казаннан яисә районнан килгән түрәме, туган-тумача яки бала-чагамы, хәтта наган таккан милиционер да...»

Романның ахыры болай тәгәлләнә: «Мотаһир онытылып укып утыра. Ләкин шулчак кемдер кинәт ишек шакый калса, Мотаһир сискәнеп китә,

чөнки тагын аны алып китәргә килгәннәрдер төсле тоела...» Әйе, әсәр каһарманы Мотаһир бүген дә, безнең көннәрдә дә куркып яши. Авторның үз әсәрен әнә шулай—укучыны тынычландырмыйча, бөтен кайгыларны юлдан алып ташламыйча тәмамлавы да уңышлы. Чөнки безнең елларда да бу әсәрдәге «наган таккан милиционер» шикелле адәмнәр көчәеп, хәтта үтә көчәеп бара. Ил буенча хакимияткә дә шовинистик һәм фашистик көчләр ыргыла. Мотаһирда булган курку безнең чор кешеләрендә дә юк дип әйтеп булмый.

Әйе, алтмышынчы елларда әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлаган Рәфкать Кәрами татар укучысы яратып кабул иткән байтак әсәрләр язды: ике романы белән күп санлы хикәяләрне исәпләмичә бары тик повестьларны гына алсак та—алары гына да дистәгә якынлаша. Һәммәсе дә онытылып, мавыгып укый торган әсәрләр!

Әле бит тагын шунысын да онытырга ярамый: боларның барысы да эштән аерылмыйча, нинди дә булса җаваплы эштә эшләгән килеш—кичләрен һәм төннәрен ял хисабына язылган әсәрләр.

Эш дигәннән, безнең татар әдипләренең эштән бәхетләре бар инде аларның! Әнә бит Рәфкать Кәрами да үзенең алтмыш еллык гомерендә нинди генә вазыйфалар башкармаган.

Сарман төбәгенең Рангазар авылында туган егет авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач башта Алабуга мәдәният техникумында укый, аннары Сарман мәдәният йортында баянчы булып, Түбән Әхмәт авылында клуб мөдире булып эшли. Шуннан инде Әлмәт яклары: гади эшче, рәссам, электрик һәм машинист ярдәмчесе... Ә аннан соң өч ел буена Хәрби диңгез флоты... 1964—1977 елларда Р. Кәрами Казан органик синтез заводын коруда катнаша—башта электрик, ә соңыннан «Казаньхимстрой» трестының төзү идарәсендә профком рәисе була. Шул ук елларда ул хезмәтеннән аерылмыйча Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлый. 1977-1979 елларда Р. Кәрами Мәскәүдә СССР Язучылар берлегенең Югары әдәби курсларында укый. Ә инде 1979-1993 елларда ул Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросын җитәкли, 1994 елда исә Татар интеллектуаль милек агентлыгын оештырып җибәрә һәм аның беренче директоры була.

Әйе, Рәфкать Кәрами бүгенге көндә татар прозасын төпкә җигелеп һәм ихлас көчен салып, илһамын биреп тартучы әдипләрдән санала. Аңа укучылар гына түгел каләмдәшләре дә зур ышаныч күрсәтә—ул инде менә күп еллар буена Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы булып сайлана, 1989 елда «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды, ә инде 1999 елда Рәфкать Кәрамигә «Каргышлы этаплар» романы өчен Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе бирелде.

Тынгысыз җанлы, ихлас күңелле, һәр мәсьәләдә принципиаль карашлы шушы каләмдәшебезгә бу айда 60 яшь тула. Аны олы бәйрәме белән кайнар котлыйбыз, яңадан-яңа иҗади уңышлар һәм нык сәламәтлек телибез!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

## 20—ТА-ҺА (ТА-ҺА) СҮРӘСЕ

**(Та-һа сүрәсе 135 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Сүрәнең исеме баштагы ике хәрефтән килә: «Т», «Һ», әйтелешләрендә «Та, Һа» була. Бу ике хәрефнең, ике авазның ни аңлатканы турында тәфсирчеләр арасында бәхәсләр күп. 1. Бу сүз Рәсүл әкрам салләллаһү (галәйһиссәлләмнең) мөбарәк исеме. 2. Ант сүзе. 3. Һәй, кеше, дип адәм баласына мөрәҗәгать итү һ. б.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Та. Һа. *(Мәуланә Алидә: Та-һа—Ий, Адәм баласы, дип шәрехләнгән.)* **(2)** Без Коръәнне сиңа кыенлыклар китерсен дип иңдермәдек. **(3)** Бары тик Аллаһ каршысында гөнаһ кылудан курыкканнарга бер үгет булсын дип, **(4)** Җирне вә күкләрне яралткан Аллаһ тарафыннан иңдерелде. **(5)** Рәхимле Аллаһ Гарешкә *(Күктәге тәхеткә)* хуҗа булды. **(6)** Күкләрдә, Җирдә вә алар арасында булган нәрсәләр белән туфракның астында бар-булганнарның бөтенесе дә Аныкы. **(7)** Син сүзеңне *(догаңны)* кычкырып *(яки авыз эчеңнән генә)* сөйләсәң дә, Ул яшерен серләрне дә, яшереннән-яшерен булганнарны да белә. **(8)** Аллаһ шулдыр ки, Аның Үзеннән башка Илаһи кодрәткә ия һичкем юк. Анын күркәм исемнәре бар.

**9.** Муса турындагы кыйсса сиңа килеп ирештеме?

**10.** Ул бер ут күрде һәм гаиләсенә әйтте:

—Сез торып торыгыз, мин бер ут күрдем, бәлки, аннан сезгә утлы кисәү алып килермен яки учак янында дөрес юлны табарбыз,—диде. **(11)** Муса *(ут янына, нурга)* килеп житкәч, бер тавыш ишетелде:

—Әй, Муса! **(12)** Хактыр ки, Мин ул—синең Раббың, Мин. Әйдә, башмакларыңны сал. Син мөкатдәс *(изге)* Тува үзәнендә. **(13)** Мин сине *(пәйгамбәр итеп)* сайладым. Хәзер инде сиңа вәхий ителәчәкләрне тыңла. **(14)** Шик-шөбһәң булмасын, Аллаһ—ул Мин, Мин. Миннән башка илаһи кодрәткә ия һичберкем юк. Шулай булгач, син Миңа гыйбадәт кыл, Мине зикер итеп, намазыңны *(калдырмыйча)* дөрес итеп укы. **(15)** Ул Сәгать *(Кыямәт көне)*, һичшиксез, киләчәк. *(Ләкин)* Мин *(аның кайчан киләсен)* белгертмимен. Һәркем ни кылса, шунынча әҗер алсын, дип.

**16.** Аңа *(Кыямәт көненә)* инанмаган һәм нәфесен канәгатьләндерү белән генә шөгыльләнгәннәр сине моннан *(Кыямәткә ышануыңнан, тугры юлдан)* яздырмасыннар *(аздырмасыннар)*. Юкса, соңыннан син һәлак булачаксың. **(17)** Ий, Муса, синең уң кулыңда ни ул?

**18.**—Бу минем таягымдыр,—диде Муса.—Мин аңа таянып йөримен. Аның ярдәмендә мин малларыма агач яфракларын коеп төшерәмен. Аның башка эшләргә дә файдасы тия.

**19.** *(Аллаһ)* әйтте:

—Ташла син аны,—диде. **(20)** Ул *(Муса таягын)* ташлады. Таяк шундук тиз шуыша торган еланга әверелде. **(21)** *(Аллаһ)* әйтте:

—Тот аны, курыкма. Без аны кире үз хәленә кайтарырбыз. **(22)** Бер

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

кулыңны куеныңа тык та, башка бер могҗиза кебек, ул җәрәхәтләнмичә вә ап-ак килеш кире чыгачак. **(23)** Тагын сиңа иң бөек могҗизаларыбызның *(берсен)* күрсәтербез. **(24)** Фиргавен янына кит. Хакыйкатән, ул хәттин ашты *(азды)*.

**25.**—Раббым,—диде Муса.—Күкрәгемне киңәйт *(миңа куәт бир)*. **(26)** эшемне кулай ит, **(27)** телемне чиш *(оста сөйләү сәләте бир)*. **(28)** Сүземне яхшы аңласыннар. **(29)** Кардәшләрем арасыннан миңа бер аркадаш бир. **(30)** Энем Һарунны. **(31)** Ул минем арка ягымны сакласын. **(32)** Аны эшемдә уртак кыл. **(33)** Сине туктаусыз данларбыз. **(34)** Сине өзлексез зикер итәрбез, иншаэлла. **(35)** Шөбһә юк ки, Син кылмышларыбызны күреп торучы. **(36)** *(Аллаһ)* әйтте:

—Ий, Муса, теләгәннәрең сиңа бирелде. **(37)** Моннан әүвәл дә сиңа ярдәмебез тигән иде. **(38)** *(Беренчесе)* синең анаңа вәхий иткән заманда булды: **(39)**

—Аны *(Мусаны)* табутка кадакла да, дәрьяга салып агыз, дингез аны ярга алып чыксын, аны Минем дә, синең дә дошманың булган берәү табачак,—дидек. Минем каршымда үсеп житсен дип, Мин сине сөю химаясенә алдым.

*(«Хәзрәти Мусаның анасы: «Башка ир балаларны да үтерғән кебек, минем улымны да Фиргавен үтерер», дип куркып, югарыдан вәхий килгәч, Мусаны тартмага салып, кадаклап, Нил дәрьясына ташлый. Фиргавеннең хатыны Асия ире белән яр кырындагы бакчада йөргәндә, судагы тартманы күреп ала. Сандык эчендәге баланы күреп, шакката. Патша сараенда үстерер өчен Мусага имезүче сөт анасы эзлиләр, Мусаның апасы ярдәмендә, сөт анасы итеп, аның үз анасын урнаштыралар».*

Мостафа Чагрыҗы тәфсиреннән.)

**40**. Синең апаң килеп *(Фиргавенгә)*:

—Аны *(табылдык баланы)* багар өчен сезгә бирәрсен табыймны?—диде. Шулай итеп, күзе-күңеле бәхет белән тулсын дип, сине анаңа кире бирдек. Исеңдәме, син бер кешене үтердең. Без сине газаптан, җәзадан коткарып калдык. Сине сынаулар аша уздырдык. Шуңа күрә, син байтак елларга Мәдьян халкы арасында калдың. Соңыннан, тәкъдирең кушканча, монда килдең. **(41)** Сине: Минем юлда хезмәт итсен *(илче булсын)*, дип сайладым. **(42)** Син дә, энең дә бергәләшеп Минем аятьләремне алып, Мине зикер итәрәк, **(43)** Фиргавен янына китегез. Чөнки ул азгынлыкның аръягына чыкты. **(44)** Әмма аның белән итагатьле итеп сөйләшегез, бәлки ул гыйбрәт алыр һәм акылга утырыр вә *(гөнаһ кылудан туктар)* куркыр. **(45)** Әйттеләр:

—Раббыбыз, дөресе шул, ул безнең белән артык дорфа булыр дип яки *(гаделсезлегендә)* тагын да ныграк хәттин ашыр дип куркабыз,—диделәр.

**46.** *(Аллаһ)* әйтте:

—Курыкмагыз, Мин сезнең белән бергә булырмын, Мин барысын да ишетеп тә, күреп тә торамын,—диде. **(47)**—Барыгыз, аның янына китегез. Әйтегез:

—Без синең Раббыңның илчеләре булабыз. Исраил угылларын тиз генә безгә биреп җибәр, аларны рәнҗетмә. Без синең Раббыңнан бер аять китердек. Тугры юлга басканнар гына котыла алачак,—дип аңлатыгыз. **(48)**—Хакыйкатән, безгә хәбәр килде: *(ул аятьләрне)* ялганга чыгарганнар вә йөз чөергәннәр җәзага тартылачак.

**49.** Фиргавен әйтте:

—Кем ул сезнең Раббыгыз, әй, Муса?—диде.

**50.** Муса әйтте:

—Безнең Раббыбыз—яралтылган һәр нәрсәгә рәвешен биреп, аннан соң дөрес тәртиптә урнаштырган *(юнәлеш биргән)* Аллаһыбыз,—диде.

**51.** Фиргавен әйтте:

—Алайса, яшәп киткән *(үлгән)* кавемнәрнең хәле ничек булачак? *(Алар бит синең бу кисәтүләреңне белмичә китте)*,—диде.

**52.** Муса әйтте:

—Алар турындагы мәгълүмат Раббы янындагы Китапта *(Ләүхел Мәхфүздә)* булыр. Раббым ялгышмас та, онытмас та. **(53)** Ул сезнең өчен Җирне ястык кебек җәйде вә анда сезгә юллар ачты, Күктән яңгыр яудырды. Төрле үсемлекләрне *(җан ияләрен)* пар-пар итеп яралтты.

**54.** Ашагыз, мал асрагыз. Шик юк ки, акылы башында булганнар өчен монда уйланырлык нәрсәләр бар.

**55.** Сезне аннан *(җирдән, туфрактан)* яралттык. Янә сез шунда китәчәксез *(үләчәксез, күмеләчәксез)*. Һәм тагын сезне *(Кыямәт көнендә)* аннан чыгарачакбыз. **(56)** Хакыйкатән, Без аңа *(Фиргавенгә)* бөтен дәлилләрне *(могҗиза аятьләрен)* күрсәттек, ул *(аларны)* тагын ялганга чыгарды вә *(аларга ианудан)* баш тартты. **(57)** Шуннан *(Фиргавен)* әйтте:

—Әй, Муса! Сихерләрең белән син безне йортыбыздан *(Мысырдан)* куып чыгарырга дип килденме?—диде.

**58.** —Алайса, без дә сиңа шундый ук күз буу-сихер күрсәтәчәкбез. Синең өчен дә, безнең өчен дә кулай булган уртак мәйданга очрашырга вакытны үзең билгелә. Вәгъдә бозыш булмасын.

**59.** Муса:

—Бәйрәм көнне, кешеләр җыелгач, өйләдән алда очрашачакбыз,—диде. **(60)** Шуннан соң Фиргавен китеп барды. Үзенең бөтен хәйләсен *(сихерчеләрен)* җыеп алып килде. **(61)** Муса әйтте:

—Сезгә язык тыр ки, Аллаһ турында уйдырмалар *(ялган)* сөйләмәгез. Ахырда Ул хәтәр җәза белән тамырыгызны кисәр. Гайбәт сөйләгән кеше, һичшиксез, тар-мар ителәчәк.

**62.** Шуннан соң алар *(сихерчеләр)* качып-посып, үзара кинәшә, пышылдаша башладылар. **(63)** Ниһаять, әйттеләр:

—Болар икесе дә *(Муса белән Һарун)* сихерләре белән сезне йортыгыздан куып чыгарыр өчен һәм сезне моңарчы тоткан үрнәк юлыгыздан, динегездән *(яхшы тормышыгыздан)* яздырыр өчен килгән күз буучылар,—диделәр.

**64.** *(Фиргавен әйтте)*:

—Алайса, хәйләләрегезне *(сихерләрегезне)* әзерләгез. Аннан соң саф-саф тезелешегез. Шик юк ки, бүген кем оста, шул җиңәчәк, җиңгән як бәхетле булыр,—диде.

**65.** —Муса, *(сихер таягын)* башлап син атасыңмы, әллә безме?—диделәр.

**66.** —Юк, башта сез атыгыз,—диде Муса. Бакса, ни күрде: күз буучыларның баулары вә таяклары үзләреннән үзләре хәрәкәт итә башладылар кебек тоелды аңа. **(67)** Муса куркуга калды.

**68.**—Курыкма,—дидек,—син, һичшиксез, җиңәчәксең. **(69)** Уң кулыңдагы *(таягың)*ны җиргә ташла. Ул күз-ачып йомганчы теге нәмәрсәләрне йотып бетерәчәк. Алар бары тик күз буу белән генә шөгыльләнә ала. Күз буучылар исә кая барса да *(ни генә кыланса да уңышсызлыктан, җәзадан)* котыла алмас.

**70.** Шуннан соң сихерчеләр йөзтүбән егылды:

—Муса белән Һарунның Раббысына иман китерәбез,—диделәр.

**71.** Фиргавен әйтте:

—Минем рөхсәтемнән башка Аңа *(Аллаһка)* инандыгызмы? Чыннан да, ул *(Муса)* сезгә сихер өйрәтүче остаздыр, мөгаен. Хәзер кул-аякларыгызны ботарлап, сезне хөрмә агачларына асып куячакмын. Менә шуннан соң сез кемнең җәзасы хәтәррәк һәм дәвамлырак икәнен күрерсез. *(Мусаның Алласыныкымы, әллә минекеме?)*

**72.** *(Иман китергән сихерчеләр)* әйттеләр:

—Безне яралтканнан *(Аллаһтан)* һәм безгә җибәрелгән ачык могҗизалардан сине өстен куя алмыйбыз. Шулай булгач, теләгәнеңне эшлә. Син бары тик

шушы дөньяда гына хөкем итә аласың. **(73)** Хаталарыбызны вә син мәҗбүр иткән сихерчелегебезне гафу итсен дип, без Аллаһка иман китердек. Рәхмәте киң булган вә җәзасы да дәвамлы булган бер Аллаһтыр. **(74)** Шунысы хактыр ки, кем дә кем Раббысы каршысына гөнаһлар төяп барса, шул турыдан-туры җәһәннәмгә керер. Ул анда ни үле, ни тере булып *(интегеп)* яшәячәк. **(75)** Кем дә кем мөселман булып, игелекләр кылып Аның каршысына барса, өстен дәрәҗәләр шуңа булыр. **(76)** Арыкларыннан чишмәләр агып торучы Гаден җәннәтләрендә мәңгегә яшәп калачаклар. Ару-пакь булганнарга бүләк шул булыр.

**77.** Хактыр ки, Без Мусага:

—Бәндәләрем белән бергә төнлә юлга чык та, *(куа килүчеләрнең)* артыгыздан житүеннән дә курыкмыйча, *(суга батып үлүдән дә)* шүрләмичә аларга *(юлдашларыңа)* дингез *(төбе)* аша коры юл сал,—дип боердык.

**78.** Һич кичекмәстән *(Фиргавен)* гаскәре белән алар артыннан куа чыкты. Алар *(Фиргавен һәм бөтен гаскәре)* дингез суы астында калып, тончыгып һәлак булды. **(79)** Фиргавен үз халкын үзе бозды, тугры юлдан алып китмәде.

**80.** Ий, Исраил угыллары, сезне дошманнарыгыздан *(Фиргавен токымыннан)* коткарып калдык. Тур тавының уң ягында сезгә вәгъдә *(Тәүратны)* бирдек вә илаһи ширбәт *(кодрәт хәлвәсе)* белән бытбылдык ите иңдердек.

*(Ш. Ногманида: Тур тавы янында Мусаның уң ягыннан сезгә Тәүратны вәгъдә иттек вә сезгә ашарга ширбәт һәм кош итен иңдердек. В. Пороховада: И с вами договор скрепили на правой стороне горы, и низвели вам манну и перепелов. Х. Чантайда: Турның уң янында сезгә вәгъдә бирдек вә сезнең өчен кодрәт хәлвәсе илә бытбылдык иңдердек һ. б.)*

**81.** Сезгә ризык итеп бирелгәннәрнең пакь булганнарын ашагыз, ләкин артык исраф итмәгез *(хәттин ашмагыз, кирәге кадәр генә ашагыз)*, көферлек кылмагыз, *(юкса)* сезне газабым тотар. Газабым тоткан һәркем, хакыйкатән, һәлакәткә дучар. **(82)** Шунысы да хактыр ки, Мин тәүбә иткән, соңра иман китергән вә игелек кылган, тугры юлга баскан кешеләрне ярлыкыймын.

**83.** —Ий, Муса, халкыңны калдырып, ашыга-ашыга ялгыз гына килергә ни сәбәп булды? **(84)**—Алар минем арттан килә,—диде Муса.—Әмма мин, Раббым, Синең ризалыгыңны казанмак өчен, шулай алдан килдем.

**85.** Аллаһ боерды:

—Син киткәннән соң Без синең кардәшләреңне *(Һарунны, халкыңны)* сынап карадык һәм Самири аларны юлдан яздырды.

*(Самири аларны бозау сынына табынырга котыртты.)*

**86.** Муса ачулы вә борчулы кыяфәттә кавеме янына әйләнеп кайтты:

—Әй, халкым,—диде.—Раббыгыз сезгә гүзәл бер вәгъдә *(Тәүрат)* бирмәдеме? Әллә мин киткәннән соң бик озак вакыт узган кебек тоелдымы сезгә? Яки сез Раббыдан бер газап килүен телисезме? Шуңа күрә, миңа биргән сүзегездә тормадыгызмы? **(87)** Әйттеләр:

—Без сиңа биргән сүзебездән үз теләгебез белән чыкмадык. Әмма безгә шул халыкның *(Мысырдагы хатыннарның)* бизәнү әйберләрен күтәреп алып килеп, утка салырга *(эретергә)* кушылды. Самири дә шулай эшләде. **(88)** *(Бу кеше)* алар өчен шул эретелгән алтыннан мөгри торган бозау сыны ясады. Шуннан соң *(Самири белән аның иярченнәре)* әйтте:

—Менә, бу сезнең дә, Мусаның да тәңресе булыр. Ләкин ул *(Муса)* бу турыда онытты гына, *(чөнки Муса башка тәңре эзләп, тау башына китте)*,—диделәр.

**89.** Ул бозау сынының һичбер сүз сөйли алмаганны, үзләренә файда да, зыян да эшли алмасын күрмиләрмени алар? **(90)** Аннан алдарак Һарун аларга әйткән иде бит:

—Ий, халкым, сез шуның аркасында *(бозауга табынып)* бәлагә тардыгыз. Сезнең Раббыгыз—мәрхәмәте киң булган бер Аллаһтыр. Шуңа күрә, миңа иярегез вә боерыкларымны үтәгез,—дигән иде.

**91.** Алар:

—Без Муса әйләнеп кайтканчыга чаклы аңа *(бозауга)* табынудан туктамаячакбыз,—диделәр.

**92.** Муса әйтте:

—Ий, Һарун,—диде.—Боларның юлдан язганнарын күргәч тә ни тыйды сине **(93)** минем арттан барырга? Минем боерыгыма каршы баш күтәрдеңме?

**94.** Һарун:

—Ий, анамның улгы *(ий, бертуган абыем)*!—диде.—Син минем чәчемне, сакалымны йолыкма. Мин синең: «Исраил угыллары арасында гауга чыгардың, сүземне тотмагансың»,—дип әйтүеннән курыктым.

**95.** Муса:

—Һәй, Самири, хәзер синең кылмышыңа килик,—диде. *(Бозау һәйкәле ясап, син нинди максатка ирешергә теләдең?)* **(96)** Самири әйтте:

—Мин алар күрмәгәнне күрдем,—диде.—Ул илченең эзеннән бер уч туфрак алып, аны *(бозау ясар өчен эретелгән алтын эченә)* аттым. Минем эчке бер теләгем шулай эшләргә кушты.

*(«Самири: мин кешеләр күзенә күренмәгән рухны, Җәбраилне күрдем яки мин Мусаның пәйгамбәр икәнен белдем, шул изгенең аяк астыннан туфрак алып, һәйкәлгә катнаштырдым. Мин изге рух катнаштырып сын ясадым, дип әйтергә тели».*

Мостафа Чагрыҗы тәфсиреннән.)

**97.** Муса:

—Күземнән югал!—диде.—Гомерең буе син: «Миңа кагылмагыз, миңа якын килмәгез»,—дип сөйләнергә мәхкүм ителдең. Синең өчен аерым бер газап, котыла алмаслык җәза Көне килер. Табына торган һәйкәлеңә бак. Ант итәмен, без аны яндырачакбыз. Аннан соң вак кисәкләргә тураклап, диңгезгә атачакбыз.

*(«Шулай итеп, беркем белән сөйләшә-аралаша алмасын дип, Самиригә чүлгә, кыргый хайваннар арасына җибәрәләр. Ул тәнне черетә торган тилчә белән авырый башлый. Кешеләр янына бара алмый. Ул шулай интегеп һәлак була».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**98.** Сезнең Аллагыз бары тик берәү генә. Аннан башка беркем дә Илаһи кодрәткә ия түгел. Аллаһның гыйлеме бар нәрсәне дә чолгап алган. **(99)** *(Ий, Мөхәммәд)* менә шулай итеп, узгандагыларның хәлләрен сиңа аңлатабыз. Хактыр ки, Без сиңа Үзебездән кисәтү *(Коръән)* иңдердек. **(100)** Аннан *(Коръәннән)* йөз чөергән кеше, һичшиксез, җыелган гөнаһлары өчен Кыяматтә җәзасын татыр. **(101)** Андый кешеләр анда мәңгегә калачак. Алар өчен Кыямәт көнендә иң авыр йөк *(аларның гөнаһлары)* булачак. **(102)** Ул Көнне Сур *(быргы)*га өрелер вә Без гөнаһкярларны *(куркудан)* күзләре *(ала-тилә)* акайган килеш мәхшәргә туплярбыз. **(103)** Алар үзара пышылдап кына сөйләшер:

—Без *(дөньяда яки кабердә)* ун көн генә булдык,—дип әйтерләр. **(104)** Аларның ни турында сөйләшкәнен Без бик яхшы ишетеп торабыз. Аларның иң зиһенлесе, иң ушлысы:

—Бер көннән дә артык булмадыгыз,—дияр.

**105.** *(Ий, Мөхәммәд)* синнән таулар хакында сорарлар *(Кыямәт көнендә тауларга ни булыр?)* Әйт:

—Аллаһ аларны тузанга әверелдерер,—диген. **(106)** Шулай ук, Җир өстен тип-тигез чүл хәленә китерәчәк. **(107)** Анда бер генә калкулык та яки инсү урын да күрәлмәссез. **(108)** Ул Көнне кешеләр чакыруга йөз тотып, унга-сулга тайпылмастан, *(Исрафилга)* ияреп барырлар. Шуннан соң, мәрхәмәтле Аллаһ каршысында тавышлар тынар. Шуңа күрә, син аларның пышылдашканнарын гына ишетерсең. **(109)** Ул Көнне Раббы тарафыннан рөхсәт алган вә Аллаһның ризалыгын казанган кешеләрдән башка һичкемгә дә шәфәгать, файда тимәс. **(110)** Ул инсаннарның киләчәген дә, үткәннәрен дә белә. Алар бу турыда белми генә. *(Аллаһның эшләрен белеп торырлык мәгълүмат аларда юк.)* **(111)** Ул Көнне йөзләр тере вә һәр нәрсәгә хаким булган Аллаһ алдына иелер. Гаделсезлек кылганнар исә тар-мар ителер. **(112)** Мөэмин буларак, игелек кылган кеше җәзадан да, хокуклары кысылудан да *(җәзасы арттырылып, савабы киметелүдән дә)* курыкмас.

**113.** *(Ий, Мөхәммәд)* Без аны гарәпчә Коръән буларак иңдердек вә *(кешеләрне гөнаһлары өчен биреләчәк газап белән)* күп мәртәбәләр куркыттык. Ихтимал, алар *(гөнаһ кылудан баш тартыр)* сакланыр. Яки ул *(Коръән)* гыйбрәт *(кисәтү һәм вәгазь)* буларак исләренә төшереп торучы булыр.

**114.** Хөкемдар Аллаһ мотлак бөектер. Сиңа барысы да иңдерелеп бетмичә, син *(Коръән укырга)* ашыкма.
—Раббым, минем гыйлемемне арттыр,—диген.

**115.** Моннан әүвәл дә Без Адәм белән *(ярамаган агачтан җимеш алып ашамаска дип)* килешенгән идек. Ләкин ул *(антын)* онытты. *(Шайтан котыртыгына түзә алмады, тәвәккәл рәвештә каршы тора алмады, ярамаган җимешне ашады, гөнаһ кылды.)* Без анда *(Адәмнең холкында Аллаһка буйсыну карары)* түземлелек күрмәдек. **(116)** Бервакыт Без фәрештәләргә:
—Адәмгә сәҗдә итегез!—дигән идек. Аларның барысы да сәҗдә итте. Иблистән башка. Ул үҗәтләнеп, баш тартты. **(117)** Шуннан соң Без әйттек:
—Ий, Адәм,—дидек.—Ул *(Иблис)* сиңа да, хатыныңа да хәтәр дошман. Аңлы булыгыз, сезне ул җәннәттән чыгарттырмасын. Юкса, бик кыен хәлдә калырсыз. **(118)** Хәзергә монда *(җәннәттә)* син ачыкмассың һәм дә ялангач булудан курыкмассың. **(119)** Сусызлыктан интекмәячәксең, эсседән дә изаланмассың.

**120.** Шайтан аны вәсвәсәгә салды:
—Ий, Адәм,—диде.—Сиңа мәңгелек агачын һәм иксез-чиксез хакимлекне күрсәтимме?—диде.

**121.** Ниһаять, алар икесе дә авыз иттеләр *(тыелган агачның җимешен ашадылар)*. Шуннан соң аларның оят җирләре ачылды. Алар шундук җәннәт агачларының яфракларыннан *(оят җирләренә)* каплавыч әзерли башладылар. Шулай итеп, Адәм Аллаһ сүзен тыңламады һәм юлдан язды. **(122)** Соңра Раббы аны сайлады һәм аның тәүбәсен кабул итте вә тугры юлны күрсәтте. **(123)** Һәм *(Адәм белән Иблискә)* әйтте:
—Бер-берегезгә дошман булып, аннан *(җәннәттән)* чыгыгыз. Миннән сезгә күрсәтмә *(Китап)* килер, кем минем өндәмәләремә иярә, шул тугры юлдан чыкмас вә бәхетсез булмас,—диде. **(124)** Кем минем кисәтүләремнән йөз чөерә, һичшиксез, аның тормышы газаплы булачак һәм Без аны Кыямәт көнендә тома сукыр килеш *(кабереннән)* кубарачакбыз.

**125.** Ул әйтер:
—Йа, Раббым, мине ни өчен сукыр килеш *(каберемнән)* кубардың? Әүвәл мин күрә идем бит,—дип әйтер. **(126)** *(Аллаһ)* әйтер:
—Шулай шул. Сиңа аятьләрем *(кисәтүләрем)* килде. Син аларны оныттың. Менә, син дә бүген онытылачаксың *(мәхрүм калачаксың)*.

**127.** Менә, Без хәттин ашкан *(тугры юлдан язган)* һәм Раббының аятьләренә инанмаганнарны шулай җәзалыйбыз. Ахирәттәге газап исә тагын да хәтәр һәм тагын да дәвамлы булыр. **(128)** Без алардан әүвәлгеләрне ничә гасыр буе һәлак итә килдек. Аларга бу сабак булмадымы? Юкса, алар һәлак булганнарның җиренә басып йөриләр. Сәламәт зиһенле булганнар өчен монда, һичшиксез, гыйбрәт алырлык хәлләр бар. **(129)** Әгәр дә *(кяферләргә биреләсе җәзаны кичектерергә)* Аллаһның вәгъдәсе булмаса, әлбәттә, *(алар дөньяда ук)* җәзадан котыла алмаган булырлар иде.

**130.** *(Ий, Мөхәммәд)* син алар сөйләгәннәргә түз. Кояш чыгар алдыннан да *(сабах намазында)*, Кояш баер алдыннан да *(ахшам намазында)* Раббыңа тәсбих әйт. Төннең аерым сәгатьләрендә дә *(ястү намазында)*, көндезен дә (тормыш мәшәкатьләре арасында өйлә, икенде намазларында да) тәсбих әйт. Син канәгать калырсың. *(Аллаһның ризалыгын казанган кеше булырсың.)* **(131)** Аң бул, аларга бирелгән байлыкка кызыгып карама. Без ул байлыкны фани дөньяда файдалансыннар дип, аларның кайсыбер кавемнәрен сынар өчен бирдек. Раббыңның сиңа биргән ризыклары хәерлерәк, дәвамлырак. **(132)** Гаиләңә *(халкыңа)* намаз укуны боер. Үзең дә намаз калдырма. Синнән ризык сорамыйбыз. Без сине ризыкландырабыз. Тәкъва кешеләр матур нәтиҗәгә ирешәчәк.

**133.** Алар:

—Нишләп соң ул *(Аллаһның пәйгамбәре булгач)* Раббысыннан бер могҗиза алып килмәде?—диделәр. Әүвәлге китапларда булганнарның ап-ачык дәлиле *(Коръән)* аларга килмәдемени?

**134.** Әгәр дә Без моннан *(Коръәннән)* алда аларны һәлак иткән булса идек, һичшиксез, алар:

—Йа, Раббым, безгә бер пәйгамбәреңне күндергән булсаң, аятьләреңне укыган булыр идек, шушы түбәнлекләргә төшмәгән булыр идек, рисвай калмаган булыр идек,—*(дип акланган булыр иде).*

**135.** Әйт:

—Һәркем көтә,—диген.—Шулай итеп, сез дә көтегез. Тугры юлдан йөрүчеләр алар кем һәм *(тәүбәдән соң)* тугры юлны тапканнар кем икәнен озакламый белерсез.

# 21—ӘНБИЯ (ПӘЙГАМБӘРЛӘР) СҮРӘСЕ

**(Әнбия сүрәсе 112 аятьтән тора. Мәккә шәһәрендә иңгән. Пәйгамбәрләр турында хәбәрләр бирелгәнгә күрә, Әнбия, ягъни Пәйгамбәрләр сүрәсе исемендә йөри.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Инсаннарның исәп-хисап тотасы көннәре якынлашты. Шулай да алар томаналыклары аркасында *(Хактан)* йөз чөерә. **(2)** Раббыдан үзләренә кисәтү-күрсәтмәләр килгән саен, алар *(аятьләрне)* чын күңелдән тыңламыйча, уен-көлкегә ала килде. **(3)** Ул залимнәр җыйналып шулай астыртын пышылдаша иде:—Ул *(Мөхәммәд)* сезнең кебек үк гап-гади бер бәндә булмый, кем булсын? Сез *(көпә-көндез)* ап-ачык күреп торганыгыз килеш, аның сихеренә ышанасызмы?

**4.** *(Пәйгамбәр)* әйтте:

—Раббым Җирдә вә Күктә *(ни сөйләнсә шуны)* ишетеп торыр. Хактыр ки, Ул—ишетеп, белеп торучы.

**5.** Алар әйтте:

—Әйе, бу *(аятьләр)* аның йоклагандагы саташуларының нәтиҗәседер. Шик юк ки, ул аларны үзеннән уйлап чыгарган. *(Аллаһтан иңде, дип ялганлый.)* Чөнки ул—шагыйрь. *(Әгәр чынлап та ул пәйгамбәр икән)* алдан иңдерелгәннәргә *(башка пәйгамбәрләргә бирелгән китапка)* охшаш берәр аять *(могҗиза)* күрсәтсен,—диделәр.

**6.** Болардан элек яшәгән һәм һәлак ителгәннәрнең *(шәһәрләрнең, халыкларның)* берсе дә иман китермәде. Болары иман китерер, дип өметләнәсеңме?

**7.** *(Ий, Мөхәммәд)* сиңа чаклы да Без вәхий тапшырылган кешеләрне генә пәйгамбәр итеп җибәрдек. Әгәр *(бу турыда)* белмисез икән, белгәннәрдән *(китаплы халыктан)* сорагыз.

*(«Аятьтәге «әһлүз-зикр», ягъни «белгәннәр» сүзен, Тәүрат белән Инҗилне яхшы белгән кешеләр, китаплы халык, дип аңларга кирәк».*

Мостафа Чагрыҗы тәфсиреннән.)

**8.** Без аларны *(пәйгамбәрләрне)* ризык ашамый торган гәүдәләр итеп яралтмадык. Алар *(фани дөньяда)* үлемсез дә түгел. **(9)** Ахырда Без аларга биргән вәгъдәбезне тәгәл үтәдек. Аларны һәм ихтыяр иткән кешеләребезне коткардык. Хәттин ашканнарны һәлак иттек.

*(«Хәттин ашканнар», ягъни тыелганнарның хәтен, чиген узып, гөнаһ кылганнар, артыгын ашаганнар, артыгын гаделсез булганнар, дөрес үлчәмәгәннәр, алдаучылар, гайбәт таратучылар, караклар һәм, гомумән, җинаятьчеләр, әхлаксызлар—барысы да хәттин ашучылар.)*

**10.** Хактыр ки, сезгә шундый мәртәбәле бер Китап иңдердек: анда сезгә

үгет-нәсихәт тә, шәрәфләр дә тупланган. Һаман шуны аңламыйсызмы? **(11)** Без көферлек кылган *(гаделсез булган)* ничә мәмләкәтне *(халыкларны)* тар-мар китердек, ахырда алар урынына башкаларны яраттык.

**12.** Җәзабыз килгәнен чамалауга ук, алар кача башлый.

**13.** *(Фәрештәләр):*

—Качмагыз, байлыгыгыз янына, мул тормышка кире кайтыгыз, йортларыгызга яңадан урнашыгыз, сорау алу башлана,—диделәр. **(14)** Алар әйтер:

—Харап булдык, чыннан да, без гаделсез залим булганбыз икән,—дип кычкырырлар.

**15.** Ниһаять, Без аларны чабып ташлаган печән кебек итеп, уты сүнгән учак көле сыман, харап итеп ташлаганыбызга чаклы шулай акыруларыннан туктамаслар. **(16)** Без Күкне дә, Җирне дә, алар арасындагыларны да шаярыр өчен генә *(Үз рәхәтебезгә күрә генә)* хасил итмәдек. **(17)** Шаярырга теләсәк, *(ул шаяруларны)* Үз тирәбездә *(Үзебезнең дәрәҗәдә генә)* эшләгән булыр идек. Әмма Без шаярулардан ерак торабыз.

**18.** Һичшиксез, Без ялганның башына Хакыйкать белән сугып *(ялганның)* миен чәчрәтәчәкбез. Шунда сез күрерсез, ул *(ялган)* юкка чыгар. *(Аллаһка каршы)* ялганнар-ялалар сөйләгәнегез өчен, сезне хәтәр җәза көтә.

**19.** Күкләрдәге, Җирдәге һәммә-барчасы Аныкы. Аның янындагылар *(фәрештәләр)* тәкәбберләнми, Аңа гыйбадәт кылудан *(туктамый)* армый. **(20)** Алар армый-талмый, кич-көндез *(Аллаһка мактау)* тәсбих әйтә.

**21.** *(Мөшрикләр)* Җир астыннан чыкканнардан *(алтын-көмештән, таштан, балчыктан)* үзләренә тәңреләр ясадылар. Әллә соң аларның шул тәңреләре җансыздан җанлы ясый аламы *(үлеләрне терелтә аламы)*?

**22.** Әгәр һәр икесендә дә *(Җирдә һәм Күктә)* Аллаһтан башка илаһи кодрәт ияләре булса, алар *(Җир белән Күк һәм ул ияләр)* әллә кайчан буталып, бозылышып беткән булыр иде инде. Аллаһ сакласын! Димәк, Гарешнең Раббысы булган Аллаһ аларның гайбәтеннән өстен вә пакьтер, азаттыр.

**23.** Аллаһ Үзе башкарганнар өчен *(беркем каршысында да)* җавап тотмас; фәкать алар *(кешеләр үзләренең кылмышлары өчен)* Аллаһ каршысында җаваплы.

**24.** Аннан башка тәңреләр уйлап чыгардылар. Син аларга әйт:

—*(Аллаһтан башка тагын ходайлар бар, дип)* дәлил китерегез *(әгәр дәлилегез булса, әлбәттә)*. Менә, мина ияргән мөселманнарның Китабы *(анда ялган юк)*. Менә, миннән элек килгәннәрнең китабы *(анда кешеләр өстәгән ялган бар)*,—диген. Хәер, аларның күбесе дөреслекне белми. Шуңа күрә, *(наданлыклары аркасында Корьәннән)* йөз чөерәләр.

**25.** «Миннән башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкем юк. Шуңа күрә, Миңа гына табынытыз», дигән дөреслекне вәхий итмәенчә, Без синнән әүвәл бер генә пәйгамбәр дә җибәрмәдек.

**26.**—Ярлыкаучы *(Аллаһ)* бала атасы булды, *(Фәрештәләр—Аллаһның кызлары)*,—диделәр. Әстәгъфирулла! *(Бу—көфер сүз!)* Аллаһ андый эшләрдән пакь. Алар үзләре *(әйткән «Алланың угыллары, кызлары» дигәннәр Аллаһның)* хезмәткә куелган коллары. **(27)** Алар Аллаһ әмереннән алда сүз сөйләми. Алар бары тик Аллаһ әмере буенча гына гамәл кыла. **(28)** Ул аларның узганнарын да, алда ни күрәчәкләрен дә белеп тора. Алар Аллаһ рөхсәтеннән башка һичкемгә шәфәгать итмәсләр. Алар үзләре Аннан куркып-калтырап торалар.

**29.** Берәрсе:

—Ул тәңре түгел! Мин—тәңре!—дип әйтсә, аны җәһәннәм газабына атачакбыз. Залимнәрне Без әнә шулай җәзалаячакбыз.

**30.** Әллә соң ул имансызлар күкләр белән Җирнең кайчандыр бергә укмашкан хәлдә булганын белмиләрме? Без аларны аердык та, һәр тереклекне дымнан яраттык. Шуннан соң да алар *(мөшрикләр)* иман китермиләрме? **(31)**

Без Җир өстендә таулар калкыттык, алар селкенмичә торсыннар өчен. Алар арасында тарлавыклы юллар хасил иттек, алар тугры юлдан барып, максатларына ирешсен өчен. **(32)** Без Күк йөзен каплавыч *(саклаучы гөмбәз)* түшәм кебек итеп яралттык. Алар *(кяферләр исә Күк йөзенең дәлилләреннән, Аллаһның)* аятьләреннән баш тарта. **(33)** Аллаһ төнне, көнне, Кояшны, Айны ясады. Аларның һәрберсе үз әйләнәсе тирәсендә Күк йөзе буйлап йөзеп-очып йөрергә тәртип ителде.

**34.** Без синнән элек яшәгәннәрнең берсенә дә үлемсезлек бирмәдек. Син үлсәң, алар мәңге яшәячәкме? *(Әлбәттә, яшәмәячәк!)* **(35)** Һәр җан иясе үлем әчесен татыр. Сезне муллык, ләззәт һәм яманлык белән *(ымсындырып)* сыныйбыз. Аннан соң сез *(кылмышларыгыз өчен җавап тотарга)* кайтарылачаксыз.

**36.** *(Рәсүлем)* кяферләр сине күргәч тә:

—Шушымы инде безнең илаһларыбыз белән авыз чайкаучы кеше?—дип мыскыл итәчәкләр. Алар мәрхәмәт илә ярлыкаучы Аллаһның Китабын инкарь итүчеләрнең нәкъ үзләредер. **(37)** Түземсезлек кешенең табигатендә бар. Сезгә аятьләремне *(һәм җәзаларымны)* күрсәтермен. Ләкин сез мине ашыктырмагыз. **(38)**

—Дөресен сөйлибез, дисез икән, кайчан тормышка ашачак соң ул вәгъдәләрегез?—диләр.

**39.** Ул кяферләр йөзләре, аркалары ялкын эчендә янганда ярдәм күрмәячәк заман киләчәген белсәләр иде! **(40)** Әйе, искәрмәстән килер ул *(Ахырзаман)*, алар каушап калыр. Алар аны кире кага алмас. Һәм *(ул газап)* вакытлыча кичектерелмәс.

**41.** Хактыр ки, синнән әүвәл килгән пәйгамбәрләрне дә алар шулай мыскыл итте. Ләкин ул мыскылчылар мыскыл сәбәпчесе *(Кыямәт җәзасы)* белән чорнап алыныр. **(42)** Әйт:

—Кич-көндез сезне Аллаһ җәзасыннан кем коткара ала?—диген. Шуңа да карамастан, алар Раббыларын зикер итүдән йөз чөерә. **(43)** Әллә соң аларның Безгә каршы торырдай кодрәт ияләре бармы? *(Аларның илаһка санаган нәмәстәләре)* үзләренә үзләре дә ярдәм итә алырлык көчкә ия түгел. Алар Бездән дә игътибар-ярдәм күрмәс, җәзабыздан котыла алмас.

**44.** Әлбәттә, Без аларның ата-бабаларын да муллыкта яшәттек. Чыннан да, алар *(бетмәс-төкәнмәс кебек тоелган)* озын гомер сөрделәр. Шулай да алар инде дә күрмиләрмени соң, ихтыяр итеп, Без иләп кенә аларның җирләрен һәр яклап киметә барабыз. Шуннан соң да алар җиңүче булып кала алырмы?

**45.** Әйт:

—Мин бары тик вәхий белән сезне кисәтәмен. Бары тик *(күңеле)* чукраклар гына бу чакыруларны ишетмәс,—диген. **(46)** Хактыр ки, аларга Раббы тарафыннан кечкенә генә *(газап)* җил(е) исеп куйса да, алар шундук:

—Харап булдык! Чыннан да, без залим булганбыз икән,—дип кычкыра башлыйлар.

**47.** Кыямәт көнендә Без гаделлек бизмәннәре корып куячакбыз. Ул Көнне инде һичбер кемгә нинди дә булса гаделсезлек кылынмас. *(Кылган эшләрегезнең)* хардал *(гәрчич)* бөртеге кадәрлесен дә *(дөрес бизмәнгә)* салырбыз. Исәп-хисап өзәр өчен Мин үзем дә житәрмен.

**48.** Хактыр ки, Муса белән Һарунга тәкъвалыклары өчен, бер яктылык—үгет вә Фуркан бирдек.

*(«Фуркан» сүзенең тәрҗемә мәгънәсе изге китапларны күз уңында тота. Ягъни, яхшылыкны яманнан аеру гыйлеме. Коръәннең бүтән атамасы да Фуркан булыр».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**49.** Эчке бер курку белән Аллаһка инанганнар Сәгать сугуын *(Кыямәт килүен)* тетрәнеп көтәләр. **(50)** Менә бу *(Коръән)* Без индергән хәерле һәм файдалы кисәтү-үгетләр *(Китабыдыр)*. Сез хәзер шуны инкарь итәсезме?

**51.** Хактыр ки, моннан әүвәл Ибраһимга да *(балигълыгыннан алда)* өлгергәнлекне *(акны карадан аера белүне)* бирдек. Һәм Без аның шундый икәнен

белеп тордык. **(52)** Шул вакытта ул атасына һәм кавеменә әйтте:

—Сез нинди һәйкәлләргә *(таш сыннарга)* табынасыз?—диде. **(53)** Алар әйтте:

—Без ата-бабаларыбызның шуларга *(үҗәт рәвештә)* табынганнарын күреп үстек, диделәр. **(54)** *(Ибраһим)* әйтте:

—Аталарыгыз да, үзегез дә ялгыш-саташу юлында,—диде. **(55)** Алар:

—Син безгә хакыйкать алып килдеңме *(син дөресен сөйлисеңме)*? Әллә син бездән көләргә маташасыңмы *(ялганлыйсыңмы)*?—диделәр. **(56)**

—Юк!—диде Ибраһим.—Сезнең Раббыгыз күкләрнең һәм дә Җирнең хуҗасы. Аларны яралтучы—Аллаһ. Мин шуңа *(Аллаһның кодрәтенә)* шаһит булганнарның *(инанганнарның)* берсе буламын. **(57)**—Валлаһи, алар *(туганнарым)* арка куеп киткәннән соң, мин аларның потларына бер-бер хәл кылачакмын,—*(диде Ибраһим)*.

**58.** Шуннан соң ул потларны ватып-җимереп бетерде. Бары тик аларның иң зурысын гына ватмыйча калдырды. Тегеләр *(кяферләр)* аңарга мөрәҗәгать итсен өчен.

**59.** Тегеләре килеп сорады:

—Кем шулай безнең илаһларыбызны ватты? Хактыр ки, ул кеше бик тә кабахәт икән,—диделәр. **(60)** Берсе әйтте:

—Бер яшь егетнең илаһларыбызны сүгеп йөргәнен ишеткән идек. Ул егетнең исеме—Ибраһим,—диделәр. **(61)** Әйттеләр:

—Алайса, аны халык каршысына алып килегез. Кешеләр үз күзләре белән күрсен. **(62)**—Әй, Ибраһим,—диделәр.—Илаһларыбызны синме шулай харап иттең? **(63)** Ибраһим әйтте:

—Бу эшне, әнә, теге зурысы башкарды,—диде.—Теле булса, шуңардан сорагыз.

**64.** Шуннан соң алар *(потпәрәстләр)* үзара сөйләшә башлады.

—Чыннан да, без үзебез гаепле,—диделәр.

**65.** Сонра алар кыенсынып әйттеләр:

—Син бит аларның сөйләшә алмаганнарын белеп торасың ич *(нигә алардан сорарга кушасың)*!—диделәр. **(66)** Ул *(Ибраһим)* әйтте:

—Алайса, нишләп соң сез Аллаһны инкарь итеп, *(хәтта сөйләшер сәләте дә булмаган, телсез, чукрак)* бер зарар да, бер генә файда да китерә алмастай мескеннәргә *(потларга)* табынасыз?—диде. **(67)**—Сезгә дә, сез табына торган *(шул ташларыгыз)* өстенә дә—тьфү! Инде дә акылга килеп, сабак алмассызмыни?

**68.**—Аны *(Ибраһимны)* утка атарга кирәк!—диделәр. Икенчеләре исә:

—Илаһларыгызны аннан яклап калыгыз, әгәр дә сез тәвәккәл кешеләр булсагыз,—диделәр.

**69.**—Һәй, ялкын!—дидек.—Ибраһимга зарар китермә, салкынчалык бир. **(70)** Шулай итеп, алар тозак корган иде дә, Без аларны бичара хәлдә калдырдык. **(71)** Без аны да, Лутны да коткарып калдык. Аларны галәм халыклары өчен житәрлек бәрәкәтле жиргә урнаштырдык.

**72.** Аңа *(Ибраһимга)* Исхакны вә Ягъкубны, аерым бер бүләк буларак бирдек вә барысын да игелеклеләрдән кылдык. **(73)** Әмеребез буенча, аларны тугры юл күрсәтүче остазлар иттек вә үзләренә хәерле эшләр башкаруны, намаз укуны, зәкят бирүне вәхий иттек. Алар Безгә өзлексез гыйбадәт кылучылар булды.

**74.** Лутка да хөкем вә гыйлем бирдек. Аны чиркаңыч эшләр кылучы халыктан коткардык. Алар, хактыр ки, фетнәче, фасикъ кавем иде. **(75)** Аны *(Лутны)* рәхмәтебезгә кабул кылдык. Чөнки ул изгеләрдән иде. **(76)** Аннан да элегрәк Нух та дога кылды. Без аның догасын кабул кылдык. Шулай итеп, үзен вә иман китергән якыннарын зур афәтләрдән коткарып калдык. **(77)** Аны аятьләребезне инкарь иткән кавемнән коткардык. Хактыр ки, алар фетнәби кавем иде. Шуңа күрә, аларның бөтенесен дә суга батырдык.

**78.** Шулай ук Даут белән Сөләйманны исегезгә төшерегез. Берзаман алар

иген басуы хосусында бәхәскә керде. Берәүләренең сарык көтүе, кичке якта икенчеләренең иген басуына кереп, бик күп зыян китергән иде. Без аларның хөкем эшләренә шаһит булып тордык.

*(«Бу гауганы хөкем итүче Даут белән унөч яшьлек Сөләйман—икесе ике төрле карар чыгара. Даут: «Зыян күргән игенчегә сарык көтүен бирергә»,—ди. Ләкин Сөләйман: «Күрелгән зыянны каплаганга кадәр генә бакча иясе сарыкларның йоны, сөте, итеннән файдалана ала, зыян каплангач, сарыклар хуҗасына кайтарып бирелергә тиеш»,—ди һәм Даут сабый углының хөкеме белән риза була.»*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**79.** Шулай хөкем йөртергә Сөләйманга Без әмер иттек. Без аларның һәр икесенә дә хөкем хокукы вә гыйлем бирдек. Кошларны һәм тәсбих әйтүче тауларны Даутка буйсындырдык. Бу эшләрне Без әмер иттек. **(80)** Сугыш вакытында сезне *(кылычтан)* саклар өчен, тимер көбә ясау гыйлемен аңа өйрәттек. Инде шөкер итәчәксезме?

**81.** Сөләйман әмеренә Без дәһшәтле искән җилне бирдек. Аның кушуы буенча, ул җил эче тулы бәрәкәтләр булган урынга туры карап исә. Без барысын да белеп торабыз. **(82)** Аның өчен диңгезгә чумып *(энҗе-мәрҗәннәр алып чыксыннар, дип)* һәм башка төрле эшләр майтарыр өчен, шайтаннарны буйсындырдык. Без аларны күреп торабыз.

*(Шайтан, Иблис, җеннәр мәсьәләсенә М. Али бу шәкелдә карый: слово шайтан (т. е. дьявол) означает того, кто чрезмерно занозчив и непокорен, независимо от того, человек это, джинн или зверь. 654 бит, 1647 нче аңлатма.)*

**83.** Әйюбне исенә төшер. Ничек итеп ул Раббысына:

—Башыма бәла килде. Син мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе бит *(зинһар, ярдәмеңнән ташлама)*,—дип ялварган иде. **(84)** Без аның бу догасын кабул иттек. Аның башына төшкән бәлане алдык. Үз тарафыбыздан рәхмәт булсын дип, гыйбадәт кылганнар өчен бер сабак булсын дип, аңа гаиләсен, малларын һәм башка нигъмәтләрне артыгы белән кайтарып бирдек.

*(«Әйюб ун ел хаста булып, йорты җимерелеп, байтак кына кардәшләрен югалтып, иза чигә иде.»*

Хәйретдин Караман белән Хәсән Чантай тәфсирләреннән.)

**85.** Исмәгыйльне дә, Идрисне дә һәм Зөлкәфилне исегезгә төшерегез. Барысы да сабыр *(түзем)* кешеләр иде. **(86)** Аларны якладык. Алар, чыннан да, игелекле кешеләр иде.

**87.** Балык кешесе Зүннүн *(Юныс)* турында да онытмагыз. Ул *(үзенең киребеткән кавеменә)* бик нык үпкәләп, ачуланып киткән иде. Үзенә көчебез житмәс, дип уйлаган иде ул. Ниһаять, караңгылыкка *(балык эченә барып)* эләккәч:

—Синнән башка Сиңа тиң һичбер зат юк. Сине генә пакь, дип таныймын. Чыннан да, мин гаделсез булганмын икән,—дип Аллаһка ялвара башлады.

*(«**Зүннүн**, **Зөлнүн**—хәзрәти Юнысның кушаматы, ягъни «Балык кешесе» дигән сүз. Юныс пәйгамбәр озак вакытлар халкын хак дингә өнди. Яхшы нәтиҗәләргә ирешә алмагач, ул үз халкына үпкәләп, көймәгә утырып, диңгезгә чыга. Һәм суга бата, аны зур балык йота. Ләкин аны Аллаһ Тәгалә коткарып кала».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**88.** Шуннан соң без аның догасын кабул иттек һәм аны бәладән коткардык. Менә, шул рәвешле Без мөэминнәрне коткарабыз.

**89.** Зәкәрияне дә исегезгә төшерегез. Ничек итеп ул Раббысына дога кылды:

—Раббым, мине ялгыз калдырма *(миңа токым, нәсел бир)*. Син варислар арасында иң мәрхәмәтлесе,—диде.

**90.** Без аның догасын кабул иттек. Аңа угыл *(Яхъяны)* бирдек. Хатынын да үзе өчен *(бала таба торган итеп)* кулай кылдык. Алар *(алда саналган пәйгамбәрләр)* игелек өчен ярышып, яхшы эшләр башкарды. Курку белән өмет арасында Безгә гыйбадәт кылдылар. Алар Безгә тирән мәхәббәт тәрбия иттеләр.

**91.** Гыйффәтлелек мөһерен саклаган *(хәзрәти Мәрьямне дә)* исегезгә төшерегез, зинһар. Без аңа рух өрдердек; аның үзен һәм углын *(Гайсәне)* бөтен галәмгә үрнәк кылдык.

**92.** Хакыйкатән, бу өммәт *(бер диндәге мөселманнар)* бары тик сезнең өммәтегез генә. Сезнең Раббыгыз—Мин. Шулай булгач, Мина гына гыйбадәт кылыгыз.

**93.** Инсаннар *(дин һәм мал өчен)* үзара талашып, бердәмлекне боздылар. Гәрчә, аларның барысы да *(җавап тотар өчен)* каршыма басачак. **(94)** Иман китереп, игелек кылган кешенең тырышулары заяга китмәс. Аларны аның файдасына *(гамәл дәфтәренә)* яза барабыз. **(95)** Һәлак ителгән шәһәрләр*(нең кешеләре дөньяга кире кайтмаслык итеп)* каргалган.

**96.** Ниһаять, Яэҗүҗ белән Мәэҗүҗ *(диварлары)* ачылып, алар биектән ташкын булып аска томырылганчыга кадәр һәм **(97)** чын вәгъдәбез *(үлем, Кыямәт көне)* якынлашканчыга чаклы, инкарь иткәннәрнең күзләре тонып, шар ачык калыр.

—Харап кына булдык,—дип кычкырырлар.—Чыннан да, без болай булыр, дип уйламаган идек. Без, чыннан да, кяферләр булганбыз икән. **(98)** Сез дә *(кяферләр)* һәм: «илаһ» дип, Аллаһтан башкага *(сыннар, потларга)* табынганнарыгыз да җәһәннәм кисәве булачаксыз. Сез шунда керәчәксез. **(99)** Әгәр алар, чыннан да, илаһ булсалар, анда *(җәһәннәмгә)* кермәгән булырлар иде. Хактыр ки, аларның барысы да *(табынганнар да, илаһ урынындагы сыннар, һәйкәлләр дә)* анда *(җәһәннәмдә)* мәңге калачак. **(100)** Алар анда ыңгырашып иңрәрләр һәм һич нәрсә ишетмәсләр.

**101.** Шик юк ки, Безнең тарафтан иң яхшы әҗерләр бирергә вәгъдә ителгәннәргә килсәк, менә шулар була инде җәһәннәмнән ераклашканнар. **(102)** Болар күңелләре теләгән нигъмәтләр эчендә мәңге яшәп калырлар һәм аның *(җәһәннәмнең)* тавышын ишетмәсләр. **(103)** Иң хәтәр *(җәза)* шаукымнар да аларны *(игелекле мөэминнәрне)* куркытмас *(гаебе булмаган кеше курыкмас)*. Аларны фәрештәләр болай каршылар:

—Менә, бу сезгә вәгъдә ителгән *(бәхетле)* көнегез,—дип әйтерләр.

**104.** Язучы язган кәгазьләрен ничек итеп төрә, Без дә ул Көнне Күкне шулай төрербез. Иң башта ясый башлагандагы хәлгә китерербез. Без шулай кылырга вәгъдә иткән идек. Без вәгъдәбездә торырбыз. **(105)** Хактыр ки, Тәүраттан соң Зәбурны да Без яздык: бары тик тугры колларым гына Җир йөзенә варис булып калачак,—дидек. **(106)** Шик юктыр ки, монда *(Корьәндә)* чын күңелдән Аллаһка инанганнар өчен күрсәтмәләр, чаралар бар.

**107.** *(Ий, Мөхәммәд)* Без сине бары тик рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек. **(108)** Әйт:

—Миңа бары тик: Аллаһтан башка Илаһи кодрәткә ия һәм Тәңре булырлык һичберкем юк, диеп вәхий бирелде. Әле һаман да мөселман булмаскамы исәбегез?—диген. **(109)** Әгәр *(синең өндәүләреңнән)* йөз чөерсәләр әйт:

—*(Хакыйкатьне)* сезнең барыгызга да тигез белдерәмен *(мөселманына да, кяференә дә)*. Сезгә вәгъдә ителгәннәр *(җәннәт белән җәһәннәм)* кайчан була *(бүгенме, иртәгәме)*, мин белмимен,—диген. **(110)**—Шик юк ки, Аллаһ кычкырып әйткән сүзләрне дә, яшертен сөйләгәннәрне дә белеп торучы. **(111)** Мин белмимен. Бәлки, бу эшләр сезне вакытлыча сынап карау *(һәм дөнья нигъмәтләреннән файдаландыру)* гынадыр. Ихтимал.

**112.** *(Мөхәммәд әйтте)*:

—Раббым, Үзең гаделлек белән хөкем ит. Безнең Раббыбыз рәхимле. Аллаһка хас булмаган сыйфатлар өстәп, ялган сөйләгәннәргә каршы көрәшергә Аллаһтан ярдәм сорагыз.

# ЯЗМЫШНЫ БУЛМЫЙ АЛДАП

## ПЕДАГОГ ҺӘМ МУЗЫКАНТ РӘГЪДЕ ХАЛИТОВКА 60 ЯШЬ

*Гармун бәләкәй булса да,*
*Әйтә ул кирәкләрен.*

Татар халык жыры.

### Көтелмәгән очрашу

«Ходай өмет итмәгән жирләрдән бирсен»,—дип теләк тели безнең халык.

Әгерже якларына барып чыгуым да бөтенләй көтелмәгәнчә булды. Аны «Татарстанның Камчаткасы» дип шаярткалыйлар. Газетлардан, радио-телевидениедән дә анда хәтле барырга бик ашкынып тормыйлар. Озын-озакка сузмадым, Әгержегә барып радиотапшырулар әзерләргә булдым.

Алдан ниятләгән эшләрнең очына чыккач, «Татарстан Камчаткасы» белән ныклабрак танышырга уйладым. Жәяүләп кенә урамнарыннан йөрим.



Кинәт колагыма музыка тавышы килеп керде. Адымнарымны акырынайттым. Як-ягыма каранам. Кечерәк кенә бер агач өй тәрәзәләреннән агыла икән. Туктап калдым. Игътибар беләнрәк тыңлыйм. Бөек Бетховенның «Аппассионата»сы түгелме соң бу? Әйе, әйе, «Аппассионата»! Фортепьянода уйныйлар. Гап-гади агач өйдә. Килеш-килбәтеннән күренеп тора: анда татарлар яши. Елмаеп куям. Музыка тавышы, кечерәк кенә агач өйгә сыешмыйча, урамга агыла.

Әгерждә бер тыкрыкка сыенган агач өйдә кемнеңдер моңа кодрәте житкән. Кем бу? Уены да колакка ятышлы, күңелгә ятышлы. Кем бу?.

Кара, мин бит Татарстан радиосында эшлим, иннәремә магнитофон асылган, кечерәк кенә агач өйдә «Аппассионата»ның серләренә төшәргә батырчылык иткән кешене күрмичә ничек китеп барыйм?!. «Ходайның өмет итмәгән жирдән бирүе» менә шулдыр инде.

Мөлаем генә бер апа ишекне ачты. Иңнәремә асылган магнитофон ышаныч бирдеме, ул күптәнге танышын каршы алган сыман:

—Әйдәгез, узыгыз,—диде.

—Исәнмесез!—дип әйтүемә елмаеп жибәрде.

—Тавышыгыз таныш, радиодан сөйләүчеме?—дип тәгаенләде.

—Әйе.

—Безнең Әгерже якларына да килеп чыккансыз икән... Ни эшләр бетереп йөрисез?

—Менә авылларыгызны әйләнеп кайттым әле. Турыгыздан узганда музыка тавышы ишетеп сезгә дә кереп чыгарга булдым. Игътибарсыз гына узып китә алмадым. Апа, фортепьянода уйнаучы кемегез ул?

—Төпчек кызым Равия, әлегә мәктәптә укый. Абыйсы, менә шуны өйрән, дип китте.

—Кем соң аның абыйсы?

—Радиода эшләгәч, беләсездер әле, Рәгъде Халитов, баянда уйнавын радиодан да биргәлиләр.

—Бар, уйнавын ишеткәнем бар, күрешеп танышканыбыз гына юк.

Күптәнге танышлар кебек сөйләшә-сөйләшә керүебез фортепьяноға «чумган» кызны бераз гажәпләндерде, ахрысы, ул уйнавыннан туктап безгә караш ташлады.

—Кызым, менә Казаннан кунак килгән, синең уйнавыңны ишетеп безгә дә керәсе иткән. Абыеңны да белә икән.

Фортепьянода уйнавын магнитофон тасмасына да яздырырга теләвемне белгәч, кызый бераз унайсызланып куйды.

—Юк инде, абый, мин үзем өчен генә уйныйм, күңегүләр ясыйм. Рәгъде абый да ачуланыр. «Рәтләп өйрәнмәгән килеш, нигә ашыгасың?»—дияр...

—Ярар, ярар, алай булгач, язмам,—дим.—Шулай да уйнап күрсәтегез әле, сеңлем.

—Уйна әле, кызым, үзебезнең татар халык көйләрен.

Әле генә «Аппассионата» белән сихерләгән кыз «Туган тел»не уйнап җибәрде.

Сизелеп тора: ул әле мәктәптә генә укып йөрсә дә, үзен шактый иркен тота, бер көйдән икенчесенә шулкадәр оста күчә: халкыбызның борынгы көйләрен Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Заһидулла һәм Фәрит Яруллиннар белән Европа классикасын да бер бөтен итеп бәйли. Музыка дөньясы чикләрне белми. Халитовларның төпчек кызы менә шушы хикмәтне тоемлап өлгергән. Җил кайсы яктан иссә, шуңа ияруче өйрәнчек кенә түгел ул. Куллары-бармаклары да, күз карашы да сихри моңнарның назын гәүдәләндерә.

Шик юк: Казан дәүләт педагогия институтында (хәзер университет) укытучы музыкант абыйсы «мәктәбе»нең йогынтысы туган якларын да колачына алган. Татарстанның төрле якларыннан, башка республикалардан һәм өлкәләрдән җыйналган талантлы яшьләрне «ачып җибәрү» өчен җан атып йөргән педагог бертуган сеңлесен күздән ычкындырмас инде.

Нурдидә апа әледән-әле улын телгә ала.

—1958 елда әтиләре вафат булгач, Рәгъде үзенең баяны белән гаиләбезнең бөтенлеген дә саклап калды—ди ул.—Өч яшеннән гармун уйный башлаган бала хикмәтсез түгелдер инде...

—Өч яшьтә гармун уйный башлагач, өегездә гармун да булгандыр?—дим.

Нурдидә апа көлемсерәп ала.

—Алдакчы буласым килми, ул урыс гармунының безгә ничек килеп керүен хәтерләмим. Гармун дисәң, хәтере калыр,—ди ул.—Ничек чыгарып атмаганбыз—шунысына гаҗәпләнәм. Бәлки, берәр туганым онытып киткәндер. Алар арасында музыка белән кызыксынучылар бар, шулайдыр, берәрсе онытып калдыргандыр. Без аны бар дип тә белмәдек... Өлкәннәр анда төрткән, монда төрткән шул гармунга өч яшьлек малайның күзе төшә. Күзе төшеп кенә калмый, тарта-суза, колак ишетмәгән тавышлар чыгара.

Өйдәгеләр игътибар беләнрәк тыңлыйлар. Әнисенең җырлаганын күңеленә салып куйганмы, әллә стенадагы «тәлинкәгә» охшатыпмы—малай тавышларны үзенчә тәртипкә китерә, көй чыгарып маташа...

1945 ел. Халыкка җиңү шатлыгын, өметләр алып килгән ел. Нәкъ менә шушы 1945 елда Рәгъде гармун уйнарга өйрәнә, үзенең моң чишмәсен ача, шуннан бирле ул ага да ага.

Тотарлыгы да калмаган гармун балалар бакчасында да уйнарга ярап куя әле. «Капиталь ремонт» үтә-үтә, ул мәктәпкә дә, клубка да барып житә. Халитовларның гармунчы малае Әгерже каласында шөһрәт казана.

Унъеллык «стажы» булган гармунчыга—бишенче класста укучы Рәгъдегә—беренче тапкыр яңа гармун сатып алып бирәләр.

Җиденче класста укыганда аккордеонга тиенделәр.

Тугызынчы класста укыган Рәгъденең әтисе авырып китә, мәңгелеккә күз йомар вакыты җитүен сизенептер, хатынына соңгы әманәтен әйтә:

—Сиңа мең-мең бәхил, тугыз баламны бактың, кеше көлдермәдең,—ди.—Шулай да бер үкенечем калды...

Хатыны күз яшьләрен тыя алмый:

—Нинди үкенеч ул?..

—Хәтерендәдер, без бит Рәгъдегә баян алып бирергә дигән идек, минем шушы әманәтемне үти күр...

Әтиләренең кырыгын үткәргәнче үк ана иренең соңгы әманәтен үтәргә ашыга.

Баянны кулына алган Рәгъде нишләргә белми. Моны сүз белән аңлатырга да мөмкин түгелдер. Бу баян... бу баян... уен коралы гына түгел. Анда әтисенең йөрәк тибеше, әнисенең әманәткә хыянәт итмәве дә. Тугыз баланы өзелмәс жепләр белән бәйләү дә ул. Бу—ата-ана алдындагы бурыч та. Бу баян белән начар уйнасаң, үзеңне жир йотар...

Татарстан радиосыннан Мөхтәр Әхмәдиев, Рокыя Ибраһимова, Рәис Сафиуллиннарның уйнавын тыңлаганда күңелдә нинди хисләр генә тумый, алар буй житмәс биеклек кебек, тик куркытмый бу биеклек Рәгъдене, ә үзенә дәшә...

Бүлмәләре тар булса да, күңелләре киң.

Кулына өлгергәнлек аттестаты алгач, «Әгерженең беренче гармунчы»сы аптырашта кала. «Мин музыкасыз яши алмам» дип үзенчә хәл итсә дә, «музыка белән яшәүнең» ни икәнен белеп бетерми икән.

Укытучылары да, классташлары да, таныш-белешләр дә: «Синең өчен борчылмыйбыз»,—дип, аңа жиңел язмыш юрыйлар. Ник дисәң, Рәгъде оста гармунчы булу өстенә бик тырыш та, эш сөючән ата-ананың асыл сыйфатлары аңа да күчкән. Аның агач эшенә дә кулы ятып торуын беләләр. Кәкре-бөкре такталардан да әллә ниләр ясап куя ул.

Ә күңеле тулы шом. Укытучыларың, классташларың белеп бетерә аламы соң аны? Әле үзеңне табып үстергән әнкәңә дә бөтенесен ачып салмыйсың.

Шунысы да уйландырмыйча калмый. Әгерже районы тулысы белән Удмуртия эчендә. Коры жирдән Татарстанның бер авылы белән генә дә чиктәш түгел, ичмасам. Кама елгасының икенче ягында—Актаныш, Минзәлә. Күрергә якын да, барырга ерак. Әгерженең булдыклы, кирәк чакта булышырдай кешеләре Ижау каласына тамыр жибәргән. Казан ерак, аның тарту көче дә әллә ни сизелми.

Рәгъде Ижауда да югалып калмас иде, яхшы гармунчылар беркайда да артык түгел, тик ул бөтен жаны-тәне белән Казанга тәбәлгән. Тукайлар, Такташлар, Сәйдәшләр рухын саклаган Казанга ашкына.

Укучысының борчуларын сизенгән шикелле, жыр укытучысы Фрид Рәхмәтуллин халык арасында бик танылып киткән Рәис Сафиуллинга хат язып бирә.

—Ул минем бик яхшы таныш, киң күңелле кеше, сине дә кире борып чыгармас,—ди.

Рәгъденең күзләре очкынланып китә.

Рәис Сафиуллинны бер күрер өчен дә әллә кайларга барырга риза ул. Татар баянчылары арасында ул үзенчә аерылып тора. Күптәннән таныш көйләрне дә янача ачып бирә. Нинди генә борылмаларга алып керми. Шундый останың өенә әллә кайдагы Әгерже малае барып керсенме?!.

—Син унайсызланып торма,—ди Фрид абыйсы.—Миннән сәлам тапшырырсың. Мин бит теләсә кемне Рәис Сафиуллинга жибәрмим. Әйтәм бит: хатыны да үзе шикелле, кече күңелле, бик ярдәмчел.

Башында мең төрле уй Рәгъденең. Шулай да аттестатын, баянын, укытучы язган хатны «күтәреп» Казанга юл тота ул. Әлбәттә, иң беренче уе Рәис Сафиуллин белән очрашу.

...Ишек ачылды.

Бер урында таптанып торган үсмер егетне күреп, хужа кеше сорап куйды:

—Безгә килүегезме, энекәш?

—Сез Рәис Сафиуллин буласызмы?

—Нәкъ үзе. Нишләп бусага төбендә сөйләшеп торабыз әле, әйдәгез, өйгә керегез.

Бусаганы атлап кергәч, Рәгъде үз күзләренә үзе ышанмады. Шундый кеп-кечкенә бүлмәдә дә кешеләр яши микәнни?!.

Рәис Сафиуллин кеткелдәп көлеп алды.

—Бүлмә кечкенә булса да, күнел иркен безнең. Әйдәгез, танышыйк.

—Мин Әгерҗедән, Фрид абыйдан сезгә сәлам тапшырырга кердем.

—Мөһимә, ишетәсенме, Фрид безгә сәлам җибәргән.

—Сәлам җибәрүчегә дә, әманәтне тапшыручыга да рәхмәт инде,—дип ханым сүзгә кушылды:

—Үзегез кем буласыз?

—Фрид абыйның укучысы, Рәгъде Халитов. Ул сезгә хат язган иде, менә ул.

Рәис Сафиуллин тиз-тиз генә күз йөртеп чыкты, аннары хатны Мөһимәсенә сузды.

—Кая укырга керергә исәп?—дип белеште Рәис Сафиуллин.

—Мин әле эшкә урнашырмын, дим. Консерваторияне әйткән дә юк, училищега керергә дә белемем сай. Эшләрмен дә, музыкантлардан дәресләр дә алырмын. Шулай итсәм, дөресрәк булыр, дим.

—Сез инде бөтенесен дә хәл итеп бетергәнсез, сезгә ничек булышырга да белмим—дип шаяртты Рәис Сафиуллин. —Шулай да уйнап күрсәтегез әле. Баяннарның теләсә кайсын сайлап алыгыз.

Радио аша тыңлаганда буй җитмәслек булып тоелган Рәис Сафиуллин бик гади кеше икән. Хатыны да бик ачык.

Уйный егет. Көй артыннан көй. Татар халкының борынгы көйләре, музыкаль драмалардан, музыкаль комедиядән өзекләр уйный.

Хуҗаларның йөзендә елмаю чаткылары уйный. Елмаюны начарга юрамыйлар. Алар егетнең уйнавын ошатуларын яшермәделәр дә.

Рәгъде үзлегеннән өйрәнүнең бөтен баскычларын узган. Укымаса, кайгыртучан остазлар кулына эләкмәсә, ул шулай калырга да мөмкин. Теләсә кайда уйный алыр, үзен яратучылар да булыр, әмма профессиональ сәнгатькә барып җитә алмас. Сәнгать юлы бик тайгак та, бик борылмалы да. Үз юлыңны таба алмасаң, гомер буе өйрәнчек булып каласың.

Рәгъде уйный, Рәис Сафиуллин үзенчә планнар кора.

—Сәләтегезгә шигем юк,—ди ул.—Ә укырга кирәк. Киләсе елга кадәр вакытны әрәм итәргә ярамый. Шушы кечкенә генә бүлмәбезгә атнасына ике тапкыр килерсез, һичьюгында музыка училищесына керерлек итәрмен.



*Айрат Арсланов, Римма Ибраһимова, Хәйдәр Бигичев, Венера Шәрипова, Рәгъде Халитов Хельсинкида концерт вакытында. 1980 ел.*

—Сезгә артык мәшәкать тудырмыйммы соң?

—Күңел тарткан эшне эшләми калудан гына куркам мин. Димәк, ризалаштык. Атнага ике тапкыр монда киләсез.

—Сезгә ни әйтергә дә белмим инде, Рәис абый, Мөһимә апа!

—Шуны истән чыгармагыз,—ди хужа,—гармунчыларның буш вакыты юк. Безнең һәр сәгать исәптә. Вакытында килергә тырышыгыз. Бүгеннән үк «өйгә эш» биреп җибәрәм. Менә шушы нотаны өйрәнеп карагыз әле, ике көннән аңлашырбыз...

Рәгъде шактый ук шомара төшкәч, Рәис Сафиуллин тагын бер мөмкинлек барын аңлатты. Ул бит Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музыка җитәкчесе, кичләрен спектакльләрне җанга якын аһәңнәр белән бизи.

—Спектакльләргә сез дә килә аласыз,—ди ул.—Мин бит сәхнә артыннан да уйныйм, шәп гармунчы булып йөри торган артистларга «булышам». Минем янда утырып сез дә уйнарсыз, шушы «эш» белән дә танышырсыз. Уйнавыгыз артистлар өчен булса, өйрәнүегез—үзегезгә.

«Сәхнә артыннан артистларга булышу» дигән сүзләр сәеррәк тоелса да, Рәгъде чамалады: сәхнәдә «буш гармун» белән уйнаучыларның көен чыгару бу.

Егеткә күк капусы ачылгандай булды. Төзелешкә эшкә урнашты, тулай торактан урын бирделәр. Рәис Сафиуллинның укытучылык сәләте дә көчле икән. Әллә нинди катлаулы нәрсәләрне дә җиңел генә аңлатып бирә, үзе үк уйнап та күрсәтә. Рәгъденең бармакларына кадәр үзгәрә кебек.

Академия театры спектакльләренә йөрү үзе бер мәктәп булды.

Театрда Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» драмасы буенча куелган спектакль гөрләп бара. Композитор Хөснул Вәлиуллин да музыкасын бик килештереп язган. Әле укуын да тәмамламаган Наилә Гәрәева тамашачыларны әсир итте.

Театрда еш кына шундый хәлләр була: бер төркем театрның үзендә спектакльләр куя, икенче төркем районнарга чыгып китә. Рәис Сафиуллинга да районга китәргә туры килде. Кичен театрда спектакль. Мондый чакта нишләргә? Хәер, артык баш ватмадылар да, Рәгъде бар ич! Берсүзсез аңа ышаныч күрсәттеләр.

Тамашачылар аны күрмәде дә, исемен дә ишетмәде, әмма артистның «өздереп гармун уйнавы»на беркем дә битараф калмагандыр, ничә тапкыр гөрләтеп кул чаптылар. Бу—Рәгъде Халитовның яңа баскычка күтәрелүе иде. Булсын, ул әлегә күләгәдә калсын, әмма кояш аны да яктыртмыйча калмас.

Яз башында ук җәйге гастрольләрнең маршрутларын ачыкларга керештеләр. Берничә төркем белән төрле якка юнәлергә булдылар. «Беренче мәхәббәт» спектаклен нефть чыккан якларда көтәләр. Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск районнарыннан көн саен диярлек телефоннан шылтыраталар. «Берүк безне читтә калдыра күрмәгез!» диләр. Башкортстанның күрше районнары да ялынып-ялварып сорыйлар. Менә бит ничек, Рәгъде көн саен күреп, сөйләшеп торган артистларны халык күтәреп алып китәргә риза. Рәгъде Халитов «кечкенә кеше», ул бу сүзләргә катнашмый да. Әлегә бит ул «күләгәдә». Күләгәдә икәнсең, телеңне дә тыясың.

«Беренче мәхәббәт» спектакле белән нефть районнарына барырга тәкъдим ясыйлар. Рәис Сафиуллин хәлне аңлатып бирә.

—Үземә ышанган кебек, сезгә дә ышанам,—ди.—Хәзер менә сезнең көчегез җитә. Сез спектакльгә язылган музыканы яттан беләсез. Үзем башка төркем белән китәрмен, сез нефть якларын күреп кайтыгыз.

—Ә төзелештән мине җибәрерләрме соң, Рәис абый?—ди егет.—Җәй көне анда да эшнең кызган чагы. Ял көннәрендә дә эшләп калырга тырышалар. Рөхсәт сорарга да уңайсызланам.

—Җитәкчегез ниндирәк кеше?

—Болай ипле, җайлы гына үзе. Михаил Абрамович Соломонов.

—Димәк, акыллы кеше. Әйбәтләп аңлатсагыз, ул безнең хәлгә керми калмас. Анда татар егетләре, татар кызлары күптер, үзләрен «Беренче мәхәббәт» спектакленә кунак итеп чакырырбыз. Иртәгә үк барысын да ачыклап килегез.

Рәис Сафиуллин икеле-микеле сөйләшергә урын калдырмады.

Рәгъде нәрсә дисең, Михаил Абрамович янына керергә булды.

Идарә башлыгы чыннан да зирәк кеше икән. Ике дә уйлап тормады.

—Шундый ышаныч күрсәтәләр икән, бар, Халитов!—диде.—Беләсенме, ул бит театр, театр... Без бит кирпеч, измә белән генә яшәмибез. Кая гаризан? Ә, әле язмадынмыни?! Алайса менә монда утыр да яз.

Михаил Абрамович гаризага кул куя да:

—Үзенә ике ай ярымга түләүсез ял бирәм. Театрга булышмыйча ярамый,—ди.—Төрле жирләрдә булырсыз, алдына-артына карап йөр анда...

Әйтерсең лә сүз куешканнар. Рәис Сафиуллин да идарә башлыгын куәтләгәндәй итте:

—Гастрольләр бик тиз үтеп китәр. Санаулы көннәрне кояшта кызынып, су коенып кына үткәрә күрмәгез. Кайту белән имтиханнар тапшырасын онытмагыз. Китапларыгыз яныгызда булсын. Өстәмә эшләр дә биреп жибәрәм. Шушы әсәрләрне нотага карап уйнарга өйрәнегез. Боларны жинү жинел булмас. Ә жинәргә кирәк!

Шул көнне Рәгъде әнисенә хат язып салды: «Минем өчен борчылмагыз, академия театры белән нефть районнарына китәбез. Китапларны да алам, имтиханнарга да әзерләнәчәкмен».

1960 елның җәйге айлары Рәгъде Халитовның бик күп сорауларына җавап тапты. Яраткан бәндәсенә ходай да өмет итмәгән җирдән бирәдер. Нәкъ шул елны Казан педагогия институтында музыка факультеты ачылды. Урта белеме булган, музыкаль белем нигезләрен дә шактый үзләштергән, баянда бик оста уйнаган Рәгъде Халитовка училищеда укуның кирәге калмады, яңа факультетта аның кебекләр укымыйча, кем укысын?..

Рәис Сафиуллиннарның кеп-кечкенә бүлмәсендә дәресләр алу, Татар дәүләт академия театры баянчысы булып нефть чыккан якларны әйләнеп кайту институтка да юллама бирде кебек.

## Кеше ничә тапкыр туа?

Казан дәүләт педагогия институтының музыка факультетына «жырлап узган» Рәгъде Халитов укулар башланганчы Әгерҗегә кайтып килергә булды. Академия театры гастроленда шактый акча эшләгән икән, баштанаяк өр-яңадан киенде. Казан Казан инде, Әгерҗе дә, Ижау гына да түгел. Монда кием икенчерәк.

Һәрвакыт пөхтәлеккә, матурлыкка тартылган музыкант егет башкалардан калышсынмы? Көзге каршысына килеп баскач, үзен-үзе танымагандай гаҗәпсенеп карап торды. Киемнәре бик килешле, бик затлы. Кара, исәеп тә киткән кебек. Үзенең туган нигезенә ул инде икенче кеше булып кайтты.

Рәгъде Халитов тормышында шулай итеп яңа чор башланды. Балачак, үсмерчак артта калды, ул инде өлгергән егет, педагог-музыкант булырга җыена. Әле имтихан алучылар да кат-кат кисәттеләр:

—Сез башкаручы-музыкант кына түгел, педагог-музыкант, мәгърифәтче дә булырга тиеш,—диделәр.

Казан дәүләт педагогия институтында музыка факультетын ачу—Татарстан мәктәпләрендә, аннан читтә дә музыка укытуга мөнәсәбәтне үзгәртергә тиеш. Талантлы балалар эзсез югалмасын.

Беренче очрашуда ук укытучы-баянчы Василий Павлович Плетнев мәсьәләне кабыргасы белән куйды:

—Чын профессиональ осталыкка күтәреләсегез килсә, минем таләпләремне жиренә житкереп үтисез. Мин үземнен улым Мишага да бернинди ташлама ясамыйм, сезгә дә шулай ук булачакмын.

Башта бик кырыс кеше кебек күренсә дә, кайгыртучан остаз булып чыкты ул. Берәр әсәрне уйнаганда «чыпчык очыра» башласаң, кул чабып туктата да күзенә карый. Түбәнсетми, йөрәгенә кадалып калырдай сүзләр әйтми. «Менә мөмкин бит»,—дип үзе уйнап күрсәтә. Уйнаганда ничек тын аласың—барысын да күрә, тоя ул.

Рәгъде еш кына аны үзенең әтисе белән чагыштырып карый. Охшаш яклары күп. Әтисе дә бик сизгер, бик сәләтле булган, әнисенең: «Әтиегез

кайтканчы шуларны эшләп куегыз»,—дип әйтүе дә житә иде аларга.

Василий Павлович, әлбәттә, икенче кеше, ул мәшһүр баянчы-педагог.

Рәгъделәр төркеменен бәхетенәдер... үз эшләренә фидакарьләрчә бирелгән педагоглар, музыкантлар факультетның йөзен билгеләде. Полифония һәм гармония серләрен ачучы Арнольд Арнольдович Бренинг, беренче декан Лариса Филипповна Паныкина, теория белән практиканы шулкадәр оста бәйләүче Маһинур Жиһаншина вакытларын да, көчләрен дә кызганмадылар.

Жәйге каникул вакытларында Рәгъдене танылган жырчылар гастрольләргә чакыралар. Ялгызың уйнау бер хәл, ә жырчы белән сәхнәгә чыгу бөтенләй икенче. Монда осталык кына житми, син жырчы белән тамашачыны бәйләргә тиешсең.

Еллар узгач, Татарстанның халык артисты, кырык еллап Татарстан радиосының музыкаль редакциясен житәкләгән Рафаэль Ильясов шундый бәя бирер:

«Рәгъдене мин күпкырлы баянчы дип әйтер идем. Мина, аның белән сәхнәләрдә утыз ел буе чыгыш ясаган кешегә, Рәгъде хакында шулай дип һич шикләнмичә әйтергә буладыр: чөнки бик күп тапкыр баянда аның соло уйнаганын ишеткәнем бар. Ә инде аңа кушылып жырлаганда ул инде бөтенләй икенче Рәгъдегә әйләнә: ул, сине тыңлап, сиңа комачауламыйча уйный, булыша. Баянчының бу сыйфатларга ия булуы бик мөһим». *(«Татарстан баянчылары», 1996. 110 бит).*

«Татарстан баянчылары» китабына, «Татар энциклопедик сүзлеге»нә керермен, дип Рәгъде уйламагандыр да. Моның өчен әле күп сынаулар аша узарга кирәк булган. Рәгъде Халитов студент чагында ук тырышлыгы белән белгән-күргәннәрне хәйранга калдыра.

Гастрольләргә йөргәндә көндезләрен жырчылар, нәфис сүз осталары ял итә, ә ул өйдән-өйгә, авылдан-авылга йөреп, әллә кемнәр белән очрашып бетә, әңгәмәләр кора, төрле уен коралларында уйнаулары белән таныша. Моңарчы беркайчан да күрмәгән музыка уен коралларына тап була. Күңелендә шундый уйлар бөтерелә: татар халкының музыка уен коралларын рәтләп белмибез икән ич. Гармун, курай, кубыз, скрипка, гөсләдән башкалар читтә «кагылып» калган. Ә халык аларны онытып бетермәгән әле. Әнә нәрсәләрдә генә уйнамыйлар: камыл, сорнай, мөгез, көтүче быргысын да ничек сайраталар!

Рәгъде Халитов боларны көндәлекләренә теркәп бара: ул үзендә яңа ихтыяж тууын сизенә. Татар музыка уен коралларын системалы өйрәнергә, онытыла башлаганнарын да яңадан тормышка кайтарырга кирәк. Татар поэзиясенен 1000 еллык тарихы бар, дип хаклы рәвештә горурланабыз, ә шигърият белән




*Һиндстанда концерттан соң курай бүләк итү. 1996 ел.*

музыка аерылгысыз бит ул. Безнең музыка уен коралларыбыз да бик ерактан киләдер. Әгәр өйрәнмәсәң, үрнәкләрен ясамасаң, онытылып калулары да ихтимал. Нишләп әле мона юл куярга?!

Башкортстаннан килеп укырга кергән Нажия исемле кыз да ул белмәгән, ул күрмәгән уен коралларын әйтә. Үзе пианинода, скрипкада уйный.

Карлыгачтай кара күзле, чем кара чәчле кыз белән сөйләшеп сүзләре бетми. Бу чибәр Мәләүз районының Жиргән авылыннан икән. Әтисе сугышта үлгән, унике яшендә әнисе дә вафат булган, апасы белән балалар йортында үскәннәр. Шулай да югалып калмаган, Уфада музыка училищесын тәмамлаган, укырга дип Казанга да килеп житкән.

Рәгъде үзе 16 яшендә әтисез калды, әле хәзер дә аны бик юксына. Ә Нажиянең язмышы тагын да катлаулырак. Егет үзенә-үзе акыл бирә: бу кызның хисләре белән сак булырга кирәк...

Монарчы кияү-килennәр белән аңлашып яшәгән Нурдидә апа Нажияне дә бер күрүдә ошатты, аңа «кызым!» дип ике кулын сузды.

Институтта да бик яхшы укыган, баянда да бик оста уйнаган Рәгъде Халитовны төрле жирләргә эшкә чакырып карадылар. Татарстанда гына түгел, аны Башкортстанда да, Удмуртиядә дә беләләр. Тик аны институттан жибәрмәделәр. Педагогия институтының музыка факультетында кадрлар житешеп бетми. Бигрәк тә милли кадрлар. Рәгъде Халитов кебекләрне дә факультетка бәйләмәсәң, педагог-музыкантларны, галимнәрне кем үстереп бирсен?..

«Кеше ничә тапкыр туа?»—дигән сорау күнелдә кабат уянды. Югары белемле музыкант-педагог, фәнни эшләр белән дә мавыгып киткән тынгысыз жан тагын юллар чатында калды кебек. Иң дөрес юлны сайлыйсы иде, соңыннан үкенерлек булмасын!

Институтта калырга ризалашты, үзе укыган факультетта ассистент булып эшли башлады.

Кайсы солдат генерал булырга хыялланмый?! Югары уку йортларында үз гадәтләре. «Профессор булырга омтылмаган ассистент юктыр» диләр. Моны гаепләп тә булмый. Югары уку йортларының дәрәжәсен дә фән докторлары, профессорлар саны белән билгелиләр. Профессор булу өчен үзеннең фәнни мәктәбеңне тудырырга кирәк. Мона талант кына житми, тырышлык та, батырлык та сорала.

Авыллардан үзе табып алып кайткан егетләрне-кызларны тизрәк ачу, аларны жәмгыятькә файдалы музыкант-педагоглар итеп үстерү өчен бөтен көчен биреп, әллә үзенең мәнфәгатьләрен онытып жибәрдеме—Рәгъде диссертация яклауны сузды. Ике-өч диссертациялек хәзинәсе фәнни әйләнешкә, уку әсбапларына керсә дә, «тимерне кызган чагында чүкеп бетермәде».

Бар андый талант ияләре. Вакыйф Шәкүров чыгарган борчак белән заманында Татарстан дан алды, ә галим үзе «агроном—селекцияче» дигән атамадан узмады. Архиограф, библиограф Альберт Фәтхи ничәмә-ничә фән докторларына, профессорларга «жим бирде», ә үзе кандидатлык диссертациясен дә якламыйча дөньядан китте.

Рәгъде Халитовка «янаган куркыныч»ның сәбәбе тирәндәрәк булган. Ул гастрольләргә-экспедицияләргә чыкканда янадан-яна табышларга юлыга. Болгар заманнарыннан, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорыннан калган музыка уен коралларын өйрәнүдә нокта куярга ашыкмый. Язмышны алдап булмый. Аспирантурада укып 12 ел үткәч, ул Ташкентка барып кандидатлык диссертациясен яклый. Аның фәнни табышлары башка халыкларның да музыкаль тарихын ачыклауга этәргеч була.

Ходайның рәхмәте киң. Рәгъде Фатыйх улы Халитовка «югалган вакыты да» кире кайта кебек. Музыка фәнен үстерүдәге, музыкант-педагоглар үстерүдәге аерым казанышлары өчен аңа профессор дәрәжәсе дә бирелә. Музыка факультетының деканы буларак та игелекле эшләр башкарды, биредә укып чыккан музыкант укытучылар беркайда да йөзгә кызыллык китермиләр. Уку йортының башка факультетларында да музыкаль-эстетик тәрбия бирүгә йөз белән борылдылар, «музыка тәрбиясе нигезләре» дигән махсус кафедра да үзенең бик вакытлы тууын раслады.

Бу тәжрибә белән чит илләрдә дә кызыксыналар. 1995 елда Казан дәүләт

педагогия университеты делегациясе Кытайда булды. Бу бит халык саны миллиардлап исәпләнгән Кытай! Шушы кадәр халкын сыйдыра, туендыра, киендерә алган Кытай. Сәнгате дә бик алга киткән, борынгысын да саклый белгән Кытай.

Без, җир шарында җиде миллион татар яши дип, бик хаклы рәвештә горурланабыз. Ә арифметикага гына таянсаң, безгә Кытайлар алдында авыз ачарлыкмы соң? Әмма халык күңелендәге моң дәрьясының үлчәме юк.

Делегациядә күренекле галим-педагоглар, тик Рәгъде Халитовны җиңелрәк аңлыйлар. Кытайлар татар аһәңнәреннән сихерләнеп калалар. Татарның музыка уен кораллары утыздан артык, аларның күбесенә Рәгъде Халитов яна сулыш өрде.

1996 елда Татарстанның күренекле җырчылары Рафаэль Ильясов, Гөлзада Сафиуллина һәм галим-педагог, музыкант Рәгъде Халитовның Һиндстанга баруы да татар дөньясының офыкларын киңәйтеп җибәрде. Күңел тибрәнешләре җырларда-моңнарда чагыла, гаҗәеп Һиндстан җирендә дә татарның моңлы балалары халкыбызның йөз аклыгы булды.

Финляндиядәге Тукай җәмгыяте чакыруы белән барулары әле дә хәтердән чыкмый. Археологлар җир катламнарын актарып хакыйкать эзли, ә галим-музыкант, педагог Рәгъде Халитов халыкның күңел катламнарын ача, кайсы юлдан барсаң да хакыйкать бер генә. Җир катламнарыннан берәмтекләп җыйган хәзинәләр-дәлилләр белән хакыйкать кайта. Һәм казанышлар да бәхәссез.

Ерак иләрдән кайткач, язмышың хакында да кат-кат уйланасың. Аларда—алай, бездә—болай. Нигә алай, нигә болай? Җавап табулары да авыр.

Әмма беркайчан да шик-шөбһә уятмаслык хакыйкатьләр дә бар. Монысы—тормышта үз юлыңны табу, үз-үзенне табу. Хатының, балаларың белән уртак тел табу да бәясе төшмәслек, төсе китмәслек хәзинә. Рәгъде Халитов язмышына һич кенә дә үпкәләми. Хатыны Нажия белән ярты сүздән бер-берсен аңлашалар, Казан педагогия училищесында 30 ел укыткан Нажия Халитова—педагогия фәннәре кандидаты. Кызлары Гөлнараның да тырышлыгына хәйран калырлык. Башта консерваториянең фортепьяно классын тәмамлады. Аннары вокал буенча да диплом алды, инде конкурсларда җиңеп чыккан җырчы ул хәзер.

Тагын кәтелмәгән ачыш. Гөлнара көйләр чыгару белән дә мавыгып китте. «Дәү әби» дигән җыр тудыруы да тикмәгә түгелдер. Энесе Салават та бик хуплады аны. Әле бүген дә Әгерҗедә төп нигез җылысын, ире Фатыйхның рухын саклап торучы Нурдидә апа ул Дәү әби. Оныкларының балалары да кайта аның янына: «Сагындык сине, Дәү әби!»—дип кайталар. Һәм менә алар җыр булып та кайтты.

Шушы төп нигездә «Аппассионата»ны, «Туган тел»не уйнап музыка дөньясына кергән Равия «Чаллы шәһәренең иң яхшы музыка укытучысы» дигән исемгә лаек булды. Монысы да Халитовларча.

«Кеше ничә тапкыр туа?» Кырык елдан артык гомерен Казан дәүләт педагогия университеты белән бәйләгән, студенттан профессор дәрәҗәсенә барып җиткән, татар музыка уен коралларын өйрәнүдә һәм аларны тормышка кайтаруда яңа юллар ярган Рәгъде Фатыйх улы Халитов үзенең «янадан тууын», рухи янарышын әледән-әле кичерәдер, шуннан көч һәм илһам аладыр.

Алтмыш яшьлек гомеренең һәр мизгеле уч төбендә кебек. Өч яшеннән кулына гармун алган, монга-көйгә йөз тоткан малайның тормыш юлы гел табышлар белән генә бизәлмәгәндер. Әмма нинди сынаулар кичерсә дә, барысы да үзенеке, язмышны булмый алдап...

Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, галим-педагог, музыкант Рәгъде Фатыйх улы Халитовның фәнни-педагогик эшчәнлеге, баянда өздереп уйнаулары педагогия университеты аудиторияләренә, концерт залларына гына сыймый, алар халык уен кораллары ансамбльләренә, «Уйнагыз, гармуннар!» бәйрәмнәренә, конкурсларга, бәйгеләргә әверелә, яңа талантларны мәйданга дәшә. Әнә, факультетның «Хыял» вокаль ансамбле хәтта Италия белән Австрия тамашачыларын да таң калдырып кайтты.

**Мидхәт МИНШИН**

**Шамил Монасыйпов**

# БАКЫЙ УРМАНЧЕ ШӘМАИЛЛӘРЕ

## Шәмаил сәнгатенең чыганаклары



*Бакый Идрис угылы Урманче (1897—1990) — мәшһүр рәссам, сынчы—һәйкәлтараш (скульптор), нәгышьче, график. Татарстанның (1960) һәм Россия Федерациясенең халык рәссамы (1987), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1967).*

Ислам культурасы дөньяга сынлы сәнгатьнең югары сакраль фикерләрен белдерә торган үзенчәлекле бер жанр бирде. Бу — шәмаилләр.

Шәмаил сәнгате чыганакларын, мөгаен, Коръән ачышларының тәүге язылу тәҗрибәләреннән эзләргә кирәктер. Бу язмаларның беренче үрнәге — илаһи дөньяның "язмыш тактасы" — ләүхелмәхфүз, анда Галәм, Җир кануннары барлык җан ияләренең дөньялыкта кыласы гамәлләре ачык әйтелгән. Шул сәбәпле шәмаилләр ин әүвәл "Язмыш китабы"ның җирдәге чагылышы буларак кабул ителгән. Шәмаилләр табигатен болай аңлау бу сүзнең мәгънәсенә үк салынган. Гарәп телендә ул кысага куелган дини текст вә характерның тумыштан килгән үзенчәлеген, ягъни нәрсәнеңдер Аллаһе Тәгалә тарафыннан югарыдан бирелгәнлеген аңлата.

Мондый хезмәтләрнең үзләрен дә югары адепт-шәйх вә гайреләр генә иҗат итә алган. Бирелә ислам таралуының беренче гасырларында күп халыклар, шул исәптән Идел болгарларының да әле сурәтчел аллан күрү халәтләрен саклаганлыкларын күз уңында тотарга кирәк. Алар, хәзерге кешедән аермалы буларак, язма тамгаларны гади шартлы билгеләр янсә бу абстракция итеп түгел, ә бәлки күңелләрендә рухани дөнья картиналарын китереп чыгарган реаль сурәт-символлар буларак кабул иткәннәр. Язу (әлифба) бит үзе тирән инстинктив гыйлемнәрдән күренешнен асыл яклары чагылышлы буларак туган. Шунысы да бар, бу язу тамгалары кешенең абстракт–мантыйк, фәнни эшчәнлегеннән түгел, ә сәнгать формасында барлыкка килгән (мәсәлән, борынгы мисыр сурәт язуын искә алыйк). Борынгы заманнарда язу тамгалары кешенең эчке хисләренә аерым бер көч белән тәэсир иткәннәр. Шуңа да инстинктив аллан күрү сәләтен саклаган урта гасыр мөселманнары Коръән текстлары эчтәлеген бик тирән вә якын кичергәннәр, шәмаилләр аркылы үз эчке халәтләренә керә алганнар.

Хәзерге заманда мондый әсәрләр инстинктив алдан күрүчәнлеген тәмам җуйган, анын урынына интеллектуаль фикерләвен үстергән Кешенен бөтен барлыгын туендыра алмый. Гәрчә кешеләр хәзер классик шәмаилләргә карата мәхәббәт тотса да, анда бары абстракт фикер күрәләр, анын рәвеше кеше анында хуш сурәтләр уятмый, һәм кеше барлыгынын төп нигезләренә, әхлакый хисләре вә ихтыяр импульсларына кагылмый. Ин яхшы дигәндә, ул рәвешләр үзләренен эстетик әзләрен генә калдыралар.

Кеше тышкы материаль культурага кереп батуы һәм фикерләвенен абстракт-логик формасы үсү белән бергә илаһи дөньяны танып өчен ике юл барлыкка килде: беренчедән, үз эчендә эзләнүләр аркылы, икенчедән, матди әйберләрне, табигатьне тикшерү аркылы. Мәсәлән, көньяк халыкларда рухи дөньяны сурәтләү тыелган булган, ә төньякта яшәүчеләрдә киресенчә иконография кин кулланылган.

Борынгы Грециянен рухани мәктәпләрендә алда әйтелгән юлларнын икесе дә билгеле булган. Дионис мистерияләрендә кешенен эчке асылы төбенә чуму алымы алга сөрелгән. Аполлон мистерияләрендә исә икенче юл кулланылган. Әмма беренчесе — эчке дөнья аша бару юлы — катлаулырак саналган. Ул юлга бик көчле, тиешле әзерлек узган җаннар кертелгән. Әзерлексез укучы эчке асылына күмелә башлаганында үзенен кайбер житешсезлекләрен (әйтик, эгоизмынын бик нечкә шәкелләрен) күрми үтәргә һәм үз эчендә идарә ителмәүче монстрлар үстереп, ялгыш юлдан китәргә мөмкин.

Бу түбәнлекне булдырмауга җаннарны яхшы көчләр тарафына юнәлтүче иконография (нәгышь, скульптура) сәнгатендә кешеләр йә сюжетлар ничек ясалуын өйрәнү һәм тасвирлау ярдәмгә килә. Шуна күрә рухани остазлар үз шәкертләрен әзерлек дәрәҗәләренә карап, теге яки бу юнәлешне алып укытканнар. Ахыр чиктә болар һәр ике үсешне үзләштерә торган булганнар. Чөнки һәр ике юл бер үк Аллага илткән һәм бер яклылык белән чикләнмичә, багышланунын ин югары баскычларына житү мөмкинлеге ачкан. Сонра Римнын Дионисий Ареопагит мәктәбендә илаһилыкнын ин югары алымнары ике юл чатында ачыла дип өйрәткәннәр: шәкерт Алланын беренинди аерым конкрет әйберендә (ни теге, ни бусында) түгеллеге турында уйлана һәм бу уен икенче фикергә чуму — Аллаһе бөтен тышкы дөньянын (һәм теге, һәм бу) әйберендә дигән медитация белән чагыштыра.

Бу юллар якынаю тенденциясе XIX–XX гасырлар чигендә ачык беленә башлый. Нәкъ шул чорда төньяк мөселманнары, шул исәптән Идел-Урал татарларында шәмаилләр кин таралыш таба, боларда бернichә гасыр дәвамында шәмаил сынлы сәнгатьнен бик мөһим, хәтта бердәнбер диярлек жанрын хасыйл иткән.

Инде татарларда нәгышь вә скульптура булмавы кебек гадәттән тыш феномен сәбәпләренә килсәк, аларнын нигезен, күп кенә тикшеренүчеләр уйлавынча, дин шәригать кануннары торгынлыгыннан түгел, ә эчке асылга төшүнен берьяклы гына юлыннан баш тартып, тышкы юл белән якынаю кеше жанынын рухани дөньяга бәйле булуын — әйберләр дөньясынын гаҗәеп күп шәкелләре даирәсендә жан югалып калмаска тиешлегеннән эзләргә кирәк. Икенче төрле әйткәндә, тышкы юлны уңышлы үзләштерү нәкъ шул шәмаил сәнгатеннән башлана ала: дини текстларны иллюстрацияләү һәм төрле төсләрдә бирү рухани дөнья турында мәгълүмат китергән.

Әлеге чор татар шәмаилләрендә тасвири элементнын роле зур. Ләкин ул тышкы бизәклардән ары китми һәм сурәтнен эчке төзелешенә үтми. Бу шәмаилләр нәгышь әсәре булудан бигрәк, орнамент һәм гыйбадәтханә рәсемнәре белән бизәлгән матур язу — каллиграфия үрнәкләре булып торалар. Гаҗәеп талантлы шәхесебез Шәехзадә Бабич (1895–1919) үзенен 1916—1917 елларга караган эпиграммаларынын берсендә юкка гына болай димәгәндер:

Сыз, Кәмал рәссам, харитәләр, шәмаилләр чыгар,
Йа Илаһем, бездә сон кайчан Рафаилләр чыгар?[1]

Һәм шундый Рафаэль килгән! Татар культурасы Бакый Урманче йөзендә дөньянын эчке кичерешләренә берьяклы күмелүнен меңъеллык традициясен кыю үзгәрткән һәм замандашлары карашын рухлылыкнын тышкы күренешләренә юнәлткән гайрәтле шәхес булдырган. Шул ук вакытта Рәссам чынбарлыкны эчке сиземләү

[1] Бабич Шәехзадә. Зәнгәр жырлар. — Казан, ТКН. 1990. 279 б.

нәтиҗәсендә тупланган мәдәни хәзинәләрне чыгарып ташламаган, киресенчә, үзенең дәртле, күтәренке рухлы әсәрләре белән әлеге хәзинәләрнең тышкы элементлар белән гармоник кушылуына ирешкән.

## Урманче шәмаилләренең серләре

*Гәүһәр ташдыр, ләкин һәр таш гәүһәр улмаз,*
*Гәүһәр кадерен тикмә кемсә кыяс кыйлмаз.*[1]
Кол Гали.[1]

Бакый ага Урманче шәмаилләр белән иҗат гомеренең соңгы елларында гына шөгыльләнә башлады, дияргә була. Ул мәҗбүри ил гизү-кангырып йөрү елларыннан соң Казанга кайткач, 60 нчы елларда яза башлый аларны. Үз гомеренең соңгы өч дистә елында (60 яшеннән 90 га хәтле) кайнап торган эшчәнлеге арасында Рәссам шәмаил стилендә тугыз әсәр иҗат итә. Тик аларның бары өчесен генә чын шәмаил дип санарга була, чөнки алар гына Коръәне-Кәрим вә хәдисләрнең изге текстларына багышланган: "*Әлхәмдүлилләһи*", "*Аллаһе җәмилен хөббел җәмалә*", "*Ля тәгъзәб*". Әчтәлеге, башкарылу стиле белән аларга якын тагы бер эше бар, ул Алланы олылау цитатасын эченә алган шигырь — "Сәйфелмөлек" дастаныннан алынган:

Гаҗәп кадыйр торур, кодрәтләрен күр,
Гаҗәп саниг торур, сәнгатьләрен күр.

Калган әсәрләрдә изге теләкләр түгел, ә рәссамның яраткан шагыйрьләре Тукай, Кол Гали һ.б. әсәрләреннән канатлы сүзләр, шулай ук шәрекънең хикмәтле гыйбарәләреннән үрнәкләр гади каллиграфия ысулында эшләнгәннәр.



*"Әлхәмдүлилләһи"*
*("Аллага мактау") шәмаиле.*

Биредә шундый сорау да туарга мөмкин: ни өчен Б.Урманче үз иҗатында бары өч-дүрт шәмаил белән генә чикләнгән? Аның искиткеч күп эшләргә сәләтле булуын, Коръәнне гаҗәеп тирәнтен белүен истә тотканда Рәссам бу өлкәдә берничә түгел, хәтта дистәләгән, йөзләгән эш калдыра ала иде, дип уйлау табигый сыман. Бу инде Оста иҗатында бик күп булган серләрнең берсе.

Урманче шәмаилләренең серләрен ачуга якынайганчы, әлек аларның эчтәлегенә күз салыйк.


Рәссамның беренче шәмаиле "Әлхәмдүлилләһи" дип атала иде (Аллага хәмд, мактау). Әлбәттә бу гыйбарә үзе тирән символик мәгънәгә ия. Кодрәт иясен мактау үзенчәлекле, зур көч бирә. Ул көч җан ялкынын гармониягә сала һәм кешенең "Мин- ан"ын, үз-үзен анлавы өлгереп җитүендә гадәттән тыш әһәмияткә ия. Ходайны олылавы белән индивидуум гади "мин"не, үз мин-минлеген кичерәйтә. Үзенең камил булмавын белә торып, ул үзендә түбән "мин-асыл" хәрәкәтен юнәлтүче һәм бәя бирүче ин югары "Мин" барлыгын ача. Шунлыктан кешедә, аның рухында бик тирән яшеренгән ин югары "Мин" киләчәктә аның җитешсезлекләрен бетерүгә, шул камил булмавы аркасында килеп чыккан кайгы-хәсрәтеннән котылырга, сафлык вә камиллек, реаль иҗади көчләр табуга ирешүенә ярдәм итәр дигән өмет туа.

Нәкъ шул Тәңрене олылау белән Коръәнне ачучы һәм кешене илаһи рухани дөньяга алып керүче "Фатиха" сүрәсе башлана.

---

[1] «Йосыф китабы»ннан цитата Б. Урманченың каллиграфик типтагы шәмаиленнән алынган. «Гәүһәр кадерен тикмә кемсә кыяс кыйлмаз»: Асыл ташның кадерен гади кеше таный алмас.

Бередә дөньяны бар иткән һәм кешелекне янадан рухани патшалыкка китүче иң югары, камил Үзлек — Аллаһе Тәгалә данлана. Бары эгоцентрик булмаган "Минан"га ия, шәфкатьле, рәхимле Асыл гына үзе барлыкка китергән кешелек дөньясына иң кыйммәтле ирекле, индивидуаль, үзен-үзен танучы "Мин"не бирә ала. Кешегә бирелгән ирек яхшылык һәм яманлык кылуның ике мөмкинлеген ача, шуна күрә хакыйкатьтән китү, хата гамәлләр кылу барлыкка килә. Ләкин Ходай — Аның исемен Хак, Абсолют "Мин" дип тә атарга була — үзе булдырган затка чиксез мәхәббәт, миһербанлы ярдәм вә ярлыкау бүләк итә. Илаһи Үзлек — Кодрәт иясен данлыклап, Коръән-Кәрим иң югары вә иң түбән "Мин"не аерып карый, дифференциацияли. Ул рухани принципка баглы, "Мин"не күтәрә, олылый, әмма физик-хисси нигездә торучы, кеше эгоизмын йөртүче "Мин"не кечерәйтә. Шулай итеп, Изге Китап шәхеснең үзен һәм башлангыч асылын нәкъ югары, Яралтучы, шәфкатьле вә рәхимле "Мин"дә табарга тиешлеген күрсәтә. Бары тик шул чакта гына шәхес үзендә Бөек, Үлемсез Рух гәүдәләндергән, зур хәрефтән башланган Кеше була ала.



"Ля тәгъзаб" ("Ачуланма") шәмаиле.

Икенче шәмаил "Ачуланма" (Ля тәгъзаб) Мөхәммәт галәйһиссәләм хәдисенә нигезләнгән. Эчтәлеге буенча ул төп христиан кануннарының берсе, шулай ук Будда диненең кеше жанын коткаруда сигез тармаклы сукмак постулатларына охшый. Анда илаһи кәсепне дөрес яктылыкта күрер вә кешенең үзенә язган урынны тиешенчә кабул итәр өчен гакыл вә сабырлык кирәк булуы хакында бәян ителә. Ул нәсихәт нигезендә дөньяның гармонияле бер бөтен булуын күзаллаулар урнашкан. Әгәр ул дөньяда нәрсә дә булса ошамый, ачу чыгара икән, әле аның камил түгеллеге турында нәтиҗә ясарга ашыкмаска кирәк. Үз көчләреңне таркатмас, гомереңне заяга уздырмас өчен сабырлык саклавың хәерле. Хәтта хәятның иң авыр, газаплы вакыйгаларында да югары позитив мәгънә була, һәм тынычлыкта гына гамәл өчен уңышлы юллар ачыла.

Ачу тотмау — без омтылырга тиешле идеал. Ләкин аңа — ачуны бетерүгә — бердән өндәп кенә ирешү мөмкин түгел. Рухани гыйлем өйрәтүенчә, ачу — кеше күңеленең әһәмиятле бер хасияте, аннан башка кеше жаны хәяткә битараф буласы икән. Ачу — үзенә күрә эчке тәрбияче. Ничек кенә парадоксаль булып күренмәсен, ачуда эгоцентризмга каршы куәтле көч бар. Әгәр кешенең тискәре күренешләргә карата ялкынланып ачуы кабарса (әмма дуамал ярсу түгел), ул башта ансыз рәвештә генә булса да, берәр ярамаган эш белән килешмәвен күрсәтә. Шәхес әкрен-әкрен аңлы рәвештә ачык фикер йөртү өчен өлгереп житә. Ул үз аның үятә, тәрбия итә. Үз жанындагы ачуын басып, шәхес мәхәббәт вә миһербанлылыкка юл ача: "рәхимлелек вә фатиха бирүче куллар ачуны жиңгән кешеләрдә генә булалар". *(Штайнер Р. Миссия гнева // Метаморфозы душевных сил. — Казань, 1999. — с. 56).*

Ачуның мондый мәгънәләре дөнья хикмәтләреннән һәм тиешсезлекләрне тигезләве белән дөнья диннәрендә бер-берсенә капма-каршы, шул ук вакытта берберсен тотыручы "Илаһи ачу" һәм "Илаһи мәхәббәт" төшенчәләрен белдерә. "Фатиха" сүрәсендәге "ачуланган" сүзләре нәкъ шул контекстта аңлашыла да: Илаһияттә Алланың рәхмәте белән бергә Аның ачуыннан да курку. "Әлхәмдүлилләһ" шәмаиле турында сөйләгәндә шул мәгънә истә тотыла.

Бакый ага Урманче иҗат иткән өченче шәмаил, алдагысы кебек үк Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләренең берсенә таяна. Бу — "Аллаһү жәмилүн йү йухиббү жәмалә" дигән хәдис. Аны рәссам үзе болай тәржемә итә: "Аллаһе гүзәл, гүзәллекне ярата". Бередә сүз тышкы сөйкемлелек турында гына түгел, эчке матурлык вә камиллек хакында да бара. Матурлык сүзе чын мәгънәсендә һәрвакыт яхшылык, тәкъвалык вә билгеле бер мәгънәдә әхлаклылык синонимы буларак кабул ителә. Шунлыктан диннәр

дөнья яралуын мәңгелек матурлык, мәхәббәт һәм бөек мәңгелек Рухның югары әхлакый импульсларына илтеп җиткерәләр. Шуннан да кешелекнең "Матурлык дөньяны коткара" дигән өмет-хыяллары туа.

Шәмаилләр эчтәлеген гомумән алып караганда, аларда идеяләр берлеге сиземләнә. Аннан да бигрәк, алар аша глобаль зирәклек, кеше табигатенең асылы белән бәйле бөек идеяләргә алып килүче үтәли бер сызык төсмерләнә. Һәр шәмаил бөек рухани тәгълиматлар нигезендә яткан принципларның изге триадасын тәшкил итүче берәр бөек хакыйкатьне белдерә. Бу — Акыл, Матурлык, Көч (хакимият). Нәкъ менә шулар кешенең һәм тышкы дөнья, һәм эчке камилләшү өлкәсендәге эшчәнлегенә юнәлеш бирә.



*"Аллаһе җәмилен йухиббү җәмалә" ("Аллаһы гүзәл, гүзәллекне ярата") шәмаиле.*

Шул принциплар асылын ачыклап китү өчен, рухани фәннең кешегә һәм табигатькә карашларын сыйфатлап үтү сорала.

Антропософия[1] кеше асылы дүрт барлыктан тора, дип саный. Табигать фәннәре таный торган җир физик җисеме белән бергә кеше бөтен галәмнән килүче космик гравитация йогынтыларыннан тукылган нечкә "эфир" җисемен дә йөртә. Мондый көчләр организмның тереклек эшчәнлеген тәэмин итеп, җирнең минераль асылы — каты, сыек, газсыман халәтләрен үзара бәйләнештә тота. "Эфир" җисеме кешене үсемлек дөньясы белән якынайта: аларда бит хәят бар (сүл хәрәкәте, чәчәк, җимеш), әмма хис эмоцияләр юк. Кичерешләр дөньясы "астраль" дигән (Парацельс буенча) җисем-кеше асылының физик һәм эфир халәтеннән соң өченче халәт белән бәйле. Бу халәт Кояш системасы планеталары, аеруча Ай йогынтысына бәйле: космик периферияләрдән килгән хаос йогынтыларын тәртипкә салалар. Астраль җисем кешегә эчке хис, канәгать яисә канәгатьсезлек кичерешләре тәэмин итә, шуның белән аны хайваннар дөньясына якынлаштыра. Шулай итеп, кеше үзенең түбән дәрәҗәдәге җисемнәре ягыннан минераль, үсемлек, хайваннар патшалыгы белән бер үк табигатькә нигезләнгән. Шушы нигездә аның үзен-үзе аңлый торган "Мин"е барлыкка килгән.

Кешедә үзан буллырып, табигать аны җир йөзенең барча байлыкларыннан өстен итеп күтәрә . Әмма "Мин-ан"лы кеше билгеле бер үсеш дәверендәге дөнья чагылышы, дип, үзен-үзе инкяр итәргә тиеш. Ул югары "Мин" ноктасына менеп, үзенең түбән асылына "Син!" дия һәм аны үсүнең югары дәрәҗәсенә күтәрә. Рухани мәктәпләрдә кешенең чын табигате рухлылыкта һәм ул үзенең түбән асылына да хуҗа булырга тиеш дип өйрәткәннәр. Бакый Урманче укыган "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә "Син дә әллә кем түгел, мин дә әллә кем түгел, синең әлләкемлегең беркемгә кирәк түгел" дигән такмак популяр булган.

Хакыйкать шунда табыла ки, үз-үзен югары дәрәҗәдә аңлауга ирешкән кешелек үзе яңа дөньялар иҗат итәргә, фән, сәнгать, үзенең эчке көче (ихтыяр) кебек табигатьтән өстен дөньялар иҗат итәргә тиеш. "Мин-ан" ярдәмендә кеше табигатьне (минераль, үсемлек, хайваннар) һәм үзен (физик, эфир һәм астраль җисемнәр) үзгәртә. Болар берсе дә хаотик дилетантизм белән түгел, ә бәлки алда әйтеп үтелгән триаданың өч изге принцибына — зирәк Акыл, Матурлык вә Көч —нигезләнеп эшләнә.

Кешенең эчке һәм тышкы эшчәнлеге бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән, чөнки тыштан кергән образлар чагылышы эчке дөньяны иҗат итә. Эчке тормышыбыз гармониядә булсын өчен, безнең күз алдындагы чынбарлыкны, мохитне үзгәртергә тиешбез. Әгәр без дөньяны җимерүче гамәлләр кылабыз икән, аның тискәре нәтиҗәләрен үзебездә күрәчәкбез. Шуңа күрә рухани мәктәпләрдә җиһанны камил Гакыл, Матурлык, Көч хөкем сөрерлек итеп җайга салырга өйрәткәннәр. Бу өч принцип

---

[1] Антропософия — рух турындагы фән. Р.Штайнер (1861–1995) тарафыннан ачылган.

нигезендә түбән жисем үзгәрә һәм башка биек жан формалары барлыкка килә.

Бакый Урманче ижаты нәкъ шуна юнәлтә. Ул татар халкынын күренекле вәкилләре һәм аларнын рухани остазлары нәгыйшь вә скульптура портретларын культурабыз тарихында беренчеләрдән булып ясый башлады. Анын шәмаилләре дә зирәк Гакыл ("ля тәгъзаб"), Матурлык ("Аллаһү жәмилүн йү йухиббү жәмалә") һәм рухани Көч табуга ("Әлхәмдүлилләһи") юнәлтелгән. Аларда ин югары акыл һәм халыкнын рухани житәкчелек серләре тыгыз бәйләныш таба.

## Шәмаилләрнең сәнгатьчә стиле

Хәзер Бакый Урманче шәмаилләренен сәнгате ягына игътибар итик. Нинди алымнар белән гәүдәләндерә рәссам аларда бу рухани хакыйкатьләрне?

Беренче карашта ук автор рәсемнәрне гади алым белән ясамаганы күренә: традицион сызма графика түгел. Ә хәреф тамгаларына ниндидер сизелерлек күләм бирә торган кин "тасма" рәвешендәге язу белән башкарылган. Моннан гайре шәмаилләргә хас орнаменталь кысалар булмавы игътибарны жәлеп итә: алар гадәттә язманы периметр буенча чикли. Менә шуңлыктан яссылыкта тасвирланмый, ә һавада, рухи дөньяда яшәеш алгандай тоела. Символик сурәт жанлы Фикер-Шәкел булып, чиксез илаһи жиһанда йөзә, аны бернинди физик киртәләр капламый.

Аннан сон язмаларны өйрәнү вә гарәп имлясынын бормалы язуына кергән саен бу хәреф тамгаларынын гажәеп тәэсирле һәм оригиналь булуы ачыла. Алар табигатен Бакый ага Урманче үзенчә сиземли.

Шәмаилләрнен график рәсемнәрен тикшергәндә мөһим бер кызыклы детальгә тап буласын. Дүрт әсәрнен барысында да рәссам зур түгәрәк фигура ясый. Сызыклар фонында алар һәм күләме, һәм шәкеле белән аерылып торалар. Бу фигуралар спираль сызыклы әйләнә-түгәрәкләрдән тора, әйләнә исә зурайтылган хәреф тамгалары һәм аларны тоташтыручы сызыклардан хасыйл була. "Түгәрәкләр"нен мөһим композиция вазифасы бар — алар рәсем тукымасын ритмлаган мәгънә үзәге булып торалар. Хосусан, "Әлхәмдүлилләһи" вә "Ля тәгъзаб" шәмаилләрендә шундый бер генә үзәк фигура ясалган, ә калган ике әсәр — "Аллаһү жәмилүн йухиббү жәмалә" вә "Гажәп санигъ торур, сәнгатьләрен күр" композицияләрендә бөтенлек һәм төзеклек бирә торган өчәр әйләнә, һәм алар төрле сүз хәрефләрендә булсалар да, бер-берсен тоташтырып торалар. Игътибар итик: шәмаил тибындагы башка каллиграфик хезмәтләрендә рәссам мондый фигуралар кулланмый.

Каян килә авторнын бу фигураларга һәвәслеге һәм ни анлата алар?

Рухани-фәнни тикшеренүләр шуны анлата ки, гармонияле түгәрәк шәкелләр ижади илаһи импульслар белән бәйле була икән. Ә жимергеч деструктив элементлар гармониясез, очлы конструкцияләрдә чагылыш таба. Бакый Урманче шәмаилләре символикасын анлату контекстын, күрәсен, шуннан эзләргә кирәктер.

"Әлхәмдүлилләһи" әсәренә килик. Тышкы яктан ул нота язуындагы "скрипка ачкычын" хәтерләтә (скрипичный ключ). Рәссам бу шәкелне анлы рәвештә сайлап алган. "Скрипка ачкычы" нота юллары башында куела торган махсус билге ул, аннан башка ноталарны укып булмый. "Әлхәмдүлилләһи" сүзе дә Коръән-Кәримнен беренче сүрәсен ача һәм рухани дөнья барлыгы хакында хәбәр бирә. Үз анында шул хәбәрне алгач кына (теоретик хәлдә булса да) Изге китапны анлауга якынаерга мөмкин.

"Скрипка ачкычы" үзенен чыганакларында оккульт (серле, гайре табигый) тамгалар системасы белән бәйле. Вертикаль рәвешендә бу таякчыкнын башы аска бөгелә дә алга таба спираль хасыйль итә. Шулай итеп эзотерикада (илаһи гыйлем) бердәм, чиксез һәм үлчәп булмый торган рухани дингез эчендә элементлар аерымлануына китерә торган һәм дөньяны санала, үлчәнә торган итеп илаһи импульслар формалашуын билгелиләр. Икенче сүз белән әйткәндә, бу индивидуаль хәятнен очсыз Гомумилектән барлыкка килгәнен күрсәтә. "Скрипка ачкычынын" капма-каршылыгы, "икенче яртысы", ягъни "баслар ачкычы" була. Ике бас ачкычы кушылганда тышкы яктан "скрипка ачкычына" охшыйлар, әмма инде өзелгән спиральне дә хәтерләтеп, өермә билгесе — һәрбер үсеш нигезендә булган сикерешлелеккә ишарә итә:

скрипка ачкычы



баслар ачкычы



"өермә" тамгасы



шәмаил схемасы



Бу тамга астрономиядә чагылыш таба. Ул зодиакаль йолдызлык горизонталь хәлдә сурәтләнгән Кысланы анлата. Безнен Жирнен хәзерге формасы атлантик афәт, ягъни Бөтендөнья Су басуыннан сон барлыкка килә. Бу вакытта яна цивилизация туган. Өермә символы да шул чорда ясалган эволюция сикерешен күрсәтә.

Бакый Урманче шәмаиленен рәсемендә "скрипка һәм баслар ачкычыныкы" гына түгел, башка бер символ белән багланышлары да күренә. Ул символ өзелгән әйләнә һәм тышкы яктан кеше яралгысы (эмбрион) вә зодиакны[1] хәтерләтә. Шәмаилдә бу өзек әйләнә тыштан килүче агымда туа. Мондый нәрсә кендек эмбрионда да, зодиакта да бар, һәм ул шәмаил үзәгендәге түгәрәк фигураны шушы планда анлатуга китерә дә. Ләкин аерым алсан, ул фигура исламнын мәшһүр символы Айны искә төшерә.

Зодиак йолдызлыкларынын кешедә Универсумнан килә торган хайвани көчләргә мөнәсәбәте бар. Кеше үзенен эмбриональ халәтендә хайваннар патшалыгы үсешенен төп нигез стадияләрен үткәне кебек, сонра аларны ташлап, карыннан чыгу һәм үзенә бер аерым чырай тапканындай гомумән кешелек тә зодиак саклавы белән үзенен астраль, күнел дөньясын таба. Биредә инде кешеләр югары кешелек башлангычы булдыру йөзеннән хайваннарга хас сыйфатларны да камилләштерәләр. Тәүрат хикәятләре моны "Оҗмахтан куылу" мифында сурәтли. Адәм һәм Һауа гөнаһлары өчен җир өстенә сөреләләр: илаһи җиһаннан зодиак белән әйләндереп алынганнар, бикләнгәннәр. Шулай итеп, зодиак рухани дөньядан аерылып чыккан кешелекнен эмбриональ үсеше символы булып тора.

Шәмаилнен үзәктәге түгәрәк фигурасын ярымайга туры китереп анлатсак та, күп аспектлы бу мәсьәләне тәфсилләп тикшерүгә керешмибез. Бары шуны әйтергә кирәк, ярымай, зодиак шикелле үк кешелек тарихкача булган заманнардан бирле илаһи көчләр куенында үскән-өлгергәнен күрсәтә. Ул илаһи көчләр эзотерикада христианнарнын Тәнре Ата дип йөртелгән символы булып тора. Ярымай исламнын әһәмиятле символы. Аны һәрбер мөселман намаз алдыннан тәһарәт алган саен үз гәүдәсендә тойгандай була. Башын сыпырганда мөэмин ике кул бармаклары белән мангайдан җилкәгә таба хәрәкәт итә, аннан сон аяк астын чылата да имән бармаклары белән колак яфраклары эченә кагылып, янадан мангайга җитә. Шулай үк ярымай шәкелен сызып, үзен һәм космоска, һәм рухани дөнья кагыйдәләренә, һәм ин югары үзанга житкереп, үз урынын билгели. Баш эчендә колак тигезлегендәге бер нокта кеше асылынын дөньяда Ата нигезе белән бәйле ин эчке үзәге булып тора. Икенче нокта мангай эчендә, кул бармаклары хәрәкәтенен башланган һәм кире кайткан урынында мөэмин игътибарын үзанына җәлеп итә. Бу пунктта кеше игътибары сәҗдә вакытында, мангае белән җиргә орынганда да була. Нәкъ шунда кеше башынын "Мин" кичерешләре бирә торган физик вә эфир үзәкләре очраша. Борын заманнардан бирле аны Мәсих (Христос Мессия) ноктасы дип атаганнар, ул ин югары "Мин" гәүдәләнеше булып тора (бу ноктага бары мөэмин үзе һәм Аллаһе Тәгаләдән килгән Мәсих импульсы гына керә ала). Зодиак әйләнәсендә ана Кучкар (Агнец Божий) йолдызлыгы туры килә.

Шулай итеп, "Әлхәмдүлилләһи" шәмаилендә кешенен Универсумнан формалашуына мөнәсәбәте булган скрипка ачкычы, зодиак, ярымай символларын күрәбез. Бу билгеләр рухани дөньяда индивидуаль хәят туу процессын күрсәтәләр. Рәссам бу эзотерик символларнын күчермәсен ясамый. Ул Изге текст язылган гарәп хәрефләре үзенчәлегеннән чыгып, үзе сурәт ясый. Шуна да анын шәмаилендә борынгы яшерен тамгалардан да әһәмиятлерәк серләр укылырга мөмкин.

---

[1] Зодиак — күк сферасында йолдызлар поясы, 12 тамга белән билгеләнә: Кучкар, Үгезбозау, Игезәкләр, Кысла, Арыслан, Кыз, Үлчәү, Чаян, Укчы, Кәҗәмөгез, Сукояр, Балык.

Сәнгатьчә сурәт ясаганда автор картографик алым да куллана. Бу алым Бакый Урманченын ин әһәмиятле эшләрендә файдаланыла. Ул нинди дә булса уйдырма фикергә нигезләнгән компози-ция уйлап чыгармый, ә реалияләргә таянып, үзләштерү өчен яна ракурс (перспективада сурәтләү) таба һәм фактларны үз яктылыгында күрсәтә.

Шулай ук "Әлхәмдүлилләһи" шәмаилендә дә автор Аллаһе сүзен житкерү өчен үзенчәлекле ракурс таба. Текстны традицион горизонталь хәлдә түгел, ә борынгы рун язуларындагыча вертикаль рәвештә бирә: хәреф тамгала-рына үзләрен бөтенләй янача күрсәтү мөмкинлеге ача. Әлеге скрипка ачкы-чына охшаш фигура өстә ике жәпле булып китә. Реалист Рәссам гарәп язуы кагыйдәләрен дә бозмый — "әл" артикле гарәп имлясындагыча ике вертикаль сызык белән бирелә.

Шәмаилдә болар илаһи дөньядан ике ташкын агу символын күрсәтә. Аларнын берсе аска таба бөтерелеп төшә һәм әлеге түгәрәк спиральгә әйләнә. Икенче агым спиральгә кермичә өзелә. Сонра икесе дә уратадагы түгәрәк эченнән чыгып, кушылалар. Нәтиҗәдә вертикаль хәлендәге өч буынлы фигура туа: 1) уртада өзелгән әйләнә; 2) анын өстендә илаһи дөньядан килгән агымнар; 3) аста, түгәрәк эчендә туган яна агымнар берләшкән.

Югарыда әйтелгән символика буенча, бу шәмаил сурәтләрендә рухани вә физик жиһан берлек идеясе чагыла. Аны әле борынгы Мисырда бөек остаз Гермес Трисмегист шундый сүзләр белән әйтеп калдырган: "Өстә шул ук аста булганнар, аста шул ук өстәгеләр". Бакый Урманче эшендә бу идея шулай гәүдәләнә: аска ыргылучы агым уртадагы өермәгә юлыгып, физик күзгә күренмәгән рухани дөньядан кеше дигән мөстәкыйль вә чагыштырмача йомык системаны барлыкка китерә.

Ул чагында уртадан өзелгән агым ни нәрсәне анлата? Бирелә без Изге язулар яшерен рәвештә күрсәтә торган кеше эволюциясе сере белән бәйле мәсьәләгә якын килләбез. Сүз монда нинди дер бер туган жаннын Адәм галәйһиссәләм белән бергә маддиләшү процессына кермәгән коткару миссиясе турында бара. Антропософиядә анын турында Адәм асылынын бик нечкә рухани субстанциясе дип сөйләнелә.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ

## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Рафаэль Мостафин**

## «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ»ННАН— «КАЗАН УТЛАРЫ»НА



***1965 ел...*** *Язгы айларның берсендә мине язучылар берлеге рәисе Мирсәй Әмир чакырып алды. Сүз «Совет әдәбияты» журналы турында барды. Мирсәй ага минем журнал турындагы фикерем белән кызыксынды. Мин яшермичә журналның шактый төссез булуын, тормыштан, чорның яңарыш җилләреннән артта калып баруын әйттем. Журналны төптән үзгәртергә кирәк, дидем. Халкыбызның тарихы, рухи мирасы турында күбрәк язарга, яшь талантларга киңрәк юл ачарга, укучылар ихтыяҗын искә алып эш итәргә... Исеме үк ятышсыз—«Совет әдәбияты»... Монда бит милли төснең эзе дә юк!*

*—Син нинди исем тәкъдим итәр идең соң?—дип сорады Мирсәй ага.*

*Менә шунда инде мин күптән уйланылган, башкаларга да кат-кат әйтеп караган исемне чыгарып салдым—«Казан утлары». Мирсәй агага бу исем ошады. Ләкин мәсьәләне ул гына түгел—идарә, идарәдән дә бигрәк, обком хәл итә иде. «Ярый, уйлашырбыз... Яңа исемгә үзенә күрә бер кечкенә генә конкурс та игълан итәргә исәп бар. Кайсы җиңеп чыгар. Син дә уйлана тор әле. Идарә әгъзалары арасында сине «Совет әдәбияты»ның баш редакторы итеп куярга дигән фикер бар. Әгәр, үзең каршы килмәсәң, мин обком кешеләре белән сөйләшеп*

Кеше ыруы Атасы ожмахтан жиргә төшкәндә ин нечкә жан өлешләре белән физик тыгызлыкка керә алмаган. *Ләкин* анын аркылы Хак Тәгалә адәм балаларына хәл кертә, рухландыра, дәртләндерә торган көчләр белән тәэсир иткән.

Рухани фәндә гадәттән тыш мөһим вакыйга, кешелек тарихында үзәк борылыш моменты буларак, Адәмнен әле эволюциягә кермәгән ин нечкә өлеше жиргә төшүе һәм анын Иисус Насари булып гәүдәләнүен саныйлар. Коръән-Кәримдә дә Иисус "Адәм г-м кебидер" дип анлатыла *(Кор. 3.52 (59))*. Кеше ыруы янадан деградациягә вә катып калуга бирелмәсен өчен, нәкъ шушы шәхескә рухани дөньяны ачу насыйп булган.

Шулай итеп, Назарет Иисусында ике асыл кушылган: кеше табигатенен физик дөньяда эволюция үткән ин түбән өлеше белән элек гәүдәләнмәгән ин югары нечкә рухани өлеш тоташкан. Бу янарган "Кеше улы" утызынчы яшендә үзенә ин югары илаһи "Мин"не кабул итә алган. Мона хәтле ул "Мин" бөтен кешелек жаны кебек кенә яши, бары рухани дөньяда гына була, әмма конкрет берәр шәхестә әле ул юк. Иисус Христос беренче кеше буларак, үзе турында "Мин бар", ди, анын "мин"е һәм илаһи "Мин" бер, ди. Шуннан бирле кешелек һаман ин югары "Мин"гә ирешү юлында, чөнки ана ирешү Аллаһе көчләренә илтә.

Шуна Коръән-Кәримдә Иисус Христос Мәсих (мессия) дип күрсәтелә *(Кор. 3.40 (45))*, коткаручы, үзендә Изге рух йөртүче диелә *(3.52 (59). 4.169 (171))*. Мона Апостол Павел сүзе, охшаш, анын тәгълиматы да Иисус Христосны икенче Адәм, ди: "Беренче кеше Адәм яшәүче жан булды; икенче Адәм — жанландыручы рух"; "Беренче кеше — жирдән,балчыктан яралган, икенче кеше — Күктән Алладан жибәрелгән" *(Коринф. 15.45, 15.47)*.

Бу яна эра кешесендә югары вә түбән башлангычлар кушылмасы Бакый Урманче шәмаилендә күз күрә, сиземләнә торган суретта.

Хәзерге яшәештә кешеләр үзләрендә тышкы дөнья белән аралашудан алына торган яна, югары көчләр булдыруы кирәк. Чынбарлык һәм анын кыенлыклары, фажигаи борылышлары белән очрашуга индивидуум үзен аямастан хезмәт итү, үзенен ин түбән башламнарын сүндерү, бетерү, басу

*карыйм. Алар сине бик үк өнәп бетермиләр, шулай да күндерергә тырышырмын...»— диде ул.*

*Бу сөйләшүдән соң бер-ике ай үткәч, журнал яңа исем белән чыга башлады. Конкурста минем тәкъдим җиңеп чыккан, обком да ризалашкан. Шулай итеп 1965 елның 6 нчы санынннан «Совет әдәбияты» «Казан утлары»на әверелде.*

*Мине редактор итеп раслау исә тагы берничә айга сузылды. Ниһаять, июль айларында булса кирәк, кандидатураны расладылар һәм 1965 елның 8 саныннан журналга мин кул куеп чыгара башладым. Ул вакытта тираж 20 500 данә иде. Өч ел үтеп эштән киткәндә (дөресрәге, алынганда!) журнал тиражы 65 меңнән ашты. Алдагы елларда исә аның тиражы йөз меңгә җитте, хәтта бу санны узды да.*

*Өч ел эчендә өч мәртәбә үсеш! Журнал тарихында мондый сикереш бүтән кабатланмады. Моны ничек аңлатып була соң?*

*Беренче чиратта чор тудырган үзгәрешләр белән. Үзәктәге «җепшеклек» («оттепель») чоры безгә, татар әдәбиятына һәм журналистикасына бераз соңлабрак килде. Бәлки, иртәрәк тә килеп җиткән булыр иде. Сталин чорыннан калган куркаклык, партиягә сукырларча табыну, «милләтчелек» шаукәсеннән өркү хөкем итте. Югыйсә бу вакытта инде яшь буын, 30 нчы еллардан соң формалашкан әдәби буын үсеп җиткән иде. Аларга тик юлны гына киңрәк ачарга кирәк иде.*

*Икенчедән, халкыбыз тарихи дөреслеккә сусаган иде. Әйтик, журналның бер санында Шиһабетдин Мәрҗани турында шактый зур материал басылып чыккач, журналны кулдан-кулга йөртеп укыдылар, чит өлкәләрдән дә журналны сорап хатлар килде. Обкомнан исә моның өчен миңа выговор чәпәделәр.*

*Оештыру эшләре дә зур роль уйнады. Бу эшкә журналның бөтен коллективы җигелде. Ул вакыттагы журнал хезмәткәрләре Вакыйф Нуруллин, Равил Фәйзуллин һ. б. көн саен диярлек уннарча хатлар язып чит өлкәләргә җибәрәләр иде. Төрле өлкәләрдә журнал турында йөздән артык мәкалә басылды. Радио, телевидение аша да тапшырулар оештырдык. Журналның авторлары да, бигрәк тә яшь һәм башлап язучылар, бик зур ярдәм күрсәттеләр.*

*Мәсьәләнең кире ягы да бар иде. Анысын үзем генә беләм. Мин эшләгән чорда журналның бер генә саны да тыныч кына, шома гына чыкмады. Журнал дөнья күрү белән обкомга иске рухта тәрбияләнгән карт-лардан шикаятьләр килә иде. Фәлән әсәрдә*

кирәгеН анлый. Аннан сон ул үзенә тышкы объекттан алынган шундый корбан символы булдырырга тиеш. Аны кан саркыган жанынын эчке кичерешләре белән кушып, шунын белән матди дөнья объектына кеше жанында туа торган шәрех вә төсмерләр өсти. Шулай ике капма-каршы юл кушылып, кеше йөрәгеннән чыккан жанлы образ туа, һәм ул рухнын күтәренке халәтен гәүдәләндерә. Мондый образ жанда яналык булдыра, танып-белүнен гадәти булмаган юлын ача. Бу михнәтләрдән сон кеше фани дөнья артында торучы әлеге көчләрне күнел күзе белән күрә башлый. Тик кеше алда әйтелгән ике капма-каршы юл белән баручылар кебек читтән торып күзәтүче генә булып калмый. Ул рух патшалыгы колына әйләнми, үз субъектив башламына бәйле булмаган объектив көчләр белән ижатташлыкка керә, үзенә өченче юл таба. Бу юлда ул кеше асылы "Мин" мәркәзенен әлеге объектив көчләр белән охшашлыгын таба. Ләкин монда туктап калмый, дөнья нигезен тәшкил итә торган "Мин" принцибын үзендә куәтләндерә башлый.

Кеше үзе булдырган бу символ ни матди, ни эчке хисләр дөньясына алып бармый. Ул сурәткә текәлеп карап, анын турында уйланып, медитациягә керсән, рухани дөньяны танып-белү сәләте ачыла. Шул ук вакытта рух патшалыгына эгоистик кереп бату нигезләре дә югала, чөнки "мин" инде үзенен символлар булдыру эшчәнлегендә үзеннән читкә чыгып, дөньяга тарала. Кеше инде буш нирванага омтылмый, монахларча үзенә бикләнүне дә эзләми, ә социумга йөз белән борылып, кешеләргә хезмәт итә.

Бакый Урманче шәмаилләре нәкъ менә шуна туры килә дә. Хосусан, "Әлхәмдүлилләһи" әсәрендә яналык алып килүче өченче юл идеяләре гәүдәләнә. Үзәктәге өермәле әйләнәдә элмәк яисә тоен урнашкан. Ул — гарәп теленен "м" хәрефе. Антропософия тикшеренүләренә караганда, "м" хәрефе нинди дә булса бер объект белән аваздаш булган, аны анлаган жанда туа. Мәсәлән, якыннан анлашып сөйләшүләр арасында ымлап кына "м—м—м" дию, тагы йогларнын рух дөньясыны белән аралашуга илтүче "АУММ" магик сүзе. Бу контекстта шәмаилдәге Коръән сүзе "Әлхәмд" (мактаудагы) "м" авазы кеше жанынын Аллага омтылуы, Аны тынларга тырышуы. "Фатиха" сүрәсендә

*партия линиясеннән читкә тайпылыш бар, имеш. Фәлән мәкалә милләтчелек рухында язылган... Әзер булган журналдан материалларны алып ташлау, номер басылып чыкканда аны туктату, номер чыккач обкомга чакыртып сүгүләр—нәрсә генә булмады!*

*Барысын да сөйләсәң, озынга китә. Бер генә мисал китерәм. 1968 нче елның икенче санында әдәбият белгече Альберт Фәтхинең «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр» исемле мәкаләсе басылды. Басар алдыннан материалны җентекләп тикшердек, әдәбият тарихчылары белән киңәштек, кат-кат редакцияләдек. Бер караганда, мәкаләдә обком бәйләнерлек берни дә юк иде шикелле. Шуңа да карамастан, бу мәкалә өчен мине обкомга чакырып сүгүләр, махсус комиссия төзеп тикшерүләр, янаулар—барысын да булды, сөйләп бетерерлек түгел!*

*Баксаң, Башкортстан обкомы исеменнән шикаять килеп төшкән икән. Нигә бәйләнгәннәр? Имештер, автор Уфа төбәген татар мәдәни учагы итеп карый (Сүз революциягә кадәрле чор турында бара иде). Имештер, мәкаләдә татарларны башкортлар тарафыннан төрлечә кысу, чикләүгә ишарә бар. Кыскасы, мәкаләне Башкортстан обкомының рәсми сәясәтенә каршы килә дип бәяләделәр.*

*Шулай итеп, журналда эшләү көннән-көн кыенлаша барды. Язучылар съездындагы чыгышым бер сылтау гына булды. Барыбер үзең теләгәнчә эшләргә, үзең сайлап алган әсәрләрне бастырырга ирек бирмиләр иде...*

*Бүгенгәчә хәтеремдә: чыгышымның икенче көнендә мине яңа сайланган идарә рәисе Ибраһим ага Гази чакыртып алды. «Рафаэль туган,—диде ул.—Мин сине чын күңелемнән ихтирам итәм, син хаклы дип уйлыйм. Ләкин мин—партия солдаты. Ул кушканны үтәргә тиешмен. Шуңа күрә сайланганнан соң беренче эшем итеп мин сине эшеңнән азат итәргә тиешмен. Үз теләгем белән китәм дип гариза язасыңмы, әллә без алганны көтәсеңме?» Мин үз теләгем белән китү турында гариза язудан баш тарттым. Икенче көнне үк идарә утырышы җыйдылар. Идарә әгъзаларының күпчелеге шулай ук минем яклы иде. Кайберәүләр хәтта, обком күрсәтмәсенә каршы килеп булса да, мине үз урынымда калдырырга тәкъдим итеп карадылар. Әмма ул чорда обкомга каршы килеп булмый иде шул. Андый кеше бер көн дә эшли алмый иде. Ирексездән, ыңгырашып булса да, мине эштән азат итәргә дигән карар чыгардылар.*

күп кенә сүзләр "м" гә бетүе һәм хәрефенен үзе дә тоташтыручы элмәк, төен шәкелендә булуы очраклы хәл булмаска тиеш.

Композиция үзәгендәге бу төен суфилар өйрәтүендәге мөһим бер пункты белән аваздаш: һәрбер инанучы диндар үз эченә "Аллаһе бер" дигән "төп төенне" бәйли.

"Әлхәмд" сүзендәге мөһим символик мәгънә "м" хәрефендә генә түгел, ә бәлки аның артыннан килүче һәм композиция үзәгендәге алгы түгәрәк эчендә торучы азаккы "д" хәрефендә дә бар. Гарәп хәрефе "д" тышкы яктан очлы тау түбәсен ямсә алга ыргылган сөнге очын хәтерләтә, һәм бу аның мәгънәви эчтәлегенә туры да килә. Рух фәне гыйлемендә "д" хәрефе ихтыяри хисне расалаган мәгънә анлата һәм анда үзлек элементы да бар. Шуна күрә шәмаилдәге бу тамганы бик нигезле рәвештә илаһи—рухани чиксезлектән аерылган мөстәкыйль шәхеснен эволюцион сикереш нәтиҗәсендә үзенен рухани ана—ватаныннан өзелү һәм һәлакәтле төстә үз эгоцентризмына йомылу символы дип карарга була.

"Әлхәмдулилләһи" шәмаилен җентекләп караса, кеше үз индивидуаль асылынын космик ераклыктан килгән өермә хәлендә икәнен анлый. Кеше җаны шәмаилдәге туры сызык — илаһи агымны да күрә. Ул агым адашкан кешелеккә күктән килгән коткару импульсын күрсәтә. Җан үзенен үсеш перспективасын инде мин-минлектән баш тартуда, эгоцентризмны юк итүдә күрә һәм ин югары Рух белән кушылу кирәген анлап, үзенә оптимизм таба: мәнгелеккә юл ача.

Бу символик сурәт акылга гына түгел, ә хисләргә дә кешенен бөтен барлыгына кирә. Кеше кичерешләре белән ул сурәт гомернен ин югары идеалына әверелә.

Бу сөйләгәннәрдән шундый фикер дә туарга мөмкин: шәмаил хакында югарыда әйтелгәннәр дөрес тә сыман, әмма асылда бу фантазия, реальлек белән бернинди уртаклык булмаган уйдырма. Әйе, һичшиксез бу сурәт бары хыялыбызда гына. Һәм Рухны тану юлын эзләүчеләр өчен бу нәкъ шулай булырга да тиеш. Әгәр ул тыштагы берәр нәрсәне чагылдырса, анын безгә кирәге дә калмас иде: тыштан керүче сиземләүләребез чагылышы бик зәгыйфь безнен. Ләкин Бакый ага Урманче иҗат иткән сурәттә без бик тәэсирле элементлар табабыз, алар сиземләү дөньясыннан алынсалар да, эчке хис-тойгы вә кузаллаулар белән бәйле. Менә шул нәрсә кеше күнеле төбендә йокымсырап яткан тирән көчләрне уятуга булыша да инде. Чөнки югары рух дөньясына фикерләү, дога кылу, медитация аркылы күтәрелүче кеше абстракт символлар эчендә яшәми, ә шул сурәтләрне иҗат иткәндә уяна торган хис вә кузаллаулар дөньясында була.

Хәзерге исламда фатальлек, кеше яшәешенен алдан билгеләнгән язмышка буйсыну проблемасы бик кискен тора. Шуна күрә рух турындагы фән кешенен гармонияле үсеше ягында. Ул фән дөньянын илаһи — рухани нигезе — Хак Тәгаләне шәхеснен танымавын авыру дип таба, Аллаһ Тәгаләдән чыккан үзәк иҗади импульсны Иблис һәм Шайтаннан коткаручы ярату, миһербанлык принцибын белмәвен фаҗига дип билгели. Ә инде бәндәнен шул рухани-фәнни танып-белү ихтыяҗы булмавын зәгыйфь акыллылык дип саный. Шул ук вакытта рухани белем Аллаһе Тәгаләнен үзәк импульсын тәшкил иткән Христосны шәхес буларак кукләрдә күрү барлык дини агымнар өчен дә мәҗбүри түгел икәнен күрсәтә. Кодрәт иясе дөньясына ишек күренмәс Алла, Изге Рухны кабул иткәндә дә ачыла. Бу хәлне христиан ортодокслары да таный: аларда Голгофа фетнәсеннән сон Иисус Христоснын (Мәсихнен) ин югары сфераларга күтәрелүе һәм ана үзенә алмашка янартылган Изге Рух, Юатучы-тынычландыручы Хакыйкать рухы җибәрелүе әйтелә. Бакый ага Урманче җиһаннын илаһи нигезен нәкъ шулай анлаганын, үзенен Аллаһе Тәгаләгә олылау мөнәсәбәтен "Иман" исемле шигырендә язып калдырган.

• • •

Безнен бу хезмәт Б.Урманче иҗатында шәмаилләр темасын тулысынча ачуга дәгъва итми. Монда безнен көннәрдә аеруча актуаль булган кайбер әһәмиятле моментлар гына искә алына. Бүгенге җәмгыятьтә танып-белү эшчәнлеге гасырлар дәвамында шактый тотрыклы урын алган ислам, христиан вә гайре дини ышанулар кочагына атыла, анда дөнья корылышын борынгы традицион анлатулардан үзенә канәгатьләнү табарга тырыша, ә ул анлатмалар хәзерге ан өчен күп нәрсә бирә

алмый. Җәмгыятьнең икенче өлеше табигый-фәнни күзаллаулар үзәнендә калырга теләп, илаһи дөньяны инкарь итә һәм кешелекнең рухани омтылышларын бары атавизм йә аномалия күренешләре дип белә.

Мондый шартларда Бакый Урманченың иҗади эзләнүләре үз әсәрләрендә фән, дин, сәнгать һәм әхлакны кавыштыра. Рәссам үзенең эшләрен, башка иҗатчыларның күбесенә хас булган рәвештә, гакыл вә эстетик хис таләпләренә генә буйсындырмый, ә кеше асылына тулысы белән бәйләнешле булуына омтыла. Бакый Урманче шәмаилләре борынгы культурада әһәмиятле роль уйнаган сурәт символизмын янәдән кайтара. Дөньяны сурәтле-символик кабул итү яшәешенең хәзерге ин кирәкле, әһәмиятле нәрсә. Ул абстракт-мантыйкый фикерләүне тирәнәйтә, баета һәм безнең анны яна югары баскычларга күтәрә. Бу баскычлардан кеше Илаһи көчләрнең эволюцион иҗади эшчәнлеген аңлау дәрәҗәсенә менә. Шунысы гыйбрәтле ки, Урманче үз эшләрендә стилизация белән шөгыльләнми һәм инде әлекке тәэсирчәнлеген югалткан тамгалар системасының онытылган трактовкасына да кайтмый. Ул шулай ук абстракционизмга да кереп батмый, әмма яна, хәзерге рухани сиземләүгә адресланган сәнгати образ-символлар иҗат итә. Рәссам илаһи текстларны тышкы бизәүдән ерак. Ул аларның эчке төзелешләренә үтеп кереп, аеруча тәэсирле, тирән мәгънәле, матур тамгалар системасын булдыра.

Мондый шәмаил инде ислам таралуының тәүге гасырлары мөселманнары өчен яраган бөти генә, яисә табыну (культ) әйбере түгел. Шулай ук ул матур, күзне рәхәтләндерә торган, шул ук вакытта Коръән сүзләрен бормалап-сырмалап гарәпчә язган гади шәмаил дә түгел. Урманче шәмаилләре кешедә Кодрәт иясенең илаһи сүзенә, игелекле Гамәленә якынайта, беркетә торган яна көчләр уята. Аның эшләре — гакыл белән анны нурландыра, йөрәкне жылыта һәм иманны янарта торган чын сәнгать әсәрләре. Бакый Урманче шәмаилләре саф эстетик хисләр сферасыннан югары булган рухани дөньяга алып керә: мәһабәт манара кебек биеклеккә омтылган "Әлхәмдүлилләһи" шәмаиле Асылның яшерен серләренә якынайткан догадай, җанга Мәнгелек һәм кеше шәхесе үлемсез дигән хисне үткәреп, иҗат нигезендә яткан чиксез космик мәхәббәт импульсын тою мөмкинлеген бирә. Нәкъ шул саф рухани мәхәббәт галәмгә, кешелеккә таралып, дөньяны коткаручы Зирәклек, Гүзәллек, Илаһи хөкемдарлык бүләк иткән иҗади көчләргә ия.

Бакый Урманче шәмаилләре образ өчен актив фикерләү, медитация хезмәте сорый. Шуның белән бергә аларга томанлы мистицизм вә хорафатлар түгел, якты көн аны кирәк. Шуңа да алар шәхеснең бөек вазифасын вә дөнья язмышы өчен җаваплылыгын күрсәтеп, Кеше дәрәҗәсен күтәрә, анда рухани башламны ача.

Кыскасы, Урманче әсәрләре Изге текстларны камил сәнгатьчә гәүдәләндереп,бөек хакыйкатьне кичерү һәм ана кушылу өчен ачкыч бирәләр. Бу Хакыйкать Аллаһе Сүзе гәүдәләнеше булган Кешене янәдән тудыра: җиһанның Илаһи-рухани нигезе үлчәнмәс рәвештә тирән, космик Фикернең төбе чиксез вә Кешегә бирелгән Сүз — ул Фикернең коралы бөтен галәмне җанлы канатлары белән кочып тәрбияли торган көч.



*Әдәбият тарихына*

# ГАБДЕЛБАРИ БАТТАЛ—ТӘНКЫЙТЬЧЕ

Баттал-Таймас талантлы педагог һәм мәгърифәтче генә түгел, ул—тарихчы һәм әдәбиятчы зур галим дә, талантлы тел белгече һәм сәясәтче дә, журналистика өлкәсендә тирән эз калдырган матбагачы да. Г. Баттал үткән гасырның унынчы елларында теоретик әзерлекле, принципиаль һәм объектив тәнкыйтьче буларак таныла. Ул 1908-1910 елларда «Вакыт» газетасында эшли, 1913-1917 еллар аралыгында «Йолдыз»да редакция мөдире вазыйфасын башкара. Күп кенә мәкаләләре «Вакыт», «Йолдыз», «Шура» кебек газета-журналларда басыла. Аның тәнкыйть эшчәнлеге иртә башлана, әдәбият тарихы белән кушылып та китә. Дөрес, әдипнең тәнкыйди мәкаләләре, әдәби әсәрләргә язылган рецензияләре, язмалары күп түгел. Әмма аларда Г. Батталның әдәби тәнкыйть һәм аның бурычлары, милли тәнкыйтьнең үзенчәлекләре, тәнкыйтьче—укучы—язучы арасындагы мөнәсәбәт турындагы уйланулары игътибарга лаек. Аның иҗатында рецензия, публицистик мәкаләләр еш очрый.



1909 елда «Шура»да аның күләмле тәнкыйть мәкаләләре басыла. Г. Батталның «Тәнкыйть» дип аталган мәкаләсе гарәпчәдән Закир Кадыйри тарафыннан тәрҗемә ителгән «Тәхрирел-мәръат» («Хатын-кыз азатлыгы»), «Әлмәръатеж-җәдидә» («Яңа хатын-кыз») әсәрләренә багышланган. Аларны Мисырның атаклы галиме, җәмәгать эшлеклесе, публицист Касыйм бәк иҗат иткән. Әлеге китапларда хатын-кызларның азатлыгы яклана, аларның тормышын үзгәртү кирәклеге нигезле дәлилләр белән раслана, искелек тәнкыйтьләнә. Бу уңайдан заманында Ф. Әмирхан да рецензия яза һәм әсәрнең идея-эчтәлегенә уңай мөнәсәбәт белдерә.

Г. Баттал мәкаләсенең «Сүз башы» аеруча кызыклы. Тәнкыйтьче матур әдәбиятның тәнкыйтькә мохтаҗлыгы турында яза да халыкта уку теләге, яңа әдәбиятны тудыру нияте көчле булмауга борчылуын сиздерә: «Хисаметдин менла»лар, «Гүзәл кыз Хәдичә»ләр, «Гөнаһе кәбаир»ләр, хәтта анлардан күп заман соңга «Сәлимә», «Шагыйрь илә студент», «Мәгыйшәт», «Өч бәдбәхет», «Бәхетсез егет», «Тәгаллемдә сәгадәт»ләр вә башкалары нәшер ителгән чакларда тәнкыйть фәлән илә маташмак бик мәүсимсез (вакытсыз) вә мәгънәсез булыр иде. Чөнки безнең арабызда әүвәл заманнарда уку һәвәсе вә яңа татар әдәбияты тәэссис (нигезләү) итү фикере бер дә юк иде». (3, 360 б.).[1] Аның карашынча, яңа эчтәлекле китаплар булмау сәбәпле, әдәби тәнкыйтькә дә ихтыяҗ барлыкка килми. Алга таба мәкалә авторы бу хәлнең сәбәпләре турындагы гамьнәрен тагын да тирәнәйтә; милли тормыш, аның артталыгы, мәктәп-мәдрәсәләрдә бер төркем гарәпчә, схоластикага корылган китаплар гына укытылу белән бәйләп куя: «Дини мәдрәсәләремездә бер такым (төркем) гарәпчә схоластика китаплары истигмал (файдалану) ителә, ак өстендә кара

[1]Искәрмә: чыганаклар исемлеге мәкалә ахырында бирелә. Җәя эчендәге беренче сан өзек алынган хезмәтнең әлеге исемлектәге тәртибен, ә икенче сан өзекнең хезмәттәге ничәнче биттән алынганын күрсәтә.

таныган ирләр, хатын вә кызларымыз арасында вакыт уздырмак, көнәлләр юатмак өчен «Йосыф» китабы, «Таһир илә Зөһрә», «Бүз егет», «Ярым алма», «Кисекбаш» китаплары кеби нәрсәләр укыла вә тынлана». Дөрес, биредә автор гасырлар буена халкыбызның рухи ихтыяҗын канәгатьләндереп килгән, аның әдәби зәвыгын, әхлагын тәрбияләгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы кебек ядкәрләрнең әһәмиятен өлешчә киметү юлына да баса. «...бонларны уку, тынлау, мәгъдәни (казылма булырлык) булындырырлык бер дәрәҗәгә житсә дә, һаман шунлардан өзелми, төрле мәүзугъ (тема) вә бәхәсләшергә даир (бәйләнешле) яна-яна рисалә (журнал) вә китапларның кирәклеге һичбер төрле сизелми иде (3, 361б.).

Татарларда әдәби тәнкыйть булмауның бер сәбәбе итеп Г. Баттал милләтебез зәвыгының түбәнлегән, хиссиятенең тупаслыгын саный: «Хөләса (шулай итеп), безнең халкымыз зәвыксызлыгы вә хиссиятенең тупаслыгы сәбәбеннән тән гыйззасында (туклану) бу көннәргә хәтле камыр илә ит тирәсеннән узмадыгы кеби, рух гыйззасы да шул иске вә эштән чыккан китаплардан уза алмыйча озын гасырлар кичермештер. Хезмәт авторы халык зәвыгының түбән булуы милләткә хезмәт итәрлек укымышлы, тәрбияле, киң карашлы галимнәр, әдипләр булмаудан дигән фикер уздыра. «...милләтнең фикеренә тәрбия итәрлек бер галим, зәвык вә хиссиятенә тәрбия итәрлек бер әдип житешмидер». Г. Баттал милләт алдында торган төп максатны «халыкта моталәга (уку) һәвәсе уяндырып, яңа әдәбиятыбызга нигез ташы куймак» рәвешендә тәкъдим итә. Мәгълүм булганча, ике гасыр чигендә дөнья күргән һәрбер әсәрне алкышлап каршы алганнар һәм идея эчтәлеге белән туры килмәсә дә, миллилек белән урынсызга мавыгып китеп, «милли роман» дип язу гадәткә, хәтта, әйтергә кирәк, модага әйләнгән: «Бинаэн галәйһи яңа чыккан һәрбер рисалә вә хикәяне алкышлап вә котлап алырга мәҗбүр идек. Хәтта ул чакта теге биш тиенлек «Өч бәдбәхет»нең тышына «милли роман» дип язып кую да ярый иде». Г. Баттал үзенең мәкаләсендә тирән йокыда булган халыкны уятырга вакыт житүен хәбәр итә. Татар дөньясында фәнни тәнкыйтькә ихтыяҗ туа һәм мәйдан барлыкка килә. «Халык яхшы ук уянды. Мөталәгагә рәгъбәт байтак артты. Моннан аңа бу көндә инде чиләк төбе кагу килешеп бетми. Хәзер дә аһәнле нотага куелган тавышлар кирәк»—дип, Баттал акыллы, төпле тәнкыйть зарурилыгын әйтә. Ул вакытлы матбугат сәхифәләрендә басылып чыккан тәнкыйть мәкаләләренең кимчелекләре турында сүз алып бара; тәнкыйтьнең сай, өстән-өстән генә булуына борчылу хисе белдерә; рецензияләрдә әдәби әсәрләргә бәя бирелмәү, тәнкыйтьченең карашы, мөнәсәбәте чагылмау шулай ук аның тарафыннан житешсезлек буларак күрсәтелә: «Дөрес, бу көндә бездә тәнкыйть вә тәкърыйз дигән нәрсә (язылган әсәргә макталган бәя бирү) бөтенләй юк түгел. Газета вә мәҗмугаләребездә махсус тәнкыйть вә мөхакәмә ... да бар. Ләкин болар бик әһәмиятсез, бик накыйсдер (кыска). Зерә күп газета вә журналларыбыз каталоглардагы кеби, яңа әсәрләрнең ачык исемнәре, мөәлләфә (әсәр) яки мөтәрҗемәләрнең адларыны мәхәл, табгаларны (басма) вә бәһаләрне гөнаһ санап чыгалар вә аларны һич бер төрле тәнкыйть вә мөхакәмә итмиләр вә алар тугрысында үзләренең фикер вә нәзарларны язмыйлар... бәгъзе тәнкыйтьләр, бары китапның мөәллифен (төзүче) сүгүдән вә аны мәсхәрә итүдән гыйбарәт».

Г. Баттал әдәби әсәрнең тел-стиленә бәя бирүне тәнкыйтьнең мөһим бурычларының берсе итеп алгы планга чыгара, ә бу, аның карашынча, ул чор тәнкыйтенең олы житешсезлеге: «Күбесенчә, безнең тәнкыйтьчеләр китаптагы нәзар (караш) вә фикерләрне генә бер дәрәҗәгә кадәр тәнкыйть вә мөхакәмә (хөкем чыгару) итәләр, тарыз ифадә тәгъбирәт (фразаларны дөрес куллану ысулы) вә имля мәсьәләләренә әһәмият биргән кеше юк». Әлеге мәсьәлә бигрәк тә тәрҗемәләргә карый. Аның карашынча, тәрҗемә ителгән әсәр нинди телдә булуына карамастан, татар теленең нормаларына, кагыйдәләренә буйсынган булырга тиеш: «Бихосус ки (бигрәк тә), тәрҗемәләрнең дөрес тәрҗемә ителмәвенә тәгъбирләр, истиляхлар (термин), өслүбләрнең татарча булып, йә булмавына вә гомумән, тәрҗемәнең җанлы, уйнак вә татар рухында булырлык чыгып-чыкмавына игътибар иткән адәм бер дә күренми. Хәлбуки безгә бу ноктаи нәзардан (караш ноктасы) тәнкыйтькә бик әһәмият бирергә тиеш». Тәрҗемә ителгән әсәрләрнең

тел вә ифадә—сүзләр бәйләнеше җәһәтеннән татар теле кануннарына туры килмәве тәнкыйтьчене, бер яктан, борчыса, икенче яктан, галимнәр тарафыннан имляның бер нормага салынмавы уйландыра. «Имлямызга сон вә гомумән мәкъбул (кабул ителгән) кагыйдәләр куелганы юк. Тәгъбират вә истиляхатымыз (атама) төрек, гарәп вә рус тәэсире астында хәйран булып йөри»,—дип, фәнни стильнең терминологиясен, әдәби телнең әйтелеш һәм язылыш кагыйдәләрен, нормаларын эшләү кебек әһәмиятле мәсьәләләрне күтәреп чыга.

XX йөз башында татар иҗтимагый фикере, әдәбият тәнкыйте үсешендә Аурупа вә Шәрык дөньясына игътибар арта. Г. Баттал үзенең мәкаләсендә аурупалыларда әдәби тәнкыйтькә зур игътибар бирелгәнлеген яза: «Хәлбуки аурупалыларда вә русларда тәнкыйть әдәбиятның мөһим кыйсмен тәшкил итә. Тәнкыйть һөнәре инде мәтхосус галимнәр бик күп».

Мәкалә авторы «Сүз башы» кисәгеннән соң журналның дүрт санында тәрҗемәләргә тәфсилле тәнкыйть язган. Иң беренче эш итеп ул тәрҗемәләргә гомуми бәя бирә. Китаптагы фикерләрнең татар дөньясына чыгуына, барып ирешүенә сөенеп, З. Кадыйри эшчәнлегенә унай мөнәсәбәт белдерә: «Закир әфәнде иң җитди китаплар тәрҗемә итә, мөселманлык дөньясында хәрәкәте фикрия (фикер хәрәкәте) вә хөррият чишмәсе булган Мисыр кыйтгасындагы (өлеш) голәма вә фөзәлаэ (алдынгы кешеләр) дин вә дөнья хакындагы әфкяр (фикерләр) вә нәзарлары (карашлар) илә үземезнең надан, караңгы вә искечәрәк халкымызны ашна (таныш) итәргә гайрәт вә һиммәт (тырышлык) итәдер (8, 393 б.). Г. Баттал тәрҗемәләргә бирелгән берьяклы бәяләргә карап, аларны укымыйча ярамый дигән карашта тора. «...мин бу китапларның саклап торучылардан вә ул китаплардагы фикерләрне яклаучылардан булудан, аларның үз телемезгә тәрҗемә булуына вә бик рәгъбәт илә укылуын бөтен вөҗүдем (гәүдә, җан) илә тели идем»,—дип, анда күтәрелгән мәсьәләләрне хуплый, аларга үзенең фикердәш икәнен белдерә. Әмма укып чыккач, тәрҗемәләрнең сыйфаты аны канәгатьләндерми. Әдип «китапларның бик авыр, вә көч илә аңлашылачак тарызда тәрҗемә ителгәнлеген» ассызыклый, аларны гарәп телен бик яхшы белгән кеше генә аңлый ала дигән фикергә килә: «Бу тәрҗемәләрдә шундый читен вә чишелмәгән урыннар бар ки, бу китапларның асылын гарәпчәсен ... әллә ничә кат укыган мин бик кыенлык илә генә аңлый аламын». Ул алга таба тәрҗемәләрдәге кимчелекләрне санап китә, шул унайдан үзенең киңәш-теләкләрен дә белдереп бара. Беренчедән, ди ул, китаплар татарча-төркичәгә әйләндерелмәгән хәлдә, исемнәре дә гарәпчә калдырылган. «Тәхрирел—мәрьат» исеме «Хатыннар хөррияте» яки «Хатыннарга хөррият» исеменә вә «Әлмәрьатеж-җәдидә» исеме «Яңа хатын» исеменә авыштырылса, яхшырак булыр иде. Икенчедән, алынма сүзләр кулланышында, сүзләр бәйләнешендәге кимчелек. Мәсәлән, бер җөмләдәге бер сүз саф татарча булган хәлдә, аны күршесендәге икенче сүзнең татарча синонимы ташланып, саф төрекчә сүз куелган. Яки бер сүз чын төрекчә язылган хәлдә аның янындагы иптәше чын татар имлясында язылган. Өченчедән, күп кенә сүзләр, тәгъбирләр, татар телендә билгеле булса да, гарәп телендә калдырылган. Боларның күбесе укучыларга аслан ишетелгән сүзләр. Дүртенчедән, җөмләләр озын вә бәгъзеләре бигрәк озын булмаклы бәрабәр гарәби өслүбтәрәк төзелгәннәр дә бик мөгъләкъ (аңлаешсыз) вә аңлашылмый торган булып киткәннәр. Бишенчедән, әсәр башыннан алып ахырына кадәр бер аһәңдәрәк. Укучыларны дәртләндерми, яки аның рухын уятмый. Алтынчыдан, тәрҗемәдә байтак кына ялгышлар бар. Гарәп газеталарында мөхәррирлек иткән Закир әфәндегә бу ялгышлыклар гафу ителми. Җиденчедән, ул китапның авторы турында бераз мәгълүмат бирүне кирәк дип саный: «Китаплардагы мәзкүр әшхас (әйтелгән шәхесләр) хакында сызык астында бераз мәгълүмат биреп китмәүдә кимчелек саналырга ярыйдыр. Чөнки бу китапларны гарәп әдәбиятыннан хәбардар зыялылар гына укыйдыр. Бик күп укучылар нисбәт, ул шәхесләрнең шулай бөтенләй мөбһәм (билгесез) калуы килешеп бетми, бәлки тәрҗемәнең җансызлыгын гына арттырадыр. (8, 396 б.).

Күргәнебезчә, Г. Баттал тәрҗемәләрнең тел, стиль җәһәтеннән кимчелекләрен күрсәткән. Әдип эчтәлекнең төгәлсезлекләрен аерым мисаллар белән дәлилли. «Әнә-менә» шигырендә Г. Тукай да китаплар тәрҗемәсен камчылап ала:

«Әнә чеп-чи бәрәңге кәлҗемәсе. Менә «Тәхрире—мәрьат» тәрҗемәсе.

Татар әдәби тәнкыйтен, аның теориясен үзенчәлекле нәзари карашлары белән тулыландырган Ф. Агиев әдәби иҗатның бу төрен шәхси һәм гайре шәхси төрләргә бүлә. Алга таба фикерен тагын да үстереп, «тәнкыйть шәркый» һәм «тәнкыйть гарби»не аерып чыгара да Г. Батталның тәнкыйди эшчәнлеген гайре шәхси, ягъни аурупа тәнкыйтенә караганлыгын раслый. (1, 40 б.). Закир Кадыйрида Г. Батталның тәнкыйте ризасызлык уята һәм ул, үз нәүбәтендә, «Тәнкыйтькә каршы бер-ике сүз» (1909) дип исемләнгән җавап мәкаләсе белән чыгыш ясый. Баттал, ике арада туган кызу бәхәскә җавап йөзеннән һәм үзара аңлашу максатын да күздә тотып, «Тәнкыйть тирәсендә» (1909) дигән язмасын «Шура» журналы битләрендә бастырып чыгара. Ул анда тәрҗемә юллары турында сүз алып бара: «Шулай ук мөтәрҗемәләрне, мөәллифләрнең (төзүче) китапларны язган чакта күңелләрендә җәвәлаи (хәрәкәт) иткән хиссият вә энже мәгънәләрне тәрҗемә итмәдекләре өчен һичкем интикад (тәнкыйть) вә мөахәзә итмидер. Бәлки шул китапларда язылган сүзләрне генә бозмыйча вә мәгънәләрен үзгәртмичә тәрҗемә итүләре таләп ителәдер (4, 262 б.). Ул алга таба сүзгә-сүз һәм ирекле тәрҗемәләрне аерып чыгара, сүз сөрешеннән авторның беренче юлга тискәре мөнәсәбәте сиземләнә. Автор әсәрнең эчтәлеген, мәгънәсен саклаган хәлдә татарча тәкъбир, истиляхат стильдә тәрҗемәләүне таләп итеп куя: «Шунын өчен гарәпчәдән тәрҗемә ителгән бер китапның сүзләре, сарыф (морфология) татарча булдыгы хәлдә өслүбе гарәпчә булса бән аны яхшы тәрҗемә дип әйтә алмыймын вә Касыйм бәк Әмин әсәрләренең тәрҗемәләре шул кабилдәнрәк (төр) дия икътикад (ышану) итәмен. Ләкин мәгънәнең үзгәртелүенә аслан разый түгелмен. Аннан соң гыйбарәләрнең асылдагы кеби рух вә куәтләрне тәрҗемәләрдә дә мотлакан сакларга кирәк димен» (4, 662 б.).

Г. Баттал—XX гасыр башы милли мәгариф тарихында оста педагог, методист буларак та тирән эз калдырган шәхес. Әдәбиятны җәдиди мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту, аның юллары, ысуллары һәм максат-бурычлары кебек сорауларга җавап йөзеннән ул, үз тәҗрибәсенә һәм бу өлкәдә, рус әдәбият фәне ирешкән казанышларга таянып, «Нәзарияте әдәбия» (Казан, 1913) дигән дәреслеген яза. Әйтергә кирәк, әлеге китап милли мәгариф йортлары укытучылары алдына куелган күп сорауларга ачыклык кертеп, бу өлкәдәге эзләнүләрне тагын да үстерә. Аның бу хезмәтендә тәнкыйть, аның үзенчәлеге, төрләре, бәяләү критерийлары турында фәнни-нәзари белемнәре дә урнаштырылган. Бирелә алдагы хезмәтендәге карашлар тагын да тирәнәйтелә, гыйльми югарылыкка куела, системалаштырыла. Тәнкыйть—Г. Баттал карашынча, бер әдәби китапка яки сәнгать (рәсем, музыка) әсәренә бәя кую, аның уңай якларын яки кимчелекләрен күрсәтү ул. Монда тикшерелгән әсәр буйсынырга тиеш булган кагыйдә вә кануннарны да истә тоту зарури. Алга таба автор әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен бәяләү таләпләре турында сүз алып бара. Әдәбият вә сәнгать әсәрләрен бәяләргә тиешле кагыйдә, кануннарны Г. Баттал критерий дип билгели. Аерым әсәрне тәнкыйть иткәндә таяныла торган кагыйдә вә кануннарның мәҗмугасен «Критериум» дип атый.

Автор тәнкыйть алдына зур таләпләр куя. Ул әдәби әсәрнең кагыйдә вә әдәби кануннарга нигезләнеп иҗат ителүен яклый. Шул ук вакытта әдәби әсәр, сәнгать әсәренең төзелеше, язылышына караган фәнни юналыклар, аңа куелган таләпләрне күз уңында тотуны да искәртә. Әсәрнең сюжет-композициясе бәяләнгәннән соң, тәнкыйтьче игътибары китапның идея-эчтәлегенә юнәлтелә. Әсәр темасының ачыклыгы, фикер дәрәслеге, аларның заманчалыгы объектив бәяләнергә тиешле сыйфатлар буларак күрсәтелә. Әсәр теленә, стиленә җитди анализ ясауны тәкъдим итеп, Г. Баттал үзен таләпчән тәнкыйтьче буларак күрсәтә.

Бу чорда әдәбият белеменең һәр тармагында әдәби бәхәсләр кабынып тора. Шул уңайдан Г. Баттал «антикритика» дигән төшенчә куллана. Аның карашынча, антикритика—каршы тәнкыйть, мөнәкъкыйднең фикерләрен рәд кылу (кире кагу) (5, 47 б.). Бу төргә мөрәҗәгать итү Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Сәгъди, Н. Хәлфин, Г. Ибраһимов һ. б. ларның тәнкыйть практикасында күзәтелә.

«Нәзарияте әдәбия» хезмәтен язганда Г. Баттал рус әдәбият белеменә мөрәҗәгать итсә дә, әдәби тәнкыйтьнең зарурилыгы мәсьәләсенә ул милли

жирлектән якын килә, аның төп принципларын һәм юнәлешләрен билгеләгәндә татар әдәбиятының үсешен күздә тота.

Галим, тәнкыйтьче татар әдәбияты әһелләренә дә бәя бирүне үзенең бурычы итеп саный. Г. Баттал тәнкыйтендә көрәштәше, фикердәше, татар әдәбиятының олы маягы Г. Исхакый иҗаты, аның аерым әсәрләре бәяләнә. 1909 елда Г. Исхакыйның «Мөгаллим» әсәре басылу мөнәсәбәте белән Г. Баттал «Мөгаллим» китабы вә өйләнү мәсьәләсе» (1909) дигән мәкаләсен яза. Иң беренче нәүбәттә, ул әсәрнең сюжетына тукталa, аның проблемаларын билгеләп үтә. Татар дөньясында катнаш гаилә мәсьәләсе хасил булуы милләти рухлы әдипнең игътибарын җәлеп итә. Аларның күбәеп китүен татар кызларының надан, артта калганлыгы белән бәйләп карый: «Русия инкыйлабыннан соң байтак зыялыларыбыз, мөселман кызлары арасында үзләренә тиң кызлар тапмадыкларыннан рус, поляк, француз вә яһүди илә өйләнмәгә башладылар». (9, 2 б.). Автор борчылу хисләрен дәвам итеп, аны милләтнең киләчәген куркыныч астына куючы сәбәп итеп күрсәтә: «Бу көндәге татар кызларының ифрат дәрәҗәсендә, тар фикерле вә надан улдыклары... бәлки мондый кызларның үзләре, кияүләрен җинеп, үз юлларына салулары, ниһаять, аларны кешелектән чыгарулары һәм өйләнгән булып балалар ясамак вә шуларны асрамак вә үстермәкләр бу дөньяда күреләчәк эшләрнең иң вакларыннан булдыгы күрсәтелмештер». Бередә Баттал, һичшиксез, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга, образларга йөкләнгән идея-эстетик мәгънә, драманың төп фикере, идеясе турында сүз йөртә. Алга таба мәкалә публицистик төсмер ала һәм автор балаларны тәрбияләү, белем бирү, аның үзенчәлекләре, баскычлары турында уйлануларын укучыга тәкъдим итә: «Ошбу тәһликәләрнең (һәлакәт) юлын белмәк өчен берничә чара кызларымызны да егетләремез кеби укытмак вә анларны да гыйлем вә мәгариф нуры илә нурландырмак вә якты дөнья илә ашна (танышу) итмәктер». Хатын-кызларны укыту мәсьәләсенә тукталып, Г. Баттал татар дөньясында хатын-кыз иреге, тигезлеге, азатлыгы, аның гаилә, бала тәрбияләү, җәмгыятьтәге урыны кебек мәсьәләләрне күтәрә.

Иҗат кешесе буларак, Г. Батталның шагыйрь Г. Тукай шигъриятен күзәтеп баруы да шик уятмый, әмма Тукай исән вакытта галим аның иҗаты, тормыш юлы турында матбугат битләрендә махсус мәкалә белән чыгыш ясамый.

Шагыйрьнең вакытсыз үлеме исә күпсанлы мәкаләләр, фәнни хезмәтләр авторы Батталны кулына каләм алырга этәрә һәм ул «Кояш» газетасының 1913 елгы 9 апрель санында Тукайның вафаты уңае белән кайгы-тәгъзия бастыра. Озак та үтми, шул ук газетаның 17 апрель санында «Габдулла Тукай» исеме астында күләмле генә мәкаләсен укучылар хөкеменә тәкъдим итә. Ул искә төшерү, хатирә шәкелендә җылы итеп язылган. Язма, иң беренче нәүбәттә, шагыйрьнең биографиясен моңа кадәр билгеле булмаган яңа фактлар белән тулыландыра. Мәсәлән, кымызга барганда Тукайны Уфадан Троицкига Батталның озатып җибәрүе ачыклана. Аннан соң, Троицкига кадәр туры поезд булмаганга Чиләбедә тукталыш ясарга мәҗбүр шагыйрьне каршы алу эше дә мәкалә авторы тарафыннан оештырыла. Хатирәдә шагыйрьнең бу вакыттагы хәле, сәламәтлеге, тышкы кыяфәте турында да әйтелә. «Караватт өстендә боегып яткан бу зәгыйфь, ябык вә чандыр гәүдәле зат әсәрләрендәге рух, голувият (бөеклек) вә мәгънәләр аркасында бик олуг вә мөхтәрәм булып күренә иде» (7,64-66 б.). 1912 елның август аенда Г. Батталга Тукай белән икенче тапкыр һәм, әйтергә кирәк, соңгы тапкыр күрешү Казанда насыйп була. Ике арада бик тиз гади һәм дустанә мөнәсәбәт урнаша. Күзгә чагылган беренче сыйфаты—гадилек, сүзгә осталык. Ул Батталны гаҗәпкә дә калдыра һәм шул ук вакытта сокландыра да: «Сүз арасында көлкеләр, ләтыйфә (мәзәк) вә мөзахлар (юмор) кыстырып җибәрә иде. Бик тиз үзләшеп киттек, аңлаштык» (7, 64 б.). Бередә бер-берсенең иҗаты белән алдан таныш булу, аның зурлыгын тану, югары бәя дә уңай роль уйнагандыр күрәсең. Мәгълүм булганча, Г. Тукай 1912 ел сәфәрләре хакында «Мәкаләи махсуса» исемле кульязмасын бастырып чыгара. Шагыйрь анда Батталның тәнкыйди эшчәнлегенә уңай мөнәсәбәт белдерә һәм «үткен вә искренний интикадлар» (тәнкыйть мәкаләләре) авторы белән күрешүе турында да җылы итеп искә ала.

Г. Баттал алга таба шагыйрь иҗатының төп үзенчәлекләрен гомуми планда ассызыклауга күчә. Ул Тукай әдәби мирасының кыйммәтен бәяләүгә, иң беренче чиратта, аның әсәрләренең теле, өслүбе аша якын килә. Татар теленең язмышы, аңа мөнәсәбәт, иҗтимагый фикер үзгәрешенә тарихи күзәтү ясаганнан соң, Тукайның, үз әсәрләрен татар телендә язып, милли әдәби телне шәкелләштерүдә, халыкның җанлы сөйләм теленә якынайтуда, аны үстерүдә, югары күтәрүдә шагыйрьгә олы бәя бирә. Шагыйрь әсәрләренең халык тарафыннан яратылып, сөелеп укылуының серен Баттал Тукай шигъриятенең халыкчанлыгында, матур һәм гади телендә күрә. Аның карашынча, Тукай халыкка үз теле белән аның бөеклеген, зурлыгын, көчлелеген, шагыйрьлеген, дәртлелеген аңлата, үз теле белән халык моңын җырлый, «халыкның кимчелекләрен шул ук халык теле белән тәнкыйть итә вә үзенең искитәргеч сатирасы куәсе белән бу турыда чын муаффакыятькә (уңышка) ирешә». Тукайның шигъри куәтенә сокланып, аның милли рухына, татар җанлылыгына басым ясап, Баттал болай ди: «Татар бәхте өчен мин җан атармын, татар бит мин, үзем дә чын татармын,—дип, түгел мактаныч вә горурлык белән күкрәк киереп сөйләгән татар угълының ялкынлы йөрәгеннән, бәлки ул моңлы йөрәкнең иң тирән җирләреннән чыккан, шунлыктан аны һәрбер татар йөрәге сизә». Шушы язмасында автор аерым мәсьәләләрдә Г. Ибраһимов белән бәхәскә дә кереп китә, аның карашларын кире кага. Әйтик, Ибраһимов шагыйрьне акыл, фәлсәфә сатуда, үгет-нәсыйхәт укуда, шигырьләрендә мөгаллимлек итүдә гаепләсә, ә Баттал, киресенчә, «Тукаев, шагыйрь булганлыктан, милләт вә миллилек хакында мөхакәмәләр йөртми вә фәлсәфә сатмый: Милләтне сөяргә кирәк, ул бик газиз нәрсә!—дип вәгазь, нәсыйхәт сөйләми, бәлки ул халыкның әкият вә әфсанәләреннән (фантастик хикәяләреннән) алып, халыкның үз теле белән шигырьләр яза» рәвешендә аларны кире кага. Аннан соң галим Тукай иҗатының замандашлары тарафыннан аз игътибар ителгән тагын бер сыйфатын—дини мотивлар, Коръәннән килә торган бәйләнешләр, гомумкешелек кыйммәтләрне барлый. Г. Баттал шагыйрьнең вакытсыз үлемен милли фаҗига итеп бәяли һәм аның хәлен кайгырту, сәламәтлеген ныгыту юлында милләтнең файдалы гамәл кылмавы өчен тирән ачынуын белдерә: «Әмма милләт аңа ярдәм итү, аның сәламәтлеген кайгырту вә тормышының бераз төзәтү өчен җүнләп кыймылдамады вә бу хосусны күп кайгыртмады. Дөрест, бәгъзе берәүләрнең кымызга чакырулары вә кунак итүләре кебек эшләр булды. Ләкин болар бик аз иде. Ниһаять, үземезнең гамьсезлегемез үз башымызга төште. Зур талант вә олуг шагыйрьләремездән мәңгегә җода булдык». Күренә ки, мәкалә авторы халыкка хезмәт итүнең олы үрнәген күрсәткән Тукайның вакытсыз арабыздан китүен татар халкының киләчәк яшәеше, әдәби-мәдәни тәрәккыяте мәсьәләсе белән бәйләп карый.

Мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслек буларак әзерләнгән «Нәзарияте әдәбия» (Казан, 1913) дигән китабында автор, лирика, аның асыл хасиятләре, жанрлары, бу төргә кагылышлы нәзари төшенчәләр турында сүз йөрткәндә, Тукай шигъриятенә еш мөрәҗәгать итә, аннан уңышлы мисаллар белән үз карашын дәлилли, китабының милли характерын тирәнәйтә.




Мәгълүм булганча, 1921 елдан Г. Батталның гомер юлында һәм иҗатында мөһаҗирлек чоры башлана. Аның татар халкы тарихын, иҗтимагый, фәлсәфи, әдәби, эстетик фикер үсешен яктырткан «Казан төркиләре» исемле китабы беренче тапкыр 1925 елда басылып чыга. Ул укучылар арасында тиз арада киң яңгыраш таба, зур кызыксыну уята, шул сәбәпле зыялылар, бер төркем яшьләр соравы буенча гарәп язуыннан латин графикасына нигезләнгән төрек алфавитына күчерелеп, аерым мәсьәләләр, карашлар янартылып, тулыландырылып икенче басмасы әзерләнә. Монда автор татар әдәбияты тарихын яктыртуга да урын бирә. Галим татар әдәбиятының XIX гасырның урталарына кадәрге, ягъни янарыш хәрәкәте башланган вакытка чаклы дәверен санаулы әсәрләр белән чикләсә дә, аның XX йөз башындагы үсешен, торышын,

әдипләр иҗатын шактый тулы күзаллый. Татар поэзиясен нәзари өйрәнүләргә багышланган сәхифәләре Г. Тукай тормышын һәм иҗатын яктырту белән ачыла. Шушы унайдан галимнең шагыйрь поэзиясен өйрәнүе фәнни яктан тирәнәя, ул Тукайның әдәби мирасын шагыйрьнең шәхси тормышы, ул яшәгән чорның иҗтимагый-сәяси чынбарлыгы, милли, мәдәни, әдәби хәяты белән тыгыз бәйләнештә карый.

Тукай әсәрләрендәге төп аһәңнәргә таянып, Баттал жиде тематик төркемне, әйдәп баручы жиде мотивны аерып чыгара: искелекне, артталыкны тәнкыйтьләү; татар тормышындагы наданлыктан, яшәешнең искергән гореф-гадәтләреннән, милли чынбарлыкның үсешен, янарышын тоткарлаган көчләрдән ачы көлү; иҗтимагый һәм милли тема; халык мифологиясе, дастаннарга нигезләнеп язылган шигъри әсәрләр; балалар һәм мәктәпләр өчен язылган оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр; мәхәббәт, рухи борчуларны һәм фани дөньядан бизгәнлекне чагылдырган лирик шигырьләре, ягъни күңел лирикасы. Аның сатирасы югары бәяләнә, хәтта Баттал тарафыннан мондый рухлы әсәрләрдә көлү объектының үзгәрүе, сатирик алымнарның төрлелеге сиземләнә. Мәсәлән, беренче чор әсәрләрендә шагыйрьнең «надан муллалардан, сорыкорт шәехләрдән көлүе, иске хорафатларны тәнкыйтьләве» билгеләнсә, ә «1908 елдан башлап һәм аннан соң язылган шигырьләрендә ялган миллиятчеләргә, байлыкка сатылган яшьләргә каршы рәхимсез көрәш ачуы» күрсәтелә. Хезмәт авторы шагыйрь әсәрләренең идея-эчтәлегенә күзәтү ясаганнан соң, ана югары бәя биреп, үзенең нәзари карашларын «Астыртын көлү үзенчәлеге белән бергә, зәгыйфь гәүдәсе тирәнлекләрендә изге уйлар һәм бөек кешелек максатлары йөрткән хисле һәм ватанпәрвәр бер төрки шагыйрь иде» (6, 122) рәвешендә тәгълли.

Г. Батталның өйрәнүләрендә бүгенге көн иҗтимагый фикере өчен тагын бер кызыклы факт бар. Совет чорында Тукай иҗатын чор идеологиясенә яраклаштыру максатыннан әдәбиятчы галимнәр, иҗтимагый фикер иясе аның дөньяга карашларын төрлечә калыплаштырырга омтылганда, Баттал егерменче елларның беренче яртысында ук аек акыл белән һәм бер дә икеләнмичә, «Тукай миллиятче булу белән бергә социалистлыкка тартым бер халыкчы—демократ та иде» дигән фикергә килә.

Батталның гыйльми-нәзари эзләнүләрендә игътибарга лаек юнәлешләрнең тагын берсе—тукайчы галимнәрнең эшчәнлекләрен өйрәнү һәм бәяләү. Аларга таянып, автор шагыйрьнең «Идел буе төркиләре арасында гына шөһрәт казанып калмыйча, Кырым, Кавказ, Төркестанда һәм хәтта Төркиядә дә танылуын» (5, 120 б.) әйтә. Үз карашын «Түрк йурду» журналының 1929 ел 16 май санында әдәбият укытучысы Фуад Көпрүлүнең язмасы, «Шималь төркиләренең шагыйре Габдулла рухына багышлау» басылу, Ногман Байбуринең Тукайга багышланган шигыре чыгу белән дәлилли. Мөһаҗирлектә булуына карамастан, ул совет чорында әдәбият фәненең торышын, үсешен, Тукай турындагы гыйлемнең хәлен шартлар мөмкинлек биргән кадәр күзәтеп барган.

Билгеле булганча, Октябрь борылышларыннан соң Тукайны өйрәнү фәнендә икенче чор башлана. Аның төп билгеләре булып: шагыйрь иҗатыннан, хакимлек иткән марксизм-ленинизм идеологиясе таләбенә нигезләнеп, яна эчтәлек, яңа мәгънә эзләү, аны «кызыллаштыру», пролетариат үзгәртеп коруларына яраклаштыру торса да, Тукай иҗатын өйрәнү бер урында гына калмый. Егерменче елларда Ф. Бурнаш, Тукай шигырьләрен туплап, зур күләмле кереш мәкалә белән китап итеп чыгара. Бу юлда Г. Нигъмәти, Г. Сәгъдиләр дә актив эшли. Г. Баттал исә үз китабының беренче басмасын 1922-23 елларда Хельсинки шәһәрендә яшәгән көннәрендә андагы университет китапханәсендәге материалларга нигезләнеп яза һәм ул 1925 елда нәшер дә ителә. Аңлашыла булса кирәк, галим, китапның икенче басмасында, совет галимнәренең хезмәтләренә таянып, Тукайга багышланган өлешне киңәйткән, тулыландырган. Галим үзе чит илдә яшәсә дә, югарыда исемнәре яңгыраган әдипләр, тәнкыйтьчеләр хезмәтләренә объектив, фәнни якын килгән. Аларның аерым карашлары белән килешә, ә кайберләре белән әдәби бәхәскә дә керә. Г. Баттал, Ф. Көпрүлүнең «Аның (Тукайның) шигырьләрендә баштан ахырга кадәр көрәш, бәхәс, хәрәкәт һәм тормыш бар» дигән фикеренә кушылып, шагыйрьнең төп юлын түбәнлекләргә, хаксызлыкка каршы көрәштә билгели. Әмма ул шагыйрь поэзиясенә мөнәсәбәттә галимнең «көчле хисселектән

һәм иҗат фантазиясеннән мәхрүм Г. Тукайның шигырьләрендә темалар, һичшиксез, практик файдалы гына күз алдында тоталар. Күңелнең самими һәм бер сәбәпсез дулкынланулары, табигать гүзәллекләре аның әсәрләрендә һич тә урын таба алмаган» рәвешендәге бәясенә тискәре карашта тора. Көпрүлү шигырьне аңлау, аны эстетик кабул итү ягыннан Г. Ибраһимовка якын тора. Шуна күрә төрек галиме Тукай поэзиясенең төп сыйфатын бәяләүдә Г. Ибраһимов белән бер баскычка баса. Алга таба Г. Баттал, Ф. Бурнаш туплаган шигырьләр җыентыгының эчтәлеген, Г. Сәгъдинең 1926 елда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» китабында шагыйрьгә биргән бәясен терәк итеп алып, Ф. Көпрүлүнең карашларын кире кага. Егерменче елларның беренче яртысында матбугат битләрендә Тукайның Казандагы көнитешенә кагылышлы «Татар буржуазиясе белән тыныша алмаган кайберәүләр, үз эчләренә бикләнеп, өметсезлеккә төшteләр һәм эчүгә сабышалар. Тукайны да бу кайберәүләр рәтенә кертеп карарга мөмкин» формасында фикерләр күренә. Баттал Г. Нигъмәтинең 1925 елда Казанда нәшер ителгән «Әдәбият мәйданында» китабында урын алган бу факт белән килешә. Аннан соң кайбер язмаларда Тукайның шигъри таланты ачылып бетә алмау сәбәпләреннән берсе итеп шагыйрьнең табигатьтән бирелгән талантына, сәләтенә тиң белем ала алмавы күрсәтелә. Бу мәсьәләдә Г. Сәгъдинең «Башка шагыйрьләребез кебек Тукай да җаһиллегеннән һәм белемсезлектән күп зарар күргән» дигән карашы Батталда яклау таба.

1947 елда Г. Баттал-Таймас ялга чыга. Аның 1965 елны төрек мәдәниятен өйрәнү институты басмасы булган «Төрек мәдәнияте» журналының июль санында «Шагыйрь Габдулла Тукай» исемле мәкалә бастыруы мәгълүм.

Шулай итеп, Г. Баттал әдәби тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре, тарихы турында нигезле, дәлилле фикерләр белән күп мәртәбәләр чыгыш ясый. Бу иҗат төренең иҗтимагый вазыйфасы, бурычлары, принциплары, шартлары турында уйлана. Татар дөньясында тәнкыйтьнең хәле, бу өлкәдәге житешсезлекләрнең сәбәпләре турында фикер йөртә. Әдәби әсәрләргә, дини китапларга төпле, принципиаль, объектив бәя бирә. Әмма аның аерым тәнкыйть мәкаләләрендә теоретик, фәнни өлешләр әдәби материалдан аерылып китә, тәнкыйть мәкаләләре кайчак публицистика төсен ала, ул әдәби әсәрне «онытып», көнитеш проблемалар хакында сөйли башлый. Галимнең Г. Исхакый, Г. Тукай һ. б.лар турындагы гыйльми карашлары, эзләнүләре исә алар иҗатын һәм тормыш сукмагын тулырак яктыртуга булыша. Аерым алганда, Баттал-Таймас, үз язмаларында Тукайның тормыш юлындагы аерым фактларны ачыклап, аның фәнни биографиясен тудыруга үзеннән өлеш кертә. Шагыйрь иҗатын чорларга бүлү, аның тел-өслүб һәм фикри-мәгънәви яктан үзгәреше, идея-тематик байлыгы, әйдәп баручы мотивлар төрлелеге, юмор һәм сатира мәсьәләләре, аның шигърияten, тормыш баскычларын өйрәнүче галимнәрнең күзәтүләренә, хезмәтләренә бәя, мөнәсәбәт белдерү—болар барсы да галим һәм—тәнкыйтьче Г. Батталның Тукайга багышланган гыйльми тикшеренүләрендә төп юнәлеш булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Агиев Ф. Мосахәбә *// Шура.—1910.—№2.—40-42 б.*
2. Әмирхан Ф. Яңа китаплар. «Тәхрирел-мәрьат» һәм «Әльмиратель җәдидә» тәрҗемәләре*// Әсәрләр. Дүрт томда. 4-т. / Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар.—Казан, 1986.—98-100 б.*
3. Баттал Г. Тәнкыйть. Сүз башы *// Шура.—1909.—№12.—360-362 б.*
4. Баттал Г. Тәнкыйть тирәсендә *// Шура.—1909.—№1.—661-662 б.*
5. Баттал Г. Нәзарияте әдәбия.*—Казан, 1913.*
6. Баттал Г. Казан төркиләре.*—Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.*
7. Баттал Г. Габдулла Тукай *// Мирас.—1993.—N4. (Кояш.—1913.—17 апрель)*
8. Баттал Г. Тәнкыйть *// Шура.—1909.—N13.—393-396 б.*
9. Баттал Г. /Мөгаллим/ китабы вә өйләнү мәсьәләсе *// Вакыт.—1909.—N 487.—2 б.*

**Таһир ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*Казан дәүләт университеты доценты*

*Безнең календарь*

## Атылган йолдыз кебек...

Тәбриз Мөбарәков татар прозасында, яшендәй атылган йолдыз кебек, тиз арада якты эз калдырып киткән шәхес. Аның әдәбиятка килү юлы да үзенчә гыйбрәтле. 1932 елның февралендә Арча районының Мөрәле авылында дөньяга килгән Тәбризнең әтисен 1937 елны халык дошманы дип кулга алалар һәм атып үтерәләр. Әтисез калган Тәбризгә фәкать үз көче һәм тырышлыгы белән зур дөньяга юл ярырга туры килә. Ул бик яхшы билгеләренә Сеже урта мәктәбен тәмамлый. Соңрак, Казан университетының физмат факультетында укып, аның аспирантурасын тәмамлап, физика-математика фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ирешә. 1970 елларда ул Алабуга пединститутында эшли, ә гомеренең соңгы 25 елы Уфа авиация институты белән бәйләнгән. Т. Мөбарәков—машиналар төзү өлкәсендә физика-математика теорияләрен куллану буенча 20 дән артык фәнни хезмәт авторы. Аның кайбер гыйльми хезмәтләре чит ил галимнәре арасында да танылу таба.



*Сулдан уңга: Шәукәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Тәбриз Мөбарәков, Гариф Ахунов. 1996 ел*

Гаҗәп хәл: гомере буе югары уку йортларында рус телендә төгәл фәннәр укыткан галимнең күңелендә, ком-таш эчендәге алтын кисәге шикелле, саф туган телебез стихиясендә кристаллашкан олуг хәзинә—әдәби талант яткан. Шунсы кызганыч—бу хәзинә галим-әдип гомеренең соңгы елларында гына халыкка ачыла алды. Т. Мөбарәковнең укучылар күңеленә кереп калган төп әсәре—«Хәтер аланы» исемле повесть. Бу әсәр «Казан утлары»нда 1995 елның 4 санында басылып чыкты. Повестьның журнал вариантын (әсәр тулысынча әлегә китап булып чыкмаган) мәрхүм шагыйребез Рәшит Әхмәтҗанов әзерләгән иде. Тормыш чынлыгы ягыннан булсын, тел җәһәтеннән булсын, әсәр гаять үзенчәлекле, һәм ул хаклы рәвештә җәмәгатьчелек тарафыннан үзенә лаеклы бәһане алды да. Соңрак журналыбызда М. Мәһдиев турында истәлекләре дә басылды. Шул ук елларда аның «Кәшемир шәл», «Аю белән Аккош мәхәббәте», «Гөләби», «Космоста булмасак та» кебек матур-матур хикәяләре «Сөембикә» журналында, «Шәһри Казан» газетасы битләрендә дөнья күрде. Т. Мөбарәков әсәрләре гади укучыны гына түгел, танылган язучыларның һәм әдәбият белгечләренең дә игътибарын җәлеп итте. Ә. Еники, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, А. Хәлим, В. Ихсанова һ. б. аның иҗатына югары бәя бирделәр. Ул Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

Ни аяныч, Т. Мөбарәков үзенең зур иҗат планнарын тормышка ашыра алмыйча, 1996 елны вафат булды. Аңа быел 70 яшь тулган булыр иде.

# Uqucı süze
# Укучы сүзе

## Чын мәхәббәт бармы?

Безнең тормышта һәм әдәбиятта «Мәхәббәт бармы ул?» дигән сорау гел кабатланып, бәхәс кузгатып тора. Татар әдәбиятында мәхәббәт турында язылган әсәрләр шактый. Мәсәлән, Себердә, Тубыл шәһәрендә яшәүче өлкән әдип Якуб Зәнкиевнең «Өтелгән мәхәббәт»е «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Язучының тылсымлы каләме белән иҗат ителгән бу әсәрне укып бетергәч, ул хәтта кыска булып та тоелды. Мондый әсәрне бастырган «Казан утлары»ннан һич тә аерыласы килмичә җәфаландым.

Һәр язучының тормыш юлы, иҗади язмышы аның үзенә генә хас, беркемне дә кабатламый торган була. Берәүләрнең тормышы язгы ташкын кебек ашкынып, давыл кеби атлыгып, шаулап уза. Ә икенчеләрнең яшәве— салмак кына, уйчан гына үзенең тирән, киң колачлы суларын горур рәвештә тибрәтә-тибрәтә еракларга юл тотучы елгага охшаш. Андыйлар үз эшләрен тыйнак кына, артык тавыш, шау-шу чыгармыйча, җиренә житкереп башкаралар. Талантларын, көчләрен, хисләрен җәлләмичә халыкка тугры хезмәт итәләр. Якуб ага Зәнкиев тә шундыйларның берсе. Нечкә күңелле, тыйнак холыклы, нык рухлы, зур талантка ия булган шәхес ул.

«Иртеш таңнары» романы язылганнан соң, бу дөньяга артык исе китмичә генә, ял итәргә мөмкинлеге булса да, күңел түрендәге изге ниятләрен, җанын кытыклап торган дәртле әдипкә тынычлык бирми.

Кешеләр күңелендәге тутыкны кырып ташлыйсы килү нияте аны яңа романга, зур әдәбиятка китерде. Мәхәббәтнең зурлыгын-сафлыгын эзләп, тагын бер мәртәбә дөньяга сәфәр чыкты.

Яз башында уйнаган аҗаган яктысы кебек булды бу әсәр безнең рухи тормышыбызда. Өлкән яшенә дә карамастан, әдипнең җаны, сәламәт йөрәге тулы хыял, күңеле тулы өмет белән язылган бу роман.

«Өтелгән мәхәббәт» безнең тормыш, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында. Романдагы төп геройларның берсе буларак, Зиннур образында без яшәгән чордагы һәркем башыннан кичкән совет иле тегермәнендә иләнгән укытучы-мәктәп директорлары язмышы тасвирлана. Кайсы гына мәктәп директорына шул чорның мәрхәмәтсез утларында янып, болганчык суларын кичәргә туры килмәде икән?

Сугыш елларында һәм аннан соңгы елларда рәхимсез законнарның һәм түрәләрнең камчысын кемгә генә үз җилкәсендә татып карарга туры килмәде икән?

Ул заманнарда демократияле яки цивилизацияле сөйләм лексиконы кулланылмый иде. Түрә иң акыллы һәм белемле саналып, ул гына дөрес фикер йөртә ала, ә калганнар—буйсынган халык, кара сарык образын гына тудыручы булырга тиешләр иде. Власть кешесе һәм гади халык, бер-берсен күрә алмый, дошманлашып яшәделәр.

Яңа роман—безнең яшәеш чорын колачлаган әсәр. Татарның горур холкын, хезмәт сөючәнлеген, илгә бирелгәнлеген, милләтнең рухи байлыгын саклап калудагы иҗади хезмәтен, шул ук вакытта аянычлы яшәвен, драматик язмышын бу кадәр киң планда һәм психологик тирәнлектә айкап-сурәтләп, кем генә күрсәтә алды икән?

Зиннур гади персонаж гына түгел, ул үзәк каһарманга әверелгән. Алай гына да түгел, халыкның милли рухын үстерүче, аның ныклыгын, халыкчан характерын тасвирлаучы, хәтер символына кадәр үскән шәхес тә ул!

Рәхимсез тормыш сынауларын батырларча үтеп, язмыш бишегендә тирбәлә-тирбәлә Зиннур белән Нуриянең сөю белән сөелү дигән гүзәл хисне күңел

түрендәге иң изге, иң яшерен сер итеп саклый белүләре безгә үрнәк булырдай. Йөрәкнең саф ялкынында януны һәркем үзенчә бәхеткә саный. Андый нечкә хисләрне башкалар күзенә күрсәтергә оялясың, тартынасың, тупасланып, бөтен нәфислеген жуюдан куркасың. Язучы укучыны шуңа ышандыра. Күрәсең, әсәрнең эстетик кыйммәте дә әнә шул ышандыру көчендәдер.

Әсәр яна гына бөреләнеп килүче һәм чәчәк атучы мәхәббәтнең бары тик үбешү-сөешү уеннары гына түгеллеген искәртә. Язучы Зиннур белән Нуриянең, Мансур белән Туктабикәнең мәхәббәт мажараларын үрнәк итеп куя.

Мансур, сөю-сөелү ташкынына бирелеп, кочагына алган кызны үбә-үбә: «Туктабикә, әйдә бүген үк безгә кайтабыз. Синнән башка бер генә көн дә яшисем килми, кушылыйк»—ди. Кыз исә: «Бу бит ата-ананы санга санамау, безнең кушылу ата-анага да түгәрәк бәхет китерергә тиеш» дип егетне ышандыра, кызлардагы әхлакый тыйнаклыкны укучыга сеңдерә.

Түзгән—морадына ирешкән дигәндәй, тиздән егет ягыннан кыз өенә яучылар да килә, уртага салып сөйләшкәннән соң туй көне дә билгеләнеп куела.

Язучы әнә шул рәвешле тәрбия мәсьәләсен хәл итә. Никахлы мәхәббәтнең никадәрле зур көч булуын аңлатып кына калмый, ана мәдхия кылып, үзе дә чал башын ия. Хәзерге яшь буынга гыйбрәт булырдай житди тормыш сабаклары аз түгел романда.

Зиннур белән Нуриянең яшьлек мәхәббәте, нинди генә озын өермәле еллар сынавын үтәргә туры килсә дә, сүрелми, алар шул мәхәббәткә тугры калалар.

Яшьлек мәхәббәтенә багышланган, бу кадәрле кешелек хисенең күпләр күрә алмаган нечкәлекләренә кадәр үтеп кергән әсәрләр дөньяга сирәк чыга шул.

Романдагы драматик һәм фажигале вакыйгалар, беренче карауга, фәкать мәхәббәт мажараларыннан гына килеп туган кебек күренергә мөмкин. Ләкин алай түгел. Аларның күбесен язучы ижтимагый тормыш арасында тасвирлаган. Билгеле, тормыш үзенекен итә. Ватан сугышы елларында да авылда якага-яка килеп тартышкан мәкерле кешеләрнең явызлык алымнары чын мәхәббәтне жиңә алмый.

Чыннан да, әсәрнең исеме үк табышмактай серле, бәхәсле һәм төрлечә аңлатуларга урын калдыра. Аны тар кысаларга, әзер калыпларга сыйдыруы кыен. Һәрхәлдә бу әсәрдә ике дөнья, матурлык белән оятсызлык, хозурый иркәлек белән женси азгынлык кебек чагыштырулар янәшә йөриләр.

Нурлы йолдызлар белән бизәлгән күк астында берәүләр кәеф-саф кора, типтерә, күбәләк төсле, чәчәктән чәчкәгә очып йөрүе белән куана, акча колы Хәйрүш исә хур кызларын кочмак була, ә ярлы авыл халкы ачлыктан тилмерә.

Бу әсәрне мин әдәбиятыбызга халык сөйләм теленең моңарчы сирәк кулланылган гүзәл үрнәкләрен алып керүе белән дә куанычлы дияр идем.

Язучы бик кадерле әйтер сүзен, прозаның киң сулышлы иркен мәйданына чыгып, халыкның бай сөйләме белән авыз тутырып әйтергә ярата. Бу аның язу алымы. Жинел укылышлы, күңелне гел хисләндереп торучы, үзенчәлекле тел!

Көндәлек сөйләм күренешендә очраган себер татарлары теленең үзенчәлеген күрсәтеп яза ул. Шуның белән ул себер татар халкының үз әдәби теленең кирәклеме-түгелме икәнлегенә, шул бәхәскә нокта куя шикелле. Татар халкының гомум әдәби телен кайбер себер татарлары куллана торган сүзләрне кертеп, әдәби татар телен үстерү, баету өлкәсендә зур ачыш ясый. Нәтижәдә, яна үрнәкләр биреп, ике телнең бер-берсен баетуына, динамик үсә алуына юл ача.

Тапкыр мәкаль һәм әйтемнәр, кинаяләр, халыкча оста сүз уйнатулар, гади генә фикерне дә жыр сыман көйләп, матурлап-бизәп әйтүләр, иң нечкә тойгыларны нәкъ менә халыкча әйтеп бирә белүе белән укучыны үзенә әсир итә.

Әсәрне укыганда дөрләп кабынган яшьлек хисләрен үз итеп, авторның ак чәчле өлкән ага булуын да онытып жибәрәсең.

Романның үзәгендә язмыш, сынау һәм бу сынауны жиңү өчен мөһим булган ныклык темасы тора. Язучы бөтен ижаты белән тормышны, кешеләрне яратырга, яктылыкка омтылырга, зарланмый-сукранмый гына кыенлыкларны жиңә белергә өйрәтә. Минемчә, автор әсәр алдына куйган бурычын тулысы белән аклаган. Кеше бар. Заман бар. Язмыш бар. Миллэт бар һәм, әлбәттә, мәхәббәт бар!

Роман тарихи әсәр дә түгел шикелле, әмма анда милли рух, тарихи рух,

хәтер рухы бөркелеп тора. Әдип авыл йолаларын, авыл психологиясен яхшы белә (аулак өйләр, кызлар Убасындагы яшьләр уены), андагы кичерешләрне елатырлык дәрәҗәдә нечкә, халыкчан итеп күрсәтә алган.

Кулга-кул тотынып бергә яшәүче, гаилә коручы татар милләте язмышында матур үзгәрешләр, яңарышлар күренеп кенә тора. Бу әлбәттә, яшәешебезгә, теләк-омтылышыбызга турыдан-туры бәйле. Тормыш мәгънәсе бары тик ашауэчү, җан асрауга гына кайтып калырга тиеш түгеллеген һәркем сизәмләсен иде.

XXI гасырда милли рухы булган әдәбият кына, милли идеясе булган халык кына яши алачагына һәркем ышанырга тиештер.

Якуб ага Зәнкиевнең барлык әсәрләре шул юнәлештә язылганнар. Ул инде күптән милләтебезнең горурлыгына әйләнгән олы әдип!

**Хатип ХӘБИБУЛЛИН**,
*Түбән өлкәсе, Акъяр авылы*

## Bəxetsezlər bəxete nindi bula?

Kürenekle prozaik Foat Sadrievnıñ 1991 yılda uq təgəlləngən, ayırım өzeklәre monnan berniçə yıl elek «Arğamaq» jurnalında həm «Mədəni comğa» gazetında basılğan «Bəxetsezlər bəxete» romanı dөnya kürde. Anı «Qazan utları» jurnalı həm Tatarstan kitap nəşriatı bastırıp çığardı. Yaza başlağanda avtor romanğa «Partiəgə qəber taşı» digən bik usal isem birgən, ləkin qayber səbəplər arqasında bu isemne üzgərtergə kirək tapqan. Partiəgə qəber taşı quyarğa ədipne nərsə məcbür itkən soñ? Ni өçen roman ozaq yıllar dөnyağa çıqmıy yatqan? Bu sorawğa avtor minə niçek cawap birə:

«...KPSS tormışında urnaşqan tərtip—general' sekretar'dan alıp raykom sekretarena qədər tezelgən kul'tlarnıñ azınuı, alarnıñ hər süzen, nindi genə axmaq həm kəlke buluına qaramastan, barlıq xalıqnıñ tənqitsez qabul itərgə həm bersüzsez ütərgə tieş buluı aqılğa sıymaslıq xəl ide. Şuşı ğədelsezlekkə niçə yıllar buyı bəğerlər telgələnde. Başqa partiələr yuq, oppozitsiə yuq, tənqit yuq. Bөten il başın igən həm buysınğan xəldə. Şuşı şartta teləsə nindi yullar belən partiənen citəkçe organnarına ürmələwçelər artqannan arta bardı. Bezdə raykomnıñ ber sekretare turında mondıy süz yөri ide: «Fələn Fələneçkə ətien belən əniennen başın kisep alıp kil, sine raykomnıñ berençe sekretare itəbez, disəñ, şunduq ikesenen də başın qapçıqqa salıp alıp kiləçək». Partiə citəkçelərе zakonnan өsten toralar, üzlərenə qarşı yalğışıp ber süz əytkən yəisə alar өnəməgən eş eşləgən teləsə kemne teləsə ni eşlətə alalar ide. Şundıy şartlarda bu roman çığaçaq ideme soñ? Yuqtır».

«Partiəgə diü bik ük dөres tə bulmas, çөnki ğadi kommunistlarnıñ ni ğəyebe bar? Xikmət anıñ barlıq izge niətləren yuq itüçe eş alımnarında, eçke tormışında, egoistik maqsatlarınnan yuğarı kütərelə almağan citəkçelərendə bit», — di tağın ber urında ədip.

Awıl həm partiə tormışın əybət belü (Foat Sadriev ğomere buyı awılda yəşəp icat itə), səngət həm ədəbiat məs'ələlərenə citdi mөnəsəbət ədipkə partiə citəkçelegenen asılın, anıñ yəşeren intrigaların, ikeyөzlelegen, quştanlığın, yalağaylığın, vlast'qa omtıluın həm qurqıtuğa qorılğan buluın KPSS raykomınıñ berençe sekretare Mirzahit Arslanov, ikençe sekretare Zəfər Şəwəliev obrazları aşa bөten tulılığı belən səngətçə yuğarılıqta sürətləw mөmkinlege birgən. Əsərdə partiənen eçke tormışındağı bozıqlıqnı şaqtıy qalqu itep kürsətə alğan avtor.

Yazmış tarafınnan waqiğalar өyerməsenə ırğıtılğan İrek Sabitovqa şuşı ikeyөzlelekkə, keşe qurqıtuğa nigezləngən citəkçelek alımnarına, andağı yalğanğa qarşı kөrəş alıp barırğa turı kilə. Awılnıñ in unğan qızlarınnan berse, şəfqət tutaşı Zənfirənen məxəbbəten yawlağan awıl yegete raykomda üzenə tapşırılğan

eşlərne namus belən ütərgə tırışa. Ləkin üz fikere bulğan prinsipial' yegetkə ələkləşü həm yalğanğa qorılğan raykom eşe oşamıy. Anı məcbüriləp rayon gazetının baş redaktorı itep küçerələr. Monda da ul Arslanovnın, üz süzen süz itü øçen keşegə teləsə nindi pıçraq atarga sələtle Şəwəlievlərnen yomışçısı bulıp yərergə tieş bula. İreknen şəxsi tormışı cimerelə. Yaratqan qızı Zənfirə üzennən 15 yəşkə zurraq məktəp direktorı Zahit Fəxrullinğa kiəwgə çığa. Ə İrek üze Arslanov həm Şəwəlievnen urtaq səyərkəse Səyembikəgə eylənə. Ul Məskəwgə yuğarı teatral' kurslarğa uqırğa kitərgə cıyına, ə raykom cibərmi. Ləkin partiə uçyotınnan da təşmiçə Məskəwgə uqırğa kitep bara həm anda awır xəllərgə yulığa. Anı partiə uçyotınnan təşmiçə kilgən eçen uqudan çığaralar, tulay toraqtan qualar. Axır çiktə, cinayətçel şaykağa eləgep İrek yaralana, Qazanğa qaytıp kitərgə məcbür bula.

Əsərne uqığaç, Çıngız Aytmatovnın ber publisistik məqələsendəge anekdot iskə təşte. Ç. Aytmatov awıllarına ətisenen apasın kümərgə qayta, çəy yanında cıyılğan qartlardan berse əlege anekdotnı səyli: «Stalin üzenen yaqın kərəştəşləren cıyğan da bolay digən: «Patşa Alla tügel, Alladan kim də tügel. Xalıq mine tere Alla itep kürsen, minem küzləremə genə qarap torsın eçen alar belən niçek idarə itərgə? Sez şul turıda baş watasız inde. Xəzer min sezgə xalıq belən niçek eş itərgə kiräklegen əyrətəm». Həm ul tere tawıq alıp kilergə quşa. Alarnın küz aldında ul aqırtıp tere tawıqnın songı qawrıyına qədər yolqıp beterə, kikrigen genə qaldıra. «Ə xəzer qarağız», — di ul həm tawıqnı irekkə cibərə. Tawıqqa küzləre qaya qarıy, şunda ğına ıçqınası da bit, ləkin ul berqaya da kitmi — qoyaşta tüzə almaslıq qızu, ə küləgədə salqın. Həm ul, mesken, Stalinnın itek qunıçına yılışa, yulbaşçı ana ber çemetem aşlıq bərtege sibə, həm tawıq anın artınnan kitə. Stalin qaya barsa — tawıq şunda. Başqaça bula da almıy, ul açqa üləçək. «Menə xalıq belən niçek idarə itərgə kirək», — dip süzen təgəlli yulbaşçı. Uylandıra torğan anekdot bu. Məstəqillegebez ayaq astına salıp taptalsa, beznen xəl yolqınğan tawıqnıqınnan nərsə belən ayırılır ikən? — digən urınlı soraw da tua.

Əye, partiə citəkçelege, ayıruça Stalinnın şəxes kul'tı turında anekdotlar, tənqit materialları küp buldı, ləkin partiənen eçke tormışındağı çerep tarqalu bilgeləren əle F. Sadrievqa qədər şulay tirənten eyrənep, materialnı üzen kiçerep, yərəktən ütkərep faş itü, bolay qalqu itep kürsətə alu, minemçə, bulmadı. Əlbəttə, mondıy qatlawlı eşne başqaru eçen F. Sadriev kebek talant iəse bulu kirəkter.

Romannın uquçığa berençe qaraşta sizelmi torğan eçke ritmı bar. Ul muzıkal' əsər kebek: xislər, kiçereşlər ezleksez xərəkəttə. Xarakterlar yasalma rəweştə sotsial' tirəlektən ayırılmağan, hər obraz üz çorı atmosferası belən suğarılğan. Romannın kompozitsiəse də avtor üze kürgən sotsial' konfliktlar nigezendə nıq uylap tezelgən. Tormışta həm icatta yalğan, yasalmalılıqnı kürə almawçı ədip əsərlərendə də üze təgəl belgənnərne yəki ışanıçlı yaqınnarınnan işetkənnərne genə surətlərgə omtıla.

Səngətçə dereslekne surətləwnen ike yulı bar: berençese — xıyaldağı obrazda küp sanlı faktlarnı ğomumiləşterü, ikençese — surətləw eçen tipik məğnələrne eçenə alğan real' faktlarnı saylaw. Tipiklaştırunın bu ısulları ədəbiat tarixında kin yaqtırtılğan, alar ikese də üzləren aqlağan alımnar. F. Sadriev eçen ikençe ısul yaqınraq. Şuna kürə anın əsərlərе dokumental'lekkə yaqın. Monın şulay ikənlegen «Şahzamanovlar eşe», «Tan cile», «Qondırlı qodaçası», «Bəxetsezlər bəxete» h. b. əsərlərendə kürergə məmkin.

Dereslekne tabarğa omtıluda üzenen qurqusız bulıı belən ayırılıp torğan İ. Sabitov obrazında, bəxəssez, avtobiografik detal'lər də küp. Ul eçkersez ğadilege, saf künellelege, tıynaqlığı həm ğədellege belən avtornı xəterlətə. Ləkin ədip üze: «Əsərdəge personajlar qayber biografik momentları belən bügenge tormışta yəşəwçe keşelərne, bigrək tə üzemne xəterlətsələr də, alarnın xıyalımda tudırılğan ədəbi obraz ikənlegen onıtmasağız ide», — di. Avtor əytkənçə, romannın yazuçı xıyalında tudırılğan bulıı şiksez, ləkin ul, minemçə, avtobiografiəgə nigezləngən, dokumental' cirlekkə qorılğan əsər. Həm, ni genə bulmasın, bu roman — çın ədəbi əsər.

F. Sadriev telgə qarata ütə iğtibarlı. Yalğan həm ikeyөzlelekne surətləgəndə anıŋ təp qoralı—çitlətep əytügə qorılğan çəneçkele kəlü. Ul telebezneŋ məgnə təsmerlərenen bəten neçkəleklərən toyıp eş itə. Uquçını əyteləse fikergə yalıqtırıp, əyləngeç yullar aşa alıp kilergə yaratmıy, ə açıq itep yarıp sala. Menə misallar: «Kiləçək ul—bügen ikən həm ul kən sayın waqlap-waqlap uzğan da kitkən. Anı eləkterep qalmasaŋ, waqıt işegeneŋ tege yağına «kelt» itep kenə çığa da ütkəngə əwerelə ikən...» «Keşegə yərdəm kirək. Anıŋ bit canın yaralğannan birle butağannar. Bətenese keşedən sorıy, taləp itə, nindider qısalarğa quıp kertep, yaxşı sıyfatlarnı ğına qaldırmaqçı, kamilləştermәkçe bulalar. Ə qayan kilgən aŋa əşəke sıyfatlar? Barı ber nərsə—əyber arqasında. Keşene yaralğannan birle, əyber belən aldap, həlakətkə səyrəp kertü dəwam itə. Nindi faciğə!»

Roman F. Sadrievqa xas ədəbi zəweq həm matur tel belən yazılğan, şuŋa kürə ul Məxəmmət Məhdiev, Əmirxan Yeniki əsərlәre kebek ciŋel uqıla.

Miŋa ədip yəşəgən Məslim rayonında turıdan-turı partiəneŋ rayon komitetı belən tığız bəyləneş taləp itə torğan eşlərdə: partkom sekretare, kolxoz rəise, məktəp direktorı, rayon məğərif bülege mөdire bulıp eşlərgə turı kilde. Bez F. Sadriev belən partiə qazanında bergə qaynağan keşelər. Menə şuŋa kürə əsərdəge waqiğalar, yazmışlar, keşelek kiçereşlәre minem өçen ayıruça yaqın. Romannı uqığaç, min yaŋadan üzemneŋ yəşlek yıllarıma, onıtılmas xatirələrgə bay ütkənnəremə kire qaytqanday buldım. Romanda personajlarnıŋ isemnəre üzgərtelgən üzgərtelüen, ləkin min alarnıŋ barısın da diərlek açıq küz aldıma kiterdem. Şuŋa kürə avtorğa, anıŋ barlıq personajlarına yəşlegemə həm borçulı ütkənnəremə səyəxət yasarğa mөmkinlek birgənnəre өçen də rəxmətlemen.

Əmma bu romanda uquçını ışandırıp betermi torğan urınnar da bar, minemçə. Tərbiəle, çibər awıl qızı Zənfirə, yuq qına səbəplər arqasında təzətə almaslıq yalğış adım yasıy: yaratqan yegete İrekne qaldırıp, üzennən 15 yəşkə zurraq məktəp direktorı Zahit Fəxrullinğa kiəwgə çığa. Bu bik ük ışandırmıy: awılda yəşəp əybət tərbiə alğan qıznıŋ üzen uqıtqan, olı yəştəge məktəp direktorına kiəwgə çığuı—awıl өçen səyerrək nərsə.

Raykom sekretare Arslanovnıŋ Səyembikəne өyenə çaqırıp qunıp yatuı, şul çağında ulı Raşatnıŋ qaytıp kerüe də yasalmaraq kilep çıqqan. Raykom sekretare qədər raykom sekretarena qızlarnı өyenə alıp qaytmasa, bütən urın betkənmeni?

Ləkin bolar ğına əsərgə küləgə təşerə almıy, çөnki, berençedən, qayberəwlər minem fiker belən bөtenləy kileşməskə mөmkin, ikençedən, bolar əsər өçen bik ük zur əhəmiətkə iə detal'lər tügel.

Roman əle təgəllənməgən, şulay da tormışnı, çınbarlıqnı dөres, niçek bar şulay surətləwe belən, dokumental' cirlekkə qorıluı, zaman ruxın çağıldıruı belən ul uquçı küŋelen tirən dulqınlandıra.

Romannı tulısınça yazıp beterü həm bezgə ireşterü өçen F. Sadrievqa sələmətlek həm uŋışlar telik.

**Zəynəğetdin VƏLİEV,**
*Tatarstannıŋ atqazangan uqıtuçısı.*
*Qazan.*

# РӘХМӘТ СҮЗЕ

Чебешне көз көне саныйлар, дибез.

Матбугат чаралары үзенең укучыларын елга ике тапкыр саный. 2002 елның беренче яртысына—«Казан утлары»ның 80 еллыгына, без 9 меңгә якын әбүнәче белән кердек. Азмы, күпме бу? Бөтен Русиядә яшәүче татарлар санына бүлгәндә, әлбәттә, күп түгел. Ләкин, бүгенге болгавыр заманда, рухи кыйммәтләрнең кыйбласы үзгәргән чорда, матур әдәбиятның яңа үрнәкләрен көтеп алган; әдәби тарих белән кызыксынган; шигырь, хикәя, романнар яратып укыр дәрәҗәдә зәвыклы, зыялы тугыз мең әбүнәчебез бар икән—димәк, киләчәгебез өметле дигән сүз. «Казан утлары» журналы рухи һәм эстетик тәрбия бирүдә, халыкның милли аңын үстерүдә мөһим роль уйный торган иң олы матбага...

Бүгенге татар әдәбиятын пропагандалау, гомумән, эстетик тәрбия эше кайсы районда ничегрәк куелган соң? Менә әбүнәчеләр саны ныклы дәлил. Безнең мәгълүматларга карасак, әдәбият сөючеләрнең иң күбесе Балтач белән Сабада яши. «Казан утлары»на язылуда алардан кала Мамадыш белән Балык Бистәсенә рәхмәтлебез. Монарчы әбүнәчеләр саны белән мактана алмаган Питрәч, Әгерже, Буа районнарында әдәби атмосфераның бераз жылынуы сизелә. Гомер буе мактаулылар сафында килгән Азнакай, Арча, Актаныш, Кукмара, Минзәлә, Мөслим һәм Сарман кебек исемнәре җырлап торган районнарда журналыбызга игътибар кимүне без гайре табигый хәл дип исәплибез. Ә инде Апас, Кайбыч, Яшел Үзән, Баулы һәм Спас районнарында «Казан утлары» журналына язылучылар санын әйтеп үтсәк—югарыда телгә алынган төбәкләрнең әтәчләре шаркылдап көләр иде...

«Казан утлары»на язылуны вакытында һәм нәтиҗәле итеп оештырганнары өчен каләмдәшләребез **Гарифҗан Мөхәммәтшин** ***(Балтач)***, **Тәлгат Нәҗмиев** ***(Саба)*** һәм **Вәзыйх Фатыйховка** ***(Балык Бистәсе)*** журналыбызның барлык хезмәткәрләре, редколлегия әгъзалары исеменнән чын күңелдән рәхмәтебезне җиткерәбез.

Беренче ярты еллыкны санау тәмам.

Икенче ярты еллыкка язылу дәвам итә.

ЖУРНАЛНЫ ТАРАТУ ҺӘМ ПРОПАГАНДАЛАУ БҮЛЕГЕ

---

## Авторлар игътибарына

Кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. Телефоныгыз *(шәһәр кодын да күрсәтеп)*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ИСЛАМ СӘНГАТЕ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

9 гыйнварда Татарстан Республикасының Милли мәдәни үзәгендә «Ислам сәнгате» күргәзмәсе ачылды. Аны Россиянең «Эрмитаж» Дәүләт музее һәм Татарстан Милли музее бергәләп оештырдылар.

Эрмитаж фондларыннан алынып күргәзмәгә куелган 140тан артык экспонат— борынгы һәм хәзерге заман Ислам сәнгатенең истәлекләре.

Күргәзмәне ачу тантанасында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Эрмитаж музее директоры Михаил Пиотровский, Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов, Казан мэры Камил Исхаков, Россиянең төрле регионнарыннан килгән музей директорлары һ. б. катнашты.

«Кубрат хан хәзинәсе» һәм «Алтын Урда хәзинәләре» күргәзмәләреннән соң «Ислам сәнгате» Санкт-Петербургтан килгән өченче күргәзмә булды. М. Пиотровский аны «Россия күләмендәге мәдәни вакыйга» дип атады. Ул, шулай ук, Эрмитаж белән Татарстан арасындагы хезмәттәшлекнең М. Шәймиевнең Санкт-Петербургка барып, Эрмитажны зиярәт кылуыннан соң башлануын билгеләп үтте. Пиотровский раславынча, Казанда бик кыйммәтле экспонатларны Лондон, Париж һәм Амстердам дәрәҗәсендә кабул итә һәм саклый беләләр.

Президент Минтимер Шәймиев Михаил Пиотровскийны Казан Кремлендә кабул итте. Очрашуда Дәүләт Эрмитажы белән җөмһүриятебез музейлары арасындагы хезмәттәшлек юнәлешләре буенча фикер алышулар булды.

Бу сөйләшүләр вакытында Казанда Эрмитаж үзәге булдыру мәсьәләсе дә күтәрелде. Бу идеяне тормышка ашыру ниятеннән 10 гыйнварда ТР милли музеенда Дәүләт Эрмитажы, ТР мәдәният министрлыгы, Казан шәһәре хакимияте һәм ТР Фәннәр академиясенең тарих институты арасында «Казанда Эрмитаж үзәге» дигән фәнни, мәдәни-агарту һәм мәгариф программасын әзерләү, аны тормышка ашыру шартлары турында ниятләүләр беркетмәсенә кул куелды.

### ҖУРНАЛИСТЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан журналистлары Россия матбугаты көнен билгеләп үтте.

Бу уңайдан Журналистлар йортында кабул итү мәҗлесе оештырылды. Анда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министрның беренче урынбасары Равил Моратов һәм башка кунаклар катнашты. Журналистлар берлеге президиумы исеменнән аның рәисе Римма Ратникова кунакларны һәм каләмдәшләрен сәламләп: «Фикерләр һәм милек формаларының төрле булуына да карамастан, берлек таркалмады, ул—берләшә, бәйрәмнәрне дә бергә үткәрә»,—дип билгеләп үтте.

Ф. Мөхәммәтшин Президентыбыз һәм парламент исеменнән журналистларны бәйрәм белән котлады. Матбугат көне уңаеннан үтүче тантаналар матур гадәткә әверелүен искәртте. «Матбугат битләрендә, телеэкраннарда төрле фикер булырга тиеш, бу хакимияткә дә дөрес карарлар кабул итәргә ярдәм итә. Журналистлар көндәшлек нәтиҗәләрен дә сизде кебек: матбугатка язылу кампаниясе йомгакларына караганда, тиражларның кимүе, ә федераль басмаларның 12 процентка күтәрелүе сизелә»,—диде ул һәм татар матбугатының 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек эшен башларга, аны Казанның 1000 еллыгына туры китерергә тәкъдим итте.

### КИНОЕЛЪЯЗМАЧЫЛАР ЮБИЛЕЕ

Казан кинохроника студиясе үзенең 40 еллык юбилеен билгеләп үтте. Студиянең тарихы 1961 елдан башлана. Бүген ул Россиянең иң көчле документаль киностудияләренең берсе. Соңгы ике елда гына да аның эшләре төрле фестивальләрдә күрсәтелде, диплом һәм бүләкләргә лаек булды.

Студияне Россиянең кинематографистлар берлеге рәисе урынбасары Клим Лаврентьев, Россия Мәдәният министрлыгының кинематография үсеше департаменты җитәкчесе урынбасары Юрий Дорожкин, Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов, аның урынбасары Зөфәр Бохараев, Казан хакимиятенең мәдәният идарәсе җитәкчесе Әлфия Тутаева, шулай ук Татарстан Министрлар Кабинеты вәкилләре, Россиянең документаль киностудияләре директорлары, республиканың иҗади берлекләре вәкилләре котлады.

### ПЕН-ҮЗӘК ТӘКЪДИМЕ

Татар ПЕН-үзәге делегаты, Үзәкнең Мәскәүдәге даими вәкиле, танылган юрист һәм гаммәви мәгълүмат чаралары мәсьәләләре буенча белгеч Борис Пантелеев Лондоннан Бөтендөнья язучыларының чираттагы конгрессыннан кайтты. Ул конг-

ресста Казанда «Халык хокуклары һәм сәяси әдәплелек» дигән темага халыкара конференция уткәрү идеясен тәкъдим итте.

Билгеле булганча, Татар ПЕН-үзәге инглиз телендә нәшер итәр өчен китап әзерләде. Бөтендөнья язучылар конгрессы делегатлары аның проекты белән дә таныштылар. Китап авторларының—ягъни, татар язучыларының позициясен һәм «Халык хокуклары һәм сәяси әдәплелек» мәсьәләсен Казандагы конференциядә тикшерү идеясен ЮНЕСКО вәкиле булган Финляндия, Норвегия, Квебек ПЕН-үзәкләре делегатлары да хуплады.

Конгресста Б. Пантелеев шулай ук татар язуын латин графикасына күчерү мәсьәләсен дә күтәрде. Бу мәсьәлә киләсе елда Македониядә үтәчәк Бөтендөнья язучылар конгрессының көн тәртибенә кертеләчәк.

### «ХӘТЕР»НЕҢ ЯҢА ТОМЫ

«Сәяси репрессия корбаннары Хәтер китабы»ның дүртенче томы дөнья күрде.

Анда 58 нче сәяси маддә белән кулга алынган, Татарстанда туган яисә яшәгән, соңыннан тоткынлыкта үлгән «Г» һәм «Д» хәрефләренә башланган 3385 фамилия бар. Аларның 360ы атылган, 745 кеше тоткынлыкта үлгән. Мең ярым тираж белән чыккан китап сәяси репрессия корбаннарының гаиләләренә, музейларга, иҗтимагый оешмаларга, уку йортларына бушлай таратылачак. Андагы мәгълүматлар бөтендөнья интернет челтәрендәге «Мемориал» Халыкара хәйрия җәмгыятенең махсус битенә дә кертелде.

### ТУКАЙ ЗАМАНДАШЫ

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә атаклы татар галиме һәм иҗтимагый-сәяси эшлеклесе **Йосыф Акчураның 125 еллыгы** уңаеннан «Йосыф Акчура һәм Россия империясе татарлары (XIX гасыр ахыры—XX гасыр башы)» дигән фәнни конференция узды.

Й. Акчура «Иттифак әл-мөслимин» фиркасен оештыручы һәм аның әйдәп баручыларыннан берсе санала. Конференцияне татар һәм башка Идел буе халыклары тарихын, мәдәниятен тирәнтен өйрәнү белән шөгыльләнүче студентларның «Эзләнү» фәнни-тикшерену түркеме оештырды.

### КЛАССИК ӘДИПКӘ БАГЫШЛАП

11 декабрьдә Казан дәүләт университетының гыйльми китапханәсендә СССРның дәүләт премиясе лауреаты **Кави Нәҗминең тууына 100 ел** тулуга багышланган фәнни конференция үткәрелде. Конференциядә галимнәр Х. Миңнегулов, И. Бәширова, Р. Рахман, Р. Сверигин, «Татарстан» журналының баш мөхәррире Р. Фәттахов, әдипнең улы Таңсык Нәҗметдинов К. Нәҗми хакында тәфсилле һәм уйландыра торган чыгышлар ясадылар.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин әдипнең иҗаты турында сөйләде, аның татар әдәбиятында тоткан урынын билгеләп: «Заманында 26 телдә дөнья күргән, Сталин бүләгенә лаек булган «Язгы җилләр» романы әле бүген дә үзенең кыйммәтен югалтмады»,—диде.

Шул ук көнне кичен К. Тинчурин театрында классик язучы иҗатына багышланган «Якты сукмак» дигән әдәби-музыкаль кичә дә булды. Кичә К. Нәҗминең бөтен тормышын күз алдына китереп бастырды. А. Арсланов язучының әсәреннән өзек укыды. Д. Нурлы белән И. Баһман репрессия елларында С. Әдһәмова белән К. Нәҗми арасында йөргән хатларны «терелттеләр». К. Хәйретдинова, М. Галиев, Казандагы 106 нчы мәктәп укучылары башкаруында язучы шигырьләренә язылган җырлар яңгырады. Г. Камал театры артистлары «Язгы җилләр»дән аерым өзекләр күрсәтте.

### ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ИСКӘ АЛУ

Шагыйрь **Сибгат Хәкимнең тууына 90 ел** тулу уңаеннан аны искә алу кичәләренен берсе 21 декабрьдә башкалабызның Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында булып узды. Анда шагыйрьнең иҗаты турындагы кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин чыгыш ясады.

Кичәдә күренекле сүз осталары һәм артистлар Айрат Арсланов, Илдус Әхмәтҗан, Хәлим Җәләлов, Фәнис Җиһанша һ. б. шагыйрьнең шигырьләрен сөйләделәр, ә җыр-чыларыбыз Айдар Фәйзрахманов, Рафаэль Сәхәбиев, Резеда Галимова һ. б. Сибгат Хәким шигырьләренә язган җырларны башкарды.

«Җыр язмышы» дигән бу кичәдә шагыйрьнең улы—сәясәтче, Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт киношчесе, ТФАнең Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов истәлекләр белән уртаклашты.

### ОНЫТЫЛМАС ДРАМАТУРГ

Декабрь башында Әгерже районының Кичкетаң авылының мәдәният сараенда күренекле драматург **Юныс Әминовның тууына 80 ел** тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Әдипне искә алу кичәсендә Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, драматург Туфан Миңнуллин, шагыйрь Ренат Харис, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, әдипнең тормыш иптәше Фәимә ханым һәм балалары, Әгерже район хакимияте башлыгы Рафис Сәетов, әгерҗеләрнең Казандагы якташлык җәмгыяте рәисе Раиф Гыйззәтуллин, Әлмәт драма театры вәкилләре һәм Чаллыдан килгән кунаклар бар иде.

### «АЛТМЫШЫНЧЫ»ЛАР АЛТМЫШТА

Камал театрында Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь **Гәрәй Рәхимнең 60 еллык юбилее**на багышланган иҗат кичәсе үтте. Шагыйрьне Татарстан Дәүләт Советы исеменнән (юбиляр үзе дә Дәүләт Советында өлкән референт булып эшли) рәис урынбасары Р. Миңнуллин тәбрикләде. Кичә барышында Г. Рәхимне каләмдәшләре—Т. Миңнуллин, И. Юзиев,

Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Ф. Галимуллин, Р. Гатауллиннар котлады, юбилярның шәхесе һәм иҗаты турында җылы сүзләр әйттеләр. Сәхнәдән Татарстанның күренекле җырчылары, нәфис сүз осталары башкаруында Г. Рәхимнең шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Юбилярны иҗат бәйрәме белән котларга туган ягы—Лениногорскидан һәм Башкортстаннан да кунаклар килгән иде.

## КОМПОЗИТОР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Россия һәм Татарстанның халык артисты, мәшһүр композитор **Фасил Әхмәт** истәлегенә ул яшәгән йорт диварына мемориаль такта кую тантанасы булып узды. Тантананы кереш сүз белән Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин ачып җибәрде. Соңыннан Фасил Әхмәтовның якын дусты, композитор Ринат Еникеев үзенең истәлекләре белән уртаклашты.

Мемориаль такта кую җыенында Фасил Әхмәтовның туганнары, дуслары, сәнгать әһелләре катнашты. Чыгыш ясаучылар композитор әсәрләрен яна җыентык итеп бастыру кирәклеге турында да әйттеләр.

## «АЛТЫНЧӘЧ»—АЛТЫН ФОНДТА

Нәҗип Җиһановның туган көне уңаеннан С. Сәйдәшев исемендәге зур концерт залында үткән концерт-кичә «Алтынчәч» операсының беренче куелышына 60 ел тулуга багышланды.

Кичәгә төрле елларда баш партияләрне башкарган опера сәхнәсе ветераннары—Татарстанның халык артистлары Усман Әлмиев, Галина Ластовка, Рөстәм Маликов, Россиянең һәм Татарстанның халык артистлары Мөнирә Булатова, Зилә Сөнгатуллина килгән иде. Алар үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. Кунаклар арасында музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина да бар иде. Ул күп еллар Н. Җиһанов белән Татарстан Композиторлар берлегендә эшләгән. Концертта баш партияләрне беренче башкаручы артистларның язмалары яңгырады.

## ШУРАДА ЯҢА ИДАРӘ

17 январьда Казан милли мәдәният үзәгендә Аксакаллар Шурасы корылтае узды. Утырышта 50 дән артык делегат катнашты. Корылтайның төп эш нәтиҗәсе—яна идарә сайлау булды. Идарәгә 9 кеше—Вахит Хаков, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Әхмәт Галиев, Рәмзи Ногмани, Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Илдус Садыйков, Фәрит Хәбибуллин, Гаел Мортазин һәм Евгений Бусыгин сайланды. Аксакаллар Шурасы рәисе итеп техник фәннәр докторы **Әхмәт Галиев** сайланды.

## МОРЗА НӘСЕЛЛӘРЕ ТУРЫНДА

Татарстан Республикасының Милли архивы тарафыннан әзерләнгән—«Казан морзалары. 1785-1917 еллар» дип аталган генеологик сүзлек дөнья күрде.

Басманың максаты—Казан губернасының морзалар нәселе китабын фәнни әйләнешкә кертү. Анарда 1558 нәселнең шәҗәрәсе тупланган. Шулай ук сүзлектә дәүләт хезмәтендә тиешле еллар эшләгәне өчен морзалар нәселе китабына кертелгән тугыз татар морзасы нәселе дә урын алган. Алар—Алкиннар, Алиев, Вәгыйзов, Ярмөхәммәтов, Сәинов, Моратов, Хәлфин, Юнысов һәм Әлморзин.

## КОРЪӘН КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Иранда IX Халыкара Коръән күргәзмәсе үз эшен тәгәлләде.

Анда шәмаилләр, 20 дән артык илнең, шул исәптән Россиянең каллиграфия үрнәкләре тәкъдим ителгән иде. Күргәзмә эшендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре, каллиграф-галим Нәҗип Нәкъкаш та катнашты.

Россия павильонында Изге Коръәннең татар, рус һәм казакъ телләренә тәрҗемәләре урын алган иде. Төрек тәрҗемәсе нигезендә язучы Рабит Батулла тарафыннан эшләнгән Коръәннең татарчасы да куелган иде.

## ЯШЬЛЕК БИЕКЛЕКЛӘР ЯУЛЫЙ

Яшь шагыйрә **Альбина Әпсәләмова** (Габдрахман Әпсәләмов оныгы) Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде һәм берлекнең иң яшь әгъзасы булды.

Финанс-икътисад институтында белем алучы Альбинаның «Осколки снов» (1998) һәм «Я люблю писать курсивом» (2001) дигән шигырь җыентыклары дөнья күрде инде. Ул шигърият һәм авторлык җырлары шәһәр конкурсында 2 тапкыр бүләк алды һәм, ниһаять, 2001 ел ахырында әдәбиятта һәм сәнгатьтә югары казанышлары өчен ел саен бирелә торган Бөтенроссия «Триумф» премиясе лауреаты булды.

## КИТАПХАНӘ МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле язучыларыбыз!

Республикабыз Казанның 1000 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнә. Борынгы шәһәребез үзгәрә, яшәрә, башкалабыз тарихы белән кызыксынучы яшьләребез көннәнкөн арта.

Китап фонды әлегә тулы булмау сәбәпле, Республика яшүсмерләр китапханәсенең милли мәдәният һәм туган якны өйрәнү бүлеге бүгенге көндә яшьләрнең ихтыяҗларына тулы җавап бирә алмый. Шуны истә тотып, шәхси китапханәгездәге Казан һәм аңа бәйле вакыйгаларны чагылдырган китапларыгыз белән бүлешсәгез иде. Сезнең китапларыгыз, аеруча элекке елларда нәшер ителгәннәре, безгә бәя биреп бетергесез ярдәм итәр, ә яшьләребезгә туган ягыбыз турында белемнәрен арттырырга мөмкинлек бирер.

Без татар һәм рус телләрендә әдәби әсәрләр белән беррәттән, элекке елларда чыккан журналлар, Татарстан икътисады, фән һәм сәнгате тарихы, мәдәнияте, сәнгате һәм спорт тормышына багышланган китаплар кабул итәбез.

*Безнең адрес: 420044, Казан шәһәре, Ибраһимов проспекты, 53 «б». Татарстан Республикасы яшүсмерләр китапханәсе. Тел: 43-79-57*

## КАЗАН ТӘХЕТЕ

Борынгы Кол-Шәриф мәчете, Сөембикә китапханәсе, Казан тажы хакындагы риваятьләр белән беррәттән, Казанның күрке булган, ләкин тарихи зилзиләләр аркасында юкка чыккан «алтын тәхет» турындагы серле хәбәрләр дә яшәп килә. Заманында гөрләп чәчәк аткан дәүләтнең рәсми атрибуты, хакимият күрсәткече һәм сарай церемонияләренең үзәген тәшкил иткән бу зарури символның реаль тарихта булуы шөбһәсез. Ләкин, кызганычка каршы, рус елъязмаларында һәм башка тарихи чыганакларда, шул исәптән, Мәскәү музейларының тасвирламаларында төрле Казан ханнарының милке исәпләнгән затлы хәрби кием, корал, шлем, көбә, исемле коръән савытлары, ювелир сәнгате әйберләре арасында «Казан тәхете» дип телгә алынган ядкарь юк... Шуңа да карамастан, Казан өсләрендә берничә гасыр буе чайкалган «алтын миражның» асылын ачыклау—тарихи җаваплы эш.

«Казан тәхете»н эзләү юллары безне Русия дәүләт хакимияте раритетлары куелган Мәскәү Кремлендәге Корал пулатына (Оружейная палатага) алып килде. Мондагы рус хөкемдарлары кигән зиннәтле киемнәр, теге я бу чорга караган дәүләтчелек җиһазлары, алтын-алмаз такыялар, асылташлар белән бизәлгән калкан-чукмарлар, кыйммәтле баш киемнәре, таҗ, тәхетләр, кием-салым, савыт-саба... Бу әйберләрнең кайберләре биредә, Корал пулаты остаханәләрендә эшләнгән, икенчеләре төрле рус сәнгать мәркәзләрендә башкарылган, өченчеләре рус хөкемдарларына Шәрык һәм Мәгърип илбашлары тарафыннан дипломатик бүләк сыйфатында ирештерелгән. Кайберләре, әлбәттә, сугыш трофейлары.

Шушы бөек держава символлары арасында игътибарны Романовлар династиясенең беренче патшасы (тәхеткә 1613 елда утыра) Михаил Федорович Романовның «алтын тәхете» җәлеп итә. Музейның искәрмәләрендә аның турында «XVII йөзнең башында Иван Грозныйның азиат стилендәге иске тәхетеннән үзгәртеп эшләнелде», диелгән. Иван Грозный көнбатыш илчеләренә үзенең трофей таҗларын күрсәтеп, бу таҗларның һәркайсы артында бу ханлыкларның казналары һәм мал-мөлкәте торуын әйтергә ярата торган була. Тәхетне «Азия стиле» белән бәйләү дә аңлашыла: XX гасырга кадәр, күзгә ташланып торган аермалыклар аркасында, татар мәдәнияте руслар өчен томанлы көнчыгыш цивилизациясе кисәге булып кала бирә.

Нинди булган соң ул әкияти алтын тәхет? Аны күзаллау өчен, Урта гасыр шәрык миниатюраларына күз төшерү дә җитә: дүрт кырлы, киң, аякны бөкләп утыру өчен җайланылган, җыйнак, өсләренә тоташ асылташлар, мәрвәритләр, энҗе-мәрҗән сибелгән утыргычлар алар. Җирдә күктәге Ходай Тәгалә исеменнән идарә иткән хөкемдарларның тәхете, һичшиксез, Коръәндә әйтелгән Аллаһының илаһи «көрси»ен (тәхетен) хәтерләтеп, алтын-көмеш, яшел-кызыл асылташларга күмелеп, тормыштагы кайгы-шатлыкларның алмашынып килүен, гомернең кыскалыгын, галәмнең мәңгелеген, һәм бу дөньяны тотып торучы бөек көчнең киң кодрәтен гәүдәләндерергә тиеш... Алтын Урда җирләренә юлыккан гарәп һәм итальян сәяхәтчеләре (Гийом Рубрук, Плано Карпини) урда ханнарының тирмәләрендә күзгә ташланырлык гүзәл, берле (так) һәм парлы-киң (хатын-кыз заты, хәләл җефетләре белән бергә утыра торган) алтын, фил сөягеннән эшләнгән тәхетләр хакында мәгълүматлар калдырган. Тарихта беренче буларак кыйммәтле металларны ачкан һәм эреткән, заманында Төньяк Кытай чикләрендә яшәгән һәм Ефәк Юлын тоткан күчмә һәм утрак төркиләрнең алтын сәнгать әйберләргә, төсле гүзәл ташларга ихласы гаҗәп түгел. Алтын Урданың дәвамчысы Казан ханнарының тәхетләре дә шуларга охшаган. Тышлыкта күрсәтелгән тәхетнең дә дүртпочмаклы ике яссылыктан торган фасадында, өстә, фирәзә, лал-рубин, энҗе-гәүһәрләр тулып ята... Риваятьләр буенча, тәхетләрнең

елга башы—кучмәләр сандыгы. Төрки ыруг юлбашчылары бу сандыкларга чабышлардан килгән бөтен табышны тутырып, шуның өстенә менеп, саклап утыра торган булганнар, имеш. «Иске тәхет» тә безнең чорларга кадәр килеп җиткән татар сандыкларын һәм, гомумән, татар ювелир сәнгате принципларын хәтерләтә.

Үзгәртүләр нидән гыйбарәт булган соң? Безнеңчә, аның киң тоташ түгәрәк арткы стенасын бүлгәләп, аның исәбенә аякларын озынайтканнар (аларга алтын җитмәгәнгә, алар шәрә калган); артына «спинка куеп», соңрак империя симво-лын—ике башлы бөркет сынын утырткканнар. Шулай итеп, Византиядән килгән православие диненә яраклаштырганнар, рус тарихчылары язганча, «епископ эскәмиясе» ясаганнар... Корал палатасы хезмәткәрләренең язмалары буенча, эскәмиягә 13 кг алтын, 1494 данә рубин һәм аның «очкыннары», төрле зурлыктагы 7300 фирәзә; ике топаз, 4 аметист, 16 кабырчыктан чыккан энҗе, 2 зур кафа (Кырым) энҗесе. «Каян килүе турында бернинди дә хәбәр юк... Бәлкем, чит җирләрдән килгәндер»,—ди 1807 елгы Музей тасвирламасы. Ләкин шунсы кызык, тарихи язмалар күрсәткәнчә, бу тәхет Ялган Дмитрий белән Мария Мнишекның никахлашу шаһиты була; аны берзаман Петр I нең әтисе «тыйнак» Алексей Михайлович да файдалана, хәзер тәхет Мәскәү музеенда экспозициядә тора.

Инде тәхетнең иясе хакында. Казан тәхетенең хуҗасы, безнеңчә, Казанда 1487-1495 һәм 1502-1518 елларда хөкемдар булган шөһрәтле хан, мәдәни мохит тудыручы, шул ук «Таҗ» иясе—Мөхәммәт Әмин. Бу хан—үзе шагыйрь, дипломат, Урта Азия, Мәскәү, Кырым һ. б. дәүләтләр белән аралаша, илчелекләр кабул итә (Бабур язмалары буенча) Казанны яңа мәчетләр, төрбәләр белән бизәп, аның өстенә яңа нур, яңа балкыш өсти: тирәсенә сәнгать, җыр, музыка осталары, алтын-көмешчеләрне җыйный. Казан музеенда сакланган шәраб кувшинына уелган язмадан күренгәнчә, аның үзенең савыт-саба ясаучылары, һәм, гомумән, нәккашьләре, һөнәрчеләре булган... Ә «Казан тарихы» («Казанская история») М. Әмин хакында «патша үзенә кыйммәтле таҗлар, савытлар ясатты... һәм купшы патша киеме юнәтте...»,—дип яза. Биредә, киемнең гадәти кием-салым булмыйча, хан хакимияте белән бәйле рәсми атрибутлар тезмәсе булуы ап-ачык. Шул исәптән, «Оружейная палата»ның 1835 елгы тасвирламасында («Историческое описание...») Мөхәммәт Әмин патшаның (һәм шулай ук Касыйм ханы Ураз Мөхәммәтнең, Себер патшасы Күчүмнең, Шаһгалинең хәрби кием фрагментлары) яшмадан эшләнгән, алтын белән капланган, 160 кызыл якут һәм 26 зөбәрҗәт белән бизәлгән булуы турында язылган... Әлегә бу хан җиһазы ансамбленең бер өлеше булган чукмар-булаваның һәм, гомумән, Казан ханлыгына караган шлем, көбә, калкан, байрак, туплар һәм теркәмәләрдә әйтеп үтелгән «Татарское вооружение»нең табылганы юк...

**Розалина ШАҺИЕВА**

---

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь Сафуан Мулла Гали.

# ЯҢА КИТАПЛАР



«Милли китап» нәшриятында Татарстанның М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, шагыйрь, прозаик, драматург, публицист һәм тәрҗемәче **Разил ВӘЛИЕВ**нең дүрт томлык «Сайланма әсәрләре» басылып чыкты.

**I томның** төп өлешен шагыйрьнең төрле илләрдә иҗат иткән шигъри әсәрләре һәм җырлары тәшкил итә. Төрле халыкларның шагыйрьләре иҗатыннан алынган тәрҗемәләр аерым бер бүлек итеп бирелгән. Китапта, шулай ук, Разил Вәлиев турында атаклы кешеләр әйткән фикерләр һәм язучы Марсель Галиевнең кереш мәкаләсе урнаштырылган.

«Сайланма әсәрләр»нең **II томында** Разил Вәлиев прозаик буларак тәкъдим ителә. Бу китапка авторның «Эт кояшы» (1968), «Иске сәгать дөрес йөри» (1981), «Яшисе килә» (1978-79) повестьлары һәм «Мирас» (1983) романы кергән.

**III томда** авторның сәхнә әсәрләре, мәзәкләре һәм тәрҗемәләре урын алган. Пьеса һәм либреттолардан—«Әйдә барыйк, кызлар карыйк», «И машина, машина, житте минем башыма», «Куркыныч уен» («Шомбай»), «Җир уллары»; тәрҗемәләрдән—«Нәни принц» (А. Сент-Экзюпери), «Маугли» (Р. Киплинг), «Баскервильләр эте» (К. Дойль) повестьлары. Бу китапта, шулай ук, авторның мәзәкләре дә бирелгән.

**IV томда** Разил Вәлиевнең публицистик язмалары, очерклары, мәкаләләре, әңгәмәләре тупланган. Эчтәлектә алар ике бүлек итеп бирелгән: әдәбият һәм иҗтимагый-сәяси тормыш, мәдәният, мәгърифәт. Җәмәгать эшлеклесе һәм халык депутаты буларак ясаган чыгышлары китапта аерым урын алып тора. Аларда—халык тарихы, бөек шәхесләре, дәүләтчелек язмышы турында әдипнең уйланулары, борчылулары... Китапта Разил Вәлиевнең тормыш һәм иҗат сәхифәләрен чагылдырган күп санлы фотоиллюстрацияләр дә бар.

*Китаплар 1999-2000 елларда «Идел-пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылган.*

*Басманың мөхәррирләре—**Н. Гамбәр**, **И. Һадиев**, бизәлеш рәссамы—**Ш. Насыйров.** I том—552 бит, II—496 бит, III—464 бит, IV—672 бит. Тиражлары—3000 данә.*

Индекс 73210



Сафуан Мулла Гали

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)